
ISSN 0206—418

# Казан утлары

11.1984






Габдерәхим Утыз Имәни

*1754—1834*

*Тавил Хаҗиәхмәтов рәсеме*

# КАЗАН УТЛАРЫ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

11

1984


## Бу санда


«БАТЫРЛЫК ДӘВАМ ИТӘ» КОНКУРСЫНА

А. ШАМОВ. **Якташым.** Хикәя . . . . . . . . 3

Ф. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. **Ишет, дөнья!** Шигырьләр . 16
А. ГЫЙЛӘҖЕВ. **Ефәк баулы былбыл кош...** Драма 20

ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Т. ЗУЕВА. **Казанда Тукай урыннары** . . . . . . 40

М. ГАЛИЕВ. **Нигез** . . . . . . . . . . . . . 41

АЗЫК-ТӨЛЕК ПРОГРАММАСЫ — БӨТЕНХАЛЫК ЭШЕ

М. МӘҺДИЕВ. **Агыйделнең бу ягында** . . . . . 101

УТЫЗ ИМӘНИНЕҢ ТУУЫНА 230 ЕЛ

Ә. ШӘРИПОВ. **Гыйлем — нурдыр** . . . . . . . 109

НУР ГАЙСИНГА 70 ЯШЬ

Н. ГАЙСИН. **Атым.** Шигырьләр . . . . . . . . 117

МАРСЕЛЬ СӘЛИМҖАНОВКА 50 ЯШЬ

И. ИЛЯЛОВА. **Үз хакыйкатеңне ачу** . . . . . . . 120

**Татарстан язучыларының X съезды** . . . . . . 125

Г. АХУНОВ. **Партия белән, халык белән** . . . . 126
С. МИХАЛКОВ. **Яңа биеклекләргә** . . . . . . . 140
Т. МИҢНУЛЛИН. **Югары идеяне — зур осталык белән...** 143
М. МӘҺДИЕВ. **Прозабыз ни хәлдә!** . . . . . . 149



КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

И. ЮЗЕЕВ. **Күкрәгеңдә шигырь уты саумы!** . . 154
Т. ГАЛИУЛЛИН. **Тәнкыйть һәм әдәби процесс** . . 162
Ш. ГАЛИЕВ. **Киләчәккә очар канатлар** . . . . . 168
М. ЗАРИПОВ. **Алгы сызыкта булыйк** . . . . . 175
К. МИҢЛЕБАЕВ. **Ана телендәгечә укылсын!** . . 180
Н. ОРЕШИНА. **Максатлар уртак** . . . . . . . 184
**Татарстан язучыларының X съезды резолюциясе** . 189

**Тышлыктагы сурәтләр** . . . . . . . . . . . 192

*Баш редактор*
**РЕНАТ ХАРИС**

*Редколлегия:*
**МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ**
**ӘХӘТ ГАФФАР**
**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ**
**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ**
**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ**
**МӘДИНӘ МАЛИКОВА**
**САЛИХ МАННАПОВ**
*(җаваплы секретарь)*
**ТУФАН МИҢНУЛЛИН**
**ФЛҮН МУСИН**
**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ**
*(баш редактор урынбасары)*
**РӘФЫЙК НӘФИКОВ**
**НУРИХАН ФӘТТАХ**
**СИБГАТ ХӘКИМ**
**РИЗВАН ХӘМИД**
**НИЛ ЮЗИЕВ**
**АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН**

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

На конкурс «Подвиг продолжается»: рассказ **А. Шамова «Земляк»**.
Стихи **Ф. Гиззатуллиной**.
Драма **А. Гилязова «Соловушка на шелковом шнурочке»**.
«К 100-летию Г. Тукая»: рис. **Т. Зуевой из цикла «Тукаевские места в Казани»**.
«К 230-летию Утыз Имани»: статья **А. Шарипова**.
Стихи **Н. Гайсина** (к 70-летию поэта).
М. Салимджанову 50 лет: статья **И. Иляловой**.
Материалы X съезда писателей Татарии: статьи **Г. Ахунова, С. Михалкова, Т. Миннуллина, М. Магдеева, И. Юзеева, Т. Галиуллина, Ш. Галеева, М. Зарипова, К. Миннибаева, Н. Орешиной**. «На наших обложках» — творчество художника **В. Кудельмина**.

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: баш редактор — 53-07-60, баш редактор урынбасары, җаваплы секретарь — 53-07-09, проза, поэзия, очерклар бүлекләре — 53-07-61, тәнкыйть, сәнгать, хатлар бүлекләре — 53-07-63.

Техник редактор *Р. Сөләйманова*. Корректорлар *Ф. Кадыйрова, Т. Сибгатуллина.*

Производствога бирелде 30.8.1984 ел. Басарга кул куелды 5.11.1984 ел. ПФ 05110. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы $70 \times 108^1/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 64049. Заказ К-338. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1984 ел.

БАТЫРЛЫК ДӘВАМ ИТӘ

**Афзал Шамов**

# ЯКТАШЫМ

хикәя



штән кайтып, киемемне алыштырырга да өлгермәдем, телефон шалтырады. Кем булуы мөмкин моның? Трубканы алсам, якташым Хәлил абый хатыны Тәзкирә апа икән. Тавышы моңсу, күңелсез. Исәнлек-саулык сорашканнан соң ул миңа:

— Кара әле, Ибраһим, Хәлил абыең авырып китте бит әле, — диде.— Иртәгә вакыт табып, безгә килеп чыга алмассыңмы икән? Сине бик күрәсе килә аның.

Мин бер мизгелгә җавап бирә алмый тордым, чөнки моннан берничә көн элек кенә Хәлил абыйны урамда очраткан идем, кәефе яхшы иде, сәламәтлегеннән бер дә зарланмады. Ә бүген — авырый. Бу хәбәр белән ничектер күңелем килешми. Шулай да үз-үземне җиңеп:

— Һәй, Тәзкирә апа, шулаймыни әле, бик кызганыч, бик кызганыч!— дип, аны юатырга тырыштым. — Борчылмагыз, терелер алла бирсә. Ни белән авырый? Кайчаннан бирле?

— Дүртенче көн инде, — диде телефондагы тавыш.

— Врач чакырдыгызмы соң?

— Чакырдык. Чакырмыйча буламыни!

— Ни әйтә соң врач?

— Ни дисең, йөрәк, ди, нервылар, ди. Ятып торырга кушты, беркая да чыкма, диде. Дарулар язды... Даруларын эчә болай...

— Тәзкирә апа, иртәгә кичкә кырын барсам, ничек булыр?

Телефон чыбыгының аргы башыннан: «Ярый, алай да ярый... Хушыгыз!»— дигән сүзләр ишетелде, аннары кыска сигналлар гүләргә кереште. Мин дә трубканы куйдым.

Хәлил абый Габбасов миңа караганда олы, өлкән могтәбәр кеше. Бөек Октябрь революциясенә чаклы туып, гасырның азагына таба бара. Моннан бер-ике ел элек алтмыш бишне тутырды. Озакламыйча җитмеш булачак. Үзенең сүзенә караганда, гомеренең түгәрәк даталарын беркайчан да бәйрәм итеп үткәрмәгән икән. Моңа сәбәпләре булгандыр, күрәсең. Ә менә бусын, исән булса, киләчәк җитмеш еллыгын, үзенчә зур итеп, матур итеп үткәрергә исәбе бар. Еллар тыныч булса, фронтташ дусларымны, кордашларымны җыям, бәйрәм итәм, дип тора, узганнарны искә төшереп, рәхәтләнеп сөйләшеп утырырга тели.

Кайда соң аның дуслары, кордашлары, фронтташ иптәшләре? Исәннәрме алар, исән булсалар, аның юбилеена килә алырлармы?

Дуслары да, кордашлары да күп булган аның. Тик аларның күбесе, төрлесе төрле җирдә, канлы көрәшләрдә ятып калганнар: Халхин-Голда, фин кампаниясендә, соңыннан, бераз өлкәнәя төшкәч, балалар атисе булгач, Бөек Ватан сугышы фронтларында, Мәскәү оборонасында, Сталинград бәрелешләрендә, Курск дугасы ялкыннарында, ниһаять, Берлинны штурмлаганда. Дәһшәтле, сынаулы көннәр аз кичмәгән алар башыннан! Соңыннан, туплар гөрселдәве басылгач, дөнья тынгач, яңа эшләр, яңа бурычлар: хуҗалыкны аякка бастыру, авыл хуҗалыгын күтәрү, яңа шәһәрләр, яңа заводлар салу...

Комсомол, партия сафларында тәрбияләнеп, чыныгып үскән токым кешеләре алар. Коммунистлар партиясе ни кушса, шуны эшләгәннәр, кая барырга кушса, шунда барганнар, гомерләрен халыкка хезмәткә багышлаганнар, Ватаныбызның азатлыгы, бәйсезлеге, шанлылыгы өчен, халык бәхете өчен көрәшкәннәр алар.. Билгеле, табигый үлем дә алып киткән аларның кайберләрен. Нишлисең, кешенең елгаларны кирегә борырга, тауларны бер урыннан икенче урынга күчерергә көче, осталыгы, кодрәте җитсә дә, табигать канунын үзгәртерлек, газраил балтасына каршы торырлык әмәле юк. Табигать кануны котылгысыз, мәрхәмәтсез...

Дуслары, кордашлары күпме калган соң аның? Һай, замана, замана, аз гына калган икән ләбаса. Хәлил абый аларны кул бармаклары белән генә саный. Еллары бик авыр, дәһшәтле, давыллы, ялкынлы булды шул. Күпләрне, менә дигән егетләрне, балалар атасы, ил агасы буласы кешеләрне бик вакытсыз алып китте. Илне, азатлыкны, бәхетне, шатлыкны саклап калу өчен корбан булдылар алар. Шунсыз мөмкин булмады. Гасырлар онытмаслык эш башкардылар алар.

Авыру янына буш кул белән баруны килештермим, ничектер уңайсыз, халкыбызның матур гадәтен бозу шикелле булып тоела. Шуңа күрә иртәгесен иртүк торып, бакчама киттем. Виктория әле кызарып, пешеп кенә килә. Балаларым шуларның иң пешкәннәрен, иң кызылларын күп итеп җыеп бирделәр, суыткычта лимоннары да бар икән, аның да икесен алып тыктылар. Карчыгым, бер литрлы пыяла банкага тутырып, варенье да тоттырды: «Тәзкирә апага миннән күчтәнәч булыр»... — диде. Әй, карчыгым, карчыгым, онытмыйсың ла син әшнәләреңне!

Мин барып кергәндә Хәлил абый залда, диванда утырып тора иде. Өстендә кыска җиңле ак күлмәк, спортчылар кия торган трико. Чәчен, гадәтенчә, пөхтә итеп тараган, сакал-мыегын кырган. Янында бүгенге газеталар, яңа журналлар сибелеп ята. Ишектән килеп керүемне күргәч, һәрвакыттагы кебек елмаеп, урыныннан торды да миңа таба берике адым атлады.

— Әйдә, әйдә, Ибраһим, түрдән уз, рәхим ит! — диде, кулларын җәеп җибәреп.— Килеп яхшы иттең. Бик күрәсем килгән иде. Сөйләшәсе, киңәшәсе сүзләрем дә бар иде.

Мин аның ятып тормавына, аяк өстендә булуына бик гаҗәпләндем. Моны ул да сизде булса кирәк, шундук шатлыгын уртаклашты:

— Шөкерләр булсын, бүген иртәдән бирле хәлем яхшы. Тик менә күңелем генә... Үземә урын таба алмыйм. Хәер, анысы турында соңыннан, табын янында.

Тәзкирә апаның да куанычы йөзенә чыккан иде.

— Шөкер, шөкер! — диде ул да. — Югыйсә, бик куркытты. Бөтенләй төсе качкан иде. Ашау-эчүдән калды... Ике төн күзенә йокы кермәде...

Кул биреп күрешкән арада якташымның йөзенә игътибар белән карап алдым. Бераз ябыккан, чырае, гадәттәгегә караганда, агара,

нурсызлана төшкән. Күзләре моңсу. Күз төпләре капчыкланып, күкселләнеп тора, — йокысыз төннәр, әрнүләр, борчылулар нәтиҗәсе булса кирәк.

Аның янына диванга утырдым.

— Өч-дүрт көн теге якта аунап яттым, — диде ул, башы белән йокы бүлмәсенә таба ымлап.—Тәмам туйдырды. Ятмас идең, врачлар куша. Нишлисең, мәҗбүр. Ярамый. Бүген монда чыктым: җитәр, дидем. Монда рәхәт, һавасы да, кояшы да...

Аннары ул, бераз тынып, тәрәзәгә карап торганнан соң ниндидер бер моңсу тавыш белән өстәде:

— Агачлары да... Күңелгә юаныч биреп торалар...

Чыннан да, тәрәзә каршында яшь каеннар шаулап үсеп утыра. Ул утырткан, ул карап үстергән каеннар алар.

Аның бик матур бер гадәте бар: ул кайда гына тормасын, кайда гына яшәмәсен, — авылдамы, шәһәрдәме, барыбер, — тәрәзә каршына, тәрәзә каршына булмаса, башка берәр буш урынга агачлар утырта, аларны карап, тәрбияләп үстерә. Аеруча каен утыртырга ярата ул. Кайларда гына утыртмаган икән ул каеннарны. Чөнки аңа үз гомерендә, партиянең кушуы буенча, бер урыннан икенче урынга күчеп йөрергә, эш урынын алыштырырга шактый туры килгән. Ул хезмәт иткән һәр җирдә аның хатирәсе булып каеннар калган. Хәзер ул җирләрдә аны эше белән генә түгел, шаулап үсеп торган каеннары белән дә искә алалар. «Хәлил абый каеннары», — диләр.

Агач утырту, аны карап үстерү турында аның фәлсәфи карашы да юк түгел. Гәрчә бу караш асылда аныкы булмаса да, ул аны сүзе белән дә, эше белән дә чын күңелдән яклый. «Һәр кеше үз гомерендә ким дигәндә бер агач утыртып, аны карап, тәрбияләп үстерергә тиеш,— ди ул. — Моның белән ул әйләнә-тирәне, табигатьне безнең кешеләрнең тормышларын ямьләндерә, аларга шатлык алып килә, шуның белән бергә дөньяда үзенең эзен калдыра», — ди ул. Кем белә, бәлки әле ул бу фикерне кайчандыр, кемнеңдер әйткәнен һәм аның бөтен дөньяга канатлы сүз булып таралуын башына да китерми торгандыр. Ләкин хикмәт андамыни. Хикмәт гамәлдә: аны тормышка ашыруда, агач утыртуда, аларны тәрбияләп үстерүдә, ә моны ул бик яратып, бирелеп эшли.

Кайчак мин аның үзен дә, шаяртып, карт имән дип атыйм. Үпкәләми, елмая гына. Моны мин аны гәүдәсенә, буй-сынына карап әйтәм. Яшьлегендә ул әллә ни матурлардан булмаса да, төз буйлы, атлетик гәүдәле егет булгандыр дип уйлыйм. Хәзер дә әле ул, җитмешкә якынлашып баруына карамастан, игътибарны җәлеп итәрлек озын буйлы, төз гәүдәле карт — артык таза да, ябык та түгел. Чәче, булмыш бөдрәләрне хәтерләтеп, ап-ак булып күпереп тора. Күз карашы акыллы, мәгънәле. Йөзендә кешеләрнең күңелен җәлеп итәрлек ниндидер бер мөлаемлык бар. Ул аның рухын, җанын, дөньяга карашын чагылдырадыр дип уйлыйм.

Ике арадагы сүзне башлап җибәрү теләге белән мин:

— Кай җирегез сызлый, Хәлил абый, ни булды? — дип сорадым.— Әле моннан берничә көн элек кенә бик матур йөри идегез бит.

Ул миңа елмая төшеп карап торды да:

— Булды инде, булды, Ибраһим, — дип кулын селтәде. — Була икән шундый авырулар... Йөрәгем бик сызлады, кан басымым да күтәрелеп китте, ике йөз егермегә җитте. Врачларга рәхмәт, карадылар, дәваладылар. Бүген, әйтмәгәнем булсын, йөрәгем тынычланды. Кан басымым да рәтләнеп килә. Тик минә күңелем тыныч түгел. Әрни, сыкрый...

Карчыгы, Тәзкирә апа, безгә табын әзерләп йөри иде. Хәлил абыйның җавабын ишеткәч, сүзгә кушылмыйча булдыра алмады.

— Сызлар, нигә сызламасын! — диде ул, ачынып. — Әрнер, нигә әрнемәсен!.. Йөри шунда кирәкмәгәнгә тыгылып. Яшь дип белә ахыры үзен. Утызда гына дип уйлый... Җитмешкә якынлашып барганын оныта. Әйт әле син аңа, Ибраһим, аңлатып бир әле үзенә. Бераз акыл керергә вакыт инде аңа. Юк бит, юк...

Бу аның ирен орышуы, шелтәләве түгел, ә бары миңа зарлануы, шуның белән аны төрле бәла-казалардан саклап калырга теләве генә. Озын буйлы, бераз агара башлаган чәчле, иренә караганда берничә елга яшьрәк булган бу хатынның гадәтен белә идем мин. Иренең эшенә тыгылмаса да, ул аның тормыш юлындагы төрле күңелсезлекләрдән, булганнарыннан, булмаганнарыннан да саклап калырга, аңа җилянгыр тидермәскә тырыша иде. Әгәр көченнән килсә, ул аны, чебиләр анасы кебек, канаты астына алып, барлык көтелмәгән күңелсез хәлләрдән теше-тырнагы белән саклап калыр иде. Һәр вакыт түгел, ә берәр күңелсез вакыйга булганда гына зарлана иде. Ачуланмыйча, тавышын күтәрмичә зарлана белә иде. Мөгаен, берәр күңелсезлек булгандыр, шуңа зарлана торгандыр дип уйладым, ләкин сүзләрен бүлеп сорашырга базмадым.

Хәлил абый карчыгына көлемсерәп карап торды да:

— Тукта әле, карчыгым, бераз тынып тор әле, — диде. — Ибраһим белән икәү генә сөйләшик әле. Бу турыда синең белән күп гәпләштек инде.

Тәзкирә апа, үзсүзләнеп, карышып тормады, өстәл өстендәге эшен тәмамлап, кухняга таба юнәлде. Шулай да ишек янына җиткәч, әйтәсе сүзен әйтеп бетерергә кирәк тапты.

— Һай, җүләрем, җүләрем, — диде ул, иренә таба борылып карап. Аның кайчандыр зәп-зәңгәр булган, хәзер инде бераз уңа төшкән күзләре, шаянланып, яшьләрчә ялтырап китте. — Җанкисәгем, синең белән сөйләштең ни дә, сөйләшмәдең ни, синең һаман үз бер тиенең — бер тиен. Син әле һаман, электәге кебек, дөньяны төзәтмәкче буласың. Белмим, син генә төзәтеп бетерерсеңме икән аны...

Тәзкирә апа кухняга чыгып киткәч кенә мин якташымнан кызыксынып сорадым:

— Нигә зарлана ул? Әллә чыннан да берәр күңелсез вакыйга булдымы?

Хәлил ага, көлемсерәп, кулын селтәде.

— Булды инде шунда. Булды... Авыруым да шул күңелсез вакыйга аркасында булды.

— Ни булды соң шул хәтле?

— Сөйләрмен әле.

Бу карт-карчыкның бер-берләренә булган җылы мөнәсәбәте мине һәрвакыт сокландыра иде. Алар бер-берләрен яраталар, ихтирам итәләр, бер-берләренең тынычлыгы, сәламәтлеге өчен җаннарын бирергә әзер торалар. Ике арадагы мәхәббәтләре, яшьлектәге кебек, гөрләп, ташып тормаса да, карт күңелләрне җылытырлык, рәхәтләндерерлек, шатландырырлык иде әле. Квартиралары да, өй җиһазлары да ошый иде миңа. Аларда бер кечкенә гаилә өчен кирәк булган әйберләрдән артык берни юк. Барысы да үз урынында, барысы да кирәкле, барысы да җанга ятышлы, күңел тынычлыгын тудырырлык.

Тәзкирә апа, табынын әзерләп бетереп, безне өстәл янына чакырды. Икебез дә, кулларыбызны юып, барып утырдык. Табын чәй өчен шактый мул иде. Мин алып килгән күчтәнәчләрне дә куйганнар. Карт белән карчык аны, капкалап караганнан соң, бер авыздан мактап алдылар: бик эре икән, матур булып пешкән икән, тәмле икән, диделәр. Чәй дә ясалды, алдыма да куелды. Ә мин, чәемә орынмыйча, Хәлил абыйның әлеге, мине кызыксындырган вакыйганы сөйли башлавын көтәм.

Ул бераздан, алдындагы чәйне эчеп, икенчесен ясаткач кына сүзен башлады.

— Башта дөньяны төзәтү турында бер-ике сүз әйтик әле, — диде ул, Тәзкирә апага карап. — Син, җанкисәгем, үпкәләмә, дөньяны төзәтергә кирәк, бик нык төзәтергә кирәк аны. Әгәр аны без төзәтмәсәк, кем төзәтер? Безнең бурыч ул. Коммунистлар бурычы. Дөресен әйткәндә, безнең бурыч кына түгел, ә барлык аңлы кешеләр бурычы, карчыгым. Менә шул.

Тәзкирә апа әле моннан берничә минут элек кенә иренең шундый сүзләренә каршы килгән булса да, хәзер бер сүз дә әйтмәде, тыныч кына тыңлап утыруын дәвам итте. Аның бу матур сыйфатын белә идем мин: табынның ямен җибәрмәс өчен өстәл янында, бигрәк тә кунак алдында, беркайчан да иренә каршы килми иде ул.

Якташым сөйләвен дәвам итте.

— Менә шул дөньяны төзәтүдән башланып китте дә бу каһәр төшкән авыруым, — диде ул, миңа карап. — Врачлар әйткәләп торалар: үзеңне тыныч тотарга тырыш, борчылырлык, дулкынланырлык эшләрдән ерак тор, диләр. Гел алар дигәнчә генә барып чыкмый икән шул. Дөнья бит ул. Дөньяда төрле хәлләр була... Аннары кеше бит мин, җаным бар, каным бар. Вөҗданым бар... Корыган агач түгел ләбаса...

— Шулай, Хәлил абый, шулай, — дидем мин, аның сүзен җөпләп. Тәзкирә апа да, аның фикере белән килешкәндәй, ияк кагып куйды шикелле.

Якташым, сулу алырга теләгәндәй, бераз тынып торды, аннары, алдындагы чәен бер-ике капкач, яңадан сөйләргә кереште:

— Узган сишәмбе көнне булды бу хәл. Бераз йөреп керим, һавада булыйм әле дип, урамга чыккан идем. Исәбем паркка бару, аннан Казанка буйларына төшү иде. Күптән булганым юк иде ул якта. Көне дә матур, кояшлы иде. Паркка түгел, урамыбызның аргы башына да барып җитмәдем, бәлагә тап булдым. Син безнең урамдагы ипи магазинын беләсеңме? Белсәң, шуннан узып киткәч, уң якта ике катлы бер агач йорт бар. Капкасы-фәләне юк, ишек шар ачык. Шунда авылданмы, әллә якын тирәдәге берәр җирдәнме, каяндыр бер олаучы килеп туктаган. Атын туарып, арбага бәйләгән дә, үзе каядыр киткән. Аты алдында ваклап, сындыргалап ташланган бер өем күмәч. Аты ак күмәч ашый. Бөтен арба тирәсе күмәч валчыклары белән тулган, чыпчыклар, күгәрченнәр җыелган. Менә нәрсә бит, якташ. Моны күргәч, аптырап киттем, баруымнан туктадым... Кем ашата моны? Кайсы җирбите? Ничек оялмый? Ипинең нинди кадерле икәнен белми әллә? Капка яныннан кешеләр узып-узып китәләр, күрәләр, ник берсе бер сүз әйтсен! Ишегалдындагы йорттан да кешеләр чыккалый. Алар да туктап тормыйлар, арбага, атка гамьсез генә карап алалар да үз юллары белән китеп баралар. Түзмәдем, шундыйларның берсен туктаттым да: «Кем аты бу?» — дип сорадым. «Ә-ә, бумы? — ди. — Бәрәңге сатучы аты бу, — ди. — Атна саен килә ул монда. Я бәрәңге алып килә, я кишер, кәбестә, шуның кебек әйберләр. Кайчак ит тә алып килә», — ди. «Кайда сата аларны?» — дип сорыйм аңардан. «Кайда булсын, монда, ишегалдында», — ди. Сатар, алырлар, алмыйча калмаслар, халыкка барысы да кирәк. «Тик нигә ул атына ак күмәч ашата?» Егетем, моны ишеткәч, шаркылдап көлеп җибәрде: «Ә, шуны әйтәсезмени, абзый кеше, ак күмәч ашатканны? — ди. — Магазинда кара ипи булмагандыр», — ди. Моны ишетеп, катып калдым, сулуым тыгылды. Ни әйтергә белмәдем... Менә бит ничек ул, туганкай! Ә үзе күрер күзгә белемле, тәрбияле кеше сыман, кием-салымы яхшы, тел тидерерлек түгел. Өстендә костюм, башында эшләпә. Студент яки берәр хезмәткәр булгандыр дип уйлыйм. Атның күмәч ашаганын күргәч, кашын да җыермады, олаучыны гаепләп, орышып, бер сүз әйтмә-

де, бары шаркылдап көлде генә. Я алла, булыр да икән дөньяда туң йөрәкләр! Исең китәр. Әйт син миңа, Ибраһим туганкай, каян килә шундый кешеләр? Кем тудыра аларны, кем үстерә?— диде Хәлил абый, бик ачынып, дулкынланып. Аннары миңа карап, миннән җавап көткәндәй кабатлады: — Әйт, Ибраһим, нинди анадан туа икән алар?

Моны ишетеп, Тәзкирә апа кеткелдәп көлеп җибәрде:

— Бигрәк инде син, картым, ааналарны гаепли башладың.

— Курыкма, сине гаепләмәм, — диде аңа каршы Хәлил абый. — Балаларыңны син андый итеп тәрбияләмәден... Мең нәрчә шөкер, аларны без гамьсез, җансыз итеп үстермәдек. Алар законга сыймаган эш янынннан беркайчан да тыныч күңел белән узып китмәсләр. Юк, узып китмәсләр! — дип кабатлады.

Мин дә фикеремне әйтергә кирәк таптым.

— Барысы да тәрбиядән, Хәлил абый, тәрбиядән. Ата-ана тәрбиясеннән, мәктәп тәрбиясеннән, җәмәгатьчелек тәрбиясеннән. Барысының да.

— Дөрес әйтәсең, барысы да тәрбиядән, — диде ул, минем сүз белән килешеп.— Син миңа шуны әйт: нигә шундый егетләрне әти-әниләре шул чаклы гамьсез, игътибарсыз, битараф җан итеп үстерәләр? Нигә ипинең бик кадерле, кыйммәтле, мокатдәс азык икәнен, аны эшләп, тир түгеп табалар икәнен ана сөте белән кертмиләр аларга?! Менә мәсьәлә нәрсәдә. Әлеге егетнең шаркылдап көлүе, ат янынннан бернәрсә булмагандай узып китүе җанымны өшетте, Ибраһим. Карт кешегә шул җитә калды. Ул китеп тә өлгермәде, ипи магазины ягыннан ат хуҗасы килеп чыкты. Карт түгел, кырык-кырык бишләр тирәсендә. Шуннан артык булмас. Базык гәүдәле, табак битле. Битенә чиртсәң, кан чыгарлык. Эчкән дә булса кирәк, борыны кызарып, күкселләнеп тора. Ике кулында ике сумка. Икесендә дә күмәч. Күреп бетермәгәнмен, арбасында ипиле капчык тора икән. Сумкаларын шунда бушатты. Тагын ипи алырга керер идеме, юкмы, анысын белмәдем, түземлегем җитмәде, бөтен ачуым — әлеге егеткә булган ачуым да, ат хуҗасына булган ачуым да — барысы берьюлы ташып чыкты. Мин аңа: «Карагыз әле, гражданин, нишләвегез бу сезнең? Ничек оялмыйсыз!» — дип кычкырып салдым. Кычкырмаска, тавышланмаска иде миңа, ә милициягә хәбәр итәргә иде. Шуның белән эш бетәр иде. Магазинда да күпләп сатуны тыярлар, моның да капчыктагы ипиен алып калырлар иде. Йөрәгем түзмәде, ычкынып киттем. «Татар акылы төштән соң» дигән мәкальне ишеткәнең бардыр. Минем дә шулай булды...

Мин, аның сүзенә кушылып:

— Нишлисең бит, андый чакта, акылга караганда хис алданрак йөри, — дип өстәп куйдым.

— Әй-йе, ачу алданрак йөри, ачу, — дип үзгәртте ул минем фикерне. Моны раслагандай, бармаклары белән өстәлне шакылдатып алды.— Ачу!.. Картайдым, күрәсең, үземне тота алмый башладым. Нервыларым бик какшаган. Әлек болай түгел идем.

Бу вакыйганың ни белән тәмамлануын беләсем килә иде.

— Бәхәс ни белән бетте соң?

— Берни белән бетмәде. Бөтен бәла менә шунда. Минем ачуланып кычкыруыма каршы, ат хуҗасы миңа эт кебек ырылдап җавап кайтарды: «Күрмисеңмени, атымны ашатам ич!— диде.— Әллә ашатмаскамы аны? Ә син үзең тыгына торгансыңдыр бит! Әнә танавың нинди!» Моны көтмәгән идем. Кычкырып, акырып, берни эшли алмаячагымны шундук төшендем. Тавышымны мөмкин чаклы тынычрак чыгарырга тырышып: ««Нигә күмәч ашатасың?— дидем.— Ярамый икәнен белмисеңмени?..» Сүземне әйтеп бетерергә дә өлгермәдем, табак бит минем башта бик каты сүкте, аннары, авызын зур итеп ачып, акырып салды: «Кара ипи булмагач, ни ашатыйм?! Бар, магазинга кереп шаула, кара

ипи сатсыннар, нигә миңа бәйләнәсең!»— диде. Әйтерсең, җирбитнең, атына, дуңгызларына, шәһәр магазиныннан сатып алып кара ипи ашатырга ярый да, кумәч ашатырга гына ярамый. Менә бит аның логикасы нинди! Бар, сөйләш син аның белән. Ишегалдында, ат янында миннән башка, ичмаса, беркем юк. Шуңа җикеренде ул. Кешеләр булса, ул чаклы җикеренмәс иде. Янәсе, бу бетәшкән карттан нигә куркып торырга. Ә тротуардан кешеләр өзлексез узып тора. Нигә берсе туктасын да, нигә берсе ярдәмгә килсен... Табак бит белән сөйләшә башлагач ук, дөресе, кычкырыша башлагач ук, йөрәгем сызларга керешкән иде, ә инде аның, мине хурлап, әшәке сүзләр белән сүгенүен ишеткәч, күкрәгем таш кебек катты, сүз әйтә алмаслык, урынымнан кузгала алмаслык хәлгә җиттем. Кесәмнән валидол алып капмыйча булдыра алмадым. Моны күргәч, әлеге кеше, олаучы, тәмам котырды, мине эттән алып эткә салды: мин холера да, эт үләксәсе дә, күптән кабердә череп ятасы бәндә дә икәнмен. Әти-әниләрне дә калдырмады... Моңача мине берәүнең дә болай сүккәне юк иде... Бу минутта син аның авызын күрсәң иде, якташ,— диде ул, миңа карап,— валлаһи, җәһәннәм дә ул чаклы булмас.

Хәлил абый бу күңелсез вакыйганы тыныч кына сөйли алмый, кирәгеннән артык дулкынлана иде. Кай мизгелләрдә ул аерым сүзләрне кычкырып-кычкырып әйтеп куя, кулларын бер секунд тыныч тотмый, сүз җаена, аның мәгънәсенә, әйтелешенә карап хәрәкәтләндерә, селки. Битенә дә ниндидер кызгылт тимгелләр бәреп чыкты, күзләре уттай яна башлады. Бу хәлне сизгән Тәзкирә апа аны берничә мәртәбә сүзеннән туктатырга талпынып караса да, файдасы булмады. Ахырда мин, аны бераз тынычландырырга теләп, сүз катарга мәҗбүр булдым:

— Карагыз әле, Хәлил абый, күңелегезгә ул хәтле авыр алмагыз аны,— дидем.— Узган эш бит, онытыгыз, тынычланыгыз. Сезгә борчылырга ярамый. Аннары бик очраклы хәл бит бу. Бөтен кеше андый түгел бит. Әллә нигә берсе генә.

Сүземне Тәзкирә апа да яклады:

— Төкерсәнә шуңа, сиңа әйтәм! Нигә ул хәтле исең китте аңа! Чәең суына, эч. Табындагы әйберләрне дә бераз капкала ичмаса. Күрәсең, кунак ашамыйча утыра. Син ашагач, ул да ашар...


Якташым, сөйләвеннән туктап, икебезгә дә гаҗәпләнеп карады.

— Юк,— диде ул, башын чайкап,— юк, төкермим, төкерә алмыйм мин аңа. Икмәк ул! Икмәккә мөнәсәбәт! Халык байлыгына мөнәсәбәт! Менә монда утыра ул,— диде, кулы белән йөрәгенә төртеп күрсәтеп,— монда! Хурлавына да ачуым килә, билгеле, анысын яшермим. Әмма җаен авызның гына түгел, теге егетнең дә икмәккә булган мөнәсәбәтен оныта алмыйм. Әгәр без барыбыз да шундый эшләргә төкереп карасак, аны тиз генә онытсак, ярар идеме соң? Ә?..

Яңадан кызып, дулкынланып сөйли башламасын дип, аны тагын сүзеннән бүлдерергә кирәк таптым:

— Бәхәс шуның белән беттеме?

— Юк, бетмәде. Бәхеткә каршы, каяндыр өч хатын килеп чыкты. Яныбызга килеп туктаулары булды, шундук тегене әлеп алдылар. Атына кумәч ашатканы өчен дә, җирдә сибелеп яткан кумәч кисәкләре өчен дә, мине, карт кешене сүгүе, хурлавы өчен дә, кыскасы, барысы өчен дә орышырга керештеләр. Әтәчләрмени. Табак битнең өстенә генә менеп кунмыйлар. Миңа гына гайрәтләнгән икән хулиган җан. Хатыннар алдында кикриге бик тиз шиңде, җебегән тавык сыман булды да калды. Чөнки хатыннар аңа: «Милиция!» дип кычкыралар, «Судка бирергә кирәк!» диләр. «Аты-ние белән хәзер үк илтеп бирик!» диләр. Һай, хатыннар, хатыннар!— дип көлеп җибәрде Хәлил абый.— Мондый хәлләрдә алардан да яхшы ярдәмче юк! Чынлап әйтәм. Рәхмәт аларга! Югыйсә, табак бит мине аяктан егачак иде. Хәлем шул чиккә җиткән



*Т. Хажиәхмәтов рәсеме.*

иде, Ибраһим туганкаем. Шуны да әйтим әле, хатыннарның сүзеннән мин менә нәрсәне аңладым: ул кеше шәһәр тирәсендәге бер совхозның каравылчысы икән. Атына дип бирелгән солыны колхоз базарына алып барып, кыйбат бәягә сата икән, атына магазин ипие ашата икән. Менә хикмәт нәрсәдә! Җирбитне син аны! Шунда да казнаны талый. Каян чыга шундый кешеләр?— дип, ул бик гаҗәпләнеп, башын чайкап торды. Аннары сүзен тыныч кына тәмамлады:

— Йөрәгемне каптырып алды бит каһәр суккан авыруым. Валидолның да файдасы булмады. Тик нитроглицерин капкач кына җиңеләйгән сыман булды. Тавышның басылганын көтмәдем, әкрен генә кайтып киттем. Үз-үземне орышып кайтам: җүләр, дим, ахмак, дим, бәйләнеп тормаска, милициягә хәбәр итәргә кирәк иде, дим.

Аның бу сүзләрен ишеткәч, карчыгы:

— Мин дә сиңа шуны әйтәм ич,— дип, сүз кыстырып куйды.— Нигә кирәкмәгәнгә тыгылып йөрергә. Яшь кешемени! Яшь кеше булсаң иде...

Карты аның иңенә кулы белән орынды гына, бер сүз әйтмәде. Бу аның: «Тукта әле, карчыгым, сүземне бүлдермә әле»,— дип әйтүе иде. Тәзкирә апа шундук тынды.

Хәлил абый сүзен дәвам иттерде:

— Чүп өстенә чүмәлә, дигән сүзне ишеткәнең бармы синең?— диде ул миңа.— Ишеткән булсаң, ярый. Күңелсезлек өстенә күңелсезлек дигән сүз ул. Шул көнне тагын бер җан әрнеткеч нәрсәгә туры килдем. Табак бит белән бәхәсләшкәннән соң сыкрый-сыкрый кайтып килам, чак атлыйм. Бераз хәл алыйм дип, урам бакчасына кереп утырдым. Асфальт мәйданда малайлар футбол уйныйлар. Зурлар түгел, бәләкәй малайлар. Ни күзем белән күрим, каткан булканы туп итеп типкәләп йөртәләр! Үзләре шаулашалар, көлешәләр, булканы мәйданның бер башыннан икенче башына куалар. Күрсәң иде, Ибраһим, бөтен булка. Күңел хакы өчен тешләп тә, кабып та карамаганнар. Түзмәдем, уйнаучылар янына бардым. Моннан соң берәү белән дә бәхәсләшмим дип, тәүбә итүемә карамастан бардым. Нишлим, җаным түзмәде.

Тәзкирә апа бу вакыйганың ничек башланып, ничек тәмамлануын инәсеннән җебенә хәтле белсә дә, пырхылдап көлеп җибәрде:

— Әй, картым, картым!— диде ул, аның аркасыннан сөеп.— Шундый әкәмәтләр гел сиңа туры килеп тора! Берәрсенә эзләп тә, туры килмәс.

Хәлил абый, аның шаяртуына игътибар итмичә, сөйләвен дәвам итте:

— Шунда... уйнаучы бер малайдан сорыйм. Зур түгел, кечкенә малай. Тугыз-ун яшендә генә булыр. Кычкырмыйм, җикеренмим, аллам сакласын! «Нигә булка белән уйныйсыз?» дим. «Тубыбызны алып чыкмаган идек», ди. «Каян алдыгыз соң аны?» дим. «Чүплектән», ди кулы белән каршыдагы йортларның берсенә таба күрсәтә. «Улым, син яхшы малай шикелле күренәсең, әйт әле: ипине шулай типкәләп уйнарга ярыймы соң?»— дип сорыйм тегеннән. Малай җавап бирми, башын иеп, тик басып тора. Борынын тарткалап ала. Кем малае икәнен дә, кайсы йортта торучы икәнен дә әйтергә теләми. Ахырда мин аңа: «Кара әле, улым, тыңла әле, менә нәрсә,— дим.— Ипине алай мыскыл итеп, типкәләп уйнарга ярамый,— дим.— Ипи бик кадерле, бик кыйммәтле әйбер. Аның һәр бөртеген эшләп табалар. Тир агызып эшлиләр. Беләсеңме, дөньяда аннан да кадерле нәрсә юк. Бер кеше дә иписез яши алмый», дим. Малай бер сүз дә әйтмәде, сүземне тыңлап торды да, мин рөхсәт иткәч, иптәшләре янына йөгерде. Малайлар шундук уйнаулардын туктадылар, нидер сөйләштеләр, миңа таба да караштыргалап алдылар, аннары төрлесе төрле якка йөгерделәр. Менә бөтен авыруым шуннан башланды, Ибраһим туганкай,— диде Хәлил ага, сүзен тәмамлап.— Бөтенесе шуннан башланды.

Чәебез суынган иде инде. Чәйнек тә суынган булса кирәк. Тәзкирә апа аны, кайнарлатып керим дип, кухняга алып чыгып китте.

Без, сөйләшүдән туктап, бер мәлгә тынып калдык. Тышта инде зәңгәрсуланып караңгы төшеп килә, залга утлар алынган. Якташым, сул кулы белән иягенә таянып, уйланып утыра. Уенның җаена булса кирәк, алдында, өстәл өстендә сибелеп яткан күмәч валчыкларын бармаклары белән бер урынга әкрен генә җыеп китерә дә аннары аларны саклаunion кына таратып җибәрә. Валчыклар сибеләләр. Ул аларны яңадан бергә җыя, яңадан тарата, ә үзе нидер уйлый, кашлары җыерылган, күзләре өстәлгә текәлгән. Мин исә әле генә сөйләнгән вакыйга тәэсиреннән арына алмыйм. «Каян килә бу чир» Чыганагы кайда аның? Нинди мохитта, нинди социаль җирлектә? Байлык, муллык сәбәпме аңа, әллә мин белми торган, уема килми торган башка сәбәпләр бармы?» Мин шулай уйланып утырам. Каяндыр, югарыданмы, әллә күрше квартираларның берсеннәнме, өзек-өзек кенә булып елап, сыкрап, скрипка моңы ишетелгәләп китә,— бер ишетелә, бер тына. Нинди көй, нинди моң? Төшенә алмыйм...

Хәлил абый да бу моңга игътибар итте булса кирәк, алдындагы валчыкларны җыеп, бер читкә этеп куйды да, башын күтәрә төшеп, бераз тыңлап торды. Аннары, урыныннан торып, ябык тәрәзәләрнең берсен барып ачты. Скрипка тавышы шундук залга тоташ моң булып, җыр булып сызылып керә башлады. Борынгы көйләрнең берсе икән. Ләкин нинди көй,— һич тә хәтеремә китерә алмыйм. Әмма моңлы көй, милли көй, хәсрәтле көй.

— Кем уйный моны?

— Мәстүрә Җаббарова. Безнең йортта тора ул.

Бу атаклы артистка концертларын мин һәрьюлы яратып, бирелеп тыңлый идем. Ул үзенең таланты, осталыгы, уенының нечкәлеге, сихри моңы, нәфислеге белән тыңлаучыларның күңел кылларын тибрәтә белә иде. Бу юлы да ул күңелемне бик тиз биләп алды, скрипка моңнары белән бергә мине табигать кочагына, чәчәкле болыннарга, яшел урманнарга, тылсымлы елга буйларына алып китте. Гүя арып-талып, кызарып кояш батып бара. Аның соңгы нурлары белән бизәлгән, алсуланган дулкыннар, бер-берләреннән калышырга теләмичә, каядыр ашыгалар, йөгерәләр; яр буендагы буш көймәләр, моңсуланып, хәсрәтләнеп, бер-берләренә бәреләбәрелә, чайкала-чайкала, аларны озатып калалар; яр өстендәге таллар да җил беләнме, әллә болай гынамы, сагышларына түзә алмыйча, сыгылалар, талпыналар. Кайдадыр, калфак чугын чәйнәп, кайгысыннан нечкәбил елый, кемнедер чакыра, өметләнә, ашкына... Ачык тәрәзәдән кечкә җил белән бергә борынгы тылсымлы көй агылып, сызылып керүен дәвам итә...

Көй кинәт өзелде, тынды, уйнаучы скрипкасын куйды булса кирәк, без дә фани дөньяга кайттык.

— Гаҗәп бит ул халык моңы, Ибраһим туганкай,— диде якташым, сүзен башлап,— гаҗәп! Ул миңа шундый тәэсир итә: яхшы музыка тыңлаганнан яисә берәр концертта булганнан соң мин яшәреп, тынычланып, сафланып китәм, күңелем яхшы уйлар белән тула, кешеләргә, җәмгыятькә кирәкле, файдалы кеше буласым килә. Җаным ашкына, каядыр омтыла. Яхшы музыка һәркемгә шулай тәэсир итәме икән әллә ул?

— Белмим. Әйтә алмыйм.

— Шулай да кайчак ул күңелемдәге әрнүле уйларны баса алмый. Начарлыкларны, бозыклыкларны күргәч, җаным әрни минем. Бик әрни, Ибраһим. Шөкер, җәмгыятебез таза, сәламәт. Халкыбыз тырыш, батыр, гадел, тугры халык. Ленин байрагы астына тупланган халык. Бөек идеаллар белән яши торган халык. Мин моңа шатланып бетерә алмыйм. Шул халыкның бер вәкиле булуым белән горурланам. Ләкин,

кызганычка каршы, шундый бөек халык арасында җанны әрнеткеч аерым шәхесләр, тискәре җаннар бар: спекулянтлар, кеше исәбенә яшәргә теләүчеләр, эрәмтамаклар, казна талаучылар, эш яратмаучылар, исерекбашлар, башка шуның кебек җан көекләре. Менә шуңа бик әрним мин, Ибраһим туганкаем. Каян, кайсы сазлыктан өстерәлеп килеп чыгалар алар? Нигә аларга безнең коммунистик тәрбиябез, яхшы сүзебез тәэсир итми? Нигә бозык алар? Нигә җәмгыятькә бернәрсә бирмичә, аннан иң зур, иң тәмле калҗаларны гына каерып алырга маташалар? Хикмәт нәрсәдә? Әллә алар туганда ук шундый рухи гарип булып туганнармы, әллә инде тәрбияләү ысулында берәр кимчелек бармы? Булса, нинди кимчелек? Нәрсә җитми?

— Белмим, Хәлил абый,— дидем мин.— Белмим. Бу мәсьәлә минне дә бик борчый.

Бераздан көтмәгәндә ул миннән:

— Урак урганың бармы синең?— дип сорады.

Нигә сорый икән дип гаҗәпләнеп башымны чайкадым:

— Юк, урырга туры килмәде. Без үскәндә колхоз иде инде. Машина белән уралар иде.

— Ә минем урганым бар,— дип, ул миңа сул кулын сузды.— Чәнчә бармагымны күрәмсең? Андагы яра эзләрен? Ә?.. Урак урганда киселгән эз алар. Җиде яшемдә урак ура башладым мин. Бер таңнан икенче таңгача уракта була идек. Беренче елларны әллә ни урдым дип мактана алмыйм. Шулай да әти белән әни үзләреннән калдырмыйлар иде. Эшкә күнегә торсын дип йөртүләре булган инде аларның.

Хәлил абый ике кулы белән чәчен сыйпап алды. Бу аның күнегелгән гадәте. Сүз арасында ул шулай, фикерен тупларга кирәк булганда, ике кулы белән чәчен сыйпап ала. Бу юлы да шулай итте.

— Безнең әти-әниләр бик дөрес эшләгәннәр,— дип дәвам иттерде ул сүзен.— Безне хезмәткә, ипинең кадерен белергә бик яшьли өйрәттеләр. Моның өчен рәхмәт аларга! Бик зур рәхмәт! Бүген дә бу хисне, ипигә булган яхшы мөнәсәбәтне, аның кадерен белүне балаларга ана сөте белән кертәсе иде. Ипигә булган мөнәсәбәтне генә түгел, бөтен социалистик милеккә булган яхшы мөнәсәбәтне дә ана сөте белән кертәсе иде,—дип кабатлады ул.—Ничек кертергә моны? Нинди юл белән? Тәрбия белән, билгеле. Хезмәт белән. Ләкин ничек? Күрәсең, балаларыбызга бирелә торган тәрбиядә ниндидер бер кимчелек бар. Нинди кимчелек? Әйтә алмыйм, чөнки белмим. Кара әле, якташ, хәзер матбугатта, телдә «исраф», «гөнаһ» дигән сүзләр бармы? Дини мәгънәсендәге сүзләр турында әйтмим. Аларны алмаштырырлык сүзләр турында әйтәм. Бармы шундый сүзләр?

— Юк.

— Юк шул менә!— дип, ул тавышын күтәрә төшеп әйтеп куйды.— Юк! Ә булсын иде. Бик кирәк андый сүзләр. Диннәр, хорафатлар белән бертөрле дә бәйләнеше булмасын аларның. Аңлыйсыңмы? Бертөрле дә! Әмма көче, мәгънәсе белән алар аннан көчлерәк, тәэсирлерәк булсыннар. Безнең социалистик аңыбыз белән, коммунистик идеалларыбыз белән бәйләнешле булсыннар иде алар. Төшенәсеңме? Коммунистик идеалыбыз белән! Менә шундый сүзләр кирәк. Гаепле эш эшләүче теләсә кемгә шундый сүзне әйтсәң, йөрәге сискәнеп, дерелдәп китәрлек, вөҗданы уянырлык булсын. Кызганычка каршы, юк бит андый сүзләр. Юк.

Хәлил абый сөйләргә ярата. Кайчак ул рухланып, янып, хәтта канатланып сөйли. Бераз авырып торганнан соң аның янына хәл белешергә килгән иптәшләре белән ул өстәл янында, чәй эчә-эчә, сөйләшеп утырырга ярата. Күрәсең, авырып ятканда ул үзенең тормыш юлын тагын бер тапкыр башыннан кичерә, андагы яхшы эшләре өчен шатлана,

ә ялгышлыклары, хаталары өчен чын күңеленнән көенә, уфтана булса кирәк. Шуның белән бергә ул киләчәк турында да хыяллана торгандыр дип уйлыйм. Авырып терелгәннән соң хәлен белешергә барган саен ул миңа үзенең нинди дә булса берәр яңа фикере, хыялы турында сөйли. Фикерләре, хыяллары бик реалистик була аның, бер вакытта да тормыштан аерылып, һавада гизеп, буталып йөрмиләр.

Хәзер ул пенсиядә, лаеклы ялда. Шулай да ул үзен эшләүчеләр сафында итеп саный, җәмгыятьтән аерылмый, күңелендә туган тәкъдимнәре белән партиянең район комитетына, я шәһәр комитетына бара, алар белән киңәшә, әгәр алар аның тәкъдимнәрен кирәкле дип тапсалар, яшьләрчә канатланып, рухланып кайта. Район комитеты аны әледән-әле җәмәгать эшенә чакыра, берәр заводка, предприятиегә пропагандист итеп билгели. Райком биргән йөкләмәләрне ул яратып, чын күңелдән бирелеп үти, үзен стройда дип саный, шуннан җан азыгы таба. Менә шундый карт ул.

Бүген мин ул ипине әрәм-шәрәм итү турында бик ачынып, янып-көеп сөйләгәндә дә, аннары, яшь буынны тәрбияләү мәсьәләсенә күчеп, шул турыда фикер йөрткәндә дә: «Шөкер, сәламәтлеге яхшыра икән»,— дип куанып утырдым.

Тәзкирә апа, чәйнекне алып кереп, икебезгә дә кайнар чәй ясап куйды, табындагы тәмле азыкларны ашарга тәкъдим итте.

Хәлил абый, чәен кашыгы белән бераз болгаткалап торганнан соң, кабат сөйли башлады:

— Мин үзем егерме беренче елгы ачлык газабын татыган кеше. Бик зур ачлык булды ул. Халык чебен урынына кырылды. Бер үләт тә, ваба да ул чаклы кырмагандыр халыкны. Бер кабарлык алабута ипие, яфрак, каеры ипие иң кадерле азык булды. Менә нинди булды ул егерме беренче елгы ачлык, Ибраһим туганкаем. Берәүгә дә, хәтта дошманыма да күрергә язмасын аны! Дошманыма да! Әле бүгенгедәй хәтердә, күз алдында...

Аның әкренәйгәннән әкренәя барган моңсу, әрнүле тавышы кинәт өзелеп киткән сыман булды, ул сүзен әйтеп бетермичә, башын ике кулы белән тотып, тынып калды.

Тәзкирә апа аның янында утыра иде. Бу хәлне күргәч, кулы белән аңа орынып, аны юатырга теләгәндәй:

— Ташласана, картым, сөйләмә шуларны, исеңә төшермә,— диде. Аның тиз генә тынычланмаячагын төшенеп булса кирәк, миңа Хәлил абый биографиясендәге кайбер фаҗигале хәлләрне сөйләп бирде. Үзе сөйли, ә үзе, моның өчен үпкәләмәсме икән дип, әледән-әле иренә карапштыргалап ала.

— Һәр юлы шулай ул... Ачлык елы турында сөйли башласа күңеле тула, сөйли алмый. Беләсеңме икән син, юкмы: егерме беренче елны ачлыктан әнисе белән ике сеңлесе үлгән. Менә шуңа күрә ул көннәрне искә төшерү бик авыр аңа. Әгәр шул вакыт Совет власте ярдәм итмәгән, ятим балаларны җыеп алмаган булса, Хәлилем дә ачтан үлгән булыр иде...

Хәлил абый белән күптән таныш булсам да, моны ишеткәнем юк иде әле. Менә нинди дәһшәтле, фаҗигале хәлләрне башыннан кичергән икән ул.

Якташым, кесәсеннән кульъяулыгын чыгарып, миңа күрсәтмәскә тырышып, күзләрен сөртеп алды да:

— Син, Ибраһим туганкай, көлмә, гаеп итмә мине,— диде.— Нервларым бик какшаган. Картлык... картлык...

Тавышы һаман моңсу иде әле.

— Нинди көлү ул!— дидем мин чын күңелдән.— Ни сөйлисең син, Хәлил абый!

...Мин, саубуллашып, урамга чыкканда инде тәмам караңгы төшкән, машиналар хәрәкәте басылган, тротуарлардан узып китеп йөрүчеләр дә сирәкләнгән иде. Мин, өемә кайтып китәргә ашыкмыйча, капка төбендә бераз уйланып басып тордым да, ниндидер бер көчкә буйсынып, якташым утырткан каеннарга таба юнәлдем. Тагын бер күрәсем килә иде аларны.

Йортны урап, Хәлил абый тәрәзәләре караган якка барып чыктым. Каеннар караңгыда, тәрәзәләрдән төшкән яктылыкта ап-ак шәмнәрдәй булып тезелешеп, басып торалар. Үскәннәр, матурланганар.

Кайчандыр бу урын бушлык иде,— кирпеч ватыклары, төзелеш калдыклары, төрле чүп-чарлар өелеп ята иде. Ә хәзер монда, зифа буйлы кызлардай, каеннар үсә. Яшь каеннар! Егерме беренче гасырга барачак каеннар! Аларны утыртучы, карап, тәрбияләп, су сибеп үстерүче якташым, кордашым Хәлил абый киләчәк гасырга барып җитә алырмы икән? Ай-һай, барып җитә алмас, картайган, еш авырый, ә каеннары барып җитәрләр. Кем белә, бәлки алар Хәлил абыйның, гади тыйнак кешенең, тынгысыз җанның исемен дә үзләре белән киләчәк буыннарга алып китәрләр. Кашки, шулай булса иде!

## Флера Гыйззэтуллина

### Ишет, дөнья!

— Бергә Идел кичик әле,
Әйдәгез! дип, Ил яшьләре!—
Әллә Идел тавышы белән
Яшь Ульянов эндәшәме?—
Әйтерсең лә бу кайтаваз
Яңрап узды хәзер генә!—
Ал гөлләрдән өзелеп төшкән
Яшьлек илгә кадерле лә!
...Яшьләр өчен бар да яңа!
Батырлык та, яр да яңа!

...Бөек Ленин исеме белән
Горурлана Идел-ана.
Горурлана Идел-ана:
Ил! Партия! Эш! Тынычлык!..
Баскан саен чыныга җир,
Ныгый буын, ныгый дуслык.
Калка кала уртасыннан
Түр бакчалар, мәрмәр сыннар.
Килә Даһи олы юлның
Без табынган кыйбласыннан.

Килә Даһи яшьлегеннән
Армый-талмый бүгенгәчә...
Ишет, дөнья! Ильич булып
Бүген сиңа Ил эндәшә.
Ил эндәшә:
— Җир йөзен, дип,
Аралагыз атом-төштән!..
Гомер бит ул бәгырьләрдән,
Ал гөлләрдән өзелеп төшкән!
...Шул ук йөрәк!.. Шул ук бәгырь!..
Бездә шул ук бер көч әле!
Ишет, дөнья! Шул сүзләргә
Беркетелгән җир күчәре.
Безнең бөек партиябез
Нигез салган шул эш өчен:
«Без бернинди коралны да
Тотмас идек сугыш өчен!»

Без яңарыр, үсәр идек,
Куәт алып Идел-судан!
Яшь Ильичның яшь тавышы:
— Әйдәгез!— дип, күкри шуннан.

### Әй, халкым

Минем дә халыктан
Күчереп аласы,
Көйләргә саласы җырым бар.
Яңа җыр җырларга,
Тыңларга теләсәк,
Күп бездә очрашыр урыннар.

Килдек без бирегә
Башаклы кырлардан,
Урманнан, тургайлы тугайдан.
Бу — безнең Тукайлы
Шигърият мәйданы,
Россия мәйданы — бу мәйдан!

Гәүдәне төз тоту,
Мәйданга йөз тоту
Килешә кешегә һәрвакыт...
Тукайның Кырлаен,
Такташның Тамбовын
Туярмы шагыйрьләр яратып?

...Мәйданнар ачканда,
Алмашка басканда
Хисебез, эшебез — бер бөтен!..

Әй, халкым, бар синең
Тарихи сәнгатең,—
Өзелмәс иң нәфис өметең!

## Ә шулай да...

Килде безгә космик очыш чоры
(Арткан чоры алтын хакының!)...
Чорга кагылып үткән үзгәрешнең
Үз иңемдә барын татыдым.
Сатулыкта үз күзләрем белән
Алтыннарның күрдем төрлесен.
...Күктә кошлар очыш дәвамында
Аваз салып барлый бер-берсен.
Шул аваздан чыгып алтын чыңы
Сафлыгына сеңә һаваның.
«Алтын кошлар безгә канатташ!»— дип,
Шатланадыр шуңа заманым.
Ә шагыйрьләр шигырь язалардыр,
Мактап алтын куллы халыкны...
Җырга ашкан бар зурлыгы белән
Туган халкым үзен танытты.
Һәм калыкты дөнья күләменә,
Тынычлыгын даулап дөньяның.
Шул калкулык белән бер төбәктә
Алтын көзләр көткән күз явым!
Үз-үзенә әгәр тугры калса
Бу замана, бу чор, бу вакыт —
Сатулашып һичбер алтын алмам!
Кош та алмам, хәтта, ук атып.
Ә шулай да алтын хәреф тезеп,
Канатына килер язымның:
«Мин — гади кыз! Мин — СССР кызы,
Татар кызы!»— диеп язармын.

*

Көтәмен кич тә, иртә дә:
Тиеш ич кайтып җитәргә!—
Юлда ич газиз балам!
Юлларда Ватан уллары!..
Талмасын аяк-куллары:
Азмасын йөрәк ярам.
Йөрәктә — узган сугышның
Ярасы сызлый гомергә,
«Сау булсын илем, балам!»— дип,
Бәгырьләр тураклана...
Җир йөрәге нишли икән?—
Яшәү иминлеге өчен
Ничәмә ватан табына
Көч-куәт сорап аңа!?

## Бу бәйрәмнәр әле...

*Сажидә Сөләйманова истәлегенә*

Мин бит синең җырларыңа күчкән
Ерактагы дустың, якының:
— Кайтып җиттем, ач, Сажидә!— диеп,
Ишегеңне кабат шакыдым.

Кабат йөгереп урамнарга чыктым:
Багышланып синең исемгә,
Киләчәккә киң юлларын сузып,
Урам үскән Әлмәт эчендә.

Кайтуымнан монда ни файда соң,—
Урамнарың урап йөрмәсәм!?
Гомеремдә, синнән үрнәк алып,
Мин дә язам, яшим, көрәшәм.
Дан-җирлегең белән яд иткәндә
Көрәшләрнең зурын, алгысын,
Җиде катлы күкнең иң югары
Тарафыннан яңгырый тавышың.
Ача кебек якты күк капусын
Илдә син калдырган хак җырлар.
Йөрәгеңнән сикереп, җир куенына
Чумдың чөнки ничә тапкырлар!
Иҗатта син үзең үскән саен,
Үсүләргә безне чакырдың.
Мин кайларга китеп юлыксам да,
Чакыруыңны ишетеп кайтырмын.
...Чакырулы булгач, Әлмәт өчен
«Ят кунак!»— дип, мине кем әйтер?
...Бу бәйрәмнәр әле хәтерләрне,
Тавышларны безнең көчәйтер.
Күчергәндә данлы калаларга
Шагыйрьләрнең абруй, исемен...
Әй, Саҗидә! Син котланган түрдән
Котлар илне Сергей Есенин!
...Котлашырсыз! Шигъри тантанада
Алкышлаулар белән зал гөрләр:
Сез — бер көнне туган шагыйрьләр ич,—
Бердәй туракланган бәгырьләр!
Ә мин — синең җырлар белән үскән,
Якындагы якташ дустың ич!

Шуңа, ахры, миңа көрәшмичә,
Юл йөрмичә яшәү — куркыныч...

## Үз-үзеңнән китеп буламыни?

Күкеле сәгать секундларны саный.
Секунд бит ул — диңгездән тамчы су,
Кояш яктысыннан бер чаткы.
Чаткылардан җыйган тойгы-уйлар
Нигә урау икән бу чаклы?

...Вакыт миннән зур уяулык сорый!—
Стеналар зыңлый, таңнар зыңлый:
«Мәртәбәгә заман юл ача...
Кояш сүнмәс, яшәү сүнмәс дигән,
Киләчәккә юл өзелмәс!»— дигән
Ышанычым — гигант куласа!

Куласасын тормыш әйләндерә,
Әйләнә дә күке чыгып баса —
Бар бит чөнки өзелеп көтүче!
Минем өзгәләнгән үзәгемнең
Җанга ялганасы ишедер ул
Сәгать-күке... вакыт күкесе.

Күкеле сәгать гасырларны җыйган!..
Ыруыбыз белән җыйналсак та,
Бу җыйнак кош бездән өрекмәс!
...Үз-үзеңнән китеп буламыни,—
Тормыш сине санга суккан җиргә
Кәккүкләрең белән береккәч,
Кояшларың белән береккәч...

## Балачак истәлеге

Мин бала чакта нигәдер
Көн озын сыман иде:
Казлар ишле, бәби елак,
Әбиләр чыдам иде.
Әбкәем каз куа иде
Инеш чирәмлегенә!—
Хәтерләмим зарланганын
Көннең сүрәнлегенә.

...Ел шулай әйбәт килгәнме
Әбиләр гомеренә?
Кирәк булганмы аларга
Гомергә йөгерергә?—
Җеп эрләп, йомгак урарга,
Көйләргә станнарын;
Үзеннән «эшкә оста»ның
Тыңларга — кушканнарын?..

...Хәтерлим бишле кылычны
Күзлексез саплаганын;
Таңгача киндер сукканын,
Ә кичен ятмаганын.

...Каз... Кылыч... Киндер станы —
Әбкәйдән калган маллар!
Үлгәнче эшләгән әбкәм,—
Кем бирсен аңа яллар!?

Ә бәлки кул-аягы
Чыдамлык яратканга —
Очкандыр газиз әбкәем
Үлемсез канатларда?

Безгә дә көтү кирәктер
Кошлы, канатлы гомер!—
Юкса, балачак төшләргә
Боегып, елап керер.

*

...Йомшаклыкның тойдым туфрактагын,
Чисталыкның күрдем судагын...
Су сафлыгын, туфрак игелеген
Уңар игенемә юрадым.

Тойгыларым җанга тугры икән,
Юрауларым, шөкер, юш икән!—
Мин үземне шуңа җир-суларның
Чын хуҗасы кебек хис итәм.

# Аяз Гыйләҗев

# ЕФӘК БАУЛЫ БЫЛБЫЛ КОШ...

ДРАМА 2 КИСӘКТӘ

*Ефәк баулы былбыл кош*
*бардыр синең илеңдә!*
*Каеш баулы лачын кош*
*бардыр минем илемдә!*

Кыз йортына килгән яучы җырыннан.

**Катнашучылар:**

| | |
|---|---|
| Мияссәр | Шифан |
| Рәшидә | Әдһәм |
| Әсма | Хурия |
| Рәсим | |

**Вакыйга XX гасырның 80 нче елларында бара.**

**Беренче кисәк**

**Күл буе. Агачлык. Бер якта интернат почмагы да шәйләнә. Мияссәр кармак салып утыра. Мавыккан, янынннан узып баручы Рәсимне күрми. Рәсим дә, ашыкканга күрә, картны күрми. Шунда ук өр-яңа бәби арбасы. Рәсим артыннан Әсма килә.**

Әсма. Рәсим, улым, Рәсим дим!

**Рәсим туктап тормый, югала. Һич көтелмәгән яктан Шифан керә, Әсма аңа каршы бара.**

Әсма. Шифан! Ни булды сезгә?

**Шифан да тукталып тормый, ишетми дә, кырт борылып чыгып китә.**

Әсма. Һич аңламыйм! Ни булган боларга?! *(Чыга.)*

**Шифан керә, аның артыннан Рәсим ияргән.**

Рәсим. Шифан! Шифан!

**Шифан эндәшми, чыгып китә. Рәсим ялгызы. Әсма керә.**

Әсма. Берәр нәрсә аңлатасыңмы, юкмы? Нигә качышлы уйныйсың? Анамы мин сиңа, юкмы?!

**Рәсим чыгып китә, яр буеннан Мияссәр калкына.**

Мияссәр. Күл буенда мондый ыгы-зыгыны байтактан күргән юк иде. Карткорыга аңа ни?.. Пөриләр адымнарын санап! Яшьләр шул, яшьләр! Алар бар җирдә хәрәкәте дә бар, тизлеге дә, ашыгыч йомышлары да күп.

Әсма. Мияссәр абзый, коры куаныч, син мондамыни?

Мияссәр. Нишлисең?! Монда шул. *(Сузып.)* Картлар интернат йортында.

Әсма. Рәсим улым кайтып төште бит.

Мияссәр. Күрәм.

Әсма. Нигәдер көлемсерәдең?

Мияссәр. Нашатыр кыстырып җибәргәннәрме әллә дим? Кайтканнан бирле

юрга тайдай чаба да чаба. Әле Шифанны эзли, әле Шифаннан кача.

Әсма. Бардыр инде, Мияссәр агэй.

Мияссәр. Тукта!.. Ә Шифан елый да елый!

Әсма. Елый?!

Мияссәр. Гыйльметдингә укол кадарга керде, куллары калтырый.

Әсма. Сизенәм.

Мияссәр. Ни булган? Студент улын хүчтәнәчкә күңелсез хәбәрләр алып кайтканмы?! Яшьләрдән чыккан күңелсезлек безне дә бик борчый.

Әсма. Әй, Мияссәр агай, үземнең дә юньләп сөйләшә алганым юк! Улымны алыштырып җибәргәннәр дияр идем, үзе!

Мияссәр. Шифан кызганыч! Һәйбәт медсестра, бигрәк сылу бала, риясыз.

Әсма. Әле кызганырлык әллә ни юк бит, Мияссәр абзый! Алай ук хафаланма.

Мияссәр. Бүген карыйм, карт-корылар гаҗәп иртә уянганнар да коридорда кыштыр-мыштыр йөриләр. Сөйләшүләр шыпыртланган. Яшьләр хәле картларны борчымый калмый бит.

Әсма. Үз әти-әнисе берни белми, сез, төн ябалаклары, барын белеп, тикшереп торасыз тагын.

Мияссәр. Тукта, алай димә син, Әсма. Ата-ана күп чакта күрми кала ул. Менә мондагы картларның, карчыкларның фаҗигасе дә шунда: алар үзләре исккткеч әйбәт булганнар, ә менә балаларының кая аяк атлавын күреп бетермәгәннәр.

Әсма. Алай димә, Мияссәр агай!

Мияссәр. Баланы, яшьләрне тәрбия итү һай авыр, әкәмәт икән ул! Әле шушы арада гына укыдым, яшь буынны тәрбия итү мәсьәләсендә безнең илдә, беләсеңме, ничә галим эшли?

Әсма. Ундыр инде, я йөздер.

Мияссәр. Ун мең галим эшли! Ун мең!

Әсма. Минем улымның монда ни катнашы бар?

Мияссәр. Кайтты. Шифан елый. Интернат гү-гү-ү килә.

Әсма. Бәйләнчек кеше син, Мияссәр агай!

Мияссәр. Ул гадәтем бар! Үз семьяң булмагач, читләр белән мавыгып, ятлар белән юанып яшисең шунда.

Әсма. Өйләндерик соң үзегезне?!

Мияссәр. Ул сүз белән шаярма, Әсма.

Әсма. Гыйшык тотып йөргән әбиегез дә бар бугай. Я, я, шаярып кына әйттем.

Мияссәр. Авыр шаярдың, авырттырып.

Әсма. Үземнен дә авыр көнем, Мияссәр агай.

**Чыга. Мияссәр кармакларын рәтләп тагын тал арасына кереп чүгәли. Шифан керә, ул Мияссәрне күрми, талга таянып җырлый:**

Көлүеңне сөям нурландырып,
Нигә моңланасың бу ара?
Матур күзкәйләрең кырыс карый,
Няк ташлыйсың авыр уйларга?
Сүзләреңнең белән кайнарлыгын,
Нигә салкын алар бу ара?
Офыклар ак, көннәр, күкләр аяз,
Үпкән бармы әллә дөньяга!?

Мияссәр. Эх, юк бит балыгы, юк! Сиңа бирер идем, Шифан, сиңа.

Шифан *(кинәт борылып карый)*. Рәхмәт, Мияссәр агай.

**Чыга. Рәшидә узып бара, арба янында тукталы, кыштырдый, Мияссәр борылып карый.**

Мияссәр. Рәшидә-ү!

Рәшидә *(ни әйтергә белми аптырап)*. Утырасыңмы, Мияссәр абзый?

Мияссәр. Урын сиңа да житәрлек, кил, күңеллерәк булыр.

Рәшидә. Балыгы юк күлгә кармак салып...

Мияссәр. ...утырырга бер тиле баш та житкән дисеңме?

Рәшидә. Алай димим дә... *(Уңайсызланып.)* Кеше көлдерәсем дә килми.

Мияссәр. Миннән көлләр, беләм! Бая күрәм: картлар йортыннан бераү торазыга ябырылган. Карый. Күчеп утырдым. Монда агачлык, мышграк.

Рәшидә. Көләләр дип, Мияссәр абзый... Әллә ничек алай да! Менә һич кирәкмәгәнгә бәбү арбасы сатып алып кайткансың...

Мияссәр. Матурмы?

Рәшидә. Житмеш-сиксән яшьлек картнорыларны үртәр өчен алдыңмы моны?

Мияссәр. Акча әрәм итеп, нәме?

Рәшидә. Эш акчада гынамыни? Хәер, акчасы да жал.

Мияссәр *(арба янына килеп)*. Матур шул, матур. Күрдем, кызыктым да алдым. Яшьрәк чагымда тал чыбыгыннан бишек үрә идем мин авылда. Кабыктан бәби арбасы кирәксә дә миңа киләләр иде. Туйлар миннән башка узмый иде, Рәшидә-ү! Яучы да идем мин. Чалбар балагын чыгарып салыр идем дә, билне чуклы зәңгәр зәр белән буып, кызлы йортка барып ке-

рер идем. *(Жырлап сәхнә буйлап йөри, аягы чак кына аксый.)*

Ефәк баулы былбыл кош
бардыр синең илеңдә!
Каеш баулы лачын кош
бардыр минем илемдә!

Ишетәсеңме? «ефәк баулы былбыл кош» дип атаганнар безнең борынгы болгар илендә! Шуннан калган җыр булыр бу! Ә егете «лачын кош»! Шулай булган. Былбыл кошлар белән лачыннарны бик күп кавыштырдым мин заманында!

Рәшидә. Былбыл кош очкан. Лачын каргага әйләнгән. Булган да уңган. Беткән. Акча әрәм итеп, валлаһи, нигә шушы күз көеген алып кайттың?! Балыксыз күлгә кармак саласың... Билләһи, картлар йортына бер әкият булдың.

Мияссәр. Шыр юләр карт, җиңеләйгән диләрме?

Рәшидә. Алай ук димиләр! Минем алда каты сүз әйтергә базмыйлар!

Мияссәр. Әһә, синең алда каты сүз әйтергә ярамаганны сизәләрме?

Рәшидә. Ни уйлап чыгарасың тагын?

Мияссәр. Һәммәсенә күнегерләр.

Рәшидә. Килгәнеңә ике ел булдымы инде?

Мияссәр. Ике ел да өч ай. Тагын унике көн. Бүген унөченче көнем. Җитмәсә, туган көнем. Җитмеш тулды!.. Сугыштан кайтып төшкән көнем. Анысына утыз биш ел тулды... Күнегерләр дигәч тә, сөенмәдем! Күнекмәсеннәр. Бусы начар. Ичмасам мәзәк итеп сөйләп куансыннар, көлсеннәр. Кырык өч карт-коры... Сирәк көләләр! *(Рәшидә китә башлый.)* Ашыкма инде.

Рәшидә. Туган көнең икәнен беләбез. Кичке чәйдә котлаулар булыр.

Мияссәр. Түгел лә!

Рәшидә. Сәрбиҗамалны, бүлмәдәш карчыгымны авылына озатабыз.

Мияссәр. Бер әйткән идең. Мине тәмам хәтерсез дип уйлыйсыңмы, Рәшидә-әү!

Рәшидә. Машина көтәбез.

Мияссәр *(чак кына мутланып)*. Бүлмәңдә берүзең каласың икән.

Рәшидә. Мияссәр абзый, тукталуымның сәбәбе шул, кичә үк әйтермен дигән идем.

Мияссәр. Әйттең инде, әйттең, калдырмадың.

Рәшидә. Бусын әйтмәдем. Сәрбиҗамал киткәч, безнең бүлмәгә кереп йөрмә инде син.

Мияссәр. Нишләп?

Рәшидә. Әллә ни уйлаулары бар. *(Үзе дә сизмәстән бәби арбасын Мияссәр кулыннан алып тәгәрәтә башлый.)*

Мияссәр *(рәхәтләнеп көлә)*. Миңа җитмеш!

Рәшидә. Котлы булсын!

Мияссәр. Син чак кына яшьрәк. Ни сөйләрләр?

Рәшидә. Күп калгандырмы гомер, аздырмы, гел монда яшисе, кеше күзендә. Авыр сүздән бер куркам, гайбәттән ике!

Мияссәр. Тиле-миле карт нишләмәс, дисеңме?

Рәшидә. Берүк мине сүздән арала, читен хәлдә калдыра күрмә.

Мияссәр. Ә-э-эх, Рәшидә-әү! Хәзер акыллы сүз әйтсәм дә ышандыра алмам инде. Ә мин Сәрбиҗамал карчыкның китүен яхшыга юрап, сиңа бер арба сүз әзерләп йөргән булам тагын. Беләм, мине тыңламас өчен аның итәгенә тагылып йөрдең!.. Менә, китте дә барды!

**Рәшидә чыга. Мияссәр дә күздән югала. Кармак сапларын шунда агачка гына элә. Рәсим белән Шифан керәләр.**

Рәсим. Нигә миннән качасың?

Шифан. Кем соң син хәзер минем өчен? Кем?! Аңлата аласыңмы шуны?

Рәсим. Мин Рәсим.

Шифан. Беттеме? Өстәп әйтер сүзең юкмы?!. Үтенеп, ялварып сорыйм. Әзәрлекләмә. Йөрмә минем арттан. Миңа болай да бик авыр икәнен сизмисеңмени? Син Рәсим генә түгел шул! Рәсим генә булсаң, белер идең, аңлар идең! *(Чыга.)*

Мияссәр. Типте бия тәртәгә!..

Рәсим. Шифан, Шифан! *(Чыга.)*

Мияссәр бәби арбасын тәгәрәтә, җырлый:

Әлли-бәү, бәлли-бәү!
Нәнекәчем-кошчыгым!
Әлли-бәү, әлли-бәү,
Йомшак сары томшыгым...

*(Кинәт җыры үзгәрә.)*

Күлем өсләрендә ак томан,
Бу илләрдә күп тормам.
Язын торсам, көзен тормам,
Сагынырсыз, мин булмам.

Елама, әлли-бәү, бәлли-бәү!.. Яшьләр елый икән, монда картларның да гаебе бар.

**Чыга. Пауза. Машина килеп туктала. Мияссәр кире кереп арбаны агач күләгәсенәрәк куя. Чыгып китә. Сагаеп карана-карана Әдһәм белән Хурия керәләр.**

Хурия *(алданрак килә)*. Кил, кил, курыкма.

Әдһәм. Кеше-кара юкмы?

Хурия. Шушындамы?

Әдһәм. Элекке килүләремдә шунда иде. Хәзер кая китсен? Кемгә барып сугылсын?..

Хурия. Кешедән читенсенгән буласың, анаң җәннәттә яши икән әле!

Әдһәм. «Җәннәт» димәгәннәр шул.

Хурия. Җәһәннәм дә түгел.

Әдһәм. Әнә, кыегына «Картлар интернат-йорты» дип язганнар. Кара.

Хурия *(таякларны күреп)*. Кармак! Балык ашап яталар.

Әдһәм. Иясе мондадыр, кузгатма.

Хурия. Үзләренә күрә түгел, бамбук таяклар! Теге җәфа әллә кайчан сорап йөри иде. Синең теләнче төпчегеңне әйтәм.

Әдһәм. Ана кеше үз баласын «җәфа, теләнче» дип йөртә.

Хурия. Әй, әй! Берәүләр үз аналары янына килгәннәр икән, кояш батыштан чыгып маташа! Мин китереп тыктыммы әллә әниеңне бу җәннәт-җәһәннәмгә?

Әдһәм. «Җәһәннәм» дә димәгәннәр. Гап-гади колхозара интернат. Ин-тер-нат!

Хурия. Ә улыңны... җәфа димичә соң? Ел саен чалбар алыштыра.

Әдһәм. Алдыра икән, буйга үсә.

Хурия. Үсә икән, тамагы тук, әнисе, әйбәт. Карый!

Әдһәм. Анысы, үпкәләштән түгел, Хурия, синең сүзне сүз итеп кенә китердем монда әнине. Өч малае бар килеш чит кулларда ята.

Хурия. Әдһәм! Күрәсеңме, аста күл. Сикер дисәм, сикерәсең. Сикерәсеңме?

Әдһәм. Сикерми кара! Муенга таш бәйләп төртеп төшерерсең!

Хурия. Шулай диген, ишәгем.

Әдһәм. Булган шул заманалар, ат белән иргә пачут булган. Хәзер сыер белән хатын-кыз алдынгылыкка чыкты. Закон да алар ягында, сүз дә.

Хурия. Ике сөйләшү юк, тәмам. Исерек булып кыланып анаң янына керәсең. Ул сине чеп-чи алкаш дип белә. «Бурычым күп, түләмәсәм үтерәләр!» дип тәгәрәп елыйсың. Һәм ике айлык пенсия акчасын каерып торып аласың.

Әдһәм. Бирсә...

Хурия. Котәргә исәбем юк, бирсә дә аласың, бирмәсә дә.

Әдһәм. Бирмәсә ничек аласың?

Хурия. Куркытасың! Өч якта өч малаең барын начальствога әйтәм, дисең. Пенсиясен аласың да аласың. Аның өчен генә мин килеп тә йөрмәс идем, рәхмәт, башка чакларда төгәл кайтарып тапшырдың...

Әдһәм. Тагын ни җитми сиңа, ачкуз? Өч бүлмәле фатирың бар. Өч җаңга! Тартма-тартма тунныарың. Төргәк-төргәк акчаң.

Хурия. Сиңа әйтелгән: онытсаң, тагын кабатлыйм — аның өй саткан акчасы бер биш йөз калган булырга тиеш. Минем исәпләвемчә.

Әдһәм. Биш йөз?!

Хурия. Син! Онытма! Машина чираты җиткән! Миңа мең сум акча кирәк.

Әдһәм. Мең сум?! Узган айда гына «ике йөз җитми» диган идең.

Хурия. Тотынды! Шуны бел: машина алгач яңа күлмәк кирәкме? Кирәк! Күлмәккә ятышлы муенса да аласы булыр. Муенсага тиң алка! Тукта әле, ни сөйләшәбез? Өйгә кайткач аңлатырмын. Бар!

Әдһәм. Барыбер машинаны сатабыз дисең ич.

Хурия. Башкалар ике бәягә алганда нигә сатмаска? Алар безне талый, без дә юләр түгел, талыйк! Берне дә сатарбыз, икене дә... Бел, әгәр янында мин булмасам, син чеп-чи алкаш булып тайга урманында агач ега идең.

Әдһәм. Трамвайда йөрерлек акча бирмисең. Кулга талон тоттырасың... Беләм, ишеткән... Элек «татар хатыны нилэр күрми» диганнәр, хәзер — «татар хатыны ниләр күрсәтми»...

Хурия. Бар, ишәгем. Дуңгыз борыным! Бар!

**Миассәр керә.**

Миассәр. Кардәшләр, теге сезнең машинамы?

Хурия. Син автоинспектормы әллә?

Миассәр. Түгел дә.

Хурия. Алайса, безнеке.

Әдһәм *(кабаренеп)*. Нәрсә булган?

Миассәр. Сез монда берәрсе янына килдегезме, әллә узып кына барасызмы?

Хурия. Кара әле моны!

Әдһәм. Безне, без...

Хурия. Балык сөзеп карарга исәп.

Миассәр. Бу күлдә балык юк.

Хурия. Сиңа ни кирәк соң, бабай?

Миассәр. Бер бик хөрмәтле кешене озатасы бар иде. Безнең интернат ятимен. Станция ягына бармыйсызмы?

Әдһәм *(сискәнеп)*. Кемне, кемне? Кая озатасыз?!

Миассәр. Бер әбине?

Әдһәм. Нинди әбине? Нигә безгә бәйләнәсең? Нигә аны безгә тагарга маташасың?

Миассәр. Сәрбиҗамал китә. Җәйгә авылына кайта.

Хурия. Юк, юк, станция ягына бармыйбыз.

Миассәр. Кая барасыз соң сез?

Әдһәм. Кайманга катык ашарга!

Миассәр. Хәзер генә танадым. Сине кайдадыр күргәнем бар. Ихлас. *(Чыга.)*

Әдһәм. Хәтерли! Картайгач күз начарлана диләр тагын.

Хурия. Әдһәм, монда казлар да бар икән.

Әдһәм. Закускага дисеңме?

Хурия. Бар, кер. Күр. Ал!

Әдһәм. Куркам.

Хурия. Башка чакта ничек алып чыга идең?

Әдһәм. Бүтән чакта теләсә нинди машинага утырып килә идем. Әләгеп. Йөз грамм булса да кабып керә идем. Салып бир!

Хурия. Син рульдә. Машина кешенеке.

Әдһәм. Керә алмыйм аек баштан! Кылана алмыйм. Мин сиңа артист түгел.

Хурия. Машина алыйк. Ике бәһагә сатыйк. Заманалар гына үзгәрмәсен. Күп итеп машина ясап эшне бозып кына ташламасыннар. Гел җитмәсен ул әйбер-кара. Акыллы кешеләргә рәхәт була. Ике бәягә сатып тагын берне алгач... Ун көн... юк, атна буе! Түгел лә, өч көн рәттән пиво эчертермен. Үзем!

Әдһәм. Булмас! Ай башында егерме кап сигарет тоттырасың бит! Акча бирмәс өчен!

Хурия. Дөнья мәшәкатьләре җилкәңә басса, ата каз булып каңгылдарсың.

Әдһәм. Тьфу!

Хурия. Яле, осталыгыңны күрсәт. *(Әдһәм исерек булып кылана.)* Фи, моңа сукыр тавык та ышанмый. Менә күр. *(Үзе исерек булып кыланып күрсәтә.)* Җиде ел алкаш булып йөреп... тьфу!

Әдһәм. Хурия! Акчаң бүгенге көндә ике машинага житә. Бәрәңге белән килька — кунак сыең да шул.

Хурия. Ике машина алабыз да, икесен дә озатабыз!.. Ах! Акчам күбрәк булсын иде әле!.. Җан рәхәте! Күңел гел сөенеп тора! Акча бар, акча бар, дип җырлый.

Әдһәм. Син машина кибете ачканчы, оят булса да, әни янына керәм.

Хурия. Бар, минем ишәгем. Бар, минем акча янчыгым. Кер.

**Әдһәм бара башлый, каршысына ак халаттан Шифан очрый.**

Шифан. Исәнмесез.

Хурия *(Әдһәмне бер якка аралап)*. Исән, исән. Әлегә аңа врач кирәкми.

Шифан *(Әдһәмгә)*. Мин сезне беләм. Сез Рәшидә әби янына киләсез. Сез аның ерак туганы. Күчтәнәчләр китерәсез. Ике ай саен хәлен белешеп китәсез. Рәхмәт сезгә.

Хурия. Нинди Рәшидә? Без машина юарга гына туктадык. Юлда тузан, тузан! Фу, борын тишекләрең кап-кара! Бар!

Шифан. Ялгыштым микәнни?

Әдһәм. Ялгыштың, ялгыштың.

Шифан. Рәшидә апаның ерак кардәшенә бик охшагансыз. *(Чыга.)*

Хурия. Нигә тормозга бастың?

Әдһәм. Әнә бит, «рәхмәт», ди.

Хурия. Әйтсә соң!

Әдһәм. Яу! Әни үзе монда таба килә!

Хурия. Шулмы?

Әдһәм. Килен! Әнине танымый башлаган!

Хурия. Күрмәгәнгә дүрт ел. Мин ычкындым. Кара аны, озаклама. Җебемә. Кил әле, түшеңә аз гына аракы тамызыйм. *(Нәни генә шешә чыгарып түшенә аракы сөртә)*.

Әдһәм. Калганын, калганын! Йотам!

Хурия. ГАИ түгел. Авызыңны иснәп карамас. Чү, бу яктан да кемдер килә.

Әдһәм. Директорлары.

Хурия. Ул да сине таныймы?

Әдһәм. Очратканы бар.

Хурия. Шылдык. Түшеңнән аракы очып бетәр инде. Иртәрәк тамыздым.

**Чыгалар. Икесе ике яктан Рәшидә белән Әсма керәләр.**

Әсма. Озаттыгызмы әбине?

Рәшидә. Китте.

Әсма. Утырып тор, Рәшидә апа. Таңнан аяк өстендә. *(Утырышалар.)* Монда җиләс. Син безгә килгәнгә дүрт ел булдымы инде?

Рәшидә. Әллә бер-бер жалу бармы?

Әсма. Юк. Нишләп алай сорадың?

Рәшидә. Сүз җаеннан гына. Дүрт ел тулып узды. Байтак гомер, байтак. Сиңа рәхмәт, Әсма... Син алмасаң...

Әсма. Сәрбиҗамал синнән ике ел алдан килгән алайса?

Рәшидә. Әйе. Мин килгәндә ул монда иде.

Әсма. Тату тормыйсыз, ахры, сез? Әллә бүлмәдәш итеп синең янга башка бирәүне кертергәме?

Рәшидә. Нишләп тату тормыйк ди?

Кем сүзе бу! Кеше сүзеннән, гайбәттән болай да бик куркам!

Әсма. Алайса, ике ай саен, ай актыгына таба, син аны нишләп авылына озатырга омтыласың? Кичә дә колагыма чалынып калды, бик нык үгетләдең.

Рәшидә. Кайтыр кешесе исән чакта авылын күреп калсын. Әйе, дөрес, якын туган-тумачан юк, ятимә, мәгәр иске күршеләренең балалары бик тә әйбәт җаннар, ди. «Бөтенләйгә кайт, әби!» дип тә әйтәләр, ди. Үз сүзе...

Әсма. Алай да... Ике ай саен шушы хәл кабатлана. Бармаса, үңкәләшәсез.

Рәшидә. Турысын ач, Әсма, берәр сүз ишеттерделәрме?

Әсма. Булмагезгә Мияссәр абзый кереп йөри.

Рәшидә. Әллә ул сүз чыгардымы?!

Әсма. Юк ла! Намуслы карт.

Рәшидә. Йөремсәк җан бит. Урын таба алмый.

Әсма. Әллә Сәрбиҗамал көнләшәме дип тә уйлап карадым.

Рәшидә. Син директор, Әсма, теләсә ни уйлый аласың.

Әсма. Миңа рәнҗи күрмә. Миңа сезнең тынычлыгыгыз кыйммәт.

Рәшидә. Яңадан безнең ишек тоткасына кагылып карасын, мин ул исәрне!..

Әсма. Исәр түгел ул, Рәшидә апа. Тыңгысыз яшәгән, чәчрәп, хәзер дә шуны кумакчы... тормыш ул түгел, шартлар башка! Интернат! Ни әйтсәң дә, боегыр кеше боегырлык та!

Рәшидә. Авыр сүз ишетәсе килми, Әсма. Тормыш болай да нык тукмады безне. Инде җан тынычлыгына ирештек дигәндә...

Әсма. Борчылма. Сөйләштек, гаепләшмәдек! Әйдә, керик. Чәй әчәрбез. Рәхәтләнеп утырырбыз. Тәмле сүз — җан азыгы булсын.

**Чыгалар. Әдһәм белән Хурия күренәләр.**

Хурия. Әш беткән боларның! Җәннәт! Чәй эчәләр. Гәп куерталар!

Әдһәм. Син аларның ни сөйләшкәнен аңладыңмы?

Хурия. Әллә... Тыңламадым! Әдһәм, бу арба машина багажнигына сыямы?

Әдһәм. Китер аракыңны!

Хурия. ГАИ... Инспектор!

Әдһәм. Мин үзем ГАИ! *(Шешәне талап ала.)* Имән экаләсе хәтле шешә тыккан бит, һу, карун! Саран бака!

**Мияссәр керә.**

Мияссәр *(шешәгә ымлап)*. Һай-һай-һай! Көпә-көндез. Үзен машинада.

Хурия. Тай моннан, карт, тиз бул!

Мияссәр *(каранып)*. Кармакларым! Ике ел беркем кагылмаган иде.

Әдһәм. Нинди кармак, карт пәри? Монда балык юк, диден ич.

Мияссәр. Син алдыңмы, исерек баш?

Хурия. Ник бәйләнәсең ана? Менә ич кармакларың. *(Бөтенләй башка җирдән алып бирә.)*

Мияссәр. Исеректән кармаклар да аякланып кача икән. Машинага таба атлаганнар! Гаҗәп кешеләр булып чыктыгыз әле сез. Беркая бармыйсыз. Нидер күзәтәсез... Тукта, директорны чакырыйм әле.

Хурия. Әдһәм! Өс, өс!

Әдһәм. Карт! Стоп! Нигә бәйләнәсең? Сакалыңнан учлап күлгә салганны көтәсеңме? Нигә мин генә өркеп торырга тиеш. Куркытасым килә! Ыргытам хәзер күлгә!

Хурия. Мә, йотып бетер!

Мияссәр. Көпә-көндез, ә?!

Әдһәм. Бәйләнә! Карт пәри! Үзе! Үһ-х! Мин сине!

Мияссәр. Кагыласы булма!

**Әдһәм аны йолыккалый, Рәсим керә.**

Рәсим. Бу ни хәл?

Әдһәм. Нигә ул минем үрталгән жаһымны үрти?!

Мияссәр. Исерек ул, сак бул!

Рәсим. Эшне зурга җибәрәсегез килмәсә, хәзер үк моннан китегез.

Әдһәм. Нишләп китим? Син кем?!

Хурия. Ну кешеләр тар күңелле хәзер! Иркенләп машина юарга да бирмиләр!..

**Чыгалар.**

Мияссәр. Нишләде бу халык, ә?!

Рәсим. Хулиган!

Мияссәр. Син булмасаң, баш беткән иде, Рәсим улым. Бугазга үрелә бит, явыз. Каушап калдым.

Рәсим. Узып барам, күрәм... Мин болай гына!

Мияссәр. Болай гына түгел. Юк, Рәсим улым, җил исми яфрак селкенми. Карт бабаңны явыздан саклап калыр өчен дә ныгыган син. Явызы бар икән, кодрәтле табигать яклаучысын да әзерләп өлгерткән.

Рәсим. Мияссәр бабай, син Шифаны күрмәдеңме? Медсестраны?

Мияссәр. Иртәнчәк күргән идем, хәзер генә юк.

Рәсим. Табармын!

Мияссәр. Кер, сакалыңны кырырмын. Йөрмә болай йонга батып.

Рәсим. Сез элек тә парикмахер идегезме?

Мияссәр. Яшь чагында мин тимерче идем. Аннан, олыгайгач, колхоз машиналарын көйләүче булып йөрдем. Мастер-наладчик диләр иде.

Рәсим. Хәзер чәч кыручы, ә?!

Мияссәр. Кая барасың, ничарадан бичара.

Рәсим. Дөрес сөйлисең, Мияссәр бабай! Моны минем әни алдында әйтерсең, яме. Непременно! Шифанга да сөйләп күрсәт. «Кая барасың авылда яшәп!» диген.

Мияссәр. Ялгыз калган карт кая барсын, дидем мин! Ә болай... Менә син! Нинди тормыш көтеп тора сине! Колхоз стипендиаты булып иркәләнеп кенә укыйсың. Җәйләрен — ата йортында. Кунак! Белгеч, зоотехник булып авылга кайтып төшәсең...

Рәсим. Юк, боларын кузгатып торма, Мияссәр бабай. Кирәкми.

Мияссәр. Ә кем көтеп тора! Нинди кыз!..

Рәсим. Көтә әнә, качып йөри!

Мияссәр. Кыз да шәп! Отличный! Сәгате житкәч, белдерерсең, яучы булып үзем барам.

Рәсим. Мин үзем дә сөйләшә алам.

Мияссәр. Алмыйсың шул! Әнә ич, әнигә тегене житкер, болай дип әйт, дип миннән ярдәм сорадың!

Рәсим. Анысы башка мәсьәлә.

Мияссәр. О, егет! Карт кешегә дә күз туктап ял итәр өчен зәңгәр күл буе гына түгел, күңел куанып өчен кешеләр дә кирәк. Яшьләр — жирне-күкне мирас итеп алып кала торган өметле кешеләр кирәк. Менә Шифанга карыйм да, сөенәм. Бетмәс куанычлар көтә бит аны!.. Шәп кыз, валлаһи! Нинди һәйбәт кызлар, егетләр бар авылда дип, көн саен куанып сөйләшәбез. Яшьләрне ярату — гомереңне озайту бит ул. Җан ял итә сезгә карап! Син кайтып сөенечебезне икеләттең. Гомерле булыгыз.

Рәсим. Мияссәр бабай!

Мияссәр. Әллә нигә күңел тулып китә. *(Чыга.)*

**Рәсим ялгызы. Тәмәке кабыза. Бәби арбасы янына һәркем үзенчә килә. Рәсим исә кулы белән буявын сөртеп карый. Кармак сапларын күрә, көлемсери.**

Рәсим. Да-а, монда кешеләр үзгәрмиләр. Кызык карт! Бер сүз белән резюме ясаганда — исәр! *(Әсма керә.)* Әни! Әти Чаллыга күчик дигәндә нигә кузгалмадың син? Ничек түздең? Ничек син шушы оешмада директор булып тора аласың? Мин ярты сәгатькә дә чыдамас идем.

Әсма. Утыр әле, улым. Иртәдән бирле сөйләшәсем килә.

Рәсим. Әйдә, сөйләшик! Дөнья күптән эзгә салынган. Нигә без үз тормышыбызны бутап, баш ватып интегәбез? Һәммәсе дә күптән ап-ачык икән!

Әсма. Сүзнең ни турыда икәнен сизәсең.

Рәсим. Бөтенесен сизәм! Син мине әрләргә керешәсең. Мин синең белән килешмим. Актыктан, барыбер син минем белән ризалашасың!

Әсма. Алай да тыңла!

Рәсим. Тыңлау кирәкме икән?

Әсма. Гармун алдырдың. Уйнамадың.

Рәсим. Шуны искә алып торасыңмы?

Әсма. Электрогитараны Казанга барып алдым. Ике-өч чирттең дә ташладың. Сүз әйтмәү генә түгел, әтиеңә дә әйттермәдем! Унынчыны тәмамлагач авиационныйда бер ел укыдың. «Сызымнар күп, көне-төне укырга кирәк!» дип яратмадың. Кайтып бер ел тик яттың... Әйе, китүчеләр бар, авыл шәһәрне азык-төлек белән генә түгел, эш көчләре белән дә туендырып тора. Әмма син авыл хужалыгы институтын үзең сайладың! «Минем урыным авылда икәнен аңладым!» дидең. Әтиең урнаштырды. Председатель! Колхоздан акча аласың. Егерме тәңкә түләп фатирда тотабыз.

Рәсим. Рәхмәт, әни, рәхмәт.

Әсма. Икеле-микеле характерыңны сизсәм дә, моңарчы түздем. Беләсеңме, нигә?

Рәсим. Син мине яратасың, әни.

Әсма. Ник бер чакта да каршы төшмәдем? Әтиеңне тыеп, яклап килдем?! Нигә?!

Рәсим. Аналар һәммәсе дә шундыйдыр инде?..

Әсма. Аналар шундый, хак. Син минем бердәнберем булдың! Врачлар катгый тыйганда, жанымны үлем астына куеп мин сине таптым.

Рәсим. Боларны әйткәнең юк иде.

Әсма. Көне-сәгате житкәнне көткәнмендер! Тыңла! Дүрт яшьтә чагында син: «минем алты балам булыр!» дия идең. Минем баламның берәү генә булуына офтанганымны ишетеп калгансыңдыр инде! Читкә борылып үкси-үкси елый идем бит! «Алты улымның алтышар бәбәе булыр, минем утыз алты оныгым туачак!» дип

әйттерә идем мин синнән. Санарга син туачак балаларыңны исәплап өйрәндең. Сигез яшь тутыргач, син һич көтмәгәндә: «Минем өч балам булачак» дидең. «Өч баланы карау җиңел булмас, улым», дигәч, син: «Мин хатыныма бик нык булышырмын, эшкә соңрак барырмын, иртәрәк кайтырмын»,— дип җавап бирә идең. Синең шул акыллы сүзләреңне әйтеп күрсәтеп, дус-ишләремнән һушын ала торган идем. Ун яшьтә син кистереп: «Минем бер генә балам булсын, әмма аның бар теләгәне тормышка ашсын», дип куйдың... Сине авылыбызның иң чибәр, иң уңган кызы сөйде!.. Һәм менә син аңа кичәгенәк ни дигәнсең?! Телем бармый... «Мин бер чакта да өйләнмим, буйдак булып калам. Минем бай буйдак булып, бик житеш тормышта гомер сөрәсем килә!» дигәнсең.

Рәсим. Ул шуларны сиңа житкердеме?

Әсма. Көчләп әйттердем... Укол кадый алмый, куллары калтырый... Әйттердем!

Рәсим. Ә мин аңа юри әйттем.

Әсма. Син байтактан инде юри генә сөйләшмисең.

Рәсим. Әни! Укып бетергәч мин авылга кайтмыйм. Стипендия акчасын кайтарып бирергә кирәк. Анысын үзем эшлим.

Әсма. Каян аласың?

Рәсим. Шабашкага йөрермен. Мебель кибетендә грузчик булырмын. Беләсеңме алар күпме суга?! Йке зоотехникның төшенә кермәгән акча ала алар.

Әсма. Каян килде бу акыл?

Рәсим. Тормыш үзгәрде. Авыллар бетә, перспективалары юк.

Әсма. Бетә? Юк?! Икмәкне каян алырбыз? Итне-майны?!

Рәсим. Үзең шаһит. Күреп торасың. Әнә ич колхоз ветераннары! Безне шул язмыш көтмимени?!

Әсма. Шифан нәрсә ди?

Рәсим. Шифан?!. Сорашма әни!

Әсма, Ә без?! Атаң-анаң?!

Рәсим. Курыкма, мин сезне дә үз яныма алдырырмын! Болар кебек яшәтмәм.

Әсма. Ә җир?! Җирне кемгә калдырырбыз?! Барыбыз да күчә, кача башласак, җирдә кем калыр?! Болар көненә калдырмам дисең... Әйе, өйләнмичә, юньле тормыш кормыйча теләсә кайда эт сугарып йөрсәң, безгә алай гына булырмы әле?!

Рәсим. Усал сөйлисең бүген, әни.

Әсма. Син йомшак сөйләп кара. Йомшарт күңелләребезне.

Рәсим *(паузадан соң)*. Шифан шәһәргә күчәчак түгел.

Әсма. Әйе, ул монда калачак, җирдә!

Рәсим. Нигә ул монда газап чигәргә тиеш?

Әсма. Ә кайда тормыш бик җиңел, бик ансат? Тормыш итү әрәмтамакларга һәм имгәкләргә генә җиңел!

Рәсим. Быел мәктәбегезгә ничә бала укырга керә?

Әсма. Бер бала.

Рәсим. Ул да читтән китерелгән инженер малае.

Әсма. Шуннан?

Рәсим. Ник кайтыйм мин авылга?

Әсма. Ә Шифан калага китәргә ризалашса... Өйләнәсеңме?

Рәсим. Юк.

Әсма. Юкмы?

Рәсим. Бала-чага карап хәсрәткә батасым килми. Мин үз рәхәтемдә генә яшәргә телим. *(Әсма китә башлый.)* Килештеңме, әни, минем белән?

Әсма. Бердәнбер баласыннан шул сүзне ишеткән ана... Аяк астында ничек җир убылмый?!

Рәсим. Син бит акыллы хатын. Кирәк чакта этине дә үз җаена бора аласың. Тыңла! Нигә миңа сез яшәгән тормыш? Нигә кабатларга тиеш ди мин аны?!!

Әсма. Үзеңчә кор. Үзеңчә оештыр. Илне-көнне, җирне без сезгә тапшырасы. Парың бар. Беләмен! Син укыган кеше. Нидер ошамый икән, үзгәрт, җайла кераш. Бирешмә!

Рәсим. Сез интеккән дә житкән. Шәһәрдә исә һәммәсе җайга салынган. Артык көч түкмичә генә арага керәсең дә китәсең.

Әсма. Һәм күренмисең! Югаласың, шулаймы?

Рәсим. Күндер этине! Ризалат!

Әсма. Бу юлы үзең ризалатып кара! Әнә, Шифан килә.

Рәсим. Синең янга килә. Йомышы зурдыр! Мин барында килмәс иде югыйсә.

**Шифан керә. Тынлык.**

Әсма. Син медикаментларга китмәдеңмени?

Шифан. Аларын шофер алып кайтырга булды. Документларны бирдем.

Әсма. Үзенә барырга иде. Заказлар тагын үтәлми кала.

Шифан. Әллә нигә аягым тартмады.

Әсма. Җибәрмә! Бер юньсезгә карап дөньяның чите кителмәгән. Кителсә дә, тормыш туктамас!

Шифан. Мин басып торган нәни генә чите китела шул аның! Мин баскан урын.

Р ә с и м. Качма, Шифан. Әни барын да беләә

Ш и ф а н. Аның белгәнен мин дә беләм. Үзем сөйләдем.

Р ә с и м. Кирәкмәс иде!

Ш и ф а н. Ул синең әниең. Ә минем бергә эшли торган һәм алда да бергә булачак кешем. Белеп торсын!..

Ә с м а. Улым, уйла! *(Чыга.)*

Р ә с и м. Барын да белгәч, аңлагач, нигә качасың миннән?

Ш и ф а н. Барын да әйтеп бетергәч, нигә әзәрлеклисең син мине?

Р ә с и м. Нигә курыктың син минем сүзләрдән? Ялган бармы аларда, ялгышмы? Каргышмы? Ни?!

Ш и ф а н. Ичмасам алда идең! Дөресен әйтмә идең!.. Болай гына, тып-тын гына югал идең!..

Р ә с и м. Минем сүзләрнең кайсысы ялгыш?! Әйе, бергә булыйк, дидем. Өйләнешмичә генә, семья богауларын такмыйча гына бәхет табып булмыймыни?! Әйдә, китик без моннан берәр яры! Шушы шомлы йорт теңкәмә тия!

Ш и ф а н. Нигә шомлы?!

Р ә с и м *(дәвам итеп)*. Өйләнешкәч күпме бала-каза киләсен белмисең син. Ә мин беләм, күреп торам. Өйләнү — газап, ызгыш, талаш, хәттә сугыш!.. Ә болай... тормыш — тоташ бәйрәм! Беребез алдында җавап бирәсе юк. Син ирекле кош, мин ирекле кош...

Ш и ф а н. Син «каеш баулы лачын кош», ә мин «ефәк баулы былбыл кош».

Р ә с и м. Кем сүзләре бу?

Ш и ф а н. Эш кем әйтүендәме?!!

Р ә с и м. Исәр Мияссәр карт сүзләре генә ич болар!

Ш и ф а н. Теләгәндә кавышабыз... Җаннар ерак булса да, тәннәр бергә...

Р ә с и м. Дөрес! Теләмәгәндә һәркем үзенчә яши! Үзенә-үзе хуҗа!

Ш и ф а н. Ә бала булса? Бала?

Р ә с и м. Бала булмас. Кирәкми дә. Кем бу дөньяда баладан рәхәт күргән?

Ш и ф а н. Әйе, бала — мәшәкать. Семья— мәшәкать.

Р ә с и м. Интернатта эшләп, син тормышның төп фаҗигасен аңлагансың. Хәзер ничек итеп рәхәт чигәргә мөмкин булуын мин төшендерим.

Ш и ф а н. Ә авыл?! Кем эшләр монда!?

Р ә с и м. Кем булса да калыр әле.

Ш и ф а н. Ил сакларга кем барыр?.. Юк, мин монда калам.

Р ә с и м. Кал! Мин кайтып-кайтып йөрермен. Кышларын, я җәйге ялында син минем янга килерсең.

Ш и ф а н. Мин андый сүзләргә җавап та бирә алмыйм.

Р ә с и м. Тормыш үзгәрде, Шифан! Хәзер бәхет төшенчәсе бөтенләй башка!

Ш и ф а н. Кеше тормышны үзе үзгәртә. Хак, авылда яшәү ансат түгел. Юллар пычрак. Кышкы төннәр озын. Ә нигә без барыбыз да ансат юл сайларга тиеш?! БАМга китәләр. Җиңелме?! Алтышар ай күктә очалар. Ансатмы?! Караңгы җир астына төшеп күмер чабалар! Бәйрәмме?! Эссе цехларда смена буе басып торалар. Уенмы?!

Р ә с и м. Авылның гомере ун-унбиш ел. Качалар авылдан! Качалар!

Ш и ф а н. Качмыйлар, китәләр. Ә калганнар кала. Матур кешеләр кала. Акыллы кешеләр кала. Китмим мин моннан!

Р ә с и м. Шушы бәлтерәгән картлар янындамы?

Ш и ф а н. Әйе. Китсәм дә авылга гына китәчәкмен! Җәйге ялга кайтып кәпәренеп йөргән буйдак, бай Рәсимне күрәсем килмәс аңысы!.. Хуш!

Р ә с и м. Шифан! Шифан!..

**Шифан чыгып китә. Рәсим дә аңа иярә. Хурия белән Әдһәм керәләр.**

Х у р и я. Фу! Башка чакта да шулай болгавыр була идеме монда?

Ә д һ ә м. Әһә, күрдеңме? Белдеңме? Ир башына күпме газап төшкәнен аңладыңмы?

Х у р и я. Монда кунар хәлем юк, ачты карыным, кер дә эшеңне башкар.

Ә д һ ә м *(тукталып)*. Җәнҗал куптарса?

Х у р и я. Бәяңне арттырырга маташма! Башка чакта дәшмәгәнне бер бүген генә...

Ә д һ ә м. Бу юлы биш йөзне сорарга куштың!

Х у р и я. Сорарга түгел, алырга! Мәнсез баш.

Ә д һ ә м. Теге шайтан таягы тагы килә!

**Мияссәр белән Шифан керәләр.**

М и я с с ә р. Кара! Машинаны хәйран озак юган сез?

Х у р и я. Бәйләнчек тә җан икәнсең син!

Ш и ф а н. Мин сезне беләм бит. Сез Рәшидә әбинең туганы. Нигә яшерәсез шуны?

Ә д һ ә м. Юк диләр ич сиңа! Вәт кырмавык! Минем туганым да, чуртым да юк.

Х у р и я. Төрле яктан ятим ул! Китик, җанкисәк. *(Чыгалар.)*

М и я с с ә р. Минем дә күргәнем бар ши-

келле. Тиккә йөрмиләр. Баягынак та директорга әйтергә теләдем... Нигә чакырдың мине, кызым?

Шифан. Мияссәр агай, мин озакламый моннан китәм.

Мияссәр. Синме? Кая китәсең, балакай?

Шифан. Әлегә белмим.

Мияссәр. Белмәгәч, ничек китәм дип әйтә аласың?

Шифан. Китүемне берәүгә дә әйтмим, беркемгә дә белдермим.

Мияссәр. Миңа да ялгыш кына ычкындыргансың алайса?

Шифан. Мин сезне бик яратам, Мияссәр агай. Сез миңа гел-гел шәфкатьле, мәрхәмәтле булдыгыз.

Мияссәр. Бәй, тукта әле. Синең яшьтә елыйлар димени?

Шифан. Әйе, китәм. Бөтенләйгә югалам. Әткәйләргә дә белдереп тормыйм. Гел.

Мияссәр. Тынычлан. Сөрт яшьләреңне. Менә шулай. Ул ничек? Ул? Рәсимне әйтәм. Юктыр ла!.. Без ничек? Безгә ни?!

Шифан. Яратмый ул мине.

Мияссәр. Ә-ә, тәмсезләшкәнсез икән. Була инде ул. Исең китмәсен!

Шифан. Яратмый, яратмый!

Мияссәр. Болытлы көннәр була, жибәрмә тирәнгә.

Шифан. Авылга кайтмыйм, ди. Хыянәтче ул!

Мияссәр. Рәсим дә кайтмыймы?! Ала-ай... Шулай ук мыни? *(Шифан раслап баш кага.)* Ә син? Син? Син дә китәм дисең түгелме?

Шифан. Мин аның янына шәһәргә бармыйм.

Мияссәр. Сиңа рәхмәтемнең иң олысы. Ала-ай... Алдагы гомереңнең ничек узса да, бүгенгең өчен рәхмәт. Мин сиңа карап кына юана идем, балакай. Сезгә карап! Өч улым бар иде минем. Өчәү! Икесе Ватан сугышыннан кайтмады. Өченчесе, иң олысы, кырык яра белән кайтып егылды. Өйләнә дә алмады. Өлгермәде. Ул ел урын өстендә тилмереп ятып, үз кулымда җан бирде! Өйләнгән генә булса соң!.. Миңа кара башлы бер бала калдырган булса!.. Үз гомереңне бирәсеңмени?! Хәсрәтләр дәрьясы карчыгымны да алып китте... Югыйсә, мин монда ята торган җан идемме?! Авылыбызда тимерче генә түгел идем мин, туйларда түрдә, тәгам атасы да идем. Кызлы йортларда зарыгып көтеп алалар иде мине. Ячусыз өйләнмиләр иде безнең Көмешле Елгада! Ячуны көтәләр, йорттагылар капка төбенә чыгып каршылыйлар иде. Ә мин киләм... Мин! Йоланың үз рәте, тәртибе, җырлары бар! *(Җырлый.)*

Ефәк баулы былбыл кош
бардыр синең илеңдә!
Каеш баулы лачын кош
бардыр минем илемдә!..

Өч лачын кошымны очырттым. Югыйсә монда килә торган зат идемме мин?!. Шуннан сезне күрдем. Йокысыз, тынгысыз төннәр кичеп, зар-интизар булып тилмереп йөргәндә, Рәсим белән син шушы күл буен урадыгыз. Икәү!.. «Ефәк баулы былбыл кош бардыр минем илемдә!» Ишетәсеңме, балакай, «өемдә» түгел, «илемдә!» Яшь кияүле, яшь киләшле йортны безнең болгар бабалар Ил дип олылаганнар... Син идең бит минем ефәк баулы былбыл кошым. Ни булды сиңа? Нишләттеләр сине? Мин ул Рәсимнеме?! Кешене шулай җәберлиләрмени?! Авылны шулай мыскыл итәләрмени?!

Шифан. Кирәкми, Мияссәр агай. Зур авыллар бар, матур, нык нигезле авыллар күпме?!

Мияссәр. Юк димим, беләм, бар! Авылларның гөрләп утырганнары бар! Ә ничаклы авыллар хәл эчендә?! Ташландык йортлар, такта тәрәзәләр, шыксыз урамнар. Менә бит, ерак барасы да түгел, Чабаклы күлгә кара! Җитмеш икенең җәендә, афәтле корылыкта, аның суын төбенә хәтле суыртып җиргә сипкәннәр. Кирәкмәгәнгә сипмәгәннәр, мәгълүм! Кара балык йөзгән элек монда, табан балык, сазан! Хәзер кәрәкә дә юк! Ике йөз метр арадагы елгадан канау казып күлгә су тутырдылар. Суы бар, балыгы юк. Күл элекке халенә кайтсын өчен тагын ярты гасыр вакыт кирәк икән. Әле ул чакта да чын-чын үз мәгънәсенә кайтырмы, юкмы. Авыл да шул күл сымак иң, кирәк чакта эшче кулларны суырып кына алабыз. Китәләр, китәләр. Күл-авыл бушап кала. Авылны да читтән кеше җыеп тутырабыз. Тик нигә елдан үз тәртибенә килер ул? Килерме?! *(Бәби арбасын тартып, гадәттәгедән ныграк аксаклап, чабып диярлек йөри, җырлый.)*

Әлли-бәлли, бәү-бәү!
Нәнекәчем-кошчыгым!
Әлли-бәлли, бәү-бәү!
Йомшак сары томшыгым!

Кисте сугыш безнең гомерне! Балыксыз күл. Бәбәйсез арба. Укучысыз класс... Бу арбаны сезгә бүләккә дип алган идем. Кая

ташлыйм мин аны хәзер? Әлли-бәлли көен кемгә җырлыйм?..

Ш и ф а н. Минем гаебем юк, Мияссәр агай!.. Минем бит Рәсим күзе җитмәслек җиргә генә китеп югаласым килә!

Рәшидә керә.

М и я с с ә р. Эх, Шифан балакай!.. Рәшидә-әү! Кая кабаланасың?

Р ә ш и д ә. Ялгыз калдыммы, күзгә күренә башлый. Әнә тегендә бер әйбер юкмы? Селкенәме?!

Ш и ф а н. Берни дә юк анда, Рәшидә әби.

Р ә ш и д ә. Мөгаен, күземә күренәдер.
М и я с с ә р. Сиңа сүзем бар.
Р ә ш и д ә. Әйт, Мияссәр абзый.
М и я с с ә р. Син мине аңларга тиеш, син.
Р ә ш и д ә. Тырышып багармын.
М и я с с ә р. Аңларсың да, ышанам.

Ш и ф а н. Мин кирәкмимме инде? Китимме?

М и я с с ә р. Син дә тыңла. Кирәге булыр. Рәшидә-әү! Минем авылым моннан илле биш чакрымда. Көмешле Елга!

Р ә ш и д ә. Сөйләгәнең бар, Мияссәр абзый.

М и я с с ә р. Алты почмаклы, такта башлы йорт. Йорт алдында өч каен.
Р ә ш и д ә. Аларын да хәтерлим.
М и я с с ә р. Өйне үзем салдым. Мичен дә үзем чыгардым. Үзем үк тәрәзәләренә такта кадаклап чыгып киттем.

Р ә ш и д ә. Нишлисең, дөнья! Мин исә йорт-җиремне тузгытып, сатып чыгып киттем.
М и я с с ә р. Әйдә, парлашабыз да, безнең авылга кайтып, минем өйдә бергә яши башлыйбыз?.. Теләсәң, Шифан кызым, сине яучы итеп җибәрәм.

Р ә ш и д ә *(көлә)*. Шушы арбаны парлашып җитәкләп кайтып керәбезме, Мияссәр абзый?! Эх-ха-ха!

М и я с с ә р. Мине тилегә чыгарасың инде, һич ни сүземә ышанмыйсың. Авыл бетә бит, авыл! Яшьләр авылны сөйми. Авыл белән моң бетә, моң! Күңел моңы бетә! Экиятләр бетә, табышмаклар... Яшьләр нигезне ныгытмыйлар, өйләнмиләр. Көмешле Елга бетә. Авылымның җан биргәнен ничек түзем генә карап торыйм? Ә ялгыз яши алмыйм. Ялгызлыктан качып чыгып киттем... Ә хәзер уйладым, уйладым да... Хәл кадәренчә тырышырбыз! Тәндә егәр барда тәвәккәллик!..
Р ә ш и д ә. Тукта, Мияссәр абзый, чү!

Ш и ф а н. Ни күрдең, Рәшидә әби? Ник алай сискәндең?

Р ә ш и д ә. Ялгыз калдыммы, күземә әллә ниләр күренә башлый дисәм, чү, чүгегез...
Ш и ф а н. Нинди яхшы кеше сез, Мияссәр агай!

М и я с с ә р. Кемне күрдең? Нигә курыктың? Ә-ә, юлаучылар алар! Баядан бирле машина юалар. Озак юалар мәгәр.
Р ә ш и д ә. Беттем.
М и я с с ә р. Хәзер сөрел җибәрәм мин ул исерекбашны.
Р ә ш и д ә. Исерек иканен дә белеп өлгергән.
М и я с с ә р. Шешә авызыннан гына чөмереп ята.
Ш и ф а н. Ул сезнең туганыгыз бит. Рәшидә әби, иеме?
Р ә ш и д ә. Белмисез шул сез, берни генә дә белмисез!
М и я с с ә р. Белдер соң.

**Әдһәм исерек булып ярым кыланып керә дә Рәшидәне кул изәп чакыра.**

Ә д һ ә м. Кил монда, кил.
Ш и ф а н. Рәшидә апа! Барасы булма!
М и я с с ә р. Үзең мондарак атла, тәти егет. Ачу кабарган чак!

Ә д һ ә м. Минем болар белән чуалып, вакланып торырга вакыт чамалы. Минем сиңа йомышым бар.

М и я с с ә р. Үзең кил диләр сиңа!
Ә д һ ә м. Әтәчләнмә, карт!
Р ә ш и д ә. Кирәкми, Мияссәр абзый. Шифан, балам... Икегез дә китеп торыгыз. Нигә өстәмә борчыларга? Юлаучының сүзе бар икән, әйдә, сөйләп карасын.

М и я с с ә р. Мин иртәдән бирле сине сагалап йөрим! Сүземне әйттем, ниһаять. Нигә җавап бирмисең? Әү, Рәшидә-әү!
Р ә ш и д ә. Алай ордым-бардым белән генә җавап бирә торган сүз түгел.

М и я с с ә р. Әйдә, Шифан! Бер кызган чакта Рәсимеңне дә табыйк... Мин анымы, мин аны! Дагаламасаммы?!. Рәшидә-әү, кирәк икән, без монда гына. Якында, яме?

Р ә ш и д ә *(Мияссәр белән Шифанны озатып)*. Ярый, ярый. *(Әдһәмгә.)* Килеп җиттеңме, исерек Газраил?! Тагын килдеңме, җәфа? Килеп төштеңме, кара хәсрәт?! *(Елый.)*

Ә д һ ә м. Килдем әни. Сиңа, бармыйча, кемгә барыйм? Кая? Коткар!
Р ә ш и д ә. Нишләтергә сине? Ни кылырга? Ничек котылырга синнән?!

Пәрдә.

**Шул ук урын — күл буе. Шул ук кешеләр — Рәшидә белән Әдһәм кара-каршы басып торалар.**

Әдһәм. Әнием, бердәнберем! Ташлама! Коткарсаң, син генә коткара аласың игелексез улыңны. Хәер, аны коткарып та дөньяга ни файда. Беләм, күңелең балавыз, эри дә китә. Беләм, шәфкатең киң. Ә мин?! Олтырак! Беткән кеше.

Рәшидә. Тагын ни булды?

Әдһәм. Сорама. Сорама да. Сорап ни файда? Әйдә бетерсеннәр, бетерсеннәр. Синең баш та котылыр.

Рәшидә. Ике айның берендә дүртенче елыңны йөрисең. Юньле берәр сүзең булырмы-юкмы?

Әдһәм. Әнә, куак артында кемнәр торганын беләсеңме? Ту-ты, белмисең. Сезнең дөнья бит ул... Әнә, әнә! Мине сагалыйлар алар. Я качыр, я коткар.

Рәшидә. Бу юлга акчам юк.

Әдһәм *(кинәт айнып)*. Пенсияңне китермәделәрме?

Рәшидә. Китерделәр.

Әдһәм. Өстең бөтен. Тамак бушлай. Кая куйдың?

Рәшидә. Бер айныкын барыбыз да, Тынычлык фондына бирдек. Бөтенебез бер булып. Калганын Сәрбиҗамалга багышладым. Ул авылына кунакка кайтып китте. Ку-нак-ка! Үзең гаепле. Очрашуыгызны теләмәдем. Узган юлы да иләндә үрмәләп, әллә ниләр мыгырдый башладың. «Әни!» дип ычкындырырсың дип бик курыктым. Ул бит сине ерак кардәшем дип белә.

Әдһәм. Әллә ниләргә акча җәлләми, ә үзенең газиз балакаена, төпчек улына...

Рәшидә. Сиңа бит акча эчәргә генә кирәк. Эчми торсаң да үлмәссең.

Әдһәм. Чыдыйм! Эчмим, әни. Әлек әчкәнне түләргә кирәк. Бурычым бар.

Рәшидә. Бурычка кердеңме? Ничәләр әйттем мин сиңа?! Алма кешедән бурыч, дидем. Үлсәң үл, мәгәр алма. Бурыч — адәм баласының муенына тагылган таш ул. Төпкә сөйри, тарта. Харап булгансың.

Әдһәм. Бәхет булмады, әни.

Рәшидә. Хатыннан уңмадың. Шулаймы?

Әдһәм. Үзем дә әллә кем түгел инде. Хатыннан да уңмадым, әти-анидән дә, туган җирдән дә — берсеннән дә корт кунмады.

Рәшидә. Һай, затсыз! Ничек аларга тел күтәрә аласың? Тел күтәргән дивана кул күтәрүне дә чит итмәс.

Әдһәм. Соң инде баш белән уйла! Кырык төтенле авылда туганмын. Бәхетме бу?!

Рәшидә. Юк бит акчам, берер идем дә олактырыр идем. Дөмек нең шунда эчеп.

Әдһәм. Ә мин шәп калада, олы урындагы ашлы-сулы кешенең улы булып туа алыр идемме? Ала идем! Кем булып яшиидем мин бүген, ә?! Нигә дәшмисең? Ту-ты.

Рәшидә. Шөкер ходайга, моны башкалар ишетми. Ана йөрәге түзә. Ничек шартламый торгандыр.

Әдһәм. Әни, син төпчек балаңның бәхетсезлеген беләсең. Яман аның хәле, баш китәрлек.

Рәшидә. Күрәм. Ничек йолып алу җаен таба алмыйм. Тол бит мин, ялгыз. Таянырым да, киңәшер кешем дә юк.

Әдһәм. Шушы атна эчендә түләмәсәм, харап итәләр, муенга аркылы чабалар. Терелэй кычкыртып туныйлар.

Рәшидә. Кемнәр соң алар? Әйдә, милициягә тапшырыйк та котыл син алардан.

Әдһәм. Абыйларга барыр идем, үзләре сволочь. Зариф абыйның ишеген кагып караган идем, пыяла күздән генә чекерәеп карыйлар, эчмыйлар да, дәшмиләр дә! Ә тегесе настаящий свинья! Алар акча бирсә, сиңа килеп йөрми идем, коиштыр. Яз әле үзләренә хат, кече энеләрен рәнҗетмәсеннәр, ныгытып яз.

Рәшидә. Бурычың күпме?

Әдһәм. Алай ук түгел дә...

Рәшидә. Сузма, барыбер әйтәсең бит.

Әдһәм. Биш йөз сум.

Рәшидә. Күпме, күпме дисең?

Әдһәм. Бусы үземнең гадел өлешем. Өй сатудан калган акчадан бирерсең. Тагын бер йөзне үзеңнән өстәрсең. Бирәчәктән котылгач та яшәргә кирәк ич әле миңа.

Рәшидә. Өй саткан? Кайчан иде ул, беләсеңме, тинтәк?!

Әдһәм. Белүемчә, сиңдә запас калды.

Рәшидә. Өйне саткач, өчегезне дә йөреп чыктым. Өчегез дә мине чират-чират пропискага кертеп, өчәр бүлмәле фатир алдыгыз. Өчегезгә дә өй котлап байтак акча бирдем. Үз өем кереп китте, колагы да күренмәде. Туйлар узып, хәвеф-хәтәр онытылгач, өчегез дә мине күпсендегез. Әллә мин монда ятар идемме?

Ә д һ ә м. Әни, хәзерге киленнәр кайнага белән тынышмый! Аннары син хөкүмәт исәбендә! Фронтовик хатыны! Сине дәүләт карый.

Р ә ш и д ә. Совет хөкүмәтеннән өч тапкыр фатир өлеше алдым. Дүртенче урынымны менә моннан бирделәр. Ник миңа тынгылык юк икән һаман?

Ә д һ ә м. Менә мине әйт син, мине! Башкалар балаларына машина калдыралар. Йортлы-җирле итәләр. Эшләтмиләр! Синең аркада гомерем буе чиләнәм, эшлим. Тузан-туфракка манчылып өч ел комбайнда йөрдем. Өч ел! Өй котлап биргән мең сумын санап ята! Берәү булса аны телгә алырга оялыр иде. Бетердең башкайларымны! Я, бирәсеңме алты йөз сум? Җиде йөзгә менгәнче биреп кал.

Р ә ш и д ә. Беттеме?

Ә д һ ә м. Нәрсә тагын? Нәрсә?

Р ә ш и д ә. Болары өйдә хатының биргән акыл. Ул өйрәткән сабак. Хәзер менә мондарак утыр да, сабыр гына, чынлыкны сөйләп бир.

Ә д һ ә м. Чынын сөйләсәм, акча бирәсеңме?

Р ә ш и д ә. Карап карарбыз.

Ә д һ ә м. Их, әни! Син кайда яшәсәң дә үзеңә үзең хуҗа. Минем бит... Зарплатадан бер тиен күрә алмыйм. «Алкаш!» дип жалу язып, турыдан-туры кассага күчертә. Кенәгә аның исемендә. Тәмәкене дә парктан шешә җыеп алам.

Р ә ш и д ә. Тартма. Ташла.

Ә д һ ә м. Өс-башны кыса. Тамакны әйткән дә юк. Былтыр гына өч килога кимедем.

Р ә ш и д ә. Нигә издерәсең шул кадәр?! Әби патша түгел лә, үз хатының.

Ә д һ ә м. Моннан дүрт ел элек, малайлар белән юләрләнеп, контейнердан телевизор урлап саткан идек. Тимер юлда.

Р ә ш и д ә. Яманның актыккы чигенә барып җиткәнсең икән, балам!

Ә д һ ә м. Ачык авызланып, шуны ычкындырып ташлаганмын.

Р ә ш и д ә. Акча хатыныңа кирәктер инде.

Ә д һ ә м. Иплән! Үзе монда. Тыңлый!

Р ә ш и д ә. Шулайдыр кебек тоела иде дә! Хурия, Хурия, кил!

**Хурия керә.**

Х у р и я *(иренә яман карап.)* Син нишләп монда сыер тәбикмәге төсле җәелдең? Көн уза! Вакыт кыса. Бурычыңны мин түләр дип көтәсеңме? Минем акчаны әнә ачарбак малаең кимерә.

Р ә ш и д ә. Исәнме, килен.

Х у р и я. Килен? Хи-хи, килен! Килен булып төшеп синнән ни хөрмәт күргән дә, ни рәхәт татыган?! Башка кайнаналар, әнә, киленгә алтын алкалар бирә, көмеш беләзекләр. Борынгы алтын акчалар калдыра.

Р ә ш и д ә *(сабыр гына)*. Боларын ишеттем.

Х у р и я. Каян? Кайчан? Дүрт ел күргәнем юк. Килен...

Р ә ш и д ә. Ирең, минем тыңлаулы каderле балакаем, барын да бәйнә-бәйнә сөйләп тапшырды. Түкми-чәчми бар сүзеңне ишеттерде. Сүзеннән бушаганга тик утыра ул.

Х у р и я. Рәхмәт әйт, әгәр аны мин кулда тотмасам, синең ул исерек башың коймa астында чуар дуңгызлар белән аунап ята иде.

Р ә ш и д ә. Рульдә! Аек ул!

Х у р и я *(Әдһәмгә)*. Булдымы?

Ә д һ ә м. Акчам юк, ди.

Х у р и я. Иртәрәк айныгансың. Шәп! Әле дә ярый — үзем килгәнмен. Булды. Гарык! Мин синең йолкышыңа саф кыз килеш кияүгә чыктым. Матурлыгымны җәлләмәдем, яшьлегемне кызганмадым. Барын бүләк иттем. Ни алдым мин аннан?! Я?

Ә д һ ә м. Хурия дим...

Р ә ш и д ә. Әйтеп куансын. Әллә кабат очрашабыз, әллә юк. Хатыныңның кем икәнен аның янында күреп кал.

Х у р и я. Кайтам да тиешле кешеләренә тапшырам мин аны. Алсыннар чебен җанын. Мәетең өстенә менә аны чакырам! *(Рәшидәгә күрсәтә.)* Сөекле төпчек улын көн яктысында күреп китсен. Болары гына җитмәсә...

Ә д һ ә м. Туктасана! Ватык самовар кебек гөжли...

Х у р и я. Гөҗләү түгел, шартларсың монда. Күрә торып улын әҗәлгә... *(Еламсырый.)*

Ә д һ ә м. Теленне авызлыкла азрак.

Р ә ш и д ә. Ә син, килен, бүген олы хата ясадың.

Х у р и я. Нинди хата? Әйт, нинди хата?

Р ә ш и д ә. Хатаңны үзең дә аңлап алдың, зирәклегең юк түгел. Иреңә ияреп акча таларга килгәнсең. Үзе генә чакта гаярь иде, хәзер әнә икеләнә. Әнкәсен этләрдән талатасы килми.

Х у р и я. Мине эт белән тиңлиләр. Әдһәм!.. *(Рәшидәгә.)* Балаңны гөлдәй итеп карап торган намуслы хатынны эт дидеңме?!

Әдһәм. Ярар дим, шыңшыма. Туйган.

Хурия. Кайтып керәсеңне онытма! Ачкыч миндә.

Рәшидә. Шулай, улым. Акчам юк.

Хурия. Җәһәннәмнең жиденче катыннан эзләп табарсың. Баланы суйдырасың килмәсә... *(Агачлыкка ымлый.)*

Әдһәм. Я дим, Хурия. Дөньяның асты өскә килмәгән. Тирә-юньдә кешеләр дә йөри.

Хурия *(кинәт ялварып)*. Теләсә ничек итеп хурла. Эт диген! Хайван диген! Акча гына тап. Улыңны йолып аласы бар! Улыңны!

Әдһәм *(паузадан соң)*. Әни, минем хәлне аңладың. Кызган, чын күңелемнән дөресен әйтәм. Көч юк миндә. Тукмар идем, тамырыңны кортыр.

Рәшидә. Ярый, актык чиккә терәлгәнсез икән, бераз табармын.

Хурия *(Әдһәмне арттан йолыккалап)*. Тизрәк сорап кал! Күпме бирә?! Ела инде.

Рәшидә. Күпме табачагымны белмим. Безнең монда акчалы халык юк. Алай да бурычка алып торырмын.

Әдһәм. Бурычка?! Бурыч муенга бәйләнгән таш диден...

Хурия. Дәшмә, юньсез.

Әдһәм. Син яманлама аны! Әнә, бурычка булса да таба.

Рәшидә *(үртәп, тегеләрдән котылырга теләп)*. Безнең картлар бик елгыр, машинагызның тәгәрмәчен чалдырмасыннар.

Хурия. Ә?!

Әдһәм. Шаярма. Әйдә, китеп торыйк.

Хурия. Сузмасын иде инде... Кайтып житәсе дә бар...

**Чыгалар. Рәшидә ялгызы. Миссәр керә.**

Миссәр. Киттеләр. Ай-һай озак гәпләштегез. Күзәтеп тордым. Рәшидә-әү! Нинди котсыз кешеләр. Ни йомышлары бар икән синдә андыйларның!?

Рәшидә *(кармак сабын тотып ала)*. Бу күл тирәнме, Миссәр абзый?

Миссәр. Шактый диләр. Үлчәгәнем юк, Рәшидә.

Рәшидә. Чоңгылдыр. Суы да салкын. Син, Миссәр абзый, гел күлгә карап утырасың. Нинди уйлар килә башыңа?

Миссәр. Төрле чак булды. Элек уйлар чуалчык иде, хәзер, үзең дә белеп торасың, гел бер тирәдә йөри.

Рәшидә. Шушы күл төбенә чумып мәңгегә югаласы килгән вакытлар да булгаладымы?

Миссәр. Ни булды сиңа, Рәшидә? Бер чакта да күз яшеңне күрсәтмәгән идең, хәзер атна буе жаныңа урын таба алмыйсың?! Олы кешегә кинәт жил кагылса, хәтәр!.. Сөйлә! Теге юньсез кешеләр ни дип килгәннәр? Белдем, алар машина юган булып, сине көтеп, син чыкканны сагалап торганнар. Сиздем, алар синең ялгыз калган чагыңны көттеләр. Баядан бирле күзәтәм! Ә сине... атна буе гажәпләнеп сагаладым! Тиешле сүземне дә ашык-пошык кына әйтергә мәжбүр булдым.

Рәшидә. Шулай ук булдымыни?

Миссәр. Сиңа бирәр бәла-каза килдеме әллә?

Рәшидә. Куйчы, Миссәр абзый. Дөнья белән эшен өзеп туры юлга чыккан кешене нинди сикәлтә көтсен ди тагын?!

Миссәр. Хәзер эзләрен сытам мин аларның. Хәзер! Көчем житмәсә, әнә, Расимне чакырам. Ул да йөри илереп! Бер очтан үзенең арт сабагын да укытасы бар.

Рәшидә. Тимә аңа. Йөрсен шулай. Теләгәнчә.

Миссәр. Нигә тыныч түгел син? Нигә тыныч түгел без?!

Рәшидә. Ил тынычмы? Жиркәебез тынычмы?!

Миссәр. Юк, син бүген үзең турында гына сөйлә.

Рәшидә. Миссәр абзый, син миңа бераз акча бирә тора аласыңмы?

Миссәр. Акча диденме?

Рәшидә. Мин өлешләп, пенсиямнән ваклап-ваклап түләрмен. Ходай кушса, бурычлы булып үлмәм.

Миссәр. Ни хажәтең килеп чыкты але алай? Кичтән сорамадың, иртән очрашканда да берни әйтмәгән идең. Ни тынычсызлый сине? Хат-мазар алмадың. Налог агенты да күренмәде.

Рәшидә. Миңа акча кирәк. Шул.

Миссәр. Бердәнбер шигем — алар! *(Читтәге Әдһәмнәргә күрсәтә.)* Акча сиңа кирәкме, әллә шул шыксыз йон төргәкләренәме?!

Рәшидә. Барыбер түгелмени? Сиңа мин түлисе.

Миссәр. Нишләп алай барыбер булсын? Мин сине үземә чакырдым. Көмешле Елгага! Бергә торырга! Ничек мин сиңа «бурыч!» дип акча бирә алыйм?!

Рәшидә. Аларга бирәчәгем калган икән. Түләнеп бетмәгән.

Миссәр. Ышанмыйм. Ас, кис, тура, син бурыч саклый торган кеше түгел.

Рәшидә. Нишләмәк кирәк соң?

Миссәр. Ярар. Бераз табармын. Мин

ул акчаны синең белән кавышып яши башлауга дип багышлап куйган идем. Җавабың әзерме? Нигә иң кирәген, шул турыда сөйләмисең син?!

Рәшидә. Җанны көйдерәсен. Мияссәр абзый.

Мияссәр *(өзеп)*. Күпме бирим?

**Рәшидә. Күпме бирә аласың инде?**

Мияссәр. Әллә күпкә өметләнәләрме мөртәтләр?!

Рәшидә. Күп кирәк диләр. Биш йөз.

Мияссәр. Күсе даруы ашаганмы әллә алар? Ятим карчыктан ярты меңне тапты-ралар. Бик нык юмартлансам да мин аларга йөз тәңкәдән ары, ну пүч, йөз ярым китсен, бирә алмыйм. Бирәм дә пумала белән куам. Яңадан эз дә бастырмыйм. Әнә, Рәсим дә килә. Икәүләп куабыз аларны. Рәсим, тизрәк атла! Тагын бер мәртәбә синнән көч-гайрәт кирәк.

Рәсим узып бара.

Рәсим. Вакыт юк, Мияссәр бабай.

Мияссәр. Кая киткән ул вакыт? Сатып эчмәгәнсеңдер бит.

Рәсим. Юк та.

Мияссәр. Шулай булгач?! Әле сине болай да күрәсе бар!

Рәсим. Тагын бәйләнәсезме?

Мияссәр. Бая узып барам, атасы белән пыр да пыр сөйләшеп яталар. Ата белән шулай сөйләшәләрме?

Рәшидә. Син аннан юкка ярдәм сорыйсың, Мияссәр абзый. Аның үзенә ярдәм кирәкмиме икән?!

Рәсим. Сез нигә миңа бәйләнәсез?! Күл буена да чыгарга ярамый башладымы?!

Мияссәр. Бәйләнү генә аз! Атаң урынында булсам мин сине дилбегә белән агачка бәйләп ярыр идем!..

Рәсим. Кыргыйлык ягында инде сез алайса? Оят, Мияссәр бабай, газеталар укыйсыз. Кулыгызда гел китап...

Мияссәр. Тәс сиңа! Шундый кызны рәнҗеттең, шундый ахак кызны!

Рәшидә. Егәрең булса, дөньяны колачлар идең, Мияссәр абзый.

Мияссәр. Әллә җавабың шул?

Рәшидә. Бер түмгәктән икенчесенә сикерәсең. Түмгәкләр бетмәс җир өстендә!..

Мияссәр. Хак! Әй, Рәсим! Тукта, тукта, китү юк. Синең кызган чак, минем кайнаган вакыт, икебез дә коры куык кияү егете, әйдә, теге әтрәк әләмнәрне интернат тирәсеннән өшкереп җибәрәбез.

Рәсим. Мин аларны белмим.

Мияссәр. Как так белмисен?! Кешегә хәсрәт китергәч әйбәт адәмнәр түгел инде.

Рәсим. Куып җибәргәч миңа бәйләнүдән туктыйсыңмы?

Рәшидә. Туктар ул!

Мияссәр. Бармыйм. Нигә юкка бер беребезгә бәйләнергә? Яшәсеннәр үзләренчә генә. Мин аларга тимим, алар миңа кагылмый.

Мияссәр. Юлбасарлар алар. Таларга килгәннәр!

Рәсим. Алайса, милиция чакыртыгыз.

Мияссәр *(Рәсимне әйләнеп чыга)*. Карыйм да, парин, исем китә. Кан иртә суынган синең. Алда ничек яшәрсең?! Шифан төс тә түгелдер әле синең ише юеш балакка!

Рәсим. Юлбасарлар... Яратасыз инде күперенке сүзләрне! Тормыш тыныч телле кешеләрне өстен күрә. Эшегез беткән, тамак тук, кайгыгыз юк, йөрисез шунда...

Мияссәр. Туктал диләр сиңа! Теге юлбасарны чакырып яллап тәки үзеңне тукмарбыз!

Рәшидә. Мияссәр, Мияссәр абзый!

**Шифан керә.**

Шифан. Нигә кычкырышасыз? Тавышыгызга кешеләр җыела. Әнә!

Рәсим. Минмени?..

Шифан. Анда әтиең белән талашкансыз...

Рәсим. Минем тормышыма бәйләнергә кемнең хакы бар?

Мияссәр. Тыел, егет, тукта.

Рәшидә. Үз ата-анаң белән дә аңлаша алма икән... Дөньяда моннан да зур газап юк. Балаң белән аңлаша алма!..

Мияссәр. Уйлаган алга килде: каршыбызда кыз бала! Әйт аның үз алдында: ни гаебе бар аның? Нигә кагасың аны?!

Рәсим. Әйдә, Мияссәр бабай, теге юлбасарларны куабыз! Минем бокстан разряд...

Шифан. Мияссәр агай, кан басымыгыз күтәрелмәсен. Керик, үлчәп карыйк. Дарулар бирермен.

Мияссәр. Басым күтәрелде, сизәм. Шуны төшерергә маташам да! Яле, Рәсим атла алга! Егетлекне күрсәтик. Постой! Әүзең?! Нигә җавап бирмәдең баягы сорауга? Безнең ишеләрне явызлардан аралыйсы урынга, үзең дә Шифанны кимсеттең түгелме?!

Шифан. Заманы шулайдыр, Мияссәр агай, үзгәргәндер. Без монда, күл буенда яшәп, арттарак калганбыздыр. Әйтмәгез аңа авыр сүз.

Рәшидә. Хак та. Нигә табалыйсың син аны?

Мияссәр. Үзе белә! Синнән-миннән артык укыган. Колхоз акчасына... Белмиме соң?!. Эх, шулай ук юкка яшәдекмени, Рәшидә-әү! Һәммәсе бушка, тиккә булып чыктымы? Әнә бер яшьрәге көпә-көндез акча талап йөри... Бездән соң бу җирдә сез каласы бит, Рәсим! Син торып каласы!

Рәшидә. Өметсезләнмә бигүк, Мияссәр абзый, монда Шифан бар. Ул кала. Вәгъдә биреп тә өйләнмәү хәсрәтенең олысы, кызым, нишлисең бит, түз. Түз!

Мияссәр. Әллә бу бик азмы? Кеше күңелен рәнҗетүе өчен мактаргамы аны? Беребез вәгъдәсен бозса, икенчебез алдашса, өченчебез урлашса... Якты көнне, якты исемебезне ничек саклап калырбыз соң?!

Рәшидә. Рәсим улым, син Мияссәр бабаңның тузынуына артык игътибар итмә.

Рәсим. Әйдә әле, Шифан.

Рәшидә. Ул бер төрле әйтер, мин икенчерәк... Һәркемнең үз үлчәве бар.

Мияссәр. Чыпчыкка үз адымы да зур димәкче син, Рәшидә-әү!

Рәшидә. Кеше сүзе кешегә ярамас. Әгәр тыныч яшисең килә икән, миннән сиңа бер генә киңәш: өйләнмә!

Шифан *(бик борчылып)*. Рәшидә апа!

Рәшидә. Бәхетле картаясың килсә, син дә кияүгә чыкма. Юләр буларсың.

Мияссәр *(таң калып)*. Ни әйттең син, Рәшидә-әү!

Рәшидә. Күпме яшәп, күпме газапланып ирешкән акылымны әйттем. Ачы тәҗрибә авазын...

Мияссәр. Юлны белеп тә, адашканга кире якны күрсәттең түгелме?!

Рәшидә. Үзем белгәнчә әйттем, гаепләмәгез.

Мияссәр. Ничек әйтә алдың мондый суык сүзләрне?! Шушы сүзләрне әйтерлек ук күңелең каттымыни?!

Рәшидә. Беләсең ич. Сорама артыгын.

Рәсим. Да-а... Ишеттеңме, Шифан?

Шифан. Син, Рәсим, бар, моннан ераграк йөр. Рәшидә апа, әйдәгез, керик. Ятып торырсыз, ял итегез. Башыгыз авырта булыр, куе чәй эчертермен! Бик кайнарын ясап бирермен.

Рәшидә. Рәхмәт, балам, бер төшем дә авыртмый.

Рәсим. Менә бу киңәш! Акыл! Аңладыңмы, Шифан?

Мияссәр. Син, егет, чынлап та читтәрәк йөр әле!

Рәсим. Ачы тәҗрибә авазы! Өйләнеп, бала үстереп кем рәхәт күргән?! Балачагымнан интернат ятимнәрен күрә килдем!

Рәшидә. Син. Шифан кызым, рәнҗемә миңа. Соңыннан, татыгач, барын белгәч, күргәч, миңа рәхмәт кенә укырсың. Читен ул семья хәлләре! Былтыр ничәү идек тә, быел күпмегә арттык? Әниең яңа бина салдырырга йөри, Рәсим улым... Ә болай, гомергә ялгыз калсаң, рәхәт! Кайгың бар икән — берүзең. Сөенечең килә икән — бер башың. Ялгыз кеше дә сөенечен таба ала! Таба!

Мияссәр. Менә сиңа Рәшидә-әү! Менә сиңа олылар киңәше! Рәсим, Шифан, эндәшүе сезгә түгел аның, ялгыш аңламагыз! Рәшидә апагызның миңа җавап бирүе! Миңа. Шулай бит, Рәшидә-әү!

Рәшидә. Сиңа да, үз-үземә дә. Балаларга да!

Мияссәр *(арбаны тартып тиҗаклап йөри)*.

Әлли-бәлли, бәү-бәү,
Йокла, йокла, йом күзең.
Төнлә йокың кала да,
Елап үтә көндезең.

Шифан. Аягың сызлыймы, Мияссәр агай?

Мияссәр. Бодай бөртеге хәтле генә миңа ярчыгы утыра анда. Тез капкачында. Ай-һай, Рәшидә-әү!

Рәшидә. Чапма алайса, тигрәк утыр.

Мияссәр. Әллә йөрәккә дә миңа ярчыгы барып тиде инде, сулкылдый.

Рәсим. Шифан, әйдә әле.

Шифан. Рәшидә апа сине коралландырдымы? Ашыгып һөҗүмгә күчәсеңме? *(Куллары күтәрә.)* Мин бирелэм. Әмма синең белән беркая да бармыйм. Аягымны да атламыйм... Монда яралылар барында, мин, шәфкать туташы... Китә аламмы?!

Мияссәр. Сакалыңны кырып ыргытыйммы, Рәсим?! Кер! Бушлай!

Рәшидә. Рәнҗемә егеткә, Шифан... Рәсим турысын әйткән, алдап-юллап маташмаган. Шуңа куан!..

Мияссәр. Ни булды сиңа?

Рәшидә. Инде чират миңа җитте! Миңа ни булганын күрмисеңмени? Колачы белән дөнья иңли торган җан!

Мияссәр *(күрсәтеп)*. Тагын бер кат сорыйм, алар гаепләме?!

Рәшидә. Кем белсен... Төп гаеп бәлки миндәдер?

Мияссәр. Син нәге җанда нинди гаепкыек булсын! Үз чордашларымның нинди авыр, данлы юл узуларын беләм. Нинди

кыеннарда да намусыбызны сатмадык. Гомерең буе колхозда. Кышын-җәен эш-хезмәттә. Орденың бар! Курорт күргәнең юк, диңгезнең ни икәнен дә белмисең. Тамагың кайчан туйды? Әһә! Ә туган илгә синең кул аша күпме икмәк узган!

Ш и ф а н *(күзәтеп карап)*. Рәшидә апа, бу кеше сезнең янга элегрәк тә килгәләде. Исемә төште! Шул! Үзе! Ул килүгә сез каушап каласыз да, китүенә чирли идегез. Басымыгыз уйный.

Р ә ш и д ә. Әйе. Хак.

Р ә с и м. Китәбезме без, Шифан, юкмы? Бәлки минем дә ярам ачылгандыр.

Ш и ф а н. Синең тәнең корыч, тирең калын. Ачылмас!

М и я с с ә р. Кем ул?!

Р ә ш и д ә *(газапланып, гасабиланып)*. Бу котсыз кеше минем улым.

Һ ә м м ә с е б е р г ә. Улыгыз?!

М и я с с ә р. Булмаганны! Шаяртма!

Р ә ш и д ә. Әле бусы төпчеге. Тагын икәү бар минем, Мияссәр абзый.

М и я с с ә р. Менә сиңа вак бәлеш! Пешсә дә авызга сыймый!.. Ә мин аның чак кына ипи шүрлеген җимермәдем.

Р ә ш и д ә. Өчесе дә сау-сәламәт. Ә мин монда ятимнәр арасында ышыкланып ятам. Ышанмыйсыңмы, Шифан! Син дә белеп кал, Рәсим улым. Сиңа «өйләнмә!» дигәнмен икән, юкка түгел. Ә сиңа «чыкма кияүгә!» дип үгет биргәнмен икән, кыланып түгел. Тормыш өйрәтте ул шыксыз ымнарга, бары тик шул гына.

М и я с с ә р. Өч улың?! Өчәү!.. Ә Көмешле Күлдә безнең өй турында өч каен. Утыртма каен агачы, кайгыга батарсың, диде миңа күршеләр... Агачларым зур инде хәзер. Кайгым да бәләкәйдән түгел...

Р ә ш и д ә. Хәйлә белән монда урын алган икән дип рәнҗемәгез миңа. Юк, аңлата китсәң озак та, авыр да... Балаларны артык иркәләдек. Яраттык! Бары шул безнең гаебебез. Җилкәдән бик озак төшермәдек, муенга алар үзләре менеп атландылар. Актыккы сеңремне дә алдыгыз. Ә син «Бергә булыйк!» дисең, Мияссәр абзый. Я, була аламмы мин синең белән?! Була аламмы? Шундый хәсрәт төяп бусагаң аша атлап керә аламмы?! Соңыннан барын да белер идең... Ничек яшәр идем мин калган көннәремдә? Кояшка карый алыр идемме?! Авыз тутырып әйткән сүзем һаман бер: өйләнешмәгез, Рәсим! Шифан әйбәт кыз, сүз дә юк... Ә нинди заман килер? Балаларыгыз кем булып үсәр? Шуннан куркыгыз!

Р ә с и м. Рәхәт булып китте бит әле, әй! Бөтенесе, олысы-кечесе «өйлән, өйлән!» дип туйдырып бетергән иде. Ниһаять! Бер чын сүз! Туры сүз! Рәшидә апа, сез бу сүзне үз тәҗрибәгездән чыгып кына әйтмәгәнсездер, мөгаен?!

Р ә ш и д ә. Миндәйләр азмы әллә? Кими барабызмы?..

М и я с с ә р. Ну кирәген бирәм моңысының! Теге уларыңны да эзләп табам. Рәсим, ярдәмең хәзер конкретно кирәк! Разрядың бар икән, давай, теркелдә!

Р ә с и м. Хәзер барырга да була!

Ш и ф а н. Менә хәзер барырга ярамый да ярамый сиңа. Хакың юк.

Р ә с и м. Нигә булмасын!

Ш и ф а н. Син дә үз ата-анаңның өметен алдадың?!

Р ә с и м. Мине таш дип беләсеңме? Бу гыйбрәтләр мине борчымыймы? Уйландырмыймы?! Рәшидә апа кызганыч түгелме миңа?!

М и я с с ә р. Кызганасыңмы?

Р ә с и м. Теге уларын да эзләшәм мин сиңа, Мияссәр бабай!

М и я с с ә р. Кешегә әверелә башладың алайса! Йөнтәс маймыл идең, хәзер агачтан төшә башладың! Әгәр теге чучкаларны да аз-маз уйландырып тукмап җибәрә алсак, томам кешегә әйләнәсең!

Р ә с и м. Көлмәгез инде, Мияссәр бабай.

М и я с с ә р. Елап та булмый.

Ш и ф а н. Соңгы сүзем: син дә алар кебек үк кансыз, шәфкатьсез.

Р ә с и м. Алай каты хөкем итмә, Шифан. Өзмә өметеңне! Әллә ничек булып китте әле. Рәшидә әбинең өч улы исән! Өч! Үз балалары! Күз алдыңа китереп кара әле! Китереп булмый! Әллә ничек күз аллары яктырып китте, яхшырак күрәм кебек! Күлнең суы күе зәңгәр икән. Тирән җирләре яшькелт! Ә сез яр читендә басып торасыз, Мияссәр бабай. Рәшидә апа да синнән ерак түгел. Һәм бер читтәрәк мин... Әллә нигә күңелгә тирән уйлар агыла...

Ш и ф а н. Кыланчык! Маймыл!

М и я с с ә р *(Әдһәмгә кычкыра)*. Әй син, карачкы! Саламторхан! Кил монда.

Р ә ш и д ә. Нигә чакырасың аларны?

Р ә с и м. Әйдә, үзебез барыйк.

Р ә ш и д ә. Хак юлга төшерермен дип уйлыйсыңмы?

М и я с с ә р. Ятып калганчы, атып кал. Вакыт!

**Әдһәм белән Хурия керәләр.**

Хурия. Нигә чакырасыз безне? Абау, чырайлары. Күл ашаганнар.

Әдһәм. Без беркемгә кагылмадык. Әйбер-карага тимәдек.

Миясәр. Килегез, кил. Якынрак. Менә шулай. Я?!

Әдһәм. Килермен дә, китәрмен дә.

Миясәр. Берниндән дә курыкмыйсың алайса?!

Рәсим. Беркемнән дә?!

Шифан. Рәсим, катышма. Кеше хөкем итәргә әле синең хакың юк.

Хурия. Хөкем?! *(Миясәргә.)* Син, карт пәри, дөньяның баш-аягын бутама. Калдык-постык көченне үзең өчен сакла.

Миясәр. Сәгать сукты, чык уртага! Әйт, кем басып тора синең каршыңда?! Яхшы кара, бутама! Таныйсыңмы?

Әдһәм. Мин болай да бик әйбәт күрәм.

Миясәр. Күргәч, әйт безгә. Кем?!

Рәшидә. Я, ходай!

Рәсим. Ну!

Әдһәм. Бумы?..

Хурия. Балаларын юньле тормыш күтәргә өйрәтә алмыйлар да менә хатыннары газап чигә аннары! Кемлеген аның үзеннән сорагыз сез! Миннән! Сөйләп бирә алам!

Шифан. Сез дә сөйләгез.

Хурия. Менә, матуркаем, ышанырсыңмы? Авылның күпер төбенә кабык арбадан төшеп калган бер бичарасы иде. Мәхлук! Җәлләп шәһәргә алып киттем. Кеше иттем. Квартиралы! Шунысы яман — эчте. Бурычка батып бетте. Карт уйнап акча оттыра! Бүгенгесе көндә мең сум бурычы гына бар аның!

Миясәр. Белүемчә, аның бурычы алай гына түгел.

Хурия. Әллә?!

Миясәр. Менә хәзер ачыкларбыз!

Рәшидә. Чыннан да әчәсеңме, улым? Элек-бер дә капмый торган идең ләбаса. Әйт, бурычың күпме?!

Хурия. Улым?! Үләм, валлаһи!

Әдһәм. Минме? Минемме?!

Хурия. Әчә! Исәп карагыз! Фу, күпчеп беткән.

Рәсим. Сездән сорамадылар, апа.

Миясәр. Яле, яле.

Шифан. Китик моннан, Рәшидә апа. Авыр монда, чиген.

Рәшидә. Улымның әҗәтенең күпмелеген тәгаен генә беләсем килә.

Миясәр. Аның күпме бурычы барын үзем әйтәм!

Хурия. Әллә синнән дә алып торды, мәрхәмәтле карт?!

Миясәр. Әтисенең якты исеме, әнисенең якты көне алдында аның бурычы — мәңге түләп бетерә алмаслык!

Хурия. Аны гына әйтсәң ярый.

Шифан. Апа!

Хурия. Хәзерге балалар ата-ананы карамый. Ата-ана гомере буе бала тәрбияли. Үзебез дә бер имгәк үстереп ятабыз, беләм.

Шифан. Әйе, киявгә чыкмыйм мин, Рәшидә апа.

Рәсим. Ашыкма, сиңа тәкъдим ясаган кеше дә күренми әле.

Шифан. Тәкъдимнәре белән соңга калдылар.

Миясәр. Үзем яучы булып килсәм, нибуч, чыгарсың!

Хурия. Ярый, акчабызны бирегез дә, без китик. Кеше машинасы. Без бит ярлыбагай, ата малы белән калмаган, булганын бөртекләп җыйган.

Миясәр. Бирәбезме акча, Рәшидә-әү!

Хурия. Нигә дәшмисең, Әдһәм! *(Шыпырт.)* Әй ачкычы миндә, баскычта кунарсың, чамала!

Әдһәм. Әйе. Бу минем әнием.

**Әсма керә.**

Әсма. Ник болай җыелдыгыз? Кыяфәтләрегез дә мазак. Сугышырга торган кыдрач әтәчләр шикелле. Болары кемнәр? Кем янына килгәннәр?

Әдһәм *(Хуриягә, шыпырт).* Директор!

Миясәр. Кемнең кем икәнен, кемнең кемгә күпме бурычы бар икәнен ачыклыйбыз.

Хурия *(кычкырып).* Директормы?

Әдһәм *(качарга ымлап).* Үзе!

Хурия. Әһә!

Рәшидә. Китегез. Барыгыз, юлыгызда булыгыз. Сораганыгызны табып салырмын.

Миясәр. Алай ук димә, Рәшидә. Акча үзебездән дә артмас.

Хурия. Кемнең кем икәненә пичәт сугу кирәк. Хөрмәтле иптәш директор бик вакытлы килде. Кайберәүләрнең балалары барлыгын яшереп, хөкүмәтне бер яктан, уларын икенче яктан мыштым гына имеп ятканын ачыкларбыз.

Әдһәм. Җиттеме сиңа, Хурия, юкмы?!!

Рәшидә. Зинһар, күземнән генә югалыгыз.

Миясәр. Чү, теләләр икән, аның белеп китсеннәр! Исемең бармы, синең, я?!

Ә д һ ә м. Әдһәм лә мин!

М и я с с ә р. Бездә дә бер зур сүз бар иде, Әсма, олы киңәш. Без, Рәшидә белән икәүләп, минем авылга, минем йортка күчеп китәргә мәслихәтләштек. Ягъни, синең элеккеге әнкәң белән була инде ул, Әдһәм Хуриянең ире!

Х у р и я. Әдһәм, анаң кияүгә чыга! Бурычын калдырмасын!

Ә д һ ә м. Тьфу! Тел түгел, чалгы янавычы.

Х у р и я. Бурычың биш йөз! Төп-төгәле! Китсә тәтемәс!

Ә с м а. Мияссәр абзый, бу сүз уен түгелдер дип беләм. Гәрчә син шаярткаларга яраткалыйсың.

М и я с с ә р. Ялгыз яшәүне дошманыма да теләмим. Хәтта менә бу ала күзгә дә! Без татыдык, мәҗбүр идек... Ә берәүләр *(Рәсимгә ымлый)* ирекле баштан ялгыз яшәргә маташалар!.. Авылны, туган җирләрен ятка калдырып китәләр.

Р ә с и м. Мияссәр бабай! Алай ук димә әле син!

М и я с с ә р. Әйтергә хакым бар! Җан әрнүем хак!

Р ә с и м. Мин сезне аңлыйм шикелле.

Р ә ш и д ә. Мин риза, Мияссәр абзый. Сине кызганам! Җаның һаман тере ич синең! Тырпылдый торган җан! Бергә булыйк. Гомеребезнең аяныч азагын бергә уздырыйк. Җиңелрәк булыр.

М и я с с ә р. Рәхмәт, сиңа, Рәшидә-әү! Какмам, рәнҗетмәм. Бергәләп яшәү икебезгә дә җиңелрәк булыр. Кайтам да тәрәзә такталарын каерып ыргытам.

Р ә ш и д ә. Мин пыяла тузаннарын юармын!

М и я с с ә р. Дөрес! Ичмасам, тагын бер авыл йортына нур керсен!

Ә с м а. Мин дә хуплыйм. Гәрчә монда, бездә диюем, начар да түгел... Алай да...

Р ә ш и д ә. Көч кенә бетеп калды. Юкка сарыф иттек без аны.

М и я с с ә р *(һаман Рәсим ягына ишарәләп)*. Яшьләр оятына көч килсен.

Х у р и я. Әдһәм!

Ә д һ ә м. Кирәкми миңа акча. Машина да кирәкми.

Х у р и я. Алайса, барыгыз да белегез! Менә ул, ягъни минем ир җәфам, Рәшидә апа дигәннәренең улы!

Ә с м а. Беләм. Мин Рәшидә апаның өч улы барлыгын әллә кайчаннан бирле беләм.

Р ә ш и д ә. Ничек?

Ә с м а. Безнең арада күп яшәгән, күпне кичергән затлар да бар. Аларның эч серләрен ачып, хәсрәтләрен арттыруның һичнигә хаҗәте юк.

Ә д һ ә м. Без барын белә торып аны монда тоттыгызмы?

Ә с м а. Күрәсең ич.

Ә д һ ә м. Хурия, Ишеттеңме?

Х у р и я. Сиңа ни кирәк соң?

Ә д һ ә м. Миңа бүгеннән берни дә кирәкми.

М и я с с ә р. Ничек? Алай булмый инде. Менә Рәсим алма кебек ярыннан баш тартты. Димәк, аңа без белмәгән нидер кирәк. «Машина кирәкми», дисең. Нидер сиңа да кирәктер инде? *(Шифан елый.)* Елама дим, түкмә яшеңне.

Х у р и я *(Әдһәмгә сырпаланып)*. Аңа мин генә кирәк.

Ә д һ ә м. Син дә кирәкмисең. Әгәр әни рөхсәт итсә, Мияссәр каршы төшмәсә, мин дә алар белән авылга кайтыр идем. Үз авылдашларымнан оялам. Йорт та юк. Көмешле Күлгә! Комбайнчы идем. Уч тутырып акчасын ала идем. Почетым бар иде! Кеше идем. Узганда сокланып карап калалар иде. Минем төп урыным авыл булган! Хурия! Өч бүлмәле квартира, ике машиналык акча, кием-салым — һәммәсе сиңа калсын. Шулар бәрабәренә мин синнән котылыйм.

М и я с с ә р. Әй, Рәшидә-әү! Ул бит әле алай карт түгел, өшәнгән генә. Без малайлы булабыз түгелме? Әй, Әдһәм! Кайту белән мин сине өйләндерәм. Безгә касмак башлы кара малай алып кайтасыз! Бүләк әзер, тот бабай арбасын!

Р ә с и м. Мияссәр бабай, коляска безгә түгелмени?

М и я с с ә р. Базардан бәрәңге ташыргамы?

Ә с м а. Улым, ачыклап сөйлә.

Р ә с и м. Шифан, читтә боегып торма алай.

Ш и ф а н. Нишлим соң? Төшеп биер идем, сәбәбе юк.

Р ә с и м. Сиңа сүзем бар!

Ш и ф а н. Миңа?

Р ә с и м. Яшьлек мәхәббәтем бәрабәренә мин сиңа үземне бүләк итәм. Гомерлеккә? Ризамы? Бирәсеңме кулыңны?!

Ш и ф а н. Рәшидә апа ни әйтер әле!

Ә д һ ә м. Әни, әйт.

Р ә ш и д ә. Бир кулыңны, балам. Бергә булыгыз.

Ә с м а. Сөендердең, улым. Тормышыбызны бизәдең. Анда әтиең пыр туза югыйсә.

Рәсим. Ул пыр тузганга түгел лә! Үз күңелем, үзем... Мияссәр бабай! Шифаннар йортына миннән яучы булып бар!

Әдһәм. Үзем кияү егете!

**Рәсим. Ефәк баулы былбыл кошны** алып кайтыйк, әни. Рәнжетмик саф күңелләрне. Шәһәргә китәм икән, бер елдан әйләнеп кайтам.

Шифан. Чын күңелдәнме, Рәсим?!

Рәсим. Ризамы син?

Мияссәр. Ризалыкны яучыга гына белдерәләр. Кайгырма, Әдһәм улым. Арбаның менә дигәнен алып бирермен. Үзенә тиң былбыл сиңа да табылыр, ил-йортыбыз буш түгел, шөкер! Бар анда затлы жаннар, бар! Ә хәзер! Тезелегез! Кыз йортына барабыз. Шифан, йөгер! Килэләр, диген.

**Шифан көлә-көлә чыгып китә. Һәммәсе дә тезелешеп, жырлая чыгып бардылар:**

**Ефәк баулы былбыл кош**
**бардыр синең илеңдә!**
**Каеш баулы лачын кош**
**бардыр минем илемдә!**

**Арба тәгәри, алар жырлый. башта кыяр-кыймасрак торган Әдһәм дә аларга иярә, Хуриягә бер тапкыр да борылып карамый.**

---

Тукайның 100 еллыгына

# КАЗАНДА ТУКАЙ УРЫННАРЫ

**Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч — шул булды эш:**
**Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакъли алмадым.**

Г. Тукай. «Кыйтга», 1913.



Элекке Клячкин больницасы бинасы (хәзерге К. Нәҗми һәм Островский урамнары чаты). 1913 елның 26 февраленнән 15 апрельгәчә — вафатына кадәр Г. Тукай шул больницада ята. Бинага мемориаль такта куелган.

Татьяна Зуева рәсеме.

## Марсель Галиев

# НИГЕЗ

ПОВЕСТЬ

### I



Көтү чираты, ниһаять, безнең капкага житте. Иртәгә тау-үзәннәргә мин хужа булачакмын. Теләсәң — кыргый ташларга исемеңне язып кит, теләсәң — кычкырып жырлап жибәр, теләсәң — ике бармагыңны кабып, әче итеп сызгырырга була — жил чыгарырсың дип, берәү дә бәйләнмәс...

Ә кичен талчыккан гәүдәмне ястыкка таратып ташлауга, күз алдымнан, бөдрә болытлар булып, сарык көтүе үтәр, мекердәп куйган бәрән тавышлары колагымда кабат-кабат яңгырар, сарыкларның миңа төбәлгән беркатлы-ышанучан күзләре йокылы күгемдә йолдызлар булып кабыныр әле...

Хәзергә мин ишегалдында. Әни аранда сыер сава. Кичке талгынлыкта чиләккә бәрелеп чыжылдаган сөт исе борынны рәхәт кытыклый. Кояш кызарып баеса, көн аязга булыр, ди өлкәннәр. Сүрәнәя барган кояш, ак тәлинкә булып, әкрен генә офыкка тәгәри. Менә ул күзгә күренеп тулыша, зурая, авырая башлый һәм Сарай тавына якынайганнан-якынная бара. Миңа калса, бүгенге кояш тау артында эреп югаладыр да, икенче көнне иртән каршы як тау артыннан бөтенләй яңа кояш чыгадыр кебек.

Озын көнне үткәргән кояш шулкадәр арыгандыр кебек тоела миңа. Әнә ул, тауга утырып, бер мизгел ял итеп ала. Әти дә бит шулай: эштән алҗып кайткач, бер тын баскыч төбендә утырып тора. Тау өстенә менсәң, кояшның тирән итеп бер сулыш алуын да ишетерсең шикелле.

Мин, йөгереп килеп, баскычтан абзар түбәсенә күтәреләм, кояш кыерчыгы тау артыннан соңгы тапкыр күз кысып алуга, бөтен күк йөзенә җете төсләр сирпелә, су буендагы кара-кучкыл өянкеләр, күе яшел төскә кергән таулар серле бер тынлыкта оеп кала.

Көн белән төн алышыр минуттагы шушы манзара уртасында мин күпмедер вакыттан соң гына исемә киләм. Абзар түбәсеннән төшкәндә искәреп алам: өйалды ишеге төбенә хәтле ачып куелган. Йөгереп киләм дә караңгыда шәйләгән аксыл шәүләнең дулкын-дулкын сырлы мөгезеннән әләктереп, тышка сөйри башлыйм. Кәҗә, минем кулны каерып, он әрҗәсенә тагын борынын төртеп ала һәм, аякларын алга җибәреп, өстерәлеп чыга башлый. Каян килгән аңа шундый акыл? Ишеккә килеп, каешыннан тартсаң, эчтәге келәнең ачыла икәнен карап торып

өйрәнгән диярсең — теше белән генә эләктерә дә... Әлегрәк ул үзе сыярлык кына ачып кирә иде дә, артыннан ишек ябыла иде, бурлыкта тотылгач, әнидән аңа нык кына эләккәли иде. Сыртын «кашыта» торгач, тәки өйрәнде бит: хәзер инде келә бавын теше белән аска тарта да, арт аякларына баскан килеш, ишекне стенага ук терәп куя. Ни дә булса эләктергәч, чыгып китәргә юл ачык дигән сүз. Әмма тояклары каты шул — өйалдына кергәнен барыбер ишеттерәләр. Тоякларына йомшак чүпрәк урарга да өйрәнсә, кәҗәне мин кешедән кала иң акыллыга санар идем.

Безнең кәҗәнең кушаматы — Алпамша. Ул нинди генә мутлык эшләсә дә, минем аңа кулым күтәрелми (сакаллы бит ул!) Алпамша минем юашлыкны белә, шуңа күрә артык көяләнми дә. Әнә бит, яңа гына бурлыкта тотылуын онытып, матур иренен кыйшата-кыйшата, күши бирә. Борыны онга буялган, сакал очы калтырып, пар мөгезе селкенә, ә үзе акыллы күзләрен миңа төбәгән. Укытучы шикелле сынап карый.

Сарыкка сакал куйсаң, бик мәзәк булыр иде. Акыллы, хәйләкәр булганы өчен кәҗәгә генә бирелгәндер шул ул. Ишегалдына үлән чемченгән сарыкларга хәзер мин йодрык күрсәтәм, барысы да кинәт кенә юеш танауларын күтәрәләр дә «ни булды?» дигән курку-аптырау белән миңа төбәләләр. Алпамша бөтенләй башка... «Нигә җүләрләнәсең, килешми болай»,— дигән шикелле мыскыллы күзләрен төбәгән. Аның мәгънәле карашыннан хәтта оялып куям. Ә ул, бер уч койрыгын горур чөеп, ыспай гына атлап китә. Алгы аяклары белән коймага таяна да, сузылып, чаган яфракларын кыерларга керешә. Шул ботакны сындырып бир үзенә — иснәп тә карамаячак. Кәҗәнең алдына ашарына салгач та вакыт-вакыт куып торырга кирәк — урлашам дип уйламаса, азыкның тәме булмый аңа, дип көлдерә безне әти. Чынлап та, бөтен нәрсә рөхсәт ителсә, киртәләр-коймалар, бикләр булмаса, үҗәт кәҗәләр, сакалсызланып, сарыкка әйләнерләр иде.

Алпамшага ни өчен сүз әйтмим — кызганам мин аны. Бер айлар элек булган фаҗигане ул үзе дә һаман оныта алмый бугай. Кайтмый калгалый торган гадәте бар иде аның. Төнгә калган сарык-кәҗәләрнең мәчет урынындагы яшел чирәмлектә төн чыгуы гадәти хәл иде.

Ул көнне иртүк авылга шомлы хәбәр таралды:

— Төнлә бүре килгән! Малларны кыерлап киткән...

Андый хәлнең булган юк иде бит әле дип, күпләр ышанмый торганда, кемнең — кәҗәсен, кемнең сарыгын бүре буганлыгы имеш-мимешкә әйләнеп, бөтен очка килеп иреште. Нидер сизенепме, әни мине иртәтеп тизрәк мәчет мәйданына ашыкты.

Чишмәгә төшә торган тар тыкрыкта хатын-кызлар җыелган. Бер кырыйда кызганыч тавыш чыгарып, якын килергә дә, ерак китәргә дә белмичә, безнең Алпамша тора. Кычытканлыкта ак мамыклы бәтие нәкъ тере кебек ята, эч тирәсендә генә канлы эз бар. «Каһәр суккыры, бөерен генә алган бүре»,— диештеләр өлкәннәр. Әни исә кәҗә бәтиен сыйпый-сыйпый елап җибәрде:

— Хараплар булды, хараплар гына булды, күңелем сизгән иде аны...

Кичә, эзләргә барыйммы дигәч, җибәрмәгән иде, ә хәзер әни бөтен гаепне миннән күрәдер сыман. Мин бер кырыйда куырылып басып торам, кырын күз белән генә Алпамшага карыйм, бөтен гаепне аңа аударасым килә. Ә ул, терелтегез бәтиемне, ярдәм итегез, зинһар, дигән өмет белән һәммә кешегә мөлдерәп карый.

Кәҗә бәтиен малайлар белән таллык кырыендагы чокырга илтеп күмдек. Балчык ташлар алдыннан мин аның мөгезен тотып карадым. Сап-салкын. Аның мөгез төбеннән тотсаң, шундый җылы, кулга рәхәт иде бит...

Соңыннан, малайлардан аерылып калдым да, елап җибәрмәс өчен, тал чыбыгы тешләдем. Әче тал кайрысы елыйсы килүне бетерә икән... Кинәт арттан тез астына нидер төрткәнгә борылып карасам... Алпамша килеп баскан, юашланып, миңа ышкына башлады. Күзләре тирәнәеп киткән, әчтән елый иде бугай ул. Мин аның йомшак мамыклы сыртын уңайга сыпыра башладым һәм аңа да әче кайрылы тал чыбыгы каптырдым.

Алпамша, бәтиен җуйганнан соң, берара боегып йөрде. Утын әрдәнәсенә дә ышкынмый, ярдан ярга да сикереп уйнамый, койма башына да үрелми, башын иеп, бер урында тик басып тора. Сакал очы, яңаклары гына селкенә, гүя ул үз-үзен юатып, әчтән нидер сөйләнә. Ә күзләре шундый моңлы, шундый моңлы...

Шул көннәрдә ул песи баласы белән дуслашып китте. Безнең песи бик мәзәк кыяфәтле: ике колагы, дүрт аягы кап-кара, калган җире апак. Әйтерсең ул колаклары һәм аяклары белән кара буяуга батып чыккан. Агартырга исәпләгәндәй, юынуны да ул аякларыннан башлый. Андый чакта мин аны үртәп җырлыйм:

Песи битен юына,
колак арты кап-кара...

Ул миңа күтәрелеп карый да, аңлап алгандай, кара тәпиен юешләп, колак артын ышкый башлый.

Кич җитсә, песи баласы Алпамшаның кайтыр вакытын сизенеп, кәҗәләр төркеменә каршы бара. Алпамша, төркемнән аерылып чыга да, аңа таба килә. Көнө буена бер-берсен күрми сагынышкан ике җанвар, урамда тукталып, борынга борын тигерешәләр: песи муенын суза, тегесе башын ия. Бу гайре табигый дуслыкка хәйран калып, күрше-тирәләр дә карап тора.

— Бәтиен сагына...

— Баласын җуйганга шулай инде ул, мескен,— дип, Алпамшаны җәллиләр.

Ишегалдына кайткач, песи белән кәҗә тагын борынга-борын тидерешәләр, песи моның белән генә канәгатьләнмичә, алгы тәпиен сузып, Алпамшаның башыннан сыйпап ала. Аның йомшак кагылуыннан кытыкланыпмы, кәҗә башын чайкап куя. Бераздан Алпамша үзенең зур гәүдәсеннән уңайсызланган шикелле сузылып ята, һәм песи аның куенына керә.

Песи баласы шуннан соң гел өйдә кунмас булды, аранда кәҗә белән бергә йокларга гадәтләнде.

Әлеге дуслык Алпамшаның кайгысын әкренләп онытырды бугай. Хәзер инде ул элеккечә: тиктормас, шук — койма, киртә белән бүленгән бакчалар янынннан тыныч кына үтә алмый.

Бу — минем ишегалды дөньясы.

Капканы ачып чыгуга, киң урам башлана. Каршыда чирәмлек. Бу яклап биш-алты өй рәттән баруга — авыл башы. Анда тармакланып күтәрелгән ялгыз өянке тора. Еракта, нәкъ олы юл турысында, шәфәкъ нурына гөмбәзе манчылган Чатыртау күренә.

Капкадан чыгуга, мин һәрвакыт иң элек Өянкегә карыйм.

---

Өянкенең дә балачагы, үткәне була. Кәүсәсенә еллар бөҗрасын өстәлгән саен, аның хәтере дә байый — арта баруын кешеләр беләләр микән?

Ул, яшел кабыклы нәзек, тал булып, дөньяга беренче тапкыр күзен ачканда, кыр-тугайлардан бүтән гасыр җиле исә, моржалардан бүтән гасыр төтене чыга, авыл урамыннан сыек тузан туздырып, җигүле атларда бүтән гасыр кешеләре уза иде әле. Аның иң беренче теләге —

бакча читәне аша үрелеп карау булды, әмма буе җитмәде. Кыска буйлы тал-тирәк, нәүмизләнеп, ихата эчен күзәтә башлады. Янәшәдә генә сиртмәле кое. Арырак салам түбәле өй. Әнә, болдырдан киндер ыштанлы, чигүле түбәтәй кигән малай йөгереп чыкты да ябага тубын тибеп җибәрде. Ишегалдында гамьсез генә чүпләнгән тавыклар, пырхылдашып, як-якка сибелделәр. Дәррәү купкан тавыштан куркып, песи баласы капка астыннан урамга чыгып шылды. Туры лапас астыннан карлыгачлар ук кебек тышка атылдылар. Һәммәсен хәрәкәткә китереп, нәни туп нәзек талның яшел кәүсәсенә бәрелеп туктап калды.

Кое сиртмәсе, шыгырдап, бер төшә, бер күтәрелә. Тимер кыршаулы агач чиләктән, шыбырдап, ләйсән тамчылар коела. Көянтә-чиләк тотып килгән хатын-кызлар арасында уен-көлке, үзара төрттерешү, җор сүз һич тә тынмый, чылтырап аккан суга кушылып ага бирә. Тал-чыбыкның күз алдында таштан-ташка басып йөргән чүәкләр, ялтыр башмаклар, читекләр бутала.

Өстә кояш кыздыра. Эссе... Ә агач чиләк, кое бурасының бозларына бәрелә-бәрелә, әле аска төшә, мөлдерәмә суын чайпалдыра-чайпалдыра, боз кисәкләрен китеп алып, әле өскә күтәрелә.

Янәшәдә генә салкын җир дымын шифалы су тәмен тою тал-чыбыкка рәхәтлек бирә. Аның тизрәк үсәсе, төпсез күктән туарылып аккан ак болытларга ябалдашы белән орынасы килә.

Тал-тирәк үсәргә ашыга. Давыт исемле түбәтәйле малай да әнә, ябага тубын алды да, сикерә-уйный, урамга чапты — ул да ятьрәк үсәргә ашыга, ахрысы.

Су буенда моңлы итеп күке кычкыра. Кайдадыр эт өреп куя. Күктә кояш кыздыра. Шулай тыныч кына кабатланыр сыман иде бу көннәр— айларга, елларга әйләнеп, бер көе генә кабатланыр сыман иде...

Гел бер урында гына тамырлар җибәреп үсәргә тиешлеген аңлаган тал-тирәк әкренләп ихата тирәсендәге шаулы тормыш белән яшәргә күнекте. Кое янында мәш килгән хатын-кызларның, читән буеннан сөйләшеп узган ирләрнең, капка төбендә гәп корган картларның сүзләрен дикъкать белән тыңлый торгач, тал-тирәк әкренләп кешеләр телен аңларга өйрәнде.

«Гомерем буе шушы очның гаме белән яшәдем мин. Кайсы гына өйнең капкасын киереп ачып, кемнәрне соңгы юлга озатканны да, олы юлдан сугышка киткәннәрне дә хәтерлим мин. Айлы төннәрдә күпме гашыйклар, күләгәле ягыма сыенып, бер-берсенә иң кадерле сүзләрне әйтешteләр — аларның сере миндә. Бәхет эзләргә чыгып киткән егетләрнең, тегермән үреннән күмелгәндә, соңгы тапкыр авыл ягына борылып карауларын да мин күрдем. Яфракларым телендә барысын да сөйли алам, тыңлый белгәннәр йөрәгенә хәтерем күчәр...

Сак кына сирпелеп киткән аваз да иң беренче минем яфракларыма килеп кагыла. Хәзер дә әнә теге очтан гармун, җыр тавышлары ишетелә түгелме? Таң белән, атларга төялеп, чалгыларын зеңгелдәтеп, ирләр печән өмәсенә киткәннәр иде. Шулар кайтып киләдер».

Яулык чөйгән хатыннар капка төпләренә чыгып баскан. Кичке урамда үзенә күрә бер бәйрәм төсе.

Атлар якыная. Өянке бер тавышны бүтәннәр арасыннан аерып ала. Әллә каян ук таный ул аны. Гармун тавышын басарга тырышып, Байтирәк җырлый:

Клубларда утлар янгач,
кинадыр дигән идем.
Чабатасын салып куйгач,
кунадыр дигән идем...

«Сугышка кадәр нинди гаярь тавышлы сылу егет иде бит. Ә хәзер

тавышы карлыгып, күкрәк читлегеннән интегеп чыга. Эчендә кайнаган дәрт-дәрманын тыя алмаганга, көчәнеп булса да, җырларга тырыша үзе.

Нинди гаярь тавышлы егет иде бит...»

Әянкенең арыган буыннары буйлап җылы дулкын, кичке тынлыкта оеган яфракларына күчеп, җиңелчә шыбырдауга әйләнде. Рәхәт тә, моңсу да иде аңа хатирәләргә бирелү...

---

Әни казан арасында нидер пешерелә, миндә кайгысы юк. Мин сөтле чәйне ашыгып кына чөмерәм дә бакчага чыгам. Кичке тынлыкта йокымсыраган агачлар арасында куе күләгәләр, кара күзле шәүләләргә әйләнеп, мине уратып алырлар кебек. Ешкынлыкка карамаска тырышыбрак, усак агачы төбенә урын җаям. Җилсез вакытта да салмак кына лепердәп утырган усак яфраклары астында йокыга китүе рәхәт. Өйалды баскычы да якында гына. Ә түрдәрәк — бер-берсенә тәрәлеп үскән шомырт, балан куаклары, сары алкаларын асылындырган чаганнар. Анда — шүрәлеләр оясы. Алар кояш нурыннан куркып, таң белән каядыр качып бетәләр — чыклы эзләре генә кала...

Гармун, җыр тавышлары якында гына ишетелә башлады. Онытып торам икән — бүген бит печән өмәсе! Әти дә шунда булырга тиеш. Әни искәрмәгәндә, тизрәк чыгып шылырга кирәк. «Иртүк торасың бар, трай тибеп йөрмә»,— дия башлар тагын. Мин дымсу-әчкелтем исле тәмәке түтәлен ерып узам да койма башыннан йомарланып урамга сикерәм.

Урам тутырып, җигүле атлар кайтып килә. Капка төбендәге утыргычта кичке эшләрен бетереп чыккан апалар утыра. Капка саен атлар туктала, ә җыр тынмый. Чалгысын печән астыннан суырып алган абзыйларның тиз генә өйгә кереп китәселәре килми. Чалгыларын коймага каптырып куялар да утыргычка, хатын-кызлар арасына кереп чумәләр. Китә көлеш, кычкырыш, уен-көлке. Атлар ары кузгала. Тояклары гармун көенә тыпырдап, биеп тора. Әнә, Нәүширван абзыйның аркылы такталы авыш капкасын өстерәтеп ачтылар. Арбадан ул үзе генә төшәрлек хәлдә түгел иде. Аны, култыклап, чирәмле ишегалдына алып керделәр. Ул арада инде баскычка биш чыгып кергән. Сабирәттәй калҗайган өйалды ишегеннән күләгә кебек кенә кереп китте дә, шартлатып, эчтән бикләп тә куйды. Аның бу гадәтен бөтен оч белә. Нәүширван абзыйның да елына бер шулай өмәдән йомшап, мәзәк хәлдә кайтасы һәммәсенә билгеле. Ирләр казык башына эленгән иске фуфайканы чирәмгә җәеп салдылар да Нәүширван абзыйны шунда яткырып китеп бардылар. Без, малайлар, киртә буена кызык карарга җыелабыз. Әтинең миңа сабаклы җиләк алып кайтасын белсәм дә, өйгә керәсем килми әле, аның гармунчы кырыенда җырлап барганын малайларның җилкәсе аша гына күзәткәләп калам.

Печәнчеләр өйләренә таралышып бетә. Атлар, чаптырып, югары очка менеп китәләр. Дыңгырдап барган соңгы арбадагы гармун тавышы гына өзек-өзек калтырап ишетелә.

Нәүширван абзый агач аягын дөпелдәтеп сала да борылып ята һәм карлыккан моңсу тавышка җыр сузып җибәрә. «Их, дускаем...» Шул вакыт калҗайган өйалды ишеге җиде тавышка шыгырдап ачыла, Сабирәттәй баскычка чыгып, нәкъ тегермәнче Сафа абзыйның күркәсе шикелле кабарынып, чәлдер-чәлдер килә башлый. Ачуланамы ул, яратып битәрләгән буламы — аңламассың. Ул кереп китүгә, Нәүширван абзый, башын күтәрми генә җырның икенче өлешен суза башлый: «...рәхәт яшә...» Өйалды ишеге тагын күгәненнән кубарлык булып ачыла, Сабирәттәй, мул күкрәген киереп, тагын чәлдер-чәлдер. Соңгы сүзләрен ул безгә атап ыргыта. Без киртә буеннан аэга гына таралышып алабыз да яңадан җыелабыз. Өченчесендә инде Нәүширван абзый карчы-

гының чыгып тормасын белә, башын күтәрә төшеп, иркенләп, җырны яңадан башлый:

Их, дускаем, рәхәт яшә,
миннән аерылгач та...

Җыр бетүгә, Нәүширван абзый, өйалды ишегенә таба борылып, йодрыгын уйнатып ала:

— Сине сагынып кайттыммыни мин сугыштан, убыр! Шушы киртә казыклары тартып кайтармаган булса...— дип, ул әллә нинди күкрәк тавышы белән ухылдап куя.— И-их, кайтма дип ни ялварды бит югыйсә, белмисез полякларның чибәрлеген! Брониславага җитәргәме синә, җен киптергән нәрсә! Кайта идеммени, шушы киртәләр сагындырмаса...

Ә без, иске чүлмәкләр, тимер кыршаудыр эленгән ярым авыш киртә казыкларына карап, тәгәри-тәгәри көләбез. Нәүшриван абзый, еламсырап, тагын җыр башлагач кына, бер-беребезгә төртешә-төртешә шымаябыз.

Җырлау түгел, җыларсың да
өзелеп-өзелеп сагынгач...

Бераздан Нәүширван абзый, үләнне сыдырып, агач аягын сузып җибәреп җайлабрак ята да озын итеп, каерып алып гырлый башлый. Киләсе печән өмәсенә кадәр ул бүтән инде полячкасы турында исенә төшермәс. Бу җырларны да ишегалдында кычкырып җырламас.

Салкынча сулыш бөркеп, төн куера. Без, әле генә Нәүширван абзыйга көлеп караган малайлар, хәзер инде аны җәлли башлыйбыз. Каз тәне чыккан ялангач беләкләребезне ышкып җылыта-җылыта, нишләргә икәнен киңәшәбез. Сабирәттәй ут та алмаган, җылыда рәхәтләнеп йокыга талгандыр. Ә монда, юеш үләндә, Нәүширван абзый төн кунсынмы? Ул бит сугышта булган кеше.

Берәм-берәм өйләрдә ут сүнә. Ихата буйларына шомлы күләгә ташлап, ай күтәрелә. Айның үзенә дә салкынча чык төшкәндер сыман.

Мин малайларга алдан ук уйланган бер хәйләмне чишәм. Алар, шатланып, риза булалар. Койма артына яшереп куйган җепле кәтүкне, эрекмән яфрагына төреп куелган бәрәңге белән булавканы алып киләм дә, эшкә керешәбез. Болай булгач, Сабирәттәйгә дә йокы мазасы бирмибез. Беребез җепнең очын булавкага беркетә, тишеп җепне бәрәңге аша чыгарып төйни дә... иң хәтәре: киртә аша бакчага шыпырт кына кереп, булавканы тәрәзә рамына кадап куя... Бераздан анысы да эшләнә. Ул-бу юк, тып-тын. Җепнең икенче очын урам аша сузып, каршыдагы Мәдинә апаның капка артына кереп өелешәбез дә... башлана шуннан! Җепне тартуга, булавкага асылган бәрәңге «тук» итеп тәрәзәгә китереп бәрә. Тагын, тагын тартабыз. Кинәт өйдән Сабирәттәйнең күкле-яшелле тавышы ишетелә. Ул тынуга, тагын тартабыз — тык-тык, тык-тык. Менә караңгы тәрәзәгә килгән шәүлә шәйләнә. Без авызыбызны каплап, көлүдән чак тыелып торабыз. Тәрәзәдә шәүлә югалуга, тагын тык-тык, тык-тык итеп «кемдер» пыяланы кага башлый.

Ниһаять, өйдә жиделе лампа кабына. Өйалды ишегенә килгән Сабирәттәй ямьсез тавыш белән тынлыкны ярып сала:

— Чукынып кит шул полячкаң белән! Кадалып кит! Барыбер кертмим, чатан тәре!

Колагына черки кебек кергән тавышка Нәүширван абзый уянып, бер ыңгырашып ала. Кулына уклау тотып чыккан Сабирәттәй аның һаман да шул урында кузгалмыйча ятуын күреп, аптырап кала. Аяк очларына басып, поса-курка гына почмактан-почмакка килә, өй тирәсен карап чыга, әмма бакчага керергә җөрьәт итми. Аннары үзалдына нидер укынып, юка такталы өйалды ишеген үз артыннан чәпәп кереп китә. Ут сүнә. Без көтәбез. Сабирәттәй, тынычланып, урынына менеп ятсын әле. Аның йокыга киткәнен күз алдына китергәч, үзебезнең дә

бер-бер артлы авызлар ачыла башлый. Ай отыры биеккәрәк күтәрелә бара. Аръяк сазлыктан бакалар җыры ишетелә.

— Башладык...

Бу юлы инде җепне тиз-тиз тартабыз. Тәрәзә пыяласы туктаусыз зыңгылдап тора. Тагын өйалды ишеге сөрән сала. Сабирәттәй, үзалдына сөйләнә-сөйләнә килеп, Нәүширван абзыйны төрткәли башлый. Тегесе, ахылдап, башын күтәрә.

— Тор әйдә, салкын тидерәсең. Болай да гыжылдап торган үпкәңә... Үзе һаман, шөбһәләнеп, як-ягына каранып ала. Ирен култыгыннан алып торгызыша. Алар кочаклашып баскычка таба атлыйлар. Нәүширван абзый әле дә бирешергә теләми:

— Тимә син, карчык. Брониславага, тимә,— дип сөйләнгән була.

— Сиңа тагын полячка, кеше көлдермә ичмасам!

— Нәрсә?!

Нәүширван абзый, йодрыгын йомарлап, читкә селтәнә. Сабирәттәй аның аркасыннан кага-кага әйдәкли, тавышы инде сизелерлек йомшарган.

— Чү, кычкырма, күршеләрне уятырсың. Булыр, булыр, ышанам. Син бит авылда бер адәм. Җә, җә, әйдә, керик...

— Шулай диген...

Ул арада урам коймаларын ут яктысы айкап ала. Без абайлап өлгергәнче, чаттан борылган мотоциклчы юл аша тартылган җебебезне өзеп тә китә. Бу тегермәнче Сафа абзый булыр. Авылда бер анарда гына мотоцикл. Күкрәкне рәхәт дөпелдәтеп киткән мотоцикл тавышы тынуга, пышан-пышан гына капка артыннан чыгабыз. Һәркемнең үз өе көтә.

Мин койма аша гына керәм дә әчкелтем исле тәмәке түтәлен үтеп, усак астындагы ятагыма киләм. Балаклары чыктан манма булган чалбарымны ботакка элеп, инде урынга авам дигәндә генә кулыма сабаклы җиләк бәйләме тиеп үтә. Әти куйган инде моны. Көне буе үзәнлектә каз, бозау саклаганга күрә, урманга барырга да вакыт тими бит безгә. Калын юрган астында, күккә карап, сабагыннан гына өзеп җиләк ашап ятуы, нинди рәхәт. Усак яфраклары бер көйгә лепердәшә, үзеннән-үзе җил чыгарып калтыраналар бугай алар. Ай яктысыннан сүрәнләнгән йолдызлар да яфракларга кунып атыналар шикелле.

Мин мөлдерәп пешкән җиләкне әчкелтем тәҗыннан аралап кабам да тел өстендә суырып тотам. Нәүширван абзый әйткән полячка нинди икән ул? Шуны бер генә күрәсе иде. Ул кыздан бәлки шушындый хуш исле җиләк тәме киләдер. Мин кайчан соң өянке яныннан олы юлга чыгып китәрмен дә зур дөньялар күрермен микән? Миңа Казан, Мәскәү, Парижлар — барысы да Сарай тавы артындадыр кебек тоела. Самолетлар да гел шул юнәлешкә карап очалар бит...

Усак ботаклары арасыннан кыйпылчыкланып күренгән күк йөзе тоташ бер күләгәгә, алагаем зур яфракка әйләнеп, мине тирбәтә башлый. Йокы җиңел канаты белән көндезге дөньямны сыпырып ала. Юк, минем әле рәхәт караңгылыкта онытыласым килми, минем әле җавап табылмаган күпме сорауларым калды, минем алардан аерыласым килми... Сораулар, якты күренешләргә әверелеп, мине үзенә чакыра, әйди...

Әнә ул! Юл уртасыннан кайтып килә. Ике толымын аркасына салган. Сары чәчәкләрдән такыя үреп кигән. Бер кулында сумка, икенче кулында сары саз чәчәкләре. Безнең авылда мондый ак челтәр якалы, кызыл күлмәкле кыз бүтән юк. «Полячка...— дип пышылдадым мин. «Бронислава...» Мин аны күптән беләм икән бит!

Бронислава дип дәшүгә, ул миңа борылып карый һәм артында кулларын кесәсенә тыккан яланаяклы малайны күргәч, баласынып, елмая. Мин аның матур туфлиләренә, бикләвечле сумкасына карыйм, кызыгып, онытылып карыйм, ә ул һаман елмая, мине бәләкәйгә санап елмая. Аның

купшы кыяфәтенә карап, минем елыйсым килә, тизрәк үсәсем, аның зурлыгы буласым килә. Ә ул кулындагы чәчәкләрне исни, аның борын очында йогып калган сары чәчәк тузанын күреп, мин дә көлә башлыйм. Ул кинәт миңа полякча эндәшә:

— БИРсиБИРнең БИРиБИРсеБИРмең БИРни БИРчек?

Мин башта аптырап калам. Аннары кычкырып көләргә итәм, тик тавышым гына чыкмый. Бу бит... безнең авылда клубка чыгып йөри торган олы кызлар сөйләшкәнчә... Без, малайлар, кырыйларына килеп бассак, шундый телгә күчәләр. Янәсе, без аңламыйбыз инде. Иҗек сәен «бир» сүзен кушасың да...

— БИРтәнБИРзил,— дим мин.

— Тәнзил.. Син аңлыйсыңмыни?— дип ул чәчәк бәйләмен иреннәренә китерә. Ак тешләренә кадәр сары чәчәк тузаны йокканын күреп, мин тагын елмаям.

Кинәт урамның теге башыннан өермә куба, бөтерелә-бөтерелә, кайнап торган гарасат күтәреп болай таба килә башлый. Мин полячканың кулыннан тотып алам да... Нигә соң әле аның кулы шулкадәр салкын, җитмәсә маңгаема куя? Нигә соң... Өермә артыннан тонык булып тавыш килә:

— Тор... тор инде, улым...

Йокы пәрдәсен көчкә ертып, күземне ачам. Томан эчендә әни басып тора, бәрәңге кабыгы исе килгән кулын маңгаема куйган. Ләззәтле төшнең өзелүенә нәүмизләнеп, йокының тәмен әле яңа гына аңлап, мин юрганга төренәм дә икенче ягыма әйләнәм. Әнинең кисәтүле тавышы, ерагайган саен, ягымлылана бара.

— Халык көтү куа башлады, соң... га..

Өстемнән җылы юрган шуып төшә, юрган астына иртәнге салкын бәреп керә, керфегемне күтәрүгә, койма ярыгыннан кысылып үткән кояш нуры күзләрне чагып ала.

— Тор, улым. Иртәрәк ятарга иде аны.

Йокының кичкесе түгел, иртәнгесе тәмле икәнен белмимени бу әни?! Мин, коймага тотына-тотына, алпан-тилпән килеп, әни артыннан иярәм. Җиз комганнан үтешли генә су агызып битне чылаткандай итәм дә өйгә керәм. Әни инде чәй кайнаткан, күкәйләр пешереп куйган, ә минем берни дә кабасым килми. Бөтен теләкләрем кичәгедә калган. Хәзер исә бердәнбер ниятем — йокы, йокы, йокы. Бер стакан җылы сөт кенә тамагымнан үтә. Төштә алданганымны әле генә төшенеп киләм...

Әни, капканы киң ачып, сыер-сарыкларны алып чыгып та китте.

Дүрт урам килеп тоташкан урында — көтү җыела торган мәйдан. Койма буенда апалар соңгы яңалыкларын бүлешәләр. Бөтен хәбәр авылга шушыннан тарала.

Әни көтүне күпергә кадәр озатыша төшә.

— Кичә Сабирәттәйләргә җен килгән. Төне буе дүрт тәрәзәсен берьюлы кагып чыккан. Балта тотып чыккач кына качып киткән, ди.

Мин читкә карап, яшереп кенә елмаеп, әнинең сүзләрен тыңлап барам. Ярый әле үзем шаһит, юкса ышанып та куюың бар. Юк кына хәбәр дә әнә ничек арттырыла, сөйләгән саен үсә, зурая башлый. Олылар гынамы, без, малайлар да шулай бит — купайтып сөйләргә ратабыз. Арттырып сөйләгәч, вакыйгага үзең дә катнашкан кебек буласың...

Мең төскә кереп, яшьнәп яткан чыклы үләндә карасу-яшел эз калдырып, сарык көтүе тауга табан күтәрелә. Мин, тирән эчле галушым белән аерым эз ясап барам. Эреле-ваклы кәҗәләр төркеме бер тирәдәнрәк атлый. Кәҗәләр барыбер көтүдә тормый, ишегалдыннан чыгарып җибәрү өчен генә куган булалар инде аларны.

Мин, йокыдан айнып өчен башымны селким дә, Челтер чишмәгә

йөгерәм. Түмгәкле аланлыкта тарлавык ясап, агач улактан тыйнак кына агып ята ул. Кепканы салып ыргытам да, тап-такыр итеп пәке белән кырылган башымны боз салкынлыгы килгән суга тыгам. Меңләгән корт чаккан кебек, баш тиресе куырылып килә. Өтеп алган авыртулы ләззәттән ничек инде ухылдап кычкырмыйсың?! Дөнья кинәт яктырып китә, зиһенем ачыла. Тирәннән бәреп чыккан чишмә янында үзенә бер төрле дымлы ис килә. Мин укып, ишетеп кенә белгән диңгез исе дә шундый түгел микән? Мин чишмә суының борыла-борыла аккан юлына карыйм. Челтер чишмә суы инешкә кушыла. Инеш Ыкка коя, Ык — Камага, Кама — Иделгә, ә Идел Каспий диңгезенә барып кушыла. Димәк, мин әле генә суын эчкән чишмә күз күрмәгән ераклыктагы диңгез белән тоташа. Каспий диңгезенең башы — безнең авыл чишмәсеннән икән бит! Мин бу ачышымнан горурланып, тирә-юнемә карыйм. Кычкырасым килә. Инеш буендагы өянкеләр, без моны инде күптән беләбез дигән шикелле, олпатларча, тын гына утыралар.

Өянке яфраклары арасыннан чәрдәкләнгән көзге булып күренгән кояш күтәрелә башлауга, тирә-юнемдә һәр үләннең, һәммә бөҗәкнең уяна башлаганын сизәм. Пәрәвез җепләреннән тукылган кебек үтә нәзберек тынлыкны кинәт сискәндермәс өчен һәммә кош, һәммә бөҗәк үз вакытын белеп кенә уяна, үз чиратын белеп кенә аваз сала башлый; шулай итеп, зеңләп торган тынлыкка җан иңә. Иртәнге тынлык төрле төстәге тавышлар белән канатланып, колакны иркәли башлый.

Мин дә үз вазифамны онытмыйча урынымнан кузгалам.

---

Өянкенең кичкырын канатлары салына, яфраклары талгын сүлпәнлектә оеп кала. Төн карасы куергач, берьялгызы каласын сизенгән Өянкенең игътибары әлегә урамны күзәтүдә, кешеләр тавышын тыңлауда.

Печән өмәсеннән кайткан атлар авыл башыннан борылдылар. Әле һаман ниндидер хозурлыктан айный алмыйча капка төбендә торган Байтирәкне хатыны Солтания, чәй суына дип, өйгә әйдәкли башлады.

— Чәй эчкән бар, карчык,— дип, Байтирәк сагышлы гына әйтеп куйды.— Өйгә керәсе килми, әйдә, өянке төбенә барып утырыйк әле,— дип, ул хатынын иңеннән кочып алды.

— Күбрәк төшердеңме әллә, картым, җаның өйгә сыймыймы? — дигән булып, Солтания аның чәчләренә йогып калган ябышкак үлән орлыкларын чүпли башлады. Ягымлылана, назлый белә иде ул ирен.

Өянке төбенә барып утыргач, Байтирәк бирчәйгән кәүсәгә учы белән сугып:

— Әткәйдән калган бердәнбер мирас бит бу безнең,— диде.— Ихатасыз-нисез, юл кырыенда... Берәрсе кисеп аударгандыр дип, иртәләрен куркып уянам.

— Безнең дисең, ә үзең Хикмәт белән ничә ел инде исәнләшмисең... Абыең бит ул синең.

— Абый дигән булып... Аерма яшь тә ике ай инде. Исәнләшмәү бит әле ул дошман күрү дигән сүз түгел.

— Бер үк сукмактан йөреп, бер үк чишмә суын эчеп... Туганың белән белешмәү...

— Нишлисең, шулай килеп чыкты бит, карчык.

Икесе дә Сарай тавы артында сүнә барган шәфәкъ сызыгына карап утырдылар. Байтирәк, шырпы алып, теш каезлый башлады.

— Шуны уйлыйм әле, карчык: сугышта ел ярым гына йөрелгән югыйсә, ә күпме кешеләр, күпме җирләр күрелгән. Кич житсә, син әйтүгыйсә... мешли, җан тарыга башлый. Шулар тынгы бирми, ахры, миңа. Алар да искә аладыр, мин дә искә төшерәм. Менә шул бергә туры килгәндә, кеше җаны бәргәләнеп аладыр.

— Әллә ниләр уйлап, бик бетеренмә,— дип, Солтания иренең агарган чигә чәчләрен бармагы белән йомшак кына аралый башлады.

— Госпитальдә ятканда, түшәмгә карап, гел бер уй уйлый идем. Исән-имин кайтып, шушы Өянке төбенә бер утырсам, үлсәм дә үкенмәм дип... Ун елдан артык гомер үткән, менә беренче мәртәбә килеп утырдым. Әйткәнен онытa шул адәм баласы...

Байтирәкнең болай ачылып китүе сирәк була иде, шуңа күрә Солтания аны бүлдермичә тыңлады, чәй турында яңадан искәртергә кыймады.

Байтирәк, гәзит кәгазе ертып, тәмәке төрде, төкереклэп ябыштырды да, кабызып, тәмләп суырды. Аннары үзенең яралануы турында сөйли башлады. Хатыны, бу хәлләрне инде ничә тапкырлар тыңлаган булса да, беренче ишеткән кебек, йөзенә газаплы теләктәшлек чалымнары чыгарып утырды.

— Снаряд шартлагач, аңымны җуеп, күпме ятканмындыр... Себер егете Петя алып чыкмаган булса... Дуслар идек без аның белән. Синең дә чәчең минеке сыман сары, күзләрең дә зәңгәр, руска охшагансың, дия иде. Кем кемгә охшагандыр бит әле, бер алла белә дим мин моңа. Син татарны кысык күзле, маңгай уртасында мөгезе бар дип күз алдыңа китерә идеңмени, дим. Ә ул шаркылдап көлә, «мөгезне арттырасың инде», ди. Колоколов Петр Онуфрий улы икәнен беләм, кайсы районнан — юк... Исән микән ул хәзер? Көн саен үлем баш очында эленеп торганда, кешеләр тиз туганлаша икән. Ә тынычлыкта... Күр инде, үз туганым белән аралашмыйбыз бит.

Байтирәк, йонлач бармаклы йодрыкларын кысып, тез капкачына сукты.

— Син гаепле бит, Байтирәк, үзең башлап эндәш...

— Юк!— дип, Байтирәк хатыны кырыеннан читкәрәк шуышып, усал итеп карады.— «Мин ул бөкре шайтанга мәңге дә эндәшәсем юк»,— дип кем әйткән, Хикмәтме?! Мин ул бөкрене үзем теләп алдыммыни!

— Ул тән ярасына кагылса, син аның җан ярасына кагылдың. Уйлап кара, кайсы авыррак?..

Байтирәкнең ачу белән тәмәкесен изеп, ашыга-ашыга атлап китүен, кече капканы атып бәреп кенә япкач, тирән сулап, Солтаниянең дә кузгалуын Өянке нәүмизләнеп күзәтте. Шундый чакта җил исеп куйса икән! Меңләгән яфраклары белән ул нидер пышылдар, шаулар, чайкалыр иде. Юк шул, дөнья тып-тыныч...

Урак ай, йолдызларны аралап, күк гөмбәзенә күтәрелгән, кабер тынлыгы иңгән авыл өстенә чалкан ятып карый.

Шушындый авыр, моңлы тынлык астында төн чыгуы ялгыз Өянке өчен никадәр кыен икәнен кешеләр башларына да китермиләр. Черем итәргә Өянкенең тамырларына кадәр төшкән хәтере ирек бирми. Изрәп йоклаган авылның хәтере сагында ул, юеш үләнгә бөркет булып сузылган кара күләгәсенең дәвамы булып, биеккә күтәрелә. Ай нуры сибенгән тәрәзәләр артында тыныч сулап яткан кешеләрнең өнендә калган иртәгәге хыялларын дәһшәтле-хәтер бер сүз челпәрәмә китерергә мөмкин бит. Теге чакта шулай булмадымыни...

«Сугыш» дигән аянычлы хәбәрнең бер көн эчендә кешеләрне ничек үзгәртеп куюын Өянкенең әле дә онытасы юк.

Сугышка алынган ирләр, хатын-кыз, бала-чага — барысы да авыл башына, Өянке янына җыелдылар. Атлар кешнәве, балалар, хатын-кызлар җылавы, эш белән изелгән ир-атларның беренче мәртәбә ачылып, үз хатыннарына җылы сүз әйтеп калырга ашыгуы, яшерен гыйшык тотып йөргән кыз-кыркын, аркасына капчык аскан егет-җиләннең тыйнаклык чиген узып, кочаклашу-үбешүе... Юк! Моны болай гына түгел, һәр мизгелен кайта-кайта, кабат-кабат, әкрен-әкрен генә искә төшерергә, яңадан кичереп карарга кирәк. Әгәр чәче булса, ул көннең чәче агарыр иде. Әгәр бәгыре булса, ул көн сулыгып-сулыгып сыкрар иде...

Кемдәдер ачы бал эчеп, беренче мәртәбә татыган хәмер башына киткән егерме яшьлек Байтирәк, Өянке кәүсәсенә тотынган да күз яшен тыя алмый. Сабыр, аз сүзле абыйсы Хикмәт аны каерып алып, инде кузгала башлаган арбага утыртырга маташа. Байтирәк, аңардан йолкынып, йодрыгы белән күкрәген төя:

— Шулай китиммени?! Бер кыз да кочакламаган килеш! Шулай китәммени?! Бер кыз да кочакламаган килеш...

Шул чак кызлар төркеменнән Солтания аерылып чыкты да, инәлеп, ялварган сыман өзгәләнеп Байтирәккә таба китте.

— Кил, Байтирәк, үзем кочаклыйм сине!

Байтирәк, үзенә таба кулларын җәеп килгән күрше кызына шаккатып, хәтта бераз шүрләп, бераз икеләнеп карап торды да кулларын чебен куган шикелле селтәп чигенә башлады. Егетләр аны арбага тартып алдылар. Инде кузгалып, берара киткәч, Байтирәк кинәт арбадан сикереп төште, халык төркеменнән читтә, башын игән килеш үз өенә таба атлаган Солтанияне куып җитеп кочаклап алды. Зырылдатып бер әйләндерде дә:

— Болай булгач, исән кайтам,— дип кычкыра-кычкыра, хәзер инде кызның үзен аптыраштта калдырып, атлар артыннан йөгерде.

Сүзендә торды Байтирәк. Арба артыннан йөгергән төз гәүдәле егет, сугышның икенче елында яшел капчык тотып, чигә чәчләре агарган бөкре булып, карлы юлдан кайтып төште. Кызганулы шатлыктанмы, шатлыкны кызгануданмы елаган әнисен юатып, бер чынаяк чәй эчте дә, кар шыгырдатып, күршегә кереп китте.

Сыер алдына печән салып, лапастан чыгып килгән Солтания йөзе суырылып, олыгаеп киткән Байтирәк солдатны әңгер-меңгердә танымыйча куркып калды. Аннары... Байтирәк аның туңган кулларына кагылды, аннары... тезләнде дә аякларын кочты.

— Син гаепле, Солтания. Кочаклыйм димәгән булсаң, исән каласы түгел идем бит!..

Солтания күзләрен чытырдатып йомды. «Тавышы үзгәргән... тавышы үзгәргән... тавышы үзгәргән! Интегеп, күкрәк читлегеннән газапланып чыга. Ничек җырлар ул моннан соң, ничек җырлар?! Ул моңлы итеп җыр сузса, бөтен оч сулышын тыя иде бит!»

Торгызырга дип иелгәндә, аның калтыранган кулы егетнең каты арка бөкресенә тиеп китте, аннары... Байтирәкнең бер башка тәбәнәгәеп калганын искәреп алды һәм кинәт, кычкырып җибәрмәс өчен, иренен тешләде дә ачык калган капкага таба йөгерде. Бу ихатадан, бу өйләрдән читкәрәк, читкәрәк китәргә кирәк иде. Итек эченә кар тулды, көрткә батып егылды, тагын торды, Өянке янына җитәрәк, сулышына буылып капланды да тавышын эченә йотып үкси башлады.

Бераздан, иңенә кагылудан сискәнеп, башын күтәрде. Байтирәк аның шәленә, чәчләренә сарган карны сыпырып төшерде. Солтаниягә кинәт җиңел, рәхәт булып китте. Ул Байтирәктән битәр үзен юатырга, тынычландырырга теләгәндәй ашыгып:

— Шөкер, исән кайткансың,— диде.

— Гарипләнеп диген. Шуннан куркып калдыңмы?

— Алай димә, Байтирәк...

Егет аның беләкләрен авырттырып кысып селкетә башлады:

— Мин анда кул-аяклары өзгәләнгән, бомбежкада ботарланып ташланган кешеләрне күпме күрдем. Тора-бара кызганмаска, игътибар итмәскә өйрәндем. Җир тулы мәет арасыннан йөреп, бәгырем каты минем, Солтания. Син генә йомшата аласың мине. Кул-аягым исән бит әле! Кире какма, юкса икебезгә дә яшәү юк!

Госпитальдә ятканын, яраланганын да әйтмичә, гадәти хатлар язып яткан бу егеттә ниндидер бер тәвәккәллек күреп, чарасыз калган Солтания калтырый башлады.

— Әгәр үзебезгә кадәр күтәреп бара алсам...!

Сүз әйткәләгәнче, кайнарланып, Байтирәк аны күтәреп алды да капкага таба юл ярып китте.

Нидер сизенеп чыккан әнисе, үзе күренмичә генә, ни булганын да аңышмыйча, ишекләрне ачып торды. Солтанияне өйгә кертеп бастыруга, Байтирәк чайкалып китте, мич почмагына тотына-тотына идәнгә сыгылып төште. Госпитальдән әле ныгып та чыкмаган егетнең көл төсенә кергән чыраена салкын тир бәреп чыккан иде. Ике хатын-кыз аны чишендереп, ике яктан култыклап, сәкегә китерделәр. Ул арада Байтирәкнең әнисе, ниндидер үлән бәйләмнәре алып кереп, кайнатырга куйды. Солтания сәке йөзлегенә утырып, салкын кулын маңгаена тидерүгә, Байтирәк күзләрен ачты һәм беренче мәртәбә елмайды.

— Син ачуланма инде, Солтания. Икебезгә дә яшәү юк дип кызган баштан гына әйттем мин. Синең ни гаебең булсын.

Солтаниянең битеннән кайнар юл ясап агып төшкән яшь тамчылары ирен читенә җыелды. Җиделе лампа уты артык якты тоелды аңа бу минутта...

Шул көннән соң ике йорт арасында кардан әрчелгән сукмак салынуга Өянке шаһит.

Онытылырлыкмы соң... Өянкенең гомерен дә Байтирәк саклап калды бит ул кышта. Утә зәһәр салкыннарда барлы-юклы утыннар ягылып бетү алдында, морҗалардан чыккан төтен баганалары сыеклана башлаган көннәр иде. Украина якларыннан күченеп килеп, вакытлыча монда көн күргән хатын-кызлар, авылныкылар белән бергә, тегермән янындагы өянкеләрне кистеләр, иске кабер бураларына кадәр утынга ташыдылар.

Ә бер көнне... кемнең башына килгәндер, авыл башындагы ялгыз Өянкегә дә чират җитте. Өч тармаклы юан агачның бөтен сынын тетрәтеп, үтмәс балта белән чаба башлауга, фуфайкасын да өстенә кияргә онытткан Байтирәк капкадан йөгереп чыкты. Карга бата-чума, кычкыра-кычкыра йөгергән ирне күреп, хатыннар туктап калдылар. Балталы куллары салынып төште.

— Тимәгез өянкегә! Нильзә, нильзә!— дип, ул гыжылдый-гыжылдый килеп, Өянкегә аркасын куеп басты.— Монысына тимәгез! Ул бит, ул бит...— Байтирәк, тончыгып, ютәлли башлады.

— Сезнең нигез агачы дип... Утын кирәк бит, менә эвакуированныйларга да,— дип теш агарта башлаган авыл хатыннарына Байтирәкнең бер сүзе җитә калды.

— Ничек кулыгыз күтәрелә? Шушыннан бит күпме ирләр сугышка китте. Урдән авыл күмелгәч, иң соңыннан шушы Өянке хушлашып калды бит безнең белән. Яу кырындагы ирләрегезнең хәтеренә кагылмагыз... ичмасам...

Кайчандыр шәһәрнекеләр икәнен искәртеп пальто кигән, хәзер инде тәмам авыллашып, билен киндерә белән буган, олтанлы зур итекләр кигән рус, украин хатыннары — бер тирәгә, авылныкылар бер тирәгә укмашып, бердәм тындылар. Байтирәк тә кинәт, үзен гаепле сизеп, сүздән калды. Аннары, капылт бер карарга килеп, хатыннарны үз артыннан ияртеп китте.

— Әйдәгез, иске сарайны сүтеп ташлыйк, барыбер түбәсе юк. Очны-очка ялгарга ярап торыр. Күрше авыллар Ширәмәт урманын кисәләр икән. Безгә дә бүген-иртәгә чират җитәр. Пошли!— дип, ул шәһәрнекеләргә русча белгәнлеген дә күрсәтергә ашыкты.

Ул көнне Өянкенең ярасын өшетеп җил исте. Читкә чәчрәгән йомычка-кайрыларны төнге буран күмеп китте.

Ә язын... гомердә күрелмәгән бер хәл булып алды. Җылымса, тымызык бер иртәдә Өянке ябалдагына киң канатларын җәеп, озын сыйраклы гаҗәеп зур кош килеп кунды. Өянкенең мондый галәмәт кошны

беренче тапкыр иңендә тоюы иде. Сәер кош, урыныннан кузгалмыйча, горур бер тантаналык белән, Алтын Болак авылы өстенә карап тора бирде. Ул арада капкалар шыгырдап ачылды, өлкәннәр дә, бала-чагалар да йөгерешеп чыктылар.

— Белый аист! Белый аист!— дип йөгерештe рус балалары.

— Лэлэко! Лэлэко!— дип кычкырышты украин балалары. Бу ят кошның исемен өлкәннәрдән сорап белгән авыл балалары:

— Ләкләк килгән! Ләкләк...— дип, төркемгә кушылдылар.

Бу кадәр тавышны кабул итә алмадымы ләкләк — мәһабәт канатларын җәйде дә, баскан ботагын сыгылдырып һавага ыспай гына күтәрелде. Салам түбәле йортлар өстеннән бер әйләнеш ясап, Алтын Болак авылын калдырып китте. Кулларын каш өстенә куеп, яше-карты аны күздән югалганчы карап калды.

Көнбатыштан, бомба, снаряд шартлауларыннан тынычлыгын җуеп, аяз күк эзләп килгән ләкләк кешеләр күңеленә гүя якты бер хәбәр салып китте. Украинадан килгәннәр өчен ул туган якның канатлы бер җаны иде. Кояшлы икмәк кырларын, торган нигезләрен искә төшерүдән аларның күзләре яшьләнде. Авыл хатын-кызлары да бу сәер кошның Өянкегә килеп кунуын яхшы фалга юрадылар. Еракта, бик еракта, үлем гарасатына кереп киткән якыннарының сәламе итеп кабул кылдылар.

Ирләре сугышны бик тиз генә хәл итеп кайтырлар дип әзерләнгән, бик өзелгән чакта да кузгатылмаган каклаган каз, казылык, җиләк вареньесы ише тәм-томнар өстәлгә куелды. Хуш исле үлән чәе уртага җыйган табында рус, татар украин сүзләре белән кушылып, гөлдерәп торды. Һәркемнең күңелендә кабынган ялгызак өмет, бердәмләшеп, олы ышанычка әверелде.

Туган җирен калдырып килгән ләкләкләр соңыннан да күренгәләделәр, оя корып, бу якларны үз иткәннәре дә булды, әмма берсе дә яңадан Өянкегә килеп кунмады...

Сарыклар тауга менеп җитүгә, кырыйдарак барган кәҗә өере, туктап, бер тирәгә җыела. Төс-кыяфәте, зурлыгы белән дә башкалардан аерылып торган, нәкъ инде хуҗасы — тегерменче Сафа абзыйга охшаган оренбур кәҗәсе кукраеп уртага чыга. Авылда малы гына түгел, өе, ихатасы, капка баганасына чаклы хуҗасына тартым була бит. Оренбург кәҗәсе янына җыелышып, «аксакаллар» нидер киңәшә, минем якка да карап алалар. Алпамша, мине таныганын белдереп, мөкри дә башлыклары янына барып баса. «Курыкма, минем хуҗаның малае гына ул, усал түгел»,— дия, ахрысы.

Оренбург кәҗәсе, тәгаен бер карарга килеп, горур башын күтәрде дә вәкарь белән алга чыгып басты. Бүтәннәр әле тын гына торалар. Ниһаять, карар кылынды: башлыклары, артына борылып, күз белән генә команда бирде дә эре-эре атлап китеп барды. Тәвәккәлләп, өтек койрыгын югары чөйгән кәҗәләр өере дә кузгалды. Кызыгыпмы, көнләшепме, кайбер сарыклар да, башын кыңгыр салып, алар артыннан карап калалар. Мин урынымнан кузгалмыйм. Сизеп торам бит: кәҗәләр күз кырые белән генә мине күзәтеп баралар. Берәр тавыш бирмәсме дип, колаклары шомрайган. Кәҗә халкына каршылык кирәк, уңай форсатны өнәмиләр алар, кычкыручы, артларыннан йөгерүче булмагач, әнә ничек сүлпән генә атлыйлар. Кәҗәләрнең йөрешләренә кадәр ниндидер мутлык сизелә, сарык рәтендә йөртергә килештереп кара син бу сакалбайларны. Аларга сикерер өчен текә ярлар, ышкыныр өчен карт өянке кәүсәләре, сөзешер өчен хәтәр сукмаклар кирәк.

Сарык көтүе, тоташ яу булып, басу кырына якынлашып килә. Башакларын дулкынлатып җил йөгергән бодай басуы ызанына дүрт-биш адым кала сусыл үләнлек, куе яшел булып, күпереп тора. Димәк, мон-

да көтүне берәү дә якын китермәгән, үләнгә кагылдырмаган. Сарык дигәнең икмәккә бер башын тыкса, аерып кара анналы... Мин аларның борын тишекләре белән еш-еш сулу алып, тәм белән үләнне керт-керт кимереп килүләрен карыйм да шушы мул, сутлы үләнлектән аерырга кызганам. Инде соңгы секундта, ызанга бер адым калгач кына, кепкамны һавага чөеп җибәрәм. Кепка килеп төшүгә, сарык көтүенең бу башы су урынына кирегә ага башлый. Кепкамны алып, икенче башка таба чөеп җибәрәм, һәм үзем дә шунда йөгерәм. Көтү, бөдрә дулкынга охшап, бөтен иңе белән тауга таба агыла. Хәзер инде аларның яклары буталды, экияттәге сыман, мин аларны кирегә борып куйдым. Юнәлеш-тау астына, үзәнлеккә таба. Сарыклар, сибелешеп, үзләре яраткан тау үләненә ябышалар. Хәзер инде мин дә тыныч, кояш җылыткан таш өстенә утырып, җәйрәп яткан авыл өстен күзәтергә була.

Әнә, Нәүширван абзый, чатанлап, капкасыннан чыгып килә. Ул, ямьсез итеп кычкыруга, каршы тау битенә сибелешкән казлар, еландай муеннарын турайталар, шомланып карап торалар да, икмәккә керергә дигән уйларын онытып, оя-оя тезелешкән хәлдә, су буена титаклый башлыйлар. Нәүширван абзый алай ямьсез тавыш бирмәсә дә, аның капка тавышыннан ук казлар сагаеп кала —ерактан ук сизә-таныйлар аны. Нәүширван абзый — кыр сакчысы. Казый дип йөртәбез без аны.

Әнә, җирән кашкасын җитәкләп, ат карауч̧ы Байтирәк абзый кайтып килә, атының борыны ерактан караганда, Байтирәк абзыйның бөкересенә тиеп-тиеп ала кебек. Бераздан велосипедына атланып, күрше Хәмит абзый чыкты, ул районда эшли.

Әнә, тыкрыктан минем әни төшеп килә. Көянтә-чиләк аскан, кулында төенчек. Чишмә янына җиткәч, ул миңа кул изи. Мин таудан төшәм, түмгәктән-түмгәккә сикереп, аксыргакларның киң, яссы яфракларына җыелган чык суын түгә-түгә әнигә таба йөгерәм. Ул инде чиләкләренә су тутырып куйган, төенчек асылган сары буяулы көянтәне сузып, миңа каршы килә.

— Эшкә киткәнче ашарыңа китерим дидем, улым.

Чирәмгә утырабыз. Әни төенчекне чишеп җибәрә. Пешкән йомыркаларны, калын итеп киселгән казылык кисәкләрен минем алга этәрә. Мин кайнар арыш ипиен умырып кабам да сөтле чәйгә тотынам. Кырда ашау нигәдер өйдәгегә караганда тәмлерәк. Элегрәк эти миңа кыр дан «куян чәе», «куян ипие» алып кайта торган иде. Шешәдә калган чәй, арыш кылчыклары кадалган ипи гадәттән тыш тәмле тоела иде, чынлап та куян биреп җибәргәненә мин аның ышана да идем бугай. Хәзер дә мин, эти эштән кайткач, аның сумкасын карыйм. Өйдән алып киткән чәй, өйдән алып киткән ипи кыерчыгы икәнен дә беләм, югыйсә, ә барыбер тәме икенче. Күрәсең, ул ипигә кырлар исе, кояш нуры, җил тәме сеңәдер, юл йөреп кайткан ипи шуңа бик тәмле тоеладыр.

— Менә, казылыгын аша, улым. Бүген әле күп йөгерәсең булыр.

Минем әни, гадәттә, коры гына сөйләшә. Аркамнан да сөйми, иркә сүзләр дә әйтми. Ләкин беренче карашка гына шулай кырыс булып күренә ул. Каядыр чит авылда, күз күрмәгән кешенең берәр фаҗига аркасында үлүен сөйләсәләр дә: «И мескен»,—дип җылап ала үзе. Моннан өч ел элек (ул чакта миңа җиде яшь булган икән), Сталин бабай үлгән көнне, бөтен авыл мәктәп радиосын тыңларга агылды. Соңыннан күрше хатыннары да безгә җыелдылар. Әни җылый-җылый шешенеп беткән. Бүтәннәр дә яулык чите белән күзләрен сөрткәләп алалар. Мин дә җылыйм.

— Сугыш башланмаса гына ярар иде, ходаем,— ди әни.

— Башланмас, илне күз карасы кебек саклагыз дигән бит.

Апалар әнә шулай бер-берсен тынычландыралар. Ничек күз карасы кебек сакларга — мин шуңа һич кенә дә төшенә алмыйм. Сорарга да

кыймыйм. Ни өчен күз карасы... Бөтен кеше дә кара күзле булмый бит. Әнинең зәңгәр әнә, этинең — куе көрән, ә минем — яшькелт.

Күз карасы кебек дигәнгә мин үзлегемнән уйлый-уйлый төшендем. Шушы кояшны, болыннарны, зәңгәр күкне эти белән әнине кинәт кенә күрмәс булсаң... күзләрең сукырайса... Юк, юк, мин ул турыда уйларга да куркам! «Күз карасы кебек сакларга...» Димәк, дөм-караңгылыкта калмаска, кояшны, кырларны, елга-үзәннәрне, эти-әниләрне сакларга дигән сүз — «күз карасы кебек...»

Әни аны «күзнең кешесе» ди. Чынлап та, малайлар белән сынашкан бар, күзгә якын килеп карасаң, анда кеше күренә...

— Аша, улым,— дип әни кояшка карап ала.— Берәр сәгатьтән туплауга да төшә башларлар.

— Сарыклар үзләре белә вакытын.

— Туплаудан иртә кузгата күрмә, тотып та тыя алмассың аннары.

— Кичкә кадәр ятсыннар шунда.

— Алай итмә, ач кайтаргансың дип күзне дә ачтырмаслар.

Әни минем һәр сүзне чынга ала, шундый беркатлы инде ул.

— Ярый, миңа эшкә китәргә,— дип әни ашъяулыгын җыеп төйни.— Төшлеккә бәрәңге пешереп калдырдым. Суганның бер төптән берәр генә кыягын өзеп җый, яме. Сөт — кар базында. Агач кашык белән болгатып ал, өстен генә чөмерсәң, зәңгәр суы гына утырып кала.

Ярар дим мин эчемнән генә. Әни, мөлдерәмә чиләкләрен бер дә чайпалдырмыйча, җил-җил китеп бара. Артыма борылып карыйм, сарыклар әллә кай арага чәчелгәннәр, тау битенә ябышып үскән түмгәкләр кебек кымшанмый да ашый бирәләр. Мин, кесәмнән лупа чыгарып, уч төбен кыздырып алам. Кояш нуры сизелеп зәһәрләнә.

Дерелдәп торган түмгәкләрдән сикерә-сикерә, аксыргаклык арасыннан тауга күтәреләм. Баш очымда, чыелдап, тәкәрлекләр әйләнә. Тау битендә оясыннан башын тыккан йомран мине үртәп сызгырып куя. Мин аңа үзе кебек сызгырып җавап бирәм. Үрә баскан йомран, мин килеп җиткәнче күзәтеп тора да кинәт юк була. Оясы, кара авызын ачып, миннән көлеп кала. Бераз киткәч, борылып карыйм — йомран тагын башын калкыткан. Ат кылыннан ясаган тозак белән бер эләктерермен әле үзен!

Таудан бөтен нәрсә уч төбендәге кебек күренә. Чишмә башында хатын-кызлар кайнаша. Әнә, арадан берсе, аерылып, монда таба килә башлады. Чуар күлмәкләр арасыннан мин аны шунда ук танып алдым. Безгә каршы йорттан Мәдинә апай. «Нати» тракторын йөртә ул. Урак өстендә этинең «Коммунар» комбайнын тарттыра иде. Мин аның туктаусыз селкенеп бара торган агач кабинасына утырып та йөргәнем бар. Гел бер төсле камыллы басуга карап бара-бара, кабина селкенгән уңайга әкрен генә йоклап китә идем. Эти биек комбайн күперчегендә, штурвал тотып бара. «Коммунар»ның алда бер генә киң тәгәрмәче бар. Кырын урыннарда ул авып китәр төсле янтая. Нигә алга бер генә тәгәрмәч куйдылар икән дип, мин гел шөбһәләнә идем. Комбайн туктагач, шомарып, елкылдап беткән тәгәрмәчкә кулны куясың — җып-җылы була.

Мәдинә апа авыр күн итек, пинжәк кигән, башында — беретка. Безнең очта ул бүтән апалардан аерылып тора. Кара тут йөзле, ут кара күзле, иреннәре дә кара-кучкыл кызыл. Мин аннан нигәдер куркам да... Бервакыт безнең капка төбендә җыелып утыралар иде, бер егет аңа чәнечкеле сүз әйтте. Мәдинә апа шунда егетне җилтерәтеп торгызды һәм сугып та екты.

Көтү арасында каранып йөргәннән соң Мәдинә апа:

— Үскәнем, кил әле,— дип, үз янына дәшеп алды.— Бүген-иртәгә мирнус сарыгым бәрәнләргә тора, әнә, муенына кызыл чүпрәк бәйләгә-

не... Күз-колак бул әле шуңа, үскәнем,— дип, сүз озайтып тормыйча, китеп барды.

Артыннан мин аны кызганып карап калдым. Нигә шулай, матурлыгын яшереп, ирләрчә киенеп йөри икән ул? Былтыр гына бит әле, былтыр гына бүтәнчә киенә иде...

Сабан туе алдыннан, Бөгелмәгә барган җиреннән ул мотоциклга утырып кайтты. Күн киемле абый кеше, мотоциклын капка төбендә калдырып, Мәдинә апаның өенә үк кереп китте. Көтү кайткач кына, капканы киң ачып, мотоциклны ишегалдына кертеп куйдылар. Капка төбендә җыелып утырган халык арасында сүз гел шул турыда гына барды.

— Бичара, шул чибәрлеген әрәм итеп, тәки утырып калды бит.

— Әнисе аркасында инде. Җиде ел урында яткан карчыкны карау җиңел дисеңме...

— Утыз яшьләр бардыр инде аңа.

— Әнисе үлгәненә дә бер ел инде.

— Кемне иярттеп кайтты икән соң ул? Җүнле кеше булса ярый да...

— Менә сиңа Мәдинә... Гомер ир-атка күз салмаган кыз. Кем уйлаган...

Аның шулай гел ялгыз яшәвенә күнеккән апалар бу көтелмәгән вакыйганы сөенеп тә, көнләшебрәк тә кабул иттеләр бугай.

Сабан туена алар бергә чыктылар. Мәдинә апа җиңел туфли кигән, нечкә билле, зәңгәр чәчәкле күлмәктән. Авыр толымын түшенә яткырып куйган. Күн итектән, ирләрчә киенеп йөрүенә мин аның шулкадәр күнеккәнмен икән, мондый чибәр итеп күргәч, ул ничектер ерагаеп калды, Мәдинә апа кыяфәтле бүтән чит бер кешедер кебек тоела башлады. Ә Сафуан абый (аның исемен иртәнгә бөтен оч белеп өлгергән иде) ак күлмәктән, иңенә әллә ничә кесәле, әллә ничә замоклы күн пинжәк салган. Кулында — фотоаппарат. Гармун куныччлы хром итеге баскан саен шыгырдап китә. Ике кесәле, кыршылып беткән күн пинжәк полуторка шоферы Таһир абзыйда гына бар иде. Ә Сафуан абыйның аныкы ише генәме соң!.. Без, малайлар, аңардан күзне алалмыйбыз. Ул бик тиз арада тирә-күрше, бөтен оч белән танышып та чыкты. Үзе, алтын тешләрен чагылдырып, гел елмая, халыкны тезеп, фотога төшерә, безгә дә сүз кушып китә, исемне сорый — кыскасы, барысына да өлгерә иде. Ул арада, тиз генә фотоаппаратын, пинжәген Мәдинә апага тоттырды да гер күтәрүчеләр арасына чыгып басты. Кулын төкереклэп, иелеп, гергә тотынган гына иде, «Сәгатең! Сәгатеңне харап итәсең!»— дип төрле яктан кычкырганга туктап калды (ул елларда кул сәгате авылда бер Сафа абзыйда гына бар иде бугай), каешын җәлт кенә ычкындырып, сәгатьне ерактан Мәдинә апага ыргытты. Мәдинә апа тотарга өлгерә алмый калды, сәгать үләнгә төшүгә, халык «аһ» итеп куйды. Ә Сафуан абыйның исе дә китми, көлә генә.

Мускулларын шыкырдатып муен тамырлары бүрткәнче чөйде дә чөйде ул ике потлы герне.

— Җитте, җитте!— дип, халык түземсезләнә башлагач, бөтенесеннән артыграк күтәрүенә тәмам ышангач кына ул, герне ташлап, мәйданнан чыгып китте.

Бәйрәм соңында алар култыклашып, икесе генә су буеннан кайтып киттеләр.

Сафуан абый шул килүеннән авылда торып калды. Мәдинә апаның тракторында эшли башлады. Авылга ул мотоцикл, фотоаппарат һәм тагын зур колаклы, зур башлы, калын тавыш белән өрә белгән эт алып килде.

Кемгәдер бура күтәрәләрме, берәрсендә мәҗлесме, болай гына сөйләшеп утыралармы — уртада Сафуан абый: ул башлап йөри, ул кузгата иде халыкны. Эшләсә — эшли, шаярса — шаяра, җырласа — җырлый белә торган үзенә бер хикмәтле кеше иде ул.

Мотоциклына тəз утырып кайтып килə, арттан эте ияргəн, өрə-өрə чаба... Капка төплəрендə карчык-корчык, эштəн арып кайткан ирлəр, бала-чагалар. Сафуан абый урамның һəр ике ягындагылар белəн дə башын борып, исəнлəшеп кайта, алтын тешлəре елтырый. Каршы өйлəр рəте безнең турыда бетə. Мəдинə апаның өе иң кырыйда. Эт өрдереп, урам тутырып кайтып килгəн Сафуан абый туры гына кереп китми әле, чирəмле таудан бер əйлəнеш ясый, аннары гына бəлəкəй капканы алгы көпчəге белəн бəрдереп, ишегалдына кереп китə, капка ябылып өлгергəнче, шатлыклы өрə-өрə эте дə кереп чума.

Безнең капка төбенə җыелган күрше-тирəлəр аның бу мəзəк гадəтенə каш җыерып та, көлеп тə карап утыралар.

— Акыл утырмаса утырмый икəн бəндəгə, кырыкка җитеп килгəн адəм югыйсə,— Төмсə чырайлы Нəүширван абзый беркайчан да əйбəт димəс, гел кирегə сукалап, эче авырткан кеше сыман, чырае сытык булыр. Аның сүзен берəү дə җөплəми, чөнки Мəдинə апа монда... Ə ул Нəүширван абзыйны ишетми дə, рəхəт елмаеп утыра бирə.

Ул арада Сафуан абый, күн пинҗəген җилбəгəй җибəреп, йөгерəатлый, болай таба килə. Əллə ничə ел күрми торган шикелле ир-атлар белəн кул биреп күрешə, минем дə кулга бензин исе йоктырып ала. Сафуан абый килүгə, тын гына сөйлəшеп утырган очташларга җан керə.

— Фирүзəттəй, черек капка баганаң аварга тора. Председательгə əйттем. Кайтарырлар. Без аны момент утыртып куярбыз!

Фирүзəттəй Сафуан абыйга туры карамыйча гына рəхмəтен əйтə. Шул чак Нəүширван абзыйның сытык тавышы арага керə:

— Син, Сафуан туган, ике тəгəрмəчле тимерне тез арасына кыстырып чабам дигəч тə... Туры гына кереп китеп булмыймыни, таудан əйлəнмəсəң аны, каз таптатырга...

Сафуан абый, башын артка ташлап, рəхəтлəнеп көлə, алтын теш шəүлəлəре иреннəрендə уйнаклап ала.

— Өйрəнелгəн, Нəүширван абзый. Аэродромга төшəр алдыннан почетный круг бирə идек шулай...

Сафуан абый бу турыда артык сүз озайтмый:

— Əйдə, карчык, трактор ватылды минем, запчасть кайтканчы — ял,— диюгə, Мəдинə апа сикереп тора. Сафуан абый аны əллə ничек кенə, җайлы гына күтəреп ала да...

— Җүлəрлəнмə, Сафуан, олы кешелəр янында,— дип, Мəдинə апа аны битəрлəгəн була, үзе муеныннан кысып кочаклаган...

Сафуан абый аны күтəргəн килеш капкаларына кадəр алып бара. Карчык-корчык бу хəлне өнəмичə читкə борыла.

— Гадəтсез...

— Шəһəр кешесенең шул инде.

— Капты Мəдинə иргə, көтə торгач...

— Сəмəлүт йөрткəн дилəр, дөрес микəн соң?

Нəүширван абзый инде икелəнеп тормый, балта белəн генə юнып төшерə:

— Моңа тагын летчик булу. Керəчин салып йөргəндер инде шунда.

Ə миңа Сафуан абый ошый. Очучы булганлыгына да ышанам мин аның. Бервакыт ул һавадан очып барган самолетны күмелгəнче карап торды, күзлəре тоныкланып калды. Əллə нинди, сынып киткəн тавыш белəн миңа:

— Мəдинə апаңа əйтерсең, соңрак кайтылыр,— диде дə, мотоциклын сикертеп кенə кузгатып, олы юл ягына җилдерде. Төн уртасында гына кайтып керде ул.

Мотоциклын сүткəн чакта мин гел аның янында кайнашам. Бер вакыйгадан соң ул минем белəн инде шаярмый, олыларча гына сөйлəшə торган булып китте.

— Кабынмый, искра балонга киткəн,— диде ул, озак азаплангач.

Аннары бик житди генә итеп миңа:

— Бар әле. Мәдинә апаңнан сорап чык, бер банка искра булырга тиеш иде,— дигәч мин торып та йөгердем. Аның йомышын үтәргә әзер сөенеч белән кереп киткәч, Мәдинә апа бот чабып, тыела алмыйча көлде, иҗемнән кочып, «искра»ның ни икәнен аңлата-аңлата, Сафуан абый янына, капка төбендәге чирәмлеккә алып чыгып китте.

— Нигә алай шаяртасың, Сафуан, үскәч күрсәтер әле искраны үзеңә,— дип яратып битәрләгән булды. Мин, алданудан комачтай кызарсам да, Сафуан абый, буасы ерылган инеш кебек, шаулап-шаркылдап көлә башлагач, әллә ничек, җиңел булып китте. Су буена төшеп, карт өянкеләр арасында шулай, Сафуан абый сыман, башны артка ташлап көлеп караганым бар минем. Булмый гына бит. Тын җитми, күздән яшь чыга. Аныңча көлә белү өчен дөнья күрергә кирәктер, мөгаен...

Шул көннән соң Сафуан абый минем белән һәрчак олыларча сөйләшә башлады. Буш вакыты булганда, мине мотоциклына утырта да болынга алып чыгып китә. Үләнгә сузылып, күктән агылган мамыктай болытларга карап ятабыз. Мин болытлар агылышыннан мәгънә күрмим, туктаусыз сораулар яудырам.

— Сафуан абый, самолетта очу куркынычмы?

— Куркак кешегә күктә түгел, җирдә йөрү дә авыр.

— Моторы туктап, төшеп китсә?..

— Андый чагы да була. Менә шунда сынала да инде — куркакмы син, түгелме?!

— Ә синең егылып, төшкәнең булдымы?

— Бу тимер тешләрне матурлык өчен куйдырган дип беләсеңме әллә син. Булды. Аяк та сынды, теш казнасы да җимерелде. Самолетны саклап калырга кирәк иде. Андый чакта үзеңне онытасың ул. Бераз төзәтергә туры килде... үземне дә, самолетны да...

— Ничә канатлы самолетта очтың син, Сафуан абый?

— АН-2дә, синеңчә әйтсәк,— ике канатлыда.

Сафуан абый, теш арасына кыстырган үлән сабагын шырт-шырт өзеп, терсәгенә таяна, миңа үз итеп, сынап карый.

— Очучы буласың киләме?

— Үскәч мин көтүче булам.

— Нәрсә-ә?!— Сафуан абый торып утырып, тезләрен кочаклый.— Көтүче дисеңме?!

— Көтү көткәндә уйланып йөрергә була.

— Кызык син,— ди Сафуан абый, башын чайкап, үзалдына көлеп куя. Тагын сузылып ята да, кулларын каш өстенә кушырып, болытларга карый.— Уйланырга дисең инде...

Мин аңа күптән инде кымырҗып торган соравымны бирәм:

— Сафуан абый, сине очучылыктан төшерделәрмени?

Ул тагын торып утыра, гадәтенчә, шаркылдап көлә башлый.

— Шәп әйттең әй! «Очучылыктан төшерделәрмени...» Нәүширван абзый сүземе инде бу?

— Бөтенесе шулай ди.

— Кстати, белеп әйтәләр. Авыл — ярык тагарак кебек ул. Анда су да, сүз дә тормый. — Сафуан абый күн итеген салып ташлады, нидер укыган сыман, бер ноктага карап, бер тын утырды.— Сөйләсәң, тарихы озын инде аның. Тумышым белән күрше районнан мин. Инәй карчык авылда берьялгызы яши иде. Шул... Сирәк кенә булса да, айга берике, авыл турысыннан очып узарга туры килә иде. Инәй, самолет тавышын ишетүгә, капка төбенә йөгереп чыга иде. Нинди самолет очса да, шулай чыга торган булган ул. Мин, әнине күреп алгач, үзебезнең оч турысыннан бер әйләнеш ясыйм. Кайсы чакта, алдан әзерләнгән яулыкчәй ише күчтәнәчләрне төенчек белән ташлап киткәлим. Ул көнне инде авылда сүз гел шул турыда гына бара икән. Сәрвәр малае Сафуан

очып узган, әнисенә һавадан кучтәнәч ташлап киткән... и тагдалие. Соңгысында... Инәй карчык сырхаулап торам дип хат язган иде, кайтып килергә җай чыкмады. Соңгысында... Кайтып киләм Бөгелмәгә, авыл турысына җиттем, инәй карчык күренми. Бер әйләнеш ясадым, икене... ишегалдында җан сизелми. Урам киң, тип-тигез безнең. Тоттым да төшереп утырттым самолетны. Җыелды халык, җыелды бала-чага... Өйгә керсәм, инәй температура белән ята. Әйдә утыртып кына алып китәм, врачка күрсәтермен дим, кая ул... Һаман үзенекен сөрә, туган нигеземнән аерыласым юк, күршеләр караша, ди. Алай итеп, болай итеп авыл фельдшерын чакыртканчы, бер сәгатьләп вакыт үтеп тә китте. Ә аэродромда самолетның юлга чыкканын белеп торалар. Сәгать буе хәбәрсез... Ул бит синең колхоз алашасы түгел, самолетның юлы-вакыты исәпләнгән... Менә шуннан соң, син әйтмешли, летчиклыктан төшерделәр мине.

— Ә каян белделәр?

— Кырыйда ярдәмчем бар иде. Хәзер ул минем урында...

— Әниеңнең авыру икәнен әйтмәдеңме?

— Һы, күп нәрсәне белмисең шул әле син.— Сафуан абый әйләнеп ятты да үлән төпләрен сыпыра башлады.— Шул җәйне инәй карчык дөнья куйды...

Бер елдан соң, җәй башында, Сафуан абый каядыр китеп югалды. Казбек исемле эте генә торып калды. Урамга чыгып ята да, түбән очтанмы атлы я җәяүле күренсә, шунда таба торып чаба. Сафуан абый түгеллеген белгәч, туктап, колакларын тырпайтып карап тора да, башын иеп, кире капка төбенә кайтып ята. Әллә ничек, тавышын чыгармаска тырышкан кебек итеп, шыңшып үзалдына җылый.

Хуҗасы киткәч, Казбек ашаудан калды, сырт йоннары таланган кебек ямьсезләнде.

Мәдинә апа тагын ирләрчә киенеп, кун итектән йөри башлады. Кешеләр белән аралашмас, сөйләшмәс булды. Күршесендә ялгыз яшәгән сукыр Газизә карчык бар иде, шуны өйдәш итеп алды.

— Бичара, авыру әнисен ничә ел карады. Тагын монысын...— дип, Мәдинә апаны жәлләп, тирә-күршеләр сөйләшкәндә минем әнинең күзләре яшьләнә иде.

Үзе барында аны аңлап, өнәп бетермәгән халык Сафуан абыйны сагына, яхшы якларын кабат-кабат хәтердән чигерә, Мәдинә апаны ташлап киткән өчен каһәрли дә иде.

Безнең очта моңсу тынычлык калдырып, Сафуан абый әнә шулай каядыр китте дә барды.

Гомер эт яратмаган карчык-корчыклар да Казбекка сөяк-санак китерә, аны сыйпап-сөеп китәләр иде. Җәй буена шулай урамда ятып, хуҗасын көтте ул. Ябыгып, керләнеп бетте. Аның белән бергә без дә көттек Сафуан абыйны. Нигә китеп барды ул — беркем белә алмады. Хикмәтле сер Мәдинә апаның кысылган иреннәренә бикләнгән иде.

Сагыштан бетеренеп, «кайда ул?» дигән сорау белән һәркемнең күзенә инәлеп караган Казбек үз хәленә бик акрынлык белән генә күнекте бугай... Бәлки ул да Сафуан абыйның кинәт югалуына минем кебек үк рәнҗегәндер, аны төшләрендә күреп уянгандыр...

Кояш су буендагы өянкеләр өстеннән тәртә буе күтәрелде. Тау битенә таралган көтү әкренләп җыела төште. Икешәрләп, өчәрләп укмашкан сарыкларда инде ашау кайгысы беткән, бер-берсенең күләгәсенә сыенып, әлсерәгән хәлдә, үләнгә битараф карап торалар. Кояш кыздырырга тотындымы — сарыкның миен парга әйләнә башлый. Ул арада, үз күләгәсенә башын тертеп, туплау ягына бөтен көтү агылырга да тотынды. Туплау урыны буа астында, карт өянкеләр күләгәсендә, әскәк белән чүпләрлек тә үләне калмаган тап-такыр җир. Эсседән аңсыз калган сарыклар анда, күзен бәйләсәң дә, бара беләләр. Аларга хәзер

кояш хужа. Көн сүрелгәнче, тоташ ябалдашлык өянкеләрнең мәңгелек күләгәсендә рәхәт чигәчәкләр. Ниһаять, мин иркле. Бераздан буа ярына малайлар төшәр.

Инешнең сай урынына, чишмә сукмагы төшкән басмага таба йөгерәм. Басмадан йөгереп чыгу — үзе бер һөнәр. Янәшә салынган ике агачы да, баскан саен, аерым-аерым сыгылып тора, шуңа күрә, тигезлегеңне саклап, бер көйгә гәүдәңне биетеп кенә тирбәлеп чыгасың. Фырт киенеп кайткан кайбер шәһәр малайларын алдан кертеп җибәрәбез дә, арттан үзебез каты-каты басып, басманы тирбәндерә башлыйбыз. Тигез асфальтта йөрергә күнеккән шәһәр малае гәүдәсен тота алмыйча, чайкалып, кулларын җәеп, суга барып төшә. Авылның кем икәнлеген белсен!

Монда, чирәмле ярга елкылдап торган җиз капкачларын, камфоркаларын тезеп, кызлар самавыр агарталар. Яр буе шау-гөр итеп тора. Без, малайлар, өянке артларыннан качып кына киләбез дә, таш атып, су чәчрәтәбез. Китә чыр-чу, китә куыш. Җиткән кызларның сөйләшүе дә серле...

— БИРкиБИРчә БИРкыБИРлубБИРка БИРкуБИРнак БИРеБИРге БИРте БИРкайтБИРкан БИРиБИРде.

— БИРкаБИРян БИРкайтБИРкан?

— БИРкемБИРңе БИРоБИРзатБИРты?

Бу сөйләшүнең хикмәтен белсәк тә, аларның теле-телгә йокмый, бик кызу аңлашканга, мәгънәсен тотып кала алмыйбыз. Ә алар сибепме сибәләр. Төшкә дә килеп керде бит, полякча, имеш... Нигә соң ул кыз төшемә полячка булып керде? Бүген күрәм бит мин аны, күрәм...

Таш өстенә басып, Нәүширван абзый агач аягын читкә җибәргән дә чиләккә су алып маташа. Мин, дөбер-шатыр чабып, басмага килеп керүгә, сискәнеп китте. Кырынмаган караңгы чыраен күтәреп, кычкырып җибәрде:

— Көтүне иртә төшердең табырга, малай!

— Соң төшермәскә ару була, Нәүширван абзый.

— А-ай, ипледән ипсез туган. Телләшә тагын!

Нигә шулай гел караңгы чырайлы икән ул? Аягын гына түгел, елмаюын да сугышта калдырып кайткандыр кебек тоела ул миңа.

Бәбкә үләне арасыннан сузылган чишмә сукмагы олы урамга күтәрелә. Мин Нәүширван абзыйларның кабыргалары беленеп торган лапас түбәсендәге тишекләрне санап барам. Әнә, берсеннән, пырхылдап, тавык килеп чыкты да муртайган саламда тибенә башлады. Авыш капкалы ихата, киртә казыклары төрле якка чалшайган, төртсәң, ыңгырашып, аварга тора.

Ир-атлар арасында өй бурау, бүрәнә юнәтү турында сүз чыкса, Нәүширван абзый шунда ук аркылы килә:

— Агач белән ерак китеп булмый,— ди.— Керәстияннең шул инде аның: черекне алыштырып, гомер үтә. Ай-яй! Яуропада күрдем мин таш сарайларны! Килеп керсәң эченә — прәме алтыннан чигелгән инде менә. Безнең Сафа тегермәне шайлы көзгеләр!.. Мин андый затлы сарайда яшәсәм, билләһи, мәңге үлмәсием.

— Ә хатын-кызлары ничек, Нәүширван абзый?

— Хатын-кыз...— Нәүширван абзый үзен бүлдерүчегә төксе карап, ямьшәйгән киез эшләпәсен маңгаендагы олы миңенә төшереп тери.— Фашист тәреләре барысын ташлап качкан иде. Ул Берлинда, минсиңайтим, килеп керәбез хан сарайларына, ачып җибәрәбез көзгеле шкафларны... У-уу!— Нәүширван абзый яргаланган иреннәрен ялап куя.— Көзге алдында агын киеп карыйм фетр эшләпәнең, карасын киеп карыйм, яшелен, көрәнен — ниндие кирәк! Ул кәчтүмнәр!— дип, ул Хикмәт абзыйның бостон костюмының итәген бирчәйгән бармаклары арасына кыстырып ышкып карый.— Бу — чепуха! Вәт киеп күрсәттем мин ан-

да кәчтүмнәрне... Ул хатын-кыз киемнәре-е... Ефәктән дә челтәрдән. Кигереп кара инде шуны минем карчыкка... Хушбуй исеннән үк башына кабып егылачак.

— Полячкаң, полячкаң турында сөйлә әле,— дип, Нәүширван абзыйны тагын бүлдерәләр.

— Нәрсә авызыгызны ерасыз,— дип, ул, өнәмичә, читкә борыла да тәмәке төрә башлый.

Нәүширван абзыйны тыңлаганда, миңа ерак дөньяларның җиле кагылып киткәндәй була. Аның ямьшек эшләпәсе дә, фәкыйрь киеме дә күз алдында үзгәреп китә. Монда аның караңгы чырайлы гәүдәсе генә йөридер, ә елмая, көлә белгән чын үзе ерактагы затлы сарайларда адашып калгандыр сыман...

...Минем уйларны бүлеп, арттан кайтып килгән Нәүширван абзыйның тагын кемгәдер кычкырганы ишетелә.

Әтәчләре дә усал аларның. Әнә бит ничек, бер якка салынып төшкән кикриген селкетә-селкетә, болайга таба атлый. Арттан искәрмәстән генә килеп, сикереп куна да муен чокырын чукый башлый ул. «Кыска ыштан» кигән әтәчкәме соң инде куып житү — минем дә галошлар кулда бит.

Безнең капка башында песи кояшта җылынып утыра. Мин ишегалдына керүгә, ул капка баганасы буйлап агып кына төшә дә, чалбар балагына ышкына-ышкына, сырпаланырга тотына. Мин аңа мендәр өстендәге сөлгегә каплап куелган арыш шишарасын сындырып бирәм. Ишек катында җиңел сандалилар мине көтеп тора. Кара күннән, арты басылмасын өчен эченә каен тузы куеп эти тегеп бирде аны. Кибеткеннән дә матуррак. Баскан саен, аеллары чылтырап китә. Агач саплы, җиз бөҗралы пәкеләре генә дә ни тора аның. Андый нәзек әйберләрне ул телен чыгарып, онытылып, үзенә бер тәм белән эшли. Нәүширван абзый да аңардан күреп, пычаклар ясаган була. Аныкы инде бөтенләй башка. Сабы да шомартылмаган, пычак йөзе дә тешләнмәгән пычкы кебек. Йомшак ала дип, күрше-тирәләр чәч алдырырга да этигә керәләр. Нәүширван абзый алса, ярты башны канатып бетерә, ябыштырырга фуфайка мамыгы җиткерәлми диләр.

— Син шуны онытма, улым,— ди эти миңа.— Эшне тизрәк бетереп, азагын күрергә ашыкма син. Һәммә әйбернең дә җаны бар. Ул синең кабаланып, аннан-моннан гына тотынуыңны сизә, сиңа карыша, баш бирми башлый. Тәмен белеп, яратып тотынсаң, ул үзе үк сиңа ярдәмгә килә.

Шуннан соң, мин нинди генә эшкә тотынсам да, этинең сүзе искә төшә; тал чыбыгыннан матурлап сыбызгы төшерәмме, әнигә, пыяла белән шомартып, уклау ясыйммы, койма кадаклашаммы — тотынган коралымның серенә, җаена төшенергә тырышам. Әйбәт чыкса, эти, улым үземә охшаган шул, дип мактап куя, ә начар чыкса, мин әнигә охшаган булам...

Мин баскычта сандалиларымны киеп торганда, арттан ишетелгән тавышка сискәнеп борылдым. Күрше Нәзифә апа үзләренең бакчасыннан дәшә икән, куаклар арасыннан зәңгәр яулыгы гына күренә.

— Тәнзил үскәнем, мә, кура җиләгеннән авыз ит,— дип, койма аша миңа бер стакан кура җиләге суза.— Көтүчеләр элек өйдән-өйгә сыйланып йөри торганнар иде,— дип елмая. Сузылган куш учыма эре җиләкләрне бушатканда, мин телемне көчкә әйләндереп рәхмәт әйтәм. Нинди гадәттер инде бу — рәхмәт әйтергә, олылар белән исәнләшергә оялып интегәм.

— Хикмәт абыең эштән кайтуга вареньe кайнатырлык булды, ди Нәзифә апа. Нидәндер кыенсынган шикелле, гел түбән карап сөйләшә ул.

Җиләкләрне тиз генә хәл иткәч, уч төбен бер-берсенә ышкып, капканы ачуга, эсселек кайнар сулышын йөзгә бәрде, ишегалдында сизелмәгән генә икән. Капка келәсен төшергәндә, мин, борылып, ялгыз Өянкегә карыйм — әлсерәп, канатларын салындырган кошка охшап утыра ул. Ябалдашы еракта күренгән гөмбәзле Чатыр тау белән нәкъ бер биеклектә.

---

Өянке күпме гомерен су буена күченеп китү уе белән уздырды. Су буендагы агачлар шавын онытылып тыңлый, аларга сокланып, мөлдерәпләр карый иде ул. Иңгә-иң терәлешеп, дымлы рәхәтлектән мәһабәт булып үскән өянкеләр өстеннән, яфракларының сул ягын әйләндереп, талгын җил исүгә, көмешсу дулкын йөгереп уза, җил борылгач, яфраклары тагын үз хәленә кайтып, куе яшел шауга күмелә.

«Күке дә анда кунып моңлана. Каргалар да анда кайтып оя кора. Ә миңа... Чыпчыклар кунаклап алганны санамасаң... Хәер, берәр йортка кунак кайтасы булса, саескан килеп, иң беренче миндә тавышын чарлый, аннары, йорт хуҗасының абзар я өй түбәсенә кунып чикаклый башлый...»

Ялгыз Өянке гомере буе инеш буендагы яшьтәшләренә кызыгып яшәде. Берәр төндә, кеше-кара сизмәгәндә, тын гына күченеп китү иде теләге.

Кинәт кенә, берничә ел эчендә, урамның бу ягындагы унлап йорт хуҗасы буш урыннар табып авылның үзәгенә күченә башлады. Өянкене утырткан Сәмигулла абзый да бүтәннәр белән беррәттән нигезен кузгатты. Ерак китмәде китүен, каршы якта иске өен сипләп торгызды да, хатыны белән бишектәге Байтирәген калдырып, биш-алты өй аша гына яшь хатынга йортка керде. Үзе белән Хикмәтне дә алды. Кайчандыр, Өянке янында ябага туп тибеп уйнап йөргән Давыт исемле түбәтәйле малай хәзер инде үсмер егет, туганнарында торып, район мәктәбендә укый иде.

Ихатаны сүткәч, шәп-шәрә кыр уртасында Өянке берьялгызы, ятим утырып калды. Сәмигулла абзый, үткен балтасын алып, кисәргә дип талпынган иде дә, тагын нидер уйлап кире чигенде. Нигез төсе булып калсын дип кызгандымы, инде буй җибәргән агачның көч каршында сабый баладай чүгеп, мең яфраклары телендә инәлеп ялваруын сизендеме, биленә таянып, озак кына басып торды, нигәдер балта күтәрергә кулы бармады.

Ихатасыз, хуҗасыз калгач, баштагы мәлләрдә, Өянкене вакыт-вакыт куркy ала иде. Сыер килеп ышкынганга, кәҗәләр үрелгәнгә, малайларның кепка атып, нәзек ботакларын сындыра-сындыра, өскә үрмәләвенә күнекмәгән иде ул.

Иң хәтәре шул булды: янәшәдәге иң тәмле сулы саналган коены, өске бурасын сүтеп, түбәдән төшкән тирес һәм балчык белән күмеп, җир белән тигезләп киттеләр. Шул чакта, томаланган суның тирәндә буылып кычкыруын Өянке тамырлары гына ишеткәндер мөгаен. Әллә кай тирәнлекләрдән үзенә эз сабып килгән су моны күтәрә алмады, кешеләргә рәнҗеп, үз юлыннан кире чигенде, еракка качты. Моны кешеләр ваемнарына да алмагандыр, ә Өянке тамырлары... Менә ничә ел инде тамырлар, мәңге караңгы җир күгендә капшана-капшана, меңнәрчә тармакларга бүленеп, һаман тирәнгә төшәләр, һаман як-якка җәеләләр. Су тавышы ишетелми, Өянке яфракларына дым җитми. Бөтен җегәрен тамырларына бирмәсә, инеш буендагы яшьтәшләре кебек югары карап үсмәс идемени югыйсә.

Инеш буена күчеп китү теләге Өянкедә нәкъ менә шул елны, су юлы качканнан соң туган иде.

Тора-бара күнегеп, үз әйләнәсендәге кешеләр язмышы белән яшәү аның үз гамен әкрен-әкрен генә оныттырды бугай.

Сугышка киткән ир-егетләрнең кайтуын көтү... Йөзләре, тавышлары истә... Байтиракнең ачы үлемнән саклап калуы...

«Ничек күченеп китәсең ди, бер оч кешеләренең ыгы-зыгылы тормышын, кайгы-шатлыкларын үзең аша үткәр дә, ничек итеп күченеп китәсең ди. Мин аларсыз, инеш буендагы тынычлыкта, җилләр көенә, кошлар тавышына гына кинәнеп яши алыр идем микән? Ныклап уйласаң, мин алардан бәхетлерәк тә бит әле. Җил-давылларны, кар-яңгырларны ялгызым күтәрүем бер хәл — нәзек ботакларымны рәхимсез сындырып, юл буйлап җил тәгәрәткәнне мин чарасыз калып күзәтәм анысы, ә су буендагылар җил-давылларны бердәм үткәрә, шуңа күрә алар миңа караганда куерак та, көчлерәк тә... Ә барыбер мин үземне аларга караганда бәхетлерәк саныйм...

Сугыш бетеп, бер ел үткәч, Алтын Болак авылы кешеләре, матур бер гадәт уйлап чыгарып, минем ялгыз моңсулыгыма җылы кул биреп кагылдылар. Җиңү көнендә хатын-кызлар, яудан кайткан ир-атлар минем яныма җыелды. Шушыннан киткәннәр иде бит алар, шушыннан озатып калганнар иде бит алар...»

Ирләре һәлак булган хатыннар кара хәбәргә әле дә ышанмыйча, әчке бер өмет белән, Өянке ботакларына үзләре чиккән кулъяулыкларны элделәр. Алардан соң, вәгъдә куешкан егетләре кайтмый калган кызлар, кулъяулык тотып, Өянке янына килделәр. Күзләре яшьләнде. Китте хатирәләр. Төркем-төркем булып, Өянке тирәсендә озак сөйләштеләр. Бәйрәм-тантана иде бу, уртак кайгыларны бүлешү дә иде бу...

Авылның шушы юлдан чыгып киткән йөз унике ир-егете кире әйләнеп кайтмады. Ә Өянке ботакларында алар истәлегенә төрле җепләр белән чигелгән, тамбур энә белән читләнгән йөз унбер кулъяулык җилферди. Бер кулъяулык... әлегә эленмәгән... Нәзифә кулында. Җиңү көнендә ул урамга йөз ертып чыга алмый, Өянке янына җыелган халыкны койма ярыгыннан гына йөрәге сызып күзәтә. Төне буе чиккән кулъяулыгы күз яшенә манчылган. Эчтән үксеп, тавышсыз җылый-җылый, ихатасыннан торып күзәтә, әмма дөньяга чыга алмый. Аның да кешеләр арасында буласы, кулъяулыкны бергә эләсе килә — кодрәте җитми. Ире Хикмәтулла турында, немецларга сатылган, үзе теләп әсир төшкән икән дигән хәбәр бөтен авылга таралган, аны пышылдап, колактан-колакка гына йөртәләр. Нәзифә сизә, карашларыннан сизә, иелгән башын турайта алмый, күзләрен күтәреп карый алмый. Ирнең йөз карасы хатын-кызның чәчләренә ак булып төшә икән. Нәзифә эштә, кешеләр арасында булганда да җаны ялгыз. Берничә мәртәбә районга чакыртып, ире турында сорашкач, тәмам сыгылып төште ул. Үлеп калса, җиңелрәк булыр иде ичмасам дип бер каһәрләсә, төннәрен торып, икенче төрле уйлый иде. Күңеленнән һич тә моңа ышана алмый, ире белән үткәргән бер ел гомерен кат-кат хәтереннән чигерсә дә, үзен мәҗбүр итеп тә, шикләнер сәбәп таба алмыйча интегә иде.

Өянке яныннан инде таралыша да башладылар. Койма аша карап торып, тәмам арыган Нәзифә, йөрәгә алгысынуына түзә алмыйча, капка келәсенә тотына, тагын кире китә, ишегалдыннан бер урап килә, ике урый, әмма капканы ачып, урамга чыгарга йөрәксенми, тагын туктап кала.

Караңгы төшкәч ул, коймаларга елышып, Байтиракләр турына кадәр җитә, аннары, тирә-юньдә ул-бу сизелмәгәнгә тәмам ышангач кына, курка-курка гына басып, Өянке янына килә. Эчкәргерәк ботагын сайлап; калтыранган куллары белән каушый-кабалана, кулъяулык почмагын төйнәп куя. Йөрәге тулышып-тулышып тибә, төн эченнән әллә нинди күзләр күзәтәдер кебек, әллә нинди шәүләләр аны уратып алырлар кебек. Һәм ул, куркудан, кимсенүдән рәнҗеп, җылый-җылый, Бай-

тирәкләр утыргычына кадәр йөгерә-атлый килә дә, җиңел сулап, башын артка ташлап, бер тын йолдызлы күк йөзенә карап утыра. Яшьләре кипкәнче бик озак вакыт узгандыр кебек тоела, һәм ул, сискәнеп койма аша карый. Байтирәкләр әле ятмаган, утлары бар. Капканы сак кына ачып, ул эчкә керә. Шушындый чакта бер җылы сүз, туганнарча караш кирәк, ничекләр генә кирәк әле. Аяк тавышын ишетепме, Солтания килендәше ишек ачып каршылый, кыстый-кыстый, табын янына китерә. Байтирәк аңа төксе генә карап ала да:

— Тагын шешенеп беткәнсең,— дип, чынаяк шалтырата.— Кешеләрдән качып эләрлек булгач аны...

Нәзифәнең бал кашыгы кулыннан төшеп китә.

— Зинһар, кешегә чыгарма, Байтирәк,— дип, ул аңа инәлеп карый, капкан чәе, утлы кисәү булып, тамагын өтеп ала.

— Бөтен нәселгә кара яккан кешене мин!..

Байтирәк, урыныннан кисәк торып, каты-каты басып, түр якка чыгып китә. Ике хатын, бер-берсенә карарга, кыймыйча, сүзсез калалар. Кайчы асылган гер өстәлгә төшеп терәлә дә, вакытны керт-керт кискәләгән сәгать теле туктап кала. Мич артында сайраган чикерткә тавышы гына пычак йөзе кебек үткен тынлыкны бераз йомшарта төсле. Нәзифә җылый алмый, бу минутта аның бөтен тәне, бәгыре отыры катылана гына бара. Яшәргә, бернигә кармый яшәргә дигән бер үҗәтлек белән торып, ишеккә юнәлә. Солтания аны капкага кадәр озата чыга.

— Үзеңне бетермә, Нәзифә, үтәр. Бу дөньяда ни булмас... Байтирәккә ачуланма, гарип кешенең җаны каты була аның. Мин аның көенә генә торам...

Нәзифә дәшми. Бик эчкәре яшерелгән ышанычын, өметен сүзләргә әйләндерү — аклану булыр иде. Икеләнү арасында, су өстендәге күбек кебек тирбәнеп торган ак өмет бөтен рәнҗү-кичерешләргә яктылык сирпи. Юатучы да бары тик үзең, үзең генә булырга тиеш...

Өянкенең ботакларында таң җилендә йөз унике кулъяулык җилферди. Йөз унике язмыш... Әгәр, үзләренә багышлап чигелгән бу кулъяулыкларның ияләре исән булса, күленмәгән күпме көлү, сөйләнмәгән күпме сүз, эшләнмәгән күпме эш — көннәрне, айларны, елларны баетыр иде. Капкалар ешрак ачылыр, өйләр артыр, морҗалардан төтен баганалары биеккәрәк күтәрелер иде.

Тумый калган күпме бала... Салынмый калган күпме нигез... Җырланмый калган күпме җыр...

Әгәр алар исән булса, күпме өй тәрәзәләре дөньяга көлеп ачылган булыр иде.

Шулай итеп, ел саен, Өянке ботакларында Җиңү көнендә йөз унике кулъяулык җилферди. Карталарда бер нокта белән генә билгеләнгән Алтын Болак авылының ил өчен башын салган күпме язмышы. Чит җир туфрагында ятып калган ир-егетләрнең исеме кулъяулык почмагына кадерләп, күз нуры кушып чигелгән.

Өянкене теләктәш итеп килгән кешеләрнең шушындый яңа гореф-гадәтен саклар өчен генә дә яшәрлек бу җирдә.

Хәтер булып, яфраклары арасында яктырып җилфердәгән йөз уникe кулъяулыкны күтәреп торган Өянке, инеш буендагылардан олы бер өстенлеген тойган хәлдә, ничек инде күченеп китә алсын ди...

---

Мин буа ярына төшкәндә инде малайлар җыелган иде. Зәңгәр күзле, аксыл-сары чәчле, нәкъ менә әтисе Байтирәк абзыйга охшаган Зәбир бөтенләй чишенеп ташлаган, су тамчылары ябышып калган күкрәгенә үзле балчыктан зур итеп йолдыз ясап куйган. Без барыбыз да җәй буена кояшта янып, куе чәй төсенә кереп бетәбез. Зәбирнең исә

зәңгәрсу-ак тәнен бер дә кояш алмый, борыны гына купшакланып, кызарып бетә.

Сөйләшергә өйрәнеп кенә килгәндә, ул, олылардан качып, беренче сәяхәткә чыга. Үзе биеклек арыш арасыннан машина тавышлары ишетелеп торган таш юлга барып җитә. Үтеп-сүтеп йөргән машиналарга хәйран калып карап тора. Адашкан малайны төш вакытында гына табып алып кайталар.

— Әни, ибадибалар күрдем,— ди ул, машиналарны үзенчә атап. Еллар үткәч, олылар хәтерендә онытылмаган бу сүзне без, кередән кайтарып, аңа кушамат итеп тактык. И-ба-ди-ба... Шул сүзне әйтүгә, аның борын кызыллыгы бөтен битенә йөгерә,— Зәбир инде сугышырга әзер!

Икенче дустымның исеме — Фирзан. Ул кап-кара чәчле, нәзек сөякле, тугыз апасы куенында гына үскән иркә малай. Чут салып кәнсәләрдә генә эшләгән, «чөнки», «ләкин» сүзләрен генә кушып сөйләшә торган этисенең кушаматы аңа да күчкән — Актәпи. Фирзан бөтенләй ук чишенеп, трусиктан гына су керә.

Гадәттә без су коенырга килгәндә, «Кем алдан! Кем алдан чума!» дип, юлда ук киемнәребезне сала-сала ярышып йөгерәбез дә килеп житкән уңайга ярдан суга кадалабыз. Ә Фирзан: «Алай ярамый — көзән җыера да, үләсең»,— ди. Ярга килеп, ул башта беләкләрен, күкрәген чылата, чирканчык ала-ала, әкрен генә суга керә.

Менә без шундый өч дус инде. Аерылмас бергәлек артында — бүтән малайлар. Буйга мин Зәбирдән тәбәнәгрәк, Фирзаннан — озынрак. Таптакыр итеп кырылган, кояш ялаган баш түбәм майлы тәбикмәк ябылган кебек ялтырап тора. Кушаматым... Бүре маңгай.

— Һай, бүре маңгай,— дип Нәүширван абзый әйтә торгач, тәки ябышып калды бит. Көзгедән карыйм да җиде бармак иңлеге текә маңгаема ачуым килә. Бүренең дә маңгае шундый була микәнни? Болай булгач, миңа кызлар карамас инде, үскәч, озын чәч белән каплар идем каплавын.

— Көтүче килә, көтүче!—дип, малайлар мине шаулашып каршы алдылар. Көтү чиратындагы малай инде ул буага да, болыннарга да хуҗа кебек. Аның сүзе сүз. Су кереп чыкканда киемеңә «каз боты» да ясалмаган, чалбар балагына кычыткан да тыгып куелмаган була.

Чумып уйный торгач, колаклар томалана. Чирәмле ярга чыгып, бер аякта титаклый-титаклый, болын буйлап йөзеп барган җилел болыт шәүләсенә карап такмаклыйбыз:

Эт кояшы, тегеләй кит,
Тәти кояш, болай кил!

Шәүлә гаҗәеп зур тизлек белән өстебездән үтеп китә, һәм без тоташ яктылык эчендә калабыз. Колактагы су учка кысылып чыга.

Бер кырыйда пәкеле уйнау башлана. Җиңелгән кешедән теш белән суырту өчен җиргә чөй кагып куелган. Кып-кызыл булып бүртенгәнче теш белән чөйне суырып алу бер хәл әле, аны югалта да белергә кирәк. Артыңнан дүрт күз белән йөгергән малайларны эз яздырыр өчен чалыклый-чалыклый, үләнле төштәрәк төшереп калдырасың. Тапсалар — беттең инде — чөй таш белән тагын җиргә кагыла, тагын суырып чыгарырга кирәк.

Шулай гамьсез генә таралып уйнаганда, кемдер:

— Буржуй килә!— дип, шомлы аваз салды.

Тегермән ягыннан, машина камерасы тәгәрәтә-тәгәрәтә килгән Корычбайны күргәч, уенның уты сүрелде. Ул бездән өч-дүрт яшькә зуррак. Абыйсы Бөгелмәдә «Студебеккер» дигән америка машинасында эшли. Фаралары алдына рәшәткәләр куелган ун тәгәрмәчле гаҗәп зур машина. Таһир абзыйның полуторкасы аның янында чебеш кебек кенә кала.

Безнең төшләргә кергән машина камерасы бары тик Корычбайда гына. Корычбайда — бездә булмаган кием. Кызыл каймалы хәрби фуражка аңарда гына. Ә без, чүпрәк кепканы киереп, эченә бөгәрләп тимер чыбык тыккан булабыз, шәүләгә карасаң, хәрби фуражка сыман күренә үзе, ә болай...

Корычбай сугыш уены оештырырга ярата. Аягында—гармун куныч-лы хром итек, кулында — күн перчатка. Чалбары галифегә охшап, кабарып торсын өчен, ике кесәсенә дә төйгечләп чүпрәк тутырган. Башында бәрәңге колагына төшеп терәлгән хәрби фуражка. Бил каешына агач пистолет кыстыра. Эре, сирәк тешләре арасыннан черт итеп кенә төкерә дә җибәрә сала башлый. Аклар, кызыллар ягына бүлү башлана. Китә кычкырыш, китә талаш — берәүнең дә аклар ягында буласы килми. Корычбай бил каешыннан пистолетын тартып ала да:

— Полундра! — дип кычкырып җибәрә. Аның кәҗә белән сарык бергә кычкырган ише тавышыннан без иелеп куйгандай булабыз. Без аңламаган бу сүздә ниндидер хикмәт бар сыман. Шуннан ул безне тезеп бастыра.

— Үрә кат! — дип команда бирә. Без эчне алгарак чыгарып, тезне тезгә тигереп тын калабыз.

— Шәлперәәй!

Бу командадан соң инде тезләрне бушатсаң да ярый. Корычбай күн перчаткалы кулын билендәге пистолет сабына салып, рәт алдыннан әрле-бирле йөренгән була.

— Аклар ягындамы, кызыллар ягындамы, барыбер, син батыр сугышчы булырга тиеш. Яратмыйм бәхәсне! — ди ул, син ак, син кызыл дип, җилкәгә сугып, рәт буенча килә башлый.

Аннары, агач автоматларыбызны кысып, аксыргаклыкка йөгерәбез. Аклардanмы, кызыллардanмы — барыбер — әсир ителгән малайны Корычбай катына китерәсең. Ул — хөкем чыгаручы, җәза уйлап табучы. Бер сәгатькә баганага бәйләп кую дисеңме, шәрәтән килеш кычыткан-лыктан үтү, ун мәртәбә башны суга тыгып алу дисеңме (Әгәр кычкырсаң, тагын өстәлә) — болар бар да Корычбайның күптәнге җәза алымнары. Әгәр инде каршы килсәң, Корычбай сине егып салып, сыртыңа менеп утыра да, кыска чәчеңне кирегә ышкып: «кәҗә мае» чыгара башлый. Минем өчен иң хәтәре болар түгел әле, иң хәтәре — умарта оясына ябылу. Хикмәт абзыйның бакча башында буш умарта оясы бар (Күч төшеп оялар дип куйган инде ул аны). Корычбай шунда яба да капкачы өстенә менеп утыра. Эчтә бөгәрләнеп яткан «әсир» кычкыра, җылый башлагач кына чыгара. Арада бер Зәбирнең генә моңа исе китми, аның җылавын күтәргә түземе җитми Корычбайның, ахырда үзе ачып чыгара.

Бүген Корычбай җиңел зәңгәр тапочкадан, чалбарын да «галифе» итмәгән, ак майкадан гына. Килеп туктады да, зыңлатып сугып, камерасын җиргә яткырды. Үзе дә үләнгә сузылды. Чылбырлы кесә сәгатен алып, капкачын чыртлатып ачты да алдына куйды.

— Бер кешегә унбиш минут вакыт бирелә.

Шунда ук чират тезелә башлады. Аның ни әйтергә теләгәне барыбызга да билгеле. Иң алга Нәүширван абзыйның урамда да гел коры ипи күшәп йөри торган бүксә Гамиры килеп баса. Аның артыннан — эреле-ваклы малайлар. Ә без өчәү читтә басып торабыз. Корычбай безнең якка күз төшереп алгалый. Камерасында бик тә йөзәсе килә югыйсә, чалбар балагын гына сызганып, киемле килеш су өстендә йөзү — үзе бер дөнья. Әмма Корычбайның шарты үзгәрүсез — унбиш минут берәү йөзә тора, шул арада икенче берәү аның табан астын кытыклап утырырга тиеш. Җитмәсә, ике кул белән, ике аягын да берьюлы. Бар-

маклар арып ялкаурак кытыклый башласаң, тибенергә тотына, йөзү вакытын кимәтә.

Сүз берләшкән кебек, без өчәү читтәрәк йөрибез. Түбәнсетми генә бирөп торсын иде ул камерасын. Күпме кытыкларга була аның каешланып беткән табанын?!

Нигә шулай соң, кызыккан әйберенә үз вакытында ирешеп булмый икән? Соңыннан булыр ул, камерасы да табылыр, ләкин инде без үсеп житкән булырбыз. Әкияттәге кебек, тылсым иясенә әйләнәсе идә дә уйлаган һәр теләгеңә ирешәсе иде.

Мин, ярдәм сорагандай, инеш ярыннан тезелеп киткән өянкеләргә, кабарынып яткан тауларга карыйм. Каяндыр серле бер шәүлә килеп чыгар да, шушы дөньяны ничек үзең теләгәнчә үзгәртергә икәнен пышылдап кына аңлатыр, тылсымын чишәр кебек. Бәлки аны еландай муенын сузып, каршыга ысылдап килгән ата каз беләдер? Бәлки аны муенын муенга ышкып, иркәләнеп торган әнә теге атлар беләдер? Юк, алар да белми бугай шул. Кояш астында изрәп яткан тугайда бер генә дә серле зат күренми. Бар да мин белгәнчә. Иртәгә дә, еллар үткәч тә шулай булыр. Инеш тә тегермән ягына карап агар, тәкрарлекләр дә һаман шулай чиелдап әйләнер. Без дә малайлар килеш калырбыз. Һәрвакыт безгә нидер житмәс кебек.

— Их, тизрәк үсеп житәргә иде. Буржуйның иен укытыр идек!

— Үскәч соң була инде ул,— ди Зәбир.

— Хәзер күрсәтергә иде аңа,— ди Фирзан.

Шул чак минем күзем арканга бәйләнгән бозауга төшә. Корычбайга ничек сабак укытырга дип, инде күпмеләр ватылган башка бер якты уй килә.

Без чокырсу жиргә жыелып утырабыз да киңәшләшә башлыйбыз. Корычбайның хәзергә күзенә бик чалынмаска кирәк. Аягын кытыклата торгач, изрәп, йокыга китү гадәте бар аның. Бер елны шулай, чирәмдә йоклап, авызы да кыйшаеп йөргән иде, хәзер төзәлде инде. Яз көне жиргә ятарга ярамый, жир суыра дигән сүзгә мин шунда ышанган идем.

Минем фикер белән Зәбир шунда ук килеште. Фирзан гына, гадәтенчә, икеләнүен белдерде.

— Әгәр уянса, нишлибез?

— Уянсамы?! — Зәбир, кабынып китеп, Корычбайны нишләтергә икәнен сөйли башлады. Торып басты да инде кытыклау чиратын, үткәргән бүксә Гамирны чакырып китерде.

— Кыйнасагыз, әтигә әйтәм. Әнә безнең моржа күренеп тора, беләңме! — дип, Гамир телен чыгарып алды.

— Син Нәүширван абзыйның иң көчле малае, шулай бит? — диде Зәбир, ак керфекле күзләрен хәйләкәр кысып.

— Юк, абый миннән көчлерәк.

— Һи-и, теләсәң, син аны жиңәсең.

— Жиңәрем дә...

— Сезнең өй безнең очта иң биек өй, әйеме?

Бүксә Гамир, көлмиләрме болар дигән шикелле, барыбызга да карап алды. Аның иң биек өй дигән бәя белән бик тә килешәсе килә иде. Ул, сынап, тагын бер күз атып чыкты да башын уңайга да, тискәрегә дә селкеп куйды. Үзең аңла шуннан.

— Моржагыз күренеп торгач, сине беркем дә кыйный алмый, курыкма,— дип, Зәбир, аның бүксәсен яратып кына кул аркасы белән чәбәкләде. Һәм төп сүзгә күчте:

— Буржуй йокыга киткәч, шыпырт кына килеп әйтерсең, яме.

Бүксә Гамир, кәкре аякларын сыгылдырып, йөгерә-йөгерә китеп барды.

— Кавалерист булыр бу,— дип, Зәбир авызын ерды. Шул чакта минем аңа якын итеп кенә Ибадиба дип эндәшәсе килде.

Таш та әзерләп куйдык. Күкрәк эчендә нидер кымырҗып тора. Бары чыгармы уебыз? Буржуйны көлкегә калдырасы иде бит, онытылмаслык итеп.

Зәбир чыраенда бернинди пошыну сизелми. Каралып беткән тавык тәпие табып, кулына ала.

— Әйбәт булды әле, безнең бер тавык аксак иде.

— Ташла шакшыны, — дип, Фирзан борынын җыера.

— Тавык тиреслектә казынып йомырка ясый. Бик тәмләп ашыйсың бит әле шуны,— ди Зәбир. Юктан да кызык таба белә ул. Сөйләшү рәвеше дә беркемнекенә охшамаган. Югары оч малайларын аптыратып бетерә.

— Мин кичә әни белән Бөгелмәгә бардым, морожный ашадым,— ди югары оч малае.

— Син!— ди Зәбир күзләрен зур итеп ачып гаҗәпләнгән була.

— Әйе, мин,— ди югары оч малае.

— Бөгелмәгә бардың?! — дип исе китеп сорый Зәбир.

— Бөгелмәгә бардым, — ди югары оч малае.

— Әниең белән?! — ди Зәбир торган саен тавышын күтәрә төшеп.

— Әни белән бардым,— ди югары оч малае горурлыгын чак тыеп.

— Син... Бөгелмәгә... кичә әниең белән барып... морожный ашадың?! — ди Зәбир гаҗәпләнүенең соң ноктасына җитеп.

Аны шулкадәр исен китәрүенә сөенгән югары оч малаеның дулкынланудан сүзләре төелә башлый.

— Морожный да ашадым... Кичә... Бөгелмәгә барып... Әни белән!— ди ул сулышына йотыла-йотыла.

Зәбир шушы урында көтелмәгәнчә нокта куя:

— Үзем генә бармагач, сөйләп тә тормыйм мин аны.

Аның шаяртып кабатлата-кабатлата сорашуын әле генә аңлаган югары оч малаеның йөзенә күләгә төшә.

— Югары очта яшәгән булалар тагын, ә аннары әкерен кыймылдый,— ди Зәбир алар турында.

Әллә нинди сораулар уйлап чыгара ул, җавапны барыбыз да эзләгән булабыз, ә иң кызыгын, хәтердә калырдаен ул таба.

...«Кәҗә нигә сакаллы? Койрыгы кыска булганга. Чатыр тау нигә зәңгәр булып күренә? Төнлә анда зәңгәр йолдызлар ява. Җәй уртасында күке нигә сакаулана? Сандугач буласы килгәнгә. Инеш нигә гел түбән очка таба ага? Сафа тегермәне шунда булганга. Энә карагы нигә дүрт канатлы? Ярдәмче канат камыт энәсе урлаганда кирәк...»

Буа ярыннан инде шактый ераклаштык. Сарыклар туплавы ягыннан әчкелтем коры ис килә.

...Зәбирнең «Борылдык!» — дигән тавышы миңа бик ерактан ишетелгән сыман. Борылып карасам, буа ярыннан бүксә Гамир күлмәк болгый, Зәбир белән Фирзан йөгерә үк башлаганнар икән.

Аяк очларында гына килеп, Корычбайның чынлап та йоклаганмы икәнен тикшерәбез. Зәбир нәзек үлән сабагын аның битендә йөртеп ала, тегә, чебен кугандай хәрәкәтләр ясый. Малайларга бик тавышланмаска кушып ишарәлибез дә, гамьсез генә күшәп яткан бозау янына киләбез. Зәбир аның тамак астын кашып тора, мин муенчагын ычкындырам. Аннары өчәүләп, какшата-какшата тимер чөйне суырып чыгарабыз. Булды, бозау, син иректә хәзер, арт сикертеп, уйнаклап чаба аласың. Малайлар башыннан йөргән буржуйны бозау хәленә калдырырга кирәк безгә.

Бик текәлеп карап торсаң, йокысыннан тиз уяныр дип, Зәбир малайларны арткарак чигерә. Арканны буржуйның чалбар балагы астыннан чыгарып, бушрак итеп, ике-өч мәртәбә уратабыз. Шул вакыт, иркә ыңгырашып, Корычбай аягын күчермәкче була, аркан җибәрми тегене,

менә ул күзләрен чак ачып, башын күтәрә, шул мәлдә Зәбир арканны тартып кыса да кычкырып җибәрә:

— Малайлар!— үзе беренче булып, инде күтәрелә башлаган Корычбайның кулына барып ябыша. Безгә ияреп, бөтен малай буржуйга ябырыла. Аның әле беркайчан да болай аста калганы юк иде, башта ул аптыраудан сүзсез, чарасыз калды, аннары, әшәке сүзләр кушып, кисәтә, яный, куркыта башлады. Кызган малайларны туктатырлыкмыни, көчләнең җиңелүе һәркемгә кызык. Буржуйның куллары артка каерылып, бөтен гәүдәсе аркан белән уратыла. Зәбир арканны шәп итеп төйни, очын беркетеп, бая әзерләнгән таш белән тимер кендекне кагып та куябыз.

Чамадан тыш үртәлгән, ачуыннан бүртенеп чыккан Корычбай нишләргә белми, әле бер, әле икенче якка тәгәрәп карый, кул-аякларын селкетә алмагач, эчендәге бөтен зәһәрен чыгарырга керешә. Иң катысы безгә эләгә.

— Ибадиба, иманыңны укытам мин синең! Син дә көлеп торма, бүре маңгай, келәймә сугам мин аңа, күрерсең менә! Бусы тагын... Актәпи, хатын-кыз арасында чигү чигеп утырасы урында... Кырык апаңны чыгарып тезсәң дә котыла алмассың миннән!

Фирзан, үзенә ыргытылган бу сүзләрдән кызарып, читкә карый. Бүксә Гамирны күр әле син... Буржуйга ялагайланып йөргәнен онытып телен чыгарган, үртәпме-үрти тегене. Моны күргәч, кайчандыр укылган әкият искә төшә. Арыслан картайган, хәлсезләнеп ята, имеш. Аңа бөтен җәнлекләр дә килеп тибеп китәләр икән. Ишәк тә килеп типкән, арысланның шулкадәр гарьлеге кузгалган, бүтән җәнлекләр бер хәл инде, ишәк килеп типте бит, ишәк, дип зарланып ята, ди...

Буржуй башын артка ташлап, йөзенә «черт» итеп төкергәч кенә бүксә Гамир телен тартып алды һәм сытылып җылый башлады.

Без, барыбыз да сүз берләшеп, өйләргә таралыштык. Ялгыз калса, сүгенә дә кычкыра да алмас, күмәк бердәмлекнең нинди көч икәнен аңласын әле...

Инешне чыкканда басма агачлары артта биешеп кенә калды. Минем бит әле бер малай да белми торган яшерен серем бар. Мавыгып китеп, чак соңга калмаганмын. Нинди рәхәт ул үзең генә белгән сергә ия булу!

Район үзәгендә өч класс югары укыган ул кызны мин моннан соң «полячка» дип йөртермен. Кичә төшкә кергәч тә мин аңа Гөлсирин дип үз исеме белән әйтә алмадым. Аны күргәннән соң, әллә нинди сүзләр сайлап сөйләшәсе, бүтәнчә атлап йөрисе, үземне олыларча тотасы килә минем.

Авыл башына чыгуга ук мин аны искәреп алдым. Тегермән үренә житеп килә. Куе булып үскән киндер арасына кереп күмеләм. Котәм. Бөтен тән сизелер-сизелмәс кенә калтырый. Бик озак вакыт үткәндәй тоела. Юлга чыгып карарга да куркам. Бәлки ул булмагандыр, бик күрәсе килгәнгә, мин аны уйлап кына чыгаргандырмын?.. Ул район мәктәбендә укый. Анда да өйләре бар, монда да. Укудан тукталгач та ул әтинең өч көнен әтисе янында тора, калган өч көнендә авылга, кибеттә сатучы булып эшләүче әнисе янына кайтып йөри. Безнең очтан ул нәкъ шушы вакытта, сәгать бер тулгач үтә.

— Бигрәк купшы ул Ханифәнең кызы,— диләр аның турында. Яратып әйтәләрме, өнәмичәме — мин аңламыйм.

Аяк тавышы ишетелгәч, мин сагаеп, тынны да чыгармаска тырышып киндер сабаклары арасыннан юлга карыйм. Килә! Калын толымы бил турысына кадәр сузылып төшкән. Бер кулында күн сумка, икенче кулында сары чәчәк бәйләме. Башына кигән такыясы да гел сары чәчәкләрдән. Безнең авылда бераү дә көпә-көндез чәчәкләр тотып, урам

уртасыннан йөрми, койма, киртә буендагы сукмаклардан гына йөри. Ә Гөлсирин төп-төз атлап урам уртасыннан килә. Мин, күпмедер ара калдырып, бер кырыйдан гына аны кибеткә җиткәнче озата барам. Ул мине искәрми дә, артына да борылып карамый. Безнең класс кызлары булса, әллә ничә борылып карарлар иде. Юк... Мин аларның кулына чәчәк бәйләме тотып, башына такыя киеп, шушылай урам уртасыннан атлап бара алуларын күз алдына китерә алмыйм. Гөлсирин исә ниндидер мин белмәгән дөньялар аръягыннан безнең авылга ялгыш килеп чыккандыр, төшкә керү өчен генә яратылган кебек тоела миңа. Мин аның гадәти чишмә суы эчүен дә өстәл артына утырып ашавын да күз алдына китерә алмыйм. Әнә ул ничек, аяк очларын як-яккарак очындырып, гаҗәп тигез атлап бара. Нәүширван абзый әйткән полячка да нәкъ шундый иде микән?

Нинди дә булса күңелсезлек чыкса, мин Гөлсиринне искә төшерәм, рәхәт булып китә. Үпкәләвем дә, ачу килүем дә бетә, гел яхшы, тыңлаучан буласы гына килә башлый. Нигә соң әле мин аның кайтыр вакытын көтеп алам? Нигә соң әле мин теге очка кадәр аның артыннан ияреп барырга ниятлим? Нигә үзем дә белмим. Әгәр мин тылсым иясе булсам, Гөлсирин тукталасы таш кибетне күз күрмәгән җиргә, бик еракка күчереп куяр идем. Ул чакта бу юлның азагы тиз генә бетмәс иде, Гөлсирин, сары чәчәкле кулын җай гына селтәп, шулай барыр да барыр иде.

Шулай үз-үземне онытып, авыл башына килеп кергәндә, кинәт кычкырган тавыш мине җиргә төшереп бастырды. Нәүширван абзый икән, Өянке төбендә ята.

— Ма-лааай! Көтүне калдырып нишләп йөрисең урамда?!

Гөлсирин борылып карамаса гына ярар иде, дигән уй мине көйдереп ала. Ярый әле игътибар итмәде. Тагын кычкырына башламагае дип тиз генә Нәүширван абзый янына йөгерәм, үзем эчтән ни әйтергә инде моңа дип сәбәп эзлим. Андый вакытта хәйләсе дә табылып тора бит аның.

— Нәүширван абзый, сине күрергә дип бара идем әле. Ни бит... Бозавыгыз арканын өзгән. Бөтен аръякны чабып йөри.

— Бер бозау бөтен аръякны бетерала димени. Сез, шельмалар, үртәп өздергәнсездер әле. Күкәй бурлары.

Мин хәзер бөтенесенә дә риза, тик Нәүширван абзый гына кычкырмасын. Ул су буена төшкәч, Корычбайны да чишәр, җиткәндер инде, җәзасын алды бит. Бозавы үзе кебек ялкау аның, беркая да олакмас.

Гөлсирин инде хәтсез китеп өлгергән. Аны куып җитәр-өчен миңа сандали аелларын чылтыратып йөгерергә кирәк.

Нәүширван абзыйның кырынмаган сытык чыраен хыялымда йөрткән полячка белән янәшә куеп карыйм. Полячка урынына түшен киереп чәлдер-чөлдер килгән Сабирәттәй пәйда була.

Таш кибеткә җитәрәк, мин тагын арткарак калам. Тимер ишекнең тышкысы киереп ачылган. Гөлсирин кереп киткәч тә кесәмдәге бакырларны учка җыеп бер тын йөренәм. Бераздан соң гына, кыюланып, пыялалы ишекне шыгырдатып ачам. Эчтә тәмле исләр килеп торган салкынча һава. Гөлсирин әнисе кырыенда, прилавка артына баскан, чәчәкләре сулы банкада.

— Нәрсә кирәк, үскәнем?

Аның шулкадәр ягымлы тавышыннан май яккан күмәч тәме килеп, тәкерегемне йотып куйдым. Бөтен кеше дә «нәстә» ди бит, ә ул, әнә ничек, матур итеп, «нәрсә» дип әйтә. Болай булгач, мин дә моннан соң «нәстә» димәячәкмен.

Учыма батып кергән бакыр акчаларымны прилавкага куям да, читкә карап:

— Перәннек кирәк ие,— дим.

Гөлсирин бармак очы белән генә бакырларны катыргы әрҗәгә коя, аннары, миңа күз дә салмыйча, энисе белән сөйләшә-сөйләшә, өч прәннек үлчәп бирә. Каушый-кабалана алганда, прәннекләремнең берсе идәнгә төшеп китә. Аны иелеп алам да тизрәк тышка атылам. Прәннек кабып, яңакларым авыртканчы кысып чәйним, ә йота алмыйм. Күзләрдән эре-эре яшь тама. Прәннек баллы шул, тал кайрысы түгел... Колагымда Гөлсириннең тавышы: «Нәрсә кирәк, ускәнем?.. Нәрсә кирәк, ускәнем?..» Бу тавыш мине кимсетә дә, иркәли дә... Нигә мин аның белән бер яшьтә түгел икән? Үзем сокланган кешеләр белән бер яшьтә буласым килә минем. Керфек очына эленгән яшь тамчыларын кул аркасы белән сыпырып төшерәм дә буш урам буйлап йөгерәм. Гөлсириннең үз кулы тигән прәннекләрдән хуш ис килә. Аның исе итеп хәтердә калдырырмын мин аны. Һәрбер ис үзенә аерым булып хәтергә сеңеп кала бит.

Беренче класска укырга барырга чыккач, Байтирәк абзый очрап, зур ускәнсең инде дип, борынны кысып киткән иде. Аның бармагыннан йогып калган тәмәке катыш камыт күне, ат ябагасы исе атна буе борыннан китмәде. Ничә тапкырлар сабынлап кат-кат юсам да, бетми генә бит. Хәзер дә әле, Байтирәк абзыйны күрүгә, шул ис борын төбендә сирпелеп китә...

Мин тиз генә өйгә кереп, рәсем альбомы белән карандашларымны алып чыгам да аръяк болынга йөгерәм. Буа ярында әлегә беркем дә юк. Нәүширван абзыйның бозавы арканда. Тапталган үләннәр генә малайларның эзләрен саклый. Туплаудагы сарыклар, җансыз түмгәкләргә әйләнеп, күләгәдә рәхәт чигәләр.

Аксыргаклар кырыена ук барып, түмгәк өстенә утырам да альбомның чиста битен ачам. Шушы тауларны, бормаланып аккан инешне, куаклар артыннан күренгән тегермәнне ясыйсы иде, тик аларны кечерәйтеп, альбом битенә сыйдырырга осталыгым җитми. Шуңа күрә кеше сурәтләре генә төшерәм. Андый рәсемнәр белән тулган ике альбомым бар инде минем. Ясалган сурәтләрнең берсе дә Нәүширван абзый кебек ачулы кыяфәттә түгел, елмаерга кызыгып торалар. Бәлки алар, олы юлдан чыгып китеп, зур җирләр-илләр күреп йөргәндә мин танышасы, бергә яшисе кешеләрнең кыяфәтләредер?..

— Кеше сурәте ясама, улым, үлгәч, үзеннән җан сорарлар,— ди әни. Аның бу сүзләре миңа мәзәк тоела. Ничек инде мин үлим ди. Ничек инде алар җан сорасын ди. Җанны мин эчтә, күкрәк турысында, офыкка барып тоташкан зәңгәр күге, чишмәсе, таллыклары, инеше булган олы бер дөнья итеп күзаллыйм.

Рәсем ясауның үз кызыгы бар. Зәбирне дә, Фирзанны да каршыма утыртып, эти кебек телне чыгарып, рәсемнәрен күпме ясадым — охшамый гына бит. Бервакыт мин моның серенә төшенеп алдым. Зәбирнең сул күзе бераз өскә табарак уелып, кысылыбрак тора. Көлгәндә дә аның уң күзе ачылыбрак кала, сул күзе бөтенләй йомылып бетә. Мин моны күптән белә идем бит югыйсә, кулга карандаш алуга исә онытылып, ике күзен дә бер төсле итеп ясыйм икән. Шуны истә тотып сызгалагач, икесе дә кычкырып җибәрделәр:

— Вәт охшаган бу ичмасам!

Карый торгач, бераздан Зәбир:

— Туктале, тукта... Охшаган да бит, нигә соң минем бер күзем кыек килеп чыккан?— дип, аптырап, рәсемне болай да, тегеләй дә күеп карады.

— Күзең шулай булгач, нишлисең инде,— ди Фирзан, кесәсеннән көзге алып, Зәбиргә тоттыра.— Мә, кара.

— Юк, юк, көнләшеп әйтәсез, алай түгел,— ди Зәбир. Без төп-төз тал чыбыгы алып, Зәбирнең күзләре турына аркылы куябыз, ә ул көзгедән карап тора.

— Чынлап та!— ди Зәбир, авырлык белән генә килешеп.— Мин үземне ничә ел беләм дип йөрим, менә бит, малай, ә!— Зәбир гаҗәпләнүдән тел шартлатып куя.— Син үзең сон! Чәүкә борынының туры дип уйлыйсыңдыр әле, кесәңдә көзге йөртеп,— ди. Һөҗүмне ул Фирзанга күчерә. Тегесе, ышанмыйча, борынын тотып-тотып карый.

— Бер якка кыеш бит.— Зәбир аңа көзгесен тоттыра. Тал чыбыгын борын буйлата куя.— Күрдеңме?!

Фирзан дәшми, бит очлары кызарып чыга. Сизелә, ул да борынының бер якка кыеграк утырганын белми йөргән.

Шул чак Зәбир җиргә ятып, миңа төртеп күрсәтә-күрсәтә, көләргә тотына:

— Карале, Фирзан! Тәнзилнең уң колагын кара, ничек тырпайган, ә сулы бөтенләй яткан, кара әле!

Ышанмыйча, көзгене алам, колакларны капшап-капшап карыйм, чынлап та шулай икән бит, ничек моңа кадәр бер дә искәрмәгәнмен. Кепканы гел бер якка янтайтып йөргәнгә шулай тырпаеп калгандыр инде сыңар колак.

Үзебез өчен ачкан бу яңалыкны өчкә бүлеп, кинәнеп көлешәбез.

Мин шуннан соң кешеләрнең йөзен игътибар белән күзәтергә өйрәндем. Ак кәгазьгә йөз сызыкларын төгәл итеп төшерәсе килә, ә чынбарлыкта алай түгел икән.

Түмгәктә менә шуларны уйлап утырган малай тирә-юненә бүтән күз белән карый. Моннан биегрәк таулар бардыр, моннан юанрак агачлар бардыр, моннан киңрәк, яры күренмәгән сулар бардыр, ә аларны ничек сыйдырыр ул альбомына?

Көтүче булам ди ул, ә үзенең еракка китәсе, яңа дөньялар күрәсе килә...

---

Сугыш яралары әкрен-әкрен генә төзәлә барган саен, Өянке ботакларына Җиңү көнендә элеңә килгән кулъяулыклар саны да елдан-ел, берәмләп-берәмләп кенә кими башлады. Урта Азия якларыннан чуклы ефәк шәлләр бәйләп кайткан алтын тешле кунак кызлары, чит җирләрдә ятып калган егетләренең кайтырына инде ышанычын җуйган, төннәр озынлыгын тоеп, дәрте сүрелә башлаган авыл кызларын төрлечә кызыктырып, үзләре белән ияртеп киттеләр.

Төннәрен тәрәзәгә күбәләк килеп бәрелсә дә, коры яфрак кыштырдаса да чәчрәп уяна торган, һаман да әле ике кешелек урын җәеп ятарга күнеккән тол хатыннар гына беркая да кузгалмады. Баласы булганнар — бала юанычы белән, тома ялгызы — ирем исәндер, бер кайтып төшәр дигән бик тирән яшерелгән өметенә турылыклы калып, торган нигезләрен какшатмадылар.

Узган ел, Җиңү көнендә, Өянке ботакларына барысы туксан ике кулъяулык эленде. Бу юлы инде Нәзифә дә бишле лампа яктысында чиккән кулъяулыгын Өянкегә китермәде...

Өянке бүгенгедәй хәтерли әле: бәйрәмгә ике көн кала, төне буе гарасатлы давыллап, яшенле яңгыр яуды. Вак ботакларын рәхимсез сындырып ыргыткан давыл белән көрәшә-көрәшә җир белән күкне тоташтырып телгәләнгән яшен камчылары һәм бөтен тирә-юньне дер селкеткән күкрәү дулкыннары астында япа-ялгызы калган Өянке исән калуына инде тәмам ышанычын җуйган иде. Бу мәхшәрнең соңы күренмәс кебек иде.

Ниһаять, калын болытлар утлы итәкләрен җыеп алып, Чатыртау аръягына китеп күмелүгә, шабәргән, манма чыланган тирә-якне авыр сулышлы тынлык басты. Мондый давыллы яшенне бу язда беренче тапкыр кичергән Өянкенең яшь, нәзберек яфраклары калтыраудан туктап, тыныч һава куенына сыендылар.

Ул таңда, гадәттән тыш көлеп, уйнаклап чыккан кояш нурлары җир-

не парландырып сузыла башлаганда, арыганлыгы бөтен тамырларына кадәр төшкән Өянкс, үзалдына оеп, йокыга талды. Көтү куганда күзгала торган мал, кеше тавышлары да тынычсызламады аны.

Кояш белән бергә торырга күнеккән авыл халкы чынаяк-тәлинкә чылтыратып, чәй табыны янына утыруга, урам тагын берара бушап кала. Нәкъ шул мәлдә йөгерек таң җиле, яфракларын шыбырдатып Өянкенең сак йокысын ачты. Таркау бер җиңеллек белән уянган Өянке, таң хозурлыгыннан кинәнеп киерелүгә, сагаеп, юлга карады. Кара пинжәк кигән, кун чемодан тоткан ят бер кеше авылга якынлашып килә иде. Тирә-юньне күзләп, ашыга-ашыга атлый. Байтирәкләр турына җиткәч, туктады, койма аша үрелеп карады да, чемоданын куеп, учына йөткереп алды. Шул чакта бәләкәй капканы киереп ачып, кулына йөгән тоткан Байтирәк килеп чыкты. Ят кешене күргәч, сискәнеп, туктап калды. Шунда ук таныды ул абыйсын. Тик... нигәдер агарып китте дә, кеше күрмиме дигәндәй, югары оч ягына күз атып алды. Гүя аның күрешми торган еллар астында күмелеп калган туганлык хисен кеше күрсә ни әйтер дигән курку томалап куйган иде.

— Саумы, энекәш, әллә танымый торасыңмы? — дип, хәсетсез күзләре белән елмаеп, ике кулын сузып килгән Хикмәтулла, чит бер караш төбәгән туганының артка чигенә башлавын күреп, аптырап туктады.— Әллә танымыйсың инде, Хикмәтулла бит мин. Кайтып төштем менә...

Байтирәк — каушаган чакта карлыгып китүчән иде — тавышын көчкә суырып чыгарды:

— Кит! Кит... Туган түгел мин сиңа! Кит!

Иягеn калтыратып, кулын бутый-бутый кычкырган Байтирәк, чигенеп, капканы эчтән шартлатып япты да әле һаман тынычлана алмыйча:

— Кеше күзенә ничек күренерсең икән?! Ник кайттың? — дип, ачуына буылып, капка келәсен төшерә алмый азапланды.

Үз гомерендә күпне кичергән Хикмәт бик тетрәндергеч минутларда да йөрәген таш белән бастырырга күнеккән, һәр каршылыкны тешләре белән өзгәләп булса да үтеп чыгарга өйрәнгән иде. Ә монда... туган авылына кайтып җиткәч... чит җирләрдә исән-имин алып кайткан ашкынулы өметен бертуганының рәхимсез рәвештә салып таптавын күргәч... сыгылды да төште.

— Баскычың бик түбән икән, энекәш,— дип, телен чак әйләндереп әйтә алды. Байтирәкнең ишегалды түрендә ераклашкан адымнарын ишетте дә, ишетмәде дә ул. Күз алдында кара нокталар биеште. Чайкалып, койма тактасына тотынды. Ун ел буена талкынып каткан җаны күз яшен бөтенләй онытkan иде аның. Шушы мәлдә, туган җир туфрагына баскач, әллә нәрсә булды. Каршыдагы Өянке, урам, өйләр йөзтүбән әйләнеп, керфекләре арасында калтырый башлады. Тоташ аклыкка әйләнеп тулышкан күз яшьләре тәгәрәп сукмакка төште дә челпәрәмә килде. Бераздан, әйләнә-тирә кабаттан яктырып, Өянке дә, өйләр дә яңадан үз урынына кайтып утырды. Ул, таяныч эзләгәндәй, моннан ун ел элек хушлашып калган өйләргә, таныш капкаларга йотылып карады. Барысы да нәкъ шул чактагы сыман, берни дә үзгәрмәгәндәр кебек. Өянкенең дә калынаеп, тармакланып буйга үскәнен, кайбер капкаларның, киртә-коймаларның да яңартылганын искәрмәде ул. Читкә ыргытылган шушы еллар эчендә туган якның һәрбер үзгәреше гүя аның аша узган, аның катнашында эшләнгән. Бик озак, бер гомергә торырлык дәвердә төшкә генә әйләнеп калган шушы таныш манзараны гамәлдә күргәч, газаплы-җәфалы айларны сыйдырган чиксез озын вакыт учка сыярлык булып кысылды да килде. Кичә генә аерылган кебек, кичә генә шушы юлдан чыгып киткән кебек... Иртәнге тын хозурлыкта басып торган ир үзен җәзалап килгән бөтен тавышлардан арынып, саңгыраулаңган кебек хәтсез басып торды. Кайту, туган жир-

гә кайтып егылу иде бит аның бөтен хыялы, ә менә кайтып җиткәч, бусага төбендә исәнгерәп калды.

Хикмәт чемоданын кисәк кенә иелеп алды, шул арада Өянкенең ас-кы юан ботагын күз белән капшап чыкты, әгәр Нәзифә дә ишектән бор-са, шушында асылынам дип астыртын бер карарга килде.

Хикмәтулла ашыга-ашыга атлады. Нәзифәнең күзләрендә бер генә тамчы икеләну-шикләну чагылып алса да, кире борылачак. Диңгез-дәрьялар кичкән юлның азагы кыска булыр... Өянкегә кадәр... Димәк, салам түбә астында яшәп яткан авылдашлары аңа бүтәнчә карый икән бит. Байтирәк әле генә йөзенә бәреп әйткән сүзләр бөтен гавам фике-ре булып, аның колагында кабат-кабат яңгырады. Энесен ул беркат-лыга санап кына барыбер кичерә алмас, бүтәнчә әйтсен, белдерсен иде. Ул аның үз бәгыреннән чыккан сүзләр түгел, як-ягына каранып алуын-нан ук сизелде.

Дөнья хәбәрләре саркып кына кергән, бер алган гадәтне озак сак-лый торган салам түбәле өйләр кызу-кызу атлап барган иргә чәчәккә бөреләнгән гөлләре, ак пәрдәле тәрәзәләре белән ятсынып карап кал-дылар.

Йөрәкне һәркемгә ачып күрсәтеп буламыни, бары бер кеше аңласа, бары бер кеше сыйдырса, туган җир аны ничек артык саный алсын. Туу һәм үлем арасында тирбәлгән бу тормыш гаярьләнеп йөргән күп-ме ирләрне хатын-кыз алдына кайтарып тезләндерми...

Бер өмет, бары бер өмет алга әйдәде Хикмәтулланы. Капка әлгече-нең чылтырап ачылуына кадәр элеккечә икән бит! Ир кулын сагынып иңә башлаган ихата уртасына чемоданын куюга, ишек келәсе әкрен генә ачылды. Бусагага чыккан Нәзифә кисәк кенә утлы һава сулады да, бө-тен кайнарлыгын эченә йотып, катып калды. Бармакларын өзеп чыга-рырга җитешеп, камырлы кулын алъяпкычына ышкый башлады, Аяк ас-тындагы баскычны бөтенләй онытып атлауга, инде егыла башлаган хатынны Хикмәт тотып өлгерде.

Соңыннан, күз яшьләре аша көлә-көлә, бер-берсен бүлә-бүлә сөйлә-шеп туймадылар.

— Тәрәзәдән күргәч, башта танымадым. Районнан берәр вәкил ки-леп төшкәндер дә, фатирга миңа керткәннәрдер дип, котым очты. Ял-гыз хатынга соң... Атлауларың бөтенләй икенче, кыяфәтең...

Нәзифә заманында иренең бармаклар чуалырлык күкрәп торган куе чәчләрен хәтерләп, пеләшләнә, агара башлаган кыска чәчләрен сый-пап куйды.

— Ят ис килә синнән,— дип, ул иренең куенына сыенды.— Беләсең-ме, киткәндә синнән нинди ис килә иде, әле дә хәтеремдә.

— Нинди?— дип, Хикмәт аны сүз әйтергә дә ирек бирмичә кысып кочаклады. Кайтып җитүенә, Нәзифәнең бернинди шик-хөсетсез кабул итүенә үзен ышандырасы килә иде аның.

— Мунча исе, тәмле, эчкелтем корым исе килә иде.

Нәзифәнең елмаюында озак гомерле сагыштан арыганлык сизелә иде.

— Әни кичтән юып, мунчага әлгән иде шул күлмәкне,— диде Хикмәт.

— Әни биш ел элек үлде.

— Беләм. Бөгелмәдән теге очның бер малаена утырып кайттым. Ба-рын да сөйләде.

Тәрәзә төбендәге гөлләр арасыннан сузылган кояш нурлары идәндә биешә, песи яткан җиреннән шым гына төшә дә, посып кына килеп, шул нурларга тәпие белән кагылып карый. Агач караватта ак җәймә белән капланган мендәрләр. Стенадагы чигүдә пар күгәрчен үбешеп тора. Тәрәзә кашагаларына чупләм сөлге эленгән. Шушы газиз тойгы-лар уяткан гадәти генә әйберләрнең чынлыгына ышанырга теләгәндәй, Хикмәт барысын да тотып-сыйпап карады. Үткәне белән хәзерге ара-

сында сәер бер бушлык ята иде. Теге вакытта, кадерле булып калган хушлашу минутларына килеп чыкканчы, аерым-аерым үткән ул ел дәвер эченнән янәшә барып кына арадагы бушлыкка җан кертергә мөмкиндер. Моның өчен күпме озын төннәр, күпме озын көннәр үтүе кирәк иде.

Чит илләр гизеп кайткан иренең авыл кешеләренә хас булмаганча гәүдә тотышыннан, чит телләрдә сөйләшүдән ирен-ияк хәрәкәтләре дә бүтән рәвеш алуыннан ятсынуны Нәзифә үзе дә сизмичә онытып, тиз күнекте. Бөтен юшкыннарны юган көтелмәгән сөенеч күзләрен каплаган иде аның. Кеше сүзләрен, йокысыз төннәрдә калкып та үзе үк үтерә барган шикләрен хәзер инде ире каршында сорауга әйләндермәде. Кинәт моңсуланып, нидер көтеп текәлгән ирен кызыклы берәр вакыйга сөйләп, читләтеп кенә юата белде.

Җиңү көне иртән, Өянке янына барырга җыенгач, төн утырып чиккән кулъяулыгын пөхтәләп төреп, иренең кесәсенә тыкты.

Бәйрәм җыенында Хикмәт чыраендагы үтеп керә алмаслык корыч сабырлыгын ачмый гына авылдашлары белән күрешеп чыкты, саран гына сөйләште. Бик сагынган иде югыйсә. Очынып, кочаклашып күрешергә хакым юк дип уйлады. Мондагы тормыштан ул ун елга артка калган иде. Ул юкта ничә тапкырлар кояш чыгып, көн килгәндер. Алтын Болак авылында нинди эшләр кузгатылмагандыр, нинди генә мәзәкләр тумагандыр, ничә тапкырлар кояш Сарай тавы артына төшеп баемагандыр.

Байтирәк белән алар бер-берсен күрмәмешкә салыштылар. Ике йортта торсалар да, бергә уйнап үскән ике туган бер ата нигезендә, уртак мирас булып калган Өянке янында сүзсез аңлаштылар: арага салкын күләгә тамыр җибәргән иде.

Соңыннан Нәзифә белән икәүләп менеп, ата-ана каберенә зиярәт кылдылар. (Хикмәтнең әтисен сугыш чыгасы елны, урман кискәндә, агач баскан иде.)

Авыл өстенә төн иңгәч, теге елларда үзенең кача-поса барып, калтырый-калтырый кулъяулык элеп йөрүләренә үч итеп, Нәзифә ирен култыклады да кабат Өянке янына алып китте. Юл уртасыннан бардылар.

Хикмәт күләгәле яфраклар арасыннан кош канатлары кебек асылынган кулъяулыкларны тотып-тотып карады.

— Кем уйлап чыгарды моны?— дип сорады. Көндезге тамашаны күреп дулкынланган иде ул.

— Ничектер шулай үзеннән-үзе килеп чыкты инде. Безнең авыл гадәте,— дип, Нәзифә, өшегән кебек калтыранып, иренә сыенды.— Мин дә элә идем. Исән икәнең билгеле түгел иде бит. Соңгы елда гына... Чакырттылар, сораштылар... Ышандым мин сиңа.

Хикмәт ялт итеп Өянкенең юан ботагына карап алды. Асылынырга дигән ус, мәгънәсен җуеп, бавы өзелгән кое чиләгедәй тирәнгә төшеп китте. Күкрәк эчендә рәхәт авырту гына сызылып калды. Тәмәкесенә зажигалкадан ут элде дә ашыгып-ашыгып суыра башлады.

— Мин дә...— дип кыска гына әйтте Нәзифә.Ниләр кичергәнен дә, кулъяулыкны ничекләр элүен дә сөйли алмады.

Артык тыныч иде бу төн. Артык рәхәт иде үз күләгәсенә чумган өйләргә карап, янәшә утыруы. Шуңамы, ничә еллар буе телен йозакта тотарга күнеккәнгәме, Хикмәтулла да үз эченә йомылган хәлләрен тиз генә ачып салырга ашыкмады. Боларның барысын да бер генә көнгә кайтып күрә алсам, үлсәм дә үкенмәс идем дип уйлый иде. Ә менә хәзер кинәнеп яшисе дә яшисе килә.

...Кырык икенче елда, концлагерьдан беренче мәртәбә качканда, ул исән калырмын дип ышанмаган иде, бары тик иректә үлү, җанны чәнчеп торган чәнечкеле тимер чыбыклы коймадан читтә, тоткын булып түгел, э кеше булып үлү турында гына уйлаган иде.

Сак астында канау казыган йөзләгән әсирләр арасында ул тик бер уй белән янды: качарга, ничек булса да качарга... Тулы бер полк белән чолганышта калып, сугышның икенче елында ук әсирлеккә эләккән гапгади солдатның бәргәләнгән җаны коллыкны күтәрә алмый иде. Кояш чыгышы ягында калган авылы, карт наратлары шаулаган зират, Өянке янында озатып калган Нәзифә — күз карасыдай кечерәеп, йөрәгенә сыйган шушы күренешкә ул мәҗүсиләрчә табына һәм туган җир кадерenә дәхеле барлыкны шушы мәсхәрәле язмышын үзгәртеп кенә үз-үзе каршында исбат итә алачак иде.

Ай буе эшли торгач, канауга күмеп барган торба озынлыгы инде ун чакрымнарга җиткәндер, елга яры күренми башлаган иде. Әсирләр арасында, иртәгә башка җиргә күчерәләр икән дигәнрәк хәбәр таралды. Бүген качарга дип карар кылган өч әсир, төштән соң, эт кебек күзәтеп торган немец солдатларыннан күз яздырып, балчык өемнәре арасыннан кача-поса килделәр дә торба эченә кереп йомылдылар. Кичен, лагерьга алып китәр алдыннан барлау булачак, шуңынчы күпмедер ара үтеп калырга кирәк иде. Алдан Хикмәт кузгалды, икенче булып Полтава егете Кочура, арттан — Алабуга егете Назыйм.

Ашыгырга кирәк иде, төнгә елга ярына чыгып җитә алсалар — ирек дигән сүз. Эчкәре кергән саен, торба эче җылына, суларга авырлаша барды. Манма тиргә батып, һаман алга шуыштылар. Алга шуышкан саен торба эче отыры кысыла, тарая сыман иде. Тынны буарлык караңгылыкны бары тик алга, алга омтылып кына җиңәргә була иде.

Арттарак калган Назыймны көтеп ял иткән арада Кочура, көйгән иреннәрен кубарып, су турында мәзәк тә сөйләп алды. Төшенкелекне белми торган тәвәккәл егет иде ул. Ә Хикмәтнең кинәт кенә тәмәке тартасы килә башлады. Күптән инде тәмәкене иснәгәне дә юк иде югыйсә. Шундый чакта ни гаҗәп: су эчәсе дә, ашыйсы да килми, үтереп тәмәке тартасы килү тамак төбен кытыклый...

Суелып беткән терсәк-тез башлары тагын хәрәкәткә килде. Бер туктагач, кузгалуы авыр икән, дип уйлады Хикмәт. Алга барырга да барырга. Елга ярына төнлә чыгып өлгерсәләр... Анда — су, анда—һава, анда — ирек!

Шулай мүкәләп тә, шуышып та күпме барганнардыр, инде хәл бетеп, аңны җуяр дәрәҗәгә җиткәч, алда тычкан уты кебек кенә якты күренде. Фонарь яктысы, немецлар сизгәннәр дип, башта курка калдылар. Дөм караңгыда, вакыт төшенчәсен югалтып, тәүлек буе шуышканнарын, инде икенче көн уртасы җиткәне башларына да килмәгән иде. Соңыннан, төшенеп алгач, төн җиткәнне көтәргә булдылар. Назыйм тәмам хәлсезләнгән иде, шунда ук йокыга китте.

Еракта, торба тишегеннән бәргән якты әкрен-әкрен сүрелә төшеп, тимер кыршау дөм караңгылыкка чумгач, тагын кузгалдылар. Якынайган саен ныграк сизелә барган салкынча һава агымы манма тиргә баткан тәнгә рәхәтлек бирсә, терсәк һәм тез башларындагы кан укмашкан яраларны йсә ачыттырып әрнетә башлады. Иң хәтәре — шулкадәр араны мең газап белән үтү булмаган икән әле. Коточкыч гаделсезлек инде килеп җитеп, ирекә кул сузымы ара калгач булды. Беләк юанлыгы тимерләрдән торба башына эретеп ябыштырылган рәшәткәгә килеп терәлгәч, кем нинди халәт кичергәндер, шушы көтелмәгән чарасызлыктан бөтен буыннары калтыранган Хикмәтнең җаны салкынаеп, каядыр түбәнгә, түбәнгә таба убыла башлады. Каршыдагы аркылы-торкылы биешкән шәүләләрне күрмәс өчен гарьлегән, көчсезлегән эченә йотып, хәлсез битарафлыктан күзләре йомылганда, ул башта тоныкы кына булып, аннары бөтен тән күзәнәкләрен уятырлык итеп, Кочураның катлыкатлы итеп әче еүгенүен ишетте һәм, кинәт хәле кайтып, башын күтәрде. Кул сузымы арада гына эчәсе килү теләгән котыртып, үртәп су ага

иде. Бер тамчысы өчен дә гомереңне бирерлек. Моңа кадәрле кайчандыр эчкән бөтен чишмә суларының тәме хәтергә килде дә чатнап ярылган иреннәр, ялварып, үзеннән-үзе ачылды. Шул хәтерне алдау, тынычландыру өчен генә булса да — бер тамчы су... Су!.. Су!..

Алда торган рәшәткәне теш белән чәйнәп өзәрлек булып, күпме генә йолкынып, көчәнеп карасалар да, комсызланып саф һаваны сулаудан кала берни дә кыла алмадылар.

Алар торбаны сала башлаганда, бу рәшәткә юк иде бит, юк иде, юк!.. Кем уйлаган?!.

...Кургашын кебек авыр хәтерен кузгатып, туган авылы тынлыгыннан сыгылып, Өянке төбендә утырган Хикмәтулла салкын тир бәреп чыккан маңгаен, күз кабакларын учы белән каплады. Әлеге чарасыз халәтнең кабатлануыннан курыккандай, икенче кулы белән капшанып, Нәзифәнең иненнән кысыбрак кочты. Күзен ачкач та әле гомер онытылмаслык булып хәтеренә кадакланып калган тимер рәшәткә шәүләсе күз алдында биеп, югалмыйча торды.

Нәзифә, бәп-бәләкәй калып, ире куенына кергән. Хатын-кыз тәне белән сыенганда, ир кеше аңа җаны белән сыенадыр. Хатын-кызның кадерен күп газаплар күргән ир-ат кына чын-чынлап аңлый беләдер, мөгаен.

Күпне күргән Хикмәтулла өчен менә шушы минуттагы җанга газиз тынычлык, йолдызлы күк йөзе, йокыга талган йортлар, хатынының авылдагы яңалыкларны тын гына сөйләп утыруы артык бәхет булып тоела иде. Моның чынлыгына төшенү өчен бәлки күпмедер вакыт үтүе, күнегү-ияләшү кирәктер.

Нинди көч-кодрәт табылган диген ул чакта. Еш-еш сулу алганны, ыңгырашу авазларын шомлы үлем авазы итеп яңгыраткан тимер кыршау эченнән тагын кирегә ике тәүлектән артык юл үтүне хәтеренә төшергәч, аның чәч бөртекләренә кадәр кыймылдап куйды.

Инде берничә мәртәбә аңын җуйганнан соң, тәмам шашыр дәрәҗәгә җиткән Назыймның үз-үзен тырный-тырный җан биргүе, инде торба коллыгыннан котылгач, Кочура белән җыентык суга капланып, дөньяда иң тәмле тоелган болганчык суны комсызланып чөмерүләре, аякка басып йөрү сәләтен җуйган, коры сөяккә калган ике ирнең кыр буйлап, өрәкләр кебек шуышып, сугылмаган арпа эскертенә житеп егылуларын чит ил күгенең гамьсез ае кырын ятып күзәткәндер. Ике тәүлек буе үлеп йоклаганнан соң, алар Германиянең үзәгеннән көнчыгыш тарафка кузгалдылар. Көннәре — эскерт астында, төннәре юлсыз юлда үтте. Кылчыгы-ние белән уылган арыш, арпа бөртеге, ач карынга ярап тора иде. Польша чиген узгач, анысы да бетте. Ачтан яшелләнеп, тала522нып-ялангачланып беткән әсир качаклар урман буендагы хуторга житеп туктадылар. Кочураның поляк телен белүе ярап куйды, хәлгә керергә теләве йөзенә чыккан хутор хуҗасы кием-салым һәм ашарга алып килергә дип киткәч, ышанып калганнар иде бит алар. Ягымлы йөз артында икенче йөз барлыгын кем башына китергән андый чакта.

Элек, кечкенә авыл тынлыгында, еракта өреп куйган эт тавышлары үзе бер моң булып ишетелә иде. Ә бүген, Өянке төбендә хатыны белән утырган Хикмәтулла, каяндыр теге очтан килгән тавышларны элеккечә кабул итә алмады, иңендәге яра җөйләре сулыгып-сулыгып ала сыман иде эт өргәндә...

Канга сусаган тешләрен ыржайтып, борын төбендә юеш тын бөркеп, алгысына-тартыла, аяусыз ярсулык белән өргән тук этләрнең каешыннан тартып, үзара нидер сөйләшә-көлешә карап торуы немец солдатларына ләззәт бирә иде күрәсең. Бу гарьлек «уен» күпмегә сузылган булыр иде, Кочура түзмәде, кинәт сүгенеп кычкырды да, каерылып, йодрыгы белән этнең танавына китереп сукты. Чиный-чиный бәргәләнгән

шома йонлы кара эт башкаларын инде шашыну дәрәҗәсенә җиткерде. Һәм шул мәлдә елмаюы йөзеннән качкан солдатлар этләрнең каешын ычкындырдылар...

Соңыннан (күпме вакыт үткәндер), хутор хуҗасы аларны салкын су сибеп аңга китерде. Таш сарайның ишегеннән табут кебек сузылган яктыда ул тагын да бөкрәя төшеп, кайнар бу чыгып торган мискигә ымлады — соңлап булса да ашарга китергән иде. Кочура аңа теш арасыннан төкергән сыман итеп полякча нидер әйтә башлагач, ул, сүзсез генә башын кагып торды да, ишек ягына сагаеп карап алганнан соң, сарай почмагындагы кисмәкне урыныннан кузгатты. Анда тавык сыярлык кына тишек күренде. Кочурага ярым пышылдап, нидер аңлаткannан соң, ашыгып кузгалды. Аның артыннан ук сарайның калын ишеге ябылып, авыр бикләнгән йозак тавышы ишетелде.

Ә немецлар өчен сарайда яткан хәлсез ике тоткын артык йөк иде бугай. Өйдән ишетелгән җыр, авыз гармуны тавышларына караганда, аларның кәефе бәйрәмчә иде.

Кичкә таба машина килеп туктаганы ишетелде. Бераздан, этләр өргән, кешеләр сөйләшкән тавышлар бергә буталып, машина гөрелдәве белән бергә ераклашып сүнде. Сарай ишеге төбендә сакчының гына вак ташны шыгырдатып йөрүе тешкә тия башлады.

Аркадагы эт тешләгән яралар кан катыш туфрак белән укмашып каткан иде, аз гына хәрәкәттән дә бөтен тәнне күз аллары караңгыланырлык сызлау биләп ала. Кочура алагаем авыртудан чыраен сытып, ике кулын да хәрәкәтләндерә башлады.

— Сызлауны сызлатып, чыгарырга кирәк,— дип ул Хикмәтне дә урыныннан кузгатты. Адәм баласында максат туса, тәненә көч үзеннән-үзе иңә икән...

Хуҗа күрсәткән тишек чынлап та тавыклар йөри торган юл булып чыкты. Туфрагы йомшап беткән, аны кул белән казып тирәнәйттеләр, як-ягындагы ташларны сак кына кузгатып киңәйттеләр дә...

Урман аларны үз куенына алды. Һәм аннары поляк партизаннары сафында ярты ел гомер. Шунда Хикмәтнең Кочура белән юллары аерылды. Күпер шартлатырга барган җирдән Хикмәт бөтен группасы белән немецлар кулына эләкте.

Тагын концлагерь... Тагын качу... Тагын, тагын...

Каян килә диген адәм баласына көч-кодрәт, каршылык булган сәен, таш кебек катылана барган рух ныклыгы... Соңгысында аны, җиденче мәртәбә качканнан соң атарга хөкем итеп, Италия чигендәге үлем лагерына китерделәр.

Баш очында асылынып торган үлемнең котылгысыз тизлек белән якынлашуын тойган хәлдә дә төшенкелеккә бирелмәде ул. Бу хәтәр язмыш белән бермә-бер алышның азагы җиткәненә ышанасы килми иде аның. Нидер булыр, болай гына тәгалләнмәс диган яшерен өмет рәшәткә аша күренгән зәңгәр күк йөзенә карап яткан әсирдә җуләр ышаныч уята иде.

Ләкин өмет белән сугарылган беренче тойгы өзлексез көтү газабыннан йомшый, әкрен-әкрен таркала башлады. Өмете дә, көче дә шәм ялкыны кебек, менә сүнәм, менә сүнәм дип бәргәләнгән көннәрнең берсендә... Таң алдыннан ул гайре табигый тынлыктан сискәнеп уянды. Күпме лагерьларның үзенә генә хас сулышын бөтен күзәнәге белән тоярга өйрәнгән Хикмәт бу мәкерле тынлыкка сәерсенеп ишегалдына чыкты. Бөтен лагерь тирән йокыда, кояш әле күтәрелеп кенә килә иде. Караса... вышкаларда сакчылар юкка чыккан, тимер чыбык киртә арасында да беркем юк, лагерь капкасы шар ачык!

Ул арада каяндыр шомлы гөрелдәү авазлары ишетелә башлады. Озак та үтмәде, ни кылырга белми торган Хикмәт ачык капкадан керәп килүче өй зурлыгы танкны күреп алды, җиңнәрен сызганулы, та-

бак битле чутыр-кара негр люктан башын чыгарган, арттан — икенче танк, өченчесе...

Төшме бу, өнме икәнен аңышырга өлгерә алмаган Хикмәт артык зур шатлыктанмы, артык нык гаҗәпләнүдәнме — эчтән күтәрелә килгән дулкынны сыйдыра алмыйча, җиргә сыгылып төште.

Пароход трюмында гына аңына килде ул. Ниндидер затлы исләр килеп торган врач күзәтүе астында әкрен-әкрен аягына басты. Хәер, йөреп китәргә коры җир юк иде, тирә-якта су да су, чиксез океан киңлегендә чайкалган пароход америка киемнәре кигән әсирләрне каядыр алып бара, вакыт исә, дәрья дулкыннары шикелле бертөсле агышка әйләнеп, мәгънәсен җуйган иде.

Алдан сөенгән — соңыннан көенгән, ди. Бу әле котылу булмаган икән. Куба утравында ирексез ялчы хәлендә шикәр камышы плантациясендә эшли башлагач кына Хикмәт моңа төшенеп алды.

Тагын качу...

Гомерендә олы су күрмәгән Хикмәт берничә иптәше белән көймәдә океан киңлегенә кереп китеп, штормда чак исән калып, ниһаять, Багам утрауларының берсенә килеп эләкте. Дөньяның череп баеган аксөякләре күңел ача торган утрау портында тамак ялы өчен йөк төяүче булып эшләгәндә аны бердәнбер хыял кеше итеп саклады — кояш чыгышы ягында калган туган ил!..

Йөк белән бергә француз пароходының трюмына эләгеп, материкка кайтып егылгач, өмете чынга ашарга инде ерак калмаган иде. Ил чиген чыгуга, туган җир офык артында гынадыр шикелле иде. Бәхетенә каршы, аның лагерьдан лагерьга «сәяхәтләрен» немецлар бик төгәллек белән теркәп барганнар икән. Сүздән кодрәтлерәк булган кәгазьләр табылу — туган авылга кайту сәгатьләрен бермә-бер тизләтте.

— Рядовой солдат булган совет әсирен атарга хөкем итү — фашистларда бик сирәк күренеш,— дип, Хикмәтнең сөйләгәннәрен үк йотылып тыңлаган тикшерүче дә моңа хәйран калды.

Чит якларда вәйран булып, ят дөнья белән яланкул көрәшергә мәҗбүр ителгән Хикмәтулла өчен йөз ел гомер үткән кебек иде. Ә монда, туган авылында, ун ел гына узган икән. Әлеге аермалыкны күңелендә килештерә алмаган Хикмәтулланың исән-имин кайту шатлыгы астында сыкрап торган ярасы шушы иде — вакыт ярасы... Бу яра чишмә сулары, авылдашларының җылы карашы, кыр-тугайларның шифалы җиле белән генә, әкрен-әкренләп кенә төзәлергә, җөен калдырып йомылырга мөмкиндер...

Нәзифә авылдагы үзгәреш-вакыйгаларны кыска-кыска гына сөйли, ә Хикмәтулла, болгавыр төштән бастырылып, ун ел буе йоклаганнан соң, әле генә уянган кебек, күбесен аңлап-төшенеп тә бетерә алмый, әмма хатынын бүлдереп сорарга да җөрьәт итми. Башта, төрле ил чикләре белән бүленгән, артта калган тормышыннан арынырга, тәмам суынырга кирәк иде аңа. Сакчы-күзәтүләрсез генә, алда торган киртәләрне җимереп, ирекә чыгарга дигән уйларсыз гына, иртәгә тып-тыныч көн туарына, кинәт кенә мәкерсез, беркатлыга әйләнеп калган яңа тормышын канына сеңдерергә кирәк иде аңа.

Шуңа күрә дә ул, капылт кына ачылып китеп, Нәзифәгә үзенең күргәннәрен хәзергә сөйли алмады.

Авыл йоклый. Каяндыр сарык йөткергәне ишетелә. Өянке ботакларында кошларның йокылы авазы ишетелеп куя.

Кош оясы кебек авыл улларын-кызларын ерак-еракларга очырып җибәрә дә кире дән үзенә җыя. Буыннан-буынга шулай кабатлана. Кемнәрнеңдер эчәр суы, кабар ризыгы бетмәгән, кире кайтып төшә, кемнәрнеңдер юлы чит җир туфрагында мәңгегә өзелеп кала... Буыннан-буынга шулай кабатланыр...

Өянке үз күләгәсенә карап утыра. Янәшәсендә кешеләр сөйләшкәнне тыңлау рәхәт аңа.

Олы юлдан чыгып киткәннәрне сагына белә, кайтып кергәннәр өчен сөенә белә бит ул да. Әгәр урыныннан куба алса, кунак кайткан өйнең тәрәзәсен шакып, иң беренче сөенчене ул алыр иде.

---

Шау-гөр килеп, су коенып ятканда, кинәт өстебездән кара шәүлә очып узды. Күтәрелеп карасак, самолет — мондый зур канатлы, ап-ак самолетны якыннан түшебездә дә күргәнебез юк иде әле, тизрәк судан чыгып, ярга күтәрелдек.

— Тавышсыз самолет! Тавышсыз самолет! Малайлар! Төшә!

Чалбар сәдәфләрен дә эләктерә тормыйча, күлмәкне кулга гына тотып, күз алдында тәбәнәгәя барган самолет артыннан йөгердек. Без, Челтәр чишмә янына җиткәндә, ак самолет отыры түбәнәеп, тау өстендәге тигезлеккә төшеп кунды.

Кинәт арттан Зәбирнең:

— Ятыгыз, малайлар!— дип куркынулы тавышы ишетелде. Ни булганын аңышмыйча борылып карасак... ышкыла язып, баш очыннан гына нәкъ шундый ук икенче самолет очып узды — җиле генә бәрелеп калды. Кая ул яту, сулуга кабып йөгерәбез. Ул арада беренче төшкән самолетның кешесе чыгып, нәрсәдер аңлатырга теләгәндәй, кулларын бутый башлады. Безгәме, әллә арттан килгән самолеткамы—аңламасың. Без килеп җиткәнче, самолет, канатын чайкалдыра-чайкалдыра килеп түбәнәйде дә тау битеннән сузылган юлга борыны белән бәрелеп туктады. Без аһ итеп чүгеп калдык. Самолет эченнән, пыяла капкачны күтәреп, кешесе чыга башлагач кына, җан кереп тагын йөгерергә тотындык. Без килеп җиткәндә, ике очучы да самолетның яньчелгән борынын карап маташалар иде.

Мондый да матур, зур канатлы, ялтырап торган ак самолетны безнең күргәнебез юк иде әле. Койрык ягына да чыгабыз, кабинасын да карыйбыз, ә тегеләр безгә сүз әйтмиләр. Шунысы кызык: галәмәт озын канатына кул белән кагылсаң да, самолетның бөтен гәүдәсе селкенеп куя. Кая соң пропеллеры дип аптырашабыз, тәгәрмәче дә бер генә.

— Яңа төр самолет бу, тавышсыз оча торган,— ди Зәбир, белдекләнеп. Ул арада тау өстенә авылдан кешеләр җыела башлады. Карчык-корчыкларга кадәрле өеннән купкан. Таһир абзыйның тузан туздырып килгән полуторкасы да күренде. Атлылар, җәяүлеләр — бөтен авыл кузгалган — Сабан туемыни!

Сизми дә калганмын — кояш инде тау ягына авышкан, сүрәнәеп бара икән. Карасам, сарык көтүе, агылып, туплаудан чыгып бара. Мин теләр-теләмәс кенә кузгалам. Көннең иң кызык җирендә бит, шулкадәр китәсе килми, авыл янына ике самолет килеп төшсен әле, моның кайчан булганы бар! Зәбир белән Фирзанның монда калуына кызыгып, тау өстеннән авыр гына атлап төшеп киләм. Бөтен кеше монда менеп килә, ә мин — кире якка. Артыма борылып карамаска тырышып, су буена төшәм дә, күләгәдә әле һаман аңга килә алмыйча яткан бер төркем сарыкны урыныннан кубарып, көтү каршысына чыгам.

Чишмә тавын халык сырып алган. Самолетлар кырмыска оясына төшкән ак күбәләкләр булып күренә. Малайлар инде әллә ниләр белеп өлгергәндер, ә мин монда берьялгызым.

Әллә каян, офык артыннан килеп төшкән бу яңалык авылымны да бәләкәйләндереп калдырды сыман. Мине хәзер буржуйның «Студобеккер» камерасы да кызыксындырмый. Самолетка утырып китәсе иде хәзер. Сарай тавы артына, кояш баешы ягына, полячканы да алып,

очасы иде биектән. Әгәр сугыш булмаган булса, мин берничә елга алданрак туган булыр идем. Нигә мин һаман бәләкәй соң әле? Тау битенә сузылган озын шәүләм мине үрти, хәрәкәтләремне кабатлый. Кинәт чүгәм дә, шәүлә кып-кыска булып кала. Шулай итеп мин озын шәүләмнән үч алам.

Тау өстендә җиргә берегеп үскән кыргый ташлар ята. Аларның да җаны бардыр кебек. Әнә бит, кояш төшкәннәре көлеп тора, күләгәдә калганнары Нәүширван абзый кебек кашын җыерган. Ни уйлый икән куныкланган бу ташлар?..

Бераздан Зәбир белән Фирзан, узыша-узыша, минем янга килеп життеләр. Яңа хәбәр алып килгәнлекләре йөзләренә чыккан.

— Самолет түгел, планер икән алар,— диде Зәбир.

— Моторсыз оча, кәгазь самолет кебек,— диде Фирзан.

— Очучыларның берсе Таһир абзыйның машинасында район үзәгенә китте. Казанга хәбәр итәргә.

— Самолет чакыртырга.

— Самолет тарттырып, күккә менгереп ташлый да, шуннан соң планер үзе оча, белдеңме?— Зәбир боларны күптән белгән, үзе очып караган сыман ук сөйли башлады.— Кояшка каршы оча алмыйча төшкәннәр алар, күзләре чагылганга. Казан шул якта икән,— дип, ул Сарай тавы ягына күрсәтте.

— Мин аны күптән белә идем,— дип, сүзгә кушылган булдым.

— Планерларны алачык янына төшереп, төнгә сак куячаклар. Җиңжиңел икән ул.

Зәбир белән Фирзанның үкчәләре генә ялтырап калды, тагын шунда йөгерделәр. Алардан көнләшүемне төкерегем белән йотып, тагын ялгыз калдым. Сарыклар шундый тәмле итеп үлән кимерәләр. Аларга самолет ни, айдан кеше төште ни — исләре дә китми.

Кояш түбәнәюгә, тугайларның төсе ачыгая, күләгәләнеп, таулар да биегәеп киткәндәй була. Сарыклар инде кайту ягына борылды. Үләннән башын күтәрмичә генә, тезелешеп киләләр. Каршыларына чыгып, аларның тизлеген киметәм. Күз һаман Чишмә тавы ягында. Әнә, планерларны бихисап ирләр күтәреп, таудан төшеп киләләр. Мәет алып барган кебек, әкрен генә кыймылдыйлар.

Түмгәкләр арасыннан ярылып аккан Челтер чишмәнең дерелдәп торган ярыннан сикереп чыгам, бу — беренче чик. Үләнгә ябырылган сарыклар агылып килә. Кояш Сарай тавы артына күмелгәнче, күпергә кадәр араны тотарга кирәк. Су юлыннан көянтә-чиләк күтәреп төшкән әни кычкырып уза:

— Кояш баеганчы кайтар, улым, соңга калдырма!

— Ярар,— дим ризасыз тавыш белән, үзем дә беләм бит инде югыйсә.

Вакыт шулкадәр акрын үтә, бүтән көннәрдә кич җиткәнен сизми дә каласың, ә көтүдә вакыт, нечкә кереш кебек, сузыла да сузыла.

Түбәндә төрле төстәге чуерташлар яткан Әмәт чишмәсе юлы — соңгы чик, аннан инде күпергә ерак калмый. Әмәт чишмәсе тимер торбадан агач улакка агып тора. Галәмәт юан имәнне чокып эшләнгән улакка атларны су эчәргә алып төшәләр. Кыш көне монда ат суялар. Ат каны, боз өстенә җәелеп, куе көрән төскә кереп ката. Ул турыда тимераяк шумый, беләү кебек боздан, киселгән эзләр калдырып, аксаклап кына чыгасың. Хут белән килеп керсәң, маңгаең белән бозны сөзәргә дә мөмкин.

Ниһаять, кояш Сарай тавы артыннан күз кысып алды да, бөтенләй күмелде. Нәрсәнедер төшереп югалткан сыман, тирә-юнемә карап куйдым. Өстән чыпчыклар төркеме очып узды. Артым белән күпергә кадәр чигенеп барам. Тыеп кара хәзер, көтү, тоташ агым булып, күпергә килеп керә һәм тыкрыктан олы урамга таба юл ала.

Хәзер инде мин ирекле. Тәмам арганлыгым шунда гына сизелә. Бүген инде урам уртасыннан да кайтырга була...

Авыш капкасын җирдән сөйрәттереп, акыра-бакыра, сарыкларын ябып маташкан Нәүширван абзый миңа таба борыла:

— Ма-лаай, ач кайтаргансың сарыкларны!

— Тук булмаска ару була ул,— дим мин Зәбирчә итеп.

— Һа-ай, бүре маңгай,— дип, Нәүширван абзый мыгырданып кала.

Казбек та мине сагынган, каршы килеп, чалбарыма ышкына башлый. Башыннан сөйгән чагында күзләрен рәхәт йомып куя, бераз ияреп бара да — кесәмдә ипи катысы юк шул — булмады синнән диган кебек аерылып кала. Капка төбендә көндезге сунардан арып кайткан Алпамша песи белән исәнләшеп тора. Бер уч тигәнәк ябышкан сакалына төртеп күрсәтә-күрсәтә көләм, ә ул уйламый да. Песине сыртына утыртам да капканы ачам. Ул арада сыер да, тук тавышка мөгерәп, авыр тояклары белән җир селкетеп, ихатага кайтып керә: көне буе ашаганын онытып, бәрәңгеле чиләккә башын тыга.

Әни чәй табыны әзерләгән, кырыемда бөтерелеп кенә йөри.

— Бер-бер хәл килеп чыкмаса ярар иде дип, көне буе куркып йөрдем,— ди.

— Нәрсә булсын,— дим, эштән арып кайткан этигә охшатып, тавышны күкрәк эченнән алам.

— Алла диген. Сарык бит ул, сазлыкка төшүе бар. Аксыргаклыкка алып кермәдеңме соң?

Аксыргак яфрагының зыянлы икәнен кем белми инде! Мин дәшмим. Эти дә шулай бит — кирәкмәс сүзгә җавапсыз кала.

Бер стакан чәйне эчеп бетерергә өлгердемме, юкмы — өйалды сайгагын дөбердәтеп, Зәбир килеп керде.

— Әйдә тизрәк, Чишмә тавына самолетлар төште!

— Нинди самолет инде тагын?

Әнинең арттан кычкырып калган тавышын ишек белән кысып, тизрәк чыгып та йөгердек.

— Бусы чын самолетлар. Кызыл утларын яндырып төштеләр.— Зәбир тынына буыла-буыла сөйли. Фирзанны да алырга дигәч, кичен апалары чыгармый аны дип, кул гына селтәде.

Чыклы үлән ерып, тау өстенә күтәрелдек. Кабинасында утлар янган ике самолет та янәшә торалар, безнең авыл өстеннән үтә торган ике канатлы чын самолетлар. Ул арада атын чаптырып, тарантаска үрә баскан Тимерхан абый да менеп җитте. Авыл советы председателе булгангамы, гел тарантаска үрә басып йөри ул. Элгрәк ул, җәйге челләдә кемнең дә булса морҗасыннан төтен чыкканын күрсә, капка төбенә килеп туктый да кычкыра башлый иде:

— Морҗаңны ишәм бит, хәзер үк сүндер учагыңны!

Мин чыннан да курка кала идем, шундый озын буйлы ул, морҗаны үрелеп кенә ишеп төшерер сыман иде...

Тимерхан абый, атын читкәрәк туктатып, очучылар янына килде, ни сөйләшкәннәре генә ерактан ишетелми. Караңгылык та куерды, салкынча җил исә башлады.

— Якын китермәгән булалар, шөребен борып алмасыек әле,— дип, Зәбиргә карыйм. Ул чалбар кесәсенә кулын тыккан да бөкшәеп тора.

— Киттек, әллә нәрсә түгел икән бу. Чытыр арба,— дип, Зәбир теш арасыннан черт итеп төкереп куйды.

Авылга төштек, чатта басып торабыз, нигәдер өйгә кайтасы килми, арыганым да онытылган.

— Әйдә клубка, кино бүген! — Зәбир, эре-эре атлап, югары оч ягына борылды.

— Кертмиләр бит анда.

— Кино карамый калган юк әле.

Кино көнне, билет сатканда өстәлне ишеккә аркылы куялар. Ут сүнеп, соңга калучылар ишеккә өелгәч, Зәбир өстәл астыннан гына шуа да үтә. Бу аның сыналган алымы. Мин исә ничә тапкырлар ымсынып карадым — булмый гына бит, өстәл астына керергә кыюлыгым житми. Клуб мөдире Дәрия апа да бик усал шул, күреп алса, ике бармагын сөңгедәй сузып:

— Бәбәгеңне алам бит,— дип, өстеңә килә.

Кайсы көнне, кинойы туктатып, утны яндыралар да качып кергән малайларны рәтләр арасыннан чүпләргә тотыналар. Тимерхан абый, каты кожан итәге белән бәреп, малайларны жилфердәтеп кенә чыгара тора.

Бүген клуб каршында — халык. Яхшы кинодыр, күрәсең, уңай форсат көтеп йөргән малайлар бер без генә түгел икән. Димәк, керү тагын да авырлаша.

Кич чыгып йөри торган жиде апасы Фирзанны уртага төреп кенә алып кереп киттеләр. Зәбир дә өстәл астыннан кереп йомылды. Ишек төбендә мин дә тагын берничә малай торып калдык. Тагын бер юл бар: иске мәчет бинасы булган клубның түрбаш почмагындагы ташлар бик жиңел алына, шуннан, капшанып, базга төшәсең дә... Идәннең олы ярыгыннан дистә еллар буена коелып, пирамидага әйләнгән чүп өеменә ятып, башны боргалый-боргалый, тишектән кино карарга була.

Базга төшсәм, монда да чират, чүп өемен малайлар сырып алган, күзләре генә елтырый. Булмады бу! Нишләп соң әле мин, якыннан самолет күргән башым белән, клуб базында йөрим. Кайттым киттем булыр. Эчтәлеген иртәгә сөйләрләр әле.

Төнге урам. Сирәк тәрәзәләрдә генә ут күренә. Каршыдагы чирәмлектән болай таба төшеп килгән ике шәүләне искәреп, тизрәк кереп китәргә ашыгам. Төнге тынлыкны уятмас өчен, койма өстеннән генә йомарланып төшәм. Безнең капка койрыгы кысылган кәжә кебек чинап ачыла да бөтен очка сөрән сала. Күземне бәйләсәләр дә, кемнең капкасы ачылганын белә алам мин. Зәбирләрнеке гырлап ачыла, Фирзаннар капкасы сикәлтәле тавыш белән шаркылдап кølә, Мәдинә апаларныкы тимергә пычак белән сызган кебек, тешкә тиеп ачыла, майлап кына торганга, Хикмәт абзыйларныкы гына бер тавыш та чыгармый...

Мин тагын, салкын юрган астын жылытып, лепердәп утырган усак яфракларына карап ятам. Үткән көннең болгавырлыгын аралап, колагыма сарык тавышлары килеп керә. Күземне йомсам, офыкка кадәр таралган сарык көтүе пәйда була. Су ерып килгән кебек, көтү эченнән, сары чәчәкләр бәйләме тотып, «полячка» килә. Сорау билгеседәй мөгезле усал тәкә янына туктала да чәчәк бәйләмен суза, сары тажларны берәм-берәм өзеп капкан тәкәнең башыннан сыйпый.

— Мин үз сарыгымны таптым,— ди, үзе мине күрми, үзе миңа дәшә.

Ныклап йокыга китәргә дә өлгермәгән идем әле, өстемә шапылдап нидер төшүгә уянып киттем, песи икән, мыек астыннан мыраулап, куенга шуып та керде.

Чү! Безнең капка төбендә мыдыр-мыдыр кемнәрдер сөйләшә түгелме? Койма аша куе сәрви куаклары салынып торган турга жәйланган безнең утыргыч төннәрен буш тормый. Бервакыт, пышан-пышан гына килеп, койма артыннан тыңлаганым да бар. Клубка чыга торган кыз белән егетләр әллә нинди матур сүзләр генә сайлап сөйләшәләрдер, ул сүзләрнең хикмәтенә безнең кебекләргә кая инде ул ирешү дип уйлый идем мин.

Ул төндә Фирзанның биюче апасы Сәлимә белән Тимерхан абыйның быел гына армиядән кайткан улы Жәүдәт абый утыралар иде. Жәүдәт абый кайтып төшкән мәлләрендә русча гына сөйләшкән икән

диләр. Имеш, әнисе коймак пешереп китергәч, коймакны әйләндереп-әйләндереп караган да:

— Әни, нәрсә бу, тәбикмәк баласы что ли?— дип сорый икән.

Шуны искә төшергәч, пырхылдап көлмәс өчен, авызны каплап торган идем, ә алар минем барлыкны уйламадылар да.

— Көзгә шоферлыкка укырга китәм,— ди Җәүдәт абый.

— Китмәгәең,— ди юка иренле Сәлимә апа.

— Шәһәрдә эшкә калам,— ди Җәүдәт абый.

— Калмагаең,— ди Сәлимә апа.

— Сине дә алып китәм...

— Китте ди! Көт! Кияүгә чыкмыйм мин, беләсең килсә. Бүтәнне эзлә.

— Кызлар барысы да башта шулай дигән була. Аннары...

— Нәрсә аннары?! Нәрсә аннары?.. Әйтеп бетер.

— Син бала яратасыңмы, Сәлимә?

— Андый уең булса, бүтән килеп йөрмә, ишетсен колагың!

— Вәт җүләр, ә! Бала яраткан кеше була, яратмаган... Шуны гына сорамакчы идем. Вәт бу авыл кызлары, ә!

— Сөйләп торган булмасана, сиңа тагын шәһәр кызы!..

— Да-а, я знаешь, ты знаешь,— ди Җәүдәт абый, русчага күчеп. Тәмәкесен еш-еш суыра башлый. Сәлимә апа читкәрәк шуыша.

— Болай булса, бер атнадан печәнгә төшәсе булыр...

— Бар, кайтып чалгыңны кайра,— дип, Сәлимә апа сикереп тора. Җәүдәт абый аның кулыннан тотып, утырырга кыстый. Мин шул арада сиздерми генә китеп өлгерәм.

Әллә ниләр сөйләшәләр дип йөргән була идем, баксаң, бер кызыгы да юк икән.

Әгәр бүген дә шулар булса... койма ярыгыннан кычыткан белән чактырам мин аларны.

Куе чаганлыктан мүкәләп үтәм дә, аяк очларына гына басып, сәрви куаклары артына посам. Утыргычта икәү... Кинәт, күкрәкне тотырып, дулкын күтәрелә башлый, кычкырып җибәрүдән чак тыелып калам. Сафуан абый бит бу! Аның корыч тавышын мин меңнәр арасыннан да таный алам. Сафуан абый кайткан! Мәдинә апа белән... Безнең утыргычта... Урамга чыгып, күрешергә иде үзе белән. Төн бит инде, оялам. Аларны качып тыңлап тору әдәпсезлек булыр сыман, ә тыңлыйсы килә. Битләрем уттай кызыша. Тавышларын ишетәм, сүзләрен аңлап бетермим, бераздан гына зиһенем ачыла. Менә Сафуан абый күн киемен шыгырдатып торды, чүгәләде дә Мәдинә апаның тезенә башын куйды.

— Шулкадәр сагындым бит мин сине, Мәдинәкәй. Дөньяда бер чибәрлегеңнең кадерен генә белмисең.

— Матур сүзләр сөйләмә, Сафуан. Без аңа күнекмәгән.

— Бер ел эчендә минем гадәтне оныттың дамыни?

— Ялгыз хатынга бер ел аз гомер түгел. Сагындым дисең. Үзең киттең дә югалдың.

— Хатлар язып тордым бит, ә синнән бер җавап булмады.

— Язып өйрәнгәнмени мин. Көләрсең дип курыктым.— Мәдинә апа сәер итеп көлеп куйды.

— Их сине... Усал дигән даның бар авылда. Беркатлы сабый икәнеңне күпләр белмидер дә...

— Синнән башка берәүне дә бусагамнан атлатып керткәнем булмады бит минем.

— Ышанам... Китик моннан, Мәдинә. Самолетка утыртам да... Иртәгә үк... Ташла бу йортыңны! Казанда менә дигән фатир алдым, яшәргә була хәзер.

— Мин үзем генә түгел шул. Дөм сукыр әбине кемгә калдырасың ди.

— Аны да үзебез белән алырбыз. Казбекны да.

Мин дер калтырап, агач ботагына тотынып торам. Минем белән бергә сәрви куаклары да калтырыйдыр сыман. Менә хәзер, менә хәзер... Мәдинә апа ризалаша да... Очның ямен алып... Тәрәзәләре кадакланган өй, алабута үскән ташландык ишегалды... Мин эчемнән генә өзелеп-өзелеп ялварам. Нигә соң Сафуан абый үзе монда кайтып тормый икән, нигә?..

Мәдинә апа тирән сулыш ала.

— Булмый, Сафуан. Туган нигезне корытып, ничек капылт кына... Монда бертуган кебек күршеләр. Шәһәрдән куркам мин. Үзең кайт.

— Нигә киткәнемне беләсең бит, Мәдинә. Аэродромсыз, самолетсыз яши алмыйм мин. Якында андый мөмкинлек булмады.

Мәдинә апа башын Сафуан абыйның иненә куеп җылый башлады.

— Күңелемне кузгаттың да... китеп бардың... Шул килеш кенә яшәгән булсам соң — ияләшеп беткән идем ялгызлыкка...

Сафуан абый аның чәченнән сыйпап юата башлады.

— Мәдинә... Җыен да китик иртәгә үк. Чәчәк кебек йөртермен үзеңне. Беркайда да эшләтмәм.

— Өйдә саргаергамы?..

— Алайса бирәр җиңел эш табарбыз.

Мәдинә апа бер сүз дә дәшмәде. Сафуан абый утыргычтан торып, арлы-бирле йөренеп алды.

— Хатларга җавап язмагач, әллә ниләр уйлап бетердем. Әле килеп төшкәч тә Тимерхан абыйдан курка-курка гына сораштым синең турыда... Көтмәгәндә шундый очрак чыгу үзе бер бәхет бит. Үзем планерда төшкән теге егетләрне сүккән булам, үзем эчтән сөенәм. Алар минем бу авылда яшәп киткәнне башларына да китерми бит... Монда калган булсам, аэродром исен сагынып үләчәк идем мин, Мәдинә, аңлыйсыңмы?!.

— Әби йоклагандыр инде, әйдә өйгә керик.

Мәдинә апаның ягымлы тавышын мин аның китәргә ризалашуы дип юрадым. Аларның ераклаша барган аяк тавышларын йоткан төнге тынлыкны кисәк ачылган капка тавышы кисеп төшерде. Мин тораташ басып торам икән. Аяклар, оеп, тәмам агачка әйләнгән.

Шушы төндә мин бер яшькә олыгайдым бугай.

Икенче көнне дә тауга халык агылды. Уракка төшкән чак булса, болай ук җыела алмаслар иде әле. Бераздан планерларны да күтәреп алып менделәр. Кайсы бәрелгәнен дә белерлек түгел, иртә-таңнан торып, төзәтеп куйганнар. Самолетлар янында башы элмәкле озын арканнар ята. Агайлар ап-ак арканнарны тотып карыйлар, баш чайкыйчайкый сөйләнәләр.

— Чын ефәктән ишкәннәр бит, ә! Мәңге өзелерлек түгел.

— Яуропада күрдек без мондыйларны. Бозау бәйләргә үтергән бу!— дип, Нәүширван абзый да шома арканны учыннан шудырып карый.

— Бозауга ишшу, эскерт тарттырырга диген!— Байтирәк абзый ныклыгын сынарга теләгәндәй, арканны тартып карый. Нәүширван абзый барыбер соңгы сүзне әйтеп кала:

— Эскерт тарттырып кая барасың инде...

Казбек миннән бәхетлерәк. Күн киемле ят кешеләр белән тыз-быз килеп йөргән Сафуан абыйның шаярып күкрәгенә сикерә, шыңшып, аягына ятып ауный, сөенеченнән койрыгын туктаусыз болгый. Ничек зарыгып көткән иде бит ул аны, ничекләр көткән иде! Мин әле һаман Сафуан абый янына барырга кыймыйча бер читтә басып торам. Кичә сөйләшкәннәрен качып тыңлаганымны күзгә карау белән сизәр дә бармак янар кебек.

Бераздан ул мине үзе күреп алды. Җил-җил килеп, бөтен тешләрен күрсәтеп көлә-көлә иңемнән кысып тотуга, бер мизгелгә җирдән аерылып калдым.

— Нихәл, Тәнзил энекәш! Үсеп беткәнсең. Нишләп болай читтән генә... Кил, күр әйдә минем самолетны,— дип, ул мине кочаклап алып китте дә кабинага күтәреп диярлек утыртты. Мин әллә нинди саннар, уклар тезелгән хикмәтле приборлар арасында калдым. Ул арада Фирзан белән Зәбир дә килеп бастылар.

— У-һуу! Безнең очлар,— дип, Сафуан абый аларны да самолетка утыртты.

Мин кабинада «сынык рульне» тотып утырам. Күз кырые белән генә кешеләр арасыннан «полячка»ны эзлим. Нишләп күренми соң әле ул? Әнә, буржуй чагылып китте. Ике кулын да кесәсенә тыккан. Исе китмичә генә карап торган була.

— Нәүширван абзый коткарган аны кичә,— диде Зәбир минем колакка иелеп.— Бердәм булсак, пычагым да кыра алмый ул.

Бераздан Гөлсирин дә күренде. Кулына куе кызыл тукранбаш бәйләме тоткан. Тауның чокырсу урыннарында сибелеп утырган тукранбашка исем дә китми торган иде, Гөлсирин кулында исә алар бөтенләй башка төскә кергән кебек. Корычбай, аңа сырышып, нидер әйтә, гәүдәсен егетләрчә тотып, кулын бутый-бутый сөйләшеп торуын кара син аның,- күрәләрме мине дигәндәй, тирә-юньгә масаюлы караш ташлап ала, астан гына безгә йодрык яный. Кичә су буенда бәйләп ташлаганны әйтсәң, «полячка» көлеп үләр иде. Ә болай... Корычбайның һәр сүзенә баш селкеп, елмаеп тора бит әле. Әгәр бер класста укымасалар, аңа да ул: «Нәрсә кирәк үскәнем?»— дияр иде микән?

Сафуан абый килеп, кулын чүпрәккә сөртте дә:

— Бар әле, Тәнзил энем, Мәдинә апаңны ашыктырып кил, безгә кузгалырга вакыт,— диде.

— Мәдинә апа китәмени?

— Кунакка, ике-өч көнгә генә,—дип, Сафуан абый җилкәмнән какты.

Сафуан абыйның йомышын үтәмиләр димени инде, халык арасыннан бәрелә-сугыла чыктым да томырылдым гына. Ләкин ерак китәргә туры килмәде, тау астыннан менеп килгән Мәдинә апа каршымда кинәт пәйда булды. Бүген ул тагын теге елдагыча, эре чәчәкле күлмәктән, яланбаш, ничектер юашланып калган сыман, ә мин сүз әйтергә кыймый басып торам.

— Кая йөгерәсең, үскәнем?— дип, ул янымнан инде үтеп тә бара, шуңа күрә ашыгып, бөтен сүземне берьюлы түгеп ташладым:

— Сафуан абый сине алырга җибәрде, Мәдинә апа.

Ул елмайган сыман итте дә туктап калды. Борылып карасам — түзмәгән ахры — Сафуан абый ашыга-ашыга болай таба килә. Телен асылындырган Казбек, алданрак җитешеп, Мәдинә апаның аякларына сыенды, аннары миңа да кагылып китте. Шатлыгын шулай бөтен кешегә тигез өләшеп йөри иде бугай ул.

— Тиз бул, Мәдинәкәй, китәбез,— дип, Сафуан абый аның кулыннан тотып алды. Мәдинә апа исә күзләрен ачкан килеш йокыга киткән сыман тик басып тора.

— Ни булды, Мәдинә?

— Ачуланма, Сафуан, бара алмыйм...

— Ике-өч көнгә бит. Кунак булырсың. Карарсың...

— Булмый, Сафуан, аңла мине. Шулкадәр еракка ничекләр чыгып китим. Аннары...

Сафуан абый башын селкеп, авыртулы йөз белән карап торды-торды да, кырт борылып, ашыга-ашыга самолеты янына китеп барды. Сүзләрдән берни аңламаган Казбек кына әле Сафуан абыйның кар-

шысына төшә, әлё Мәдинә апага килә. Мәдинә апа кешеләр җыелган җиргә якын килмәде, шул урыннан самолетлар киткәнче кузгалмады.

Күп тә үтмәде, самолетларга тагылган ефәк арканнарны сузып, планерларга беркеттеләр. Гомер буе аэродромда эшләгән диярсең — авыл агайлары бөтенесен дә белеп өлгергәннәр: кузгалып киткәнче гел янтаерга торган планерның канат очыннан тотып тордылар. Көчле җил белән үләннәрне егып тарый-тарый кузгалган беренче самолет әле җирдән күтәрелмәгән дә, планер инде, кәгазь очырткыч кебек җирдән аерылды.

Сафуан абый Казбекны иелеп сөйде, тиз генә сикереп менде дә ишекне ябар алдыннан авылдашлар белән хушлашып, кул изәде. Агарып киткән йөзеннән гадәттәге елмаюы качкан иде аның. Аерылышуны яна гына сизгән Казбек инде ябылырга өлгергән ишеккә сикерде, самолетның әле алдына, әле артына чыгып бәргәләнергә тотынды. Сафуан абый кабина тәрәзәсен шудырып ачты да:

— Казбекны тотыгыз, винтка урала күрмәсен!— дип кычкырды.

Этнең муенсасыннан алган ике-өч таза егет аны көчкә тыеп торалар: тартыла, йолкына, шашып өрә-өрә җылый иде ул.

Теге самолет артыннан Сафуан абыйның самолеты да биеккә күтәрелеп, Сарай тавы ягына борылгач, кулдан ычкынган Казбек, күккә карап өрә-өрә, шул тарафка карап чабып китте.

Самолетлар ерагаеп, офыкта эреп югалгач кына тау өсте бушап калды. Шунда гына искәреп алдым: Мәдинә апа һаман да әле баягы урында басып тора икән. Яныннан безнең үтеп киткәнне дә сизмәде бугай, томанлы күзләрен күтәреп карамады.

Бу самолетлар үзләре кузгаткан җил белән нәрсәнедер еракка алып киттеләр сыман. Дөнья тараеп калды. Без, өч дус, узышмыйча гына, боегып, инешкә таба төшеп барабыз.

Төш турында Мәдинә апа мине буа ярыннан чакырып алды. Күн итектән, киң җилкәле пинжәген кигән, башында беретка — кечәге Мәдинә апа. Ут янып торган күзләре генә ничектер сүнеп калган шикелле.

— Тәнзил, үскәнем, минем белән барасыңмы? — дип, тимер керәге белән үләнне кистереп алды.— Казбекны күмеп кайтырыек, йөрәге ярылып үлгәндер инде мескеннең, шулкадәр чабып...

Аңым әле бу хәбәрне һаман кабул итә алмый, Мәдинә апа һаман сөйли:

— Үзем гаепле... Алып китәм дигән иде бит... Калдыр дип үтенгән булдым... Үзем гаепле...

Кинәт яшел тугайлар бер ноктага әйләнеп, керфек арасыннан сытылып чыккан яшь бөртегендә тирбәлә башлады. Күз яшен кул аркасы белән сыпырып төшердем дә чишмәгә таба йөгердем. Бу кояшны, өянкеләрне, тугайларны элекке хәлендә күрер өчен, башны Челтер чишмәнең утлы салкынына куярга кирәк иде...

Соңыннан... урман юлыннан кайтып килгәндә, Мәдинә апаның ялгызын гына алдан җибәрдек тә, үзебез Сарай тавы ягына борылдык. Күлмәген җил кабарткан Зәбир алдан менә, мин — аңа, Фирзан миңа тотынганбыз.

Тауның иң биек ноктасында, ерак дингезләр, упкын-кыялар телендә гүләгән җилгә колак салып, тын гына сөйләшеп утырган өч малайның да йөзләре гадәттән тыш уйчан, сүзләре гадәттән тыш җитди иде. Бу аларның ваемсыз балачак белән саубуллашу көне булгандыр, мөгаен...

---

Кояш бишегендә тирбәлгән Өянке нигәдер бүген тәкатьсез бер алгысыну кичерә иде. Гүя ул үзенең дәвамын, тармаклы тамырлары бар-

лыгын оныткан да, җир асты һәм җир өсте дөньясы бүленгән сызыктан икегә аерылган; шундый рәхәт-җиңел халәттә аның бер әйләнеп, бөтерелеп аласы килү дәрте җил белән шаярган яфракларына, сыгылмалы ботакларына кадәр күчкән иде.

Әллә соң Чишмә тавына җыелган халык төркеме аның уртак тынычлыгын кузгаттымы? Биектән, төпсез һава киңлекләрен дерелдәтеп очкан, казларны да башын кыйгайтып карарга кызыктырып киткән самолетларның шушылай якынга төшеп кунаклавын аның да бит беренче тапкыр күрүе иде. Әллә соң Өянке, тимер кошларга карап, кайчандыр чит җирләрдән килгән гаҗәеп кош — ләкләкнең, зур канатларын җәеп, иң өске ботакларына кунуын хәтерләдеме?

Юк, ахрысы, сәбәбе бүтәндәдер... Ерακта, Чишмә тавына җыелган халыкның бүген аңа һич тә кагылышы юк иде. Аның бәйрәме елга бер генә килә — Җиңү көнендә.

Берничә елдан соң, авыл үзәгенә һәйкәл салынып, сугышта һәлак булган каһарманнарның исемнәре язып куелгач, бәйрәм тантанасы да шунда күчәр, кульяулык элү кебек матур гадәт сагынычлы бер хатирәгә әйләнеп калыр дип, уена да китерми иде әле ул.

Ә көн шундый матур, ә көн шундый кояшлы. Бәрхет итәген уйнатып, йөгерек җил исә. Нигә соң әле Өянкенең үз күләгәсе тирәли бер бөтерелеп аласы килә?..

Моннан бик күп, бик күп еллар элек, беренче җәенә кергән тал-тирәк чагында, менә корый, менә корый дип көткәндә, ниһаять, июньнең нәкъ шушы көнендә, сулыш юлы ачылып, соңлап булса да яфрак ярып тернәкләнә башлавын оныткан, туган көнен хәтерләми иде ул.

Ел саен, җәйнең кыл уртасында, сусыл күзәнәкләренә йомшак дулкын булып таралган рәхәт алгысыну билән ала иде аны. Нәкъ менә шушы көндә, кәүсәсенең тыгыз үзәгеннән таралган еллар сызыгын тагын бер боҗра бөтереп алганын Өянке үзе дә белми иде шул.

Аның хәтере тыгыз боҗралар арасында җил-су-кояш теле белән язылган. Соңыннан... укый белгән кешеләр күрерләр: Өянкенең шалкан кебек ак тәнендәге боҗраларның берсе — иң юкасы — каралган булыр... Кырык беренче елның рәхимсез салкыны тудырган эз... хәер, салкыны гына микән?..

Шул кара боҗраны кысып чыгарырга теләгәндәй, сәламәт эзләр салып, яңалары өстәлә бара, өстәлә бара.

Кояш тирәли Җир әйләнгән уңайга сызылган боҗраларда — еллар тибрәнеше...

## II

Тау өстеннән караганда, авыл ак түбәләре белән уч төбендәге кебек җәйрәп ята. Сирәк кайтылганга күрә үзгәрешләр бигрәк тә нык сизелә. Ә мин, җүләр, һаман әле иске урамнарны, салам түбәле өйләрне юксынам. Малай чакта үзем ачып кергән капка тавышлары да хәтердән җуелмаган. Зур шәһәрләрдә, чит-ят илләрдә патшалар яшәгән, корольләр салдырган затлы сарайларны карап йөргәндә дә мин арыш саламы ябылган гади авыл өйләрен юксынып күз алдыма китерә идем. Алтын белән чигелгән стеналар, читтән карап сокланыр өчен генә ярατылган асыл әйберләр — салкын купшылык иңне баса, җанны кыса башлый һәм шул чакта сиздерми генә артыңнан килеп, кемдер чабуыңнан тарта, борылып карасаң... артыңда, беркатлы елмаеп малайчагың басып тора. Күзгә кебек идәндә ул ялан тәпиеннән яфрак-яфрак дымлы эзләр калдырып, сине үзе белән ияртә дә очыртып кына диңгезләр, кыя-таулар аша салам түбәле өйгә алып кайта. Тик... ул өйнең инде эченә сыеп керә алмыйсың, тәрәзәсеннән дә килеп карый

алмыйсың... Арыш саламы ябылган «алтын түбәле» өй бала чакның бөек акияте булып хәтер утравына күчкән.

Кешеләр генәме, сулар да бит туган ягына кире кайта. Диңгезгә барып җиткән чишмә сулары, парга әйләнеп, болыт хасил итәләр дә, яңгыр булып, туган якка кайтып явалар. Табигатьнең ашкыну һәм сагыну арасындагы мәңгелек әйләнеше...

Алтын Болак авылы үзәнең тыйнак таулары, карт өянке тамырларын сыйпап аккан инеше белән эссе җәй хозурлыгында изрәп ята. Кадерле көннәрең онытылып калмаганмы монда, ашыгып үтеп китмәгәнсеңме мәрхәмәтле карашлы авылдашларың янынннан? Дөньяның фани икәнен онытып, рәнҗетмәдеңме берәрсен? Бәгыреңне йомшарту өчен, кабер өстендәге тирәкләрнең җилдә пышылдавын тыңлый белергә өйрән. Соңыннан гына үкенү-сызлануыңны үлгәннәр кичермиләр, кеше — изгелеккә, җылы сүзгә исән чакта мохтаҗ.

Мин зәңгәр рәшәткәгә тотынып, озак басып торам. Һәлак булган егерме яшьлек Зәбир, хәрби киемнән, һаман элеккечә, эчкерсез елмаеп карый, нидер әйтергә теләгән сыман, хәйләкәр күзләрен кыса төшеп елмая. Балачактан ук газиз бер төсмердә хәтергә уелып калган сүзе, тере тавышы белән колагымда яңгырый: ибадиба. Бу аның: «Әни, мин яңа дөнья күрдем!» — дигән сүзе, булгандыр мөгаен. Зәбирдән соң тагын бер гомер яшәвемә уңайсызланып, рәсеме каршында чарасыз онытылам. Мин инде тәгәрәп кенә үткән еллар эчендә күпме «ибадибалар» күрергә өлгердем, ә ул, тормышка гашыйк чиста елмаюын җуймыйча, мәңге яшьлегендә туктап калды.

Янәшәмдә Фирзан да юк. Татар бугазын кисеп чыгып ул Сахалиннан бик сирәк кенә кайткалый икән. Юлларыбыз очрашмый, күрешергә туры килгәне юк.

Олы юлдан чыгып китеп таралыштык та бүтән инде җыела алмадык. Алар малай чак хатирәсенең мин онытып калдырган кызыкларын хәтерләгән булгандыр. Бергә утырып, искә төшерергә, барын да кабат кичерергә иде бит хәзер. Өчебез иңенә салынган балачак дөньясын берүземә күтәрү авыр, чиксез авыр иде бу минутта.

Мин Язулы тауның өй тәүмәле ташларына гарәп, латин, хәзерге хәрефләр белән язылган исемнәрне күздән кичерәм. Без дә үз исемнәребезне бер килеп язарбыз, соңыннан, еллар үткәч, шушында очрашырбыз дип хыялланган идек. Ашыкканбызмы, оныткканбызмы, әллә инде вакыт таба алмаганбыз — монда безнең исемнәр ташка уелмаган. Менә мин, ташлар күләгәсендә берьялгызым басып торам. Туган якның тауларыннан тәгәрәп-уйнап искән җилгә йөзне куям. Аста, аксыргаклыкта, җылап тәкәрлекләр әйләнә — яшел үзән акчарлаклары. Шушы моңлы манзара сыйган йөрәкне сыйпап юатучы җил мине тагын тау астына алып төшә.

Сафа абыйның тегермәне урынында куе камышлык. Зирекләр күләгәсеннән аккан арык суы да кипкән. Минем бәләкәй генә Ниагарам — тегермән шарлавыгының гөжелдәвен дә мин хәзер күңелемнән генә тыңлыйм.

Буа урынында инеш, ярын ашап кереп, өянке тамырларын ялангач калдырып, болайрак шуышкан. Аргы, сөзәк ярын үги ана яфраклары каплаган. Ялан аякларны корт чаккан кебек чәнчеп ала торган шайтан таяклары да андый ук ямьсез булмаган икән — тропик үсемлеге сыман купшы булып утыра.

Үткәннең тавышлары шулкадәр якында гына, аермачык ишетелә, үрелеп, юка гына пәрдәне күтәр дә бөтенесен дә яңадан күрерсең һәм ваемсыз уенга кушылып китәрсең кебек. Дөнья үз канунына тотрыклы шул; бер кергән суга яңадан кереп булмый. Без коенган сулар олпат өянкеләр күләгәсеннән ерак-еракларга агып киткән, кабатлану булмый. Сукмагын үлән баскан Челтер чишмәнең утлы-салкын суына да

инде мин чал кер́ә башлаган башымны куя алмыйм, бит-кулны чылатып, тәме хәтердә сакланган суны йотылып эчәм дә ары кузгалам.

Кайчандыр тибрәнеп кенә чыккан басма урынындагы күпергә җиткәч, тукталмыйча калып буламы соң? Ярда әнә мөгезләрен чыкы-чыкы бәрдереп, шаярып кына сөзешкән булып, ыспай бөгелешләр ясап сикерешә-сикерешә, кәҗәләр уйный — сакаллы сабыйлар. Гореф-гадәтләре үзгәрмәгән, һаман шулай элеккечә. Кыргыйлыгына, үз ирегенә хыянәт итмәгән йорт җанварлары. Аларны күзәтеп, берьялгызың икәнне дә онытып, ирексездән елмаясың. Нинди гадәттер инде миндә, кечкенә кызым, олыларча кыланып, очынып-очынып нидер сөйләнә башласа да тыела алмыйча елмаям, ә ул көләсең дип үпкәли, янадан сиңа берни дә сөйләмим дип китеп бара. Ярату тойгысы эчтә тыелып тора алмыйча, тышка бәреп чыкканны ничек аңлатасың инде аңа. Мәктәптә дә шулай иде бит: бик хөрмәт иткән укытучым кызып-кызып ачуланырга тотына, ә мин елмаям, аның битәрләве дә ошый миңа, якын итүдән шулай елмаям, ә ул, бүтәнчә аңлап, отыры кыза иде. Әлеге сәер гадәтем хәзер дә мине ташлап китмәде. Соклану-ярату кебек сирәк килгән мизгелнең рәхәтең эчкә яшереп, йомык чырай белән кабул итә алмыйм — картаерга теләмәгән сабыйлык хисе мине шулай уңайсыз хәлләргә калдыра, ахрысы.

Искәрми дә торам — тыкрыктан әни төшеп килә икән.

— Аш суына, улым. Туйга да чакырдылар үзеңне,— дип, ул миннән кыенсынган кебек аска карый.— Читтән кайталар да шул аръяк болында йөриләр, ни калгандыр инде анда,— ди әни, үзалдына көлеп. Читтән кайтканнарның үзгәрмичә калган болыннар-таулар арасында үткәндәге эзләрен хәтерендә яңартып йөрүләрен гомере буе авылдан беркая чыкмаган әни каян инде аңласын?! Өлкәнәйгәнче беркатлылыгын саклаган әнине мин ак күңелле каенга охшатам. Шәһәргә кунакка алып килгәч, мин аңа үзем укыган бинаны күрсәттем. Имән ишекләре урамга караган борынгы бинаны ул ис китеп карап чыкканнан соң:

— Монда хәзер укыйлармы соң?— дип сорады. Мин эчтән көлеп куйдым. Аның бердәнбер малае укып чыккач, бу бинаның инде керәге калмаган, япсалар да ярый, янәсе...

Мастерскойда ул минем картиналарны озаклап карады. Стенага фотолардан кала бернинди сурәт элдермәгән әнигә нидер булды, күңеле тулуы тавышына ук чыккан иде. Бераздан соң юаш кына итеп, икеләнгән сыман:

— Җан сорамаслармы соң үзеңнән?— диде. Бала чакта ул шушы ук сүзләрне кистереп, һич тә икеләнмичә, кисәткән кебек әйткән иде.

Кулыма төсле буяулар алып, чиста киндер каршына киләмме, зур галереяларда борынгыдан алып бүгенгечә килгән рәссамнарның әсәрләрен карап йөримме — шушы хикмәтле сүз искә килә дә төшә. Ислам дине рәсем ясауны тыймагандыр, бары тик олы курку уятып, ясаган сурәтеңә җан иңдерерлек булсаң гына бу шөгыльгә алын!— дип хәтәр кисәтеп кенә куйгандыр кебек. Әлбәттә, мин моны хәзер шулай уйлыйм. Заман башка, кылга эленгән кылыч баш өстеннән алынган. Гасырлар дәвамында күпме бөек рәссамнар үз-үзендәге сәләтне буып, билгесезлектә югалгандыр...

Нигә соң әле уйларым болай еракка сикерде, мин бит югыйсә якягына котырынып кычытканнар үскән чишмә тыкрыгыннан әни белән кайтып барам. Авылда шәһәрне сагынып, шәһәрдә авылны сагынып, ниндидер ике арадагы ноктада тирбәлгән күңел гадәттән тыш тынлыктан үзенә урын таба алмый башладымы әллә?

Бәбкә үләнле сукмактан күз алмыйча, әни белән сөйләшә-сөйләшә атлыйм. Менә хәзер, менә хәзер күтәрелеп карасам... уң якта Нәүширван абзыйның тавыклар пырхылдап чыга торган тишек түбәле лапасы булыр. Аны үтүгә, китек чүлмәкләр эленгән киртә казыклары, җиргә

ярымтүгәрәк сызып ачыла торган авыш капкасы... Менә хәзер күтәреләп карасам, «Әй, бүре маңгай!»— дип, чатанлап, Нәүширван абзый үзе килеп чыгар сыман. Аягын гына түгел, елмаюын да сугышта калдырып кайткан Нәүширван абзыйны кочып алыр идем хәзер.

— Аңлыйм мин сине, Нәүширван абзый, аңлыйм...— дияр идем. Элек аның төмсә йөзе ошамый иде бит югыйсә, гел аркылы килеп сөйләшүе дә тешкә тия иде, хәзер менә сагынам үзен. Гел буйга сөйләшүчеләр арасында бер аркылы килүче дә кирәк икән ул...

Алдану рәхәтен бүлеп, кинәт башымны күтәреп карыйм, юк, авыш капка да, тишек түбәле абзар да, Нәүширван абзый үзе дә юк инде. Юксынган җил аның миңа тавышын гына ишеттерә: «Әй, бүре маңгай-ай!..»

Бу нигездә хәзер тоташ коймалар — таза ихата-кура, калай түбәле гүрнәчә өй минем хәтеремнән көлгән шикелле тәкәббер биеклектә тора. Уйларымны сизгәндәй, әни:

— Гамир урында эшли хәзер, буксә үстереп җибәрде, кара, сандык кебек нинди йорт җиткерде,— диде...— Атасы Нәүширван гына күрә алмады, мәрхүм...— Әнинең дулкынланган тавышы шунда өзелеп китте.

Гамир авылда могътәбәр кеше, инженер булып эшли. Бәләкәй чакта әйтеп безне көлдергән сүзен инде ул бөтенләй оныткандыр да... Шәһәрдә мин, кемнән булса да нахакка рәнҗетелгән чакларымда, биек манара башына менеп, офык артындагы авылым ягына карап, нәкъ Гамирча итеп:

— Әнә безнең морҗа күренә, кыйный алмыйсыз!— дип кычкырасым килә...

Без кайтып җиткәндә, капка төбендә Хикмәтулла, Байтирәк абзыйлар һәм минем әти сөйләшеп утыралар иде. «Аю каны» шәрабы, башына кырлы стакан киеп, утыргыч астында посып утыра. Барысының да йөзенә җыерчыклар арасыннан яшьлек төсе саркып чыккан.

— Син кайда йөрисең?— дип, Хикмәтулла абзый миңа каршы сикереп торды.— Яшьләр ду китерә анда, әйдә, кер тизрәк.

Ул арада йөгерә-атлый Нәзифә апа да килеп җитте.

— Картлар исәбенә язылдыңмы әллә, кер әйдә, Тәнзил, сине көтәбез,— дип, ул мине култыклап ук алды. Үпкәләтмәскә тырышып, ничек кирәк алай котылып калдым. Артык шаулы мәҗлесләрдә гомум шатлыкка кушылып китә алмыйча, үз эчемә йомыла гына барам мин. Бүген мине биләп алган тойгылар мәҗлес рухына бөтенләй ярашмас иде, яшьләрнең эчкерсез бәйрәменә нигә әле моңсу күләгә төшерергә...

— Кара син аны, картлар мәҗлесенә кермәкче безнең белән,— дип, сирәк тешләрен күрсәтеп, Байтирәк абзый тәмәке алырга дип, кесәсенә тыгылды.

Картларның шундый килештереп гәпләшүләренә кызыгып карыйсың. Үз чорында күп авырлыклар күргәннәр генә ялның шулай кадерен белеп, онытылып утыра беләләрдер. Ике туган — Байтирәк һәм Хикмәт абзыйлар хәзер инде элекке үпкәләрен онытып, бер-берсенә йөрешәләр, Зәбирне күмгән көнне сөйләшә башлаганнар, уртак кайгы якынайткан иде аларны. Туганлык җебе еллар үткәч тә яңадан ялгана ала, олыгайган саен нечкәрә, тартыла барып, түене дә сизелми башлый икән.

Хикмәт абзый арада иң бәхетлесе бүген. Җиде малай арасында үскән бердәнбер кызының туе көненә ул тәмам яшәреп киткән. Авылга сирәк кайтылганга күрә, һәр кешенең йөз чалымындагы әз генә үзгәрешне дә сизеп аласың. Ни гаҗәп: Хикмәт абзый һаман да бер көе, чырае вакыт җиле кагылгысыз каратут тышча белән өртелгән кебек.

Хикмәт абзый уллары белән ачыктан-ачык мактанырга ярата. Капка төбендә һәр көнне техника тезелгән булыр. Кара «Победа» — олы малаеныкы. Аның кырыенда — бишекле «Урал» мотоциклы. Алгы пыяла-

сына әллә нинди сурәтләр төшерелгән, утыргычы төлке тиресе белән тышланган «Ява» мотоциклы арттарак тора. Коймага моторлы велосипед һәм тәкә мөгезе сыман кәкрәеп килгән рульле спорт велосипеды сөялгән булыр. Иң кече малаена кадәр, абыйларыннан күрмәкче, өч тәгәрмәчле велигын шул рәткә китереп куйган була бит. Малайларның берсе кайтуга, икенчесе армия хезмәтенә китә тора. Велосипедтан мотоциклга күчү дә шул тәртип буенча бара.

— Бер взвод солдат үстереп бирдем илгә,— ди Хикмәт абзый, горурлыгын яшермичә. Кулы костюмына беркетелгән бердәнбер орденга ялт кына кагылып ала. (Поляк ордены аны моннан берничә еллар элек кенә эзләп тапты. Партизанлыкта йөргәне эзсез калмаган икән. Польшага чакыртып, зурлап-хөрмәтләп тапшырганнар көтелмәгән бүләкне).

«Аю каны» стаканга бүленеп, кулдан-кулга күчеп йөргәннән соң, сүз арасына тәмле итеп тамак кырулар кушыла.

— Фәтхелбаян шәп күрше минем, тик бер начар ягы бар,— дип, Хикмәт абзый этинең иңенә кулын сала.— Гомер буе көнләшеп, миннән арттырырга тырышып яшәде ул, — дип, күзен хәйләкәр кыса. Уң кулын тиз өстенә куя.— Минем өч бармак тырнак төбеннән генә өзелгән, ә ул, миннән арттырыйм дип, кара инде нишләде,— дип, ул этинең моннан егерме еллар элек үк өздергән кулын селкеп күрсәтә.

— Яз житсә, без аның белән кан дошман булып бетәбез,— дип дәвам итә Хикмәтулла абзый.— Ике арадагы ызанга якын килмим дип, мин бер адым ара калдырам, ә Фәтхелбаян, миннән арттырып үз ягыннан ике адым калдыра. Моның бакчасы киңәйсен, эшләп чиләнсен Хикмәт дип шулай итә инде ул аны, хәйләкәр...

Хикмәтулла абзыйның кире яктан уңайга сөйләвен елмаймыйча тыңлый алмыйсың.

Хәзер инде этинең дөньясы ишегалды һәм капка төбендәге утыргыч белән генә чикләнгән. Буш вакыты булдисә, әни әйтмешли, китапка кадала. Бу кайтуда ул:

— Мә, улым, укы әле, шәп китап,— дип, Толстойның «Яңадан туу» китабын кулыма тоттырды.— Бүгенгеләрне дә укыйм мин, әллә нәрсә генә шунда... сарай кырыенда йөриләр, ишеген ачып керергә кыймыйлар. Ә бу ачып кергән,— дип, ул Толстойны үзенчә мактап та алды.

Байтирәк абзый инде күзгә күренеп бирешкән. Бөкресе аның гәүдәсен торган саен җиргә ныграк иңдерә бара, күрәсең. Үзе һаман әле кул кушырып ятмый, ихата тирәсен ныгытып йөри. Мин аның белән күрешергә дип барганда, ул яңа койманы сыек сары төскә буяп йөри иде. Бер төштә иске койманы сүтмичә калдырган.

— Каен такта черүне белми икән, торган саен ката гына бара. Егерме елдан артык бит инде югыйсә... Сүтәргә кулым бармады, Зәбир кадаклаган иде бу төшне,— дип, ул эчкә батып кергән кадак башларын бирчәйгән бармагы белән сыйпап-сыйпап чыкты.— Әйберләре исән, үзе генә юк,— дип, Байтирәк абзый битен сыпырып куйды.

Менә хәзер, утыргычта бер-берсен бүлә-бүлә гәпләшеп утырган өлкәннәргә карыйм да, ачынып уйлап куям: мәңге картаймас кебекләр иде бит алар — безнең балачакның җанлы шаһитлары. Вакыт нинди рәхимсез, астыртын гына үз төсләрен, үз чалымнарын сала, кешене тугач ук әзерләп куйган өлгесенә кертә бара.

Ачык тәрәзәдән яшьләрнең җыр, дәртле тавышлары ишетелә. Өметнең аргы яры алар өчен әле бик ерак. Биек хәтер тавына менгән картларның моңына алар җырлаган җиңел көйләр тәңгәл килми инде. Моңлы җыр яшенә житәргә иртәрәк әле бу яшьләргә.

— Картайдык, Тәнзил апаем,— дип сүз башлый Байтирәк абзый.— Без генәме, тал да картайды әнә,— дип, ул үз өе турысындагы Ялгыз

Әянкегә ымлап күрсәтә.— Җитмәсә... быел яз... шәһәрдән кунакка кайткан мертәт малайлар ут салып киткәннәр. Өч тармакка аерылган җире чокылып кергән ие бит, тәмам черегән булган үзәге, төпкә кадәр янып төшкән... Иртән генә күреп алдым. Кабыгында гына тора хәзер, җилле көннәрдә авыру кеше сыман ыңгырашып чыга, бичара.

— Каян туа диген шундый бәгырьсезләр, ә?!

— Каян чыга дип... Ата-анасы шушы авылдан киткән бәндәләр лә.

— Өс бөтен, тамак тук, җүләр көчне кая куярга белмиләр.

Дөнья гаменә керешкән сүз шунда өзелде, өйгә генә сыеша алмаган туй мәҗлесе урамга ташып чыкты. Чирәмлектә түгәрәкләнеп бию башлангач, аяк йөзенә кадәр төшкән бөтерелмә итәкле ак күлмәк, ак фата кигән яшь килен, кулларын җәеп, аккош кебек йөзеп кенә безнең янга килеп җитте. Кай арада шулай сылу булып үсеп җитте соң әле минем күрше кызы. Әнә, ничек, чигенергә урын калдырмыйча, ягымлы итеп кенә картларны берәм-берәм урыннарыннан торгызды.

— Кермәгән өчен сиңа үпкәлим, Тәнзил абый, биеп кенә котыла аласың,— дип, мине култыклап ук алды.

Яшьләрнең күмәк кул чабуы астында кулыннан таягын ычкындырмаган Байтирәк абзый чүгә-чүгә бии, Хикмәт абзый матросларча кулларын чәбәкләп, кызына таба якынлаша, әти белән мин дә алар арасында тыпырдаган булабыз. Күзләр — килендә. Ул бүген тантананың үзәге. Килен һәркемдә яшерен гашыйклык хисе кузгатырлык чибәр булганда гына туй мәҗлесе соң ноктасына җитеп кыза ала. Яшьләрнең карашын үзенә буйсындырып, уртада аккош булып балкыган Нәзилә дөньяга үч итеп шулай артык чибәр булып туган диярсең. Әнә бит, безнең кебекләрдә тагын бер тапкыр яшәреп карыйсы килү теләген котыртып, ярым ачык күкрәкләрен биетеп кенә уртага чыкты да кияү егетенең кулыннан тартып алды. Мондый чибәрлекне тормыш буйлап кулда алып бару, ай-һай, кыенга туры килмәсме бу оялчан егеткә...

Вакытында китә белү кирәк: без яшьләр дулкыныннан читкәрәк тайпылдык.

— Мин кайтып килим әле, күкрәк кыса, даруны онытканмын,— дип, Байтирәк абзый бил аркылы салган шомырт таягына терсәкләрен бөкләп тотынды да үз-үзен этеп кузгаткан шикелле китеп барды.

— Озаклама. Бүген төне буе йоклау юк. Иртәгә кыз озатасы,— дип, Хикмәт абзый аның артыннан кычкырып калды. Йөзенә сизелер-сизелмәс кенә моңсулык күләгәсе төште. Кызын күрше авыл егетенә биреп җибәрәсен әле генә аңлап алгандай, башын небрәк кузгалды. Мин, мәҗлескә соңрак керергә ышандырып, югары очка менеп киттем.

Таныш тавышлар... Таныш эзләр... Үзгәрә барган дөнья каршында үзең генә белгән кадерле хатирәләр...

Борынгы кибетнең калын пыялалы ишеге электәгечә чыгырдап ачылган чакта мине рәхәт бер калтырау биләп ала. Прилавка артында торган тулы гәүдәле хатынның исеме Гөлсирин булса да, мин кайчандыр «полячка» дип йөрткән кыз белән аның арасында нинди уртаклык бар соң әле?..

Гөлсирин минем белән битараф кына күрешә. Аның яшендәге хатынкызның якын иткән кешеләре өчен генә сакланган аерым елмаюы була. Мин бу елмаюга лаек түгел. Артык бәхетле күренгән йөзеннән колак алкалары, бармакларындагы балдак-йөзекләрнең алтын шәүләләре аша, затлы читлектә әсир калган кош булып, аның миңа гына таныш, мин генә белгән үткәне карый. Такыя киеп, кулына сары чәчәкләр тотып, урам уртасыннан барган кызны, ихтимал, хәзер инде күптән оныткандыр. Ә ул, һаман шулай төз басып, минем хәтер урамыннан самими матурлык иленә таба атлый. Гомеремнең азагына кадәр мин аның ар-

тыннан шулай ияреп барырмын. Ни генә булса да, үсмер чагын күңелемдә калдырып киткән Гөлсирингә барыбер рәхмәтлемен. Мин аның яшенә җитә барам, ә ул тагын алга китә, шушы аермалык аңарда теге вакыттағы миңа карата баласытып карау тудырмаса, мәңге сер булып калган кадерле хатирәм булыр идемени!

Такыялы кыз минем картиналарыма күчкән. Гөлсирин алардан хәбәрдар түгелдер, хәер, күрсә дә, ул инде үзен таный алмас иде.

Керүче-чыгучылар беткән арада кибет эче бушап калган икән. Гөлсириннең арыган куллары прилавка өстенә салынып төште. Бармаклары гүя миңа сорау белән текәлгәннәр иде. Шунда гына мин, йомышсыз терәлеп торуымны аңлап, Гөлсирингә күтәрелеп карадым.

— Ни аласыз?

Үткәннең бөтен төсмерләрен җуйган тавышы, ниндидер өстенлеген сиздерергә тырышып, кысылган иреннәре арасыннан ялкау гына чыкты.

Туй бүләген әйтеп, иллелекне бирдем дә... Кабатлану була димени! Ә шулай да кабатларга кирәк иде, малай чагыма хыянәт итмәс өчен...

— Өч прәннек бирегез тагын,— дидем аныңча күплек затында эндәшеп. «Син» димәү дөрестер дә уйласаң, чынлап та шулай бит әле, минем өчен дөньяда ике Гөлсирин бар: берсе аның кулына чәчәк тотып, һаман әле мине үз артыннан ияртеп бара, икенчесе — өч прәннек дигәч, сәерсенеп елмайганы — хәләл ире Корычбайның әле кызыл «Жигули»ена (яңгырлы көннәрдә), әле ак «Жигули»ена (кояшлы көннәрдә) утырып, кибеткә көн дә эшкә килә-китә йөри.

Бик күп нәрсәләр үзгәрде минем дәвердә генә, ә менә прәннектән һаман шул — балачак исе, балачак тәме килә. Кайсы гына авылдан, кайсы гына шәһәрдән сатып алма — тәме бер.

Кайтып барганда каршыма Мәдинә апа очрады. Хәзер инде ирләрчә киенеп йөрмәсә дә, кул кысып күрешүе ирләрчә иде аның. Күмер кебек кара чәчләре арасында көмешсу көл сибелгән кебек. Күзләре дә элекке кебек чаткы чәчрәтеп тормый, талган моңсулык аша карый.

Хәл-әхвәлләрне сорашкач, мин Сафуан абыйны искә төшердем. Мәдинә апаның карасу-кызыл иреннәрендә рәхәт елмаю уйнаклап алды.

— Былтыр... капка төбенә машина туктагач йөгереп чыксам... Сафуан басып тора. Куроорттан кайтышыбыз ди. Хатынын-балаларын да иярткән. Чәй эчереп чыгардым үзләрен. Ул да онытмаган икән...


Мәдинә апа Сарай тавы ягына төбәлеп, сүзсез калды. Бәйләм куллмәгенең сәдәфен бөтергәли башлады. Мин еллар көле каплаган кадерле сагышына кагылдым да, хәзер инде ни әйтергә, ничек юатырга белмичә аптырап торам. Хәер, кайгысын да, шатлыгын да эченә йомарга күнеккән Мәдинә апа юатуга мохтаҗмыни соң?!

Мин аңа теге вакытта Сафуан абый белән утыргычта сөйләшкәннәрен качып тыңлаганымны һаман да әйткәнем юк икән бит. Әле дә урам уртасында капылт кына ачылып китеп булмый. Тагын икенче вакытка кала инде. Шуңа ышанасың, иркенләп бер утыру җаен алдагыга калдырасың. Мәдинә апа да каядыр барырга йомышлап чыккан бит әнә. Ашыгу гадәте авылга да бәреп кергән. Вакыт хәзер монда да җәяүле түгел — машиналы, мотоциклы... Көн — тәгәрмәчләр өстендә.

Ашыгуның сәбәбен Мәдинә апа үзе бик гади генә аңлатып бирде:

— Югары очтагы Нәфисә әби авырып киткән. Балалары кайтып җитмәгән әле. Шуңа тавык шулпасы илтешем.

Мәдинә апа һаман шулай, үз ялгызлыгын онытып, бүтәннәр кайгысы белән яши икән. Бәлки шуңа күрәдер дә аның йөзендә мәрхәмәтле матурлык — күңел чагылышы булып, картаю-олыгаю салган еллар агышына бирешмичә сакланып калгандыр. Ихтимал, яшьлегендә бәреп чыккан ялкынланасы бөтен хисе — ягымлылыгы, әкрен генә пыскып, аның бөтен гомеренә тигез таралгандыр.



Ниндидер үзем дә аныклый алмаган уйлар белән (кызганумы, сокланумы, гыйбрәт алумы?) Мәдинә апа чаттан күмелгәнче борылып карап калдым.

Югары очның тыгыз өйләре һәм казылып беткән катканаклы урамнарыннан соң түбән оч капка төбендәге чирәмлекләре, саф һавалы үзгә бер тынычлыгы белән яшел учын җәеп каршы ала. Туй бүләген култыгыма кыстырып Байтирәк абзыйлар тыкрыгына борылыр алдыннан, күңелемә сеңеп калган күренеш тагын мине тукталырга мәҗбүр итә: авыл башындагы ялгыз Өянке... каршысында бөкресе белән койманы терәп утырган Байтирәк абзый... Еракта — зәңгәр гөмбәзле Чатыр тау... Өянке... бөкрәеп, Байтирәк абзыйга охшаган, Чатыр тау киң ябалдашлы Өянке сыман күренә. Шушы өч бердәмлеккә карагач, кан тамырларыннан аккан вакыт тукталып кала. Гел шулай булыр сыман: Байтирәк абзый үзе ясаган утыргычта кояшта җылынып утырыр. Өянке талгын җилдә яшь ботакларын тибрәтер. Чатыр тау текә маңгаен күтәреп офыктан карар — ничә кайтсам да шушы күренеш, иминлеген җуймыйча, мине каршы алыр шикелле.

Яшәешнең бакыйлыгын тойган бу мизгелдә мин Өянкенең кеше гомереннән озаграк, тауның исә Өянкене дә узып яшәячәге турында онытырга тырыштым.

---

Өянке үзенең инде тәмам картайганын күләгәсенә карап та белә. Араланып калды ботаклары, сирәгәйде яфраклары. Элек сутлы үлән бәрхетенә кара бөркеттәй төшкән күләгәсе хәзер инде тетелеп тузган җәймәгә охшап калган.

«...Дөньялар үзгәрешенә дә яраша алмыйм бугай. Аңламассың: кояш аязга байый, ә икенче көнне китерә дә яңгыр коя. Кышка карап җәй килми. Нидер үзгәрде. Яз иртә килә дип, җир җылысына ышанып, бөреләремдә яфрак өлгеләрен әзерләп кенә бетерәм — кинәт салкыннар башлана, җир катыра, энәле җил исә башлый. Инде ачылыр мәле җиткән бөре биләүләрен кая яшерим, ничек җылытыйм дип, төннәрен ут йотып чыгам... Сизгерлегем кимеде... Кешеләр әнә утырып та, ятып та хәл алалар, ә мин — гомерем буе аягүрә. Буыннар катканлыгын җил искәндә аңлыйм, бөгелә алмый хәзер ботакларым — сына гына.

Ә шулай да... кешеләр белән янәшәдә үткәргән елларымның мәгънәсе бер гомергә генә торырлык...»

Казларның тук тавышка каңгылдашулары, бушап калган кырлардан искән җилләре белән көзләр үтә. Морҗалардан күтәрелгән әчкелтем-хуш исле төтен баганалары белән салкын кышлар килә. Кара каргалар кайтып, су буендагы өянкеләргә оя кора башлауга, тау битләре челтәр карлардан арына, кышкы йокыдан арынып, кояшка битен ачаязлар килә.

Аннары... көннәр кайнарлана, авыл җәйге хозурлыкта яши башлый. Яшел үлән төрткәнне күрсәм, терелерием дип, кышын сырхауга калган картларга кадәр капка төпләренә чыгып; таягы белән серләшеп утыра — күзләрендә нур, йөрешләренә кадәр үзгәргән, шөкер, бу җәйне дә күрдем дигән рәхмәтле карашлары, тәмле сүзгә әверелеп, телләренә күчкән.

Ә яшьләр... мотоциклда, машинада чабучы яшьләр гел хәрәкәттә. Айлы төннәрдә тын гына килеп, Өянке янында серләшеп утырмыйлар инде. Гадәтләре башка...

«Элегрәк авылга кереп килгән ят кешене кулларын каш өстенә куеп яисә тәрәзә пәрдәсен күтәреп күзәтәләр, олы бер яңалык итеп кабул итәләр иде. Хәзер инде авылга килү-китүченең исәбе-хисабы юк. Өянкегә тузан бөркеп, машиналар чебен кебек үтеп кенә тора — абай-

ламый да каласың. Җигүле атлар хәзер бик сирәк күренә шул. Әй ул атларның үтүе! Тояклар тупырдавы җир тирәнлекләре аша, рәхәт кытыклап, тамырларыма кадәр тарала да әллә нинди хатирәләр сулкылдап күтәрелә башлый. Андый чакта урыннан кубасы-кузгаласы, атлар эзеннән, үткәннәрне эзләп, юлга чыгасы килә.

Үткәннәр дигәннән... Исән кеше бер кайтып күренә икән. Кайчандыр сиртмәле кое янында ябага туп тибеп уйнаган Давыт исемле малай Өянке хәтерендә төш кенә булып, бөтенләйгә югалган иде. Бик олы урында эшли, чит илләрдән кайтып керми икән дигән хәбәрләр ишетелгәли иде аның турында. Хикмәтулла яисә Байтирәккә әллә нинди маркалар ябыштырылган хуш исле конвертлы хатлар елга бер булса да килгәләп торды да соңгы елларда бөтенләй өзелде.

Көтмәгәндә-уйламаганда кайтып төште бит беркөнне. Хәер, кайтты дию бик үк дөрес булмас, үтешли, сугылып кына чыкканлыгын авылдашлары да искәрергә өлгерә алмый калдылар».

Башта... Байтирәк белән Хикмәтулланы машинага утыртып, район үзәгенә алып киттеләр. Төштән соң дүрт-биш кара машина Өянке янына килеп туктады. Бер-бер артлы чыртлап ачылган ишекләрдән затлы киемле таза-таза ирләр, арттагы машинадан исә кара плащлы, үткен карашлы егетләр төште.

Барысының да игътибар үзәгендә булган чал мыеклы ир кеше фетр эшләпәсен салып кулга тотуга, аның озын чәч учмасы ак ялкын булып, җилдә уйнаклый башлады. Менә ул салмак кына атлап килде дә Өянке кәүсәсенә кулын куйды. Озын, ак бармаклары сизелер-сизелмәс кенә калтырый иде. Нидер әйтергә теләде чал чәчле кеше, әмма гадәттән тыш дулкынлануданмы, сүзләре тамак төбенә дулкын булып өелде. Аның өчен инде балачак теле дә салам түбәле өйдә, ялан аяклы ерак дөньяда онытылып калган иде бугай. Нигез урынын актарып, туфрак катламы астыннан таныш чүлмәк, чынаяк китеге эзләгән шикелле, күңел төбеннән ул, азапланып, кадерле сүзләрнең кайтавазын эзли иде. Менә ул, ярдәм сорагандай, авыл ягына борылып карады. Капкалар, коймалар, өйләр үзгәргән, аның каршында бөтенләй ят бер авыл җәйрәп ята иде. Авыл гынамы, янәшәсендә уңайсызлык тоеп торган Хикмәт белән Байтирәк тә, кан туганнар булса да, аның өчен хәзер инде барыбер чит-ят иде. Кешелекле әчке бер тойгы гына аларның кан туган икәнен искәртә, ә чынында исә сизелми дә үткән дистә-дистә еллар арага салкын түбәле таулар өйгән иде.

Байтирәк үзен уңайсыз сизә, дәрьялар артындагы ят илләрдә эшләгән бу кеше абыйсымы аңа, түгелме — һаман әле ышанырга да, ышанмаска да белми. Җитмәсә, бөкресе дә, үзен сиздереп, иңне баса башлады. Озын буйлылар янында ул гел шулай, арка тиресенең тартыша башлавын сизә иде.

Хикмәт исә кара тут чыраена пәрдә төшергән, ваемсыз кыяфәт белән читтәрәк тора.

Өянке кәүсәсеннән күтәрелгән туган җир җылысы Давытның куллары аша йөрәгенә җиттеме, кинәт аның зиһене ачылып китте, балачакта калган сүзләр ком юшкынындагы алтын бөртекләре шикелле елтырап, иң өскә калыктылар.

— Монда... безнең нигез...— дип, Давыт плащын ычкындырды да, үлчәргә тырышкандай, кайчандыр өй торган урынны чамалап, эре-эре атлап йөреп чыкты.

— Шулай?..— дип ул сораулы карашын әле Хикмәткә, әле Байтирәккә төбәде. Хикмәт, чыраен ризасыз сытып, ым какты. Тип-тигез чирәмлектә кайчандыр өй торганлыгына берничек тә ышана алмаган кунаклар да Давытка теләктәшлек белдереп, сүз кыстырырга ашыктылар.

— Монда кое...— Давыт үлән арасыннан көмешсу әрем баш төрткән турга килеп басты, нидер сөйлисе килеп тә, теле җитмәгән сабый бала шикелле мәзәк хәрәкәтләр ясап алды.

«Ялгышасың, кешем, дип уйлады Өянке, өй урыны уңдарак иде, оныткансың, туган, нигезеңне, оныткансың... Кое урыны да син баскан төштә түгел, болайрак, болайрак кил, кешем»,— дип пышылдады яфраклар.

Ят кунакларның сәгатькә карап алуларына караганда, алар бик ашыгалар иде, күрәсең. Давыт кулъяулык чыгарып, читкә борылды да тиз генә күз төпләрен сөртте, аннары, иелеп, кулъяулыгына туфрак алып төрде. Ул арада машиналарны кабыздылар. Кузгалу шаукымында Байтиракка дә кыюлык инде:

— Давыт абый, әнә безнең өй — каршыда гына, чәй эчеп чыгар идек ичмасам,— дип кыстый башлаган иде, абыйсы, моңсуланган күзләрен түбән төшереп, баш селкеде. Ул инде ике энекәшен дә район ресторанында кунак иткән иде. Өйгә үк кереп торса, ныклап кайту була, ә туган җирен бик күп еллардан соң гына кайтып күргән кеше озак яшәми, диләр. Шул ырымга ышана һәм шуннан курка да иде Давыт. «Эш тыгыз булды шул, гел кайтам дип йөреп, гомер сизелми дә үтеп киткән...»

Берсен-берсе уздырырга тырышкандай, шапы-шопы ишекләр ябыла башлады. Давыт ике энекәшен берьюлы кочаклады, битләреннән өчәр мәртәбә үпте дә машинага таба кузгалды. Ир кеше үбүен беренче мәртәбә татыган Байтирәк, үзе дә сизмичә, кул аркасы белән яңагын сөртеп алды.

Машиналар төтен бөҗралары уйнатып кузгалдылар. Артына карап, һаман әле кул болгап барган Давыт чал чәчләре белән яктырып, машина тәрәзәсеннән күренә, тегермән үреннән күмелгәнче, Өянке алар ягына үрелеп карап калды. Соңгы тапкыр... дип пышылдады яфраклары. Соңгы тапкыр...

Машиналар үр артына күмелгәч кенә, ике туган Өянке төбенә килеп утырдылар. Тәмәке кабызгач, Байтирәк карлыккан сүзләрен мул төтен арасыннан этеп чыгарды.

— Җитмеш яшьтә бит инде югыйсә, ә бездән яшь күренә,— дип абыйсына карады да төзәтеп куйды.— Чырайга миннән яшьрәк. Кырда куна-төнә эшләп ватылмаган шул.

Хикмәт, ниндидер мәгънә салып, тамак кырудан узмады.

— Нигез урыны анда түгел дип әйтәсе килгән иде дә, яхшысынмадым инде... Әйдә, шулай ышанып китсен.— Байтирәк, үзен хуплауны өмет итеп, абыйсына карады. Әмма Хикмәтнең кара тут чырае корыч салкынлыгы бәреп тора иде. Аптырагач, Байтирәк куллары белән җиргә таянды да, арка бөкресен өскә чөеп, урыныннан калыкты.

— Әйдә, алайсам, чәйләп алыйк.

Хикмәт, кул селтәп, үз өенә таба китеп барды.

Әгәр дә кешеләр агачлар кебек үк бер урында гына тамыр җибәреп яши алсалар, ничек булыр иде икән, дип уйлады Өянке. Киту-кайтулар, сагынулар булмас иде. Кешеләр бер-берсенә явызлык кыла алмаслар, кинәнеп яшәрләр, бары тик яшәрләр генә иде кешеләр, әгәр, агачлар кебек үк, тамыр җибәреп, бер урында гына тормыш кора алсалар...

Өянкенең ул чактагы уйлары, әлбәттә, бүгенге көнгә үз хасиятендә килеп җитмәде. Бер-бер артлы алмашына барган буыннар — кешеләр язмышы матурлый җирне, озак дәвер яшәгән Өянке моңа инде күптән төшенгән иде.

Бүген таң нинди тыныч, йомшак, нурлы булып туган иде, югыйсә, төшкә таба әллә каян гына җил чыкты: кисәк кузгала да машина эз-

ләрендәге тузанны урыны-урыны белән күтәреп алып бөтерә башлый, ялкауланып, тагын икенче төшкә илтеп сала. Түбән очта бәйрәм шаукымы кузгалган шушындый да кояшлы көнне әле болайдан, әле тегеләйдән искән тотрыксыз җилнең һич тә кирәге юк иде шикелле.

Бүген — кыз озату көне...

Хикмәтләр капка төбендә машина-мотоцикл кебек «заман арба»ларының хисабы юк. Гадәттә, авылның бер өендә кузгалган мондый сирәк килә торган бәйрәм шаукымы, җылы дулкын булып, бүтән йзбаларга да тарала. Матуррак яулыклар бәйләнә. Яшьлегә сүнеп барган хатыннарның да бит очларына кызыллык йөгерә. Капкалары ешрак ачыла. Килен китүне күреп калганда һәркем күңеләшүле яшәреп ала.

Кызы да нинди бит! Очта бер, очта гынамы — авылда бер чибәр, авылда гынамы — тирә-якның даныын күтәрерлек.

Очның яме иде ул. Аның ике толымын түшенә салып, гаҗәп төз басып судан кайтулары. Аның исәнләшкән чакта, тигез тешләрен күрсәтеп, ике бит очын күләгәле упкынлатып елмаюлары... Байтирәкләр коесыннан үзләренә кадәр араны ул чирәмле сукмактан шундый килешле итеп атлап бара ки, хәтта капка төбендә утырган карчык-корчык, хатын-кызларга кадәр, сүзләреннән өзелеп, озак карап калалар. Сокланууларын эчкә яшереп, тизрәк гаеп-кыегын табарга тырышулары өскә калкып чыга.

— Уклау йоткан кебек гәүдәсен катырып йөрмәсә.
— Кемгә охшап шулай кыланчык булгандыр...
— Ояла да белми бит, күзгә карап сөйләшә.
— Элгәре без башны иеп кенә йөри торган идек, ә?!
— Заман башка, түтекәем...
— Хикмәткә тартса, морҗаңнан кереп, тәрәзәңнән чыгар бу!

Хатын-кызлар әнә шулай бер-берсен бүлә-бүлә, үз карашларын әйтеп калырга ашыгалар. Ә күңелләрендә бу сылу кызга яшерен соклану, яратып көнләшү һәм... сүз белән генә баса алмаслык сагыш ята. Үзеннән чибәррәкне таныган хатын-кыз картая баруы белән инде килешә башлаган дигән сүз. Әнә бит, кайсылары соңыннан, өйгә кергәч, көзге каршына килеп, күз төбендәге җыерчыкларын тигезли-тигезли, гомер буе күнеккән йөзеннән уңай сыйфатлар эзли һәм үзалдына уфтанып куя.

Алар инде күрше авыл киявенең нинди нәселдән чыгуын да җиде бабасына кадәр белеп алганнар. Нәзилә сайлаган егет күз күрмәгән затлы бер егет булырга тиеш дигән эчке уйларына каршы килеп:

— Әллә кем түгел икән...— дигән булып, кияүгә мөһер дә сугып куйдылар.

Бүген — кыз озату көне...

Нәзилә киткәч, бөтен оч күңелсезләнеп калмасмы? Ул үткәндә, тәрәзәләр яктырып китә, өйләр биегәя, урамнар киңәя иде бит. Көянтәчиләк асып, Нәзилә узганда, Байтирәк тә бөкресен онытып турая, хәтта коймага сөягән сердәш таягын да онытып калдыргалый иде.

Очның яме — Нәзиләдә. Моны чирәмле сукмаклар белә. Моны Өянке белә.

Тик менә көннең бозылырга торуы гына... Кияү ягындагылар: килен усал булыр ахрысы димәсләрме, артык матурлыкка сагаеп карау кешеләргә хас сыйфат түгелмени.

Байтирәк бүген нindидер уе бар шикелле иртәдән үк кыбырсып йөри. Туйлы йортка биш барып, биш кайтты инде, ике арада тик киләпсарып йөри. Күкрәк кысуын да оныткан, атлаулары шәбәйгән. Бау алып чыгып, болай таба килде дә Өянкенең буш күз урыны сыман караеп калган ботак тишегенә карап торды, кәүсә төбендәге кара күмергә әйләнгән куышлыкны кулы белән сыпырып караганнан соң шушында ут салып киткән шәһәр малаен тагын бер каргап алды һәм кәүсә

әйләнәли уратып, сүс бауга әлмәк ясый башлады. Әз генә тарткан иде, черек бау өзелеп тә чыкты. Нииндидер йомыш белән күршегә кереп барган карчыгына ул җилкә аркылы гына дәште:

— Әй, син, җүнлерәк бау алып чык әле!

Солтания сагаеп башын борды, соңгы елда колакка катыланган, вакыт-вакыт гел дә начар ишетә иде ул.

— Мә дигәнне генә ишетәсең шул, карчык, бир дигәнне колагыңа да элмисең,— дип, Байтирәк түзмәде, үзе капкага таба китте.

— Мәдинәгә ни булган тагын?— диде беркатлы Солтания.

— Бар, юлыңда бул,— дип, Байтирәк капкадан кереп күмелде.

Бераздан инде эшен тәгәлләгән иде. Элмәкле бау Өянке кәүсәсенә бәйләнгән. Юл кырыендагы чирәмгә озын колга сузып салынган. Кырыена килеп баскан хатынына Байтирәк борын астыннан хәйләкәр елмаеп карады.

— Күкәй салган әтәч кебек йөрисең, ни булды соң сиңа?— диде Солтания.

— Күрмисеңмени, машина килеп җитте дигәндә генә — шап! Колганы юлга аркылы салам да... Буләксез котыла алмый кияү миннән.

— Талның теге ягыннан әйләнеп үтәлмиләр дисеңме?

Байтирәк бу турыда башына да китермәгән иде, кинәт аптырауга калды, ләкин карчыгы каршында болай чарасыз мәлҗерәп төшүгә күнекмәгән акылы хәйләне тиз тапты:

— Туры юлдан үтмәсә, нинди җегет ди ул! Беренче көннән үк читкә каера башласа, кияүлеге бер тиен!— Байтирәк тәмәке кабызды да:— Кайчан кузгалалар икән, бар, белеп кайт әле, мин чәй куя торам,— дип, капканы ачык калдырып, өйгә кереп китте.

Ул арада Хикмәтуллалар капка төбендә халык дулкынлана башлады. Гармун тавышын бүлеп, мотоциклар тырылдап кабынды. Кояш нурын чагылдырып, машина ишекләре ачыла-ябыла башлады. Аккош булып килен дә балкып китте. Кузгалалар, кузгалалар...

Җилне дә онытып, каерылып карый Өянке. Иң беренче булып аллы-гөлле тасмалар белән бизәлгән машина юлга үрмәләп чыкты, аның артыннан ялык-йолык килгән пыялалы мотоциклар тигез рәт булып килә. Артта — калган машиналар. Тезелешеп, әкрен генә киләләр.

«Нигә соң әле Байтирәк күренми? Соңга кала бит инде! Иртәдән бирле көтте, көтте дә, вакыты җиткәч кенә...» Кычкырырга әзер, йөгереп китәргә әзер Өянке Байтирәкнең нәкъ кирәкле мәлдә пошмаслыгына аптырап та, тынычсызлап та калган иде.

Шул вакыт капка ачылып китте, йөзе гадәттән тыш агарган Солтания килеп чыкты да кая барырга белмәгәндәй туктап калды. Әле югары оч ягына, әле түбән оч ягына карый, иреннәре селкенә, тавышы чыкмый, үзе һаман каядыр омтыла...

«Байтирәк нишләп күренми соң әле, килеп җитәләр бит инде!»

Шул чак Өянке атка атланган малайның машиналар артыннан чаптырып килүен күреп алды. Тимер ташкын аша тояклар тупылдавын ишетәсе килүдән ул җилкенеп, бөтермә җил иркенә бирелеп, алга каерылды да... кинәт өстәге ак болытлар, каршыдагы өй тәрәзәләре, чирәмле сукмаклар, буталып, баш әйләндергеч рәхәтлектә йөзә, якты бер түгәрәккә әверелә башлады.

Кырт туктап калган алгы машинадагы киленнең кычкырып, кияүнең беләгенә чытырдап ябышуын да, җыр-гармун тавышларының кисәк тынуын да ишетмәде ул. Җылы җир тирәнлегендә кое суының нәкъ менә бүген үз юлына кайтып төшәсен дә белми калды.

Юлга аркылы ауган карт агач без белгән Өянке түгел иде. Өянкенең асылы бу мәлдә кояш нурлары буйлап чиксез биеклеккә күтәрелә, дөнья хәтеренә кушылырга ашыга иде.

**Мөхәммәт Мәһдиев**

# АГЫЙДЕЛНЕҢ БУ ЯГЫНДА...

Агыйделнең аръягында «бер энәгә бер сыер» биргәннәрен балачактан ишетеп үскәнгә, Агыйдел ягы минем күңелне күптән тарта иде. Әлеге шигъри төбәкне мин олыгая төшкәч күрә алдым. Туктале, дип уйладым шул чакта, Агыйделнең бу ягында бер энәгә ниләр алып була икән?

## Алыш-биреш

Сөн буена урнашкан берничә колхоз соңгы ике төн эчендә тетрәнеп калган: колхоз көтүлекләренә бүреләр һөҗүм ясаган! Сентябрьнең Сөн буе якларына бүләк иткән бик тә, бик тә исәпле кояшлы көннәре иде бу! Бу якта 1983 елның августында йөреп без моны тоймый да ятканбыз. Басулар җебегән, юллар эрегән. Урырга кереп караган комбайннар күчәргә кадәр баткан, аларны трактор белән өстерәтеп, бодай арасыннан чак-чак юлга чыгарганнар. Инде — көтелгән кояш, көтелгән аяз көн! Райком бинасында дисталәгән бүлмәләр буш: каттан-катка йөреп бер кеше таптык — беренче секретарьның алгы бүлмәсендә дежурлык итүче апа:

— Бөтенесе — чөгендердә, бөтенесе — ындыр табагында,— диде ул. Аннан үз якларынча әйтеп куйды:— Шушындай кояшлы көнне бүлмәдә ничек утырасың ди, апаем? Бөтен кеше басуда... Әле ишеттегезме? Бүреләр, «Чишмә» колхозына кереп, утыз сигез баш сарыкны буып киткәннәр?...

«Чишмә» колхозына дип, транспорт юллап торганда гына бу хәбәр мине шатландырмады. Бүре — бүре инде ул. Галим-голәма күпме генә мактаса да, табигатьнең тигезлеген тотар өчен, бүре кирәк, дип, күпме генә сөйләсәләр дә, бүре — ерткыч. Комсыз ерткыч. Сораштым: сигез баш ди. Ата, ана, алты бала. Балалар апрель тирәсендә туган. Буй җиткәннәр. Ата-ана аларны кышка — кырыс буран-салкыннарга, атналар буе азык эзләп йөрү режимына әзерли һәм өйрәтә: менә сарык көтүе. Тәҗрибәсез бүре көтүгә килеп керә дә, бер сарыкны тотып ботарлый, туйганчы кайнар ит ашый. Ашый, комсызларча йота, гәүдәсе авырая; качарга кирәк, кешеләр-аучылар килүе бар, атлавы кыен, тамак гүргә кертә — андый бүрене куып җитәләр. Бер тапкыр туйганчы ашаган өчен. Әмма тарихи-биологик тәҗрибә бар: җиңел азык ашап, җиңел ашказаны белән атна буе тук яшәргә була. Карт бүреләр яшь буынны шуңа өйрәтәләр: иң җиңеле һәм иң уңайлысы — бәраннең фонтан булып бәреп торган каны. Бүреләр утарга килеп керәләр дә бер-бер артлы мәхлук бәраннәрне бугазлый башлыйлар.

Бүреләрнең бу көтүен икенче көнне Мөслим районында күргәннәр. «Чишмә» колхозы председателе Ясәви Хөсәенов әйтте:

— Бүген таңда бүреләр Башкортстанга чыгып киттеләр,— диде.

— Ничек? Ике арада Сөн бар бит?!

— Бүреләр теләсә нинди елганы йөзеп чыгалар,— диде Хөсәенов, тәҗрибәле аучы.— Алар хәзер балаларын мөстәкыйль яшәргә өйрәтәләр — сарык буарга, каз алырга, елга кичәргә... Яшь буын кышны әти-әни ярдәменнән башка чыгарга тиеш. Көз — авыл хуҗалыгына бүреләр һөҗүм итә торган иң хәтәр чак.

Бу тирәдә кабат күренсәләр, әлеге тәмле тамаклар Казан мех комбинатына «путевка» алырлар, дип уйладым мин, чөнки председатель верандада ике көпшәле мылтыгын алып, нигәдер, бер чөйдән икенчесенә күчереп куйды. Аучылык — аның гомер буе иң яраткан шөгыле икән. Үз гомерендә ул күп кенә поши, кабан дуңгызы, бүре, төлке алган. Ә инде кыр үрдәге, куян кебекләрнең исәбе-хисабы юк.

— Әле дә ауга йөрисезме?— дип сорыйм.

— Куян ата алмыйм хәзер.

— Нигә? Күзләрегез начарландымы әллә?

— Юк, күзләрем әйбәт. Әле бу җәйдә генә Башкортстаннан килгән һәвәскәр аучылар белән бәхәсләшеп егерме метр ераклыктагы казык өстенә утыртылган авторучканы бәреп төшердем. Кечкенә калибрлы мылтык белән. Куян атмавымның сәбәбе башка. Узган ел сезонны ябар алдыннан бер куян аттым. Яшь куян туры килде, дүрт аягы да чәрдәкләнгән, янына килгәч, иелеп ала алмый тордым: күземә карап елады. Нәкъ сабый бала кебек. Күз яшьләре белән елады. Ә теге бүреләр утыз сигез сарык бәясен сигез тире белән түләячәкләр... Менә бераз бушаныйк кына... Алар белән алыш-бирешне хәл итмичә кышка кермибез инде аны...

## «Искра»ның бер саны

«Чишмә» колхозында республиканың иң алдынгы дуңгыз караучысы Социалистик Хезмәт Герое Александр Сальников яшәгәнен беләидем. Мәрхүм Сальников белән без таныш идек. «Чишмә» колхозында югары сыйфатлы кымыз ясаганнарын, бу колхозда ике йөз гектар чамасы күлләр булуын, ул күлләрдә карп үрчетелүен, ул карпны сорап, Әлмәт тирәсе районнары, Башкортстан сәүдә оешмаларының байтак машина куып Хәсәеновның «ярар»ын ишетергә йөргәннәрен дә, бу колхозга Сара Садыйкова белән мәрхүм Мостафа Ногман килеп, махсус җыр язганнарын да белә идем.

Әмма «Чишмә» колхозының тарихи музеенда «Искра» газетасының Беренче саны булыр дип башыма да кермәгән иде... Татарстанда барлыгы ничә икән ул тарихи газетаның беренче саны? Мин авылларда йөргәндә колхоз музейларын карарга яратам: аларда һәрчак «тапталмаган» хәзинә була.

Азнакай районы Чалпы авылы музеенда бу музейны оештыручыларга — Советлар Союзы Маршалы Г. К. Жуков язган хатны күреп тынсыз калган идем. Инде монда — «Искра».

...Хәсәенов өлкән укытучы Сафа Гарипов агайга эндәште:

— Музейны карыйк!— диде.

Мин уңайсызландым. Кадерле кояшлы көннәр, кырда комбайннар эшли, ындыр табагы гөрли, юл тулы техника. Колхозда икенче көнем, ә шул вакыт эчендә бу колхозда райкомның беренче секретаре Х. М. Низамов — ике тапкыр, секретарь Г. Ә. Камильянов бер тапкыр булып китте, РАПО председателе Ә. Камалюков Татарстан авыл хуҗалыгы Министры урынбасарын алып килде.

— Бодай уруны кайчан тәмамлыйбыз?

— Тагын ничә гектар калды?

— Иртәгә кичкә бетереп булмасмы?

Әнә шундый киеренке бер көннең үзәгендә без —музейда. Ничек инде председатель кеше вакыт таба, дисәм, музей — аның горурлыгы икән. Музейда КПСС Үзәк Комитеты, СССР Министрлар Советы, ВЦСПС һәм ВЛКСМ Үзәк Комитетының 1979—80 елда Бөтенсоюз һәм республика социалистик ярышында ирешкән уңышлары өчен бирелгән Мактау грамотасы саклана.

— Шундый ук грамотаның икенчесе быел килергә тиеш безгә,— ди Хәсәенов,— ярышта җиңүебез белән безне бик күп оешмалар тәбрикләде.

Соңыннан «Социалистик Татарстан» газетасыннан укыдым: «1982—83 еллардагы кышлатуны уңышлы үткәреп, терлекчелек продуктлары җитештерү һәм хәзерләүне арттырганнары өчен, «Чишмә» колхозы кабат Мактау грамотасы алган. Димәк, музей шүрлекләрендә тагын бер кыйммәтле документ артты». Бу музейның республикадагы башка музейлардан нинди аермасы бар соң?

...Ясәви Хәсәенов 1948 елда, бу колхозга председатель булып килгәч, авылны йө-

реп чыга да, фотограф чакыртып, авыл күренешләрен рәсемгә төшерткән: кыйшык йортлар, җимерелгән абзарлар, авышкан читәннәр, ябык, сөяккә калган кәҗәләр, ишегалдындагы байлык — өч-дүрт тавык, йорт эчләрендә тузган какшау сәкеләр, ямаулы түшәк-ястык. «Чишмә» колхозы сугыштан соңгы елларда әнә шундый булган. Музейда, димәк, мамонт тешләре, элекке эш кораллары, чабагач-табагач кына түгел, әнә шундый истәлекләр дә бар. Мәктәп программасы буенча һәр уку елында аерым классларга СССР тарихы буенча музейда дүртәр сәгать дәрес бирелә. Дәресне музей директоры пенсионер укытучы Сафа Гарипов алып бара. Музейның әдәбият һәм сәнгать бүлегендә бу колхоз тарихы белән генә чикләнмичә, бөтен Актаныш районы тарихын бирергә тырышканнар. Актаныш төбәгеннән республикада танылган ничә галим, язучы, артист, журналист чыккан, кайсы авылда туган — болар турында тулы мәгълүматлар бар. «Батырлык» бүлеге дә таң калырлык. Актаныш туфрагында туып-үскән алты кешегә Советлар Союзы Герое исеме бирелгән икән.

Председатель колхозчыларның йортларын салганда катгый күрсәтмә биргән: каенусактан йорт салмаска! Техника, транспорт, ссуда белән бары тик нарат, чыршы бүрәнәсе әзерләүчеләргә генә ярдәм итәргә! Һәм авыл танымаслык булып үзгәргән. Шуңа күрә, музейга кергән колхозчылар, 1948 елгы йортларның рәсеменә карап, гаештомаша кылып тынсыз торалар: «Безме бу? Безме?..»

Музейның бер бүлеге колхозның кадрлар әзерләү системасын чагылдыра. Бу — үзенә күрә бер социологик лаборатория. Урта мәктәп кайсы елны күпме кадр биргән, шулардан күпмесе СПТУда белем алып, колхозга кайткан, күпме кеше шәһәргә киткән, кадрлар әзерләүнең перспективалары ничек?..

«Искра»ның беренче санынннан башланып киткән биш бүлмәле колхоз музее — җанлы организм кебек яшь, матур тормыш, рухи байлык өчен көрәшә, хезмәт итә. Музейдан чыкканда мин председательнең моңа никадәр әһәмият бирүенең мәгънәсен аңладым.

## Сөн буенда тын алан

Сөн елгасының башкорт ягындагы тау битләре гаҗәеп куаклар, төрле яшьтәге имәннәр, каеннар белән капланган. Балан, чия, кура, тагын әллә ниләр, әллә ниләр. Кояшка чумган тын аланда — «Чишмә» колхозының умарталыгы. Йөз егерме баш умарта.

Умарта асрау, бал җитештерүнең нәрсә икәнен еракта калган балачак буенча белә идем, әмма мондагы тәэсирләрем әйтеп-сөйләп бетергесез булды. Монда үз эшен фанатикларча ярата торган Хәниф Шәрипов эшли: ярдәмчесе — хатыны Флүдә Шәрипова. Тагын бер ярдәмчеләре — уллары. Узган ел җәе — бал алу өчен бик уңайдан исәпләнмәгән. Ел яңгырлы, кортлар, бал җыясы урынга, еш кына өйдә ызгыш-талаш чыгарганнар (эш булмаган җирдә гел шулай бит ул!), гел ял әвергәннәр. Шулай да, технологиянең дөрес кысаларга куелуы аркасында, һәр умартадан 22 килодан артык товарлыклы бал алынган (1982 елгы җәйдә — 41 кг). Хәниф белән Флүдә дәүләткә бал сату планы буенча инде 13-нче бишьеллыкка чыкканнар! Алар дәүләткә өч ел эчендә 41 центнер бал сатканнар! Чәчәкләрдән миллиграммлап җыелган 41 центнер шифа! Хәниф Шәрипов һәм Флүдә апасе дә — коммунистик хезмәт ударниклары, менә өч елдан бирле инде Хәниф «Беренче класслы умартачы» исемен йөртә. 1981 елгы уңышлары өчен СССР Бөтенсоюз халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенең бронза медале белән бүләкләнгән. 1983 елгы җәйдә Актаныш районы колхоз-совхозларның бөтен умартачылары Сөн буендагы бу аланга җыелып семинар уздырганнар, тәҗрибә уртаклашканнар.

Мин ботак чаптым, Хәниф ут җайлап җибәрде. Транзистор өстәлдә, өстәл — агач яфраклары ышыгында, без чәй кайнаттык. Аш инде пешкән иде.

— Ничек умартачы булып киттең? Нәселдәнме?

— Юк, умартачы булырмын дип башыма да китергәнем юк иде. Туйдан башланды. Флүдә ягыннан килгән туганнар туйга бүләк итеп бер оя умарта бирделәр. Карамый хәлең юк.

— Шуннан?

— Шуннан, бер көнне Хәсәенов абый чакырта. Килдем, кабинетына кердем. Сүз башланды. «Син умарта асрыйсың икән»,— ди Хәсәенов абый, миңа карамыйча гына.

Мин куркып калдым, аклана башладым. «Асраем, ну дә ләкин төп эшемә комачау итмәй ул»,— дим. Хөсәенов абый елмайды: «Әйдә, без сине укырга җибәрик әле, энекәш»,— диде.

Хәзер бал кортларыннан башка яши алмаем. Кышларын йөрмәсәң дә була, йөрәк түзмәй. Малай белән дә килем. Агач асларында бозау тикле кыр кәҗәләре көтүе ята. Мине күргәч сикерә-сикерә качалар. Умарталарны тыңлаем. Аларда бит кышын да тормыш, көрәш бара.

— Ә нинди көрәш?

— Мәсәлән, күселәр, тычканнар.— Ул аш өстәле янындагы эскәмиядә күзләрен кысып, суфиланып утырган ике песине башларыннан сыйпады.

Тавык ашы да, сөтле чәебез дә инде суына төшкән иде, без баланлы әрәмәлекләрне урап килергә булдык. Хәниф сөйли:

— Күсе-тычканнарны менә шулар хәл итеп бара инде, әмма песиләрне кышын ничек монда тотасың? Исән калган тычкан халкы, ризык эзләп, умарта эченә керә.

— Кортлар ничек каршы ала соң ул «кунакларны?»

— Кортлар-кортларча. Чагалар җыелышып, «нарушитель» үлә. «Диверсант»ның гәүдәсен шифалы җилем — прополис белән төрәләр. Кортлар кетә: март-апрель аенда аларның хәлен Хәниф абый белән Флүдә апай беләчәкләр, һәм шунда мәңге ятса да бозылмаячак бу үләксәне алып атачаклар. Ләкин башкасы куркыныч: кортларның вак дошманнары бар. Корт бете. Умарта кортының корсагына кадала. 1977 елдан бирле Актаныш зонасындагы умарта кортларына әнә шул паразитлар зур зыян сала башлаган. Ничек көрәшергә?

Хәниф — фәнгә таяна. Ул алан кырыендагы бер умартаны ача һәм рамнар арасыннан вазелин сөрткән металл поднос ала. Өсте — мыжгыган бөҗәк. Энә очы кадәре генә, төсе кызгылт, күп аяклы.

— Монысы — механик юл. Электр миче-термокамера файдалырак. Һәр рамны мичкә тыгып алабыз, 38 градуска кадәр җылытабыз. Умарта корты чыдый, теге паразитлар коела. Димәк, 120 баш умартадагы барлык рамнарны шулай эшкәртеп чыгасы бар.

Җиңел машина гудогына сискәнеп без умартачы өе янына киләбез. Аш өстәлендәге транзистордан җырчының «Әнкәй безне Сөннән алып кайткан» дигән моңы коела, мактаулы песиләрнең өлкәнрәге каен ботагы астындагы өстәлгә менеп мин ашап бетермәгән тавык ботын тәлинкәдән алып бик тә тәмләп кимереп утыра иде, без килгәч тә качмады, өстәлдән төшмәде.

Гудок бирүче — председатель Хөсәенов икән. Мин хәтерне эшкә җиктем. Председатель нинди күрсәтмәләр бирер, нәрсә әйтер?

— Карале, Хәниф, синең фацелияң урылмаган, сугылмаган бит?— диде ул күрешкән арада.

— Бәй, комбайннар бодайдан бушасын инде, әйтелгән, сөйләшенгән.

— Я, алай булса, ярый. Кая, сараеңны ач әле. Егерме минуттан уятырсың. Башкорт ягындагы бодай басуыннан кайтып килеш...

Хәниф белән без тагын егерме минут умарталар арасында йөрдек. Күрсәтелгән вакытта Хәниф председательне уятты, мин кызганып уйлап куйдым: Хөсәенов һәр көн иртән дүрттә тора, бер стакан чәй эчеп, эшкә китә, иртәнге ашны сәгать унда гына ашый. Аның сиксәнне узган әнисе Акъәби өчен иң изге сәгать әнә шул — иртәнге ун. Тәүлек буе аяк өсте йөрерлек итеп, шәп, ләззәтле итеп ашатып куя ул председательне.

Председатель сарайдан чыкты, күк йөзендәге менә күмеләм, менә болытка капланам дип кешеләрне әсәртеп торган моңлы кояшка карады һәм умарта янына килеп чалбар балагын сызганды.

— Хәниф, чактыр әле бер-ике тапкыр, аякларым бик сызлый,— диде.— Элек чактырганыңның шифасы унбишләпкә җиткән иде...

## Укырга вакыт юк...

Хөсәенов мине башкорт ягындагы бодай басуына алып китте. Иксез-чиксез бодай диңгезе. Инде ава, ята башлаган. Көтеп алынган аяз көннәрдә бөтен Актаныш, Мөслим, күрше Башкортстанның Илеш районы алтын нурга коена, кәефләр шәп. Имән

урманы буенда комбайнчылар, шоферлар — төшке ялда, ашап яталар. Яталар, дим, чөнки өстәл-урындык юк, һәркем учак өстендәге казаннан үзе ашый алганча — аш, ит сала да, имән төбенә барып ята. Һәр имән төбендә — бер егет. Ятып сөяк кимерәләр, аннан күпереп пешкән күмәч белән чәй эчәләр. Мин дә күмәч алам... «Кайсы пекарнядан бу?» — дип сорыйм, үзем туган Казан арты гадәтенчә. Барысы да көлә.

— Бәй, безнең хатыннар күмәчне үзләре сала,— ди имән төбеннән берәү. Хәсәенов аңлата:

— Безнең колхозчы хатыннар арасында ярыш бара,— ди.— Ирләрнең дә абруе шуның белән билгеләнә: кем хатыны салган икмәк тәмлерәк? Кайбер гаиләләр турында болай әйтеп куялар: ничек яши икән болар — хатыны салган ипи кибет ипие төсле бит!

— Китап укыйсызмы?— ди Хәсәенов ике савыт белән аш алып килешли. Без дә бер имән төбен сайлыйбыз.— Менә сезгә бер язучы алып килдем.

Ит ашап, җелек суырып яткан бер кара егет озак уйлап тормады. Әйтте:

— Юк. Укымыйбыз. Вакыт юк.

— Син инде бер шагыйрьне дә шулай рәнҗетеп җибәрдең.

— Бәй, нигә рәнҗетергә? Мин бит әйттем: ядасың, ядасың, бер юньле шигырең юк, дидем. Бу абыйны да белмәйбед...

— Ну бит, кышын укыйсың бит инде...

— Кыш көне булса, таныйм. Бу — «Торналар төшкән җирдә» дигән китапны язган абый. Ну инде, ул кышка кала.

Икенче бер «имән төбе».

— Ядучы абый барында бодайны бетерсәк, «ахыры» булырмы?

Хәсәенов, тәҗрибәле кеше, көлде:

— Борчылмагыз, эшне бетерегез генә. Ахырын оештырырбыз.

Бернинди командасыз берәм-берәм тордылар да комбайннар, машиналар янына киттеләр. Сөн аръягындагы бодай диңгезе кояшка коена иде...

## Антонида Пугачева

Мин Алла Пугачеваның җырлавын яратам. Ул җырларда — тормыш, гаделлеккә омтылыш, мәхәббәт... «Миллион, миллион, миллион алых роз....», «Маэстро» кебек җырлар, сәнгать әсәре буларак, минем рухи дөньямны баеталар. Карале, дөньяда тагын бер Пугачева бар бит! Актаныш районының һич тә көтелмәгән почмагына Михайловка дигән рус авылы урнашкан. Су тулы бер елганың ике ярына — ике урам булып. Председатель үзенең шәхси хуҗалыгын шунда корган. Урам уртасында су, яр буе читәннәр, таллар белән ныгытылган, елга тулы үрдәк, каз. Инде дә йоклатмыйлар кешене! Яктылык бәлендеме, үрдәкләр бытылдый башлый. Елга аркылы мәһабәт озын басмалар, әйтерсең ике дәүләт чиген узасың. Тегә, икенче Пугачева, шул басма төбендә генә яши. Килеп төшкән көнне үк Хәсәенов миңа:

— Антониданың фермасын карап чык! Дуңгыз балалары чиста, линолеумга гына басып йөриләр. Бер үзе мең баш дуңгыз карый,— дигән иде.

Антонида мин тукталган Михайловка авылында миңа күрше булып чыкты. Хәсәенов сөйләве буенча мин инде белә идем. А. Пугачева өченче, икенче дәрәҗәдәге Хезмәт Даны орденнары, Бөтенсоюз халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенең өч — алтын, бер көмеш медале белән бүләкләнгән. Оныклары булган бу яшь, көләч хатын — сигезенче, тугызынчы, унынчы бишьеллыклар ярышында җиңүче. 1982 елда Антонидага «Москвич» бүләк иткәннәр. Ярдәмчесе — фронтовик Нәҗми Исламов, сугышта өченче дәрәҗә «Дан» ордены алган, ракета частенда Берлингача барып, җиңү яулаган кеше. «Чишмә» колхозы ел саен дәүләткә тапшыра торган 4—4,5 мең центнер итнең яртысыннан күбрәген безнең Антонида Пугачева озата. Менә сиңа — «Миллион, миллион, миллион алых роз!»...

Антонида колхоз председателенең баскыч төбенә килде.

— Кило, кило ярым бал кирәк иде, авыру бар өйдә,— диде.

Председатель сәгать унга Акъәби әзерләгән иртәнге ашка кайткан иде.

— Я инде, Антонида,— диде ул ишек алдындагы юынгычта кул чайкап яткан җир-

дән,— син дә таптың йомыш. Бар, бухгалтерга әйт. Күпме кирәк, шулай язып бирсен. Таптың гозер. Әйдә, чәйгә кер!..

Антонида, сентябрьнең исәпле кояшын бөтен йөзенә сеңдергән көләч хатын, Акъәби белән исәнләште, ике буынның ике хатыны ни турындадыр гәпләшеп алдылар, бер-беренә ихтирам, күршелек хисләренә чик-чама юк иде...

## Татар белән башкорт арасы...

«Чишмә» колхозының чикләре, Сөннең аргы ягына чыгып, башкорт җиренә барып тоташа. Мин гомер буе, ике республика арасындагы чик халык тормышына ничек тәэсир итә икән, дип кызыксынып йөргән идем, инде аңладым: «Чишмә»гә бер өзлексез башкорт ягы колхозларыннан йомыш белән чыгып торалар. «Чишмә» үзе дә шулай икән: Актанышка, Казанга барып йөргәнче, колхоз өчен кайбер кирәк-яракны башкорт ягыннан гына юнәтә. Бу колхозлар, вакыт режимы буенча, ике сәгатькә аерылсалар да, бер җан кебек, яшиләр икән. «Чишмә»гә кымыз сорап та киләләр: кемгәдер врач кушкан, кемгәдер кунак килгән — кымыз кирәк. Ә «Чишмә»дә кымызны бик белеп ясыйлар. Мастер Гыйлай Гыймаев бу сирәк һөнәргә махсус курсларда өйрәнеп кайткан. Сөн буендагы бу гаҗәеп хуҗалыкка кайвакыт 20—30 машина килеп туктый: Башкортстан колхозларыннан, Октябрьск шәһәреннән, КамАЗдан, Әлмәттән, Минзәләдән, хәтта Сарапулдан, Чайковскийдан...

...Сөн буеның яшь куаклар каплаган сөзәк иңкүлегеннән йомылып чабып ат көтүе кайта. Җир селкенә. Болар —«Чишмә» колхозы бияләре, савылырга кайталар. Бер читтә, яшь имәнлектә — Гыйлай цехы. Бер катлы ап-ак таш йорт ерактан ук күренеп тора. Эссе көнне моның эчендә салкынча, яз җиткәнче үк Сөн бозын кисеп цехның бер бүлмәсенә тутыралар, пычкы чүбе белән каплыйлар. Ә ул чүп арасында салкын бәс белән капланган шешәләр ята. Ихтыяҗ зур: «Чишмә» кымызын әллә кайлардан соратып алалар.

Кымыз — шушы тирә үләненнән аеруча шәп була, ди Хөсәенов. Гадәте — читтән килгән кунакны шул цехка алып бару, табигатьнең иң гүзәл бер урынында — аста Сөн буйлары, янында катнаш урман, икенче ягында бәрәкәтле Башкортстан җире — әнә шунда «Чишмә» колхозының кымыз цехы, шунда үз эшенә галимнәрчә, фанатикларча бирелгән Гыйлай һәм аның гаиләсе. Сөн аръягындагы тау буенда кеше өчен шифалы эчемлек әзерләнә. Ике республика читендәге «Чишмә» кымызы әнә шулай чикләрне бетергән, тугандаш халыкларның уртак ихтыяҗына әверелгән. Татар да, башкорт та моның сихәтен тарихи тәҗрибә буенча яхшы белә: кымыз — көч, куәт, кымызда — сихәт, кымызда — эшкә-хезмәткә дәрт...

## Алтын көшел янында

Хөсәенов белән урамнан үтәбез. Ул миңа быел гына башыннан кичергән зур вакыйганы сөйли. Моннан кырык ел элек каты сугыш вакытында аларның отделениесе бер сәгать эчендә кырылып беткән. Исән калган солдат Хөсәенов авыр яралы командирын, шинельгә салып, коточкыч салкын төн буе сөйрәгән. Ярчык умырып ташлаган эченнән кан китә икән командирның. Хөсәенов яраны гел кар белән туңдырган. Ничек итсә-иткән, ерак кыр госпиталенә тапшырган. Аңына килгән командирына әйткән:

— Син исән калдың, мин дә исән калсам, сугыштан соң мине эзләп тап,— дигән.— Мин,— дигән,— Ясәви Хөсәенов булам, Татарстаннан.

Сугыш беткәч, командир еллар буе солдатны эзләгән. Әмма нәтиҗәсез, чөнки Ясәвинең исеме Әхмәтясәви икән. Инде менә быел — 1983 елда табышканнар. Дәүләкәндә күрешкәннәр, елашканнар. Бу очрашуны күрүче журналист Мөдәррис Мостафин газетада зур мәкалә язып чыкты. Мин күкрәкләре орден-медаль тулы ике ветеранның бергә төшкән рәсемнәрен генә күрдем. Бер кадр йөрәкне тетрәтте: мәһабәт гәүдәле 59 яшьлек Хөсәенов белән карсак кына 70 яшьлек Солтанаев Шәйдулла кочаклашканнар да елыйлар...

Амбарга таба барабыз икән. Юлга бодай сибелгән. Башта бөртекләр генә чәчелгән кебек иде, бераздан юл яктыра башлады. Амбарга якынлашкан саен яктылык

арта. Председатель ничек карый моңа? Бу бит — югалту. Председатель дерелди башлый инде хәзер, дип уйлыйм. Сораулы караш.

— Ну, казлар бетә икән инде бүген,— ди ул атлау җаена.— Казлар тиләрә инде бүген. Юл өстендә чиста бодай булганда аларның машинага реакцияләре бетә. Бу шофер — әлбәттә, исерек.

Күпмедер баргач күрәбез: юл кырыенда тәкә кадәр ике ала каз ята. Каурыйлары таралган, канлы мамыклар. Ә бодай катламы һаман калыная. Председатель идарәгә китте, мин — ындыр табагына. Кояш астында алтын көшел, суырткычлар, конвейер ленталары гүелди, березлексез йөк машиналары кайтып тора, алтын көшел өстендә кояш уйный. Үземнән бик азга гына өлкән булган өч хатынга, «сеңелкәшләр», дип, сәлам бирәм.

— Нинди «сеңелкәш» булаек бед седгә, бед инде пенсионерлар,— ди берсе көләч елмаеп.

— Өчегез дәме?

— Бәй, өчебез дә булмай! Инде бедгә ничә яшь?

— Бригадир ялындымыни? Сезнең бит чыкмаска да хакыгыз бар?

Сизеп торам, соравым бик урынсыз. Аңлыйм: журналистлык сәләте юк, тәҗрибә юк. Шундый тозсыз сорау бирәләрме инде?

— Бәй, ничек инде шушындай кояшлы көнне өйдә ятасың?

Икенчесе кушылды:

— Эшләү бер нәрсә түгел. Сәламәт булганда... Тик менә кайгыбыд бик дур.

— Нәрсә булды, апа?— дим мин ясалма «сеңел»дән чынбарлыкка күчеп. Өч хатын өчесе бергә сөйләп китте, хатын-кыз гына булдыра ала торган бер эш инде ул, монысына мин ияләнгән.

— Нәрсә дип... Менә Хәсәенов абыйга киләсе елга алтмыш тула. Пенсиягә китсә, без нишләйбед? Бед бит шуңа хөрмәт йөденнән генә чыгабыд эшкә. Калхудны шул гына аякка бастырды бит! Бөтен председательләргә председатель бит! Райкомда да яраталар бит аны, бед генә түгел. Гел халык өчен яшәй бит, үден кайгыртмай бит!

Мондый сүзләрдән минем күңел тулды. Кунарга мин Михайловка авылына, татары рәхәтләнеп — урысча, урысы иркенләп татарча сөйләшеп яши торган авылга, председатель йортына кайттым. Хәсәеновның йортына урамнан керү өчен дүрт урында дүрт капка бар — тәүлек буе монда кайсы колхозчы гына, кайсы район, республика кешеләре генә керми.

Иртән верандада тыңлап ятам: сәгать дүрт, Хәсәенов торды, авыр-авыр атлап йөрде, чынаяк тавышы ишетелде, бераздан машина газ бирде. Аннан соң Акъәби янына березлексез кеше килә башлый. Берәү, аяга барышлый, саз итекләре сорап алды, башкорт ягыннан чыккан бер председатель Акъәби белән ниндидер торбалар турында сөйләште — шулай унга кадәр.

Сәгать унда, чәй янында төп мәсьәләгә күчәм:

— Кичә бодай коеп кайткан шоферның кем икәнен ачыкладыгызмы?

— Ә-ә, белдек без аны. Читтән килгән автоколонна шоферы икән, исерек булган, үз җинаятен үзе аңлап, качкан. Казларны да шул таптаткан.

— Ә күпме бодай югалткан?

— Анысын да белдек. Бункер белән амбар арасында талон системасы бар бит. Бер генә центнер түгел...

— Аңа нинди җәза инде?

Бу сорау белән мин ашыктым кебек. Хәсәенов зур зәңгәр күзләреннән акыллылык та, шаянлык та чәчеп елмайды:

— Егетнең үзеннән тора инде. Карарбыз. Яшьләрнең төрлесе бар. Моны бит әле мин белмим. Әгәр бүген кичкә хәтле идарәгә килсә, гафу үтенсә, гаебен таныса, яшь егетне нигә җәзаларга? Аның бит әле яшисе, тормыш корасы бар. Гафу үтенгән кешедә өмет була. Инде килми икән — качып калмакчы икән — закон бар. Карарбыз. Утыз биш ел председатель булып эшләү дәверемдә мондый кешеләрне күп күрдем инде мин. Әле дә хәтеремдә: беренче елларым иде. Бер абзый зур хата ясады. Әллә нинди судлар, прокурорлар, милицияләр, судьялар турында уйлап, тегене идарәгә чакырттым. Өлкән кеше иде, сугыш узган, башын иеп керде дә идарәгә, болай диде:

— Иптәш Хөсәенов, гафу итегез, теге гаебем ходай ушны алган чакка туры килде... Адәм баласы хатадан хали түгел, дигәннәр борынгылар...

## Байлыкның чиге юк

«Чишмә» колхозы 1983 елда дәүләткә 44 мең центнер ашлык 4000 центнер ит, 15800 центнер сөт, 40 центнер йон сатарга планлаштырган. План үтәлгән. Арттырып үтәлгән тармаклары да бар. Бер колхоз, нибары бер колхоз дәүләт складларына, кибетләргә никадәр хәзинә озата! Ашаган белми, тураган белә, диләр. «Чишмә» колхозы «турачы». Ләкин «Чишмә»нең үзенә генә хас мәшәкате дә бар: бу колхоз ничә еллар инде республикабыз өчен (һәм тугандаш Башкортстан өчен) карп балыгы кебек затлы ризык җитештерә. Ел саен утыз тонна шундый сихәтле азык саталар «Чишмә»леләр күрше-тирәгә. Әлмәт районының инде ташка тамга салган, һәр көзне биш тонна карп сорыйлар алар. Центнердан алып тоннага кадәр сораучылар бар. Әмма әлегә бодай сугу, чөгендер алу бара, халык контроле комитеты председателе — ындыр табагында, аннан башка шлюзларны ачтым юк.

Татарстан табигатенең иң шигъри, бай урыны кайда? Бер дә шиксез әйтергә мөмкин — «Чишмә» колхозының күлләре буенда. Артык катлаулы булмаган дренаж системалары, дамбалар, торбалар, күл артыннан — күл. Тирәне бар, сае бар. Меңнәрчә гектарга җәелгән Сөн буе, куаклыклар, сазлыклар, әрәмәлекләр. Монда аерым микроклимат, микрофлора, фауна. Сөн аръягында — шәмәхә, сары мәтрүшкәләр аланы, балан куаклары, кыргый чияләр. Күлләр арасында хикмәтле әрәмәлекләр — анда балык аратучы челәннәр, кыр үрдәкләре, яр буенда елтыр ондатралар. Вакыт-вакыт монда торналар, аккошлар төшә, берәр ай яшәп тә алалар икән. Челәннәр гаҗәп! Атлы казак диярсең — пар-пар булып күлнең сай җиренә килеп басалар да, «кечкә аш», «иртәнге аш» «мәҗлесен» уздыралар. Инде балык үстерү осталары Әмир Галимов белән Дәниф Мотаваловлар төнлә тугайда учак та ягып җибәрсәләр, дөнья әкияткә әйләнә. Ул утка сентябрьнең өлгергән әремен сындыргалап салсаң, шул вакытта Сөн аръягыннан — башкорт ягыннан зур кызыл табак булып ай да күтәрелсә — күлләр дөньясында сихри тормыш башлана.

Төн җылы. Сентябрьдә сирәк булучан җылы һава бөҗәкләрне кабат терелткән, күл өстендә чебен-черки уйный. Моны күреп булмый, әмма күлләр өсте «ду» килә. Сарык тәкәсе кадәр карплар фосфорлы күзләре белән без күрмәгәннәрне күрә-күрә йөзәләр. Әле анда, әле монда, күл өстенә авыр металл болванкалар ташлагандай чупырдау тавышы ишетелә, болар икән — су өстендәге чебенгә ауга чыккан саллы карплар. Су коенганда каршыңа туры килсә, бәреп егар төсле...

Председатель белән авылга кайтабыз. Авыл урамы су эчендә. Берничә генә көнгә чыккан кояш машина эзләрендәге суларны, әлбәттә, киптереп бетерә алмаган. Урамны иңләп бер комбайн туктаган, алгы корылмалары кара балчыклы юл йомшагына сеңгән.

Хөсәенов машинасын туктатты. Мин бу вакыйгага аның реакциясен күзәтәм. Урам уртасында комбайн батып калу — нәрсә инде?

— Бу кайгылы һәм шатлыклы хәл,— дип аңлатты Хөсәенов.— Кайгылы шунысы: мин машина белән үз авылыма кайта алмыйм, бүтән юл юк. Шатлыклысы шул — теге башкорт ягындагы дүрт йөз гектарны тәки бетергәннәр болар. Әйткәннәр ие бит!

...Таң ата, учаклар инде сүнгән. Иксез-чиксез әрәмәләр арасыннан җиңел генә, кинәт теге кошлар күче күтәрелә, болар — «Чишмә» колхозының игелекле җирләрендә үскән кыр үрдәкләре. Кояш чыкканда, елга аръягында электр машинасы тавышы ишетелә, әйләнә-тирә авыллар белеп тора: Гыйлай бия сава. Сәгать алтыларда «Чишмә»нең бәрәкәтле җирендә тракторлар, йөк машиналары хәрәкәткә килә. Колхозчылар безгә ит, сөт, икмәк, йон, май, бал, балык җитештерер өчен эшкә тотына.

Бу вакытта председатель инде беraз арыган була һәм, бөтен объектларны кәрап чыгып, иртәнге унга ашарга өенә кайта...

Агыйделнең бу ягында әнә шундый хәлләр.



# ГЫЙЛЕМ — НУРДЫР...

Быелның август аенда күренекле татар шагыйре Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгариның тууына 230 ел тулды. Ул татар әдәбияты тарихында тирән эз калдырган шәхесләрнең берсе.

Габдерәхим Утыз Имәни (тулы исеме — Габдерәхим бине Госман бине Сәрмәки бине Кырыйм Утыз Имәни әл-Болгари) 1754 елда Татарстанның хәзерге Чирмешән районының Яңа Кади (элекке исеме — Утыз Имән) авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Шагыйрь үзенең әдәби псевдонимы итеп туган авылы исемен алган. Аның әтисе, Госман бине Сәрмәки, хәзерге Лениногорск районы Тимәш авылы кешесе була. Габдерәхимнең әнисе, Утыз Имән авылында туып үскән кыз[1], Тимәш авылына Госманга кияүгә чыккан була. Габдерәхим туганчы ук әтисе үлеп китә. Ярдәмчесез калган әнисе туган авылы Утыз Имәнигә кайткан. Һәм шунда, бабасы йортында, Габдерәхим дөньяга килгән. Балага 2—3 яшьләр чамасы булганда, әнисе дә үлеп киткән. Булачак шагыйрь туган тиешле җиңгәсе кулында фәкыйрьлектә үскән.

Укырга, белем алырга омтылган Габдерәхим бик яшьли үз авылларындагы Вилдан мулла мәдрәсәсенә йөри башлый. Зирәклеге, үткен зиһенлелеге белән ул башкалар арасында «укымый белә торган шәкерт» дип танылган.

Вилдан мулла мәдрәсәсеннән соң Габдерәхим берничә ел буе күрше-тирә авылларга барып укыган. Аннан соң шул чорда атаклы булган Оренбург Каргалысында икенче мәчет каршындагы мәдрәсәдә, Вәлид бине Мөхәммәд әл-Әминнән белем ала.

Оренбург Каргалысында уку гына канәгатьләндерми башлагач, ул 1788 елда, гаиләсен алып, Урта Азия шәһәрләренә гыйлем эстәргә чыгып китә.

Башта ул шул чакта зур гыйлем үзәге булып саналган Бохара шәһәренә килә. Анда берничә ел яши, исеме еракларга таралган мәдрәсәләрдә белем ала, күренекле укымышлылар белән аралаша. Бераздан үзе дә мәдрәсәдә укыта башлый.

Бохарадан соң Габдерәхим Акча, Түфи, Сәмәрканд, Мәзаре Шаһимәрдән шәһәрләрендә яши, андагы гыйлем ияләре белән аралаша, мәдрәсәләрдә уку-укыту эшләре белән шөгыльләнә. 1796 елда хәзерге Әфганстан территориясенә чыгып китә; Бәлех, Һират, Кабул шәһәрләрендә була. 1798 елда, Кавырмач дигән урында хатыны Хәмидә үлгәч, ул балалары белән туган иленә кайтып китә.

Туган иленә кайткач, Габдерәхим туган авылы Утыз Имәнидә төпләнеп калырга тели, әмма аңа: «Синең атаң Тимәш кешесе иде, — дип, йорт салырга урын, җир

[1] Моңа кадәр шагыйрьнең әнисенең исеме билгеле түгел иде әле. 1976 елгы археографик экспедиция вакытында шагыйрь яшәгән Куакбаш авылында (Лениногорск районы) 77 яшьлек пенсионер укытучы Гаян апа Хәкимова безгә Габдерәхимнең әнисе Гафифә исемле булганлыгын әйтте. «Сез аны каян беләсез?» дигән сорауга ул: «Гафифә әби турында мин яшь чагымда Габдерәхим хәзрәт кызының улы (Бәдигыльҗамалның улы — Ә. Ш.) Мөхәммәтфазыйл бине Котлыгбай бине Мирас бине Иманголдан күп тапкырлар ишеткәнем бар иде. Фазыйл бабай Гафифә әби турында бик күп хатирәләр сөйли иде дә, алары инде хәтеремдә калмаган», — дип җавап бирде.

бирмиләр. Шуннан соң ул үзенең ерак туганнары яшәгән күрше авылга — Кара Чишмәгә китә, анда бер ел яши. Ләкин анда да озак торырга рөхсәт итмиләр, һәм ул хәзерге Чистай районының Исләй авылына китә, анда бер ел чамасы мәдрәсәдә укыта. Аннан хәзерге Лениногорск районының Сарабиккол авылына күчә, өч ел буе мәдрәсәдә хәлфәлек итеп яши. Шуннан соң Куакбаш авылына (хәзерге Лениногорск районы) килә; авыл тарихында беренче мәдрәсә салдыра, шәкертләр укыта. Әнә шулай авылдан-авылга күчеп йөри торгач, ниһаять, әтисе туган Тимәш авылына килеп урнаша һәм үзенең соңгы көннәренә кадәр шунда яши, укыту белән шөгыльләнә.

Тимәштә аның кечкенә генә йорты, аз гына җире булган; хайван асрамаган, мал җыймаган. Картлык көннәренә кадәр иҗат эшен дәвам иттергән. Шагыйрь сиксән яшенә кадәр яшәп, 1834 елның апрель башында Тимәш авылында үлгән. Каберенә таш куелган, анда исеме һәм үлгән елы күрсәтелгән.

Утыз Имәнинең иҗат мирасы гаять зур һәм күпкырлы. Алтмыш елга якын сузылган иҗат дәверендә ул, бүгенге мәгълүматлар буенча, йөзгә якын (төгәлрәк әйткәндә — 99) исемдә хезмәт язып калдырган. Алар Утыз Имәнинең үз чорының олы шагыйре генә түгел, бәлки күпкырлы галиме дә булганлыгын күрсәтеп торалар. Шушы 99 исемдәге хезмәтнең бүгенге көндә барлыгы 67 сенең тексты табылган[1]. Әдип язган хезмәтләр арасында поэзия җәүһәрләре белән бергәттән, тел, философия, әхлак-хокук мәсьәләләре, экономика, медицина, астрономия һәм башка мәсьәләләргә кагылышлы фәнни хезмәтләр дә бар.

Утыз Имәни иҗатының үзәгендә аның поэзиясе тора: аның таланты тулысынча нәкъ менә поэзиядә ачылып китә һәм татар әдәбиятындагы урыны да нәкъ менә аның поэтик әсәрләре, аларның әһәмияте белән билгеләнә.

Утыз Имәни поэзиясе шактый катлаулы һәм каршылыклы. Бу каршылыклар, әлбәттә, беренче чиратта шагыйрь яшәгән чордагы иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең катлаулы һәм каршылыклы булуы белән бәйләнгән.

Билгеле булганча, Утыз Имәни бөтен Россияне дер селкеткән Е. И. Пугачев восстаниесеннән соңгы чорда, ягъни Россиядә феодализм, җәмгыятенең таркалу һәм аның эчендә капиталистик мөнәсәбәтләр үсү чорында яши. Шуның белән бәйле рәвештә дини идеологиянең җәмгыять тормышында моңа кадәр алып торган позицияләре әкрен-әкрен генә үзгәрә башлыйлар, һәм идеологиянең бер өлкәсе булган татар поэзиясендә дә моңа кадәр күрелмәгән дөньяви мотивлар туу өчен җирлек хәзерләү процессы башлана. Бу процесс Утыз Имәни иҗатында ачык чагылыш таба.

Әлбәттә, Утыз Имәни поэзиясе дә шул чорда татар җәмгыятендә хакимлек иткән ислам дине йогынтысыннан читтә кала алмады. Аның әсәрләре дини фикерләр тәэсирендә язылганнар. Ләкин шуның белән бергәттән, аның поэзиясе дини рамкалар эчендә генә бикләнеп калмады, бәлки үз чорының җәмгыять тормышына караган күп кенә актуаль мәсьәләләрне дә күтәрде һәм аларны үзенчә чишәргә, үзенчә хәл итәргә тырышты. Дини һәм дөньяви мотивлар аның поэзиясендә бер-берсе белән үзара бәйләнеп, бер җепкә үрелеп бирелделәр. Шунысы кызыклы, бу мотивлар аның поэзиясендә еш кына бер үк әсәр эчендә дә янәшә килергә, бер-берсе белән янәшә яшәргә дә мөмкин. Бу күренеш Утыз Имәни иҗатының үзенчәлеге булып тора һәм шуның белән бергәттән, аның поэзиясенең катлаулылыгын, каршылыклылыгын китереп чыгарды.

Утыз Имәни поэзиясенең үзәген зур күләмле әсәрләр — поэмалар тәшкил итә. Бүгенге мәгълүматлар буенча, ул барлыгы ун поэма иҗат иткән. Нәкъ менә шушы поэмаларда шагыйрь үз чорының җитлеккән мәсьәләләрен күтәреп чыга, аларда әдипнең иҗтимагый йөзе, актив позициясе һәм эшчәнлеге чагылыш таба.

Шагыйрь җәмгыятьнең гади бер члены булып яши. Ләкин җәмгыять тормышы аның идеалы белән туры килми. Аның карашынча, җәмгыятьтә начар, ялгыш, бозык фикерле кешеләр күбәеп киткән. Шагыйрь кешеләрнең мондый начар әхлаклы булуларының сәбәбен эзли. һәм аның сәбәбен Утыз Имәни барыннан да элек кешеләрнең надан, укымаган буларында дип аңлый. Шуңа күрә ул үз замандашларын

[1] Шушы 67 исемдәге хезмәтнең 21 е әле соңгы вакытта гына, ягъни 60—70 елларда шушы юлларның авторы тарафыннан табылды һәм фәнни кулланылышка кертелде.

барыннан да элек укырга, белемле булырга өндәп чыгыш ясый. Укырга, белем алырга өндәү — Утыз Имәни поэзиясенең буеннан-буена сузылып бара торган төп темасы, төп мотивы булып санала.

Шагыйрьнең идеалы — белемле, мәгърифәтле кеше, галим. Әмма ул «гыйлем» төшенчәсен каршылыклы аңлый. Бер яктан, ул гыйлемне тормышның нигезе, кешеләргә тормыш авырлыкларын җиңәргә, аның серләрен ачарга ярдәм итә торган гаять куәтле чара, корал итеп карый.

*Гыйльмә дырыш, гыйлемдер асһы хәят,*
*Гәйльмиләдүр кәшеф җөмлә мөшкилят,*

(Гыйлемгә тырыш, гыйлем тереклекнең (тормышның) нигезе ул, Гыйлем белән барлык авырлыклар ачыла (җиңелә), — ди ул, мәсәлән, «Әбйате төрки фи фазыйләте гыйлем» («Гыйлемнең өстенлеге турында төркичә бәетләр») исемле шигырендә.

«Тәнзиһ эл-әфкяр фи нәсаих эл-әхйар» («Фикерләрне пакьләндерә торган игелекле үгетләр») поэмасында автор гыйлемне дөньядагы барлык нәрсәдән дә өстен һәм көчле итеп тасвирлый, ягъни рационалист буларак чыгыш ясый. Аның рационализмының үзенчәлеге шунда: Утыз Имәни белемне тормыштагы байлык, алтын-көмеш белән дә, кешеләрнең йөз күркәмлекләре белән дә чагыштырып карый һәм гыйлемнең аларның барысыннан да өстен булуын исбат итә. Аның фикеренчә, алтын-көмеш тә, кешеләрнең матурлык-күркәмлекләре дә вакыт үтү белән, кулланган саен кимиләр, азаялар, шиңәләр, тоныкланалар, ә гыйлем исә вакыт үткән һәм кулланган саен арта, күбәя һәм ныгый гына бара. Шуңа күрә шагыйрь гыйлемне кешедән дошман да, угры да тартып ала алмаслык кыйммәтле хәзинә, кеше күңеленең нуры дип атый. Гыйлемнең өстенлеген күрсәтү өчен автор антитеза алымын куллана, ягъни гыйлемне аның капма-каршысы наданлык белән чагыштырып карый:

*Гыйлем нурдыр, нурлардур күңелләри,*
*Җәһел нардыр, яндырыр һәп диләләри*[1],

— ди ул.

«Гыйлем» төшенчәсенә дөньяви мәгънә салып, Утыз Имәни аны халыкның тормыш-көнкүреше белән бәйли. Аныңча, гыйлемнән башка бер кеше дә һөнәр ясый була алмый:

*Гыйльмә улмаянда, юк дорыр һөнәр...*

Гыйлеме булмаган кешене дәүләт хезмәтенә дә алмаска кирәк, ди автор. Аныңча, дәүләт хезмәтендә булган, җәмгыять белән идарә итүдә катнашкан кешеләр һәр яктан аңлы-белемле, мәгълүматлы булырга тиешләр:

*Кемнең кем улмаса даниш әләндә,*
*Аны куймак кирәкмәз мәнсабында.*
*Җәһаләт әһлигә мәнсаб ярашмаз,*
*Зәгыйфьләр көчлигә каршу торышмаз.*

*(Кемнең кем кулында белем булмаса,*
*Аны дәүләт хезмәтенә кую кирәкмәс (дәрәҗәле урынга).*
*Надан кешегә чин (дәрәҗә) ярамас,*
*Зәгыйфьләр көчлегә каршы тора алмас.)*

Күренә ки, шагыйрь биредә «гыйлем» төшенчәсенә барыннан да бигрәк дөньяви мәгънә сала. Әмма шуның белән бергә Утыз Имәни «гыйлем» төшенчәсен дини мәгънәдә дә куллана: «гыйлем белән дөнья да, ахирәт тә алынып; икесендә дә хөрмәт һәм дәүләт булыр», ди ул. Гыйлем-мәгърифәттә ул үзенең дини идеалларын да күрә, гыйлемне шул идеалларга ирешү юлында бер чара итеп саный. Җәмгыятьтәге барлык кешеләр дә дини өйрәтмәләрне үзләштерсәләр һәм шул өйрәтмәләрне үзләренең көндәлек тормышлары өчен җитәкче итеп куллансалар,— җәмгыять тормышы да савыгыр, гомуми бәхеткә ирешелер иде, дип исәпли. Бу фикерләр аның иҗатында шактый еш очрый.

Шагыйрьнең үз идеалында йөрткән галим турындагы фикерләре дә кызыклы һәм каршылыклы. Бер яктан, Утыз Имәни фикеренчә, галим булган кеше беренче чиратта үзенең байлыгы, тыныч һәм рәхәт яшәве турында кайгыртмыйча, башкалар турында уйларга, башкаларны укыту, белемле итү турында уйларга, халык бәхете өчен яшәргә тиеш. Икенче яктан, галим кеше дин юлын да ташламаска, ул юлда да баш-

[1] Гыйлем нур ул, күңелләр нурыдыр ул. Наданлык ут ул, яндырыр барлык күңелләрне.

каларга үрнәк булып торырга тиеш. Шундый кеше генә, шагыйрь фикеренчә, «галим» дигән исемгә лаек була һәм шундый галимнең генә «үзе үлсә дә, исеме саклана».

Утыз Имәни тормыштан, тирә-ягыннан үз идеалына туры килә торган галим кешеләрне эзли, әмма таба алмый. Менә шул вакытта ул игътибарын ислам дине дөньясына, аның тарихына юнәлтә һәм идеаль галимне шәригать өлкәсендә хезмәт күрсәтеп калдырган шәхесләр арасыннан таба.

Ә реаль тормышка, чынбарлыкка килгәндә исә, шагыйрь белгән, үзләрен «галим» дип йөрүче кешеләрнең күбесе яки бик надан, белемсез булып чыгалар, яки артык вак, җәмгыять һәм халык өчен бөтенләй кирәксез мәсьәләләр белән шөгыльләнәләр — бары үзләренең бай, тук, тыныч яшәүләре турында гына кайгырталар, ә гади халык, аны агарту, укыту турында уйлап та карамыйлар. Менә шуңа күрә шагыйрь иҗатына шул чордагы «галим-укымышлылардан», имам-шәехләрдән, дин әһелләреннән ризасызлык, аларны тәнкыйтьләү мотивы килеп керә дә. Бу тема аеруча аның «Гавариф эз-заман», «Төхфәт эл-гораба вә ләтаиф эл-газаэ» («Ят кешеләр бүләге һәм яшьлекнең йомшаклыгы») поэмаларында һәм «Бәет дәр-зәмми суфиян мә-замана» («Замана суфыйларын шелтәләү бәетләре») исемле шигерендә калку чагыла.

Җәмгыять тормышын төзек һәм камил иту өчен шәригать кануннарының тулысынча җавап биреп бетермәүләрен аңлагач, Утыз Имәни шуның белән бергә әлеге шәригать законнарының үзләрен беркадәр үзгәртергә, аларны реаль тормышка, объектив чынбарлыкка яраклаштырырга кирәк, дигән фикергә килә. Шагыйрь моны шулай уйлап кына калмый, ә бәлки шушы фикерләрен, беркемнән дә куркып тормыйча, кыю рәвештә әйтеп чыгарга үзендә көч тә, кыюлык та таба алган. Шагыйрь шул чорда ислам динендә урнашкан тәртипләрдән дә, башка галим-укымышлыларның өйрәтмәләреннән дә нык аерылып тора торган үз фикерләрен, үз юлын барлыкка китергән. Бу фикер юнәлеше халык арасында «Утыз Имәни мәсләге» исеме белән таралган.

Әйтергә кирәк, яңа мәсләк төзү татарларда бер Утыз Имәни исеме белән генә бәйләнмәгән. Үз чорындагы җәмгыять тормышының ихтыяҗларын нечкә тоя алган һәр зур укымышлы чын хакыйкатьне үзенчә аңлаган, тормышны яхшырту юлларын үзенчә күргән. Алар үз карашларын әйтү өчен төрле чаралар, төрле мөмкинлекләр эзләгәннәр. Менә шушы омтылыш аларның кайберләрен яңа мәсләк төзүгә алып килгән. Мәсәлән, Габденнасыйр Курсавиның да үзенә аерым мәсләге булган[1]. Алардан бераз соңрак яшәгән Ш. Мәрҗани да бу турыда: «Мин үземне һичкемнең фикер һәм мәзһәбенә иярергә мәҗбүр дип белмим»,— дип белдергән[2].

Ф. Энгельс, феодализмга хас булган сыйфатларны күрсәтеп, «Германиядә крестьяннар сугышы» исемле хезмәтендә болай дип язды: «Феодализмга каршы революцион оппозиция бөтен урта гасыр буенча яшәп килә. Ул оппозиция үз заманындагы шартларга карап, я мистика төсендә, яисә ачыктан-ачык ересь төсендә, яки коралль восстание төсендә чыгыш ясап килә[3].

Утыз Имәни һәм татар әдәбиятының кайбер башка вәкилләре өчен дә хас булган мәсләк төзү күренешен шул чорның алдынгы укымышлыларының үзләре яшәгән чор тәртипләре белән килешмәүләреннән килеп туган күренеш, яки аның үзенчәлекле бер чагылышы итеп карарга мөмкин.

«Утыз Имәни мәсләге»ндә, автор карашынча, шул чор татар җәмгыятенең җитлеккән, «көн кадагында торган» күп кенә мәсьәләләре күтәрелә. Шагыйрь аларны ислам дине өйрәтмәләре яктылыгында, шәригать законнары белән бәйләп хәл итә. Ул үзенең бу фикерләрен, нигездә, поэмаларында бәян итә.

Шагыйрь мәсләгендә күтәрелгән иң төп, иң изге мәсьәләләрнең берсе — аның үзеннән алда яшәгән укымышлыларның әйткән сүзләренә сукыр рәвештә иярергә теләмичә, үзенчә фикер йөртергә хокук, акыл һәм зиһенгә ирек таләп итүе. Бу — үз чорында ислам дөньясында зур бәхәс, шау-шу күтәргән мәсьәлә. Бу бәхәскә үз чорының күп кенә галимнәре, укымышлылары катнашкан. Бәхәскә катнашучылар капма-каршы ике лагерьга бүленгәннәр. Бер төрлеләре — безнең заманда инде иҗтиһад киселгән, ягъни шәригатьтә яңа фикерләр әйтү, әйтелгән фикерләргә карап

[1] Фәхретдинев Р. Асарь, 1 җилд, 3 җөзьэ, 126—130 битләр.
[2] Ибраһимов Г. Бөек остазымызның кайбер тәэлифләре.— Китапта: Шиһабетдин Мәрҗани. Мәкаләләр җыентыгы. Казан, 1958, 51 бит.
[3] Энгельс Ф. Германиядә крестьяннар сугышы. Казан, 1941, 42 бит.

нәтиҗәләр чыгару инде мөмкин түгел, бары тик элеккеге галимнәр әйткәннәрне тикшереп-нитеп тормыйча ятларга гына кирәк, дигәннәр. Ә икенчеләре исә исламның инде искерәп беткән, схоластик кагыйдәләре белән килешергә теләмәгәннәр, үзләренә дә фикер йөртергә хокук таләп иткәннәр, яңа фикерләр әйтергә омтылганнар. Утыз Имәни шул чорның иҗтимагый тормышына караган кайбер әһәмиятле фикерләр әйтә алган һәм ул фикерләрне тормышка ашыру юнәлешендә практик эш тә алып барган.

Шундый әһәмиятле фикерләрнең берсе — мәдрәсәләрдә тормыш өчен кирәкле фәннәр укыту. Билгеле булганча, ул чор мәдрәсәләрендә шәкертләргә күбрәк дини дисциплиналар һәм, беренче чиратта, ислам тарихы, гарәп теле, мантыйк (логика), идеалистик фәлсәфә һ. б. предметларны укытканнар. Гасырлар үтү белән җәмгыять тормышы алга киткән, үсеш-үзгәреш кичергән, ә ул фәннәр һаман шул формаль кее калганнар, аз гына да үзгәртелмәгәннәр, шуңа күрә халыкның тормыш-көнкүрешеннән тагын да ераклаша, читләшә төшкәннәр.

Һәр күренешкә үзенчә карарга өйрәнгән Габдерәхим мондый хәл белән килешеп тора алмаган. Ул яшьләрне уку йортларыннан тормышка яраксыз итеп чыгаруга протест белдергән. Мәсәлән, «Гавариф эз-заман» әсәрендә шагыйрь фәлсәфә, мантыйк һәм хикмәт гыйлемнәрен өйрәнүне үзенең замандашларында күрергә теләмәгән сыйфат, ягъни бидгать сыйфат итеп тасвирлый.

Шунысы игътибарга лаек, ул фәннәргә Габдерәхим нәкъ менә аларның мантыйк, фәлсәфә яки хикмәт фәне булганнары өчен түгел, бәлки аларның формаль һәм искергән булганнары өчен каршы чыга, нәкъ менә шул сәбәпле яшьләргә әлеге фәннәрне укытмау ягында тора. Шуның белән бергә шагыйрь ул фәннәр урынына фикъһе (ислам юриспруденциясе) һәм хәдис фәннәрен укытуны алга куя, чөнки бу фәннәр, аның карашынча, дөньяви тормышка, халыкның тормыш-көнкүрешенә күпмедер дәрәҗәдә якынрак торалар, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләргә тәртип урнаштырырга, тыныч һәм тату яшәргә ярдәм итәләр. Шагыйрьнең бу фикерендә үз чоры өчен билгеле бер дәрәҗәдә хаклык та булган, чөнки фикъһе фәне, башлангыч чорында ук дөньяви характердагы фән буларак барлыкка килгән. Бу турыда Швейцария галиме Адам Мец болай дип күрсәтә: «... уже в следующем веке[1] аль-Газали, родоначальник позднейшего мусульманского правоверия, квалифицирует правоведение[2] как нечто светское, чуждое богословию»[3].

Утыз Имәни иҗатында үзәк урыннарның берсен алып торучы проблема — әхлак мәсьәләсе. Шагыйрь кешеләрнең начар әхлаклы булуларын гыйлем-мәгърифәт белән китереп бәйли. Аның фикеренчә, бары тик укыган, белемле кеше генә яхшы әхлаклы була ала һәм, киресенчә, надан кеше үзенең наданлыгы аркасында әхлаксыз була. Шуңа бәйләп, шагыйрь кешеләрне укырга, белем алырга чакыра. Шагыйрьнең мәгърифәткә чакырган фикерләре бу яссылыкта тагын да әһәмиятлерәк, тагын да көчлерәк яңгыраш табалар, шуның белән Утыз Имәни рационализмының тагын бер үзенчәлеген тәшкил итәләр.

Габдерәхим реаль тормышта бик гаҗәп күренешләр белән очраша: имам-мөдәррис булган кешеләр, яшь буынга аң-белем бирүчеләр еш кына үзләре үк иң элементар әхлак кагыйдәләрен бозалар, үзләре әхлаксызлык күрсәтәләр. Ул гына да түгел, әерым очракларда шул кешеләр үзләре алып торган югары урыннарын начар ниятләрдә файдаланалар. Әлбәттә, шагыйрь мондый күренеш белән килешеп тора алмый. «Төхфәт эл-гораба вә ләтаиф эл-газаз» («Ят кешеләр бүләге һәм яшьлекнең йомшаклыгы») поэмасында автор Бохара мәдрәсәләрендә тамыр җәйгән тискәре күренешләрне көчле нәфрәт белән тәнкыйтьләп чыга. Бу әсәр XVIII гасыр ахырындагы Бохарадагы реаль тормыш картиналарын тасвирлавы һәм җәмгыятьтәге бозык күренешләрне көчле сатира утына алуы белән әһәмиятле. «Төхфәт эл-гораба...» поэмасы нигезле рәвештә татар әдәбияты тарихында иң беренче сатирик поэмаларның берсе булып каралырга хаклы.

Дин әһелләрен сатирик тасвирлау шагыйрьнең башка әсәрләрендә дә урын ала. «Бәет дәр зәмми суфиян мә-замана» («Замана суфиларын шелтәләү шигыре») әсә-

[1] Биредә сүз XI гасыр турында бара.
[2] Сүз фикъһе фәне турында бара.
[3] Мец А. Мусульманский Ренессанс. М., 1966, 160 бит.

рендә, автор үзләрен «мин — суфи» дип йөрүчеләрнең комсыз булуларын, бөтен гомерләрен аштан-ашка йөреп уздыруларын сатирик планда тасвирлый.

*Сире сөфрә һәр сәбах дәм та бә шам,*
*Бәхрекяр, һәркяр хәвәрди тәгам,*

(һәркөн иртәдән кичкә кадәр аш өстәле янында: Диңгез кадәр азык ашарга осталар.) — ди ул алар турында.

Шунысы кызыклы, Утыз Имәни югары сыйныф вәкилләренә, гомумән, тискәре караштa булган, алар белән нинди дә булса мөнәсәбәтләргә керергә теләмәгән. Мәсәлән, «Мөнаҗат» шигырендә ул болай ди:

*Илаһи, әйләмә мохтаҗ*
*Шу дүрт адәм капусина*[1]
*Бери казый, бери вәли*[2],
*Бәри мөфти, бери солтан.*

Күренә ки, Габдерәхим үзе дин әһеле булуга да карамастан, үзеннән югарырак дәрәҗәдә булган казый һәм мөфтиләр белән алыш-бирешләргә керергә теләмәгән.

Үзенең иҗат йөзен характерлый торган иң төп поэмаларының берсе булган «Тәнзиһ эл-әфкяр фи нәсаих эл-әхйар» әсәрен дә Утыз Имәни әхлак мәсьәләләренә багышлаган. Бу поэмада автор, барыннан да элек, саф, чын, эчкерсез дуслык мәсьәләсен күтәрә: ул үзенең тирә-ягыннан шундый эчкерсез, ышанычлы дус булырлык кеше эзли, әмма таба алмый. Автор үзләрен дус дип санап йөрткән кешеләрнең дә икейөзле булуларыннан — бер төрле сөйләп, икенче төрле гамәл кылуларыннан зарлана.

*Әгәрчә сүзләремни тасдыйк әйләр,*
*Өнүгә барса, бидгать эшне әйләр,*

(Гәрчә сүзләремне раслап торса да, Өенә кайткач, бидгать эшне тотар,) — ди ул алар турында. Шагыйрь аларны бозык фикерле кешеләр, ягъни «бәд әндиш» дип атый, алар белән бергә яшәүнең үзе өчен каты газап икәнлеген белдерә.

Шушы ук поэмасында шагыйрь, әхлак мәсьәләләре белән бергәттән, гыйлем-мәгърифәт мәсьәләләренә дә туктала, шул турыда үзенең фикерләрен әйтеп китә. Поэма эчендә китерелгән «Хикәят бәр сәбиле тәмсил» («Чагыштыру өчен китерелгән хикәя»)дә автор үзенең рус телен дә белүе турында искәртеп үтә. Бу бик әһәмиятле деталь. Ул гына да түгел, Утыз Имәни үз замандашларын, таныш-белешләрен, якыннарын да русча өйрәнергә өндәгән. Утыз Имәни турындагы мәкаләсендә Каюм Насыйри болай дип яза: «Янә риваять кыйлалар, Габдерәхим хәзрәт әйтер икән: «Русиядә тереклек кыйлучы мөселманнарга кырык бер фарыз, — кырык беренчесе — урысча белмәк»,— дир икән»[3].

Димәк, шагыйрь шул чорда ук татар халкына рус телен белүнең никадәр кирәк, зарур икәнлеген тирән аңлаган һәм шул фикерне замандашларына шәригать кагыйдәләре формасына әверелдереп әйтеп биргән. Бу факт тагын бер тапкыр Утыз Имәнинең шәригать законнарын реаль чынбарлыкка, татар халкының тормыш-көнкүрешенә яраклаштырырга омтылуының бер дәлиле булып карала ала.

XVIII һәм XIX гасыр араларында Утыз Имәни тарафыннан әйтелгән бу сүзләр XX гасыр башында татар халык шагыйре Г. Тукайның:

*Рус беләң тормыш кичердек сайрашып,*
*Тел, әдәбият, гадәт вә әхлак алмашып...*
*Һич бетәрме тарихи бу бергәлек?—*
*Без туган бер җепкә бергә теркәлеп,—*

— дигән сүзләренә авазааш яңгырый, бу сүзләрнең дөреслеген тагын бер тапкыр раслап, куәтләп тора.

Утыз Имәни иҗатында үз чорының көн үзәгендә торган башка мәсьәләләр дә күтәрелә. Шундый темаларның берсе — хатын-кызга караш мәсьәләсе. Бу тема шагыйрьнең «Мәрсияи Хәмидә, зәүҗәте Габдерәхим Болгари» (Габдерәхим Болгари хатыны Хәмидә мәрсиясе) һәм «Мәрсияи Габденнасыйр вәләде Габдерәхим» (Габдерәхимнең улы Габденнасыйр мәрсиясе) исемле әсәрләрендә чагылыш таба. Аларның

[1] Капусина — капкасына.
[2] Вәли — губернатор, башлык, хуҗа.
[3] Насыйри К. Казан календаре, 1877 елга. Казан. 1876, 44 бит.

икесен дә автор сөекле хатыны Хәмидәнең үлеме тәэсирендә 1798 елда иҗат иткән. Билгеле булганча, ислам дине күп гасырлар буе хатын-кызга кимсетеп, бары җанлы курчак итеп кенә карап килде. Шундый бер вакытта Утыз Имәни, үзе дин әһеле булуга да карамастан, Хәмидәне бары яхшы сыйфатлары белән генә тасвирлады. Нәтиҗәдә укучы күз алдына тыйнак, уңган, акыллы, тугрылыклы, ягымлы, олы җанлы, гади һәм белемле бер татар хатыны образы килеп баса.

«Мәрсияи Габденнасыйр, вәләде Габдерәхим» әсәрен шагыйрь үзенең өлкән улы Габденнасыйр исеменнән язган. Бу шигырьдә автор Хәмидә образын тагын да тулыландыра төшә, аңа яңадан-яңа сыйфатлар өсти. Бирегә инде Хәмидә үз балаларын чиксез яратучы, алар турында даими кайгыртучанлык күрсәтеп торучы киң күңелле ана булып күз алдына килә.

*Кичәләрне йиге булгән*[1]*,*
*Минем өчен уягъ торган,*
*Кечеклектә сөтен биргән*
*Шәфикимдин җөда булдым*[2]*.*

Шунысы әһәмиятле, Хәмидә образы тормыштан алып язылган. Бу яктан ул XIX гасыр башы татар шагыйре Г. Кандалый тудырган хатын-кыз образларына барып тоташа. Әмма Хәмидә образы алдагырак чорга карый. Шуңа күрә аны XIX гасырга кадәрге татар әдәбиятында тормыштан алып сурәтләнгән татар хатын-кызларының иң әһәмиятлеләреннән берсе дип карарга мөмкин.

Габдерәхим яшәгән чорда халык арасында төрки-татар теленең байлыгына, шул телдә катлаулы мәсьәләләр турында язу мөмкинлегенә шикләнеп карау хөкем сөргән. Габдерәхим мондый фикерләр белән килешә алмаган, үз туган теле — төрки-татар телен яклаган, бик катлаулы мәсьәләләрне дә үз телендә аңлатып та, язып та була, дип исәпләгән. «Нәзмы Габдерәхим Болгари фи хакке Казыйзадә» шигырендә автор төрки-татар телен яклап чыга:

*Күреп, төрки имеш, дип санма йиңел,*
*Чалыш, сәгый ит, җәмигъ сүзләрен бел*[3]*.*
*Әгәр чәндике*[4] *төрки булса, и яр,*
*Гаҗәеп мөшкил улан йирләре вар.*

Шагыйрь поэзиясендә күтәрелгән, алда карап үтелгән темалар һәм мотивларның күбесе тарих аренасына Утыз Имәнидән соң аяк баскан татар мәгърифәтчеләренең карашлары белән аваздаш яңгырыйлар. Шуңа күрә Утыз Имәни татар әдәбияты тарихында үз иҗаты белән мәгърифәтчеләр туу өчен җирлек, нигез хәзерләгән шагыйрь булып карала ала.

Утыз Имәни китаплар күчереп язу эше белән дә шөгыльләнгән. Мәсәлән, ул фарсы поэзиясенең атаклы шагыйре Сәгъди Ширазиның мәшһүр «Гөлстан» поэмасын, Җәлалетдин Руминең зур күләмле атаклы «Мәснәви» әсәрен (барлыгы алты томнан, 26 мең 936 бәеттән тора) тулысынча үз кулы белән күчереп чыккан. Ул күчергән китаплар арасында Мөхәммәд әл-Газалиның «Ихйа эл-голүм» («Гыйлемнәрне тергезү»), төрек шагыйре Мөхәммәт Хафизның «Мирьат эл-әхлак» («Әхлак көзгесе»), Фәридетдин Гаттарның «Мәнзуман исламия» («Ислам турындагы шигырьләр») һәм башка әсәрләр дә бар. Ул гына да түгел, Габдерәхим үзе күчереп язган әсәрләргә шәрехкомментарийлар, сүзлекләр төзү белән дә шөгыльләнгән. Мәсәлән, ул Шәмсетдин Мөхәммәт әл-Хорасаниның «Җәмигъ әр-ромуз» («Символлар җыентыгы»), Суфи Аллаярның «Сөбат эл-гаҗизин» («Көчсезләрнең ныклыгы») һәм «Морад эл-гарифин» («Укымышлыларның максаты») әсәрләренә гарәпчә шәрех-аңлатмалар язган һәм шул ук «Җәмигъ әр-ромуз» әсәрендә, әл-Газалиның «Ихйа эл-голүм» китабында, Җ. Руми мәснәвиләрендә очрый торган авыр аңлаешлы сүзләргә гарәпчә-фарсыча сүзлекләр төзегән, күчерүчеләр тарафыннан җибәрелгән хата-ялгышларны төзәткән.

Шагыйрь яшәгән чорда халык арасында укылып йөртелә торган кайбер әсәрләрнең, белем дәрәҗәсе төрле булган кешеләр тарафыннан күчерелеп йөртелүе нәтиҗәсендә, күп вариантлары барлыкка килгән. Габдерәхим шул вариантларны үзара чагыштырып, әсәрләрнең чагыштырма-төп текстларын төзү эше белән дә шөгыльләнгән. Мәсәлән, болгар-татар язма поэзиясенә нигез салган мәшһүр шагыйрь Кол

[1] Кичәләрдә күз йоммаган.
[2] Җөда булдым — аерылдым, югалттым.
[3] Тырыш, иҗтиһад ит, барлык сүзләрен бел.
[4] Чәндике — кайберсе, күпмедер.

Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы. Шагыйрь бу әсәрнең берничә нөсхәсен үзара чагыштырып төзәткән, күчерүчеләр тарафыннан өстәлгән дип уйланылган урыннарын төшереп калдырган, авыр аңлаешлы сүзләрне ачыклаган,—шундый юл белән поэманың чагыштырма-тәнкыйди текстын барлыкка китергән. «Кыйссаи Йосыф» поэмасы 1839 елда беренче тапкыр менә шушы Утыз Имәни тексты буенча басылган һәм дөньяга таралган. Кол Галинең тууына 800 ел тулу уңае белән чыгарылган «Кыйссаи Йосыф»ның юбилей басмасында да нигезгә поэманың Утыз Имәни тарафыннан эшләнгән редакциясе алынган[1].

Югарыда китерелгән мисаллар Утыз Имәнинең әдәби һәм фәнни мираска зур ихтирам белән каравын күрсәтәләр, аны татар әдәбият белемендә текстологик эшка башлап юл яручыларның берсе итеп карарга мөмкинлек бирәләр.

Габдерәхим үз чорының иң укымышлы кешеләренең берсе булган. Мәдрәсәдә укыган елларында ук ул төрки-татар теле белән беррәттән гарәп һәм фарсы телләрен дә тырышып өйрәнгән, аларны ана теле кебек үк белү дәрәҗәсенә ирешкән. Бу хәл шагыйрьнең иҗатына да йогынты ясаган. Иҗат процессында Габдерәхим татар теле мөмкинлекләреннән генә түгел, бәлки гарәп һәм фарсы телләреннән дә киң файдаланган: үз фикерен төгәл һәм матур итеп әйтеп бирү өчен кайсы телнең материалын уңышлырак тапса, шул телнең сүзен кулланган. Бу хәл аның әсәрләренең гарәп-фарсы сүзләре шактый чуар булуын китереп чыгарган.

Шагыйрьнең күпчелек әсәрләре татар телендә язылганнар. Шуның белән беррәттән, шагыйрь кайбер әсәрләрен гарәп, фарсы телләрендә дә иҗат иткән.

Шулай ук ул кайбер әсәрләрен мөләммәгъ алымы белән, ягъни ике телдә язган. Мәсәлән, «Тәнзиһ эл-әфкяр фи нәсаих эл-әхйар» һәм «Әл-карзы микъраз эл-мәхәббәт» поэмалары урыны-урыны белән татарча, ә урыны-урыны белән фарсыча язылганнар. Барлыгы 586 юлдан торган «Тәнзиһ эл-әфкяр» әсәренең 400 юлы татарча, ә 186 юлы фарсыча һәм «Әл-карзы микъраз эл-мәхәббәт» поэмасының баштагы 164 юлы татарча, шуннан соңгы 24 юлы фарсыча язылган.

Утыз Имәни шигырьләре татар халкының укымышлы вәкилләре тарафыннан яратып укылганнар, тиз таралганнар. Габдерәхимнең замандашлары һәм аңардан соң килгән күп кенә шагыйрьләр Утыз Имәни әсәрләренең төгәл ритмлы, музыкаль яңгырашлы, зур, көчле аһәңле булуларына, аз сүз белән күп мәгънә алып килүләренә сокланганнар, аның шигъри форма һәм калыпларын үзләренә өлге итеп алганнар. Мәсәлән, XIX гасырның икенче яртысында яшәгән Габделвәли исемле кеше үзенең хатыны Хәбибә бәнат Әхмәдулла үлгәч язган мәрсиясен нәкъ менә Утыз Имәни мәрсияләре формасында һәм калыбында иҗат иткән[2].

Шагыйрь Габдерәхим үзеннән соң аерым бер шигъри мәктәпкә нигез салып калдырган. Габдерәхимнең уллары һәм ул тәрбияләгән шәкертләрнең кайберләре үзләренең остазлары Габдерәхим юлы белән киткәннәр, гомерләрен Утыз Имәни кебек гыйлем-мәгърифәт, әдәбият өлкәсенә, иҗат эшенә багышлаганнар. Шундыйлардан мисалга Әхмәтҗан исемле өч кешене күрсәтергә мөмкин: аларның берсе — шагыйрьнең улы Әхмәтҗан бине Габдерәхим бине Госман әл-Болгари һәм ике кияве — Әхмәтҗан бине Шәмсетдин бине Сәлим әл-Болгари һәм Әхмәтҗан бине Фазлулла. Алар өчесе дә гомер буе гыйлем-иҗат эше, шигырь язу белән шөгыльләнгәннәр. Утыз Имәни әсәрләренең дә күпчелек күчермәләре, нигездә, алар кулы белән башкарылган.

Утыз Имәни әсәрләрендә XVII — XVIII йөзләр татар әдәбияты өчен дә һәм XIX гасырдагы татар поэзиясе өчен дә хас булган сыйфатлар бер-берсе белән үзара аралашып, үзара үрелеп биреләләр. Аның поэзиясендәге дөньяви мотивлар XIX гасыр татар шагыйре Г. Кандалый иҗатына барып тоташалар. Менә шуңа күрә дә Утыз Имәни шигырьләре һәм поэмалары татар әдәбияты тарихында урта гасырчылык идеяләре белән сугарылган поэзиядән мәгърифәтчелек мотивлары белән характерләнә торган поэзиягә күчү процессында гаять җитди урын билиләр, шушы ике чор поэзиясен бер-берсе белән тоташтырып торучы күпер ролен үтиләр.

**Әнвәр ШӘРИПОВ**

филология фәннәре кандидаты

---

[1] Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. Йосыф турында кыйсса. Казан, 1983.

[2] Казан университеты фәнни китапханәсенең кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге, 301 т. 5 бит.



*Бөек Ватан сугышында катнашкан шагыйрь, КПСС члены, СССР Язучылар союзы әгъзасы Нур Гайсинга 70 яшь тулды.*

*Нурулла Әхьяр улы Гайсин 1914 елның 2 ноябрендә Башкортстанның Чакмагыш районы, Әхмәт авылында туа. Яшьли ятим калган малай башта үз авылында белем ала, аннары Уфада курслар тәмамлап, Баймак районында телеграфист һәм почта бүлеге мөдире булып эшли. 1933 елда Казанга килеп, рабфакта укый, аннары Казан педагогия институтының татар әдәбияты бүлеген тәмамлый; Ютазы районында балалар укыта.*

*Бөек Ватан сугышында зенитчы командир булган Н. Гайсин 1946—1952 елларда Совет Армиясендә хезмәт итә. Демобилизацияләнгәч, яңадан Казанга кайтып, иҗат эшенә керешә.*

*1937 елда «Ватаным өчен» исемле беренче шигырьләр китабын бастырган әдип — хәзер зурлар һәм балалар өчен татарча, русча басылып чыккан егермедән артык шигырь һәм проза китаплары авторы. Аның юмор-сатира әсәрләре дә «Чаян» журналы аша укучыга ярыйсы ук билгеле, ул пьесалар да язды. Әмма Н. Гайсин — күбрәк балалар өчен язучы шагыйрь: аның «Таза Мортаза», «Безнең мәктәп», «Минем әнием», «Мәктәптә яз» исемле китаплары нәниләргә яхшы таныш. Быел исә шагыйрь иҗатының барлык тармакларын да туплаган «Таныш моң» исемле күләмле сайланма китабы дөнья күрде.*

*Укучыларыбыз исеменнән шагыйрьне юбилее белән котлап, бу санда аның балалар өчен төрле елларда язган берничә шигырен тәкъдим итәбез.*

# Нур Гайсин

## Атым

Миңа алып кайтты әни
Магазиннан агач ат,
Мин, иркәләп, битен үбәм
Әнинең кабат-кабат.

Атым агачтан булса да,
Чын ат шикелле үзе,
Кыска гына койрыгы бар,
Пыяла ике күзе.

Җирән яллы минем атым,
Мин аны бик яратам,
Төнен чыгып китмәсен дип,
Кроватька бәйләп ятам.

## Кар җыры

Күгәрченнәр, аяк төреп
Утырганнар — көн бик салкын;
Тышка чыксаң, бит очыңны
Ялап ала гүя ялкын.

Аяк асты җырлап тора
Йөргән чакта урам буйлап,
Әйтерсең кар озата безне,
Күкрәгендә кубыз уйнап.

Аяк асты нигә шулай
«Шыгырт-шыгырт» итә икән?
Көн җылынгач, ул авазлар
Тамчы булып китә икән.

## Үзе бит уйнап йөри

Минем абый бик кызык,
Кайчакта китә кызып:
— Син чыкма,— ди,— урамга,
Адашырсың буранда!

Тыңла сүземне, малай,
Кире булсаң син алай,
Битеңне чеметер,— ди,—
Ачулы,— ди — кыш бабай.

Үзе сүзендә тормый,
Капыл ишекне ачып,
Минем янда утырмый,
Чыга да китә качып.

Ник курыкмый суыктан,
Үзе бит уйнап йөри.
— Кыш бабай ачулы,— дип
Әйтәдер миңа юри.

## Сөт эчәм

Чылтырый зәңгәр чиләк —
Әнием сыер сава;
Яңа чиләк эченә,
Әйтерсең, яңгыр ява.

Юк, яңгыр яумый аңа,
Сөт ага бит, сөт ага:
Күперә ап-ак күбек,
Казан кайнаган кебек.

Өйгә кергәч, үземнең
Тәти савытны алып,
Әнием бирә миңа
Яңа сауган сөт салып.

Яңа сауган сөт эчәм,
Ай үсәсен көн үсәм.

## Кәҗәләр хоккей уйный

Ике кәҗә буранда
Шар сугалар урамда.

Шар дигәч тә, шар түгел,
Шар дигәнем — кәбестә,
Арлы-бирле йөртәләр
Хоккей уйнаган төстә.

Каршыдагы капкага
Кем шайба итеп кертә,
Шушы өлгер кәҗәне
Тәмле кәбестә көтә.

Уен кызганнан кыза,
Вакыт сизелми уза.

Тәпәләнгән кәбестә
Тик бәлагә тарыга,
Мөгез-кашәкә бәргәч,
Урталайга ярыла.

## Йорт салдым

Кулга корал алдым мин,
Биш катлы йорт салдым мин;
Стеналары тигез,
Тәрәзәләре сигез,
Акка буялган бары.

Ишекләре куе сары,
Балконнары күксел таш,
Берсе берсенә тоташ.
Кулмәккә тап тигезми,
Буядым бик тигез мин.

Өй түбәсен бизәдем
Яфрактай яшел төскә,
Кызыл байрак та элдем,
Җилфердәсен дип, өскә.

Куйдым бөтен көчемне,
Яраттылар эшемне.
Нинди матур, күрәмсез,—
Чын йорт түгел, тик рәсем.

## Абый лагерьга китә

Абый лагерьга китә:
— Кышын укып ардым,— ди,—
Тәнемә көч җыярга
Үткән ел да бардым,— ди.

— Мин дә бакчада арыйм
Хәрефләр өйрәнеп,— дим,—
Китим әле, этием,
Абыйга ияреп,— дим.

Елаган булып күзгә
Су да сөрткәләп алам.

— Үскәч,— дип әти көйли,—
Син дә барырсың, балам.

Күңелне тапкан була
Конфет биреп әни дә,
Юатасы юк мине,
Гүя белмим берни дә...

Лагерьга бит баралар
Тик укучы балалар.
Ә мин бакчага йөрим,
Сораган булам юри.

# ҮЗ ХАКЫЙКАТЕҢНЕ АЧУ

Милли сәхнә сәнгатебезнең төрле буын вәкилләреннән Ф. Халитов, Һ. Солтанов, Ш. Биктимеров, Р. Таҗетдинов, Н. Дунаев, Ф. Әхтәмова Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры М. Сәлимҗанов турында сөйлиләр:

— Бер үк вакытта ул фикер иясе дә, сештыручы да, тәрбияче дә, педагог та. Мин үзем Сәлимҗанов репетиция ясаганда вакытның узганын да сизмим. Ул һәрдаим эзләнә һәм сине дә эзләнергә чакыра, җәлеп итә. Ә аның сокландыргыч дәрәҗәдәге төгәл экспериментлары, актерны гадәти амплуа кысаларыннан «йолкып алып», гүзәл нәтиҗәләргә китерүче экспериментлары!

— Киң масштаблы режиссер. Ташып торган көч, гаҗәеп эшсөярлек, бай фантазия. Ә аның пьесада төп нәрсәне тотып ала белү сәләте бигрәк тә сокландыра.

— Казан университетының юридик факультеты, ГИТИСның режиссерлык бүлеге һәм театрга, аның һавасына, андагы барлык әйберләргә мәхәббәт, кече яшьтән үк көчәя баручы мәхәббәт — сәхнә сәнгатенә ул менә нинди байлык белән килде, режиссер, художник, остазларның алдынгы фикерләре белән коралланган көчле шәхес булырак килде.

— Әсәрне халык язмышы көзгесенә әверелдерү, шәхси драма тарихын халык драмасы рәвешендә сөйләп бирү — моның өчен талант кына җитми...

— Артист талантының кәтелмәгән яшерен якларын ача белү, минемчә, Марсельнең иң яхшы сыйфатын билгеле. Ә мондый режиссерлар, дөресен генә әйткәндә, сирәк очрый.

— Марсель «диктатор» түгел, ул актерга иҗат иреге, рольне үзенчә үзләштерергә мөмкинлек бирә. Төптә яткан мәгънәне табарга, характерның икенче һәм өченче катламнарын ачарга; образны калку, реаль һәм шул ук вакытта сәнгатьчә бөтен итеп гәүдәләндерергә булышып, ул актерда иҗат активлыгын уята, җаның-тәнең белән бирелеп эшләргә дәрт кузгата. Студентлык елларында Сәлимҗановның спорт мастеры, фехтование буенча бернича тапкыр Татарстан чемпионы булуы һәм РСФСРның җыелма командасында торуы, минем күзәтүемчә, эзсез югалмаган: кайчак аның парадоксаль фикерләре рапирачының көтелмәгәндә алга ыргылуын һәм башка кискен, төгәл хәрәкәтләрне хәтерләтә.

Ә хәзер вакытлы матбугатта чыккан кайбер бәяләмәләрне күздән кичерик.

«Театрның баш режиссеры Марсель Сәлимҗанов милли колоритларны бирү формаларын иҗат итүдә чын мәгънәсендә зирәклек күрсәтә» («Правда», 1975).

«Режиссер карашының ачыклыгы, әсәрләрне заманча укый белү — аңа әнә шундый сыйфатлар хас...» («Советская Россия», 1975).

«Режиссер М. Сәлимҗанов эшендә «интеллектуаль драма» эстетикасын үзләштерергә омтылу ачыктан-ачык күренеп тора... Бер яктан, ул «идеяләр театры»на омтыла, икенче яктан, ул «характерлар театры» белән нык һәм органик төстә бәйләнгән» («Театр», 1982).

Татар театры һәм аның бүгенге баш режиссеры турындагы күп санлы бәяләмәләрдә Марсель Сәлимҗановның иҗат йөзе шактый тулы ачыла, һәм алар илле яшен тутырган режиссерның Татарстан һәм, гомумән, Россия Федерациясе сәхнә культурасында тоткан урынын да ачык билгелиләр. СССРның халык артисты, ТАССР һәм РСФСР Дәүләт премияләре лауреаты... Мондый югарылыкка ул кырык яшен узуга ук күтәрелде.

Шикләнмичә әйтергә мөмкин: режиссер М. Сәлимҗанов — татар театрының иң күренекле фигураларыннан берсе. Бүгенге милли театрны аннан башка күз алдына китерүе кыен, шулай ук аны да театрдан башка күзаллап булмый. Һәм шушы урында бик табигый сорау туа: режиссер иҗатының «чишмә башы» кайда, туган җирлеге белән аны нинди тамырлар бәйли? Мөгаен, боларны ачыклар өчен шәхеснең гомер башына күз ташларга кирәктер.

Шушы хактагы уйлар сугыш алды балачагына алып кайта. Театр ишегалдындагы данлыклы флигель. Әлеге кечкенә йорт өлкән буын артистларның бик күбесен хәтерли. Истә калган беренче картина — кечкенә малайның зурлап үткәрелгән туган көне. Ә чынлыкта исә актерлар Октябрьның чираттагы еллыгын бәйрәм итәләр (Марсель 1934 елның 7 ноябрендә туган). Гомер чишмәсе менә шундый истәлекле көннән башлана.

Балачакның бер сәхифәсен икенчесе алмаштыра. Артистлар, язучылар, рольләр... Кече яшьтән үк ул менә нинди мохиттә тәрбияләнә, һәм аның театрга гомерлеккә гашыйк булуы, театрда яшәү мәгънәсен күрүе бик тә табигый.

Шаулы умарта оясын хәтерләткән ике катлы кирпеч йортта Сәлимҗановлар үзенең кызы белән яшәүче күренекле актриса Н. Таждарова белән күршедәш булалар. Марсель аларга кереп йөрергә ярата. Кышкы озын кичләрдә, спектакльдә уйнамаган көннәрдә Нәгыймә апа үзенең яшьлек истәлекләрен сөйли башлый, татар сәхнәсенең корифейларыннан Г. Кариев, Н. Сакаев, кыскасы, «Сәйяр» артистларын искә төшерә. Ә Марсель исә мич янындагы тәбәнәк урындыкка «җирләшеп», үзенә күрә легендага әверелгән истәлекләрне тын да алмыйча тыңлый. (Әлеге урындык Сәлимҗанов өендә хәзер дә саклана.) Менә шуңа күрәдер дә, Нәгыймә Таждарова аның хәтерендә зирәк һәм интеллигентлы кеше буларак, хатын-кызларның чеховча идеалы үрнәге буларак уелып калган.

Балачакта Марсельнең берничә кумиры була: Нәгыймә Таждарова, Салих Сәйдәшев, Кәрим Тинчурин һәм әтисе Хәким Сәлимҗанов. Атаклы драматург, масштаблы фикер йөртә белүче театр эшлеклесе, татар труппасы җитәкчесе, катлаулы язмыш кешесе К. Тинчурин шәхесе аны бик яшьтән кызыксындыра. Башта актер буларак, соңрак драматург сыйфатында. Режиссер М. Сәлимҗанов иҗатында аның әсәрләре үзенә күрә бер этап рәвешен алуы тикмәгә генә түгелдер.

Сугыш елларында ук Марсель актерлык хезмәте белән якыннан таныша башлый. Күп кенә актер балалары кебек үк, массовкаларда катнаша. «Хуҗа Насретдин» спектаклендә исә аңа беренче мөстәкыйль роль — озын сакаллы кечкенә вәзир ролендә уйнауны тапшыралар. Шулай да бераз үсә төшкәч, әти-әнисе Марсельне театрдан акрынлап читләштерергә ниятли. Артист тормышының кыен булуы еш телгә алына, театрның актердагы эмоциональ һәм физик көчне «сыгып алуы» кат-кат искә төшерелә. Кыскасы, үзләре театрга гомерлеккә тугрылыклы булып калсалар да, ата белән ана улларын башка юлны сайларга киңәш итәләр. Әмма Марсель барыбер үзенекен эшли — күп вакытын театрда үткәрә. Иң югары ярустан Ш. Сарымсаков, Г. Юсупов репетицияләрен карарга ярата. Ә кичен сәхнә артыннан күзәтә. Театр аның туган йортына әверелә. Бишенче класска кадәр шулай дәвам итә. Күтмәгәндә ул фехтование белән мавыга башлый. Ә дүрт елдан соң кичке мәктәпкә күчә — спорт аның бик күп вакытын «суыра» башлый. Фехтование буенча ирешкән уңышлары Марсельне Татарстан һәм соңрак РСФСР җыелма командаларына алып килә.

Спорт белән шөгыльләнү аны күпмедер дәрәҗәдә театрдан читләштерә. Әмма тормышта кискен борылышлар була. Табигый көчләр, әйтерсең, кешенең киләчәк яз- мышын билгеләү өчен бөтен энергиясен бер максатка туплый. Шушы ук кичке мәктәп- тә, ГИТИСның актерлык факультетын тәмамлаганнан соң, Празат Исәнбәт укый башлый. (Яңадан Мәскәүгә барып, режиссерлык факультетында уку өчен аңа өлгергәнлек таныклыгы кирәк була.) Празатның театр институты турында мавыгып сөйләгәннәре Марсельнең күңелен кузгата. Шулай да ул әлеге институтка мәктәп тәмамлагач ук йөгереп китәргә ашыкмый.

Илленче еллар башында Казан университетында юридик факультет ачыла. Үзенең әти-әнисен сөендереп, Марсель шушы факультетка имтиханнар тапшыра. Юристлыкка укуда да аның өчен ниндидер бер логик бәйләнеш бар шикелле. Ә бит юристлар да, актерлар шикелле үк, кешеләрне әхлакый тәрбияләү белән шөгыльләнәләр. Университ-

тетта укыган елларда да ул спортка шактый вакытын багышлый. Өстәмә кыенлыклар тудыруга карамастан, фехтование егетнең характерын формалаштыруда, ихтыярын һәм тотрыклылыгын ныгытуда уңай йогынты ясый, кирәк вакытта көченңне «бер ноктага» тупларга булыша. Ә инде режиссер буларак эшли башлагач, Марсель спорт белән шөгыльләнүнең файдасын ачыктан-ачык сиземли. Режиссер пьеса трактовкасы дәреслегенә актерларны ышандырырга тиеш, ә моның өчен исә ихтыяр көче һәм башка сугышчанлык сыйфатлары сорала. Болардан тыш, фехтование кешенең пластик культурасын үстерә һәм кеше тәненең матурлыгын күрергә, үз гәүдәң белән сыгылмалы рәвештә «идарә итәргә» булыша. Бүгенге заман театры өчен мондый сыйфатлар бик кирәк.

Университетның бишенче курсына җиткән студент, шактый вакытын спортка бирүгә карамастан, театрдан бер генә карышка да читләшми. Алай гына да түгел, фехтование аны театрга тагын да якынайта — спектакльләрдә ул фехтование алышларын куя башлый. Илебез башкаласында үткәрелгән Татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре (1957) аның өчен аеруча истәлекле булып хәтердә калган. Авырып киткән артистларның ролен ул бик теләп башкара. Спектакльләрне тикшерүдә чыгыш ясаган театр белгечләренең һәр сүзен зур дикъкать белән тыңлый һәм аның үзендә дә зур җаваплылык тойгысы уяна. Боларның бөтенесе дә егетнең аңына сеңеп бара һәм акрынлап тормышта кискен борылыш ясау зарурлыгы тудыра.

Әдәбият һәм сәнгать декадасыннан соң Татар дәүләт академия театры коллективы Ташкентка китеп бара. Ә Марсель, беркемгә дә әйтмичә, ГИТИСка керергә әзерләнә башлый. Ниһаять, ул күренекле режиссер һәм педагог А. Лобанов курсында укый башлый—җан һәм тән омтылышына бирелә. Егет дөрес карарга килгәнме? Театрда күп еллар буе уңышлы эшләве аның үз хакыйкатенә илтүче дөрес юл сайлавын раслый.

Шушы ук елларда Мәскәүнең М. Щепкин исемендәге училище каршында эшләүче Татар студиясендә Р. Таҗетдинов, Р. Шәрәфиев, Н. Ихсанова, Н. Дунаев, Г. Исәнгулова, Ә. Шакиров, Ф. Әхтәмова кебек өметле яшьләр дә укый. Хәзерге көндә исә алар халык ихтирамын казанган артистлар булып танылдылар. Бу җәһәттән шуны әйтеп үтәсе килә: М. Сәлимҗанов һәм аның буындашлары шул яктан бәхетлеләр—алар дулкыны килгән вакытта, ягъни илленче еллар ахыры һәм алтмышынчы еллар башында бөтен совет театры яңарыш кичерде. Дөньяны танып-белергә омтылучы драматурглар, бүгенге заман һәм классика әсәрләрен яңача «укырга» сәләтле режиссерлар калкып чыкты. Англия, Франция, Япония, Италия һәм башка илләрнең күренекле труппалары Мәскәү сәхнәләрендә ешрак чыгыш ясый башлады.

Яшь тамашачылар театры... Югары белемле режиссер буларак, М. Сәлимҗанов беренче мөстәкыйль адымнарын менә шушында ясый. Ә өч сезон узып киткәч, 1966 елның язында аны Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры итеп билгелиләр. Шул рәвешле ул 31 яшендә танылган коллективның җитәкчесенә әверелә. Әлеге адымда күпмедер тәвәккәллек тә була, әмма ул тулысынча аклана.

Әйтергә кирәк, М. Сәлимҗановның килүе театрның иҗади яктан шактый катлаулы чорына туры килә. Шулай да коллектив үзенең абруен югалтмый, киресенчә, илебезнең күренекле театрлары югарылыгына күтәрелә. Күзгә күренеп үсүнең берничә алшарты бар: КПССның XX съездыннан соңгы чорда күпмилләтле совет сәнгатенең гомуми күтәрелеше, аерым алганда, яшь режиссерның һәм театр директоры Р. Җиһаншинаның ныклы иҗади хезмәттәшлектә, алга зур бурычлар куеп эшләүләре, коллективның щепкинчылар хисабына яңаруы, татар драматургиясенең яңа сыйфат үзгәреше кичерүе...

Театрны заманчалаштыру эшен М. Сәлимҗанов бик саклык белән, әмма эзлекле рәвештә башлап җибәрә. Заманча репертуар булдыру өчен ул театр активына драматурглар туплый. Мәсәлән, Х. Вахитның күңелле һәм шактый тирән мәгънәле пьесалары, Ш. Хөсәеновның гаять зур уңыш казанган «Әни килде» әсәре, шулай ук Д. Вәлиев, Р. Хәмиднең үзенчәлекле драматургияләре соңгы унъеллыклардагы эзләнүләрне шактый ачык чагылдыралар. Ниһаять, театрның үз әдибенә әверелгән драматург Т. Миңнуллин коллективны тагын да киңрәк орбитага чыгарырга булышлык күрсәтте «Моңлы бер җыр» публицистик трагедиясе, «Канкай углы Бәхтияр» тарихи драмасы, «Әлдермештән Әлмәндәр», «Дуслар җыелган җирдә» философик притчалары, «Дилафрүзгә дүрт кияү» водевиле, «Монда тудык, монда үстек», «Әниләр һәм бәбиләр»

психологик драмалары, бер яктан, драматургиябез казанышлары хәзинәсен баетсалар, икенче яктан, алар сәхнә сәнгатендә режиссерның актив иҗади эзләнүләрен чагылдырган күренекле вакыйгалар буларак кабул ителәләр.

Заманча спектакльләр тудыру белән беррәттән, М. Сәлимҗанов академия театрында эшли башлаган беренче көннәреннән үк татар классикасы үрнәкләрен сәхнәләштерүнең яңа формаларын эзли һәм аларны уңышлы тормышка ашыра. «Миркәй белән Айсылу» (Н. Исәнбәт)— шушы юнәлештәге эшчәнлекнең беренче казанышы. Шушы куелышта ук режиссер «камерный яңгыраш»тан катгый рәвештә баш тарта. Пьеса трактовкасының үзенчәлеге шунда: спектакльдә халык һәм аның фаҗигале язмышы баш герой итеп алына. Деспотлык әхлагы, югары катлауларга хас карашлар белән каршылыкка кергән мәхәббәт, татар сәхнәсендә инде күп мәртәбә күрсәтелсә дә, әлеге куелышта бөтенләй яңа яктан ачыла, киеренке драматизмы белән тамашачыларның күңелендә давыл кузгата.

Классик драматургыбыз К. Тинчурин әсәрләре М. Сәлимҗанов иҗатында үзгә бер урын алып торалар. Егерме ел эчендә ул аның биш пьесасын — «Американ», «Сүнгән йолдызлар», «Назлы кияү», «Зәңгәр шәл», «Казан сөлгесе» әсәрләрен сәхнәләштерде. Режиссер һәрбер куелышта спектакльнең заманча образын табарга омтылды һәм, эчке хәрәкәт логикасына таянып, пьесаларның камил гәүдәләнешен бирүгә иреште. Әлеге пьесаларның элекке куелышларын кабатламыйча, ул әсәрләрнең сәхнәдәге яшәешләрен яңача формалаштырды. Режиссер актерларның игътибарын персонажларны хәрәкәткә китерүче эчке логикага юнәлдерде һәм уенчыларны, геройларның эч йөзен, конкрет гамәлләрен күрсәтеп, төп мәгънәне төгәл ачарга чакырды.

Шуңа игътибар итмичә мөмкин түгел: әлеге спектакльләрдә М. Сәлимҗанов үзенең психологик театр тарафдары булуын сиздерә. Әйтик, «Американ»ны ул, характерларның эчке психологик реальлегенә ирешеп, аерым кысалар белән чикләнмәгән «тамашалы» спектакльгә әверелдерсә, «Сүнгән йолдызлар»ны катгый рәвештә сугышны гаепләүче социаль мелодрама итеп сәхнәләштерә. Әлеге спектакльләрнең идеяләре психологик яктан табигыйлек дәрәҗәсенә күтәрелгән характерлар аша гәүдәләндерелә.

Үзенең яраткан драматургы Т. Тинчурин әсәрләрен сәхнәләштерү барышында табылган яңа формалар, яңа сурәтләү чаралары башка спектакльләрдә дә, аерым алганда, Н. Исәнбәтнең «Качаклар» пьесасы куелышында да уңышлы файдаланыла. Әлеге әсәр туган илен ташлап китүчеләрдән үтергеч рәвештә көлүче сатирик комедия итеп куела. Кәмит уенына хас эксцентрик, «зәһәр» буяулар кулланыла. Бизәлешнең әйләнүгә корылуы карусель символы буларак кабул ителә. Барысы да әйләнә: шау-шу, ыгы-зыгы... Тормыш каруселе аларны, башларын әйләндерә-әйләндерә, үзләренә кире алып кайта. Характерларның җисми бирелешендә психологик тирәнлек, мөнәсәбәтләрнең виртуозларча эшләнеше әлеге спетакльләрдә аеруча ачык сиземләнә.

Татар драматургиясе үрнәкләрен сәхнәләштерү белән беррәттән, М. Сәлимҗанов рус һәм башка милләт, шулай ук чит ил авторлары әсәрләренә дә еш мөрәҗәгать итә. Иң элек И. Дворецкийның «Чит кеше» драмасы буенча куелган спектакльне искә төшерик. Искергән традицияләргә каршы көрәшне чагылдыручы конфликтны ачып бирү белән беррәттән, режиссер, беренче тапкыр буларак, психологик драманы үткен публицистик әсәр рәвешендә калкытып бирүгә ирешә. Ә менә Б. Горбатовның «Бер төн», Л. Леоновның «Ябырылу» пьесалары куелышында, психологик башлангыч белән бергә, гротеск-сатира, плакат элементлары да шактый мул күренә. Һәм, әйтергә кирәк, мондый юнәлештәге эзләнүләр үзмаксатка түгел, ә эчтәлекне төгәл ачуга, уңай геройларны һәм позитив тенденцияләрне калку итеп күрсәтүгә юнәлдерелә. Шундый ук эзләнүләр нәтиҗәсе А. Островскийның «Котырган акчалар», «Агай-эне, ак мыек», «Бирнәсез кыз» пьесалары куелышында да чагыла. Әгәр беренче һәм икенче спектакльләрдә шуклык-шаянлык, кыланчыклык сизелер, соңгысы Островский буенча куелган иң яхшы спектакльдер. Бирелә автор тарафыннан салынган төп мәгънәгә беркинди дә хилафлык килмәгән һәм спектакль режиссерның бүгенге театр процессы үзәгендә торуын да раслый.

Режиссер М. Сәлимҗанов заманча актерлар тәрбияләү, труппаны сәләтле яшьләр хисабына тулыландыру юнәлешендә дә эшлеклелек күрсәтә. Актерлар коллективының күренекле труппалар сафында торуы әнә шундый тырышлыкка да бәйләнгәндер. Баш режиссер булып эшли башлавының беренче елларында ук ул актердан рольне со-

циаль-психологик планда үзләштерүне һәм аның төгәл гәүдәләнешен табуны таләп итә башлады, образларны пластик, ритмик һәм башка яктан ачуга игътибар юнәлтте. Ә максатка ирешү турында спектакльләр үзләре сөйлиләр.

Геройларның фикер сөреше һәм хәрәкәт логикасы тирәнлегенә ирешү, жанр һәм авторның стиль үзенчәлекләренә төшенү... Әлеге омтылыш театр үсешендәге яңа этапны билгели. Чыннан да, коллектив һәр спектакльнең жанрын төгәл билгеләргә омтыла. Менә шуңа күрә, репертуарда, психологик драмалар белән беррәттән, трагедия, фарс, мелодрама, водевиль, героик һәм публицистик драмалар булуы бик табигый. Ә күп кенә спектакльләр төрле сурәтләү чараларын үзләштерү юлында үзенә күрә баскыч ролен дә үтиләр. Театр эзләнә. «Халык язмышын, кешелек язмышын» социаль яктан тагын да дәлиллерәк һәм тирәнрәк итеп күрсәтергә омтыла.

Табигый ки, М. Сәлимҗановның иҗат юлы тоташ чәчәкләргә генә күмелмәгән. Плюслар белән күпмедер минуслар да бардыр. Шулай да аның иҗатындагы үсеш тенденцияләре, режиссер-куючы буларак та, театр җитәкчесе буларак та, позитив яктан аерылып торалар. «Советская Россия» газетасында (1983) театр һәм аның баш режиссеры турында бик дөрес бәяләмә бирелә: «...Марсель Сәлимҗанов театрның кешеләр күңелен тирәнтен дулкынландыра торган тасвирлы һәм колоритлы палитрасын билгеләүче коллектив, үз фикердәшләренең таза-нык коллективын туплауга ирешкән. Театрның анык гражданлык позициясе, башкаручыларның профессиональ дәрәҗәсе, спектакльнең идея-художество яңгырашы, тема һәм жанр төрлелеге, репертуарның тирән уйланып һәм барысын да тигез үлчәп төзелүе, үзенчә бер мөстәкыйльлек, ерак үткәннән килүче милли традицияләргә тугрылык, спектакльләрне художество ягыннан да, музыкаль яктан да күренекле, кызыклы һәм органик камил итеп формалаштыру театрга үз йөзен билгеләргә ярдәм иткән».

Иҗат юлын күздән кичергәндә, шулай уйлап куясың: М. Сәлимҗанов үзенең беренче зур бәйрәменә нинди казанышлар белән якынлаша? Ә җавап эзләгәндә, ирексездән: «яңа», «заманча» сүзләрен беренче итеп әйтәсе килә. Пьесаларны яңача «уку», актерлар, художниклар, композиторлар белән яңача эшләү, тормышка чын мәгънәсендә яңача караш... Менә боларның барысы да Марсель Хәкимович Сәлимҗановка илле яшьтә дә яшь булып калырга ярдәм итә.

Ильтани ИЛЯЛОВА,
сәнгать фәннәре кандидаты.

# Татарстан язучыларының X съезды

*Быел, 21—22 майда Казанда Татарстан язучыларының чираттагы X съезды булып узды.*

*Республика язучыларының иҗади эшчәнлеге һәм ТАССР Язучылар союзы идарәсенең ике съезд арасындагы эше турындагы отчет докладын идарә председателе Гариф Ахунов ясады.*

*Съездда СССР Язучылар союзы секретаре, РСФСР Язучылар союзы идарәсе председателе, Социалистик Хезмәт Герое С. В. Михалков чыгыш ясады.*

*Жанрлар буенча өстәмә докладлар тыңланды. Поэзия буенча — Илдар Юзеев, проза буенча — Мөхәммәт Мәһдиев, драматургия буенча — Туфан Миңнуллин, әдәби тәнкыйть буенча — Тәлгат Галиуллин, балалар һәм яшүсмерләр өчен әдәбият турында — Шәукәт Галиев, очерк һәм публицистика турында — Марсель Зарипов, Татарстанда яшәүче рус язучыларының иҗаты турында — Нонна Орешина һәм тәрҗемәчеләр эшчәнлеге турында Кыям Миңлебаев сөйләде.*

*Докладлардан соң фикер алышуларда Татарстан Язучылар союзының Әлмәт бүлеге җаваплы секретаре Э. Гаффар, Брежнев бүлеге җаваплы секретаре Р. Вәлиев, Язучылар союзының партия оешмасы секретаре Р. Мөхәммәдиев, республика укучыларының А. Алиш исемендәге әдәби берләшмәсе җитәкчесе Р. Мингалим, Казан телевидениесенең әдәби-музыкаль тапшырулар редакциясе баш редакторы Р. Миңнуллин, РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре Н. Доризо, «Казан утлары» журналының баш редакторы Р. Харис, Татарстан китап нәшрияты директоры Г. Шәрәфетдинов һ. б. иптәшләр катнашты.*

*Съездда КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев чыгыш ясады.*

*Съезд эшендә КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Г. И. Усманов, ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе Ә. Б. Бәһаветдинов, ТАССР Министрлар Советы Председателе И. Х. Садыйков, КПСС Үзәк Комитетының Культура бүлеге инструкторы С. В. Потемкин, КПСС өлкә комитетының икенче секретаре В. С. Дергунов, КПССның Казан шәһәр комитеты беренче секретаре М. М. Сухов, ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.*

*Түбәндә кыскартылган күләмдә съезд материаллары урнаштырыла.*

## Гариф Ахунов

# ПАРТИЯ БЕЛӘН, ХАЛЫК БЕЛӘН

1

Менә без — инде ничәнче мәртәбә! — чираттагы съездыбызны язын, Идел дәрьясы һәм вак елгалар шаулап тынгач, урман-кырлар яшелдән киенгәч, язгы зәңгәр күккә сабан тургае күтәрелгәч, җир кешесе иген басуларына чиксез бер өмет һәм тирән борчылу белән күз текәгән вакытта башлыйбыз.

Быелгы съездыбызны без «нурлы һәм моңлы» Казаныбыз — өч орденлы республикабызның башкаласы — илнең иң зур бүләгенә — Ленин орденына лаек булган, күңелләребез чиксез дулкынланган көннәрдә башлыйбыз.

Чираттагы съездыбызның СССР Язучылар союзы, шул исәптән Татарстан Язучылар союзы да төзелгәнгә 50 ел тулган елны үткәрелүе безгә аеруча зур җаваплылык өсти. Чөнки әдәбият-сәнгать мәсьәләләре бездә дәүләт күләмендә хәл ителә, әдәбият безнең тормышыбызның аерылмас бер мөһим өлеше булып яши.

Татарстан Язучылар союзы идарәсенең тугызынчы һәм унынчы съездлары арасындагы оештыру-иҗат эшчәнлеге югары политик бердәмлек һәм хезмәт күтәренкелеге шартларында алып барылды, ә ул күтәренкелекне партиянең XXVI съезды һәм КПСС Үзәк Комитетының аннан соңгы Пленумнары карарлары тудырды. Бу елларда без Совет Социалистик Республикалар Союзы төзелүнең, Татарстан АССР төзелүнең 60 еллыкларын тантаналы рәвештә бәйрәм иттек. Совет власте елларында Ватаныбыз ирешкән уңышларга йомгак ясадык. Бу тарихи вакыйгалар безнең тормышыбызга, шул исәптән культура тормышыбызга да, зур һәм уңай йогынты ясады.

Партия Үзәк Комитетының 1984 елгы февраль һәм апрель Пленумнары карарлары язучылар коллективында зур бер канәгатьләнү тойгысы уятты, тулысынча бердәмлек шартларында узган ул Пленумнар партиябезнең XXVI съездында кабул ителгән эчке һәм тышкы политиканың тайпылышсыз булуын расладылар.

Безнең съезд коммунизм идеаллары өчен армый-талмый көрәшүче күренекле ленинчы иптәш Константин Устинович Черненконың КПСС Үзәк Комитетының Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе булып сайлануын кайнар рәвештә хуплый.

Күпмилләтле совет әдәбиятының зур оркестрында татар әдәбиятының тавышы отчет чорында ышанычлы һәм көр яңгырады. Республикабыз язучылары, пролетар интернационализм принциплары белән коралланган хәлдә, социалистик реализм методы ирешкән казанышларны иҗади файдаланып, илһамланып эшләделәр, барлык әдәби жанрларны тагын да үстерүгә ирештеләр, унынчы съездыбызга идея ягыннан чыныккан, ныгыган хәлдә килделәр. Ике съезд арасында иҗади эзләнүләребез күбәйде һәм тирәнәйде, тормышны белүебез артты, отчет чорында әдипләр заманабызны күп яклы итеп тасвирларга, аның рухи дөньясын тирәнрәк ачарга омтылдылар.

Ике съезд арасында Татарстан язучылары 12 роман, 86 повесть, 20 поэма иҗат иттеләр, дистәләгән җыентык: очерк һәм публицистика, әдәби тәнкыйть һәм әдәбият белеме, шигырьләр, пьесалар, рус һәм дөнья әдәбияты классиклары, рус совет язучыларының ил күләмендә танылган әсәрләре, тугандаш халыклар әдәбиятыннан иң яхшы үрнәкләрне тәрҗемә итеп бастырып чыгардылар. Бу биш ел эчендә без сәхнәдә драматургларыбызның пьесалары буенча куелган 40 тан артык яңа спектакль карадык. Шулар янына илебезнең үзәк нәшриятларында, союздаш һәм автономияле республикалар нәшриятларында басылып чыккан 130 китапны, чит илләрдә басылган 9 китапны өстәсәк, эшләгән эшебезнең зурлыгы тагын да арта төшәр.

Китапларның саны хакында сөйләү күңелле, әмма аларның сыйфаты ничек?

Съезд шушы гаять зур әдәби хуҗалыкка, республикабызда тату бер семья булып яшәүче татар, рус, чуваш язучыларының әсәрләренә бәя бирергә тиеш булачак.

Съездда без әдәбиятыбызның үсеш тенденцияләрен, аның проблемаларын һәм алда торган бурычларын партиянең XXVI съезды һәм КПСС Үзәк Комитетының аннан соңгы Пленумнары карарлары яктылыгында барлап чыгарга, ирешкән уңышларыбызны, эшләнеп җитмәгән эшләребезне, үз-үзебезгә таләпчән килеп, анализларга тиеш булабыз.

Бер генә әдәбият та үзара аралашу, бер-берсенә йогынты ясау кебек зур һәм җитди сыйфатларыннан башка уңышлы рәвештә үсә алмый. Безгә әдәби байлыгыбызны күпмиллә́тле совет әдәбияты ирешкән югарылыктан, дөньяның прогрессив әдәбиятчылары ирешкән югарылыктан торып бәяләргә туры киләчәк.

## 2

Узган бишьеллыкта безгә бүгенге әдәби процесс турында күп төрле фикерләр ишетергә туры килде. РСФСР Язучылар союзының проза Советы Казанда, Ижевскида, Уфада үткәргән күчмә утырышларда, республикабыз газета-журналларында, радио һәм телевидениедә, күп санлы укучылар конференцияләрендә, «Казан утлары» журналының бер ел буена алып барган дискуссиясендә бүгенге татар прозасының торышына карата байтак кына файдалы фикерләр әйтелде. Бәхәс вакытындагы артык кызып китүләрне, кылычларның чамасыз чыңлавын тактик бер түземлелек һәм сабырлык белән бер читкә алып куеп, бәхәснең үзәгенә үтеп кергәндә, без ул дискуссиядән һәм чыгышлардан үзебез өчен кирәкле нәрсәләрне аерып ала алырбыз дип беләм. Безнең бүгенге драматургиябез РСФСР Язучылар союзы үткәргән киңәшмәдә югары бәя алды. Киңәшмәнең компетентлы булуын аны идарә председателе Сергей Михалковның үзе ачкан булуы ук әйтеп тора. Безнең поэзия соңгы елларда күпмилләтле совет әдәбиятына лаеклы өлеш булып керде, бөтендөнья аренасында да үзенең җитлеккәнлеген сиздерде. Болгар-татар язма поэзиясенең нигезен салган Кол Галинең 800 еллыгы һәм ул хакта «Юнеско» кебек халыкара бюллетеньдә зур мәкалә басылып чыгу, Муса Җәлил шигырьләренең немец һәм инглиз телләрендә аерым китаплар булып басылуы, Сибгат Хәкимнең поэзиясе социалистик илләрдә тәрҗемә ителүе, Гомәр Бәшировның «Намус» романы һинди телендә дөнья күрүе, Шәүкәт Галиевкә «Заяц на зарядке» исемендә русча басылган балалар өчен шигырьләр китабы өчен Г. Х. Андерсен исемендәге халыкара Почетлы диплом бирелүе, безнең шагыйрьләребездән 17 авторның әсәрләре 200 томлык дөнья әдәбияты китапханәсенә кертелүе — менә болар барысы безнең әдәбиятның күтәрелештә икәнен, тәгәлрәк итеп әйткәндә — барлык жанрларының уңышлы рәвештә, бертигез дип әйтерлек үсеп баруын дәлилли торган конкрет мисаллар. Ә әдәбиятта жанрларның тигез үсештә булуы ул аның җитлеккәнлеген раслый торган хәл.

Әдәбиятның зурлыгын, җитлеккәнлеген исбатлый торган әдәби жанрларның берсе һәм иң зурысы — проза. Югарыда әйтелде — 12 роман иҗат ителгән. Башка съездларда да шулай иде. Димәк, иң масштаблы, киң колачлы әсәрләргә игътибар кимемәгән. Нинди өлкәләрне яктырта бу әсәрләр? Хисам Камалов үзенең ике романын немец фашистларына каршы совет халкының героик көрәшенә багышлый. «Һәркемнең гомере бер генә» исемле беренче романы ике съезд арасында русча да басылып чыгып югары бәя алды. Романнан тормыш чынлыгы, сугышның кайнар сулышы бөркелеп тора. Камалов геройлары сугыштан романтика эзләмиләр, сугыш алар өчен авыр хезмәт, җиңүне якынайту хакына пуля яңгыры астында, «кайнар кар» өстендә фидакарьләрчә эшләү, кара тир түгеп, төшне кысып эшләү.

Атилла Расих ике съезд арасында шулай ук ике роман иҗат итте: «Сынау» һәм «Ямашев». Шушы романнары өчен аңа Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелде. Авыл тормышын бик яхшы белүе, ветеринария белгечлеге буенча озак еллар институтта укытуы аңа бүгенге авыл тормышыннан хәтердә кала торган картиналар, геройлар иҗат итәргә мөмкинлек биргән. «Сынау» романы авторның элегрәк елларда иҗат иткән талантлы романнары «Язгы авазлар» һәм «Ике

буйдак»ның дәвамы, өченче китабы булып саналырга хаклы. Өч китапны бергә алып карагáнда, А. Расих колхоз авылы тормышын утыз ел дәвамында эзлекле итеп, үсештә итеп сурәтли алды дип әйтә алабыз. Ул иҗат иткән уңай герой — галим образы



*Съезд президиумы. Өлкән шагыйрь Сибгат Хәким кереш сүз сөйли.*

аеруча игътибарга лаек. «Ямашев» исемле тарихи-революцион романында исә автор егерменче гасыр башындагы атмосфераны, халыкның революцион аңы уянуны, аның алдынгы вәкилләрен — беренче профессиональ революционерларын ышандыргыч итеп сурәтли алган.

Тугызынчы съезд трибунасыннан без хезмәт темасына багышлап язылган бер дистәдән артык романны күрсәтеп узган идек. Бу съездда да хезмәт темасының беренче планда булуы күңелле факт. Ә. Баяновның «Таш китап», Ш. Бикчуринның «Тирән катлам», М. Хәсәновның «Шөгеровлар», М. Хәбибуллинның «Сулар үргә акса да...», М. Маликовның «Ак буранда тал бөресе», Ә. Гаффарның «Бодай бөртеге һәм тегермән ташы», Б. Камаловның «Өметең өзелмәсен» романнары нефтьчеләргә, төзүчеләргә, иген үстерүчеләргә, халык интеллигенциясенә багышланганнар, аларда әхлакый-этик аспектлар кузгатылган, язу алымнары, стильләре ягыннан төрлечә булган бу әсәрләр тиешле сәнгать югарылыгында язылганнар, көн таләпләренә җавап бирәләр, әмма, бәяләүдә максимум таләпләрдән чыгып эш йөртсәк, алар әдәбиятыбызның алтын фондына кергән әсәрләр белән ярыша алырлар микән? Ихтимал, ярыша алмаслар. Ник алай соң? Миңа калса, киң планлы эпик әсәрләр соңгы елларда ашыгыбрак язылалар, аларны иҗат итәр алдыннан зур хәзерлек алып барылмый кебек. «Язгы җилләр» романын язар алдыннан К. Нәҗми Казан заводларының тарихын, Казан пролетариатының тууын бик җентекләп һәм озаклап өйрәнеп чыга. Табигый, әсәр ил күләмендә яңгыраш тапты, СССР Дәүләт премиясенә лаек булды. Тукай образын иҗат итүгә халыкта киң танылган шагыйрь Ә. Фәйзи гаять зур җаваплылык белән керешә. Романны иҗат иткәнче әле ул Тукай йөргән барлык урыннарда булып чыкты, никадәр мәкалә язды, пьеса иҗат итте, күпме кеше белән — Тукай замандашлары белән сөйләште, тик шуннан соң гына әсәргә тотынды. Г. Әпсәләмовка «Алтын Йолдыз» романын, сугыш батырлары турындагы романны язганга кадәр үзенә Бөек Ватан сугышын башыннан алып ахырына кадәр үтеп чыгарга туры килде, эшчеләр тормышыннан алып язган «Сүнмәс утлар»га кадәрле ул озак еллар буе Мәскәү

заводларында слесарь булып эшләде. Г. Бәширов СССР Дәүләт премиясенә лаек булган «Намус» романына безнең илдә колхозлар һәм МТСлар төзү буенча тупланган тәҗрибәне күңел күзеннән үткәрде, шуның янына үзенең бай тормыш тәҗрибәсен салды, әсәр зур булып туды, илебез халыклары, Европа халыклары теленә тәрҗемә ителде.

Уйлап баксаң — гыйбрәтле мисаллар!

Соңгы елларда без роман жанрына таләпне киметә төштек булса кирәк. Романны кульязма хәлендә проза секциясендә бергәләп тикшерү кебек бик матур гадәтебезне онытып җибәрдек. Ә бит сугыштан соңгы елларда иҗат секцияләрендә тикшерелеп уңай фикер алмаган, секция утырышыннан соң автор кабат карап чыкмаган кульязманы матбугатта чыгарырга кабул итмиләр иде. Әле соңгырак елларда да без андый эшнең, бергәләп фикер алышуларның файдалы икәнен аерым мисалларда күреп килдек. Әйтик, М. Хәбибуллин колхоз авылы турындагы «Чоңгыллар» романына РСФСР Язучылар союзының бүләгы премиясен алды. Роман җитди, премиягә лаек. Автор аны озак язды, кат-кат эшкәртте, иптәшләре белән киңәшеп, алар фикеренә колак салып, гел камилләштерде. Кыскасы, аерым китап булып чыкканчыга кадәр автор тарафыннан бик зур һәм бик җитди эш эшләнде. Шуңа күрә роман рус телендә дә берничә мәртәбә басылды, матбугатта уңай бәя алды. Ә менә «Сулар үргә акса да...» исемле икенче романын, миңа калса, М. Хәбибуллин матбугатка ашыгыбрак тапшырды, «Чоңгыллар» кебек үк популярлык казана алырмы ул роман, юкмы — билгесез. Әгәр казана алмый икән, моңа автор үзе генә түгел, без, идарә членнары да, гаепле моңа: соңгы елларда без авторларның үзләренә карата да, редакторларга карата да ныклы таләпчәнлек белән килмәдек. Моңа «Казан утлары» журналы редакциясенең эшеннән дә мисал китерергә була. Дөрес, журналда чыккан материалларның гомуми дәрәҗәсе түбән дип әйтеп булмый,— җитәкчелекнең һәм намуслы тырыш хезмәткәрләрнең тырышлыгы белән күпчелек әсәрләрнең идея-художество югарылыгы сакланып килә. Шулай да вакыт-вакыт редакцияләнеп җитмәгән әсәрләр дөнья күрә әле. Әйтик, Ә. Гаффарның «Бодай бөртеге һәм тегермән ташы» исемле романы автор тарафыннан эшләнеп җитмәгән килеш чыкты. Ә бит романның акыллы икәне, заманча икәне, татар әдәбияты өчен новаторларча булуы сизелеп тора, журнал вариантында аның телдәге шарадалары һәм эчпошыргыч озынлыклары да булмаса, әсәрне укучылар җәмәгатьчелеге тагын да әйбәтрәк кабул итәр иде.

«Казан утлары»— Татарстан Язучылар союзы органы, әдәбиятыбызның көзгесе, илебездә әле 1922 елда, Совет властеның беренче елларында ук, чыга башлаган әдәби-нәфис, иҗтимагый-политик калын журналларның берсе. Аның битләрендә әдәбиятыбыз корифейлары Г. Ибраһимов һәм Ш. Камал, Һ. Такташ һәм М. Җәлил, К. Тинчурин һәм Х. Туфан әсәрләре басылу үзе үк аның нинди югарылыкта торганын раслый. Шулай булгач, безгә аның авторитетын өзлексез күтәрергә, редакциянең яхшы эшләрен якларга, аның бүлекләрен кирәк булган саен, талантлы, тәҗрибәле редакторлар белән ныгыта барырга кирәк.

Бүген без кыю рәвештә бер нәрсәне әйтә алабыз: б у б и ш ь е л л ы к т а п р о з а ж а н р ы н д а п о в е с т ь а л г а к и л е п ч ы к т ы. Мускуллы, экспрессив, нигездә кыска (өч табактан биш табакка хәтле) повесть безнең өметләрне аклады, менә аның илебездәге җитди проза әсәрләре белән ярышырлыгы бар дип уйлый алабыз. Бу югарылык нигездә М. Мәһдиев, Ә. Баян, А. Гыйләҗев, В. Нуруллин, Х. Сарьян, М. Юныс, М. Галиев һәм башкалар тырышлыгы белән эшләнде. Барыбыз да яхшы беләбез, колхоз авылы хакында — сугыш вакытындагы һәм сугыштан соңгы авырлыклар турында — Мәһдиевкә хәтле дә повестьлар язылмый тормады. Ләкин аларның берсе дә Мәһдиев хәтле тирән катламнарга төшеп җитә алмады. Узган бишьеллыкта Мөхәммәт Мәһдиев авыл кешесенең рухи халәтен зур итеп ачып бирә ала торган тегәл детальләр табып кына калмады, әдәби телебезнең яңадан-яңа бизәкләрен ачу белән генә чикләнмәде, крестьян тормышындагы көндәлек кырыс реализм янына романтик биеклекне дә китереп ялгады, җир кешесенә хас шушы сыйфатларны аерым шәхесләр аша сурәтләп бирде.

Бүгенге заман прозасында Ә. Баян бик кыю һәм тайпылышсыз рәвештә эш алып бара. Аның геройлары кызыклы, яңа. Ул туктаусыз эзләнә, яңа формалар таба,

шартлылык алымын күпчелек очракта уңышлы кулланып, новаторлыкка омтыла, әмма кайбер тәнкыйтьчеләр аның ачышларына күз йомарга, аны күрмәскә азапланалар. Ә. Баянның телгә булган тигезсезлеге безне бераз борчый: вакыт-вакыт аның әсәрләренең теле җырлап тора, шигъри булып агыла, вакыт-вакыт ул телне никтер катлауландыра, андый чакта инде әсәр аңлашылмый башлый, тоныклана.

А. Гыйләҗев бу бишьеллыкта авыл тормышыннан ике повесть бастырып чыгарды: «Җомга көн кич белән» һәм «Әтәч менгән читәнгә». Шушы әсәрләре өчен ул Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды. Башка повестьларындагы кебек үк, автор бу ике повестенда да җир кешесенә булган ихтирамын җете буяуларда, төгәл сүзләр белән, темпераментлы итеп әйтеп бирә, авыл кешеләренең күңел матурлыгын зур итеп ача, ә «Әтәч менгән читәнгә» исемле сатирик повестенда виртуозларча җитезлек белән бүгенге авыл мещаннарын камчылый укучыларга аларның күңел фәкыйрьлеген, рухларының ярлылыгын ачып күрсәтә.

Сугыштан соңгы прозабызда без Р. Төхфәтуллинның лирик табигатьле ягымлы геройларына, кичке шәфәкъ төсле моңсу табигать күренешләренә соклана идек. Бүгенге заман татар прозасына Вакыйф Нуруллин документаль ныклык өстәде; М. Хәбибуллин фәнни-техник революция сулышын алып килде; ерак урман авазлары, сүзнең мәгънәлелеге һәм язу алымының тыгызлыгы белән М. Галиев үзенчәлекле әдип икәнен раслады; күптән түгел, съезд алдыннан гына, тәнкыйтьче Р. Мөхәммәдиев «Беренче умырзая» исемле яңа повестен «Казан утлары»нда бастырып чыгарып, укучыларга көтелмәгән бүләк ясады — чишмәләр, йолдызлар, бүгенге яшьләрнең кайнар тойгылары белән тулы бу повесть өлкән әдипләребезнең реалистик алымын бик матур дәвам итә; көнкүреш дәгъвалары, геройларның портретын бераз көлемсерәп, хәтта мин әйтер идем, дорфарак штрихлар белән сурәтләп, Р. Кәрами үз алымы белән килә; ике съезд арасында безнең прозага психологик төгәл ике повесте белән шагыйрь Г. Рәхим кушылды; «Бер ананың биш улы» һәм «Егет язмышы» повестьлары белән тел остасы Х. Сарьян безнең хәтердә калды; Ә. Гаффар, Р. Вәлиев, Ф. Яруллин, Ф. Гыйльметдинов — дүртесе дә яшь, энергияле һәм талантлы иптәшләр — чын мәгънәсендәге заманча повестьлары белән укучыларны шатландырдылар; М. Юныс үзенең повестьлары өчен материалны «диңгезнең тозлы җиленнән» тапты, ләкин аның иҗаты шушы көнгә кадәр бер генә тәнкыйтьче тарафыннан да җентекләп тикшерелмәгән. Озак еллар буена совет сәүдә флотында эшләү, океан лайнерларында төрле илләргә барып чыгу аңа бер генә авторда да булмаган үз материгын табарга ярдәм итте. Аның «Биектә калу» дигән символик исемле повесте Бөек Ватан сугышы дәверен укучылар күңелендә кабат яңарта, геройларының күңел сафлыгы, Ватанга бирелгәнлеге белән, курку белмәс батыр җаннары белән нәкъ менә бүгенге яшьләрне тәрбияләргә кирәкле уңай геройны тулы канлы итеп безнең каршыга китереп бастыра.

Бу бишьеллыкта повесть жанрында Л. Ихсанова, К. Тимбикова, М. Маликова, безнең арадан иртә китеп барган С. Сөләйманова уңышлы эшләделәр. Тел-стиль мәсьәләләренә игътибарсыз караган кайбер яшь авторлардан аермалы буларак, яшь прозаик Ф. Бәйрәмова «Болын» повестенда тел стихиясен яхшы белүе, дөньяны шигъри итеп күрә алуы белән яхшы якка аерылып чыкты.

Татар прозасы соңгы елларда, төрлерәк, баерак була бара. М. Әмир, Г. Бәширов, Ә. Еники, А. Шамовларның мемуар китаплары, С. Хәкимнең заманыбызның күренекле шагыйре Хәсән Туфан турындагы истәлекләре, М. Насыйбуллин, Ф. Фәтхетдинов, Р. Ишморатова, Ә. Мушинскийның композицион төзек һәм мавыктыргыч итеп корылган маҗаралы повестьлары яшьләргә тормыш хакында ныклап уйларга, фикер йөртергә, узган белән бүгенгене чагыштырып карарга мөмкинлек бирә.

Хикәя жанры ике съезд арасында әллә ни зур уңышка ирешә алмады. Әле мыек та чыкмаган яшь авторлардан башлап өлкән яшьтәге прозаикларыбызга тикле без барыбыз да зур полотнолы әсәрләр белән мавыктык. Ш. Камал, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, М. Гафури кебек классикларыбызның хикәя осталарының традициясен үз вакытында А. Шамов, М. Әмир, Г. Галиев, Ф. Хөсни, М. Шабай, И. Гази алып барганнар иде. Ибраһим Гази, мәсәлән, җитмешенче елларда «Тургай да картаямы?», «Алсу томаннар артында», «Сарбай — сары эт» исемле кыска хикәя-җәүһәрләрен иҗат итеп калдырган иде. Аңардан соң хикәя жанрын, ихтимал, чын мәгънәсендә олы

итеп алып барган әдип Ә. Еники булгандыр. Аңа быел хикәяләр һәм повестьлар җыентыклары өчен Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелүне укучылар да язучылар җәмәгатьчелеге дә хуплап каршы алдылар. Бу бишьеллыкта да аның «Тынычлану» хикәясе әлеге жанрдагы иң яхшы әсәрләрдән санала. Г. Бәшировның «Сарут» хикәясен дә тәнкыйтьчеләр уңай бәяләде. Ике хикәя дә әхлак мәсьәләләренә багышланган, сәнгатьнең югары законнарына нигезләнеп язылган. Бу өлкәдә армый-талмый эшләгән тагын бер язучыны, авыл тормышын бик яхшы белгән Гариф Галиевне аеруча әйтеп китәргә кирәк дип саныйм. Ел саен, инде яше олы булуга карамастан, ул үзенең туган-үскән яклары Азнакайга кайтып килә, документаль ныклык белән язылган, кеше күңеле тибрәнешләренең яңа якларын тотып алган тормышчан хикәяләр иҗат итә. Безнең республикада яшәп, әсәрләрен русча язган авторлардан Т. Журавлев, Р. Кутуй, М. Рафиков, М. Скороходов бу бишьеллыкта да хикәя жанрына лаеклы өлеш керттеләр.

Әдәби процессның барышы хикәя жанрының безгә әдәби осталыгыбызны арттыру өчен дә кирәк икәнен исбатлады. Чөнки хикәя мәктәбен узмаган яшь авторлар күпчелек очракта композицион таркау, тел ягыннан зәгыйфь повестьлар һәм романнар иҗат итә башладылар.

Әдәби практикабызны җентекләп өйрәнү безгә тагын бер нәтиҗә ясарга хокук бирә: алга таба татар прозасында лирик, кайнар тойгылы экспрессив повестьлар белән бергә эпик роман да бертигез дәрәҗәдә үсәчәк.

Фикеремне илебездәге милли әдәбиятларның зур белгече, СССР Фәннәр Академиясенең член-корреспонденты Г. И. Ломидзе сүзләре белән беркетәсем килә. Бу хакта ул менә нәрсә диде:

«Әгәр без төрки телләрдә иҗат итүче олы әдипләр иҗатына мөрәҗәгать итсәк (М. Әуэзов, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, К. Нәҗми, Г. Бәшировтан башлап 31 исем китерелә — Г. А.), аларда без бер закончалыкны — озак вакыт эчендә һәм зур пространствода эпик колач белән сабыр гына хикәяләүне күрәбез. Лирик тәүбә, ялангач эмоциональлек, ассоциатив проза, экспрессив романтик шашкынлык күпертү-кабартулар аларга кагылмый диярлек. Аларның әсәрләре кеше күңеленә юнәлтелгән, кеше характерының һәм тарихи вакыйгаларның үсешен эзлекле рәвештә тасвирлауга корылган... Төрки телләрендә иҗат итә торган әдипләрнең күбесенең реалистик эпик алымга турылыклы булулары менә нәрсә белән аңлатыла: бу әдәбиятлар әле тарихи танып-белү функцияләрен үтәп бетермәделәр, шартлы рәвештә әйткәндә, үз милләтләренең узган юлын дөньяга тулысынча сурәтләп бирмәделәр әле». («Бөтенсоюз фәнни конференция материаллары», Казан, октябрь, 1978 ел, рус телендә).

Күргәнебезчә, галим үзенең фикерен бик нигезләп әйткән. Соңгы елларда казакъ, үзбәк, кыргыз, төрекмән, башкорт телләрендә, шулай ук Балтик буе республикаларында тарихи пландагы киң колачлы, зур сулышлы романнар иҗат ителә. Моның сәбәпләре билгеле: узганнарны без әле сыйнфыйлык һәм тарихилык карашыннан чыгып ачыклап бетермәдек. Безгә әле бу нисбәттән бик күп эш эшләргә, тарихтагы тирән тамырларыбызны табарга, дөнья тарихында тоткан урыныбызны ачыкларга кирәк. Н. Фәттахның «Этил суы ака торур» һәм «Сызгыра торган уклар» исемле романнары безнең бу өлкәдәге бушлыкны беркадәр тутыралар.

Халыкларыбызның ерак узганына күз салу, шул гасырларны сәнгать чаралары белән эпик әсәрләрдә сурәтләп бирү безгә Бөек Октябрь социалистик революциясенә нинди рухи байлык белән килгәнебезне ачыклау өчен дә кирәк. Патша заманасының иң кара, иң реакцион елларында да халык үзенең күңел байлыгын ничек саклап кала алган? Халыкның Тукайларын нинди көч тудырган? Такташлар, Сәйдәшләр, Җәлилләр һәм Туфаннар безнең борынгы үткәнебездән үз арсеналларына нәрсә алганнар? Мулланур Вахитов, Галимҗан Ибраһимов, Камил Якуб кебек революционерларыбыз турындагы романнарны, Идел-Кама буйларын интервентлардан, ак адмирал Колчактан һәм башка килмешәкләрдән азат итү эпопеясен социаль тетрәүләр һәм политик конфликтлар, буржуаз-алпавытлар хакимлеген юк итү фонында, халык массаларының күпләп катнашуын сурәтләү аша гына иҗат итеп була. Егерменче гасырның даһи художнигы Михаил Александрович Шолоховның вафат булуына бөтен дөньяның чамасыз кайгыруы «Тын Дон» эпопеясенең мәңгелеккә калачагын исбатлады. Без яшь язучыларны кабартылган-күпертелгән ашыгыч повестьлар язуга түгел,

рус һәм дөнья классикасы, алдынгы совет язучыларының иң яхшы әсәрләре үрнәгендә монументаль проза иҗат итүгә юнәлдерергә тиешбез.

Совет җәмгыятенең бүгенге үсеш этабы язучы хезмәтенә зур таләпләр куя. Бу исә культурабыз үсү, кешеләрнең рухи таләпләре арту, тормышның көннән-көн катлаулана баруы, идеологик көрәшнең кискенләшүе, җәмгыять тормышында әдәбиятның роле арту белән бәйләнгән.

Ике съезд арасында татар әдәбиятында документаль нигездә язылган әсәрләр арта төште, бу исә тормыш белән бәйләнешнең артуын раслый. Отчет чорында татар әдәбиятының тормышчанлыгын, аның югары иҗтимагый активлыгын, халык тормышының барлык проблемаларына игътибарлы булуын публицистика жанры көчәю әйтеп тора. Үзебезнең һәм үзәк нәшриятларның ел саен зур йөк автомобильләрен төзүчеләр, нефтехимиклар турында махсус китаплар бастырып чыгаруын әйтү дә җитә. Бөтенсоюз удар төзелешләрнең, нефтьчеләр һәм химикларның елъязмасын алып барган М. Зарипов китаплары моңа мисал була ала. Зариповларның өлкәне — Изаил Зарипов хакында да җылы сүз әйтү урынлы булыр. Ул инде менә ничә еллар Себер нефтьчеләре арасында яшәп, бу промыселларда батырлык үрнәге күрсәткән якташларыбыз хакында Төмәннән һәм Уренгойдан очерклар язып, «Казан утлары» һәм башка журналларда, газеталарда бастырып килә.

Публицистика һәм очерк отчет чорында халыкның сугыштагы һәм хезмәттәге батырлыгын чагылдыру буенча магистраль юлдан барды. Моңа мисаллар байтак. Ш. Рәкыйпов, үз иҗатына Бөек Ватан сугышы геройларын документаль нигездә сурәтләүне сайлаган әдип, бу бишьеллыкта «Зәңгәр күктә карлыгачлар» исемле документаль-нәфис китап язды. Мавыктыргыч итеп, кызыклы сюжетларга корып язылган бу китап, авторның моңарчы иҗат иткән башка китапларыннан аермалы буларак, сугышта һәлак булган татар халкы улларын гына түгел, төрле халыкларның улларын сурәтли, «бердәм гаилә тойгысын» зур итеп ача. Минем уемча, бу китап рус телендә дә басылып чыгарга лаек. Мин Ш. Рәкыйповның документаль китаплары барысы да бердәй тигез осталык белән язылган дип санамыйм, сәнгатьчә дәрәҗәләре аларның төрлечә, әмма документальлек ягына автор үзенең әдиплек фантазиясен дә китереп кушкан чагында, сугышта һәлак булганнар безнең каршыга барлык олылыгы белән, тере булып килеп басалар.

И. Низамов, шулай ук иҗатына төп жанр итеп документальлекне сайлаган, СССР Язучылар союзына членлыкка публицист һәм очеркист буларак кабул ителгән автор, бу бишьеллыкта «Ул кабызган маяклар» исемле тирән эчтәлекле китап язды. Китапның нигезенә тарихи факт — В. И. Ленинның 1900 елны Нижний Новгородтан, Казан губернасы аша, Уфага баруы, юлда «Искра» газетасына хәбәрчеләр туплавы алына. Хәзер шушы маршрут буйлап очеркист килә. Ул үзе һәм укучылар өчен яңарган авылларны һәм калаларны, танымаслык булып үзгәргән Идел буйларын сурәтли, бөек юлбашчыбыз хыялланганнарның гамәлгә ашуын татар халкы язмышында калку итеп сурәтләп бирә. Ильич образы заман геройлары аша, аларның уй-тойгылары аша ачыла.

Алгарак узыйк. Хезмәт вазифасын фидакарьләрчә үтәгән чакта вафат булган солдат хакында Рәзил Вәлиев кече форматлы, әмма ут сулап торган кайнар тойгылы повесть иҗат итте, әсәр республикабызның М. Җәлил исемендәге комсомол премиясенә лаек булды, русчага тәрҗемә ителде, аны быел ВАПП социалистик хезмәттәшлек илләрендә — ГДРда, Венгриядә, Болгариядә бастырып чыгару өчен тәкъдим итте.

Безнең очеркистлар ярдәме белән Арча районының «Искра» колхозы председателе, үз авылларында 40 ел буена председатель булып эшләгән Ф. Галиев «Икмәк язмышы» дигән китап язды, ул «Казан утлары»нда басылды, аерым китап булып чыгып килә. С. Шакир, Р. Хисмәтуллин, Равил Вәлиев, Р. Ишморат, Р. Ишморатова, М. Елизарова, Д. Зөбәерова, Э. Касыймов, Г. Иделле, М. Скороходов очерк китаплары бастырдылар; А. Гыйләҗев «Казан утлары»нда нефтьчеләргә багышланган монументаль очерк игълан итте; Н. Орешина, бүгенге заман пилотлары белән бергә бик күп очышларда катнашып, алар турында, очучылык эше проблемалары турында

«Правда» битләрендә дәвамлы рәвештә очерклар бастырып барды; М. Әмирнең, С. Хәкимнең, Г. Бәшировның, Ә. Еникинең, Т. Журавлевның һәм башка авторларның сайланма әсәрләрендә очерк һәм публицистика зур урын алып тора.

Отчет чорында иң нык игътибар үзәгендә булган жанр: ихтимал, очерк һәм публицистикадыр. Идарә бу бишьеллыкта Язучылар союзы каршысында тугызынчы иҗат секциясе — очерк һәм публицистика секциясе оештырды. М. Зарипов җитәкләгән бу секция «саф» очеркистларны гына түгел, башка жанрларда эшләүчеләрне дә узган көннәрнең һәм заманыбызның актуаль темаларына юнәлдерде.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, документаль жанрга җан керде, әдәбиятка ул хәзер кирәкле сугышчан тон бирә. Ләкин без әле моны хәзерге шартларда эшнең башы гына дип саныйбыз. Чөнки тормыш катлаулы, күп яклы, аның ритмы ашкындыргычрак, сабырсызрак була бара. Моны узган ел авылның социаль үсеш-үзгәрешләренә багышлап үткәрелгән партия өлкә комитеты пленумы ачык күрсәтте. КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре иптәш Г. И. Усманов докладын тыңлагач, игенче хезмәтенә зур ихтирам белән оештырылган искиткеч әйбәт күргәзмә белән танышкач, бер уйга киләсең: гомер-гомергә халык кайгысының, тарихи фаҗигаләренең шаһите булып килгән бөек Идел һәм Кама дәрьялары хәзер бу якларда үзгәргән тормышның, елга тугайларында үсеп чыккан Культура сарайларының, торак йорт массивларының, терлек каралтыларының, «Юбилейный» «Актаныш» кебек яңа заман поселокларының шаһите булып әверелделәр.

Хәзер безнең бурыч — авылны рухи азык белән баету.

Язучылар оешмасының бөек төзелешләргә, промышленность предприятиеләренә, колхоз-совхозларга шефлык итүе, «Казан утлары» журналы редакциясенең Татарстан атом электр станциясендә үз әдәби постын булдыруы билгеле бер нәтиҗәләргә китерде — очерк һәм публицистика өчен генә түгел, зур күләмле проза, поэзия, драматургия әсәрләре өчен дә тормыштан материал сайлап алынды. Әгерҗе, Арча, Актаныш, Буа, Питрәч, Мамадыш районнары соңгы елларда әдипләрнең дусларына әйләнделәр, тормышлары белән безне бик теләп таныштырдылар. Безгә тормыш белән бәйләнешнең бу формасын алга таба да көчәйтергә, аның эчтәлеген, формаларын баетырга кирәк булыр. Без экономик, социаль үсешнең, илебезнең оборона куәтен арттыруның заман таләпләре куйган югарылыгында булырга тиешбез.

Ике съезд арасында безнең шагыйрьләребез тематик яктан киң планда, шигъри алымнар ягыннан төрле формаларда илһамланып иҗат иттеләр. Гәрчә без бу бишьеллыкта поэзиягә Юзеевләр, Афзаллар, Фәйзуллиннар, Әгъләмовлар кебек бөтен бер буынның килүен, яңа «поэтик шартлаулар» булуын күрмәсәк тә (әлеге термин IX съезд трибунасыннан күп әйтелде), татар совет поэзиясе күпмилләтле совет поэзиясе аккан елга үзәненнән зур ышаныч белән, тулып-ташып акты. Безнең поэзиядә төрле шигъри алымнар, юнәлешләр булды, үзенчәлекле поэтик шәхесләр эшләде. Поэзиянең иң яхшы әсәрләренә чынбарлыкның мәңгелек проблемаларын философик фикерләү, социалистик җәмгыятьнең рухи бөтенлеген, гармоник үсешен сурәтләү хас булды.

Өлкән шагыйребез С. Хәким бу бишьеллыкта да активлыгын киметмәде. Күп санлы шигырьләр һәм җыр текстлары белән бергә, ул ике поэма иҗат итте. «Эзлиләр Европа буйлап» һәм «Күги» поэмалары, гәрчә традицион классик алымда язылсалар да, икесе дә яңа, новаторларча, узган сугышның фәлсәфи эчтәлеген, аның каһарманнарын көчле гәүдәләндерәләр. Безне бер нәрсә аеруча шатландыра: С. Хәким поэзиядә һаман алгы сафта, Тукай, Такташ, Җәлил, Туфан эстафетасын ул намус белән, ир-егетләргә хас ныклык белән дәвам иттерә.

Бу съездда инде Хәсән Туфан катнашмый, ул безнең арабыздан китте. Әмма ул безнең өчен Ватанга, туган халкыңа, әдәбиятыңа хезмәт итүнең югары үрнәге булып калачак. Еллар узар, без бу искиткеч тыйнак кешенең шигъри батырлыгын, аның күп яклы кабатланмас поэтик шәхесен тирәнрәк аңларбыз. Аның бер үк вакытта моңлы да, трибун да поэзиясенең дөньякүләм әһәмиятен күбрәк төшенербез. Туфан шигърияте киләчәк буын кешеләрне гаделлеге, гуманистик юнәлеше, канатлы фикерләре, хисләренең кайнарлыгы һәм чынлыгы белән дулкынландырып торыр. Хәзер ул Тукайлар, Такташлар, Җәлилләр янына килеп басты!

Икенче бер өлкән шагыйребез Н. Арслан бу бишьеллыкта тарихка мөнәсәбәтен

һәм киләчәккә булган якты өметләрен Көнчыгыш классикасы регионындагы шагыйрьләр алымы белән әйтеп бирде. Ә. Исхак, галимнәр М. Усманов һәм Ф. Фасеев белән бергәләп Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасын аерым китап итеп әзерләде. З. Нури, М. Садри, Г. Афзал, Х. Камалов, Г. Латыйп, Н. Дәүли, Ә. Маликов, Э. Мөэминова, күп еллык иҗатларын туплаган китаплар бастырдылар; «Шигырь китапханәсе»ндә И. Юзеев, Ш. Галиев, Ә. Баян, М. Шабаев, Р. Фәйзуллин, С. Сөләйманова китаплары дөнья күрде. Болар барысы әйбәт, боларны хупларга кирәк, чөнки болар сугыштан соңгы буынның һәм алтмышынчы елларда поэзиягә килгән буынның инде сайланма әсәрләр чыгарырга хакы барлыгын әйтеп тора. Әмма шуны истән чыгармаска кирәк, әдәбият, тулаем алганда, бүгенге тормыш белән яши, аның тамырлары бүгенге көн туфрагыннан дым ала. Әнә шул яктан караганда безнең поэзия планетаның глобаль проблемаларына йөз тотуы белән, күпмәгънәле эчтәлеген иҗтимагый ситуацияләр, юнәлешләргә бәйле рәвештә, җәмгыятьнең идеологик, этик, эстетик интересларына бәйле рәвештә үзгәртә һәм баета баруы белән аеруча мөһим эш эшләде. Ике съезд арасында 20 поэма язылу да безнең фикерне бик әйбәт раслый: шуны әйтергә кирәк, поэмалар арасында, эпик проза жанрыннан аермалы буларак, бер генә дә җиңелчә язылган әсәр юк. Поэзиягә сукадан килгән, тарихи вакыйгаларның шаһите булган С. Хәкимнән, поэма жанрына үзеннән иң күп өлеш керткән И. Юзеевтән, алтмышынчы еллар вәкилләре Р. Гатауллин, Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Г. Рәхим, Ә. Рәшитовлардан алып, җитмешенче еллар буыны Зөлфәтләргә, Әгъләмовларга, бүгенге яшьләргә тикле поэмага үз өлешләрен керттеләр. 20 поэманың барысын бергә алып караганда, аларның зур бер күмәк рухи халәт барлыкка китерүен, фикерне һәм тойгыны дәвамлы итеп сурәтләвен күрү кыен түгел. Шагыйрьләребезнең вакыт һәм пространство белән акыллы эш итүләрен күрү аеруча күңелле хәл. Бу поэмалар социалистик реализм методы әдәбиятының мөмкинлеге нинди зур, арсеналы нинди киң, сәнгать чаралары нинди чиксез икәнне тагын бер мәртәбә расладылар.

Шагыйрьләр сафын барлауны дәвам итәбез. Р. Гәрәй, К. Сибгатуллин, Роберт һәм Рәшит Әхмәтҗановлар, К. Булатова, Ш. Маннапов, Г. Нәбиуллин, М. Рафиков, З. Мәҗитов, Р. Рәкыйпов, Н. Мадъяров, М. Галиев, Ә. Гадел, М. Газизов, З. Насыйбуллин, Х. Әюпов, З. Мансуров, Р. Юнысов, Р. Низамиев, Х. Гайнетдинов яңа шигырьләр язып, җирне, табигатьне олыладылар, халкыбызның сугыштагы һәм хезмәттәге батырлыгына дан җырладылар. Яшь шагыйрь Р. Закировның «Шахтер моңы» исемле беренче шигырь җыентыгын аеруча билгеләп узуны кирәк табам, бу — поэзиябез өчен яңа, өмет баглата торган китап.

Шагыйрьләрнең күмәк җырында хатын-кызларның тавышы елдан-ел ачыграк ишетелә. Ф. Гыйззәтуллина, С. Гәрәева, Р. Вәлиева, Р. Хәлиуллина, Н. Измайлова, Л. Шакирҗановаларның СССР Язучылар союзына бу бишьеллыкта член итеп алынулары да шул хакта сөйли. Отчет чорында үз иҗатларына игътибар иттергән яшьләр арасында Э. Шәрифуллина, А. Минһаҗева, Э. Блинова, Ф. Низамова, И. Лимонова, Г. Моратов, Н. Акмалов, Л. Зөлкәрнәев, Н. Әхмәдиев, Б. Рәхимовалар бар.

Җыр поэзиясе аерым сөйләшүне таләп итә. Бу өлкә зур, күп яклы. Биредә мин бер генә нәрсәне әйтү белән чикләнәм: җыр жанрында бу бишьеллыкта С. Хәким, И. Юзеев, Ш. Галиев, Г. Зәйнашева, М. Хәсәен кебек тәҗрибәле әдипләр, җыр осталары белән бер рәттән Н. Дәүли, Р. Байтимәров, Р. Гатауллин, Р. Фәйзуллин, Р. Вәлиев, Ш. Маннапов, Ф. Сафин аеруча күп һәм нәтиҗәле рәвештә эшләделәр.

Бүгенге заман җырында хәл ителмәгән мәсьәләләр байтак. Безгә «Карурман», «Олы юлның тузаны», «Гөлҗамал» кебек киң сулышлы, тирән эчтәлекле җырлар кирәк. Җыр текстларының гражданлык һәм патриотлык ягын көчәйтәсе бар. Г. Афзалның «Газинур турында баллада»сы, С. Хәкимнең «Күңелем Ленин белән сөйләшә» җыры, Роберт Әхмәтҗановның сугыш реквиемы, Р. Фәйзуллинның «Аккошлар»ы, И. Юзеевның «Бөркет турында баллада»сы, Г. Зәйнашеваның «Менәсе иде Урал тауларына» кебек зур популярлык казанган җыры, Х. Туфан, М. Ногман сүзләренә Р. Яхин иҗат иткән һәм халыклашкан җырлар шундыйлардан иде. Көчле рухлы яңа җырлар иҗат итү өчен узган этапка әйләнеп карау да кирәктер дип беләм.

Ике съезд арасында безнең драматургия зур уңыш ялады. Ә бит әле күптән түгел, ун-унбиш ел элек кенә безнең драматургия ил күләмендәге уңышлардан артта бара дип санала иде. Үсешкә нәрсә сәбәпче булды соң? Күренекле өлкән драма-

тургларыбыз Н. Исәнбәт, Р. Ишморат, М. Әмир, Ю. Әминов, Х. Вахит, Ш. Хөсәеновлар белән бергә тормышны һәм сәхнәне яхшы белгән яңа буын драматурглар эшли башлады. Барыннан да элек Туфан Миңнуллинны күрсәтергә кирәк. Соңгы ун ел эчендә ул, классик драматургиябезнең иң яхшы традицияләрен дәвам иттереп, новаторлыкка чыкты, акыллы һәм тирән эчтәлекле, юморга бай үткен телле үз театрын тудырды. Аның «Әлдермештән Әлмәндәр», «Ай булмаса, йолдыз бар», «Моңлы бер җыр» пьесалары драматургиябезне яңа сыйфатлар белән баеткан әсәрләр дип икеләнмичә әйтә алабыз.

Диас Вәлиев драматургиясе ил күләмендә танылды. Мәскәүдә аның пьесалары рус телендә, Казанда каләмдәшләренең тәрҗемәсендә татар телендә басылып чыктылар. Д. Вәлиев пьесаларының төп юнәлеше гражданлык хисе белән бәйле; тамаша залы белән ул зур социаль-әхлакый проблемалар хакында сүз алып бара. Аның пьесаларын илебезнең күп кенә театрлары куйды, барыннан да элек — башкаланың М. Н. Ермолова исемендәге театры аны илгә танытты.

Безнең драматургиягә талантлы шагыйрь И. Юзеев шигъри саф агым өстәде, поэтик драматургия жанрын нигезләде; Аяз Гыйләҗев персонажлар сөйләмендәге халыкчанлыкны, үткенлекне, мәгънә төсмерен тирәнәйтте; Батулла, Р. Мингалим, Р. Хәмид, Ә. Гаффар һ. б. драматургияне яңа бизәкләр, яңа геройлар белән баеттылар, сәхнәгә заман сулышы алып килделәр.

Драматургиябезгә нәрсә җитми? Тормышны зур итеп колачлап алу, хезмәт кешеләрен сәхнәгә күтәрү, истә калырдай уңай герой җитешми. Әйтик, Т. Гыйззәтнең «Ташкыннар»ындагы чабаталы Биктимер, М. Әмирнең «Миңлекамал»ындагы батыр йөрәкле, булдыклы, нык куллы җитәкче Миңлекамал юк. Миңа каршы килүләре мөмкин: Т. Миңнуллинның халыкчан юморга бай бөек оптимисты, туксан яшьлек Әлмәндәр бар бит, ул авторына һәм Академтеатр эшлеклеләренә РСФСРның К. С. Станиславский исемендәге Дәүләт премиясен алып бирде бит, дип әйтүләре ихтимал. Әйе, болар дөрес. Бу — безнең казаныш. Ләкин бит Әлмәндәр ялгыз, аның янына картның үзе төсле үк кыю, үзе төсле үк шат күңелле яшь герой кирәк, яшьләрне үзе артыннан алып китәрдәй баһадир кирәк. Миңа калса, безнең сәхнәдә заман герое әле тулы канлы булып гәүдәләнми, бигрәк тә халыкара темаларга үткен политик спектакльләр җитешми. Андый әсәрләрнең кирәклеген К. Әмировның әфган халкының тормышын һәм ирек өчен көрәшен гәүдәләндергән «Зөлфия» спектакле исбат итте. Аны илебез театрлары куя башлады. Оригиналда ул әдәби эшләнеше ягыннан кайтышрак булса да, театр белгечләре аны арсеналга алырга булдылар, тәрҗемәсендә сәнгатьчәлеген эшкәртеп җиткерделәр.

Тагын бер нәрсәне басым ясап әйтергә кирәк: әле күптән түгел генә без пьесаларыбызның көнкүреш ваклыгыннан, гаилә гаугаларыннан арынмавына үкенә идек, дөнья күләмендәге проблемаларны күтәрүләрен таләп итә идек. Хәзер андый әсәрләр юк дип әйтә алмыйбыз. И. Юзеевның шигырь белән язылган куәтле трагедияләре инде ничә ел сәхнә көтеп яталар. И. Юзеев глобаль масштабта карурманнар, хаташ диварлар, мәңгелек тынлык белән сөйләшә. Кешелек дөньясының язмышы хакында сүз алып бара. Аның Тукайга, Җәлилгә багышланган трагедияләре дә игътибарга лаек. Әмма аларны сәхнәгә Татар дәүләт Академия театры яки Казанның зур рус драма театры гына куя ала. Өлкән драматург Р. Ишморат та отчет чорында Тукайга багышлап киң масштаблы драма иҗат итте, тик аның белән бер режиссер да кызыксынмады. Сәбәбен сорасаң, сәхнәчә түгел, диләр. Ләкин бу, миңа калса, котылу өмәле генә. Сәхнәчәлекне төш юрау белән чагыштырырга мөмкин, зирәк карчыклар әйтмешли, төшнең муены нечкә, кай якка борсаң, шул якка борыла ала.

Безгә яшь тамашачылар, балалар һәм курчак театрлары өчен ныклы репертуар кирәк. Балалар драматургиясе өлкәсендә эшләгән Р. Батулла белән Н. Дәүлигә хуплаарга, Р. Мингалимнең балалар пьесасын илебез сәхнәсенә алып чыгуын аеруча басым ясап күрсәтергә кирәк. Музыкаль драматургияне үстерү юлында да җиң сызганып эшлисе бар әле. Һәркемгә мәгълүм, музыкаль драматургия шагыйрь белән композиторның дуслыгыннан башлана. Җәлил белән Җиһанов, Исәнбәт белән Җиһанов, Гыйззәт белән Фәйзи кебек, бер-береңне эзләргә, бер-береңә омтылырга кирәк. Соңгы елларда Гәрәй Рәхим белән Бату Мулюков бер-берсен таптылар. Аларның беренче җитди хезмәтләре — «Каһәрләнгән мәхәббәт» операсы — уңыш казанды.

Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды. Кайчандыр шагыйрь Зөлфәт белән композитор Хәйретдинова балалар өчен кызыклы опера иҗат иткәннәр иде. Талантлы бу авторларга узганны искә төшереп, яңа операга тотынырга вакыт җитте шикелле.

Тәнкыйтьне гадәттә әдәбиятның намусы дип йөртәләр. Ләкин ун-унбиш ел буена әдипләр арасында бер фикер яшәп килде: безнең ул «намусыбыз» татлы йокыда утырмыймы? Еллар буена иҗат иткән әсәрләребез тәнкыйтьтән читтә калмыймы? Әгәр без агымдагы тәнкыйтьне әдәбият белеменнән аерып карамасак, аларның икесен бер бөтен итеп алсак, бу бишьеллыкта тәнкыйтьчеләребез белән әдәбият белгечләребез икесе бергәләп гаять зур йөк күтәрергә сәләтле икәннәрен исбатладылар. Татар әдәбияты тарихының алты томлыгы, татар халык иҗатының унике томлыгы, Кол Галинең 800 еллыгына һәм аның үлемсез поэмасы «Кыйссаи Йосыф»ка багышланган фәнни конференция — барысы да алар тарафыннан әзерләнде. Шулар янына тагын татар театры тарихына караган зур һәм җитди хезмәтне, аңлатмалы сүзлекне, Тукай, Гафури, Камал, Такташ, Нәҗми, Фәйзи һәм башкаларның күп томлыкларын әзерләүне өстәсәк, әдәбиятчы-галимнәребез, тәнкыйтьчеләребез башкарган хезмәтнең зурлыгы тагын да арта төшәр. СССР Фәннәр Академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты коллективы боларның барысын Татарстан китап нәшрияты белән бергә башкарды, безнең нәшриятта борынгы һәм хәзерге әдәбиятны яхшы белә торган эрудицияле, тәҗрибәле редакторлар җитешә.

Ике съезд арасында аерым зур хезмәтләр дә дөнья күргән. М. Хәсәновның Г. Ибраһимовка багышланган нигезле зур монографиясе, Н. Юзиевнең татар шигырь поэтикасына багышланган хезмәте, Н. Хисамовның «Кыйссаи Йосыф» поэмасы хакында үзәк нәшриятта чыккан китабы, Т. Галиуллинның, Ф. Мусинның бүгенге заман әдәби проблемаларын яктырткан җыентыклары, А. Әхмәдуллинның драматургиябез хакында Мәскәүдә русча чыгарган китабы, Ф. Миңнуллинның прозаның гражданлык йөзе турындагы хезмәте, М. Гайнуллин, Х. Хәйри, Г. Халит, И. Нуруллин, Б. Гыйззәтнең әдәбият тарихына багышланган тикшеренүләре, Р. Мостафинның мәкаләләр җыентыгы, Ф. Мусинның «Правда» битләрендә әледән-әле басылып килгән оператив мәкаләләре, Э. Нигъмәтуллин, Ф. Галимуллин, Р. Мөхәммәдиев, Мансур Вәлиев, яшьрәк тәнкыйтьчеләрдән С. Маннапов, Ф. Зөлкарнәев һәм башкаларның җитди уйланып язылган мәкаләләре соңгы елларда әдәби тәнкыйтьнең һәм әдәбият белеменең җанлануын әйтеп торалар. Моңа, әлбәттә, КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карары да зур һәм уңай йогынты ясады. Ике съезд арасында тәнкыйтьчеләребез һәм әдәбият белгечләребезнең фәнни-тикшеренүләре, монографияләре, мәкалә җыентыклары 59 исемдә басылып чыккан. Аларда теоретик базаның ныгуы, марксистик-ленинчыл методологиянең киң кулланылуы, югары уку йортларында белем алган яшьләрнең артуы, проза, поэзия, балалар әдәбияты китапларының, спектакльләрнең башка бишьеллыкларга караганда сан ягыннан күбрәк бәяләнүе күзгә ташлана.

Безнең ике иптәшебез — Т. Галиуллин белән Ф. Мусин — отчет чорында уңышлы рәвештә докторлык диссертациясе якладылар, фән кандидатлары да артты.

Тәнкыйть һәм әдәбият белеменең үсеше өчен кирәкле шартлар тудырылу алга таба бу жанрда эшләүчеләргә зуррак бурычлар йөкләргә дә мөмкинлек бирә. Бу, барыннан да элек, агымдагы тәнкыйтькә кагыла. Укучы проблемалы мәкаләләрнең күбрәк булуын, чын мәгънәсендә тирән эчтәлекле, кызыклы бәхәсләргә юл ачылуын таләп итә. Бездә соңгы елларда комплиментарлык кимеде, аның каравы барлык әсәрләрне бергә тезеп яманлау арта төште. Бу хәл безнең тәнкыйтьчеләр ил матбугатында мәкаләләр белән чыккан чакта аеруча сизелә. Андый мәкаләләрне укыгач, татар әдәбиятының үсеме-юкмы, үссә нинди юнәлештә үсә икәнен дә аңлау кыен. Рецензияләү практикасы да хәзергә безне шатландыра алмый, анда очраклылык шактый нык хөкем сөрә, тәнкыйтьчеләр еш кына икенче, өченче дәрәҗәдәге әсәрләрне сәнгатьчә югары язылган әсәрләр белән янәшә куялар, яки яхшы әсәрләрне онытып калдыралар.

Тәнкыйтьнең сугышчан бурычы — яңа әсәрләргә шундук бәя бирү, сәнгатьчә көч-ле язылган, югары идеяле, тирән эчтәлекле әсәрләребезне пропагандалау, сәламәт һәм бай әдәбиятыбыз тәненә чир булып ябышкан халтураны, төссез соры әсәрләрне үз вакытында фаш итү, яңага юл ачу.

Балалар әдәбиятының уңышлары поэзия өлкәсендә күбрәк булды. Отчет чорында Шәүкәт Галиевкә Г. Х. Андерсен исемендәге Халыкара Почетлы диплом тапшыру, дөресен генә әйткәндә, балалар һәм үсмерләр әдәбияты өлкәсендә эшләүчеләргә карата ихтирамны арттырды. Ш. Галиевнең үз иҗаты, аның шигырьләрендәге көязшлы юмор, тапкырлык, ритмикадагы тигезлек һәм поэтик аһәң, ул иҗат иткән геройлар — Шәвәли һәм Котбетдин — балалар әдәбияты өлкәсендә эшләүче бик күпләргә үрнәк булды. Әгәр без драматургиядә Туфан Миңнуллинның классик драматургия алымнары аша новаторлыкка чыгуын билгеләгән булсак, балалар әдәбиятында Шәүкәт Галиевнең Тукай, Фәйзи, Рәхмәт традицияләрен үзләштереп, бер генә әдипне дә кабатламаган үзенчәлекле балалар дөньясы тудыруын әйтә алабыз.

Кайчандыр, революциядән соң, без шатланып һәм горурланып илебездә саф балалар язучылары үсеп чыгуын әйтә идек. Бу барлык совет әдәбиятында уникаль күренеш иде. Хәзергесе көндә саф балалар язучылары күп түгел. Үз иҗатында кызыклы сәяхәтләр жанрын иҗат иткән Л. Ихсанова, иҗатын тулысынча фантастикага багышлаган А. Тимергалин, фәнни фантазия, әкият, маҗара жанрын алып баручы С. Радзиевская, табигать бизәкләрен Абдулла Алиш үрнәгендә ихлас сурәтләгән Г. Хәсәнов бу бишьеллыкта да күп эшләделәр, яхшы әсәрләр иҗат иттеләр. Соңгы елларда укучылар арасында киң танылган Роберт Миңнуллин поэзиясе игътибарга бик лаек. Аның иҗаты республика комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясенә лаек булуы да моны раслый. Үзенчәлекле, көяшлы, юморга бай шигырьләре белән Р. Миңнуллин балалар әдәбиятында ялган да, кылану да, тормышны бозып ясап күрсәтүләр дә, стандарт та булмаска тиешлеген исбат итте. Шундый ук юнәлеш Х. Халиковка да балалар өчен чын шигырьләр иҗат итәргә булышты.

Балалар шагыйрьләре Н. Гайсин, Ә. Бикчәнтәева, Җ. Тәрҗеманов, М. Фәйзуллина, Р. Вәлиева, юбилейларына багышлап, йомгак китаплары бастырып чыгардылар. Нигездә балалар әдәбияты өлкәсендә күп эшләгән К. Латыйпов, М. Мазунов СССР Язучылар союзы члены булып алындылар.

Балалар һәм үсмерләр әдәбиятының проза өлкәсендәге уңышлары күп түгел. Мәктәп һәм укучылар, педагоглар тормышыннан әсәрләр, үкенечкә каршы, юк дип әйтерлек. Фидакарьләрчә эшләүче Ф. Яруллинны, арабыздан вакытсыз киткән талантлы Ф. Шәфигуллинны, үҗәт бер тырышлык белән хикәяләр һәм повестьлар язган Альберт Хәсәновны, бөтенләй дә яшь Аяз Хәсәновны күрсәтә алабыз. Вакыт-вакыт бу өлкәгә М. Хәсәнов, Н. Дәүли, Р. Фәизов килеп чыгалар. Ихтимал, шушылар гынадыр. Хәер, балалар прозасында эзлекле эшләүче Р. Хафизова бар икән. Ул иң актуаль темаларга яза, кызыклы сюжет таба белә, әмма телендәге кимчелекләр, психологик тәгәлсезлекләр аның әсәрләренең әдәби кыйммәтен шактый киметәләр. Бу җәһәттән игътибарны менә нәрсәгә юнәлтәсем килә: соңгы елларда тәнкыйтьчеләребез әдәби әсәрләрнең теле-стиле мәсьәләләрен бөтенләй дә оныттылар.

Узган елны Н. Фәттах «Казан утлары» журналында яшь язучы Н. Гыйматдинованың әсәрләрендәге тел материалына карата җентекле фәнни анализ ясады. Гаделлек хакына әйтик, Н. Гыйматдинова — сәләтле, тормышны әйбәт белүче, инде укучылар игътибарын җәлеп итәрдәй берничә повесть һәм байтак кына хикәя иҗат иткән автор. Н. Фәттахның бик җитди һәм объектив анализыннан яшь автор үзе генә түгел, тәнкыйтьчеләребез дә нәтиҗә ясарга тиешләр дип беләм. Ачыктан-ачык сөйләшик, без әдипләребезнең тел кимчелекләрен ак кәгазь өстендә күпме генә төзәтмик, әгәр аларның телгә булган карашлары дөрес түгел икән, ул хаталар тагын кабатланачак. Икенче төрле әйткәндә, язу машинкасындагы шрифтлар ватык икән, машинка кәгазь өстенә адым саен ватык хәрефләр төшерәчәк. Тел материалына менә шулай фәнни анализ ясау яшь авторларга иң нәтиҗәле, иң кирәкле ярдәм булып тора. Тәнкыйтьчеләребезнең үз вакытында яшьләргә аларның тел кимчелекләрен күрсәтеп бирмәве аркасында ул авторлар үсә төшкәч тә зәгыйфь телле булып калдылар. Димәк, әсәр-

ләребезнең телен һәм стилен өйрәнү, идея эчтәлеген анализлау кебек үк, төнкый чәләребез өчен беренче дәрәҗәдәге бурыч булып кала.

### 3

«Иҗат союзларының һәм берләшмәләренең бурычы,— диелә партия Үзәк Комитетының 1983 елгы июнь Пленумы карарында,— культура эшлеклеләрен халык алдында җаваплылык рухында тәрбияләү, алар арасында идеялелекне, әхлакый һәм эстетик таләпчәнлекне арттыру».

Боларның барысына ирешү, әдипләребезнең тырышлыгын югары идеяле, сәнгатьчә нәфис әсәрләр иҗат итүгә юнәлдерү өчен отчет чорында Татарстан Язучылар союзы идарәсе күп төрле оештыру-иҗат эшләре алып барды. Үзебезнең нәшрият һәм үзәк нәшриятлар белән, вакытлы матбугат, радио һәм телевидение белән элемтәне ныгытты. Һәр елны әдәби ел йомгаклары, Поэзия көне, Казан язы, районнарда әдәбият көннәре үткәрү безнең коллективта иҗат атмосферасы тудырды, әдәбиятыбызның төп үсеш тенденцияләрен ачыкларга, бурычларын билгеләргә ярдәм итте. Тугандаш халыклар әдәбияты белән бәйләнешләребез ныгый төште, даими комиссияләр һәм иҗат секцияләре үз эшләрен җаваплылык белән, төгәл алып барырга тырыштылар. Татар әдәбияты ил күләмендә башка бишьеллыкларга караганда күбрәк һәм яхшырак сыйфатлы булып чыга алды. Язучылар белән укучыларның бәйләнеше, элемтәләре арту безнең иҗатыбызга йогынты ясаган факторларның берсе булды. Без матур әдәбиятны нәтиҗәле пропагандалаганы өчен Республика китап сөючеләр җәмгыятенә, нәшрият коллективына, газета һәм журналларга, радио һәм телевидениегә, полиграфистларга, китапханәчеләргә, культура-агарту өлкәсендә эшләүчеләргә рәхмәтле. Алар безне укучы белән тоташтырдылар, алар безнең китапларыбыздагы уйтойгыларны киң катлау халык массасына илтеп җиткерделәр.

Әгәр бездән, ике съезд арасында Татарстан Язучылар союзы идарәсе башкарган эшләрнең иң зурысы нәрсә дип сорасалар, яшь язучыларны тәрбияләү, дип авыз тутырып әйтергә мөмкин булыр иде.

«Иҗат яшьләре белән эшләү турында»гы партия Үзәк Комитеты карары, яшь алмаш тәрбияләү мәсьәләсен КПССның Татарстан өлкә комитеты бюросында махсус тикшерү, РСФСР Язучылар союзы секретариатында безнең идарәнең отчетын тыңлау — болар безгә яшьләр белән эшләүне кирәкле зур юлга салырга мөмкинлек бирделәр.

Идарә председателенең урынбасары И. Юзеев, яшьләр белән эшләү комиссиясенең председателе Ш. Галиев, комсомолның Татарстан өлкә комитеты белән бергәләп, биш ел эчендә республикабызның барлык районнарында яшь язучыларның зона конференцияләрен үткәреп, йөзләрчә кульязмалар укып, бу эшкә мәктәпләрдә әдәбият белән кызыксынган сәләтле балаларны да тартып, файдалы зур эш башкардылар. Яшь каләмнәрнең кулъязмаларын уку, алар алдында үзләренең күп еллык иҗат тәҗрибәләре белән уртаклашу буенча республикабызның танылган каләм осталары бик теләп катнаштылар һәм шуның белән әдәби алмаш тәрбияләүнең мөһим мәсьәлә икәнен тагын бер мәртәбә расладылар. «Казан утлары» журналы, «Идел» альманахы, республикабыз газета-журналлары яшь һәм башлап язучыларның беренче «каләм тибрәтү» үрнәкләрен, яхшы дип табылган хикәяләрен, шигырьләрен, әкиятләрен дөньяга чыгара тордылар, бу исә яшьләргә тизрәк җитлегергә мөмкинлек тудырды. Ниһаять, быел әдәбият белән шөгыльләнүче балаларның Казанда конференциясе үткәрелде.

Яшьләр белән эшләүне яхшырту күзгә күренеп торган практик ярдәм дә алып килде. Безнең коллектив бу бишьеллыкта ишәя төште. Әгәр тугызынчы съездны үткәргән чакта без 154 язучы булсак, хәзер 182 гә җиттек. Яшь авторлар белән нәтиҗәле эшләү һәм шул хакта РСФСР Язучылар союзы секретариатында отчет ясау безгә илебезнең данлы бер төбәгендә — Брежнев шәһәрендә язучыларның яңа оешмасын ачарга мөмкинлек тудырды. Моннан 20 ел элек республикабыз нефтьчеләренең башкаласы Әлмәттә шундый ук оешма ачылуын искә алсак, хәзер бездә, Казандагы төп иҗат союзыннан тыш, тагын ике оешма бар. Алар белән Ә. Гаффар,

Р. Вәлиев кебек энергияле, булдыклы оештыру-иҗат эшләренә сәләтле, иҗатлары ягыннан талантлы иптәшләр җитәкчелек итәләр. Хезмәт кешесе, бигрәк тә нефтьчеләр һәм химиклар турындагы масштаблы, киң колачлы әсәрләрне без шушы ике оешманың вәкилләреннән көтәбез. Чөнки алар тормышның кайнап торган үзәгендә яшиләр!

Яшь алмаш әзерләгәндә безгә бер нәрсәне истән чыгарырга ярамый. Партия Үзәк Комитетының мәгълүм карарында яшьләргә карата игътибарлылыкны таләпчәнлек белән бергә алып барырга кирәклеге әйтелә. Юкса соңгы елларда яшьләр үзләренә игътибарлы булуны яраталар, алай гына да түгел, алар аны таләп итеп алалар, кайберләре исә язу машинкасыннан гына төшкән әсәрләрен тизрәк бастырып чыгарырга ашыгалар. Менә мондый очракларда яшьләргә бик тә сабыр һәм түземле рәвештә аңлата белергә кирәк: әдәби әсәр бик зур тырышлык, кайнар тир түгү, тел-стильне өзлексез чарлау аркасында гына туа ала, укучыларда популярлык казана ала. Әдәбият әдипләрдән барлык көчен, гомерен таләп итә. Шуңа риза булмасаң, әдәбият эшенә тотынмаска да кирәк.

Татарстан Язучылар союзы идарәсенең алга таба аеруча игътибар итәргә тиешле өлкәсе дип мин әдәби тәрҗемә мәсьәләләрен саныйм. Русчадан һәм тугандаш халыклар теленнән тәрҗемә итү бездә ныклы нигезгә салынган. Әле революциягә кадәрле үк башланып, Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң тагын да ныграк үскән, Я. Халитов, К. Миңлебаев, Р. Даутов, Т. Нурмөхәммәтов, С. Ибраһимова, Ф. Гайнанова кебек аерым осталары җитешкән, алар янына Ф. Миңнуллин, Ф. Зыятдинова, Л. Хәмидуллин кебек яңа әдипләр килеп кушылган бу өлкә татар укучыларына Толстой һәм Пушкинны, Достоевский һәм Маяковскийны, Шолохов һәм Твардовскийны, Әуэзов һәм Айтматовны, Есенин һәм Гамзатовны, тагын бик күп, бик күп каләм осталарын, дөнья әдәбияты җәүһәрләрен безнең телдә сөйләшә торган иттерде. Рус классикларының, совет язучыларының, дөньяның прогрессив язучыларының бездә хәзер яхшы тәрҗемәләре бар дип горурланып әйтә алабыз. Әмма безнең үз әсәрләребезне русчага, рус теле аша тугандаш халыкларга, ниһаять, бөтен дөньяга чыгару ягыннан күп эш эшлисе бар әле. Дөрес, без илгә чыкмыйбыз дип зарлана алмыйбыз. Совет власте елларында татар язучыларының 600 дән артык китабы 50 миллионнан данәдән артык тираж белән илгә таралган икән, бу — бик зур катаныш. Без моның өчен рус язучыларына рәхмәтле. Тик безнең киң дөньяга чыккан барлык әсәрләребез дә Бөтенсоюз укучысына оригинальдәге көче белән барып җитә дип уйлау да бигүк дөрес булмас иде. Шуның өстенә классикларыбызны, мең ел буенча җыелган рухи хәзинәбезне илгә чыгару буенча зур эш эшлисе бар әле. Язучылар союзы идарәсе никадәрле генә тырышмасын, колач җитмәс дәрәҗәдә зур һәм дәүләт күләмендә әһәмиятле бу эшне бер ялгызы гына башкарып чыга алмый. Шуңа күрә Татарстан китап нәшрияты каршысында классикларыбызны татарча һәм русча чыгару редакциясе булдыру кирәклеге хәзер кичектергесез бер эшебез булып алга килеп басты.

Татарстан язучыларының тугызынчы һәм унынчы съездлары арасында идарә башкарган зур әдәби-иҗтимагый чараларга шатланган хәлдә, без бер нәрсәне һич тә исебездән чыгармыйбыз: болар барысы партия Үзәк Комитетының, КПССның Татарстан өлкә комитетының, Татарстан хөкүмәтенең, СССР һәм РСФСР Язучылар союзлары идарәләренең һәм секретариатларының булышлыгы белән, ышанычы белән эшләнде. Безнең эшкә катнашы булган барлык иптәшләргә ярдәмнәре өчен, иҗат атмосферасы тудырырга булышканнары өчен, бер-беребезгә ихтирам җирлегендә, максатлы рәвештә җитәкчелек иткәннәре өчен кайнар рәхмәтебезне белдерәбез.

Татар совет әдәбияты күп милләтле совет әдәбиятының аерылгысыз бер өлеше буларак, илебез әдәбияты белән бергә, магистраль юлдан бара. Совет халкының сугыштагы һәм хезмәттәге батырлыгын җырлау, замандашыбызның уңай образын киң колачлы, масштаблы итеп дөньяга тудыру, тынычлык өчен көрәш байрагын югары йөртү, идеология дошманнарыбызга каршы рәхимсез булу, әдәби осталыгыбызны күтәрү — безнең алда торган бурычлар әнә шундый.

# С. В. Михалков,

СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре,
РСФСР Язучылар союзы идарәсе председателе,
Социалистик Хезмәт Герое

# ЯҢА БИЕКЛЕКЛӘРГӘ

Кадерле иптәшләр!

Безнең Бөек Советлар иле, Ватаныбызның миллионнарча һәм миллионнарча хезмәт ияләре язның бу якты көннәрендә гаять зур иҗади һәм хезмәт күтәренкелеге белән яшиләр. Без үз илебезнең генә түгел, ә кешелек җәмгыятенең, Җир планетасының якты, тыныч, киләчәккә даими омтылышы хисләре белән яшибез. Сөекле Коммунистлар партиясенең, аның Үзәк Комитетының тарихи карарлары безгә әнә шулай тирәнтен гуманлы, иҗади яшәргә булышлык итә. КПСС Үзәк Комитетының апрель (1984 ел) Пленумы документлары һәм КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре иптәш Константин Устинович Черненконы бертавыштан СССР Верховный Советы Президиумы Председателе итеп сайлаган унберенче чакырылыш СССР Верховный Советының беренче сессиясе карарлары — моның ачык дәлиле.



*Татар язучылары Р. Фәйзуллин, Г. Ахунов, РСФСР Язучылар союзы идарәсе председателе С. Михалков, Чувашстан язучылар союзы идарәсе председателе А. Емельянов, РСФСР язучылар союзы идарәсе секретаре А. Волков (сулдан уңга).*

Бу язгы көннәр Казанның барлык хезмәт ияләре өчен аеруча якты һәм шатлыклы: хезмәтчел шәһәр, бөек Ленинның революцион яшьлеге шәһәре Ватаныбызның иң югары бүләгенә — Ленин орденына лаек булды. Без сезнең белән, кадерле иптәшләр, каләмдәш дуслар, өч орденлы Татарстан язучыларының унынчы, юбилей съездына менә шундый истәлекле көннәрдә җыелдык. Күпмилләтле Россиянең барлык әдипләре исеменнән, СССР һәм РСФСР Язучылар союзы идарәләре Секретариатлары исеменнән мин шушы югары трибунадан съездның барлык делегатларын,

язучыларны, яшь әдипләрне һәм хәзерге татар совет әдәбияты һәвәскәрләрен чын күңелдән котлыйм. Сезнең съездның әһәмияте Татарстан автономияле республикасының культура тормышы өчен генә түгел, бәлки бөтен Советлар иле халыклары өчен гаять зур. Быел СССР Язучылар союзы төзелүгә 50 ел тула. Без илебездә Максим Горький катнашында төзелгән Язучылар союзларының берсе Татарстан Язучылар союзы булуын һәрвакыт истә тотабыз. Алексей Максимович Татарстан Язучылар союзын төзүдә турыдан-туры катнашты, бу хакта матбугатыбызда күп яздылар, татар әдәбияты аксакаллары моны зур рәхмәт хисе белән искә алалар.

Иптәшләр!

Татар әдәбиятының күп гасырлык тарихы татар язучыларының иң югары бәяленерлек әсәрләр иҗат итәргә сәләтле булуын ышандырырлык итеп күрсәтте. Хәзерге әдәбият сөючеләр, ягъни Советлар иленең хезмәтчел кешесе бүгенге язучыларның, замандашларыбызның бу югары марканы ничек саклауларына һич тә битараф кала алмый. Минем уйлавымча, татар язучыларының хәзерге заман әсәрләре, шул исәптән съездлар арасындагы чорда иҗат ителгән әсәрләре совет укучысының югары таләбенә күп яктан җавап бирә. Әмма, миңа билгеле булганча, сезнең әле хәл ителмәгән проблемаларыгыз шактый, Татарстан әдәби хәрәкәте алдында байтак бурычлар тора. Алар сезгә яхшырак билгеле, һәм мин бу съездда хәл ителмәгән проблемалар турында да таләпчән сөйләшү булыр, дип ышанам. Мин хәзерге татар әдәбиятының кайбер жанрларына гына тукталырга телим.

Проза жанрын алыйк. Сүз дә юк, Совет власте елларында татар прозасы Бөтенсоюз күләмендә генә түгел, ә бөтендөнья күләмендәге биеклеккә күтәрелде. Мин Галимҗан Ибраһимов, Гомәр Бәширов, Габдрахман Әпсәләмов, Ибраһим Газиз романнарын күздә тотам. Бу авторларның романнары үз вакытында Советлар Союзының күпмилләтле укучысында зур уңыш казанды, чит илләрдә басылды. Бу исә чын мәгънәсендә татар романының күтәрелеш еллары булды. Безнең көннәрдә татар прозасында бик актив, сәләтле, кызыклы прозаиклар эшли. Әмирхан Еники, Атилла Расих, Гариф Ахунов, Нурихан Фәттах, Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев, Шамил Бикчурин, Миргазиян Юныс, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Вакыйф Нуруллин һәм яшь прозаикларның тулы бер буыны шундыйлар рәтенә керә. Бу язучыларның китаплары Татарстанда һәм үзәк нәшриятларда актив басылып килә, аларның әсәрләре Бөтенсоюз укучысына мәгълүм. Әмма, хәзерге дәвам үсә баручы татар прозасының барлык уңышларын тану белән бергә, алтмышынчы һәм җитмешенче елларда татар романының, бигрәк тә хезмәт кешесе турындагы романның үз позицияләреннән бераз чигенүен әйтми калырга ярамый. Бу — республика индустриясенең куәтле үсеше фонында, атаклы КамАЗ төзелешләренең, данлы нефтьчеләрнең, нефтехимикларның, машина төзүчеләрнең һәм Татарстан авыл хуҗалыгы эшчәннәренең героик җиңүләре фонында аеруча ачык сизелә. Татар әдәбиятында мондый әсәрләр бар, дип әйтүчеләр дә булуы мөмкин. Әмма бу әсәрләр рус теленә җитәрлек кадәр сыйфатлы итеп тәрҗемә ителми, шунлыктан Бөтенсоюз күләмендәге тәнкыйтькә һәм илебезнең күпмилләтле укучысына барып җитми. Бу очракта, иптәшләр, сезгә тәрҗемә эшен җайга салырга, тәрҗемә проблемаларын уңышлы хәл итү өстендә эшләргә кирәктер.

Хәзерге татар драматургиясенең сизелерлек уңышлары безнең барыбызны да шатландыра. Бу хакта мин Әдәби тәрҗемә советының Драматургия һәм театр тәнкыйте советының берләштерелгән утырышын ачкан чакта да зур канәгатьләнү белән әйткән идем (әлеге утырыш 1982 елда РСФСР Язучылар союзы идарәсендә барды). Моның — берләштерелгән утырышның Татарстан әдәби хәрәкәте өчен дә, тулаем Россия Федерациясе әдәби хәрәкәте өчен дә әһәмияте зур. Беркемгә дә сер түгел, безнең иҗат советларында мондый типтагы киңәшмәнең һәм утырышлар оештыруның төп сәбәбе булып еш кына әле хәл ителмәгән проблемаларны карау, әдәби тормышыбызның теге яки бу өлкәсендәге артталыкның сәбәпләрен ачу тора. Ләкин без РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретариатында татар драматургиясе буенча Мәскәүдә киңәшмә оештыру турындагы мәсьәләне тикшергәндә, хәзерге татар дра-

матургларының уңай тәҗрибәсен Россиянең башка тугандаш әдәбиятларына күрсәтергә, бу иҗади күтәрелешнең сәбәпләрен ачарга теләдек. Соңгы вакытта театр тәнкыйте, Бөтенсоюз телевидениесе һәм илебез театрлары хәзерге татар драматургиясенә җентекле игътибар бирәләр. Туфан Миңнуллин, Аяз Гыйләҗев, Илдар Юзеев, Диас Вәлиев, Рөстәм Мингалим, Ризван Хәмид һәм күп кенә башка гүзәл татар драматургларының әсәрләре көннән-көн тамашачының игътибарын яулый бара.

Иптәшләр!

Татар поэзиясенең үзенең гаять сугышчан шигъри традицияләре бар. Тукай һәм Җәлил, Такташ һәм Кәрим, Туфан һәм Хәким исемнәре бу хакта ачык сөйли. Татар совет шагыйрьләре патриотизм байрагын, Ватанга, туган халкыбызга булган мәхәббәт хисләрен һәрвакыт югары тоттылар һәм тоталар. Нури Арслан, Илдар Юзеев, Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Рөстәм Кутуй һәм Татарстанның аеруча актив шагыйрьләренең бөтен бер плеядасы шигырьләре һәм поэмалары күп гасырлык татар поэзиясенең иң яхшы традицияләрен уңышлы дәвам иттерәләр. Әмма, чагыштырмача яшь шагыйрьләрнең Бөтенсоюз мәйданына актив чыгуына карамастан, тулаем татар поэзиясен рус теленә тәрҗемә итү сыйфатының канәгатьләнерлек булмавын әйтеп китәргә кирәк.

Иптәшләр!

Коммунистлар партиясе Үзәк Комитетының соңгы вакытта чыккан карарлары, СССР Верховный Советы Президиумының гомуми белем мәктәбе һәм профессиональ мәктәп реформасының төп юнәлешләре турындагы Указлары балалар өчен эшләүче язучылар алдына гаять зур бурычлар куя. Биредә сүз безнең киләчәгебез хакында, киләчәк гасырлар турында бара. Соңгы вакытта татар балалар әдәбияты шактый уңышларга иреште. Шагыйрь Шәүкәт Галиев иҗаты Андерсен исемендәге халыкара премиягә лаек булды. Һәм, гомумән, мин татар балалар поэзиясенең уңышларын билгеләп үтәр идем. Балалар прозасы һәм драматургиясе жанрларын активлаштырасы бар. Олылар драматургиясе шундый зур уңышларга ирешкән бер вакытта балалар һәм үсмерләр драматургиясенең шактый артталыгы борчымый кала алмый.

Татар әдәбиятында сатира һәм юмор жанрының хәзерге торышыннан канәгать булмавымны әйтергә телим. Соңгы елларда татар язучылары Бөтенсоюз укучысын сатира һәм юмор әсәрләре белән бик куандырмыйлар. Ә бит елмаерга һәм көләргә яратучылар татарларның үткен һәм зирәк юморы белән тирәнрәк танышырга телиләр. Бу өлкәдә сезнең яхшы традицияләрегез бар. Мирсәй Әмир, Гамил Афзал, Зәки Нури һәм башкаларның яхшы сатира-юмор әсәрләре барыбызга да таныш. Республиканың яшь язучылары бу традицияләрне дәвам иттерерләр дип ышанасы килә.

Безнең оештыру-иҗади тормышыбызда нәшрият эшләре гаять зур әһәмияткә ия. Сезгә билгеле булганча, узган ел без, «Современник» нәшрияты белән бергәләп, Казанда РСФСР Язучылар Союзы Әдәби тәрҗемә советының күчмә утырышын үткәрдек. Анда сүз Идел һәм Урал буе автономияле республикаларында яшәүче язучыларның әсәрләрен тәрҗемә итү проблемалары турында барды. Казанның бу чараны үткәрү урыны итеп сайлануы очраклы түгел. Үзәк нәшриятлар, шул исәптән «Современник» нәшрияты да татар язучыларының әсәрләрен һәм татар фольклорын тәрҗемә итү һәм чыгаруда бай тәҗрибә тупладылар. РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретариаты бу тәҗрибә белән уртаклашуны кирәк дип санады. Идел һәм Урал буе халыкларының барлык әдипләренә киңәшмә зур файда китергәндер, дип уйлыйм. Татарстан китап нәшрияты һәм Татарстан Язучылар союзы арасындагы үзара дуслык һәм эшлеклелек мөнәсәбәтләре безне шулай ук канәгатьләндерә.

Чыгышымны тәмамлап, мин республика язучыларының уңай көнкүреш һәм иҗат шартлары турында даими кайгыртулары өчен КПССның Татарстан өлкә комитетына, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумына һәм Министрлар Советына чын күңелдән рәхмәт әйтергә телим.

Туфан Миңнуллин

# ЮГАРЫ ИДЕЯНЕ — ЗУР ОСТАЛЫК БЕЛӘН...

Ике съезд арасында әдәбиятыбызның иң нык макталган жанры драматургия булды, дисәм, ялгышмамдыр дип уйлыйм. Үзебезнең республика матбугаты да, үзәк матбугат та драматургиябезнең алга китүе турында кабат-кабат язып тордылар. Драма әсәрләрен һәм аларның авторларын аерым-аерым да, бергә җыеп та мактадылар. РСФСР Язучылар союзында уздырылган драматургия һәм тәнкыйть советларының берләштерелгән утырышында, мәсәлән, сәнгать фәннәре докторы, күренекле белгеч В. В. Фролов доклад ясап, безнең драматургияне жанрларга бүлеп тикшерде. Трагедия жанрында да, драма, комедия жанрларында да уңышларыбызны югары бәяләде. Ә совет утырышын ачкан Сергей Владимирович Михалков «Татар драматургиясе соңгы ун ел эчендә аеруча зур үсешкә иреште. Бу безне бик шатландыра. Әлеге алга омтылышны чагыштырмача яшь драматурглар өйдәп бару безне куандыра. Алар өлкән буын тәҗрибәсен оста файдаланып, татар драматургиясендә бер адым алга киттеләр»,— диде.

«Литературная газета» битләрендә барган дискуссиядә шулай ук дәрәҗәле белгеч, сәнгать фәннәре докторы Вишневская бүгенге драматургиябезне бик күпләргә үрнәк итеп куйды. Һәм чыннан да безнең әсәрләр белән илебездәге театрлар елдан-ел күбрәк кызыксыналар. РСФСР, СССР Культура министрлыклары оештырган мәртәбәле семинарларга безнең драматургларны зур ышаныч белән яратып чакыралар. Һәм әлеге семинарлардан безнекеләр чакыручыларның өметләрен аклап, кәпәчне кыңгыр салып кайталар. Озак та үтми Ризван Хәмид һәм Әхәт Гаффар кебек егетләребезнең пьесалары, ил күләмендә дан алган драматургларның тәрҗемәсендә, «Советская драматургия» альманахында басылып та чыга. Хәбәрдар булмаган иптәшләргә белешмә биреп китик: әлеге альманахта басылыр өчен «тамак төбе белән сөйләшеп, бармак очлары белән генә көрәшүче» агайлар да еллар буе чират тора.

Янә тагын шуны өстәү дә урынлы булыр: Татар дәүләт академия театрының 1983 ел җәендә Мәскәүдә, МХАТ бинасында үткәрелгән иҗат отчетына багышланган мәкаләләргә «Правда», «Известия», «Советская Россия», «Советская культура» һәм башка вакытлы матбугат органнарында зур урын бирелде. Отчет тәмамлангач та «Огонек», «Театр», «Театральная жизнь» журналлары театрның эшен олылаган зур күләмле мәкаләләр бастырдылар. Театрны бу очракта искә алуым шуның өчен: үз драматургиясе булмаган яки йомшак булган театр беркайчан да макталмый.

Эшебезне югары бәяләгәнгә без, драматурглар, әлбәттә, куанабыз, мактаучыларга рәхмәтләр укыйбыз. Кайвакыт кирәгеннән артык очынып китеп, хаклы әйтелгән тәнкыйть сүзләрен дә кабул итмибез, аларны чырайны сытып тыңлыйбыз... Хәер, ул турыда соңрак әйтелер, хәзергә уңышларыбыз хакында сөйләүне дәвам итик. Бу хакта сүзне төрле мактауларны кырыйгарак куеп торып, сабыр гына алып барсак дөресрәк булыр. Мәсәлән, без үзебез, драматурглар, биш еллык эшебезгә ничегрәк карыйбыз? Чыгарган продукциябез сыйфат билгесенә җавап бирәме? Әллә безне мактаучылар әз-мәз генә арттырып җибәрәләрме?

Иң беренче шуны әйтергә кирәк: без, әдәбиятның бүтән жанрларында эшләүчеләр кебек үк, үзебезнең ил, халык, партия алдындагы олы бурычларыбызны тирән аңлап иҗат итәбез. Безнең бүгенге һәм һәрвакыттагы төп бурычыбыз — коммунистик идеялелек белән коралланган, ил, халык мәнфәгатьләре белән яшәүче, туган җирен, туган туфрагын яклап изге көрәшкә чыгарга әзер торучы, рухи нык, акылы аек, күңеле саф совет кешесе тәрбияләү. Нинди генә жанрда язсак та, кайсы гына темага мөрәҗәгать итсәк тә әсәрләребезнең яңгырашын шушы камертон белән тикшерергә, үзебезнең кыйблабызны шул компаска карап билгеләргә тиешбез! Иҗатыбызның иҗтимагый һәм эстетик кыйммәтен билгели торган икенче бер таләп — ул әдәби осталык. Без — сәхнәдән — биек урыннан торып залга сөйләүчеләр; сүзебездән зур мәгънә эзләп, безне берьюлы әллә ничә мең кеше тыңлый. Шуңа күрә, безнең һәр сүзебез төрле яклап уйланган булырга тиеш. Кайчак әйтә белмичә әйтелгән матур сүз дә кеше күңеленә



*Әзербайҗан кунагы шагыйрь Г. Имамвердиев, татар әдипләре А. Гыйләҗев һәм Т. Миңнуллин (сулдан уңга) әңгәмә вакытында.*

барып җитмичә адашып кала, я дуслар күңеленә ярамый, я булмаса, дошманның теленә барып кунып, изге ниятләребездән көлү объектына әйләнә.

Инде хәзер ике съезд арасында дөнья күргән кырыкка якын драма әсәренең һәрберсенә тукталып тормыйча, югарыда әйтелгән таләпләр югарылыгыннан торып, кайбер конкрет күзәтүләргә күчик.

Әдәбиятның асылын, чын йөзен, өлгергәнлеген заманның актуаль, мөһим мәсьәләләрен күтәргән әсәрләр билгели. Безнең драматургиядә дә төп урын бүгенге көн проблемаларына бирелгән. Әйтик, өлкән драматург Аяз Гыйләҗев биш елда иҗат иткән җиде әсәренең алтысы бүгенге кешеләрнең язмышына багышланган. Язмышлар төрле. «Әткәй җырлый да, елый да», «Ефәк баулы былбыл кош» драмаларында уйландыра торган язмышлар, «Биш бармакта биш балдак»та шомландыра торган язмышлар. Драматургның геройлары төрле төбәктә яши, төрле профессия кешеләре. Әмма алар автор фантазиясендә бер фикерне әйтү өчен туганнар: әйбәт булыйк, кешеләр, шушы катлаулы дөньяда Кеше дигән бөек исемебезгә кулэгә төшермик! Әйе, бүген кайсы гына темага язсак та, безнең төп проблема әхлак проблемасы булып кала бирә. Безгә югары әхлаклы кешеләр көннән-көн күбрәк кирәк. Бүгенге заманның герое — югары әхлаклы кеше. Эштә дә, кирәк икән, көрәштә дә без шундый геройга гына таяна алабыз. Заманның бу темасын Илдар Юзеев үзенчә, күңелендә гүзәллек йөрткән образлар аша яктырта. Илдар — шигырь, поэмаларындагы шикелле үк, драматургиядә дә, матурлык, сафлык җырчысы. «Хәтерлим мин гүзәл мизгелне», «Онытылган бәет» драмалары чәчмә формада язылсалар да, алар асылда шигъри әсәрләр. Ләкин Илдар Юзеев матурлыкка тышкы соклану белән генә мавыкмый, матурлыкка ул философик категория буларак карый, безнең кешеләребездә шундый гүзәллек тәрбияләргә омтыла. Ә дөнья саф күңелле, матур кешеләргә көннән-көн күбрәк мохтаҗ.

Драматурглар Ризван Хәмид һәм Рөстәм Мингалимнең каләмнәре кырысрак. Аларның геройлары да, юктан гына очынып китеп, теләсә кемне кысып кочакларга яки кочагына ташланырга әзер тормыйлар. Әсәрләрендәге персонажлар еш кына берберсенә сырт куеп сөйләшәләр. Мылтыксыз-фәләнсез бүре тоту да, үзе ашатып үстергән этне, кешеләргә өрмәгән өчен, атып үтерү дә, хатын-кыз була торып, ир-ат хулиганнарны тотып тукмау да аларга чүп тә түгел. Ризван белән Рөстәм пьесаларының исемнәре дә күп очракта коры, «ачуланып» әйтелгәннәр төсле: «Кайтыр идем», «Китәм инде...», «Иске йорт кешеләре», «Кайда сез, ирләр», «Өченче булмәдә эт яши»... Ләкин нишләтәсең, андый кешеләр дә безнең арада яши, алар да безнең җәмгыятьнең әгъзалары. Кырыс икән, алар бит шулай булып тумаган, тормыш аларны шулай итеп калыплаган. Драматурглар әнә шул имгәнгән язмышлы кешеләрнең күңеленнән, җаныннан яхшылык очкыны, кешелеклелек эзлиләр. Кешеләр берсен-берсе аңларга тиешләр, ди алар. Бүгенге заманда без бер-беребезне аңлауга бик тә, бик тә мохтаҗ.

Р. Батулланың «Каерылмасын канатың» исемле пьесасын Минзәлә театрында

карагач, «Ну, Батулла, хәтта миндәй каты күңелле кешене дә елаттың», дип шаярткан иде. Чыннан да спектакльдә шактый тамашачылар елыйлар, Робертның «Кичер мине, әнкәй» пьесасында да кулъяулык тартып чыгарырга мәҗбүр итәрлек урыннар бар. Драматург күңел кылларын тибрәтеп, тамаша залын елатырлык әйберләр язган икән, аны хупларга кирәктер. Сәхнәдәге кешеләр кайгысын күреп, шул кайгыны уртаклашып, күз яше чыгара икән, кемдер, аның күңеле нечкә дигән сүз. Нечкә күңелле кешеләр кирәк безгә, битарафлардан дөнья үзе сакласын. Битарафлык чире — һәр заманның да иң куркыныч чире.

Биш елда иҗат ителгән драматургия үрнәкләренә тулаем бер караш салып уйланганда, бөтен драма әсәрләребезгә хас уртаклыкка юлыктым.

Бер җыелышта проза жанры турында сөйләгәндә Фәрваз Миңнуллин яшь прозаикларның әсәрләрендәге геройларның гел картлар булуын искәрткән иде. Ул хаклы. Бу хәл прозада гына түгел, драматургиядә дә шулай икән. Һәм яшьләр генә түгел, өлкән драматурглар да күп кенә пьесаларында аталар һәм балалар, дересрәге, бабайлар һәм оныклар проблемасына мөрәҗәгать итәләр икән. Мин үзем монда әллә ни хилафлык күрмим. Бу — мәңгелек проблема. Безнең илдә әлеге проблема, антогонистик булмаса да, җитди. Бөек Октябрь революциясен ясаган, героик бишьеллыклар аша узган, Бөек Ватан сугышы сынауларын үткән ветераннарның бүгенге яшьләргә, «Безнең рух яшиме сездә?» дип сорарга тулы хокуклары бар. Яшьләр дә үз алларына «Сезнең рухны югалтмадыкмы?» дигән сорау куялар икән, бу бик табигый һәм актуаль сорау.

Бүгенге көн темасына язу, тыштан караганда, бик җиңел кебек: барысы да күз алдында, геройлар үз арабызда йөри, вакыйгаларның күбесендә үзебез дә катнашабыз. Ләкин менә шушы «артык танышлык» күп очракта безгә комачаулый да. Иң мөһим проблеманы сайлап алып, иң герой геройны үз арабыздан табу ифрат читен икән ләбаса. Үткәнгә без хәзерге тәҗрибә аша карап бәя бирәбез, әзер бәяләрдән дә файдаланабыз. Бүгенге көн темасына язганда кайбер җитешсезлекләр килеп чыга икән, димәк, шушы читенлек белән акланып та буладыр. Янәсе, чын күңелдән эзләп тә таба алмаска мөмкин. Ишетүемчә, фән даирәсендә уңай нәтиҗә бирмәгән тикшерү, эзләнүләр дә гыйльми эш булып санала икән.

Шулай да бүгенге көн темасын үзләштерү өлкәсендә үзебездән торган кимчелекләр дә бик күп. Әсәрләребезгә тирәнлек җитми. Сай сөрәбез, чи калдырып сөрәбез. Кайвакытларда унбишәр потлы йөк күтәреп атларлык көчебез булган килеш, ике кадаклы төенчек тотып йөгерәбез. Җитмәсә, әле шуны бик авыр итеп күрсәтергә тырышабыз. Сәбәп нәрсәдә? Билне имгәтүдән куркабызмы, әллә инде унбиш пот күтәргән өчен дә, ике кадакны чөйгән өчен дә бертигез бәялиләр ич, дип акланабызмы? Чөнки тәнкыйть еш кына авыр күтәрергә тырышучыдан җитешсезлек эзләп, шомартып йөрүчеләрне күрмәмешкә салыша, шикелле.

Заман темасына кагылышлы җитешмәгән якларыбызның тагын берсе — әсәрләребездәге геройның яшәгән урыны һаман да авылда булды. Болай дип әйтеп, мин авылны онытырга чакырмыйм. Болай да күпмедер оныттык инде без аны. Ләкин бит кешеләр авылда гына яшәми. Дөрес, без интеллигенция вәкилләрен сәхнәдә шактый күрәбез. Ә менә эшче сыйныфы тамашачы ролендә генә утыра бирә. Бүгенге яшьләр кереп уйланырлык, бәхәсләшерлек әсәрләребез дә юк дәрәҗәсендә. Яшьләребез, театрга хөрмәт йөзеннән, тамаша залларын тутырып утыралар, тик күп очракта җаннарына азык таба алмыйча нәүмизләнеп яки ачуланып кайтып китәләр. Бу — безнең төп бәлабез. Бәлки гаебебездәдер. Ул хакта һәрвакыт сөйләшеп торабыз, әмма эш сөйләшүдән узмый. Бүгенге заманның чын эшчесен, аның шатлык-кайгыларын, яшьләребезнең уй-борчылуларын сәхнәдән күрергә тамашачы гына түгел, без, драматурглар, үзебез дә зарыктык. Әйдәгез, нык кына итеп бер селкенеп алабызмы әллә, иплар, төшләр. Бер чирканчык алсак, бәлки елганың уртасынарак кереп чумарбыз.

Җитди кимчелекләрне бетерү юлларын эзләгәндә Культура министрлыгыбыз, театрлар һәм җитәкче органнар активрак булсыннар иде. Соцзаказ дигән нәрсәне онытып җибәрмәскә иде. Әйтик, нигә менә Ризван Хәмидне, Әхәт Гаффарны, хәтта Аяз Гыйләҗевның үзен чакырып алып, «Яле, агай-эне, бүген шундый-шундый әсәр кирәк. Фантазияңне эшләт, осталыгыңны җик», димәскә. Таяну ноктасы итеп бирер конкрет тема да бирергә була. Мәсәлән, Юрий Гагаринның үзен очарга әйрәткән

очучы Ядкарь агай Акбулатов исән-сау. Остазлыкның нәрсә икәнен тирәннән аңл тырлык нинди бай материал! Драматурглар аңламыйлар икән, аларга бу материалнь кадерен аңлатырга кирәк. Ничек итепме?

«Наука и жизнь» журналында шундый информация чыккан иде. 1853 елда Көнь Америкадагы Коста-Рика дәүләтенә Англия һәм АКШ илчеләре килергә тиеш бул Ләкин аларны тантаналы итеп каршы алу өчен дәүләтнең гимны булмый. Илнең прези денты Гутьеррес исемле музыкантны чакыртып ала һәм аңа гимн язарга куша. Музь кант андый җитди эшнең болай тиз эшләнмәгәнен аңлатып, гимн язудан баш тартә Ләкин президент мәсьәләне үзенчә хәл итә: Гутьерресны төрмәгә ябарга боера һәм гимн язылмыйча торып, шуннан чыгармаска куша. Музыкант дүрт көн эчендә гимннь яза һәм ул гимн бүгенге көндә дә уйнала.

Билгеле, безне яздыру өчен мондый ук алым кирәкмәстер. Драматургтан нәкт менә бүген кирәкле әсәр яздыртырга теләүче иптәшләр кешелекле алымнар белән дә эш итә алалар.

«Үткәнен оныткинның киләчәге булмый», дигән бер акыл иясе. Шуңа күрә дә тарихчылар ерак һәм якын тарихны туктаусыз тикшереп торалар. Иҗат әһелләре дә еш кына бүгенгене аңлар өчен үткән турында уйланып әсәрләр иҗат итәләр. Без, драматурглар да, әлбәттә, бу өлкәне онытып бетермибез. Ветераныбыз Риза ага Ишморат бөек Тукаебыз турында «И мөкатдәс моңлы сазым» исемле әсәр язып, «Казан утлары» аша укучыларга бүләк итте. Илдар Юзеев Тукай яшәгән чорның философиясен үзенә хас стильдә — поэтик-драматик формада ачуга ирешә. Тукайның «Очты дөнья читлегеннән», дип әрнеп әйткән сүзләре бүген дә күңелләрне сискәндереп куя, һәм автор аны тирән фикерле әсәренә исем итеп алган. Хәтта тарихтан да алгарак китеп, борынгы кешеләр чын итеп сөйләгән мифлар нигезендә «Мәңгелек белән очрашу» исемле тагын бер фәлсәфи трагедиясен язып, Илдар Юзеев безне тагын бер тапкыр сөендерде.

Татар халкының тарихында халык өчен зур фаҗигагә әйләнү мөмкинчелеге булган мөһаҗирлек дигән куркыныч бер күренеш булган. Реакцион дин әһелләре, һәртөрле шарлатаннар, алдап, куркытып, мөселман динендәге татарларны Төркиягә күченергә өндәгәннәр. Ышанып күченүчеләр дә булган, әлбәттә. Аларның фаҗигасен зур талантлы язучыбыз Мәхмүт Галәү «Мөһаҗирләр» исемле романында гаҗәеп осталык белән сурәтләде. Белгәнебезчә, «мөһаҗирлек теориясе»н татар халкы кабул итмәде. Халыкның бу мәсьәләдәге фикерен «Рус белән тормыш кичердек сайрашып», дип, Тукай әйтеп бирде. Кешеләрнең туган җиренә тугрылыгын мактаган әсәрләр бүген бик кирәк. Аяз Гыйләҗевны, шушы мөһим мәсьәләне яктыртып, «Син минеке, мин синеке» исемле драма язганы өчен хупларга кирәк. Әмма шунысын да әйтик: әсәрне масштаблырак, катлаулырак, тирәнрәк фәлсәфирәк итәргә мөмкин һәм зарури иде. Бу очракта ашыгыбрак китте шикелле Аяз әкәбез.

Тарихи-революцион теманың мөһим икәнен бик яхшы беләбез, әмма аңа сирәк мөрәҗәгать итәбез. Ярый әле Әхәт Гаффар ялкынлы революционер Мулланур Вахитов турында драма язды. һәм ул, русчага тәрҗемә ителеп, тиз көннәрдә «Советская драматургия» альманахында чыгачак. Мин бу драманы укыдым. Әмма басылып чыкмаган яки театрда куелмаган әйбер турында фикер әйтергә ярамыйдыр. Шулай да ул әсәр бик шәп булса да, бер генә пьеса азрак безнең өчен. Казаныбыз — революцион шәһәр, күпме революционерларыбыз бар. Ә әсәрләр кайда? Югыйсә бөек Ленин биографиясенең Татарстан белән бәйле вакыйгалары да әллә ничә пьесага нигез була алырлык.

Беренче бишьеллыклар — безнең бик якын тарихыбыз. Әмма бу чор каһарманнары инде дөньядан китә торалар. Кызганычка каршы, кайбер батырларның исемнәре дә онытыла бара. Мин, мәсәлән, Магнитогорск шәһәрендә Магнитканы төзүчеләр турында бер спектакль карадым. Анда бетон изү буенча дөнья рекорды куеп, бөтен илне шаулаткан Хәбибулла Галиуллинны хәтерләткән образ юк иде. Анда Шәйхетдиновка охшаш фамилия дә юк. Ә бит Шәйхетдинов — Магнитогорскида Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнгән беренче кеше. Гариф абый Ахунов «Ардуан батыр» исемле повесть иҗат итеп, бер егетлек эшләгән булса, шуның нигезендә драма әсәре тудырып, икенче егетлек эшләде. Бик кирәк иде. Онытмыйк батырларыбызны.

Бөек Ватан сугышы батырлары бүгенге совет әдәбиятында хаклы рәвештә түр

урынны алып торалар. Без дә ул темага әледән-әле зур хөрмәт белән мөрәҗәгать итә торабыз. Мәсәлән, Илдар Юзеевның «Соңгы төн» трагедиясе, Әхәт Гаффарның «Хөкем» драмасы шундый пьесалар рәтенә керә. Әгәр дә совет халкының Бөек Ватан сугышында җиңеп чыгуына 40 ел тулуга багышлап бер-ике генә булса да яхшы әсәр бирсәк, бәхетебез өчен корбан булганнар каршында йөзебез ак булыр иде.

Безнең халыкара темага багышланган әсәребез юк иде. Сәхнәгә зур тырышлык һәм үҗәтлек белән сукмак яручы Кашшаф абый Әмиров «Зөлфия» дигән драма язып, бу темага беренче өлешне кертте. Мактауга лаек эш эшләде. Һәм аның әсәре, русчага тәрҗемә ителеп, күп театрларда куелды да. Вакыйга Җир шарының гаҗәеп киеренке нокталарыннан берсендә — Әфганстанда бара. Тормышчан була алырлык вакыйганы тапкан автор. Күченнән килгәнчә, аны сөйләп тә биргән. Әмма осталык, тәҗрибә җитенкерәмәү аркасында, шактый «шөрепләре» борылмыйча калган сыман. Беренче белән төерләрәк була, дигәндәй, тора-бара яхшы-яхшы әсәрләр дә туар. Аның өчен безнең егетләргә дә чит илләрне күрсәткәләп кайтарганда зыян булмас иде. Моның өчен драматургларыбызның политик хәзерлекләре җитәрлек. Барган җирләреннән ил йөзенә кызыллык китермичә кайта беләләр безнең егетләр.

Шушы кыскача күзәтүдән үк күренеп торганча, иҗат эшебездә хәл ителәсе мәсьәләләр шактый. Проблемалар төялгән драматургия арбасын тырышып-тырмашып сөйрәгәнебезне күреп, ярдәмгә берничә прозаик та килде. Әмма, кызганычка каршы, Марсель Галиевтән башкалары, тартышасы урынга, мыек астыннан елмаеп кына бераз ияреп бардылар да прозада янып-пешеп, ныклап уйлап эшләргә утырдылар. Уңышлар телибез аларга. «Исемсез утрауда» пьесасын язган Марсель драматургиядә үз исемен алыр дип өметләнәбез. Төкле аягы белән килсен.

Ике съезд арасында Язучылар союзына член итеп өч яшь драматург алынды. Ризван Хәмид, Юныс Сафиуллин һәм Фоат Садриев. Шуларның берсе, элегрәк әйткәнемчә, биш-алты ел эчендә танылган драматург булып җитеште. Фоат әле һаман көттерә. «Кондырлы кодача»сы яшь драматург өчен начар әсәр түгел, ләкин Фоатны инде олы итеп күрәсе килә. Юнысыбыз да өч пьеса язып куйдырганнан соң запасы саекты шикелле. Үзегез дә сизәсездер, болай гына булмый бит, егетләр. Малай булып күпме йөрергә була? Драматургиябезнең киләчәге өчен җаваплылыкны үз җилкәгезгә алырга вакыт.

Әдәби осталык турында тезис формасында әйтеп киткән идем инде. Инде кинрәк тукталырга кирәктер, чөнки ул, минемчә, безнең шактый ук йомшак ягыбыз. Без нәрсә әйтергә кирәклеген беләбез, әмма ничек итеп әйтергә икәнен белеп бетермибез.

Иң беренче — әсәрләребезнең теле. Бик күпләребез телнең стихиясен тоеп җиткермибез. Әсәрләрдәге геройларыбыз җыелышып гәҗиттә язылганча яки бүтән телдән тәрҗемә ителгәнгә охшаш бер тел белән сөйләшәләр. Бу үз чиратында геройларның индивидуальлеген югалтуга, характерларның бертөрлелегенә, дөресрәге, төссезлегенә алып бара. Бу хакта нык уйланырга кирәктер. Тирән фикерне ничек әйтсәң дә ярый дип уйлаучы иптәшләр ялгышалар. Ризван Хәмид тә тел белән саксызрак эш йөртә, Әхәт Гаффарның персонажлары кайвакыт шулай сөйләшеп җибәрәләр ки, аларның ни сөйләгәнен автор үзе аңлыймы икән дип уйлап куясың. Чыкырдап торган авыл малае Фоатны тормышта тыңлап туймаслык, ә менә яза башласа, көязләнә, төчеләнә, кылана. Ни хикмәттер, хәтта табигыйлек остасы Мөхәммәт Мәһдиев геройлары да сәхнәдә ясалма тел белән сөйләшкәләп алалар. Сәхнәгә күтәрелгәч «артистланып» сөйләшергә кирәк дип саныйлар, ахры, пьеса язучылар.

Безнең икенче җитешмәгән ягыбыз — геройларыбызның табигый яшәве өчен дөрес урын һәм дөрес ситуация сайлый белмәү. Ясалма ситуация, ясалма характерлар арасында, әсәрләребезнең ышандыру көче җитәрлек булмый. Безнең кайбер пьесаларны караганнан соң күп кенә тамашачыларның «Алай булмый бит инде», дип әйтүләрендә хаклык бар. Мәсәлән, өлкән драматургыбыз Сәет ага Шәкүровның «Карт гашыйк» комедиясе яртысына хәтле әйбәт кенә килә дә шуннан башлана галәмәт. Була алмый алай. Бу ситуация бу геройның характерына туры килми, ул персонаж ул ситуациядә алай эшли алмый, андый сүз сөйли алмый. Характерлар логикасы, «предлагаемые обстоятельства» дигән нәрсәләр бар, профессионал язучылар аны белергә тиешләр ләбаса.

Интрига дигән сүзнең әдәби термин буларак ни аңлатканын да әдәби әсәр язарга алынган кешенең белүе мәҗбүри. Югыйсә, язган пьесаларыбызның шактые маймылы булмаган зоопаркны хәтерләтә. Кайвакыт эре-эре темаларны эләктерергә дип ауга чыгабыз да, туры төзи алмавыбыз аркасында, темаларны «яралап» кына җибәрәбез. Әдәби осталыкның җитешмәве, минемчә, наданлыгыбыздан түгел, күп очракта иренүебездән килә. Җентекләп уйларга иренәбез. Театрларыбыз да сыйфат мәсьәләсендә еш кына талымсызлык күрсәтәләр. Объектив сәбәпләр дигән сылтау табып, әдәби әсәр булып җитешмәгән пьесаларны сәхнәгә чыгаралар. Ә без, мыштым гына шул «объектив сәбәпләргә» ышыкланып, вакыт-вакыт халтура да төрткәлибез. Шома гына үтеп китә. Тәнкыйтьчеләребез, шөкер, тәнкыйтьтән түбән нәрсәләрне тәнкыйтьләп вакланмыйлар.

Тәнкыйть сүзен куллангач, тәнкыйть турында да әйтми үтеп булмас. Драматургия белән махсус шөгыльләнгән тәнкыйтьчеләребез бик аз. Азат Әхмәдуллиннан башка җитди итеп уйланган кешебез юк шикелле. Калганнар күбрәк театр тәнкыйте белән шөгыльләнә. Пәри башка, җен башка, дигәндәй, болар икесе ике нәрсә. Дөрес, теге яки бу спектакльдә язылган рецензияләрдә драматургның исеме телгә алына, әмма аның әсәренә спектакльдән алган тәэсирдән чыгып бәя бирелә. Бик яхшы пьесадан да бик начар спектакль эшләп булганны, начар пьесадан беркайчан да яхшы спектакль ясап булмаганны беләбез. Тик менә кайчакларда спектакльгә рецензияне пьесаны укымаган килеш язабыз.

Без төрле җыелышларда тәнкыйтьчеләргә бәйләнергә яратабыз, алардан гаеп эзлибез, тәнкыйтьләмиләр, дибез, әгәр тәнкыйтьләсәләр, югарыда әйтеп үткәнемчә, аларның фикерен, тешләр шыгырдатып кабул итәбез. Әле җитмәсә, тәнкыйтьчеләрне тәмам өркетү, куркыту өчен, аларның борын төпләренә Мәскәүдә тәрҗемә ителгән пьесаларыбызны китереп терибез. Янәсе, син минем белән шаярма — Мәскәүдә юкбар нәрсәне тәрҗемә итмиләр...

Шул уңайдан соңгы елларда еш телгә алына торган мәсьәлә — Бөтенсоюз аренасына чыгу мәсьәләсенә тукталып үтәргә телим. Ул драматургиягә генә түгел, әдәбиятыбызның башка жанрларына да кагыла. Әлбәттә, идеология эшендә аренаның зурысы, бәләкәе була алмый. Үзебезнең аренада да без югары сыйфатлы итеп эшләргә тиешбез. Әмма безнең сүзебезне илебездә яшәүче башка халыклар да ишетсә, ул сүзнең кыйммәте күп тапкыр артачак.

Кайбер спортчылар була: алар ил эчендә үткәрелгән ярышларда искиткеч нәтиҗәләр күрсәтсәләр дә, дөнья күләмендәге җаваплы ярышларда җиңү яулый алмыйлар. Күрәсең, психологик хәзерлекләре җитешми. Мин үзебезне дә шул спортчылар хәлендәрәк күрәм. Ярыйсы гына язабыз да шикелле, тик зур съездларда бүтәннәр мактала. Осталыкны арттыру белән бергә, үшәнлек, мокытлык барьерын да узарга, оештыру мәсьәләләрен оештырырга да кирәк. Ә бит Бөтенсоюз аренасына чыгарга безгә комачаулаучы юк. Киресенчә, РСФСР Язучылар союзы, РСФСР Культура министрлыгы, Мәскәү нәшриятлары, үзәк газеталар һәм журналлар безне ачык йөз белән каршы алалар.

Нәшрият сүзе телгә алынган икән, безнең пьесаларны вакытында укучыларга җиткереп торганы өчен Татарстан китап нәшриятына да драматурглар исеменнән рәхмәт әйтәсем килә.

Әйтергә теләгәннәрем әйтелде шикелле. Гәрәй Рәхим, опера өчен либреттолар турында да әйтергә онытма, дип хат язган иде. Бу безнең үзәккә үткән нәрсә, әйтеп кенә булмый инде, күрәсең. Шул үксез, ятим жанрны сөйрәп барырга омтылучы Гәрәйнең үзенә рәхмәт әйтергә генә кала.

Чыгышымда мин җитешмәгән ягыбызга күбрәк тукталдым бугай. Әмма бу үзебезне бетереп ташлау өчен түгел, ә уңышлардан башыбыз әйләнеп китмәсен өчен. Димәк, эшләгән эшебез белән бергә, эшлисе эшләребез дә күп. Әйбәтлекнең чиге юк һәм беркайчан булмаячак. Үсүдән генә туктый күрмик. Безнең алга партия куйган бурычларны һәр даим истә тотыйк. Югары идеяле, югары осталык белән язылган әсәрләр иҗат итеп, ил, халык мәнфәгатьләре белән яшәүче совет кешесе тәрбияләргә булышыйк.

# Мөхәммәт Мәһдиев

# ПРОЗАБЫЗ НИ ХӘЛДӘ?

Проза — әдәбиятны әйдәп бара торган жанр. Һәр әдәбиятның казанышлары турында иң элек проза жанрының хәленә карап фикер йөртәләр. Проза — әдәби процессның көзгесе кебек. Ул көзгедә безниләр күрәбез соң? Беренче карашка ук кайбер тематик цикллар аерылып торуын күрәбез. Әлбәттә, матур әдәбиятның эшче, колхозчы, интеллигенция темасына бүленүе шартлы нәрсә. Иң элек ул кешене өйрәнә. Шулай булса да, язучы тормышның аерым бер катламын ала, шуның турында әсәр яза.

Соңгы биш елда бездә эшче темасына багышланган әсәрләр шактый язылды. Бу юнәлештә Ш. Бикчурин, Ә. Баянов, Р. Кәрами, Җ. Рәхимов, М. Хәбибуллин һ. б. эшләде. Дөресен әйтергә кирәк, бу җиңел тема түгел, авторларның материалы да яңа. Алар игътибар үзәгенә әле күптән түгел генә авыл кешесе булган нефтьчеләрне, автогигант төзүчеләрне алдылар.

Әлеге юнәлештә нинди уңышларга ирештек соң? Яңа тип эшченең — нефтьченең, төзүченең, автогигант салучының — тормыш-көнкүрешен сурәтләдек. Татар прозасы бу җәһәттән РСФСРның милли әдәбиятлары арасында иң актив эшләгәне булды, ул бүгенге эшче образын ачарга, кызыклы типлар булдырырга тырыша. Бу гаять катлаулы һәм авыр эш. Шуңа да карамастан, безнең язучылар әлеге өлкәдә шактый кыюлык күрсәтәләр.

Ике съезд арасында безнең прозада производствоның төрле якларын тасвирлаган романнар, повестьлар, хикәяләр язылды. Монда Түбән нефтьчеләре дә (Ш. Бикчуринның «Тирән катлам» романы), КамАЗ эшчеләре дә (Ә. Баянның «Таш китап» романы), су каналы үткәрүчеләр тормышы да бар иде (Ә. Шәминның «Яңа ярлар» повесте). М. Хәбибуллинның «Хәтер ярлары», Җ. Рәхимовның «Тәвәккәл таш яра» повестьлары да үз укучысын тапты. Моңа М. Хәсәновның «Шөгеровлар» романын, А. Хәсәнов, Ф. Гыйльметдинов, Ә. Сафиуллин, Л. Хәмидуллин повестьларын һәм хикәяләрен дә өстәргә кирәк. Аларның һәрберсе вакыйгасы һәм сурәтләү манерасы белән аерылып тора. Ә. Баянов реаль фактны шартлы алымнар белән үреп сурәтләргә ярата, башкалар мавыктыргыч композиция төзиләр. Шул ук вакытта бу теманың йомшак ягы да бар,— ул да булса — очеркка якын тору. Кайбер әсәрләрне очерк дип атыйсы килә... Әмма очерк та бит төрлечә була. Вл. Овечкинның «Деревенские будни» исемле очеркларын, Ф. Галиев, М. Юныс эсселарын алыйк! Әгәр рус әдәбиятында иң яхшы очеркларны Овечкин язган булса, татарларда, һичшиксез, колхоз председателе Ф. Галиев һәм М. Юныс...

Безнең прозада икенче тематик цикл — ул авыл прозасы. Ике съезд арасында бу темада Х. Сарьян, Б. Камал, Г. Гыйләҗев, В. Нуруллин, Р. Төхфәтуллин һ. б. актив эшләде. Күргәнебезчә, авыл темасын шартлы рәвештә урта һәм өлкән буын дип аталган әдипләребез тартып бара.

Прозаикларыбызның барысы да диярлек авылдан чыккан кешеләр. Алар сугыш
елларын күргән, сугыштан соңгы елларның авырлыгын да татыган. Алар. мәктәпне
яки берәр училищены бетереп, югары уку йортларына омтылдылар, башлыча, фило-
логия бүлеген тәмамладылар, аннан соң шәһәрдә утырып калдылар. Эшне дә иҗат
оешмалары тирәсеннән сайладылар — редакцияләргә, нәшриятка урнаштылар. Акрын-
лап яза башладылар. Нәрсә турында? Яңа төзелешләр, нефтьчеләр, автозавод салу-
чылар, химиклар турында язу җиңел эш түгел, монда кыска сроклы командировкага
барып кайту белән генә эш майтарып булмый. Кайберәүләр яңа материалны үзләш-
терә алмадылар. Шул ук вакытта бүгенге авыл тормышы да — язучы өчен менә дигән
материал — алар өчен каты чикләвек булып чыкты. Авыл тормышының язучы ал-
дында социаль-экономик мәсьәләләр генә түгел, фәлсәфи-әхлакый мәсьәләләр дә
куюын бу буын язучылар яхшы аңлыйлар. Һәм шушыны аңлаган хәлдә күп кенә
әдипләребез җиңел юлны сайладылар.

Бу хәл бигрәк тә яшьләр иҗатында ачык чагыла. Бүгенге авыл тормышында кай-
ныйсы урында, алар шәһәрдә тупләнеп калдылар һәм авылларның үзгәрүе, бетә ба-

руы турында яшь агызырга керештеләр. Авылга карата сентименталь-романтик мөнәсәбәт хасил булды. Безнең прозага авылдан киткән геройның сагыну-сыкрану авазлары килеп керде. Нилектән бу? Тормышны белмәүдән! Хәзер авыл яңа үсеш, күтәрелеш чорын кичерә, партия авылларны саклау, анда яшәгән халыкның материаль хәлен яхшырту курсына басты. Һәм безнең проза бу үзгәрешләрне бөтен тирәнлеге, катлаулылыгы белән аңларга, чагылдырырга бурычлы.

Әйе, кайбер прозаикларыбызның ялгышы күз алдында. Без, авылдан чыккан язучылар, мәсьәләне бер ягыннан гына күрдек. Кайсы ягыннан? Мәсьәләнең әхлакый-этик ягын гына күрдек, төп игътибарны шуңа юнәлттек. Әмма шуны да әйтеп узарга кирәк: әхлак мәсьәләләренең роле безнең әдәбиятта үскәннән-үсә бара. Әдәбияттагы геройларыбызның яшәү рәвеше, нинди мохиттә булуы безне борчымый кала алмый. Хәзер бездә санаторий-больница-палата әдәбияты чәчәк ата. Хәтта уңышлы язылганнарында да (М. Маликованың «Ак давылда тал бөресе», Б. Камаловның «Өметең өзелмәсен» романнары, Л. Хәйдәрованың «Кырым хикәясе» повесте, Р. Төхфәтуллинның «Ике каен, бер карама», М. Рафиковның «Айрат» хикәяләре, Р. Кәраминең «Йөрәгемне ут алган» повесте)— вакыйгалар я больница палатасында бара, яисә анда яткан кешенең хатирәләре аша бирелә...

Нилектән бу? Телгә алынган әсәрләрнең барысы да укыла, күбесе — кызыклы әсәрләр. Эш шунда ки, прозаик үз авылыннан һәм югары уку йортыннан башка берни дә күрмәгән. Аның «дөньясы» көнкүреш ыгы-зыгысы, мәхәббәт, аерылышулар, мавыгулар һәм күңел сүрелүләр белән тулган һәм бу үз чиратында язучының материалына әверелгән. Һәм шул сәбәпле кайбер язучылар дөньяны массовый укучы югарылыгында гына күрәләр. Шулай булгач, укучыларның иң зур бәяне урта кул хикәягә, яисә тормыш-көнкүреш мәсьәләләренә, гаиләдәге ыгы-зыгыга багышланган урта кул романга бирүләре гаҗәпләндермәскә тиеш. Массовый укучыга шул ошый. Бәхетсез гаилә тормышы турындагы романга килгән укучы хатларына гына таянып, үзеңне иң популяр язучы дип уйларга ярамый. Шунысы кызык: моның чше әсәрләр бер-берсенә бик охшаш булалар: яшьлек, студент еллары, беренче мәхәббәт, кыз яки егет мәхәббәткә бәя бирәп бетерми, аерылышу, еллар узгач яңадан очрашу; ирнең инде чәчләренә чал кергән, ялгыз яши, ә хатын яратмаган кешесенә кияүгә чыккан, аерылган, кызы үсә һ. б. А. Ивановның «Повесть о несбывшейся любви» исемле повесте бар. Анда бер танылган язучының газаплы тормышы сурәтләнә. Бервакыт язучы яңа повесть язарга уйлый: әсәрнең героинясы, шәһәр коммутаторындагы телефонистка, мәхәббәте җавапсыз калудан газаплана, балага узып, ерак Себергә качып китә.

Язылачак әсәр сюжеты белән танышкан тәнкыйтьче аңа болай ди: «Монда хисләрнең кайнарлыгы Шекспирдагы кебек! Ләкин героиняңны кая озатмакчы буласың? Себергә? Ташла! Нечерноземье зонасына китсен. Актуаль төбәк!»

Безнең татар прозасында да соңгы елларны шушындый алым күбәеп китте. Исең китәрлек: әллә безнең җәмгыятьтә гаилә борчуларыннан бүтән язарлык әйбер юкмы? Бәхеткә каршы, бар. Безнең әдәбиятта да язучылар зур темаларга алыналар, шул исәптән, шактый югары идея-эстетик планда әхлакый мәсьәләләр күтәрелә. Үрнәк өчен А. Расихның «Сынау» романын гына алыйк. Ул ике съезд арасындагы иң яхшы романнардан санала, гәрчә тел ягыннан кайбер таләпләргә җавап биреп бетермәсә дә.

Соңгы еллар татар прозасының иң мөһим казанышы «рухисызлык белән көрәшү» дип атап булыр иде. Бу көрәш безнең прозада күп планда бара. Монда рухи мещанлык, әйбер җыю тенденцияләренә каршы көрәшү дә, кешенең җанын саклап калырга омтылыш та бар... Бу өлкәдә А. Гыйләҗев, М. Юныс, В. Нуруллин, Ә. Баянов һ. б. уңыш казанды.

80 нче еллар прозасына иң зур өлеш керткән язучы А. Гыйләҗев булды. Шәхеснең эшчәнлеге һәм әхлакый кыйммәте, яхшылык белән явызлык проблемасы, җаваплылык, кеше алдына куелган бурыч, намус, яшьләрне тәрбияләү — болар әдипләребезне борчымый кала алмыйлар. Гыйләҗев повестенда нәкъ менә шундый мәсьәләләр күтәрелә, шуңа күрә дә язучының әсәрләре үз укучысын тапты, әйтергә кирәк, дөнья язмышы белән борчылып яши торган зирәк һәм акыллы укучысын.

Әхлак мәсьәләләре татар прозасында «ФТР чорында кеше һәм табигать» дигән

проблема белән бергә күтәреләләр. Кеше һәм табигать, кеше һәм җир — бу темалар көн тәртибенә әхлакый-этик планда куелдылар. «Кеше һәм табигать» темасына багышланган прозабызның күпчелек өлеше замандашыбызның табигатькә булган мөнәсәбәтен күрсәтә. М. Юнысның «Табу һәм югалту» повесте бу җәһәттән аерылып тора. Сюжеты гади, бәлки, әллә ни яңа да түгелдер. Авылдан чыккан шәһәр кешесе шәһәрдә үскән кызы белән берничә көнгә туган авылына кунакка кайта. һәм шунда үз-үзен таба. Әмма бу табу аңа җиңеллек китерми, зур һәм ыгы-зыгылы шәһәрдә яшәп, ул үзенең нәрсәләр югалтуын тагын да тирәнрәк аңлый. Ф. Бәйрәмова да «Болын» повестенда шушы ук идеяне үткәрә.

Ике повесть тә лирик дулкында язылган. Лирик проза башлыча авыл тормышына, табигатькә багышланган әсәрләр җирлегендә барлыкка килә. Соңгы еллар татар прозасында тематика һәм проблематиканың баюы белән беррәттән авторлар составы да үзгәрә. Язучылар союзы — тере организм, анда даими хәрәкәт бара, көчләр гел үзгәреп тора. Мәсәлән, соңгы ун ел эчендә байтак шагыйрьләр үзләрен прозада сынап карадылар. һәм бу кайбер уңышларга да китерде. Ф. Яруллин, Р. Гәрәй, Ф. Шәфигуллин, М. Галиев, Р. Вәлиев, Р. Низамов, Б. Сөләймановлар Язучылар союзына шагыйрь буларак кабул ителгәннәр иде. Әмма проза да язалар. Тәнкыйтьче Р. Мөхәммәдиев тә үзен прозада күрсәтеп алды. Н. Гыйматдинова белән К. Кәримов та уңышлы гына әсәрләр яздылар. Ике съезд арасында күбесенең хикәяләр һәм повестьлар җыентыгы дөнья күрде. М. Галиевнең «Ерак урман авазы», Г. Рәхимнең «Көннәр язга авышкач» повестьларын да яшьләр яратып кабул итте. Мәрхүм прозаик Ф. Шәфигуллин да ике съезд арасында бик үзенчәлекле эз калдырды. Аның «Өй салуның ние бар?» исемле повесте авыл малаеның тәҗрибәле диңгезче, нык характерлы чыныккан ир-атка әверелүен сурәтли. Повесть укучылар тарафыннан бик җылы каршыланды. Киләчәктә безнең арадан бик иртә киткән бу язучының әсәрләрен тулы басма итеп чыгару турында кайгыртырга кирәк.

Н. Фәттахның «Сызгыра торган уклар» романы татар прозасында тарихи романның үсешен билгеле торган әсәр булды. Роман безнең эрага кадәр үк яшәгән төрки сөн кабиләләренең берләшүе өчен көрәшен тасвирлый. Дөресен әйтергә кирәк, ерак тарихны сурәтләү җиңел нәрсә түгел. Авыр материал. Борынгы сөннәр турында роман язу җитди эш, аны язу өчен бик күп чыганакларны, фактларны өйрәнергә һәм бүгенге көн белән бәйли белергә кирәк. «Сызгыра торган уклар» борынгы чорга багышланган булса да, актуаль яңгырый. Үзәккә куелган проблемасы һәм идеясе белән бүгенге көн таләпләренә җавап бирә: дөньяда тынычлык өчен халыкләр үзләре көрәшсәләр генә аны саклап булачак, ди. Безнең укучы тарихка һәм тарихи шәхесләргә бервакытта да битараф булмады. Җәмгыятебез тарихы, революцион хәрәкәт мондый шәхесләргә ифрат та бай. А. Расихның «Ямашев» романын да нәкъ менә шул планда карарга кирәк. Большевик Х. Ямашев тормышын сурәтләү авторга җиңел булмагандыр — чөнки бу бик тә катлаулы һәм авыр чор. Ул даими рәвештә полиция һәм жандармерия күзәтүе астында яшәргә мәҗбүр. Материалның авырлыгы тасвирлау чараларына да тәэсир итми калмаган, чөнки һәр геройга индивидуаль тел, холык кирәк, аларның бер-берсенә туры килүе дә кирәк. Автор Х. Ямашев образын фикердәшләре белән җанлы элемтәдә сурәтләгән.

Безнең прозада һаман әле гражданнар сугышы, авылда барган сыйнфый көрәш, коллективлашу елларына багышланган әсәрләр язылуы сөенечле хәл. Бу җәһәттән Г. Бәшировның «Сарут» хикәясен тәнкыйть иң яхшы әсәрләрдән дип тапты. Хикәядә тормыш тарафыннан фаҗигагә хөкем ителгән дуамал кеше язмышы сурәтләнә. Гражданнар сугышы темасына Г. Галиев, С. Сабиров та мөрәҗәгать иттеләр. һәм иң кызыгы — ул яшьләр иҗатына килеп керде. Мәсәлән, яшь прозаик М. Галиев «Ерак урман авазы» повестенда заманнар арасындагы бәйләнешне табарга тырыша, ул чордан бүгенгегә күчеп, хәзерге яшьләрдә Октябрь идеяләренең дәвамын күрә. Шундый ук омтылыш Ә. Гаффарның «Бодай бөртеге һәм тегермән ташы» романында да бар. Роман композициясе ягыннан кызыклы, материалы бай, шулай да М. Горькийның К. Нәҗмигә әйткән сүзләрен авторның исенә төшерәсе килә. Ул болай дигән: «Если разрешите, я бы посоветовал Вам писать проще, истинная красота и мудрость всегда в простоте... И слова тоже должны быть простые, ясные...»

Укучылар Х. Сарьянның соңгы «Җәза» повестен да яратып кабул иттеләр. Анда

гады тел белән, куертуларсыз авылда барган сыйнфый көрәш сурәтләнгән. Кызганычка каршы, ул тәгәлләнмичә калды.

Күренә ки, бүгенге татар әдәбиятының тарихи проблематикасы киң: борынгы көннәрдән алып Октябрь революциясе, коллективлашу һәм Бөек Ватан сугышына кадәр. Хәзер бу өлкәдә эшләүче язучыларыбыз алдында бай тарихыбызның башка дәверләрен яктырту бурычы тора.

Хәрби тема хакында да берничә сүз әйтеп китәсе килә. 70 нче еллар ахырында безнең сугыш прозасы ирешелгән казанышларны синтезлау тенденциясе белән килде. Ике съезд арасында Бөек Ватан сугышы темасы бездә төрле формада күренгәләде: монда Ш. Рәкыйповның «Кайда син, Жан?» документаль повесте, А. Шамов хикәяләре, М. Юнысның «Биектә калу» повестьлары бар. Әйе, безнең укучы сугыш прозасын яратып укый. Сугыш әдәбияты — яхшы тәрбияче, тарих укытучысы кебек ул. «Биектә калу»да сугышның соңгы көннәре җиткәч самолет экипажы авыр сугышта һәлак була. Повестьның ахыры тетрәндерә: улы янган самолетта җиргә кадалган чакны ерак татар авылындагы әнкәсе, күрше карчыкларын җыеп, сугыш бету, газиз баласы исән калу хөрмәтенә аш уткәрә. М. Юнысның «Биектә калу»ын «Казан утлары»нда дөнья күргән сугыш турындагы әсәрләрнең иң яхшыларыннан берсе дип әйтергә була. Бездә хәзер фронтовик-язучыларның саны көннән-көн кими. Бу җәһәттән сугыш темасына язылган иң яхшы солдат романы Х. Камаловның «Һәркемнең гомере бер генә» булып кала. Ул автор гүя безгә: «Әгәр дә сугыш темасына алынасыз икән, Ватан өчен сугышкан кебек кыю булыгыз һәм дөресен языгыз», ди.

Шушы теманың икенче ягында сугыштан кайтмаган әтиләрен сагынучылар тора. Бу төр әсәрләр лирика белән сугарылганнар, аларда фронтовикларны сагыну көчле. Сюжет-композиция ягыннан алар бер-берсеннән әллә ни аерылмыйлар. Шулай да Б. Камаловның «Актуган Габсаттары» исемле повестендагы фронтовик карт образы башкалардан аерылып тора. Яшь язучы С. Шәмсинең «Балконда» исемле хикәясендәге яратып, җылы хис белән язылган фронтовик карт та истә кала.

Моннан башка да кайбер авторларның әсәрләрендә бүгенге армия тормышы чагыла. Бу — кирәкле һәм мөһим тема, безнең әдәбиятта ул 30 нчы еллардан ук килә. Р. Вәлиевның «Яшисе килә!» повесте безнең прозаның уңышы дип әйтергә лаеклы. Повестьта якташыбыз Рифгат Миргазизовның тыныч көннәрдәге батырлыгы сурәтләнә. Элекке офицер Г. Кашапов та хәрби темада уңышлы гына эшләп килә. Дөрес, аңа әлегә осталык, стиль йөгереклеге җитеп бетми, әмма үзенә таләпләрне арттырганда моны төзәтеп булачак дип уйлыйм.

Көнбатышта хәзер хәрби тема модадан чыккан. Нью-Йорк нәшриятларыннан бер директор язучы А. Адамович белән әңгәмәсендә хәрби темага язылган китаплар бездә сатылмый ята, зыян гына китерә, ди. Башка капиталистик илләрдә дә бу теманы онытырырга тырышалар. Ләкин сугыш югалтулары нинди булса, аның хәтере дә шундый! Халыкның бөек батырлыгы онытыламы соң? Совет язучылары сугыш афәтләрен сурәтләп сугышка каршы көрәшәләр, һәм бу юкка гына түгел. Безнең язучылар сугыш чукмарларының планнарын фаш итәләр.

Без хәзер бик зур бәйрәмне — фашистлар Германиясен тар-мар итүнең 40 еллыгын билгеләп үтәргә хәзерләнәбез. Безнең әдәбият бу бөек бәйрәмгә яхшы романнар, повестьлар, хикәяләр һәм сугыш турындагы мемуарлар белән килә. Бөек Ватан сугышы ветераннары әле дә безнең сафта!

Татар прозасында галимнәр, сәнгать кешеләре, укытучылар — интеллигенция вәкилләренә дә зур игътибар бирелә. Безнең әдәбиятта бу гаять көчле һәм тулы канлы юнәлеш. Шушы биш елда гына да А. Расихның «Сынау», М. Маликованың «Ак давылда тал бөресе» романнары, Т. Миңнуллинның «Хәсән Вагыйзович», В. Нуруллинның «Һәлакәт», К. Тимбикованың «Кышкы талпыну», И. Сәлаховның «Мәхәббәт картаямы?», Р. Вәлиевның «Иске сәгать дөрес йөри» повестлары, Ф. Хөсни, Р. Ишморатова һ. б. хикәяләре басылды. Һәрхәлдә, безнең интеллигенция язучыларның игътибары җитмәүгә зарлана алмый.

Бу елларда «Казан утлары» журналы рус телендә язучыларга да игътибарын көчәйтте. Кызык күренеш бу — рус телендә язган хәлдә, алар безнең әдәбиятның интернациональ характерын тирәнәйтәләр, үзенчә бер төсмер өстиләр. Журнал битләрендә басылган Р. Кутуй, М. Зарипов (Казан), И. Кашафетдинов (Обнинск), А. Миф-

газетдинов (Магадан), Р. Вәлиев (Чиләбе), Р. Мирхәйдәров (Ташкент) әсәрләре укучыларда канәгатьләнелек хисе уятты, чөнки бу әсәрләрдә безнең якташлар яшь, алар башка милләт вәкилләре белән янәшә торып эшлиләр.

Әдәбиятта мемуар-биографик жанрның көчәеп китүе — заман күренеше, ул үзенең һәм гражданлык активлыгының үсүенә бәйләнгән. Шушы вакыт эчендә татар әдәбиятында мондый характердагы дүрт повесть басылып чыкты. Һәркайсы вакыты, материалы, язылу ысулы белән бер-берсеннән аерылып тора: Ә. Еники — «Соңгы китап», М. Әмир — «Үсә төшкәч», Г. Ахунов — «Йолдызлар калка», Г. Бәширов — «Көзге ачы җилләрдә».

Ә. Еники повестендагы вакыйгаларны лиризм берләштерә. Анда Дим буеның матур тугайлары, Дәүләкәннең эшчән һәм бай күңелле кешеләре, тугандаш Башкортстанның кунакчыл халкы һәм гаҗәеп матур табигате сурәтләнә — болар барысы да язучыга хас нечкәлек белән вәземләп язылган, укучыны әдипнең хисләр дөньясына алып кереп китә, кешедәге рухи тормышның катлаулы булуына тагын бер кат инандыра. «Соңгы китап»ны укыгач, нилектәндер ямансу булып китә, аның битләренән кырлар, урманнар, елгаларның моңсу авазы ишетелә. Әмма бу — укучының күңелен яктырта, сафландыра, баета торган моңсулык. М. Әмир автобиографик повестенең өченче кисәге бөтенләй башка манерада язылган. Бу әсәре дә аңа хас юмор белән сугарылган, ул безне Казан тормышына, 20 нче еллар ахырында иҗат иткән рәссамнар, язучылар, шагыйрьләр арасына алып кереп китә. Киләчәктә 20 — 30 нчы еллар татар әдәбияты турында монография язарга алынучыга бу повесть гаять кыйммәтле чыганак булып хезмәт итәчәк. Г. Бәшировның «Көзге ачы җилләрдә» повестенда да Татарстанның әдәби хәрәкәте сурәтләнә. Г. Ахуновның «Йолдызлар калка»сы да әдәбият белгечләренә кыйммәтле мәгълүмат бирәчәк. Бирелдә әдәби хәрәкәт тасвирлана, бигрәк тә Татарстан Язучылар союзының 60 нчы елларда оештырылган Әлмәт бүлеге тормышы яктыртыла. Бүлекнең нефть районында алып барган эшчәнлеге, нефтьчеләр тормышына багышланган әдәбиятның үсеп чыгуы, ныгуы тасвирлана.

Әлбәттә, һәр язучы мемуар язарга хаклы, һәркемнең үз язмышы, үз биографиясе бар. Һәм, язучы буларак, ул зур кешеләр белән очрашкалап тора. Тик мондый акцентларның дөрес куелуы шарт. Автобиографик жанрдагы әсәр язганда «автобиография үзең турында гына язу түгел, ә яшәү дәверендә син күргән һәм яратып елгергән әйберләр» икәнен онытмаска иде. Мемуар жанрына алынган һәрбер автор өчен бу кагыйдә булырга тиеш.

Соңгы 10—15 ел эчендә татар прозасында детектив жанры актив үсә. Әдәбиятта детективка тәрбияви бурычлар да йөкләтелә, ул гражданнарда уяулыкны арттыра, җинаятьчел элементлар һәм совет власте дошманнары белән көрәшергә ярдәм итә.

М. Насыйбуллин безнең татар прозасында иң актив «детективист», аның юриспруденция өлкәсендә дә зур тәҗрибәсе бар. М. Насыйбуллин күп яза, журналларда һәм газеталарда да аны еш күрәсең, нәшриятны да әйләнеп узмый. Мондый ашыгу кайчакта тел чараларына игътибар җитмәүгә, кабатлануларга, стиль чуарлыгына китерә. Ике съезд арасында аның «Ярканат» исемле зур повесте басылып чыкты — кирәкле, бүгенге көн әсәре.

М. Хәбибуллинның «Сулар үргә акса да» романы да шул ук идеяга корылган — әсәрдә милиция хезмәткәрләренең эшчәнлеге сурәтләнә. Мондый әсәрләр укучыга бик тә кирәк. Алар яратып укыла. Әмма детектив әдәбиятның төп максаты мавыктыргыч вакыйгалар гына түгел, ә укучыны тәрбияләү.

Шулай итеп, без ике съезд арасында дөньяга килгән проза әсәрләренә күз йөртеп чыктык. Күрүебезчә, прозаиклар заман таләпләренә җавап бирергә тырышып, интенсив эшләгәннәр, тормышыбызның катлаулы мәсьәләләрен күтәреп чыкканнар. КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре иптәш Г. И. Усманов үзенең 1984 елда «Казан утлары»нда басылып чыккан мәкаләсендә: «Матур әдәбият әсәрләренә бәя биргәндә аларның бүгенге тормышыбызга, производство атмосферасына ни дәрәҗәдә йогынты ясавын да исәпкә алырга вакыт түгелме икән?» — диген иде. «Механизаторны, терлекчене, һәм шунда ук язучыларга конкрет сорау да бирелде: «Механизаторны, терлекчене, авыл яшьләрен тормышыбызның иң мөһим проблемаларын хәл итүдә тупләрдәй, үз артыннан ияртердәй уңай геройларыбыз күпме соң безнең?»

Бу сорауга җавап бирү — республикабыз язучыларының партия һәм гражданлык бурычы булып тора.

Илдар Юзеев

# КҮКРӘГЕҢДӘ ШИГЫРЬ УТЫ САУМЫ

Астрономнар Галлей исемле комета ачканнар. Җирдә аны соңгы мәртәб 1910 елны күзәткәннәр. Ул безгә яңадан 1986 елны күренәчәк. Халыклар ның даһи шагыйрьләре дә, шул комета шикелле, бик сирәк кенә туа Нәкъ Тукай шикелле. Ул бездән ерагайган саен, йөз еллык юбилее якынлашкан саен, якыная зурая бара.

Галлей кометасын символлаштырып, без әдәби галәмебездә сигез гасыр элек калыккан һәм безнең күңелләрдән китми торган Кол Гали кометасы дип тә күз алдына китерә алабыз. Тукай йолдызлыгы да шуннан, борынгы Галиләрдән.

«Галлей кометасын күрәм әле мин»,— дип кабатларга ярата иде Хәсән Туфан. Кометадан да бигрәк, Кол Галинең 800, Тукайның 100 еллыгын күрергә ашкынгандыр инде шагыйрь. «Үтте тормыш пычрагын гәүһәр кеби вөҗдан белән, аз гына кер кунганын да кай җиреннән кем табар»,— дип, идеал кеше тибын эзләгәндә, Тукаебыз Хөсәен Ямашевлар белән бергә, Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Хәсән Туфан кебек, үзеннән соң киләчәк шагыйрьләрне дә күз алдына китергән сыман. Поэзиябез 80 нче елларга Туфанын — бөек шагыйрен югалткан хәлдә килеп керде. Әмма шагыйрьнең рухы, изге мираска әверелгән иҗаты шигъриятебезнең җанында кала бирә.

*Поэмага ничә яшь дисәгез, җиде йөз дә илле яшендә,*
*Барлык әсәрләргә ул Дәү әни шигъри шәҗәрәбез башында.*

Утыз буын язучыларына әдәби тел, көй һәм җыр сеңдергән, халык тормышының энциклопедиясенә әйләнгән беренче татар поэмасы —«Кыйссаи Йосыф» алдында без бүген хөрмәт белән баш иябез. Күпме поэмалар әле тарих хәрабәләрендә күмелеп калган, күпмеләре сугыш утында яндырылган, юк ителгән... Муса Җәлилнең табылган дәфтәрендәге язмасын без хәзер тирән үкенеч һәм әрну белән укыйбыз: «Әсирлектә һәм таш капчыкта 135 шигырь һәм бер поэма иҗат иттем... Әмма кайда языйм? Үзем белән бергә үләләр...»

Рәхим Саттарның серле һәлакәте — үзе бер югалган поэма.

«Язылмаган поэма»ны язгач, мин Дахау концлагеренда үлем барагында соңгы тапкыр Хәйретдин Мөҗәйне күргән Вәли Бикташевтан хат алдым. «Крематорийда яндырылыр алдыннан Хәйретдин миңа күңелдән шигырьләрен һәм бер поэмасын сөйләде»,— дип язды ул. Хәйретдин Мөҗәйнең соңгы поэмасы да үзе белән бергә фашистлар тарафыннан яндырыла. Фашизмга каршы көрәшеп туфракка һәм көлгә әйләнгән ике шагыйрьгә һәм ике поэмага мәңгелек дан!

Татар совет шигърияте фашист тоткынлыгында да үзенең җиңелмәс рухын күрсәтте. Муса Җәлил, Абдулла Алиш шигырьләре белән бергә, авторлыгын югалткан поэзия, көрәшчеләр иҗаты туа. Кулдан-кулга телдән-телгә күчеп, патриотизм тойгылары уяткан, актив көрәшкә чакырган яңа төр халык иҗатын аерым китап итеп тә чыгарырга, халык иҗаты китапларына кертеп тә өйрәнергә вакыттыр.

Хәзер мин атылулардан, янулардан исән калган, тыйнак фронтовик шикелле онытылган бер поэма — Ватан сугышының шигъри елъязмасы — дастаны турында сөйләргә телим. Бу — 2 нче Белоруссия фронты сугышчыларыннан татар халкына хат. Татар сугышчыларының үткән җиңүле юлын, каһарманлыгын реалистик-поэтик сурәтләп, киләчәк гасырларга калдырган киң масштаблы героик эпос. Дастанның геройлары — маршаллар, генераллар, солдатлар... Аның астына генераллар Чанышев, Булатов, Ганиев, герой очучы Мәгубә Сыртланова, шагыйрь Шәриф Мөдәррис, язучылар Хатип Госман, Атилла Расих, Гамир Насрый һәм башкалар... барысы дүрт мең татар сугышчысы кул куйган. Халыклар дуслыгына, батырлыгына дан җырлаучы бу гаҗәеп

шигъри документ онытылган, архив тузаннарына күмелгән. 1945 елны «Совет әдәбияты» журналында һәм шул ук елны аерым брошюра булып чыкканнан соң, аның әле бер тапкыр да дөнья күргәне юк. Дастанның иҗатчылары (инде аларның күбесе дөньяда түгел) — явыз дошманны юк итүчеләр — ышаныч белән киләчәккә мөрәҗәгать иткәннәр:

*Ирешсен сиңа хатыбыз мәңгелек китап булып,*
*Яуда җиңгән улларыңнан сугышчан хисап булып.*

Мәңгелек китап булып антологияләргә, дәреслекләргә керерлек бу шигъри хәзинә, килер буыннарга сәлам хаты онытылып ята бирә...

Ә сугыш, кырыктан артык ел узса да, онытылырлык түгел...



*Шагыйрь Г. Рәхим, «Казан утлары» журналының баш редакторы Р. Харис һәм РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре А. Волков (сулдан уңга).*

Дуга дәһшәтләрен онытмаган Сибгат Хәким сугыш-җинаятьтән торган Җир шары буйлап, җәлилчеләргә суд булган Дрезден залына барып җитә, татар шагыйрьләренең язмышын, горурланып, Европа уртасына басып сөйли. Лорка, Җәлилләр, Неруда лар рухын алып, тынычлык солдаты булып, сугышчыларга каршы күтәрелә. «Эзлә... ләр Европа буйлап» һәм «Күги» поэмалары укучыларны сугышка каршы үз артыннан ияртерлек көчкә ия лер һәм алар поэзиябезнең соңгы еллардагы уңышлары дип бәяләнергә хаклылар.

Иң авыр жанр булуга карамастан, поэмалар туа торалар. Биш елда гына да егермегә якын поэма басылган. Ә. Рәшитов, Ф. Гыйззәтуллина, Р. Хәкимуллина, Р. Рәкыйповлар берәр, икешәр поэма язып, осталыкның кайбер серләрен ача башлауларын һәм киләчәктә уңышлырак эшли алачакларын раслаганнар. Бу елларда поэманың эпик, лиро-эпик, лирик-публицистик, драматик цикл, трагедия, поэмалар бәйләме кебек формалары активлашкан. Поэманың төзелешенә, тукымасына башка жанрларның — проза, драма, опера сәнгатенең йогынтысы үтеп кергән, тәэсире көчәйгән, шуның нәтиҗәсендә синтетик төрләр барлыкка килгән. К. Сибгатуллинның «Ветераннар»

исемле шигъри новелласын проза итеп тә язып булыр иде, әмма авторның шигъри осталыгы вакыйга сюжетында да өстенлек алган. Р. Харисның «Ат нярләү» әсәрен дә поэтик новелла дип атарга мөмкин. Вакыйгага корылган кечкенә формалы поэмада геройның каршылыклы психологиясе ачыла. «Җәлилчеләр» исемле икенче поэмасында Р. Харис унике җәлилченең лирик монологын бер лейтмотив белән бәйли алган һәм бу темага үзенчә якын килгән. Р. Мингалимовның «Күк астында» әсәре авторның бу жанрда тагын да остара баруына дәлил. Р. Фәйзуллинның «Сәйдәш» поэмасына алынуы да кыю омтылыш иде. Әсәрдә кечле әйтелгән фикерләр, бүлекләр бар. Шулай да Р. Фәйзуллинның Сәйдәшкә әлегә шигъри ачкыч табалмавын хаклы әйттеләр. Заман проблемасының үзәгенә үтеп кергән, мәхәббәт һәм нәфрәт хисен трибуналарга күтәргән, публицистик дәртле, үзенчәлекле поэма туды. Ул — Зөлфәтнең «Йөрәкләрдә үлмәс дастан»ы. Иң матур әкиятне — кешелекне, киләчәкне юк итәргә уйлаган дошманнарга каршы набат-чакыру авазы булып яңгырый бу поэма. Әгәр автор әсәрнең берничә кимчелегенә игътибар итсә, ул тагын да зуррак яңгыраш алыр иде. «Циркта бунт» һәм «Биеклек» бүлекләре әсәрнең олы идеясен ваклыйлар, зур фикерне таркаталар, драматизмны киметәләр. Поэманы укып чыккач, миндә үкенечле бер уй туды. Родариның «әкиятне югалтмыйк!» дигән фикеренә дәлил итеп үзебезнең әкиятчебез Абдулла Алишны да алганда, әсәр отар гына иде. Җирдә әкиятне югалтмас өчен гильотинага барган баһадир үзе бит инде Алиш!

Һади Такташ «Киләчәккә хатлар»ын язып, һичшиксез, аларның килер буынга барып җитәренә ышанды. Бүгенге заман шагыйрьләре моңа кадәр беркем алдында да тумаган куркыныч проблема алдында калдылар: безнең Киләчәккә язган хатларыбыз адресатларына барып җитәрләрме, әллә, Роберт Әхмәтҗановның «Япон шагыйрьләренә» мөрәҗәгатендә әйтелгәнчә, илләр Хиросимага әйләнерме? М. Әгъләмов публицистик поэмасын «Онытма, Европа!», Х. Әюпов «Кеше тавышы» дип атады. Поэтик яктан әллә ни зур ачышка дәгъва итмәсәләр дә, мондый әсәрләр укучыны уяу булырга, тынычлык өчен көрәшче булырга чакыралар.

Поэмаларда геройларның дөнья белән бәйләнешләре, гомумкешелек проблемалары белән яшәүләре, масштаблы фикерләүләре көчәйде. Кайбер тәнкыйтьчеләр вакыйга сюжетының чигенүен, фикергә корылган поэманың гына заманга хас булуын раслап килделәр. Иҗат тәҗрибәсе заман фикере һәм хисе, актуаль олы проблема белән үрелгәндә, эпик поэманың да яшәргә хаклы икәнен исбат итә. Яңа фикере һәм хисе булмаган поэманы сюжет та, сюжетсызлык та коткара алмый. Күп кенә поэмаларны баштан ахырга кадәр үсә барырга тиешле фикер, бөтенлек һәм драматизм булмау көчсезләндерә. Халкыбызның узган героикасын, тынычлык өчен көрәшен күрсәтүдә уңышлар булса да, поэмаларда бүгенге көн кешесенең уена-хисенә, яшәешенә игътибар кимегән. Димәк, безнең алда чор кешесенең образын — 80 нче елларның Алсуларын, Мокамайларын, Гайҗан бабайларын, Аникиннарын, Әүхәди-Майшәкәрләрен тудыру традициясен яңарту бурычы тора.

Бу кимчелекне шигырь җанры бераз төзәтә шикелле. Шигырь заман сулышы белән яшәргә омтылган: КамАЗ; Әлмәт якларында, Уралда һәм Себердә яшәүче авторларыбыз үзләре аралашып яшәгән эшчеләрнең тормышын чагылдырганнар. Бик күп шагыйрьләребез игенче хезмәтенә дан җырлаганнар. Фәнни-техник революция китереп чыгарган конфликтлы проблемалар да, мораль-әхлак, мәхәббәт мәсьәләләре дә күтәрелгән. Эчтәлек-тема ягыннан караганда, поэзиябез шактый киң яңгырашлы.

Соңгы елларда Фәнис Яруллин иҗаты туктаусыз үсә бара. Роберт Әхмәтҗановның «Хәтер елгасы» китабын укыгач, аның үзе генә ачкан лирик материгына барып керәсең. Н. Арслан күккә ашулы романтик рухын, төрки халыкларының борынгы тарихлары аша бүгенге көннең реаль проблемалары белән куша алды. «Иделем-илем» исемле җыентыгы — поэзиябезне яңа бер биеклеккә күтәргән шагыйрьнең зур ачышы. Традиция буларак яңарып, баеп яшәүче романтик юнәлеш Әхсән Баян, Рәшит Әхмәтҗанов, Зөлфәтләр аша, яңарак буын яшьләренә: Рашат Низамиев, Нурия Измайловаларга күчә. Шигъриятнең төрле юнәлешләргә, стильләргә бай икәнен картаюны белмәс иҗаты белән һаман алдынгы сафларда барган Сибгат Хәким дә, тормышчан гади фәлсәфәгә ия булган Нәби Дәүли дә, реализмнан бер адым да чигенмәгән Хисам Камалов та, туган ягының уҗымнарын күрмичә яши алмаган, авыл белән

шәһәр арасында яшәүче кешенең драматик кичерешләрен өзелеп җырлаган Рәшит Гәрәй дә, Ык буеның табигатенә мәңге гашыйк Марс Шабаев та, «Шахтер моңы» исемле беренче җыентыгы белән үзенчәлекле тавышын ишеттергән Рифгат Закировлар да раслыйлар.

Бездә Тукай, Такташлардан калган дусларча елмаю һәм үтергеч көлү жанры яшь, әллә ни күтәрелеп китә алмаса да, яңача сыйфатлар ала. Гамил Афзал озак еллар лирика белән кочаклашып яшәгәннән соң, аңа хыянәт итмичә генә, яңадан үзенең башлангыч нигезенә — юмор, сатирага кайтты. Ул һич тә бирешмичә «бер елмаю белән ун ялганны сугып ега», «хөсет җанлы мәкер белән», «алтын тешле заман хәерчеләре белән» якалаша. Лирика белән сатираны бергә алып бару сәләте бик сирәк шагыйрьләргә генә эләгә. Гамил Афзалның ике өлкәдә дә ачышлары зур.

Бу жанрның тәҗрибәле осталары Салих Баттал, Әхмәт Исхак, Зәки Нури, Шәүкәт Галиев, Фәнис Яруллин, Роберт Миннуллиннар да бу фронтта үз постларын ташламадылар. Дөрес, Шәүкәт Галиев үз артыннан Р. Миңнуллинны да ияртеп, табигый, акыллы юморын балалар поэзиясенә күчерде һәм ул өлкәне алга алып китте. Сөенәбез генә: бер ук фронт бит! Мәннур Саттаров, ниһаять, картайгач, кытыклап көлдерерлек тә хәле калмагач, нәшриятта «Мылтыклы шүрәле» исемле җыентыгын чыгаруга ирешә.

Күрәсез, юмор-сатира жанрын алып баручыларыбыз бик аз. Шигырь китапларын чыгаручы яшьләр арасында бер генә юмористны да эзләп табалмагач, мин шөбһәгә калдым. Мәктәп яшендәге авторлар конференциясендә нәни юмористларны күргәч кенә бераз тынычландым.

Поэзиябезне сыйфат ягыннан үстерүдә үзебезнең остазлар, рус һәм тугандаш халыклар классиклары белән бергә, дөнья шигъриятенең осталары да катнаша. Хәзерге заман татар шагыйре ул — бөтен дөнья поэзиясе казанышларын үз милли шигърияте җирлегендә дәвам итүче, баетучы да. Шул ук вакытта безнең поэзиябез үз милли традицияләренә тугрылыклы булып кала. Милли үзенчәлеген югалткан шагыйрьнең башка халык укучыларында кызыксыну уятуы шикле. Ни өчен татар «Шүрәле»се поэма булып та, балет булып та иләр гизә? Ни өчен бәләкәй генә татар малае Шәвәлине башка милләт балалары да үз итеп кабул итәләр? Димәк, аларда миллилек белән бергә башка халыклар өчен хас сыйфатлар да бар. Кайбер шагыйрьләребезнең шигырьләрендә миллилек «минем бабаларым — болгар!» дип күкрәк сугып мактанудан узмый... Тукай үз халкының бөеклеген дә, фикер-хис байлыгын да, тапкырлыгын да, алга бару өчен комачаулаган мокытлыгын, наданлыгын, комсызлыгын да ачып салган һәм, фикерен халык массаларына җиткерү өчен, үзеннән алда туган бай әдәби алымнарны кулланган, алар гына җитмәсә, үзе яңа формалар тапкан.

Алымнар, формалар бертөрлелегә шигырьне ярлыландыра, эчтәлекнең тәэсирен киметә, укучыны да туйдыра. Әмма тирән эчтәлек алып килмәгән формалар, нинди
генә яңалык алып килсәләр дә, әдәбиятны баета, үстерә алмыйлар. Гадәттә, талант-
лы яшь шагыйрь үзеннән алдагы шигъриятне инкарь итеп, юкны табарга дип килә.
Яшь Такташ шулай. Туфан да бунтарьларча, йөрәкне инкяр итеп килә. Кушаматында
ук-өермә, давыл, җимерү... Ике бунтарь: Туфан һәм Такташ, искене җимереп, яңа
пролетар поэзиясе тудыру өчен көрәш башлыйлар. 26 яшьлек Туфан, табигый лирик
җанына ирек бирмичә, бунтарь Хабулны иҗат итә. Шагыйрь өчен шигырьдә иң
элек — акыл, образ-сурәт. Чор шундый геройларны таләп итә. Ритм — ватык, ирекле,
авыр. Хабулның үзе шикелле дуамал. Аннан соң эшче Минап, Чапый, Гыймай...
Шагыйрь-рәссам кулы белән сурәтләнгән типлар, шигырьләрдәге образ-сурәтләр шул
килеш тә поэзиядә кабатланмас бер чор булып калалар. 1930 елларда Туфанда —
борылыш, 1933 елда язылган «Аккаен» шигыреннән башлап ул «йөрәк кебек җылы
уйга күчә башлый, ритм төзекләнә, фикер хистән, эмоциядән туа. Белмим, бәлки
аны якын дусты Такташның үлеме тетрәткәндер... Ә бәлки, Такташ ирекле шигыре-
нең, новаторлыгының миллионнар күңеленә барып тоташканын үзе тоеп торган Ту-
фан, йөрәгенең табигый агышына ирек биргәндер... Бәлки, Такташның аның турын-
да: «Соңгы вакытта Туфан үзенең шигырьләре эчендәге сирәк, ләкин яшь, яңа
хисләре, күп вакытта гакыллы тирән хисләре белән җанга җылылык кертә башла-
ды»,— дип язып калдырган сүзләре уйга калдыргандыр... Кем белә, бәлки аны Сәй-

дәш музыкаль ритмнарының халык күңеленә нәкъ Такташча табигый агышы уйга калдыргандыр... Ничек кенә булмасын, Туфан үзенең эволюциясендә иҗатының иң олы биеклегенә — Гүзәл Гамьгә бара һәм 50 нче елларда «Агыла болыт агыла», «Сөйли торган материя», «Ә Җир барыбер әйләнә», «Киек казлар», «Кайсыгызның кулы җылы» кебек шедеврларын тудыра. Шулай итеп, Туфан Гамьне, уйны-фикерне гүзәл итеп бирүнең югары дәрәҗәсенә ирешә һәм поэзиябезне Гүзәл Гамь дигән яңа үргә күтәрде.

Иректле шигырьнең иң гүзәл яңгырашын тапкан, шул алымда шедеврларын иҗат иткән Такташ гомеренең соңгы елларында иректле ритмнар белән артык мавыкмый. «Киләчәккә хатлар»да инде нигездә тигез үлчәүле ритм... Заманында Сәгыйть Рәмиев тә ирекле шигырьгә чыгып карый һәм, ахры, ямь табалмыйча, үз формасына кире кайта. Бәлки, мондый формада эзләнүләрдән безгә дә ваз кичәргәдер? Юк, талантлы шагыйрь эчтәлек таләп иткән теләсә нинди формада да поэзияне ачышлар белән баетә ала.

60—70 нче елларда кызыклы эзләнүләр, буыннарны бер-берсенә каршы кую, хис белән фикерне сугыштыру кебек бәхәсләр, үзләреннән алдагы ачышларны санга сукмау кебегрәк моментлар булып алды. Шигъриятебездәге шушы чор төрле буын шагыйрьләрен эзләнүгә, яңа ачышларга тартты. Бераз нигилист, бунтарь акыллы, хәзер урта буын дип йөртелгән талантлы шагыйрьләр инде үзләре дә сабырландылар һәм үз принципларын дәулашып түгел, иҗатлары белән исбат итә башладылар. Әмма ул елларның инерциясе иҗат процессында тенденция буларак яшәешендә дәвам итә.

Фәнни-техник революция китереп чыгарган яңа катлаулы эчтәлекне чагылдыру формаларында, шагыйрьләрнең күпчелеге гасырлар буена сыналган алымнарга, дөнья әдәбияты һәм гыйлеме казанышларыннан күбрәк авыз иткән яшьләрнең кайберләре ирекле шигырьгә таяндылар. Ничек кенә булса да, бу юнәлешләр поэзиябезне яңа эчтәлек һәм формалар белән баетты. Татар поэзиясе традицияләренең ислы булмыйча, яңаны тудыруы белән аерылып торды һәм шул сыйфаты белән гомумсовет шигъриятендә дә алдынгы позицияләрнең берсен яулады. Заман героеның уй-кичерешләрен С. Хәким, Н. Арслан, М. Садри, Г. Латыйп, Ә. Маликов, З. Нури, З. Мансуров нинди генә формаларда бирмиләр? Хисам Камаловта, Рәшит Гәрәйдә, Мәхмүт Хәсәендә, Зөлфәттә, Мөдәррис Әгъләмовта шигырьнең нинди генә төсмерләрен, төрләрен тапмыйсың... Димәк ки, борынгы шигъри калыпларыбыз да үз эченә заманыбызның катлаулы уй-кичерешләрен сыйдырырга сәләтлеләр икән.

Инде кызыклы бәхәсләр кузгаткан шагыйрьләрнең кыю эзләнүләренә килик. Алдыбызда — Шамил Анакның шигырьләре тупланган «Тыйнак табын» җыентыгы. Заманча эчтәлек: чорның иң үзәк, четерекле проблемалары! Ш. Анакның иң көчле ягы — образ, сурәт, фикернең логик үсеше нык, таркалмаслык. Заман шигърияте өчен кирәкле сыйфатлар болар! Дөнья поэзиясендә туган эчтәлек һәм форма яңалыкларын татар шигърияте белән бәйләргә, җиһанның масштаблы интеллектуаль фикерен милли тел чаралары белән бирергә омтылу, әлбәттә, прогрессив күренеш. Ш. Анакның китабы катлаулы язмышка очрады. Шигырьләре башкортча, русча, татарча берничә тапкыр басылуга, тәнкыйтьтә уңай бәя алдылар.

Шулай да, минемчә, аның күп кенә шигырьләре туган халкының рухыннан, күңеленнән, теленнән, әнкәсенең күкрәк сөтеннән сеңгән уй-хистән, моңыннан, җаныннан өзелеп төшмәгәннәр. Кайбер әсәрләре дә үзенең шигырендәге болытларны хәтерләтеп куя: «мәңге мосафирлар, язмышлар — мәңге күчәбәләк, алар — ватансыз, илдән-илгә гизәләр, бар микән аларның үз илләре?» Ш. Анакның кайбер шигырьләре чит илдә бик озак яшәп, заграничный формага киенгән, башка телдә уйлап, фикерен салмак кына үз теленә тәрҗемә итә-итә артыгы белән җитди сөйләүче кешене хәтерләтәләр. Кайбер шигырьләрендә акыллы, файдалы фикер колакка, мигә керә, ә йөрәккә үтми. Шагыйрь моны үзе дә аңлый бара, күрәсең... Иҗатының соңгы чорында, кайбер әйбәт әсәрләрендә традицион шигырь белән ирекле ритмның табигый кушылуына ирешә. Ш. Анакның шигъри системасыннан, бәлки, киләчәктә яңа зур шагыйрьләр күтәрелеп чыгар...

Остазларның уңышларын һәм кимчелекләрен искә алып, яшьрәк буын шагыйрь-

ләре (әлбәттә, өлкәннәр дә алардан калышмады) эчтәлек таләп иткән формаларны эзләүләрен дәвам итәләр.

«Арсланнар йөрми көтү белән»,— дип яза Равил Фәйзуллин «Кыска шигырьләр» китабында. Әйе, Равил үзе дә, аның белән бергә җыр башлаган Ренат Харис, Рөстәм Мингалимов, Гәрәй Рәхим, Рәдиф Гатауллиннар да өлгереп, һәрберсе Нури Арсланның үзе белән ярышырлык арсланнарга әйләнделәр. Уңышлы эзләнүләрнең һәм ачышларның бер мисалы — Равил Фәйзуллин иҗаты. Әйбәт тәрҗемәгә очраган шигырьләре союз күләмендә дә яңгыраш ала бара. Равил соңгы елларда кыска шигырьләрнең фанатигына әверелде. Бу формада да ул үзен әдәби осталыкның шактый нечкә серләрен ачучы итеп күз алдына бастыра. Биш-ун сүз. Парчалар, мәкальгә тартым әйтемнәр, чагыштырулар, этюдлар, кинаяле тезмәләр. Традицион үлчәү дә, рифмасыз ак шигырь дә, ирекле шигырь дә бар. Дүрт юл, өч юл, ике юл, бер юл... Уйның-хиснең нюанслары... Бер китап өчен бу — уңыш, әмма Р. Фәйзуллин киләчәктә дә үзен шул фанатизмында чикләсә? Кыскалык абсолютизмына бирелеп, озынрак формаларда уңышсызлыкка очраса? Мин әле аның фикер һәм хис ташып торган егет чакларын, «Наз»ларын, «Мәрмәр»ләрен сагынып куйдым. Әлеге кызыклы китабында Р. Фәйзуллин үзе дә сыймаслык читлеккә үзен ябып куйган да, талантының чаткыларын гына чәчрәтә сыман. Шагыйрьнең үсешендә төрле халәтләр булуы табигый хәл инде... Мин аның күз явын алырлык бизәкләр генә түгел, көрәшчеләр өчен сүзләрдән хәнҗәр әзерләвенә дә ышанам.

Гәрәй Рәхим фикер һәм хис ягыннан өлгерде, олыгайды. Хәтта иң интим кайгы — әнисенең үлемен дә ул олы төшенчә — Ватан белән бәйли һәм Әнкә образы үсә, зурая. Шигырьләрендә борынгы көй кебек салмак та, сагышлы да, дәртле дә булган халык уе-моңы. Кызганычка каршы Гәрәй, ни өчендер, кызыклы бу эзләнүләрен туктатты. Шагыйрь әле шушы юнәлештә дә ташып чыгар сыман... «Кисәтү» исемле кыскарак шигырьдә, «Табылдыклар өстәле» исемле поэма эчтәлеген сыйдырган шигырендә автор укучыларны битараф калдырмый. Ялкынлы, публицистик, үтемле, политик лирика! Моңа кадәрге съезд докладларында шагыйрьләребезнең либретто язу белән шөгыльләнмәүләре зур бер кимчелек итеп телгә алына иде. Гәрәй авыр бу жанрга җиң сызганып тотынды. Хәзер аның борынгы Болгар тормышыннан икенче либреттосы да әзер.

Рөстәм Мингалимов шигърияттендә заманның тизлеге, хәрәкәте. Әмма автор бу тизлеккә ияреп кенә бармый, алгарак чыгарга да омтыла. Чорның катлаулы драматик күренешләре аны уйландыра, ләкин тизлек моңланып озак торуны кабул итми, ашыктыра. Шагыйрь моңның нюансларын эләктерергә өлгерә, аның моңы да якты, оптимистик, заманча. Тормышта трагик хәлләр дә бар, шулай да елап торырга вакыт юк, чор тизлеге алга өнди.

Тик зур тизлек белән алга баргәнда без поэзиянең олы таләпләре турында онытмасак иде.

Соңгы елларда Рәдиф Гатауллин масштабын киңәйтте, күтәрелгән мәсьәләләре дә зур. Шагыйрьләребезнең чит илләргә үзләре чыгып, үз күзләре белән күреп язылган шигырьләре поэзиябезнең офыгын баетып, киңәйтеп җибәрде. Рәдиф кебек шагыйрьләр Европаның үзәгеннән, Эйфель башнясыннан торып дөньяга карадылар, үз илебезнең биеклеген горурланып җырладылар, капитал дөньясын фаш иттеләр. Рәдифнең гражданлык активлыгы мактауга лаек. Шулай да аның иҗтимагый-политик шигърияттендә ихлас лирика кими төште. «Европада татар шагыйрьләре» кебек ялкынлы трибун шигырьнең авторы үз талантының көтелмәгән яклары белән ачылыр әле...

Озак еллар үзен табалмыйча йөргәннән соң Каюм Латыйп ирекле шигырьдә һич тә көтелмәгәндә табигыйрәк булып ачылды. «Вакыт канатында» исемле китаптагы әйбәт шигырьләрендә автор бу юнәлештәге иң авыр сыйфатка — фикер белән хис бөтенлегенә ирешә. Бер нәрсә шикләндерә мине: К. Латыйп шул үзе тапкан формалар эчендә туктаусыз әйләнеп, үсештән туктап калмасмы? Ни әйтсәң дә, ирекле форма эчтәлек бирүнең бер төре генә бит. Бу юнәлештә яшьләрдән Г. Сәлимовның эзләнүләре дә игътибарга лаек. Гомумән, ирекле формада кызыклы ачышлар булгалап торса да, аның әле ныклы системага салынып, чорыбыз героеның уй-хисен,

халку образын бөтен тулылыгы белән ачып бирерлек хәлгә җиткәне юк. Күрәсең, ул үзенең яңа Такташларын көтә.

Күргәнебезчә, биш ел эчендә югалтулар да, сөенечле табышлар да, ачышлар да булып торган. Без бүген «поэзиябезнең рус теленә тәрҗемә ителеп, ил аренасына чыгарырлык зур шагыйрьләр бар!» дип горурланып әйтә алабыз. Чыннан да, соңгы елларда шигъриятебез ил мәйданында тәрҗемә аша сан ягыннан күпләп чыга башлады. Арада бәхетлерәк язмышка очраганнары да бар, әлбәттә. Шуңа карамастан, бүгенге поэзиябез ил күләмендә без көткән олы яңгырашны ала алмый. Күпләрдә: «Ни өчен безнең кайбер милли республикалардагы шикелле, ил арасына чыккан бер шагыйребез юк?»— дигән борчулы сорау туа. Минемчә, һәр милли поэзиянең үзенә хас сыйфатлары бар. Татар поэзиясе үзенең тарихи үсеш чорында бер шагыйрь шигърияте генә булмады, ул һәрвакыт ил күгенә кабатланмас шагыйрьләр йолдызлыгын хәтерләтеп калыкты: Тукай, Гафури, Дәрдмәнд, Рәмиев йолдызлыгы, Такташ, Җәлил, Кәрим, Туфан йолдызлыгы... Бүгенге көн поэзиясе дә ил күгендә бер шагыйре белән генә түгел, һәрберсе аерым күренерлек йолдыз төркеме булып янарлык! Ни өчен соң ул кабынып китә алмый? Мәгълүм бер мәзәк искә төште. Мөхәммәтҗан абзый, русча белмәве аркасында «тону!» дип әйтәсе урынга «ныряю!» дип кычкырган һәм су төбенә киткән. Әлбәттә, дәһшәтле дулкыннарны да, штормнарны да күп күреп чыныккан поэзиябез үз елгаларында батмас. Шулай да бай шигъриятебезне елгалардан диңгезләргә, океаннарга чыгару заманы, дөнья шагыйрьләре белән ярышу дәвере бит. Рус телен су урынына эчкән Мөхәммәтҗаннарыбыз хәзер, борынгы мәкальне кулланып: «Татарга тылмач кирәкми!»— дип кенә җибәрәләр. Бүген бу мәкальне поэзиябезгә карата юнәлтеп, үзгәртәсе һәм «Татар шигъриятенә талантлы тылмачлар кирәк!»— дип әйтәсе килә. Классикларыбызны да, хәзерге шагыйрьләребезне дә талантлы тәрҗемәчеләр йөрәге аша үткәрмичә торып, поэзиябез югарыда булса да, илебезнең барлык халыкларына күренерлек балкый алмас!

Сыйфат ягыннан билгеле бер үсешебезне таныган хәлдә, поэзиябезнең ил, дөнья күләмендә киләчәктә яңгырарлык эчке халәтен тоеп, үземдәге кайбер борчуларны әйтүне кирәк табам.

Күп кенә шагыйрьләрнең иҗатында бүгенге чынбарлык бөтен тирәнлеге, катлаулылыгы белән чагылмый әле. Еш кына фәлсәфә (әгәр булса), реаль тормыш җирлегеннән түгел, хыялдан гына һәм китаплардан алган белемнән генә килеп чыга. Соңгы елларда килгән яшь шагыйрьләрнең артыгы белән кыюсыз, тыйнак булулары, күнегелгән түгәрәкләрдә генә әйләнеп йөрүләре дә эчне пошыра. Кайбер шигырьләрнең формасы-калыбы бар, ә эче — буш... Аннан соң... шигъриятнең бер полюсында борын-борыннан килгән әткә-әнкә теленә, бишек җырыннан сеңгән моңга, хискә караш салкынаймый микән? Мин моңны аһ-зар, сагыш дип кенә аңламыйм һәм «моң», «сагыш», «күңел», «йөрәк» сүзләре тулып яткан, әмма моңның әсәре дә булмаган, фикерсез, образсыз шигырьләр турында да әйтмим. Сәйдәш маршында, музыкасында Киләчәккә, Өметкә, Матурлыкка чакыра торган Гүзәл Гамьле моң бар. Сәйдәшнең новаторлыгы борынгы көйләрдән — «Карурманнар»дан килеп чыккан, бөтенләй яңа, заманча, дәртле моң табуда. Муса Җәлил үлем алдыннан кичергән чорын «минем гомерем моңлы бер җыр иде» дип атый. Кайбер шигырьләребездә лирик геройның эчке кичерешләре, нечкә рухы азрак ачылу, бәлки, әнә шул сыйфатны — моңны югалта бару белән бәйләнгәндер?..

Безнең шигырьләребез киң катлам укучыларыбыз арасында эмоциональ тәэсир итү көчен киметмиләрме? «Татарстан яшьләре»ндә бәхәс ачып, укылмый яткан шигырь китаплары турында яшьләр, бәлки, юкка гына борчылмыйлардыр?.. Шигырь китапларының тиражы әле кайчан гына 8—10 мең иде, хәзер 2—3 меңгә кадәр төште. Әлбәттә, шигырь продукциясен халыкка җиткерергә тиешле сәүдә оешмаларының поэзиягә салкын карашы, һичшиксез, кире йогынты ясый. Бу мәсьәлә аерым сөйләшүне, хәл итүне көтә. Без хәзер үзебезнең иҗатка турыдан-туры бәйләнгән эшләр турында сүз алып барыйк.

Узган ел районнарда һәм Казанда мәктәп яшендәге яшь авторларның конференциясен үткәргәндә сәер бер хәлгә очрадык: иҗат белән кызыксынучыларның иң күбесе — кызлар... Илле кыз арасында качып, оялып кына бер малай утыра... Әл-

бэтта, кызларның шигырь сөюләре, нечкә күңелле булулары гүзәл күренеш. Алар арасыннан киләчәктә, һичшиксез, яңа Саҗидә Сөләймановалар күтәрелер. Ә малайлар, малайлар нигә шигъ척яттән суынды әле? Димәк, поэзиябезнең киләчәген көчле итеп күрергә теләсәк, мәктәпләргә тагын да якынаерга, шагыйрьләр тәрбияләүне мәктәп яшеннән үк башларга кирәк.

1981 елны Казанга чит илләрнең берсеннән язучылар килгәч, бер прозаиктан сорыйм:

— Арагызда шагыйрьләр бармы?

— Юк. Бездә хәзер гомумән профессиональ шагыйрьләр юк.

— Аңламыйм.

— Әйе. Студент-яшьләр арасыннан бер төркем «новатор» шигырьләр язабыз дип, традицияне инкяр иттеләр, салкын акылга гына корылган шигырьләр яза башладылар. Халык алардан баш тартты. Шигырьләрне бик аз тираж белән генә чыгаралар, тәнкыйтьчеләр генә ала, калганнары ята...

Безнең поэзиядә мондый хәлнең туганы юк һәм тумас та дип ышаныйк. Традицияләребезгә тугрылыклы шигъриятебез — алга таба хәрәкәттә, үсештә, ул милли һәм бөтен дөнья поэзиясендәге процессларның алдынгы, революцион, халыкчан традицияләренә таяна. Мин бу күңелсез хәлләрне гыйбрәт өчен генә әйттем. Шундый хәл килеп чыга күрмәсен! Хискә дә, акылга да тәэсир итми торган, сай эчтәлекле, дәртсез-ялкынсыз шигырьләр бездә газета-журнал битләреннән йөз меңләгән тиражлар белән таратылмыйлармыни? «Гражданлык лирикасы» маскасын киген сәләтсез такмаклар чын шигъриятән күпләгән укучыларны биздерергә сәләтлеләр. Гражданнар сугышы чорында һөҗүмнең уңышын ат менгән кавалерист хәл иткән. Ул вакытта белеме чамалы булган көрәшчеләргә декламацияләр, такмаклар да тәэсир иткәндер. Ә бүгенге идеологик көрәштә баштанаяк заманча коралланган дошманга каршы поэзия гамәлдән чыккан арсенал белән баралмый. Поэзиянең борынгы символы Пегас булса да, атның һаман да үз урыны булса да, бүген атка менеп, кылыч селтәнеп көрәшкә чыккан шагыйрь Дон-Кихот хәлендә калачак. Хәзерге идеологик көрәш, катлаулы халыкара хәл шагыйрьдән гражданлык, халыкчанлык, партиялелекнең яңача, заманча чагылдырылуын сорый. Бу — миллионнар таләбе, бу — партиябезнең июнь Пленумы таләбе. Идеология фронтының алдынгы сызыгында баручы шагыйрьнең һәрбер сүзе җаннарга үтеп кергәндә генә, шигъриятебез солдат поэзиясе дигән горур исемне аклаячак!

Хәзерге укучыларыбызның күбесе югары белемле, аның аңына һәм йөрәгенә үтеп керү өчен, шигърият дигән мәңгелек чишмәне суындырмас өчен, бөек шагыйрьләребез күтәрелгән биеклектән дә төшмәскә, төрле буыннарның бердәмлегендә яңа чор поэзиясен, киләчәк сагынып сөйләрлек 80 нче еллар поэзиясен тудыру кирәк.

Безнең арабызда яшәп, Тукайларча, Такташларча янунын ни икәнен раслап киткән Гүзәл Гамь иясе «Лирика» исемле соңгы китабындагы анкетада: «Иң бәхетле чагыгыз?» дигән сорауга менә ничек җавап бирә:

«Иң бәхетле чагыммы?

Иҗади накалда яшәгән чак. Җанның, күңелнең, йөрәкнең, бәгырьнең дәрләгән, кайнаган чагы, уй һәм хиснең аера алмаслык булып кушылып, ташып торган чагы!»

Галлей планетасы сыман һаман зураеп, безгә якынлашып килгән мәңге яшь Тукаебыз да, Гүзәл Гамь иясенең сүзләрен раслагандай, безгә, әдәби оныкларына якыннан гына дәшә кебек:

*«Күкрәгеңдә синең шигырь уты саумы?..»*

## Тәлгат Галиуллин

# ТӘНКЫЙТЬ ҺӘМ ӘДӘБИ ПРОЦЕСС

Матур әдәбиятның таянычы, рухи юлдашы, изге намусы, хөкемдары булган тәнкыйть һәр чорда да киң җәмәгатьчелекнең игътибары үзәгендә тора. Ә соңгы ун-унбиш ел эчендә аңа игътибар моңарчы күрелмәгәнчә үсте. Бу юлда КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында», «Әдәби-нәфис журналларның коммунистик төзелеш практикасы белән иҗади элемтәләре турында» кебек тарихи карарлары якты маяк булдылар. Партиянең тәнкыйтьне дөрес юлдан үстерү турындагы практик кайгыртуы әйбәт нәтиҗәләр бирә. Күпмилләтле совет тәнкыйтенең халык тормышы һәм әдәби процесс белән бәйләнеш алымнары камилләшә төште, марксистик-ленинчыл тәгълиматны тирәнтен үзләштергән, югары зәвыклы яңа буын кадрлар мәйданга чыкты.

Партия Үзәк Комитетының июнь Пленумы (1983) тәнкыйтьнең торышына шулай ук зур әһәмият бирде, аның әдәбият һәм сәнгать үсешендә авангардлык роле уйнавын тагын бер кат искәртте, тәнкыйть партиялелек, халыкчанлык һәм тарихилык принципларын раслау өчен армый-талмый көрәшергә, актив, сизгер булырга һәм шул ук вакытта идея ягыннан зәгыйфь һәм сәнгатьчә йомшак әсәрләргә карата килешмәүчән, кырыс булырга тиеш дигән фикерне калкытып куйды.

Хәзерге тәнкыйтькә нык үскән социализм идеалларына тугрылык, интернационализм, әдәби күренешләрне чынбарлык, тормыш практикасыннан чыгып аңлату, киңлек һәм тирәнлек, профессиональ осталык, башка халыклар ирешкән рухи кыйммәтләргә игътибарлылык хас. Соңгы елларда басылып чыккан әдәби-тәнкыйть китаплары татар тәнкыйтьчеләренең иҗади ялкын, актив тормыш белән яшәүләрен дәлилли, әдәби-эстетик фикернең үсеш тенденцияләре турында бай мәгълүмат бирә. Әйтик, М. Хәсәнов, А. Әхмәдуллин, Ф. Миңнуллин, Ф. Мусин, Х. Госман, Р. Мөхәммәдиев, Р. Мостафин, Ф. Хатипов, Ә. Мәхмүдов, М. Вәлиев, С. Маннаповның китаплары шундый хезмәтләр рәтенә керә. Шулар янына Ә. Кәримуллинның татар китабы тарихына багышланган хезмәтен, Х. Госман һәм З. Мәҗитовның «Әдәбият теориясе» кулланмасын, «Урта гасыр татар әдәбияты тарихыннан» җыентыгын, «Казан утлары»нда, «Социалистик Татарстан»да басылган күп санлы мәкаләләрне өстәп булыр иде. Аларның күбесендә сүз гомуми анализ, эчтәлек һәм биография сөйләү рухында бармый, ә үзәккә әдәбият үсешенең теге яки бу тенденциясе, проблемасы алына. Ф. Хатиповны «Геройның рухи дөньясы» китабында прозада кеше рухын, «җан диалектикасы»н, психологияне ачу юллары кызыксындырса, Р. Мөхәммәдиевне («Якутлар табыладыр вакыт белән») поэзиядә шагыйрьнең халык тормышына якыная баруы, гражданлык пафосының лиризм, кешелеклелек белән кушылуы, яңа матурлыкның сурәтле сынын эзләү юллары борчый. Әдәбиятның драма жанры да игътибардан читтә калмаган. А. Әхмәдуллин күп еллар буена, бигрәк тә Мәскәүдә һәм Казанда рус телендә дөнья күргән хезмәтләрендә, үзенә бер үҗәтлек белән, драматургиябезнең үсеш юлларын, совет чорында ирешкән казанышларын, сәхнәдәге яшәү рәвешен күрсәтү, аның идея-эстетик күтәрелешенә аеруча зур өлеш керткән К. Тинчурин, Т. Гыйззәт, Н. Исәнбәт, М. Әмир кебек сүз осталарының кешелек һәм художниклык сыйфатларын ачу рухы белән яши.

Табигый буларак, тәнкыйтьнең төп көчләре бүгенге җанлы әдәби процессны өйрәнүгә юнәлтелгән. Күпчелек чыгышлар социалистик реализм әдәбиятының яңа чордагы үсешен, жанрлар хәрәкәтен, сурәтлелек чараларының байый, яңара баруын конкрет анализлауга багышланган. Җәмәгатьчелекне борчыган, уйландырган проблемаларны уртага салып, күмәкләп сөйләшү хәзерге әдәби процессның бер үзенчәлекле сыйфатын билгели. Ике съезд арасында әдәбиятның өч төп жанры да игътибар үзәгендә торды. Татар драматургиясенең торышы Мәскәүдә зурлап тикшерелде. Поэзия һәм проза турында «Казан утлары»нда барган сөйләшүләрдә, тәнкыйтьчеләр һәм

язучылар, тарихчылар һәм журналистлар белән бергә, киң катлау укучы да актив катнашты. Бу хәлнең объектив сәбәпләре бар. Бер яктан, әдәбият мәсьәләләренә игътибар арту аның халык тормышында мөһим роль уйнавына дәлил булып кына калмый, гомумән, иҗтимагый аңның дәрәҗәсен дә билгели. Икенче яктан, әдәби-тәнкыйть мәкаләләрен туплаган җыентыклар, газета һәм журнал битләрендә урын алган чыгышлар, өзлексез процесс булган әдәбиятны тар вакыт кысалары белән чикләргә мәҗбүр әдәби ел йомгаклары сүз сәнгатенең бөтен байлыгын иңли алмый. Ә дискуссия берәүне дә чикләми: кемнең күңеленә, рухына нәрсә якын, кемне ни борчый — шул хакта үз фикерен әйтә ала.

Поэзия, проза драматургия турындагы дискуссияләрдә идеялелек һәм халыкчанлык, традиция һәм яңачалык кебек категорияләр турында уйлану татар әдәбиятының гомуми үсеш үзенчәлекләрен тагын да тирәнрәк аңларга булышты. Поэзиягә багышланган дискуссия хакында матбугатта сүз бигрәк тә күп булды.

С. Хәким, Х. Госман, Р. Харис, М. Вәлиев, Роб. Әхмәтҗанов, Р. Мөхәммәдиев, Ф. Сафин, З. Мансуров чыгышлары хәзерге татар шигъриятенең торышын, кеше рухының камиллеген, дәверебезнең бөеклеген ачу юнәлешендәге киеренке эзләнүләрен, форма, стиль, ритмика өлкәсендәге уңай һәм тискәре тенденцияләрне шактый тулы күз алдына бастыра. Дөрес, конкрет шигырь һәм поэмаларны тәнкыйть күзлегеннән чыгып анализлау очраклары аз булды, бигрәк тә шагыйрьләр үзләре, аерым шәхесләргә кагылмыйча, теге яки бу әсәргә карата, «аргы урамнан әйләнеп үтеп», гомумирәк фикерләрен әйтеп калырга тырыштылар.

Проза турында сөйләшү, киресенчә, иң югары киеренке нотадан башланып китте һәм соңга табарак, дискуссиягә галимнәр, профессиональ тәнкыйтьчеләр килеп кушылгач кына тышкы темпераментын суыта төшеп, җитди фикер алышу юлына чыкты. Дискуссияне башлап җибәргән А. Гыйләҗев хәзерге прозага, аның аерым вәкилләре эшчәнлегенә карашын анык һәм тәгаен әйтеп салды, үзен борчыган мәсьәләләргә шәхси мөнәсәбәтен киеренке рәвештә, полемик дәрт белән әйтеп бирде. Автор татар әдәбиятының барыр юллары турында борчылып, ачынып язды. Шулай да прозабыз казанышларына карата ниндидер нигилистик мөнәсәбәт аның сыйфат дәрәҗәсенә реаль бәя бирүдән, гомуми хәзинәгә керткән өлешен дөрес күзаллаудан ераклаштырды. Һәм шулай ук бәхәс барышындагы констатация (проза артта кала), чагыштыруда берьяклылык (бездә Ч. Айтматов юк), буыннарның бертөслелеге (берничә язучы бик яхшы, башкалары бер тиенгә яраксыз) прозаның рухи көчен, әхлакый бөеклеген, башка жанрларга ясаган тәэсир көчен, алдан тою зирәклеген ачып бирүгә күпмедер комачаулады. Стильләр хәрәкәте, үзара керешү процессы бөтенләй диярлек читтә калды.

Прозага багышланган сөйләшү тагын бер мәсьәләдә «дөрес бирде» һәм шундый хакыйкатькә инандырды: уңышның яртысы аны дөрес оештыра белүгә, төп көчләрне дискуссия орбитасына тарта һәм дөрес юнәлеш бирүгә бәйле икән.

Тулаем алганда, әдәбиятның үзәк жанры турында фикер алышу шактый югары профессиональ дәрәҗәдә барды, һәм аның шифалы тәэсире үзен озак көттермәс дип ышанасы килә.

Шулай да иң зур бәхәсләр алда булса кирәк. Әдәби процесс һәр көнне һәр сәгатьтә яңа проблемаларны куеп тора. Тәнкыйтьнең игътибарыннан читтәрәк калган иң өстәге мәсьәләләрнең берничәсен генә атап үтик.

Соңгы елларда Г. Бәширов, Ш. Маннур, Ә. Еники, С. Баттал кебек өлкән буын язучылар иҗатында ярым автобиографик, ярым истәлек әсәрләр зур урын алды. Һәркайсы яңа материал күтәрә, аны үзенчә тасвирлый, әмма аларда ахыр чиктә тулы бер буынның әхлакый һәм рухи дөньясы чагыла. Бу күренеш махсус өйрәнүгә һәм гомумиләштерүгә лаек. Аннан кул селтәп кенә котылып булмый.

Нурихан Фәттахның тарихи әсәрләрен татар әдәбиятында үзенә бер феномен буларак кабул итәбез. Әмма аларның мәгънәсен, фәлсәфи көчен, заманга бәйләнешен һәм әһәмиятен аңлатырга алынган тәнкыйтьче юк. Бу романнар тарихи, тарихка нигезләнгән әсәрләрме, яисә теләсә нинди халыкның үткәненә (күпчелек халыклар үсешләрендә бер-берсен кабатлыйлар) яраклы бер модельме? Әллә алар тулысы белән язучы хыялында туган маҗаралы-мавыктыргыч әсәрләр генәме?

Барлык әдәбиятлардагы шикелле үк, бездә дә мифологик образларга, символ-

ларга мөрәҗәгать итү фактлары күбәйде. Икенче яктан, повесть жанрында кешелекле юмор усал сатирага юл бирә (А. Гыйләҗевнең «Әтәч менгән читәнгә» повесте), җиңел укыла торган беллетристик жанр тернәкләнә төште (В. Нуруллинның «Һәлакәт» әсәре).

Ә поэзиядә гомум вакыт белән аерым вакыт арасын, үткән белән бүгенгене якынлаштырган, ерак тарихи ассоциацияләр, мифик образ-сурәтләр аша хәзерге көн проблемаларына тоташкан эпик әсәрләр күбәйде (И. Юзеев, «Мәңгелек белән очрашу», Зөлфәт, «Йөрәкләрдә үлмәс дастан»). Аларда шартлылык теория түгел, ә реальлек; ул авторның идея-эстетик концепциясенә, тормыш фәлсәфәсенә буйсынып, поэманың бөтен күзәнәкләренә үтеп керә. Лирикада янәдән романтик-субъектив башлангыч көчәеп бара. Ә драматургия «аягына кырмавык кебек ябышкан» экология проблемасыннан һәм конкрет эштән бигрәк, акыл сатарга яраткан дидактик картлардан туеп, кеше зиһененең тирәнрәк катлауларына, тормышның бер яссылыгына гына сыймаган мәгънәсенә үтеп керергә тырыша. Бу процессларга да тәнкыйть күзен тутырып ачып карарга тиеш иде шикелле.

Үзәк тәнкыйтьтә, шартлы рәвештә, милли әдәби мәктәпләрне аерып куярга яраталар: литвалыларның психологик романы, эстоннарның ироник-фәлсәфи прозасы, украиннарның «химер» романы һ. б. Шуның өстенә, лирик проза, интеллектуаль әдәбият, авыл повесте кебек терминнар да заманында киң кулланылды. Моннан сүз татар әдәбиятын теге яки бу системага, типологик схемага сыйдырырга тырышу хакында барырга тиеш түгел. Бездә үзебезнең әдәбиятта реаль яшәгән «милли мәктәпләр» күздә тотыла. И. Гази, М. Әмир, Г. Әпсәләмов, А. Расих, Г. Ахунов иҗатында тәмам формалашкан олы эпик жанрның язмышы ничегрәк булыр? Ул, чор рухыннан артта калып, вакыт һәм интеллектка яраша алмыйча, үз урынын соңгы елларда М. Мәһдиев, А. Гыйләҗев, М. Юныс, В. Нуруллин алга сөргән тыгыз һәм җыйнак повестька бирерме, әллә алар янәшә үсәргә дә хаклымы? Әле бит һәр язучы жанрның яңа моделен тудырырга омтыла. Бу мәсьәләләрне тирән анализсыз һәм башка әдәбиятлар үсеше белән бәйләп аңлатмыйча хәл итүе кыен.

Әдәбиятның үсешен тәнкыйть ничегрәк яктыртырга тиеш? Идея-эстетик яктан иң өлгергән әсәрләрне үзәккә алыпмы? Әйдәп баручы язмалар иҗатына йөз тотыпмы? Төп эстетик концепцияләр, этик-фәлсәфи проблемалар, стиль бердәмлекләре ни дәрәҗәдә исәпкә алынырга тиеш? Бездә ачыкланмаган мәсьәләләр җитәрлек.

Әдәбиятның башка жанрларындагы шикелле үк, тәнкыйть әсәрендә дә авторның кабатланмас үзенчәлеге, тормышны аңлавы, концепциясе, темпераменты, фикерләү рәвеше, хәтта холкы ярылып ятарга тиеш. Безнең тәнкыйть андый исемнәргә бай. Г. Халитның гадәти әдәби күренешне катлаулы фәлсәфи категорияләр, Г. Сәгъдиләрдән килгән академик тел белән аңлатып биргән стилен Н. Юзиевның салмак, ышанычлы язуы, тыштан тыныч күренеп, эчке янулы фикерләве, Р. Мостафинның иҗади интеллектуальлек белән укучыга якынаю алымнарын аралаштырып барган ысулы тулыландыра. Бер шигъри күзәнәктә дөнья вакыйгалары чагылышын, чәчәк атуда Париж коммунарларының дәвамын күреп, шунда ук төгәл, нечкә күзәтүләре белән сокландыра алган, тәнкыйтьтә шагыйрь булып кала белгән Х. Госман янында әдәбиятта логик эзлеклелекне, төгәллекне алга сөргән, вак-төяктә дә олы принципиальлек таба белгән И. Нуруллин тәнкыйте, Ф. Миңнуллинның төгәл, лаконик фикерле, ювелирларча эшләнгән, педант җөмләсенең йөрәге типмәсә, татар тәнкыйте күпкә оттырыр иде. Ләкин, кызганычка каршы, менә шулай үз йөзен тапкан тәнкыйтьчеләр санаулы.

Тикшерү үзәгенә алынган мәсьәләгә сан ягыннан килгәндә, тәнкыйтьнең хисап чорында шактый актив эшләгәнлеген күрүе кыен түгел. Р. Мостафин «Эстетик критерийлар дәрәҗәсе» исемле мәкаләсендә «Казан утлары» журналында 1970 нче еллар башында тәнкыйть рубрикасы астында басылган мәкаләләрнең җиде-сигездән артмавын әйтеп үтә. Хәзер хәл үзгә. 1980 елда журнал битләрендә әдәби тәнкыйтькә караган 15 мәкалә урын алса, 1981 дә — 18, 1982 дә — 16, 1983 тә егермегә якын җитди чыгыш бирелде. Шулар янына еллык күзәтү, иҗат портреты, рецензия һәм әдәби мираска, әдәбият һәм культура тарихына караган күп санлы материалларны өстәргә кирәк.

Татарстан китап нәшрияты үзенең планында әдәбият теориясенә, тарихына һәм гамәлдәге тәнкыйть китапларына ел саен 8—10 урын биреп бара. Мәскәүдә уртача

ел ярымга бер хезмәт дөнья күрә (ике съезд арасында Р. Мостафин, Н. Хисамов һәм А. Әхмәдуллин китаплары басылды). Күпме бу, азмы? Чынлыкны күз алдына бастыру нияте белән, тәнкыйтьче кадрлар составына күз салыйк.

Татарстанда җитлеккән һәм шактый көчле тәнкыйтьчеләр отряды эшли. Язучылар союзы билетын кесәсендә йөрткән 23 тәнкыйтьченең 7 се фәннәр докторы, ә кандидатлар саны 15 кә җитеп килә. Шулар белән җилкәгә җилкә терәп, рәсми рәвештә язучылар корпусына теркәлмәгән 25 ләп кеше әдәби процесска хезмәт итә. Әйтергә кирәк, соңгылары арасында тәнкыйть фикере үсешенә җитди өлеш кертүчеләр аз түгел.

Бездә китап күзәтүләр бихисап күп басыла, әмма күңелдә калырдайлары сирәк. Аларның күбесе бер калыптан коелган кирпечләрдәй яисә машина тәгәрмәчләре шикелле бер-берсенә охшаганнар: схемалары да, төче фикерләре дә уртак. Мондый «брак» турында Р. Мөхәммәдиев «Эстетик офыклар киңәйгәндә» исемле мәкаләсендә бик төпле итеп, уйланып, ачынып һәм конкрет исем-фамилияләрне атап язды.

Күзәтүләр күрсәтүенчә, тәнкыйтьнең төп йөге урта һәм алар артыннан килгән буын җилкәсенә төшә. Тәнкыйтьче исеменә һәм дәрәҗәсенә дәгъва итүчеләр арасында иҗади һәм гражданлык активлыгы бер үк дәрәҗәдә булмады. Гадәттә әдәби тәнкыйтьнең четерекле, катлаулы мәсьәләләрен актарып чыгарып, беренчеләрдән булып күтәреп алучы өлкән буын ике съезд арасында нигәдер сүлпән эшләде. Г. Халит, Х. Госман, Б. Гыйззәт, Н. Гыйззәтуллин, Х. Хәйри агымдагы әдәби процесста элекке еллардагы шикелле үк актив катнашмадылар.

Басылып чыккан китапларның да байтагы — элегрәк дөнья күргән хезмәтләрне сипләп, исемен алыштырган, әмма җисемен саклаган җыентыклар. Бу эш тә кирәк, әлбәттә. Әмма бу очракта да басма үзенең элгәрен турыдан-туры кабатламасын, автор соңгы елларда фән ирешкән казанышларга таянсын, аларны әйләнешкә кертсен иде.

Урта буын вәкилләре арасында Н. Юзиев, Р. Мостафин, Ф. Мусин, Ф. Миңнуллин, И. Ахунҗанов А. Әхмәдуллин эшчәнлеге игътибарга лаек. Аларның уңышлы чыгышларында эзләнүчән рух, фикерне гыйльми-теоретик нсбатлауга омтылыш көчле. IX съездда иҗади пассивлыгы өчен тәнкыйтькә юлыккан Ф. Миннуллин, осталыгын һәм активлыгын бермә-бер арттырып, төгәл эстетик критерийларга таянып, үзенең чыгышларында проза үсешенең күп якларын иңли алды. Ф. Хатипов, М. Госманов, Р. Сверигин, Э. Нигъмәтуллин, Ф. Галимуллин, З. Рәмиев, М. Гайнетдинов кебек каләм иялəре иҗатында да тормышчан рух һәм гуманистик пафос артты. Әдәби күренешләргә бәядә очраклылыкка таяну, теге яки бу әсәрнең күләгәле якларын ачканда алдан уйланылган идеяне авторга тагу кебек зәвыксыз мәкаләләр азайды. Әдәбият үсешендәге перспектив тенденцияләрне вакытында күреп алуга омтылыш көчәйде.

Шулай да югарыда санап үтелгән тәнкыйтьчеләрнең бериш чыгышларына янукөю, дулкынлану, перспектив уйлану җитми; укучының зиһененә, хисенә тәэсир итү алымнарының стереотиплыгы, шаблонлык, фикерләү ярлылыгы үзен сиздереп-сиздереп куя.

Чагыштырмача яшьрәк буын вәкилләреннән Р. Мөхәммәдиев, М. Вәлиев, Ә. Махмүдов, Р. Кукушкин, С. Маннаповны якынлаштырган уртак нигез — методологик төгәллеккә омтылыш, иң перспектив традицияләргә таяну, әдәбиятның үсешенә көч биргән фәлсәфи-иҗтимагый нигезне эзләү, аның эстетик көчен, җегәрен, матурлыгын ачарга омтылу. Әлеге буын тәнкыйтьчеләре әдәбиятның хәзерге халәте, үсеше, киләчәге турында табигыйрәк итеп сөйлиләр, язучының индивидуальлеген ачу юлларын эзлиләр. Әйтергә кирәк, алар тәнкыйтьнең телен, анализлау чараларын әдәби алымнар белән бизәргә омтылалар, язмаларына тормыш рухын, чор фәлсәфәсен (вакыты белән реаль пропорцияне бозып булса да) алып керү дәрте белән эшлиләр.

Исемнәре аталган тәнкыйтьчеләр «Казан утлары» журналының йөзен, юнәлешен билгеләүдә мөһим роль уйныйлар. Теоретик әзерлекләре, әдәби процесста актив катнашулары белән алар күпмедер күләмдә Г. Нигъмәти, Г. Гали кебек тәнкыйтьчеләрнең журналда эшләгән чорларын хәтерләтәләр. Мондый хәл исә җаваплылыкны тагын да арттырырга тиеш.

Татарстан язучыларының X съезды трибунасыннан Г. Ахунов заманның җанлы тәнкыйте өлкәсендә «Р. Мостафин, Ф. Мусин, И. Ахунҗановтан кала, әллә ни актив-

лык күрсәткән тәнкыйтьче күренми шикелле», дигән иде. Бүген болай әйтергә урын юк шикелле. Шулай да тәнкыйть резервы дигән нәрсәне көн тәртибеннән алырга иртә, аның турында эшлеклерәк кайгыртырга кирәк.

Дөрес, Татарстан Язучылар союзы идарәсе яшь тәнкыйтьчеләр тәрбияләүгә зур көч куя. Аларның иҗаты әледән-әле тәнкыйть секциясендә тикшерелә, өметле дип табылганнары газета һәм журналларга тәкъдим ителә. «Казан утлары»нда соңгы елларда «Яшь тәнкыйтьче сүз сорый», «Яшь тәнкыйтьче сүз ала» рубрикасы даими рәвештә бирелә. Ф. Зөлкарнәев, Р. Ягъфәров, Х. Янов, Л. Хәйдәрова, З. Хөснетдинов, Ә. Зиннәтуллина, Ә. Сәхапов, Р. Юнысов, И. Шаһиев тәүге рецензияләрендә замандашларыбызның әхлакый эзләнүләре турында уйланалар. Аларга профессиональ таләпләр кую кыен булса да, яшьләрнең әдәбиятка хезмәт итү өчен кулларына каләм алуы һәм үз сүзләрен әйтергә тырышуы тәнкыйтьнең киләчәгенә күпмедер өмет уята. Х. Янов исеме матбугатта еш күренә башлады, Ф. Зөлкарнәев проза турында барган фикер алышуда уңышлы чыгыш ясады. Ләкин шулай да аларның басма сүзләрендә тормыш тәҗрибәсе җитешмәү, иҗтимагый активлыкка омтылмау үзен сиздерә. Язучылар бар, әмма араларында талантлы тәнкыйтьчеләр бик-бик аз.

Соңгы дискуссия барышында прозаның Бөтенсоюз әдәбиятындагы иң яхшы казанышлар дәрәҗәсенә сирәк күтәрелүе турындагы фикер дә ачык яңгырады. Сәбәпләр аталды. Безнең тәнкыйть алдына да илкүләм аренага исәп тоту шартын калкытып кую вакыт түгелме икән?

Әйе, Ф. Мусин татар әдәбияты проблемаларын «Правда» газетасы битләренә алып менде. Р. Мостафин үзәк әдәби газеталар, «Дружба народов» журналы эшендә актив катнаша, еш басыла, Р. Мөхәммәдиев тә үзәк матбугатта бер-ике җилпенеп алды, Н. Хисамов, А. Әхмәдуллин хезмәтләре абруйлы «Наука» нәшриятында дөнья күрде. Әмма безнең кайбер хезмәтләргә теоретик тирәнлек, иҗади кыюлык, рухи казанышларыбызны башка милли әдәбиятлар белән янәшә куеп, чагыштырма яссылыкта өйрәнү җитми.

КПСС өлкә комитетының X Пленумында ясаган докладында иптәш Г. И. Усманов тәнкыйтьчеләргә дә таләпләр куйды. Шунысы аерым игътибар сорый: әдәбиятта да, музыкада да, сынлы сәнгатьтә дә, документаль кинода да әле уртакул, ә кайвакыт идея һәм художество ягыннан бөтенләй йомшак әсәрләр шактый күренә. Монда, әлбәттә, тәнкыйтьчеләр үз сүзләрен әйтергә тиешләр кебек. Докладта әйтелгәнчә, бездә тәнкыйтьчеләр җитәрлек санда һәм аларның моның өчен тиешле квалификацияләре бар. Әмма аларга еш кына принципиальлек һәм партиячә таләпчәнлек җитешми.

Тәнкыйтькә алдан күрүчәнлек, бүгенге чынбарлык белән иҗтимагый идеалның әдәбиятта якынаю процессын сиземләп алып, сурәтле фикерләүнең үсеш тенденцияләрен ачыклау җитми. Кызыклы гына мәкаләләрдә дә җанлы иҗат процессы теоретик аңлатма тапмый. Әдәби күренеш социалистик реализм контекстында каралмый. Нәкъ менә шуңа күрә, тәнкыйтькә вакыты белән теоретик фикер киңлеге, фәлсәфи тирәнлек, күренешләрне гомумилектә кабул итү сәләте җитенкерәми.

Моннан әле тәнкыйтьчеләр әдәби процессның теоретик аспектларын бөтенләй читләтеп үтәләр икән дигән фикер калырга тиеш түгел. Мисаллар рәвешендә М. Хәсәновның «Социалистик реализм һәм татар совет әдәбияты мәсьәләләре», И. Нуруллинның «Әдәбиятта шартлылык», Э. Нигъмәтуллинның «Типиклаштыру турында» кебек чыгышларын китереп булыр иде. Соңгы ике мәкаләдә бәхәсле һәм ахыргача ачыкланып җитмәгән урыннар булса да, авторларның, гомум теория югарылыгыннан торып, татар әдәбиятын Бөтенсоюз масштабында тикшерергә омтылулары игътибарга лаеклы.

Шул ук вакытта язучыга дөньяга карашын ачыкларга, иҗат методының мөмкинлекләрен, жанр һәм стильләр хәрәкәтен, осталык, зәвык мәсьәләләрен аңларга ярдәм итәрдәй теоретик мәкаләләр дә аз языла.

Тәнкыйть әдәбият тарихы әдәбият гыйлеме белән тыгыз бәйләнгән. Этрафлы фәнни хезмәт әдәбият үсеше өчен тәнкыйть кебек үк кирәкле. Әдәбият тарихына, халык иҗаты җәүһәрләренә игътибарның артуы, Кол Гали юбилееның югары дәрәҗәдә үтүе — фәндә объективлыкның өстенлек алуын, халык аңының үсешен күрсәтүче дәлилләр.

Фольклорга мөнәсәбәт тә җитдилеге белән характерлана. 1976 елдан башлап татар халык иҗатының төп жанрлары — кыска җырлар, табышмаклар, әкиятләр, мәкаләр, йола һәм уен җырлары, бәетләр дөнья күрде. Дастаннар, риваять һәм легендалар, мәкальләр чират көтә. Томнарны төзүчеләр комментарийларда, текстларны бирүдә, аңлатмаларда, заман дәрәҗәсендә эш итеп, шактый төгәллеккә ирешәләр. Халык авыз-поэтик иҗатын фәнни тикшерү эшендә дә прогресс күз алдында. «Татар фольклоры жанрлары» җыентыгы (1978), Х. Мәхмүтовның фольклордагы «вак» берәмлекләрне өйрәнүгә багышланган «Кечкенә дә төш кенә» (1980), М. Мәһдиев, А. Яхин, М. Бакировның халык әдәбияты жанрларын тикшерү юнәлешендә туплаган тәҗрибәләре шуңа мисал була ала.

Хәзер Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты җитәкчелегендә КДУ, шулай ук Казан һәм Алабуга педагогия институтлары галимнәре, Язучылар союзы идарәсе катнашында авторларның зур коллективы татар әдәбиятының алты томлык тарихын тудыру өстендә эшли. Хәзерге совет фәненең иң соңгы казанышларына таянып язылган бу хезмәт әдәби тарихыбызга багышланган зур гомумиләштерүгә ия кыйммәтле чыганак булачак.

Тәнкыйтьне әдәбиятның мөстәкыйль тармагы, бу өлкәдә эшләүчеләрне шул ук язучылар дибез икән, бу синтетик жанр үзе дә игътибарга һәм өйрәнүгә лаеклыдыр. Бер яктан, безгә татар тәнкыйтенең объектив, фәнни һәм методологик яктан төпле уйланылган тарихын булдырырга кирәк. Югары уку йортлары программасына кертелгән «тәнкыйть тарихы» дигән курс та шуны таләп итә. Дөрес, тәнкыйть үсешенең аерым чорларын өйрәнүгә Г. Халит, М. Хәсәнов, Х. Госман, И. Нуруллин, М. Мәһдиев, Ф. Мусин, Р. Мөхәммәдиев, Э. Бариева кебек галимнәр мәгълүм өлеш керттеләр. Ләкин әлегә тәнкыйть тарихын тулылык белән яктырткан дәреслек тә, хрестоматия дә юк.

Икенчедән, агымдагы тәнкыйть үсешен гомумиләштереп бару тарих өчен дә, әдәбият теориясе өчен дә, ахыр чиктә, тәнкыйтьнең эчке хәрәкәтен объектив бәяләү өчен дә кирәк.

Соңгы елларда тәнкыйтьнең асылына, үзенчәлегенә һәм үсеш перспективасына багышланган мәкаләләр күбәйде. И. Нуруллинның «Киләчәккә карап», Р. Мөхәммәдиевнең «Эстетик офыклар киңәйгәндә», А. Яхинның «Фикер дәлилле булсын!», З. Мансуровның «Юбилей мөнәсәбәте белән» кебек чыгышлары турыдан-туры тәнкыйтькә бәйле мәсьәләләрне үзәккә алалар. Авторлар бу өлкәдә эшләүнең җаваплы, катлаулы булуын һәм принципиальлекне таләп итүен вакытлы һәм урынлы искә төшерәләр. Әйтик, З. Мансуров төрле уңай белән языла торган юбилей мәкаләләренең бихисап артуы, бер-беребезне талымсыз, урынсыз күккә чөеп әйтелгән, социаль нигезсез «дифирамблар»ның күбәюе турында ачынып яза, бу авыр йогышлы чиргә каршы бергәләп көрәшергә чакыра. Ләкин мәкалә артык озынга китүе, конкрет булмавы белән оттыра. Бер яклы бәяләүнең, мәдхиячелекнең нык тамыр җибәрүе турында күп языла, аны классиклардан мисаллар китереп исбатлап торуның хаҗәте юк. Ә менә бу зарарлы тенденция белән ничек һәм ни рәвешле көрәшергә, кемнәрнең кулына «сугарга» — гомуми фәлсәфи уйлануларга бирелеп, юбилейлар турында гомуми сүз алып барганчы, конкрет фактлар һәм атамалар белән эш итү файдалырак булыр иде шикелле.

Бүгенге тәнкыйтькә төп игътибарны үсеш авырлыкларына, файдаланылмаган мөмкинлекләрне ачуга, тормыш белән бәйләнеш алымнарын төрләндерүгә юнәлтергә кирәк. Тәнкыйть өлкәсендә эшләүчеләргә еш кына теге яки бу күренешкә бәя биргәндә ачыклык һәм принципиальлек җитми. Кайвакыт вакыйга булырдай ачышларга игътибар ителми. «Хәрәкәттәге эстетика» әдәбиятның үсеш юлын төгәл күзалларга, аерым әсәрләрнең һәм язучыларның әдәби процесста тоткан урынын тигаен билгеләргә, идея-художество кыйммәтен киң укучы массаларга түкми-чәчми җиткерергә тиеш. Кыскасы, ике съезд арасында активлашып, хәзерге әдәби процесста торган саен мөһимрәк роль уйный барган тәнкыйтьнең партия документларында күрсәтелгән югарылыгына күтәрелерлек потенциаль мөмкинлекләрне бетерә барып, яңа үсеш кимчелекләрне киңлеге зур.

## Шәүкәт Галиев

# КИЛӘЧӘККӘ ОЧАР КАНАТЛАР

Татар балалар әдәбияты ничә яшьтә, дисәләр, ул — Кол Гали яшендә. ЮНЕСКОның Парижда чыга торган «Яңалыклар» информацион бюллетене Йосыф кыйссасы турында: «мәдрәсәдә ул китап уку әсбабы булды» дип язды.

Татар совет балалар әдәбияты революцион кызыл байрак астында көрәшергә чакырган беренче шигырьләрдән башланды. Ә 1934 елны, моннан илле ел элек, Татарстан язучыларының беренче съездында балалар әдәбияты турында доклад ясаган Фатих Кәрим: «Хәзерге көндә татар совет балалар әдәбиятына ныклы нигез салынып бара»,— дип белдергән иде. Бу нигезнең ныклыгы бик тиздән — җиде елдан соң ук— Бөек Ватан сугышында сыналды. Патриот язучылар — балаларның рухи комиссарлары — үз әсәрләрендәге иман һәм инануны гомерләре белән раслап, үзләре үстергән укучыларны әйдәп, Туган ил хакына ут эченә керделәр һәм җиңүчеләр булып чыктылар. А. Гайдар, Ю. Фучик, Я. Корчаклар белән бер сафта М. Җәлил, А. Алиш, Ф. Кәрим, Г. Кутуй, Х. Мөҗәйләр дә бар. «Бозган идем мөгезен, юашланды үгезем» дип атаклы шигырен язган Мөхәммәт Әхмәтгалиев кебек бик күп яшь язучылар фашизмның мөгезен генә түгел, муенын сындырдылар. Бу көрәштә балалар әдәбиятының киләчәктә эшләргә тиешле язучылары корбан булды. Әйе, дәһшәтле сынау көннәрендә балалар әдәбияты да җитди сынау үтте, әмма сынатмады. Миллионлаган укучылары какшамас рух ныклыгы, туган илгә тугрылык, чын совет патриоты булуларын күрсәттеләр.

Безнең балалар әдәбияты ныклы рухи нигездә үсә. Бүген икеләнмичә әйтергә мөмкин: татар совет балалар әдәбияты үзенең ирешкән уңышлары белән күпмилләтле илебез халыклары арасында алдынгы сафка басты, аның илдә танылган, дөньяга мәгълүм булган әдипләре бар. Ике съезд арасында жанрларның һәркайсында яңа сыйфат үзгәрешләре булды, аларның киләчәктәге үсеш мөмкинлекләре ачылды.

Безнең заманда гадәтигә әйләнеп киткән могҗизалар күп. Бер дә ис китми генә: акыллы машина, уйлый торган машина дип сөйләшәләр. Әмма чын могҗиза кеше үзе — хикмәтле машиналарны да ул тудырган. Могҗиза түгел диген — дөньяга килеп дүрт яшенә җиткәндә ул инде гомерлек мәгълүматларның яртысын туплап өлгерә! Шулай да күп нәрсәгә, төрле фәннәргә өйрәтәсе бар әле аны. Кеше булу фәненә— шәфкать-миһербанлылык, яхшылыкка — Ватанга хезмәт итәргә дә аны әдәбият өйрәтер. Укытучы булырга әзерләнгән кешеләрнең әдәбият дигән бөтенхалык аудиториясенә килүләренең хикмәте шундадыр. Андый укытучылар бездә аз түгел. Татар совет балалар прозасының күренекле вәкиле Л. Ихсанова 35 ел инде балаларны олы тормышка әзерли. Аның дәресләре — укучылар кулына кергән уникe повестенда, күп санлы хикәяләрендә, публицистик һәм тәнкыйть мәкаләләрендә. Язучы иң кирәкле дәресләрне алып бара — үсмерләргә коммунистик әхлак, дөньяга карашның югары совет гуманизмын өйрәтә. Соңгы биш елда иҗат ителгән унлап хикәясендә, «Фаил һәм Наил», «Милиционер малае» повестьларында — бүгенге мәктәп, гаилә һәм тынгысыз үсмерләр. Проблемалар тормыштагыча кайнар, хәвефле һәм катлаулы, аларда һәркайсыбызны борчыган актуаль мәсьәләләр куела. Психологик тирәнлеге, чынлыгы белән ышандыра ул сурәтләгән тормыш. Л. Ихсанова үсмерләр турында белеп һәм яратып, аналарча кайгыртып яза. Бик җаваплы миссия бу. Ф. Достоевский әйтмешли, киләчәк буыннар үсмерләрдән хасил була бит.

Р. Вәлиевның «Яшисе килә!» — исемле повестена М. Җәлил премиясе бирелү безнең хәзерге буын яшьләренең батырлык традицияләрен лаеклы дәвам итүләре турында сөйли. Бөек Җиңүебезнең 40 еллыгы якынлашкан көннәрдә без моны аеруча канәгатьләнү хисе белән билгеләп үтәбез. Язучылар союзының хәрби-патриотик комиссия председателе Ш. Рәкыйпов бу өлкәдә күп еллар буе эшли, төрле милләт

халыкларының батыр уллары язмышын ачыклап, бик күп онытылган сәхифәләрне терелтте. «Аяз күктә карлыгачлар» исемле яңа китабы аның профессиональ осталыгы үсү турында сөйли.

Батырлык дигәч, Ф. Яруллин искә төшә. Аның балалар әдәбиятында эшләве үзе бер вакыйга, язганнары балаларның көндәлек тормышыннан туган, алар яшәешенә бик якын. Якынлык мәктәп яныннан үтеп йөрүдә түгел ул — күңелең, тынгысыз җаның белән алар янында булуда. Тиз үзгәрүчән бүгенге тормыш калейдоскобыннан балалар характерларын, үзенчәлекләрен күреп ала Фәнис. Шигырьләре һәм хикәяләре, язучының шәхси үрнәге кебек үк, ихтыяр ныклыгына, кеше рухын югары тоткан иҗади хезмәт батырлыгына өнди.

Хәзерге фән-техника заманы балалары үткен акыллы булса да, йөрәкләре салкын, дигән сүзләр ишетергә туры килә. Р. Мөхәммәдиевнең «Кояш нурлары» исемле якты да, моңсу да повесте нәкъ менә шушы күңелләрне эретер өчен язылган сыман. Бала җанында ярату, башкалар өчен әрнү-сызлана белү сыйфатлары уята торган әсәр ул. Димәк, авторның «Яңа елга күчтәнәч» исемле беренче хикәяләр җыентыгына фатиха биреп дөрес эшләгәнбез.

Ф. Шәфигуллинның үзеннән соң да бер-бер артлы хикәяләре укучыларга җитеп торды, «Ак яллы бүреләр» повесте басылды. Үзе яратып язган «якты күзле малайлар» күңелендә калган нурлар сүнми, алар яхшылык, гаделлек, игелек булып тормышны яктыртачак. Ф. Шәфигуллинда балаларны үзенә тарткан сыйфатларның берсе — җитди сүзенә бик табигый кушылган мөлаем юмор иде.

Заманында И. Гази балалар әдәбиятында юмор булмауга борчылып: «Китап битләрендәге эчпошыргыч күңелсезлеккә, җансызлыкка, ике куллы, ике аяклы кагыйдәләргә чик куярга вакыт җитмәдеме икән?» — дигән иде. Килде андый вакыт балалар әдәбиятына, үсешенә көчле импульс бирде, тынын-сулышын, офыкларын ачып җибәрде, табигый геройлар, җанлы тормыш килеп керде. Юмор — халкыбызның күркәм сыйфатларыннан берсе, мең еллар яшәешендә туган оптимизм билгесе, ул аның Шомбайларында, Насретдиннарында яшәгән, буыннан-буынга күчә килгән. И. Гази Г. Мөхәммәтшинның балалар өчен язган чын халыкчан әсәрләрен күреп өлгерде. Газиздән соң бу сыйфатны Ф. Шәфигуллин күтәреп алды халык тормышыннан, туган телдән үскән язучыга бу жанрның мөмкинлекләре чиксез икәнлекне исбат итте. Ф. Яруллин юморның төсмерләре тормышның үзе кебек төрле икәнлекне күрсәтте. Аңа тагын да яшьрәк буын — К. Кәримов чаялыгы килеп кушылды. Әдәбиятта камилләшүнең дә чиге юк бит — хәзер инде Р. Сәлимҗанов уңышларына сөенәбез. Прозадамы, поэзиядәме, драматургиядәме, кайсы жанрда булса да, юмор үзмаксат түгел, әлбәттә, сүзне балага җиткерү чарасы, аның табигатенә иң якын юл. Һәр әсәр мәзәкле булсын димибез, мәзәк мәгънәле булган кебек, җитди сүз дә тапкыр булсын. Чор үзе шуны таләп итә — фән-техника тирәсендә йөгерек, җитез уйлылар алдыра, кыю фикерлелләр ота.

Сатира турында аерым әйтәсе килә. Фольклорны хәтерләгез, тормышларын күзәтегез — балалар бер-берсенең кимчелегенә шактый түземсез, хәтта ки шәфкатьсез дәрәҗәдә усал! Күрәсең, яхшырып үсәргә инстинктив омтылыштыр бу. Рухи сәламәтлекнең сере дә балачакта. Табиблар тикмәгә генә бала чактагы авырулар белән кызыксынмыйлар... Соңгы елларда безнең балалар әдәбиятында сатира тернәкләнеп килә. Чиренә карата — даруы, диләр. Сатира дәвалардай чирләр барын яшерми. Озак яшәү өчен, иң элек, гомерне кыскарткан сәбәпләрне бетерергә кирәк...

Бүгенге мәктәп тормышы — реформа уңае белән бу тагын да ачыграк күренде — бөтенхалык игътибар үзәгендә. Мәктәпләрдә илнең киләчәге әзерләнә, куәте һәм кодрәте нинди булачагы аңа бәйле. Балалар әдәбияты өчен реформа күтәргән проблемалар элек тә игътибардан читтә булмады. Әмма бер сулышта, органик бәйләнештә яшәү җитенкерәми иде. Бу өлкәдә дә үзгәрешләр бар. Л. Ихсанова повестьлары янына К. Кәримовның «Өй артында шомыртым», Ә. Гаффарның «Хәтер», Р. Хафизованың «Тантаналы вәгъдә», М. Хәсәновның «Диас, Ильяс һәм робот МИАЗ» повестьлары өстәлде. Боларда, төрлесе төрле дәрәҗәдә булса да, бүгенге мәктәпнең кайнап торган тормышы, беренче мәхәббәт яктысы, алгыша-тәзәлә үскән яшь, тынгысыз күңелләр, аларның уй-тойгылары чагыла.

Бай һәм төрле безнең балалар прозасы. Менә Беренче съездыбызда пионер булып чыгыш ясаган, хәзер табигать җырчыбыз Г. Хәсәнов парчалары, диңгезче язучыбыз М. Юнысның кызыклы, мавыктыргыч язмалары, Н. Дәүлинең яңа повесте, Ә. Баяновның дәреслекләр өчен бик кирәкле кыска хикәяләре. Балаларны хыялга, иҗади фикергә канатландырган фантастыбыз А. Тимергалиннның «Таш алиһә» исемле маҗаралы повесте. Шулай ук бу жанр ишеген ачкан Р. Фәизов хикәяләре. М. Галиевнең бала күңелендә каршылыклы кичерешләрне — намус уянуын, кешенең үзен җиңүен сурәтләгән хикәяләр җыентыгы.

Ике съезд арасында балалар өчен шактый хикәяләр дә язылды. Конкурсларда бүләкләнгәннәре дә, мактап телгә алынганнары да булды. Әмма, еш кына, бу жанрда канат җегәре җитеп бетми, бала күңелен, үсмер хыялын кабындырырлык энергия сизелми. Бу исә дөнья танырга атлыккан, әзләнүчән җаннар көткән мавыктыргыч вакыйгалар, фикерләр булмаудан киләдер.

Балачакта күргән бер эстрада номеры искә төшә. Зур тәргәк бүләк күтәреп сәхнәгә чыкты да артист, шуны сүтә башлады. Әй сүтә бу, әй сүтә, бөтен җир кәгазь белән тулды... Сүтеп бетергәч, бер кочак кәгазь эченнән бармак башы кадәр сыбызгы чыкты. Кайсыбер проза әсәрләрен «сүткән» укучыларга сыбызгы да чыкмый, аптырап үзе сызгырырга кала...

Әлбәттә, балалар һәм яшүсмерләр прозасының торышын бүгенге көн таләпләренә җавап биргән уңышлы әсәрләр билгели. Шулай да, Гайдар традицияләрен еш искә төшереп, геройларын юксынуыбыз, әсәрләребездә бүгенге ишләрен күрергә теләвебез дә тикмәгә түгелдер... Бу бурычны үтәр өчен өлгереп җиткән әдипләребез бар, димәк киләчәктә иҗади казанышларының берсе шул булыр дип ышанырга урын бар.

Балалар поэзиясенең тематикасы баеды, эчтәлеге тирәнәйде. Катлаулы, олы тормыш киңрәк чагылыш таба, актуаль проблемалары килеп кушылды. Психологик кичерешләр гаммасы тулырак бирелә хәзер, замана баласының рухи дөньясы торган саен үзенчәлерәк ачыла. Тарихыбызда беренче тапкыр, Татарстан китап нәшрияты әзерләп чыгарган «Татар балалар поэзиясе антологиясе» бу жанр ирешкәннәрне тулы итеп, ышандырырлык күрсәтә алды, әдәби тормышыбызда вакыйга булды.

Бүгенге балалар поэзиясе турындагы сүзне Р. Миңнуллиннан башлау дөрес булыр. Ике съезд арасында ирешкән иҗат уңышларының саны белән дә, сыйфаты белән дә сөендергән шагыйрь ул. Аның бу этаптагы хезмәте югары бәя алды — М. Җәлил премияләре тарихында беренче булып балаларга язылган шигырьләр өчен лауреат исеме бирелдe. Г. Тукай, Б. Рәхмәт традицияләрен дәвам итеп, Р. Миңнуллин балалар поэзиясен үз ачышлары белән баета килә. Иҗат диапазоны киң — балаларның үз дөньясын табигый сурәтләгән хәлдә, олы тормыш проблемаларын шундый ук чынлык белән катнаштыра. «Дөнья балаларының кешелеккә әйтер сүзе», «Бөтендөнья балалары, берләшегез!» исемле шигырьләре, мәсәлән, тынычлык турында, илләр, халыклар язмышы турында публицистик рух белән язылганнар. Бу уңайдан әлеге теманың безнең поэзиядә яңача һәм үтемлерәк ачыла баруын әйтеп үтәргә кирәк. Җир язмышы кыл өстендә торган мондый хәвефле чорда башкача булуы да мөмкин түгел.

Х. Халиков мәктәп белән гомер буе тыгыз бәйләнештә, ихтыяҗларын яхшы белә, октябрятлар, пионерлар белән бергә кайнап иҗат итә. «Иң шатлыклы көнем» җыентыгында дөнья язмышы турында уйлана белүче балалар бар. Телевизордан сугыш афәтләрен күреп бер малай: «Дөньядагы һәр кешегә шатлык өләшәсе килә... Күрәшәсем килә!» — ди. Соңгы елларда безнең поэзиядә интернациональ дуслык темасы көчлерәк яңгыраш алды. Африка илләренең берсендә азатлык өчен көрәшүче Фернандо, кубалы Хосе, гарәп малае Әхмәт һәм башкалар шигырьгә керделәр.

Бу урында балалар әдәбиятының идеологик көрәштә нинди җаваплы позиция тотуын искәртеп китәсе килә. Көрәшнең алгы сызыгы балалар һәм үсмерләр күңеле аша уза. Көнбатыштагы берәүнең язганнары турында белгәч, рухи дошманның ни дәрәҗәдә мәкерле һәм оятсыз булуын төшенәсең. Ул адәм болай язган: «Россиягә сугыш белән ничә барып та отмадык һәм ота да алачак түгелбез. Ул илне эчтән җиңәргә кирәк, моның өчен һәр күңелдәге Ленинны үтерергә...» Күрәмсез, юлбашчыга атучылар хәзер дә бар, агуланган пуля кебек, агуланган сүз белән аталар. Моны бәяләп җиткермәү, җавапсыз калдыру хата булыр иде.

Совет ленинианасында беренче зур әсәрләрдән булган «Гасырлар һәм минутлар» поэмасы язылганга алтмыш ел тулды. Такташ дәвамчыларын һәр буыннан күрсәтергә була. С. Хәкимнең нәкъ менә шул рухтагы поэмалары, шигырьләре РСФСР Дәүләт премиясе белән бәяләнде. Татар совет поэтик ленинианасы үзе бер том булыр иде. һәм аны укучыларыбыз юлбашчының тууына 115 ел тулу уңае белән көтәргә хаклы дип уйлыйм. Китапны балаларның Ильичка багышланган шигырьләре белән ачып җибәрү урынлы булыр. Күрсен дошманнар, Ленин исеме, Ленин идеяләре һәр нарасый йөрәгендә — киләчәк йөрәгендә яши, һәм аны үтерү мөмкин түгел! С. В. Михалков балалар һәм яшьләр әдәбиятын бик урынлы рәвештә, биектә очкан пар канат белән чагыштырган иде. Ул ике канатның йөрәге — Ленин Ватанына булган мәхәббәт хисе, әдәбиятны киләчәккә илткән канатларны шул биек күтәрә.

Р. Фәйзуллин олы төшенчәләрне балага ишеттереп куярга, күңеленә салып калдырырга омтыла. Бәлкем кайберсен яши-яши төшенеп җитәр бала, үз тормышы, тәҗрибәсе аша аңлар. Балалар өчен язганда шагыйрь фикере табигыйрәк, ачыграк тоела. «Ничек яхшы булырга?» шигырендә ул болай ди: «Билгеле инде нишләсә — гел яхшы эш эшлисең! Ә эш эшләгән кеше — була бик яхшы кеше!» Эшкә өндәү — баланы тормышка әзерләү, тормышны төзүче тәрбияләү — балалар әдәбиятының төп бурычларыннан берсе. Хезмәт маймылны кеше иткән, дисәк, хезмәттән качканнарның кире маймылга әверелүен дә күрергә туры килә...

Хезмәткә багышланган шигырьләрне ике төркемгә бүлеп карап булыр иде. Эчтән сурәтләү — эш тәмен тойдырып, шул илһамлы процессны укучыга тәэсир итәрлек итеп язу. Икенчесе — тыштан сурәтләү — эшнең әзер нәтиҗәләрен санап чыгу... Хезмәт турындагы шигырь үзе дә илһамлы хезмәттә туарга тиеш. Шагыйрьләр бу темага үз ачкычларын табарга тырышалар. Я. Игәнәй шигырендә малайлар «кем булырга» дип баш ватканда берсе сүзгә катнашмый: «Хуш! Ашыгам, кырга китеш менә — комбайнда ярдәмче мин әтиемә...» ди. Я. Игәнәй кебек, Р. Вәлиев, Х. Хөснуллин, Н. Мадъяров, Р. Бәшәров, М. Матшин да КамАЗда яшиләр, якыннан әйбәтрәк күренә икән — гади автомобиль дип түгел, туган якның горурлыгы дип күрсәтәләр.

«Табигать турында, кешеләр турында, бар дөнья турында балалар җыры бу!» — ди Г. Рәхим «Чәчәк такыя» исемле китабында. Болай әйтергә хакы бар — чын балалар җырын җырлый ул, туган телнең тәмен тойдырып, тапкыр итеп җырлый.

Туган җиргә мәхәббәт, илнең батыр уллары турында язылган Р. Миңгалимов, Җ. Дәрзаманов, М. Әгъләмов, Н. Арсланов, Р. Вәлиева, М. Шабаев, К. Булатова, Ә. Рәшитов, З. Гомәроваларның китапларында чын балалар интонациясе белән туган шигырьләр бар.

Балалар әдәбиятын үз жанры итеп килгән яшьләргә аеруча текәлеп һәм өмет белән карыйсың. А. Нигъмәтуллин — Ш. Маннур якташы, Мамадыш районында чит тел укыта һәм балаларны туган телнең тәмен белергә өйрәтә. Ул көннәр буе балалар арасында, бүгенге көн төсмерләренең бала холкында чагылышын алданрак күреп ала.

Гадәттә, фамилияләр санау ялыктыручан. Балалар поэзиясе сафларына ышанычлы адымнар атлаган тагын берничә каләмдәшемнең исемен бик рәхәтләнеп саныйм. Менә алар: М. Галиев, Х. Гайнетдинов, Р. Корбанов, Д. Гарифуллин, Г. Садә, Г. Моратов, Л. Леронов, Рәниф Шәрипов...

Балалар әдәбиятында озак еллар эшләгән Ә. Бикчәнтәева, Г. Латыйп, Н. Гайсин, Г. Нәбиуллин, Э. Мөэминова, Җ. Тәрҗеманов, М. Фәйзуллиналарның да, юбилей даталары уңае белән, әсәрләре кабат басылып чыкты.

Поэзиябез ирешкәннәр зур, бу тагын да җаваплырак бурычлар йөкли. Биегрәк очу өчен кимчелек балластларыннан арына барырга кирәк. Әйтик, шигырьләр шома гына, теле дә йөгерек, материалы да кызыклы гына. Ә күңелдә канәгатьсезлек... Бу инде кемдер ачкан сыйфатның санын арттыру гына икән. Нәтиҗәдә кабатлаулар күмеп китә башлый — икенчеллек баса. Алдакчы умартачылар иска төшә, алар шикәр куеп, бал кортларыннан бал ясаталар. Әмма чын чәчәктән җыелган түгел инде — икенчел бу...

Сурәтләү чаралары да байый, яңара барырга тиеш. Туган телнең мөмкинлекләре иксез-чиксез. Атом заманында сүзнең эчке энергиясен ачарга кирәк, сүзлектән мөнаник күчереп утыртылган сүз тере булмый — сүз белән дә бала чактан ук бергә уйнап, дуслашып үсү тиеш.

Балалар драматургиясенең уңышлары быел 50 яше тулган Казан дәүләт курчак театры белән бәйле. А. Алиш: «Театр коллективы нигездә таза, нык, үсәргә омтылучан, үз эшенә нык бирелгән коллектив»— дигән иде. Театр бүген дә бу бәяне акларга тырыша. Репертуарда — язучыларның сыналган һәм яңа әсәрләре, гастрольләре — бөтен ил буенча. Театр яшүсмерләр һәм балалар өчен Т. Миңнуллин, Р. Батулла, Г. Рәхим, Н. Дәүли, Г. Сабитов пьесаларын шактыйдан бирле күрсәтеп килә, тамашачылар яратып кабул итәләр.

Т. Миңнуллин кебек танылган драматургның бу өлкәдә җитди эшләве күңелле күренеш. Иҗат стихиясе, җаны-сулышы белән чын балалар драматургы да ул. «Кәрлә — мәктәп баласы» исемле әкият-пьесасында Дию, Убырлы карчык, Шүрәлеләр катнаша. Әмма алар борын-борын заманда түгел, бүген хәрәкәт итәләр, аларга бик заманча бурыч йөкләнгән.

Театр өчен яңа автор Р. Харисның «Серле алан» әкияте уңышлы юл алды. Яхшылык белән яманлык бәрелеше ак һәм кара шарлар рәвешендә сурәтләнгән. «Җир шары язмышы өчен һәркем дә җаваплы» — әкият-тамаша балаларда шул олы хисне тәрбияләргә булыша. Н. Дәүлинең «Старт мәйданчыгы» пьесасы да актуаль темага багышланган. Киләчәктә театрның репертуар тематикасы нәкъ менә шушы юнәлештә үссә икән.

Р. Мингалимовның «Сихерләнгән урман» дигән лирик-героик тамашасы Мәскәү курчак театры сәхнәсенә менүгә иреште — бу безнең балалар драматургиясе яулаган биеклек.

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрына да рәхмәтле безнең балалар. Ю. Сафиуллинның «Алмазбулат» әкияте буенча куелган спектакль берәүне дә битараф калдырмый. Кеше буласың килсә, туган җиреңне, Ватаныңны, туган телеңне онытма — менә шул хакыйкатьне күңелгә уеп сала спектакль.

Бездә әкиятләр аз языла. Шигырь белән язылганнары да чыга тора. Р. Хафизова да шактый язды әкиятләрне. Балалар әдәбиятының мәгълүм әкиятчесе — Батулла, дисәм, ялгышмамдыр. «Көн уртасында могҗиза» әсәре илебез шәһәрләрендәге курчак театрларында бара. «Серле сандык» исемле зур китабы һәм русчага тәрҗемәдә Мәскәүдә өч әйбәт әкияте дөнья күрде. Тик бер әкиятендәге малай теләгенә генә кушылып бетәсе килми: «Әкият сөйләче, булсын аждаһа, булсын анда патшалар»,— ди ул. Бәлкем бүтән «катнашучылар» кирәктер? Юкса, карагыз инде, барлык әкиятләрдә шул ук штатный диюләр бит. Әлбәттә, яхшылык белән яманлыкны әзер образкалыпларга салып бирү ансатрактыр, әмма образ-маскаларга сюжет-шаблоннар иярүчән... Дөньядагы әдәби әкиятләр практикасы күрсәткәнчә, автор ачкан фәлсәфи тапкырлык яңалыгы кирәк, әйтәсе фикер үзенең яңа формасы, персонажлары белән гәүдәләнсен.

Балалар өчен очерк, публицистиканың да Такташ, Җәлилләрдән килгән сугышчан традициясе бар. Балаларны олы дөнья белән иң өлгер таныштырган, гражданин буларак, Ватан, халык интереслары белән яшәргә өйрәткән актив жанр ул.

«Алар Ильичка ант иттеләр» исеме белән «Яшь ленинчы»да басылып килгән очерклар ленинианы иҗади дәвам итә. Газетаның бу эше ил күләмендә яңгыраш алды: ВЛКСМ Үзәк Комитетының беренче дәрәҗә Дипломы белән бүләкләнде. «Комсомолданы елъязмасы»на кертелде. Хәзер бу тема «Хыялыңда без идекме, Ильич?» дип яңартылып дәвам итә, яшь буынның җаваплылыгы турында ачыктан-ачык сөйләшүне күздә тота. «Алар Ильичка ант иттеләр» исеме белән китап булып чыккан күпчелек очерк һәм публицистик язмаларның авторы — шагыйрь Зөлфәт. Шушы практика аңа Дж. Родарига багышлап «Йөрәкләрдә үлмәс» исемле үзенчәлекле поэма язарга этәргеч булды.

Һәр съезд саен диярлек балалар тәнкыйте булмау турында сөйләнелә иде. Бу юлы традицияне бозарга туры килер. Моның иң беренче сәбәпчесе — Р. Кукушкин. Ике съезд арасында ул ике китап чыгарды: «Шигъри бишек» һәм «Канатлы дөнья». Поэзиябезнең зур тарихын, юлын күздән кичергән, бүгенге үсеш тенденцияләрен, закончалыкларын ачкан хезмәтләр бу. Белинскийның, балалар язучысы булып туарга кирәк, дигән сүзләре тәнкыйтьчегә карата да дөрес икән. Равил үзе дә шигырь язган кеше, балалар шигыре стихиясен җаны белән тоя. Мөгаен, аның активлашуы өчен әдәбиятыбызның хәзерге күтәрелеш, яңарыш чорын кичерүе кирәк булгандыр. Соңгы ел-

ларда ул балалар прозасын, драматургиясен җентекләп өйрәнде. «Хыялый чынлык» исемле хезмәте — шуның нәтиҗәсе. Димәк, беренче тапкыр поэзия, проза, драматургия жанрларын тулаем эченә алган фундаменталь хезмәт башкарылды.

Р. Ягъфәров исеме дә балалар матбугаты битләрендә еш күренде. Балаларны фольклорның төрле өлкәләре белән чын-чыннан кызыксындыра алды, туган тел, халык иҗаты чыганакларына юнәлтте. Балалар фольклорына багышланган фәнни-тәнкыйди хезмәте «Шигърият чыганагы» дип атала. Балалар әдәбияты буенча бу ике тәнкыйтьченең диссертация язуы да безнең өчен яңалык, казаныш. Пушкин бик төгәл билгеләгән: тәнкыйтьнең торышы бар әдәбиятның өлгергәнлек дәрәҗәсен күрсәтә.

Балалар әдәбияты тәнкыйтендә электән эшләп килгән «олылар тәнкыйтьчеләре» дә безне онытмады: Н. Юзиев, Р. Мостафин, Р. Мөхәммәдиев, М. Вәлиевләрнең белеп һәм принципиаль язылган, бүгенге әдәби процессны яктырткан мәкаләләре күренә торды. Балалар язучылары үзләре дә проблемалы мәкаләләр белән матбугатта чыгыш ясадылар.



*Залда һәр чыгышка игътибар зур булды.*

Жанрның киләчәге дә өметләндерә. Үзенчәлеген төшенеп, кайгыртып язган күп кенә мәкаләләре белән Г. Моратов, Л. Леронов, Ә. Сәхапов, Ф. Зөлкарнәев, З. Хәснетдинов исемнәре укучыларга мәгълүм.

Балалар әдәбиятының бүгенгесенә игътибар арта икән, аның киләчәге дә өметле дип уйларга урын бар. Бу ышанычны ныгыткан җитди бер чара итеп «Татарстан яшьләре» газетасында «Яңавыз» исемле республика яшь тәнкыйтьче студиясен әйтер идем. С. Маннапов җитәкләгән бу студия иҗади эшли, ул әдәбиятта яңа исемнәр ачар, фикерле яшьләрне күзгатыр дип ышанабыз.

Соңгы өч съезд арасында мин дәреслекләрне күзәтеп барам — үзгәрешләр яхшыга таба. Әмма тормыш таләпләре тагын да тизрәк үсә. Иң беренче тәэсир — бала табигатенә хас җанлылык, тапкырлык җитми. Без укып үскән китаплар нәкъ әнә шул сыйфатлар белән истә калган. Балачак тәэсире генә түгел микән дип, профессор М. Корбангалиев төзегән 1936 елгы әлифбадан соңгы уку китабын алып карадым. Кырыклап материал балаларча зирәк, шаян һәм үтемле. Шаян рәсемнәр саны дистәдән артык. Шуларның берсе — урындык аякларын тигезләүче малай хакында. «Урындыкның аягы озынрак, кисеп алыймчы аны азрак»,— ди торгач, бөтенләй кисеп бетергән дә «Их, ялгышканмын икән азрак!»— дип башын кашып тора. Хәзерге дәреслек авторлары да, кыскарта торгач, дәреслекләрдәге юморны да әлеге урындык аяклары сыман иттеләр бугай...

Үзебез укыган әлифбаны да карадым. 140 мең бала укыганбыз икән ул чакта. Тукайның да биш шигыре бар. Санадым, ник дисәгез, бүгенге атаклы әлифбабызның 20 нче басмасында шигыре дә, исеме дә юк. Тиражын карап әйтсәк — 26500 бала Тукайны ишетмичә әлифба белән хушлаша. Моны ничек тә аңлатып булмый. «Татарстан яшьләре» газетасында басылган бер хаттан Тукайны белмәүчеләр бар, дигәнне укып сәерсенгән идек, болай булгач, ышанырга да туры килер...

«Гомуми әдәби хәрәкәттә һәрбер жанрның үзенчәлекле урыны бар»,— диелә X класс дәреслегендә, һәм барлык жанрлар санала, ә менә балалар әдәбиятына, нишләптер, урын юк. Хәер, бер җөмлә бар икән: «Ә. Фәйзи балалар өчен дә матур-матур шигырьләр, әкиятләр иҗат итте»,— диелгән. Балалар әдәбияты үсешенә зур этәргеч ясаган әдип турында бары шул гына. Анысы да һәркемгә тәтеми. Б. Рәхмәт иҗаты бөтенләй өйрәнелми. Бары тик «Кызыклы грамматика» дигән китапта: «Шигырең өчен, Бари Рәхмәт, бездән сиңа зур рәхмәт»,— диелә. Рәхмәтегезгә рәхмәт инде, әмма бу хакта җитдирәк уйланыр вакыт җитте, моны балалар әдәбиятының зур тарихы да, бүгенге дәрәҗәсе дә таләп итә — балалар әдәбияты буенча махсус дәреслек китабы кирәк! Бу жанр укытылган Алабуга педагогия институтының башлангыч класс укытучыларын әзерләү факультеты өчен, Арча һәм Минзәлә педагогия училищелары өчен кирәк. Әлегә исә расланган программасы да юк. Мәктәп реформасы уңае белән бу проблема әлбәттә искә алыныр дип ышанабыз. Рус совет балалар әдәбияты буенча бик матур үрнәкләре — дәреслеге дә, хрестоматиясе дә бар.

Безнең балалар матбугатында күркәм гадәт яши: укучылар иҗатына урын иң түрдән бирелә. Мәктәп әдәби түгәрәкләрендә җанлану сизелә. Язучылар союзы идарәсе председателенең яшь авторлар белән эшләү буенча урынбасары И. Юзеев иҗатчы мәктәп балаларының республика конференцияләрен үткәреп, стратегик масштабларда эш башкарды. Бу — киләчәккә юнәлтелгән, озак дәвам итәсе чара.

Балалар өчен нәшриятыбызда чыгарыла торган китапларыбызның художество эшләнеше, техник башкарылышы турында сүз кузгатып, башта ике язучыбызның фикерен китермәкче булам. «Балалар китабы һаман начар кәгазьдә, начар оформлениедә һәм соңга калып чыгуда дәвам итә. Инде моңа чик куелырга вакыт»,— ди берсе. «Нәшриятларга бу съездда балалар китабының техникасын яхшыртуны нык куярга туры килер»,— ди икенчесе. Ф. Кәрим белән М. Җәлил сүзләре бу. Беренче съездыбызда борчылып әйткән бу сүзләрдән соң зур тарихи чор узды. Бу өлкәдә ирешкәннәр аз түгел. Әмма проблема кала, ул заман белән бергә акселерат бала сыман үсә— төсле дәреслек, төсле телевизорга иялəшкән бала төсле рәсемле китаплар эзли. Дөньяны үз төсендә таныйсы килә аның, һәм бу бик табигый. Балалар китабы совет иле гражданины, көрәшче тәрбияли торган чара, политик китап сыман игътибарга лаек, балалар китабы да — политика! Безнең дөнья ярминкәләренә чыгып тәкъдим итәрлек әсәрләребез бар. Бары тик аларны тиешенчә «киендерергә» генә кирәк.

Үткән съездда күп томлы «Татар совет балалар әдәбияты» китапханәсен бастырып чыгару турында тәкъдим булды. Әдәбиятыбызның күренекле вәкилләренең заман сынавы үткән әсәрләрен тиешенчә чыгару күздә тотылган иде. Тәкъдимне нәшрият кабул итте. Әмма «Балалар китапханәсе» сериясеннән съезд арасында нибары бер китап чыкты. Андый китаплар берәмләп тә түгел, күпләп чыгарылырга тиеш — шунсыз без байлыгыбызны укучыга җиткерә алмаячакбыз.

Язучыларның балалар әдәбиятында эшләвен стимуллаштыру максаты белән СССР Госкомиздатының махсус күрсәтмәсе булды. Олылар өчен китабы чыккан елны да язучы балалар китабы чыгара ала, диелгән анда. Безгә дә моны гамәлгә кертергә кирәк, аннары нәниләр өчен бик кирәкле «Мои первые книжки» тибында зур тираж белән татарча, русча китаплар чыгару мөмкинлеге булыр иде, һәм бу балалар өчен язуны хуплау булып кабул ителер иде.

«Балалар китапханәләрендә СССР Мәгариф министрлыгы тәкъдим иткән китапларның 30—50 проценты, авылларда 80 проценты бөтенләй юк»,— дип яздылар Р. Шәмсетдинова һәм Т. Дунаева иптәшләр 1983 елны «Казан утлары»нда басылган «Китап һәм укучы» дигән мәкаләдә. Сискәндерә торган хәл бу. Мәсьәлә гаять җитди һәм уйланырлык. Балалар өчен китап бастырып чыгару эше безнең балалар әдәбияты ирешкән дәрәҗәдән артта кала.

А. М. Горький, балаларны ярату, аларны тәрбияли белү искиткеч зур дәүләт эше, дигән иде. Моның шулай икәнен мәктәп реформасын тикшерүдә бөтен илнең катнашуы ачык күрсәтте. «Гомуми белем мәктәбе һәм профессиональ мәктәп реформасының Төп юнәлешләре»ндә бөтен тирәнлеге белән чагылды. Татар совет балалар әдәбиятының киләчәк буынны коммунистик рухта тәрбияләү кебек җаваплы эштә керткән лаеклы өлеше бар, алда торган бурычларның җитдилеге безгә тагын да зуррак җаваплылык өсти, илһамлы иҗатка өнди.

## Марсель Зарипов

# АЛГЫ СЫЗЫКТА БУЛЫЙК

Публицистиканың урыны, чыннан да, паровозның алдында! Татарстан язучылары съездында сөйләнгән төп докладта очерк һәм публицистикага багышланган махсус бүлекнең булуы әлеге жанрның рухи тормышыбызда гаять әһәмиятле роль уйнавы турында сөйли, һәм, гомумән, бу хәл аның табигате буенча ук әдәби фронтның алгы сызыгында хәрәкәт итәргә тиешлеген тагын бер мәртәбә искәртә.

Шулай ук иҗат оешмабызда (автономияле республикалар арасында, минемчә, бердәнбер буларак) махсус рәвештә очерк һәм публицистика секциясе төзелү дә бездә мондый жанрга зур игътибар бирелүен раслый. Дөрес, СССР һәм РСФСР Язучылар союзлары каршында эшләүче очерк һәм публицистика Советлары белән бездәге секция арасында ниндидер охшашлык бар, әмма алар үзләренең «эш шартлары» буенча бер-берсеннән шактый аерылалар. Югарыда телгә алынган Советлар документаль жанр буенча эшләүче профессиональ осталарның зур «штаты»н берләштерә. Алар арасында данлы исемнәр дә байтак. Мондый авторларның эшләре исә шәхси уңыш булу белән бергә, күп милләтле совет әдәбиятының уртак казанышына әверелә бара. Ә бездә очерк һәм публицистика йөген үзләренең күпчелек көчләрен башка жанрларга бирүче прозаик, шагыйрь, драматург, тәнкыйтьче һәм журналистларга тартырга туры килә. Аларны бу эшкә алынырга, гадәттә, бүгенге көндә күпләрне кызыксындырган актуаль темалар, җәмгыять һәм дәүләт игътибарын сораучы проблемалар мәҗбүр итә.

Киң җәмәгатьчелеккә бигүк таныш булмаган яңадан-яңа сугыш каһарманнарын ачучы тынгысыз эзтабар язучы Самат Шакир тарафыннан язылган утызлап китапның яртысы очерк жанрына карый. Ике фронтта — проза һәм драматургия өлкәсендә эшләүче Гариф Ахунов очерк һәм публицистика жанрын үзләштерүгә дә үзеннән лаеклы өлеш кертә. «Яшисе килә» исемле документаль повесть — Разил Вәлиевнең зур уңышы, һәм автор әлеге әсәре өчен хаклы рәвештә Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясенә лаек булды. Үзенең иҗат биографиясен Шамил Рәкыйпов очерктан башлады. Хәзер ул үз эшчәнлеген документаль повесть һәм романнар сериясе тудыру юнәлешендә дәвам иттерә. Ә мондый әсәрләр, әйтик, традицион беллетристика алымнары белән язылган китапларга караганда яратыбрак укыла һәм китап укучыларның мондый серияләргә ихтыяҗы артканнан-арта бара.

Очерк һәм публицистика өлкәсендә башкарылган оештыру чаралары һәм конкрет нәтиҗәләр, бер яктан, язучыларыбыз коллективының ресурслары турында сөйлиләр, икенче яктан, әдәби фронтның алгы сызыгында әле күпме мөмкинлекләр булуын һәм аларның әлегә аз файдаланылуын искәртәләр, үз алдыбызга зур бурычлар куярга өндиләр.

Популяр энциклопедик сүзлекләрдә аңлатылганча, публицистика — заман ихтыяҗларын нечкәләп тоючы, үзенең игътибарын иң киеренке вакыйга һәм процессларга юнәлдерүче оператив әдәбият төре, җәмәгатьчелек фикеренә, кешеләрнең йөрәгенә һәм күңеленә турыдан-туры йогынты ясау максатыннан, киң-үзәк социаль мәсьәләләр хакында уртага салып сөйләшү чарасы. Ә тирә-ягыбызда төрле хезмәт кешеләренең — фәнни лабораторияләрдә, кырларда һәм фермаларда, станок янында һәм башка урыннарда эшләүчеләрнең игътибарын кичекмәстән юнәлтерлек мәсьәләләрне санап бетерерлек түгелдер. Әмма язучыларыбыз арасында заман чакыруын алдан ук ишетеп алучылар, бүгенге көннең актуаль проблемалары турында, әйтик, роман, повесть, поэма иҗат иткәндәгечә җаваплылык белән җитди очерк яки зур китап язарга алынучылар бармак белән генә санарлык. Күп кенә каләм осталары үзләренең уку-

чыларына киң эпик полотнолар яки шигъри китаплар гына бирәләр. Ә мондый әсәрләр, гадәттә, шактый акрын языла һәм шулай ук озак басыла.

Хәзер документаль жанр үрнәкләренә, әйткәнебезчә, ихтыяҗ артты, чөнки мондый әдәбият (югары идея-эстетик дәрәҗәдә эшләнгән очракта) үзенең нәтиҗәләрелеге ягыннан башка төр әсәрләрдән ‌ еш кына бер башка югары ‌ тора. Җир һәм кеше, ‌ авыл һәм шәһәр, КамАЗ һәм фән, бүгенге көнкүреш һәм иртәгәге көн бурычлары, узган еллар героикасы һәм замандашларыбызны борчыган мәсьәләләр — бездән тирән итеп үзләштерүне таләп иткән темалар әнә ничаклы! Ә без... мәсәлән, КамАЗны ‌ Мәскәү язучылары безгә караганда активрак үзләштерәләр. Безнекеләр әлеге гигант төзелешкә карата ничектер суындылар. Шулай ук гаять мөһим тема — Ленин темасы буенча да, Сибгат Хәким поэмалары, Рафаил Төхфәтуллинның унбиш еллап элек язылган «Давыл чәчәге» һәм Виктор Байдеринның «Ленин Казанда» исемле китапларыннан соң, әйтергә мөмкин, безнең авторлар язмый башладылар; Шагинян һәм Прилежаева, Ульяновскидан Миндубаев һәм шулай ук Трофимов тарафыннан язылганнар һаман да үрнәк булып кала бирә.

Публицист таланты — үзгә талант. Яхшы публицист булу өчен әдәби күнекмәләр генә, тирән белем һәм компетентлык кына җитми, чын мәгънәсендәге гражданлык кыюлыгы да таләп ителә. Үзенең геройлары алдында икейөзләнүче, стандарт редакторлар көен көйләүче, авторитетлардан куркып торучы авторлардан беркайчан ‌ да чын публицистлар чыкмыйдыр. Публицистка бик авыр миссия йөкләнгән. Менә шуңа күрә дә, югарыда санап үтелгән кимчелекләрдән тулысынча азат булган документаль жанр осталары бик сирәк очрыйлар. Танылган публицист Анатолий Стреляный тикмәгә генә болай әйтмәгәндер: конкрет материал, уйлап чыгарылмаган тере геройлар белән эш итүче язучыларга, сәламәтлеккә зыянлы производстводагыча, өстәмә рәвештә сөт белән түләргә кирәк.

Сүз дә юк, чыккан китаплар, «Казан утлары», «Азат хатын», «Ялкын» кебек журналларда басылган язмалар, телевидение һәм радио аша яңгыраган чыгышлар күп, әмма, кызганычка каршы, авторлар арасында бүгенге чынбарлыкка югары дәрәҗәдә политик һәм социаль анализ биргән, кичәге һәм бүгенгенең «очын-очка» дөрес ялгаган, хәл-шартларны дөрес аңлаган, фикер йөртүдә, бәя бирүдә һәм нәтиҗә чыгаруда партиячел һәм гражданлык принципиальлеге күрсәткән каләм ияләре алай ук ‌ мул күренми.

Әгәр дә ки язучылар коллективының очерк һәм публицистика тармагындагы эшчәнлегенә югары таләпләрдән чыгып бәя биргәндә, шуны әйтергә мөмкиндер: ‌ бу юнәлештә без беренче адымны атладык — әлеге жанрның алгы ‌ сызыкта ‌ хәрәкәт итәргә тиешлеген аңладык. Ә хәзер бер карыш та чигенмәскә кирәк. Ә эшлисе эшләр бик күп. Алар публицистиканы үстерергә омтылганда бигрәк тә ачык күренә, чөнки һәрбер башкарылган эш үз чиратында тагын да җитдирәк һәм җаваплырак проблемалар китереп чыгара.

Шуны да ачык тоясың: безнең публицистика үрнәкләре казанышларны гына түгел, ә җитди югалтуларны, әйтик, язучыларыбызның тормыш материалын әлегә ‌ тиешле дәрәҗәдә гомумиләштерә алмауларын, фикер йөртәсе, уйланасы урында, плакат һәм лозунглар белән сөйләүләрен, нигезсез мактауга бирелүләрен дә чагылдыра. Мәсәлән, ‌ кайбер публицистлар гомер эчендә бер яхшы уңыш ‌ җыйган ‌ хуҗалыкларга баралар да, тирәнтен уйлап тормастан, тиз генә шундый нәтиҗә ясап куялар: «җир белән сөйләшә беләләр...» Ә минемчә, «сөйләшергә өйрәнәләр», дип язу дөресрәктер (гәрчә игенчелек бик борынгы шөгыль булса да). Әнә бит, безгә бик яхшы мәгълүм булган «җир академигы» Т. Мальцев кырчылык эшендәге алым һәм формаларны камилләштерү юнәлешендә кешеләр яңа ачышлар бусагасында тора дип белдерә.

Уйландырырлык бер факт китерик. Эшче куллар җитешмәгән кайбер колхоз һәм совхозларда авыл мәктәпләрен тәмамлаган яшьләрне ике еллык мәҗбүри хезмәткә тарту «тәҗрибә»сен кертергә омтылалар, һәм, алай гына да түгел, әлеге наив модель үрнәк-эталон сыйфатында башкаларга да тәкъдим ителә. Ә тормыш үзенекен «сукалый». Борынгы крестьян хезмәте вакытлы кешеләр кулында яши аламы? Ни өчен авыл кешеләре миграция стихиясенә каршы тора алмыйлар? Безне менә нинди сораулар борчырга тиеш.

Иң төп бәла шунда: без кайчак публицистиканың бурычын онытып җибәргәлибез— дөреслекне маңгайга бәреп әйтәсе урында, бөтенесен дә ал да гөл итеп күрсәтергә тырышабыз. Әлбәттә, тормыш матурлыгы турында күбрәк язарга кирәк, әмма көнкүрештәге кайбер кыенлыклар хакында да сүз кузгатырга онытмыйк. Уртага салып сөйләшик. Зарланырга яратучыларга, шыңшып йөрүчеләргә азык калмасын. Бүгенге заманның иң катлаулы проблемаларын хәл итүдә катнашучы гайрәтле кешеләрне данлыйк, аларның физик һәм әхлакый көчен, кыюлыгын һәм яхшы мәгънәдәге үҗәтлеген, рухи матурлыгын һәм киң карашлылыгын калку итеп күрсәтик. Ә бит авырлыкларны җиңәр өчен нәкъ менә шундый сыйфатлар сорала, һәм алар КамАЗ куәтләрен үзләштергәндә дә, БАМ төзегәндә дә, Кара туфраклы булмаган зонаны үзгәртеп корганда да, галәм киңлекләрен ачканда да кирәк.

Күзәтүләр күрсәткәнчә, безнең кайбер очерклар дөреслек принцибыннан түгел, ә «матур сүз әйтү» максатыннан, ялгыш караштан чыгып языла. Мисалмы? Бездә һәм башкалада китаплар чыгарып, актив кына иҗат итүче Әхәт Гаффарның «Казан утлары» журналында (1982 ел, 1 нче сан) басылган бер очеркын искә төшереп үтик. Белгәнебезчә, 1981 ел безгә корылык алып килде, мәрхәмәтсез стихия тир түгеп үстерелгән игеннәрне көйдерде. Менә шундый авыр елда Ә. Гаффар «1981 ел икмәге» исемле очерк язды. Әйтергә кирәк, күпләрне борчыган мәсьәләне күтәреп, автор үзенең гражданлык вазифасын үтәде. Әмма... Кузгатылган мәсьәлә очеркта ялгыш хәл ителә.

Рәхимсез корылык хуҗалык белән идарә итү осталыгын катгый тесте сынады. Табигать бәла-казасы тотрыксызларны егып салды, ә көчсезләрне селкеткәләп кенә узды. Очерк авторы үзенең уйланулары өчен республикабыздагы иң икмәкле төбәкләрнең берсе — Буа районын нигез итеп ала. Ә бу район, дөресен генә әйткәндә, сиксән беренче ел корылыгын авыр кичерде, һәм, алай гына да түгел, унынчы бишьеллык планнарын үти алмады. Чынлыкта корылык кырларны түгел, кешеләрнең оешканлыгын, осталыгын һәм ныклыгын сынады. Югыйсә, конкрет хәлләр публицистка максатны үзләре үк әйтеп торалар: бөтенесен дә һава шартларына гына сылтаргамы, табигать стихиясенә каршы көрәшергә әзерләнмәгән кешеләргә гаепнең күпме өлеше туры килә?.. Ә очерк авторы «корылык алдында борыннарын төшермәгән» кешеләрне юатудан узмаган. Һәм, җитмәсә, әлеге очерк ТАССР Министрлар Советы ашлык җитештерүдәге кимчелекләр турында җитди карар кабул иткән айда басылып чыкты. Ә тәнкыйть ителгән районнар арасында Буа районы да бар иде.

Шундый очраклар да була: кайвакыт язучы карашы рәсми органнар фикереннән шактый аерыла. Бу уңайдан Сергей Залыгинның партиячел позициясен, язучылык принципиальлеген бик ачык чагылдырган шундый бер фактны искә төшерик. Түбән Обь гидростанциясе проекты инде күп кенә хөкүмәт инстанцияләрен үтеп, раслану сәгатенә якынлашканда язучы әлеге төзелешне тормышка ашыруга каршы чыга. Ни өчен? Сәбәбе шунда: сусаклагыч Түмәндәге булачак промыселларның зур өлешен басып китәчәк. Язучы моңа каршы чыга һәм үзенең хаклыгын раслый. «Залыгин конфликты»ннан соң инде чирек гасыр узды. Хәзер Түмән сазлыклары астындагы катламнардан көн саен бик күп нефть һәм газ чыгарыла.

Кызганычка каршы, «1981 ел икмәге» очеркында гомум файдалы эш өчен яну, дөреслекне ачу юлында кыюлык күрсәтү сизелми. Дөрес, 1983 елгы эш нәтиҗәләре өчен Буа районы КПСС Үзәк Комитеты, СССР Министрлар Советы, ВЦСПС һәм ВЛКСМ Үзәк Комитеты байрагына лаек булды. Әмма күпмедер вакыт аралыгында ирешелгән җиңү тынычланырга нигез бирми. Хуҗалыклар унберенче бишьеллык планнарын үти алырлармы? Ә бүгенге көндә район дәүләткә 42 мең тонна бөртекле ашлык, 10 мең тонна шикәр чөгендере, 2,6 мең центнер ит биреп җиткермәде. Ә план, КПСС Үзәк Комитетының апрель (1984) Пленумында иптәш К. У. Черненко тарафыннан басым ясап әйтелгәнчә, «партия, политика җаваплылыгындагы эш».

Бүгенге тормыш күренешләрен, замандашларыбызны борчый торган проблемаларны тирәнтен өйрәнмичә, өстән-өстән генә язылган мәкаләләр язучыга бернинди дә мәртәбә алып килми, киресенчә, алар гомум эшкә зыян гына китерәләр.

Әдәбиятыбызның иң алгы сызыгында торучы иҗат көчләрен туплау өчен оештыру эшләрен хәзер туктаусыз дәвам иттерү сорала. Азык-төлек, энергетика программаларын, авылларны үзгәртеп кору, шәһәрләрне һәм промышленность үзәкләрен тагын да үстерү кебек дәүләткүләм әһәмиятле планнарны тормышка ашыру политик, иҗти-

магый, экономик, социаль һәм әхлак өлкәләрендәге уңышларга турыдан-туры бәйләнгән, һәм бу уртак эштә публицистиканың да ярдәме таләп ителә. Бу җәһәттән «Казан утлары» журналының Татарстан атом электр станциясендә әдәби пост оештыруы хуплауга лаек. Соңгы вакытта журнал битләрендә төзелешнең барышы әйбәтрәк яктыртыла башлады.

«Публицист» сүзе язучының публика, халык белән сөйләшүен аңлата. Әмма безнең очерк китапларыбыз әлегә республика чикләрендә генә калалар. Аларны тәрҗемә итү, Бөтенсоюз аудиториясенә җиткерү — күтәрелмәгән чирәм. Шөкер, Мәскәүдә прозаик һәм шагыйрьләрнең китаплары чыга тора, ә менә татар публицистларының хезмәтләре бөтенләй диярлек күренми. Соңгы унбиш ел эчендә язучыларыбыз республикадан читтә дүрт йөздән артык проза, поэзия китаплары бастырдылар, ә очерк һәм публицистика жанрындагы казанышлар шулкадәр аз, аларны санар өчен бер кулдагы ике бармак та җитә. Ачыклабрак әйткәндә, ике съезд арасында Мәскәүдә очерк һәм публицистика жанрына караган бары ике китап — Э. Касыймов һәм Г. Ахунов китаплары дөнья күрде.

Бу юнәлештә ни өчен пассивлык күрсәтәбез? Беренчедән, нигәдер мәкаләне, очеркны, документаль китапны русчага тәрҗемә итү гадәткә кермәгән. Икенчедән, кирәк-кирәкмәгәндә ике йөзгә якын членыбыз бар, яшь һәм башлап язучыларны да исәпләсәк, меңгә җитәбез, дип күкрәк кагарга яратсак та, бездә үзәк матбугатка үтеп керерлек көчләр юк дәрәҗәсендә. Үзәккә кемнәр юл яра? «Москва» журналы трибунасыннан Геннадий Паушкин чыгыш ясады. «Дружба народов»та — Рафаэль Мостафин, «Смена»да Диас Вәлиев публицистик мәкаләләрен бастырдылар. Шулай ук Нонна Орешина да «Правда» газетасына үзенең яраткан геройлары — хәрби очучылар турында язгалап тора. Әмма әлеге язучыдан күбрәк тә көтәргә хакыбыз бар.

Очерк һәм публицистика жанрында үзәккә тиешенчә чыга алмау, бәлки, тәрҗемә өлкәсендәге кыенлыклар белән аңлатыладыр?! Әмма республикабызда чыга торган газета һәм журналларда да яхшы публицистика үрнәкләре алай ук мул күренми. Үзеннән-үзе аңлашыла: әдәбиятның иң оператив һәм эшлекле жанрын үстерүне оештыру, аның югары нәтиҗәлелеген тәэмин итү вакытлы матбугат органнарының гына түгел, Язучылар союзы идарәсенең дә даими кайгыртучанлыгын таләп итә.

...Атаклы кавалерист-кыз Надежда Дурова, хәрби хезмәттән китеп, Алабугага кайта һәм язучылык эше белән шөгыльләнә башлый. Менә ул үзенең «Кавалерист-кыз язмалары»н А. С. Пушкин хөкеменә җибәрә. Бөек шагыйрь аның әдәби күнекмәсенә уңай бәя бирә, каләм белән, гусар кылычын уйнаткандагыча, оста эш итүен әйтә. Шуннан соң бер ай үтә — кульязма беркайда да басылмый. Ике, өч ай уза — нәтиҗә күренми. Дүртенче айга чыккач, кылыч сугышларында күп мәртәбәләр катнашкан каһарман кавалерист-кыз, Россиянең бөек шагыйре авторитеты алдында югалып калмыйча, Александр Сергеевичка үзенең канәгатьсезлеген белдерә. Ә Пушкин исә җавап хатында китап бастыру эшенең четерекле һәм катлаулы булуын, шуңа күрә, дүрт айлык тоткарлануларның ихтималлыгын аңлата.

Ә хәзер дүрт ай элек бирелгән кульязма турында сорашып нәшриятка мөрәҗәгать итсәң, синә сәерсенебрәк карыйлар һәм кайчак җавап та биреп тормыйлар. Парадокс: нәшрият эшләре белән идарә итүдә күбрәк тәҗрибә туплаган саен, «нәшрият машинасы» (үзәктәгеләре дә исәпкә алына) акырынрак тәгәри шикелле. Югыйсә планлаштыру эшендә математик компьютерлар кулланыла, авторга консультантлар, рецензентлар торган саен күбрәк ярдәм күрсәтәләр. Ә нәтиҗә... Нәшрият машинасының тизләгән арттыру язучыларның көченнән килми, әмма иҗат эшчәнлеген төптән уйлап оештыру китапларның чыгу срокларына йогынты ясарга мөмкиндер.

Шундый күркәм кагыйдә барлыкка килде: Татарстан китап нәшрияты һәм Язучылар союзы идарәсе китаплар чыгару планын бергәләп тикшерәләр. Әлеге форманы камилләштерү таләп ителмиме? Бу уңайдан шуны гына әйтеп узасы килә: без җыелган уңышны, кул астында булган әзер кульязмаларны гына планлаштырабыз түгелме? Шулай да китаплар шактый озак чыга, кимендә ике-өч елдан соң гына дөнья күрә. Тормыш темпы елдан-ел арткан заманда очерк яки башка документаль китапларның шулай соңгарып чыгуы белән килешәсе килми, чөнки алар инде кешеләргә кичәге көн турында сөйләячәкләр. Менә шуңа күрә, эшне «көлтә суктыру»дан түгел, ә күпкә элегрәк башлау нәтиҗәлерәктер.

Белгәнебезчә, китапларны спецзаказ буенча яздыру да бар. Әмма язучылар оешмасы һәм нәшрият мондый алымны бик сирәк кулланалар. КамАЗ турында беренчеләрдән булып очерклар китабы чыгарган Г. Паушкинга берничә ел элек нәкъ менә шундый заказ бирелде. «Түбән Каманың бәхетле сәгате» исемле документаль китап та шулай язылды. Әгәр мондый практиканы үстерү күздә тотылса, язучылар оешмасы һәм нәшрият планны финишта түгел, ә авторлар кулъязма өстендә эшләгәндә ук карый башларга тиештер. Язучыга конкрет эш йөкләргә кирәк. Хәтта роман, повесть, пьесаларны да басылу вакытын алдан билгеләп яздыртырга мөмкиндер. Әлбәттә, мондый алым күп очракта әзер кулъязмалар белән генә эш итүче нәшриятка өстәмә мәшәкатьләр тудырачак. Язучылар союзына да китап бастыру буенча гына түгел, ә китап яздыру юнәлешендә дә оештыру эшләрен киңәйтергә туры киләчәк. Иң әһәмиятлесе: мондый алым язучыларның иҗат активлыгын тагын да арттырыр иде.



*Үзбәкстаннан килгән кунак Тураб Тула һәм татар язучылары Азат Әхмәдуллин белән Лирон Хәмидуллин (сулдан уңга)*

Очерк һәм публицистика жанрын үстерү турында сөйләшкәндә, әдәби тәнкыйтьнең йогынтылы көчен дә истә тотарга кирәктер, чөнки бу эштә белгечләребезнең дә үзләрен җаваплы итеп тоюлары сорала.

Күптән түгел профессор Мөхәммәт Гайнуллинның «Татар әдәбияты һәм XX гасыр башы публицистикасы» исемле зур теоретик китабы дөнья күрде. Үткән тәҗрибәне анализлау яхшы, әмма мемуар үрнәкләрен бүгенге көн практикасы үрнәкләре белән тулыландырганда, тагын да яхшырак булыр иде. Хөрмәтле аксакалның яшь каләмдәшләре, фикердәшләренең шундый китаплары нигә күренми? Югыйсә, анализлау, тикшерү, киңәшү, бәхәсләшү өчен эшләр бихисап! Каләм осталарының очерк язу практикасы, публицистика өлкәсендә газета һәм журналларның, шулай ук радионың тәҗрибәләре дә җитди гомумиләштерүләрне көтәләр. Телепублицистика да үсте. Нәрсәнең яхшы икәнен, чиратта нинди проблемалар торуын җентекләп анализлыйсы, нәтиҗә ясыйсы бар. Дөрес, без Ф. Әгъзамовның бүгенге очеркләрдагы геройлар, И. Низамовның газета һәм журналлар теле турындагы аналитик хезмәтләрен беләбез. Әмма болар гына аз. Әгәр мондый алымнарда барса, очерк һәм публицистика проблемалары белән шөгыльләнүче тәнкыйтьнең җанлы әдәби процесс темпына өлгерә алмавы мөмкин.

Очерк һәм публицистиканың өстенлеге шунда: әйтик, театрга, студиягә, режиссерга бәйле пьеса яки сценарийдан аермалы буларак, бу жанрлар үзләрен үзләре аклыйлар. Әмма моның өчен мәҗбүри шарт бар. Алар югары таләпләргә җавап бирерлек булырга, тормышның социаль-политик күренешләре белән тирән кызыксынуны гәүдәләндерергә, тикшерелә торган проблемалар халык хуҗалыгы һәм гомум кешелек әһәмиятенә ия булырга, бәя һәм нәтиҗәләр, фикер, тел, стиль һәм форма тәгәл булырга тиеш.

Әгәр дә шундый дәрәҗәдә эшләсәк, яхшы оешканлыкка югары гражданлык кыюлыгы һәм профессиональ җаваплылык та өстәсәк, без партиягә, дәүләтебезгә һәм халыкка тагын да зуррак файда китерербез. Язучы өчен моннан да мөһимрәк бурыч юк.

## Кыям Миңлебаев

# АНА ТЕЛЕНДӘГЕЧӘ УКЫЛСЫН!

Туган телендә язылганны гына укып, башка телләрдә иҗат ителгән гүзәл әсәрләр белән кызыксынмаучы халыкны бүгенге көндә күз алдына китерүе дә читен. Ә башка халыкларның әдәбият җәүһәрләре белән танышу мөмкинлегенә һәр халык тәрҗемә аркылы ирешә.

Безнең республикада татар язучыларының әсәрләрен русчага тәрҗемә итүчеләр булган кебек, бүтән телләрдән татарчага тәрҗемә итүчеләр дә бар. XX йөз башыннан бирле яшәп килгән әдәби тәрҗемә соңгы елларда аеруча нык камилләшеп китте. Бүген татар укучылары тәрҗемә китаплардан аларның идея эчтәлеге, аерым вакыйгалар белән танышып кына калмыйлар, бәлки әле әсәрнең кыйммәте, оригиналның тел үзенчәлекләре, авторның стиле, язу ысулы хакында да мәгълүмат туплыйлар һәм боларның җәмгысе нәтиҗәсендә эстетик ләззәт алалар.

Прозаны тәрҗемә итүдә элегрәк С. Әдһәмова, К. Басыйров, И. Гази, С. Фәйзуллин, А. Шамов бик күп файда китерделәр, әдәбиятыбызны гүзәл әсәрләр исәбенә баеттылар. Әйтик, рус классикасын берничә буын укучылар шул талант ияләре тәрҗемәсендә уку бәхетенә ирештеләр.

Илленче елларда әдәбиятка килүче яшьләребез һәммәсе диярлек тәрҗемә белән мавыкты, ә инде тора-бара кайсыберләре — Г. Ахунов, Н. Фәттах кебекләре — үз китапларын язарга кереште, ә икенчеләре исә тәрҗемәгә тугрылыклы булып калды. Шулай итеп, безнең әдәбиятта нык әзерлекле, белемле һәм фикерле, эшчән һәм сәләтле тәрҗемәчеләр мәктәбе хасил булды. Кая ул хәзер аерым сүзләрне яисә җөмләләрне тәрҗемә итү белән генә чикләнү! Бүген бәйге тотучы тәрҗемәчеләребез тулы картина, күренешләрне күчереп куялар да, алар тасвирлаган ул күренеш, вакыйгалар белән мавыгып китеп, укучы ирексездән үзен шул китаптагы персонажларның дусты яки дошманы буларак хис итә, үзен әлеге сурәтләнгән дөньяда итеп сизә башлый, дәртләнеп һәм рухланып яши.

Үз эшләрендә зур камиллеккә ирешкән тәрҗемәчеләр һичбер вакыт ни әлекте шуны эшләргә, күңелләренә хуш килмәгән китапны тәрҗемә итәргә алынмаслар. Чөнки алар үзләренә бик таләпчән киләләр. Һәркайсының үзенең яраткан авторлары, дөнья бәясенә тиңләгән язучылары, әле аларның да ничә кат укып та ялыктырмый торган китаплары бар. Әйтик, берәвесе үткен сюжетлы әсәрләрне яратып укый, андый кеше мәшһүр француз язучысы А. Дюманың «Өч мушкетер» романын тәрҗемә итәргә керешә; икенчесе психологик сюжетка, геройларның гыйбрәтле язмышына гашыйк була да Ф. М. Достоевскийның романнарына тотына; өченчесе авторның гуманистлыгына һәм тел культурасына, җөмләләренең нык эшләнгән булуына соклана да А. Н. Толстойның «Михнәтле заман» трилогиясенә тәвәккәлләп алына. Ә инде үзе мөкиббән киткән язучының арада бер күренекле әсәрен укучы кулына китереп тапшырырга хыялланган иҗат кешесе бу тәрҗемәгә бөтен көчен салачак, үзенә зур таләп куячак, авторның стиль үзенчәлекләрен дә, тел байлыгын да мөмкин кадәр тулырак сакларга тырышачак. Әнә шундый олы максат куеп эшләү нәтиҗәсендә безнең укучыларыбыз зур әдәби дәреслеккә ия булырдай, эмоциональ яктан нык тәэсир итәрдәй әсәрләрне ана телебездә уку бәхетенә ирештеләр.

Татар телендә сингармонизм законнары яши. Әгәр дә без олы әдипләребез Г. Баширов, Ф. Хөсни, Ә. Еники әсәрләрен аерыла алмыйча укыйбыз икән, бу аларның тел өстендә ныклап эшләүләреннән, сүзләрнең генә түгел, җөмләләрнең дә үзара гармонияле булуына игътибар итүләреннән, яңгыраштa музыкальлеккә омтылуларыннан да килә. Тәрҗемәчеләребез текст өстендә эшләргә әнә шул әдипләребездән өйрәнәләр.

Бүгенге тәрҗемәчеләрдән иң әүвәл Рәис Даутов исемен әйтү гадел булыр. Аның ничаклы әзерлекле вә мәгълүматлы булуы, әдәбиятны сиземләве һәм яратуы, тәрҗе-

мә өлкәсендә нинди зур тәҗрибә туплаганлыгы А. И. Куприн әсәрләрен эшләгәндә аеруча нык чагылды. Яраткан язучысының ул бөтен иҗатын өйрәнеп чыкты, күңеленә иң ошаганнарын тәрҗемә итеп, «Повестьлар һәм хикәяләр» дигән күләмле генә китабын чыгарды. Әмма үзе башкарып чыккан хезмәтеннән канәгать булып җитмәде: «Менә аның «Атышу»ын да эшләсәң икән!» — дип хыялланды. Бу повестьны тәрҗемә иткәндә ул авторның рәвешле тасвирлавына тагын да ныграк игътибар итте һәм укучыларыбызга гүзәл бер китап бирә алды. Шуннан соң ул Ф. М. Достоевскийның «Җинаять һәм җәза» исемле романын эшләде. Бу дәвердә аның үз алдына иң изге максатны куюы игътибарга лаек: тәрҗемә китабы әллә каян: «Мин тәрҗемә! Мин тәрҗемә!» дип кычкырып тормасын, ә оригиналь әсәр шикелле укылсын.

Р. Даутовның чит ил әдәбиятын эшләүдә дә тәҗрибәсе зур. Иң яңа хезмәте — О'Генриның «Новеллалар»ы. АКШтагы тормышның күп якларын күрсәткән бу җыентыктан фәкать бер генә әйбергә — «Төрле мәктәп җимешләре»нә генә тукталыйк. Бу новелланың тәрҗемәсендә Р. Даутов гаҗәеп иркен эш итә. Юк, ул үзенең күңеленә ошап җитмәгән кисәкләрне төшереп калдырып, алар урынына яңа абзацлар өстәми. Һич юк. Безнең тәрҗемәчеләр, гомумән, андый «төзәтү» белән мавыкмыйлар. Даутов гүя үзен О'Генри геройлары арасында хис итә; күзе белән күргән, колагы белән ишеткән вакыйгаларны тасвирлагандай, абзац эчендәге җөмләләрнең сүзләрен, урыннарын алыштырып бетерә, автор сурәтләгән картинаны өр-яңадан, нәкъ татар теле законнарына буйсындырып, саф татарча язып чыга. Шуның нәтиҗәсендә авторның стиль үзенчәлекләрен дә гаять оста чагылдыра.

Татарстан китап нәшрияты хәзерге рус совет язучысы Ю. Бондаревның әле быел гына басып чыгарган «Кайнар кар» исемле романы укучыда зур кызыксыну уятты. Башкача булуы да мөмкин түгел: Бөек Ватан сугышының язмышын хәл иткән Сталинград янындагы бәрелешләрне күрсәтүгә багышланган романнар ел саен чыгып тормый. Безнең телдә шундый китапның дөнья күрүе үзе сөенеч. Вакыйгаларны тасвирлауда, геройларның эчке кичерешләрен сурәтләгәндә тәрҗемәче Яхъя Халитов зур осталык күрсәткән. Аның тел байлыгы да мактауга лаек. Я. Халитов тәрҗемәчеләребез арасында авторның теленә, сурәтләү чараларына, стиль үзенчәлегенә иң нык тугрылык сакларга омтылучы художник. Вакыйгаларны тасвирлаган чагында ул ничек тә оригиналдан читләшмәскә тырыша. Күпчелек урында Я. Халитов русча җөмлә конструкциясен саклый, сүзләрне дә турыдан-туры күчереп кую белән чикләнә; чамасыз эре, ятышсыз җөмләләрне безнең тел таләпләренә туры китереп бүлмәгән кебек, ваграк җөмләләрне дә логик яктан бердәм итеп җыймый. Тексттагы мәгънәне аңлатучы сүзне үз телебездә тапмаса, шуңа якын, ә кайчагында ныграк туры килердәй сүзне эзләп маташмый, тота да калька ясый. Ә бу инде безнең телдә чыккан китаптан гайре табигый яңгыраш ала, ара-тирә мәгънәгә дә хилафлык китерә. Бер телдә йөзәр ел буе эшкәртелеп камилләшкән идиоматик әйләнмәләрнең аерым сүзләрен генә икенче телгә күчереп утырту дә тиешле нәтиҗәне бирми. Андый чакта үз телебездә шуңа якын килердәй адекват эзләп табу мәгъкуль. Я. Халитовка, М. Шолохов, В. Каверин, В. Лацис һ. б. бик күп авторларның романнарын тәрҗемә итеп зур тәҗрибә туплаган остага, киләчәктә һәр яңа китабы хакында, укучылар ничек кабул итәр икән, аңлашылырмы икән, дип уйланырга кирәк булырдыр.

Тәрҗемә китабының кыйммәтен-җисемен гадәттә исеме үк сиздереп торучан. «Горячий снег» дигәнне «Кайнар кар» дип тәрҗемә итәләр икән, И. А. Гончаровның «Обыкновенная история» дигән романын бик ансат кына «Гади тарих» дип алырга ярыйдыр сыман. Әмма Фәния Гайнанова калька ясау юлына басмый, ныклап уйлана һәм «Гыйбрәтле язмыш» дигән вариантка тукталa. Һәм бу исем яңгыраш ягыннан да матур, шулай ук әсәрнең эчтәлегенә дә таңгал килә. Шунысы кызык, рус дворяннарының тормышын гәүдәләндергән, шул замандагы атмосфераны вагына-төягенә кадәр тәфсилләп биргән китап бүгенге татар укучысына яхшы аңлашыла. Чөнки тәрҗемәче үз эшенә иҗади килә. Сүзләрне берәмтекләп барлап кына, синонимнарның кирәклесен сайлап кына энҗе урынына тезә, гаҗәеп зур түземлек һәм тырышлык күрсәтеп аерым вакыйгаларны, картиналарны тасвирлаучы җөмләләр арасында да гармония, аларның табигый яңгыравын китереп чыгара. Персонажларның кичерешләрен сурәтләгәндә автор оста кулланган образлы үткен сүзләрнең кыйммәтенә тиң килердәй тәгъбирләрне дә әллә кайлардан актарып эзләп таба, шуның белән әсәрнең эстетик тәэс-

сорат көчен тулысынча саклый ала. Миңа калса, авторның стиленә, әдәби әсәрнең тел байлыгына тугрылыкны һәрчак әнә шул юл белән яулап алырга кирәк.

Уннарча ел дәверендә башкарган хезмәтләренә күз салганда, һәр яңа китапны элеккеләреннән әйбәтрәк итәргә омтылып, тәрҗемәчеләребезнең иҗат кешеләре булараk үсүен, колачлары киңәя төшүен, каләмнәре шомара баруын, яңадан-яңа үрләр яулап алуларын күреп сокланасың, хәйран каласың. Таһир Нурмөхәммәтов иҗаты моңа дәлил була ала. Кайчандыр ул фәкать үзе тәрҗемә итә торган китап белән чикләнә, язучының башка әсәрләрен укып азапланмый, юл арасына язылганнарны күрми, һәм аның тәрҗемәләре бик сай була торган иде. Әнә шул фәкыйрьлектән качу юлын ул башта матур бизәкләрдә күрде һәм кирәксә-кирәкмәсә дә куршырак сүзләрне кыстырып җибәргәли иде. Әмма вакыт үзенекен итте: ул иптәшләренең сүзенә дә колак сала башлады, алар башкарып чыккан эшләрне дә караштыргалады һәм хикмәтнең бизәктә түгел икәнлегенә төшенде. Шуннан инде бөтен көчен авторның стиль үзенчәлекләрен саклауга, оригиналны мөмкин кадәр тулы көе күчереп куюга бирә башлады.

Зур талант иясе В. Астафьевның «Бәхилләшү» дигән китабына ул зур дәрт белән тотынды. Вакыйгаларны татарча язып чыгу белән генә канәгатьләнә алмыйча, яраткан язучысының бөтен иҗаты белән кызыксынып, аның язуына хас алымнарны әйбәтләп өйрәнде. Зур түземлелек белән бер әсәрен эшләп чыккач, икенчесенә кереште. «Талау»дагы кыз һәм малайларның язмышы гаҗәеп авыр, атасыз-анасыз калганнар, еллар буе урам «тәрбиясе» алганнар, хәзер инде яңа тормышка аяк басып киләләр. Һәм аларның үзара мөнәсәбәтләрен язганда автор нәкъ әнә шул малайлар-кызлар күзлегеннән карап, шуларның лексиконын мул кулланып яза. Бар син тиз генә аңлап кара аның телен! Аңлаганнан соң икенче тел чаралары белән шуларны сөйләп кара. Һәм Т. Нурмөхәммәтовка ныклап уйланырга, эзләнергә туры килә. Тырыш хезмәте нәтиҗәсендә ул оригиналның аһәңен — яңгырашын, үзенчәлекле колоритын түкми-чәчми безнең укучыга китереп җиткерә. Фәкать азакка таба гына дилбегәне бераз «бушата»— пафосы йомшый төшә. Т. Нурмөхәммәтов яраткан авторының «Патша балык» дигән өченче китабын ахырына чаклы нык көч куеп эшләр дип ышанасы килә.

Саимә Ибраһимованың тәрҗемәләренә теоретик дәрес фикерләү һәм авторның стиль үзенчәлекләрен саклау хас дип әйтәсем килә. Ике телне дә әйбәт белгәнлектән ул әүвәл татар язучыларының (А. Алиш һәм Д. Аппаковаларның) әсәрләрен русчага тәрҗемә итүдән башлап җибәрде. Тора-бара татарчага тәрҗемә итү белән мавыгып китте. Иң соңгы хезмәте — А. П. Чеховның хикәяләре. Борынгы рус тормышыннан алынган тирән психологик вакыйгалар татар укучысы да булган хәл дип кабул итәрлек эшләнгән. Шул заманга хас синонимнар да табылган. Ә инде «Казак» һәм «Тегермәндә» исемле хикәяләр табигый яңгырашлары белән аеруча мактауга лаек. А. П. Чехов хикәяләренең моңарчы бу дәрәҗәдә камил тәрҗемә ителгәне юк иде шикелле. Ә бит аның тагын да күләмлерәк китабын әле әйткән хикәяләр шикелле әйбәт эшләп чыгарганда, бер дә начар булмас иде.

Соңгы елларда тәрҗемәчеләребез арасында яңа исем — әдәби тәнкыйть өлкәсендә каләмен шактый шомарткан Фәрваз Миңнуллин күренә башлады. Аның әдәби зәвыгы хакында фикер йөртү өчен нинди китаплар сайлавын әйтеп үтү дә җитә торгандыр. Г. Уэллсның «Күренмәс кеше» һәм Джек Лондонның «Мартин Иден» исемле романнары. Беренче хезмәтендә үк тәрҗемәче үзенең сәләтен күрсәтергә өлгерде. Образлы фикер йөртүе, җөмләләрне бик рәхәтләнеп үз ана телебездә оештыруы, мәкаль һәм әйтемнәргә халыкта йөргән адекватлар таба белүе һәммәбезне сөендерде. Бербер артлы ике китап эшләве Ф. Миңнуллинның тәрҗемәчеләр сафына очраклы рәвештә килеп кермәвен исбатлый.

СССРның халык артисты, соңгы көненәчә сәхнәне ташламаган Габдулла ага Шамуков хәйран оста мәсәлче, шагыйрь һәм тәрҗемәче дә иде. Шекспирга ихлас гашыйк икәнлеген ул берәүдән дә яшерми, киресенчә, бөек драматург персонажларының күп кенә монологларын үз тәрҗемәсендә, гаҗәеп кыяфәтләргә кереп, яттан сөйли, төшенеп җитмәгәннәргә Шекспир сүзләренең мәгънә тирәнлеген төшендереп бирә иде. Габдулла ага классикны телдән генә сөйләп калмады, бәлки әле тәрҗемә итеп тә дөньяга чыгарды. В. Шекспир һәм П. Бомаршеның «Комедияләр» исемле китабы әнә шундый фидакарь хезмәт җимеше. Авторларга мөкиббән китү, сәхнә кануннарын биш

бармагы кебек белү,[т] тезмә юлларның кыйммәтен аңлау-болар барысы да уңыш юлар өчен зарур сыйфатлар. Бу комедияләрне ничектер сәхнәдән күрергә туры килмәгән иде, әмма китапта алар шундый табигый, шундый татарча булып җиткән, бик рәхәтләнеп укып чыктым, ләззәт алдым.

Соңгы вакытта безнең әдәбиятта күренекле шәхесләр тормышына багышланган китаплар дөнья күрә башлады. Җәмәгатьчелекнең бу жанрга ничек караганы һәркайсыбызга мәгълүм: «Хөсәен Ямашев» өчен А. Расих, «Габдулла Тукай» өчен И. Нуруллин Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләренә лаек булдылар. Коләхметовлар гаиләсен әйбәт белгән Гайшә ханым Шәрипова рус телендә язган «Семья Гафура» китабы да шул ук жанрга карый. Татарчага аны бер дә ашыкмыйча гына Миргалим Харисов эшләде. М. Харисов тәрҗемә белән күптән кызыксына. һәм бу хезмәтендә ул оригиналга бик тә игътибарлы килә, авторның сурәтләү чараларына хөрмәт белән карый, безнең телдә аларны алыштырырдай сүзләр эзли. Шуның нәтиҗәсендә XX гасыр башында яшәгән һәм хөррият өчен көрәшкән татар интеллигенциясен аермачык күзалларга мөмкинлек туа. Шундый уңыштан соң М. Харисов тәрҗемә эшенә җиң сызганып тотыныр дип ышанасы килә.

Янә дә бер әдәби тәрҗемә остасы — Вакыйф Зыятдинов хакында бер сүз дә әйтмичә китү килешеп бетмәс. Ул Вьетнам язучыларының хикәяләрен, М. Максимовның «Камо» дигән повестен, Н. Островскийның «Давылда туганнар» һәм Г. Тушканның «Жура» исемле романнарын тәрҗемә иткәннән соң, тәҗрибә туплаганнан соң, И. С. Тургеневның лирик повестьларын һәм «Аучы язмалары»н безнең телдә дә, оригиналдагы шикелле үк, поэзиягә тиңләрлек. В. Зыятдинов та яраткан язучысының иҗатын ныклап өйрәнүне дәвам иттерә һәм иң әйбәт романын тәрҗемә итәргә әзерләнә.

Тугандаш халыкларның әдәбиятын тәрҗемә итүдә Лирон Хәмидуллин актив эшләп килә. Төрки телләрне әйбәт белгәнлектән, яңа чыккан китапларны укып бара һәм үзе яхшы дип тапканнарын укучыларыбызга тәкъдим итә.

Поэзияне тәрҗемә итүдә күренекле шагыйрьләребез Әхмәт Исхак һәм Нури Арслан зур эшчәнлек күрсәттеләр. Әдәбиятның традицияләрен үзләштергән, гарәп һәм фарсы телләрен белгән, тынгысыз аксакалларыбыз бер дә кеше кушканны көтеп ятмадылар, күңелләренә хуш килердәй шәрык шагыйрьләрен еллар буе акрынлап тәрҗемә итә килделәр. Ниятләре бик изге: элек-электән китап яратучы татар укучысына поэзия җәүһәрләрен китереп тапшыру, сөендерү. Ашык-пошык эшләмәгәч, алар шәрык поэзиясенең аһәңен тулы көенчә саклауга ирешәләр.

Калмык шагыйре Д. Кугелтинов китабын Гәрәй Рәхим бик тә рухланып тәрҗемә итте. Бу шигырьләрне укыганда авторның олы җанлы шәхес икәнлеген сизәсең. Ә инде татар шагыйренең үлемсезлегенә, бөеклегенә дан җырлаган «Моабит тоткыны» поэмасын укыганда моңа тагын да ныграк ышанасың.

Татарстан китап нәшрияты кул яссуы кадәр генә форматта сувенир итеп чыгарган «Без яшибез Совет илендә» дигән җыентык яшь шагыйрьләрнең нинди матур шигъри тәрҗемәләр бирүгә сәләтле икәнлеген исбатлый.

Гомумән, тәрҗемәгә яшьләр аз килә. Мөгаен, берәүнең дә ина белән кое казыйсы килмидер, фидакарьлек җитенкерәмидер. Югыйсә, бүген бу һөнәргә өйрәтерлек осталарыбыз да бар инде. Ә бит эшлик дисәләр, эшли алалар яшьләр! Әйтик, Г. Мулаева — Д. Гранинның һәм В. Богомоловның повестьларын матур гына тәрҗемә итте; Н. Вәлитова — В. Распутинның «Онытма гомергә» дигән китабын уңышлы гына тәрҗемә итеп чыгарды; Ф. Зыятдинова К. Паустовскийның хикәяләрен әйбәт кенә эшләде; Бөек Ватан сугышында немец фашистларын җиңүгә 40 ел тулу уңае белән эшләнгән «Рәхмәт сиңа, солдат!» дип исемләнгән җыентыкны хәзерләгәндә Н. Вәлиуллина, Л. Нәҗмиева, З. Миңнуллина һ. б. үзләрен эшкә сәләтле итеп күрсәттеләр.

Киләчәктә безнең сафка СССР халыклары әдәбиятларының үрнәкләрен дә, чит ил әдәбиятының гүзәл өлгеләрен дә турыдан-туры оригиналдан тәрҗемә итәрдәй өметле һәм сәләтле яшьләр килер, дип ышаныйк!

Нонна Орешина

# МАКСАТЛАР УРТАК

Язучы кулына сүз дигән куәтле корал бирелгән. Шул коралга ия булу язучыны кешеләр алдында гаять җаваплы итә. Әйе, ул әйткән сүзләре өчен генә түгел, әйтә алып та, төрле сәбәпләр аркасында әйтми калган, әйтеп җиткермәгән сүзләре өчен дә бурычлы.

Ике съезд арасындагы биш ел Диас Вәлиев өчен аеруча нәтиҗәле булды. Әдәбиятта үз-үзен раслау җиңел бирелмәде аңа. Әмма тапканы — төпле, ышанычлы. Эзләнү, кызыксыну офыклары, кузгаткан проблемалар диапазоны киң. Һәм шулар нәтиҗәсе — драма әсәрләреннән торган ике җыентык. Аларның бер өлеше илебезнең күп театрларында куелды. Тәнкыйть тә, тамашачы да Д. Вәлиев драмаларын җылы каршылады, һәм мин моны бик хаклы дияр идем: сәхнә дөньясының үзгәлеге, конфликт киеренкелеге, көчле кичерешләр, куелган проблемаларның актуальлеге — болар бөтенесе безне яшәү мәгънәсе, тормыштагы урыныбыз турында уйланырга мәҗбүр итә.

Менә хәзер безнең алда — прозаик Вәлиев. Аның «Мәңгелек түгәрәк» дип исемләнгән повестьлар һәм хикәяләр җыентыгы — кешеләрне психологик яктан анализларга омтылыш ясау. Очрашу-кавышулар, әйтеп бетерми сөйләшүләр, яшерен хисләрнең ымсындыргыч дөньясы — сүз аһәңенә ләззәтләнеп укыганда мавыктыра бу. Әмма китапны ябып, бераз тын торганнан соң, хыялый дөньядан, төштән арынгандай сискәнеп куясың, әнә генә бит ул тормыш — шау-шу, төрле авазлар, хәрәкәт тулы дөньяга тәрәзәңне генә ачып җибәр... Диас Вәлиевнең байтак драмаларында уңышлы сәхнә алымы дип табылган, символ-персонажларга, хисләрнең гадәттән тыш киеренкелегенә, күпертелгән тойгыларга урын калдыручы шартлылык — тирәнтен уйлаучы, максатчан, тормыш күренешләрен үзенчәлекле һәм шул ук вакытта табигый анализларга сәләтле прозаик Диас Вәлиев әйтә алган һәм әйтергә тиеш булган зур, чын сүзне күләгәли.

Соңгы вакытта мин анык бер максат куймыйча һәм статистик мәгълүматлар тупламыйча гына, яшьләрнең нәрсә укуын күзәтәм. Минем күзәтүемчә, китап укучылар өч категориягә бүленә: берәүләр тарихи һәм документаль жанрны, ягъни мәгълүмат бирүче әсәрләрне өстен күрә; бүтәннәрне маҗаралы һәм детектив әдәбият мавыктыра. Психологик анализ һәм тормышны аңлап төшенү өстенлек иткән әсәрләрне яратучылар аз. Калганнары исә мондый төр әдәбиятка сагаеп карыйлар. Нигә? Җаваплар менә болайрак: «Чын-чыннан акыллы әсәрләр аз, хисләр белән уйнау, сөю-гыйшык вариантлары, чынга ашмаган бәхет кыйссалары туйдырды инде. Классикларны кабат алып укуың мең артык». Ә яшьләр тагын да өзебрәк әйтә: «Китаплардан яшәргә өйрәнәсе һәм аз гына булса да геройга охшарга тырышасыбыз килә».

Үзебезнең балачакны һәм сугыштан соңгы яшьлегебезне хәтерләтмиме бу сүзләр? Ул чагында «Чын кеше» повесте малайларны очучылар училищесына китерде, Павка Корчагин да әле безнең арада яши кебек иде, ә яшь гвардиячеләрне чордашларыбыз, яшьтәшләребез кебек якын күрдек. Батырлыклар, чын кешеләр турында йотлыгып укыганда скрипка кылыдай сизгер күңелләребездә нәрсәдер зыңлап куя иде, без батырлык эшләү турында хыяллана һәм шуңа әзер икәнлегебезне тоеп яши идек. Аннары әдәбиятка яңа агым килеп керде. Бу китапларның күбесендә сүлпән, гадәти, төссез әдәби геройлар яши иде, алардан бернинди рух-илһам бирерлек көч бөркеп тормый, шуңа күрә үзләрен әдәби герой дип тә түгел, персонаж дип кенә атыйсы килә иде. Бу этап та кирәк булгандыр: язучылар, гүя, реаль тормышка текәлебрәк карарга, персонажларны күрәләтә уңай һәм хәттин ашкан тискәре персонажларга бүлүдән арынырга өйрәнәләр кебек иде. Тәнкыйть, әдәби сүзнең кырыслыгын һәм нәфисләнген, фактларның психологик чынбарлыкка туры килүен таләп итеп, әдәбиятта икейөзлелеккә каршы көрәште.

Ләкин сәер бер күренеш күзәтелә: гаделсезлек һәм явызлык тамырына көнку-

рәш ситуацияләре аша төшеп, укучы күңелендә караңгыдан яктыга чыгу теләге уятып, ягъни тискәре аша уңайга килеп, без баштарак үзебез теләгән нәтиҗәгә ирешәбез — кешедә намуслы, әмма көчсез, физик һәм мораль яктан таянычсыз, кай яклары беләндер, үзенә охшамаган затларга карата теләктәшлек уяна. Соңрак укучы ирония белән нәтиҗәләр ясый: эгоистлар, ялагайлар көчлерәк, ә тискәре геройлар еш кына уңай геройлардан чынрак килеп чыга һәм алар ансатрак яши. Кемгәдер бу җитә кала. Китаптан ул үзенчә сабак ала: көрәшеп тору файдасыз, яманлыкка җайлашу отышлырак. Икенче берәү сыгылып төшә, бирелә. Бөек максатлар куеп яшәү, романтика, фидакарьлек, идеяләргә тугрылык — кешеләрне массовый геройлыкка илткән характер сыйфатлары — хәтта кайчак алар өчен искергән булып та күренергә мөмкин.

Ләкин бит бу төшенчәләр барыбер яшь һәм билгеле бер образны, мәгънәне гәүдәләндерә, аларның чын кыйммәте юкка чыга алмый. Эгоистик максатлар һәм омтылышлар белән агуланмаган яшь йөрәкләр олы җанлы, көчле шәхесләрне тансыклый. Мондый герой әдәбиятка тормыштан гына килә ала.

Бу җәһәттән мин Тихон Журавлевның «Юлда һәм өйдә», «Авыл повестьлары» җыентыкларына түгел — болары икенче басмалар — ә бәлки бераз элгәрәк дөнья күргән әсәренә тукталыр идем. «Шәфкать туташы»— якташыбыз, чын героиня Фаина Чанышева турындагы документаль повесть әнә шулай дип атала.

Авторның җанлы сөйләме, героиня белән танышуны тасвирлавы, әңгәмәләр, фронт истәлекләре — болардан шундый бай тормыш материалы чамалана ки, аптырыйсың: үзе фронтовик язучы, сугыш шартларын биш бармагы кебек яхшы белүче Тихон Кононович, җилкенеп китеп, нигә роман язып ташламады икән? Бәлки бу һәр язучы хыялланa торган «иң-иң» китап булыр иде.

Сугыш чынлыгы... Геннадий Паушкинның «Кар ява да ява», «Миннән хәбәр көт» дип исемләнгән җыентыкларга кергән повестьлары һәм хикәяләрендә ул, фронтовик язучылар прозасына хас булганча, нечкә һәм тотнаклы, солдат Паушкинга хас булганча югары сәнгатьчә бирелгән. Сугышның беренче көннәре, үлем белән, каһарманлык белән, рухи күтәрелеш һәм түбәнлек белән беренче мәртәбә йөзгә-йөз очрашу. Еллар саны белән түгел, баштан кичергәннәр исәбенә олыгаю, уңышлар белән уңышсызлыклар чиратлашу, йөзләрчә чакрымнарны сугышып үтеп, җиңү сәнгатенә өйрәнү.



*Композитор Сара ханым Садыйкова һәм аксакал язучы Гомәр ага Бәширов.*

Дмитрий Сычовның «Болытлар өстендә күкрәү» дигән кечкенә күләмле китабы да сугыш темасына багышланган. Авиация полкының техниклары һәм механиклары, аларның беренче карашка гадәти күренгән, әмма шуннан башка бер генә самолет та һавага күтәрелә алмый торган хезмәте. Сугыш — ялыктыргыч хезмәт, батырлык — гадәти күренеш. Бу — сугышның яңа бер ягын ачу. Әмма асылда батырлык булган нәрсәләрне үтә гадиләштерүдә әсәрнең үзен дә, аның тәрбияви әһәмиятен дә киметкән, ярлыландыра торган нидер бар.

Михаил Скороходовның «Быргылар җыры» исемле документаль хикәяләр җыентыгы — республикабыз пионерлары кылган эшләр турында. Балаларның иҗтимагый-политик эшләренә кагылышлы бүлекләрне укыганда бу теманың бүген никадәр актуаль булуын һәм ничек аз яктыртылуын аңлыйсың. Күптән түгел менә ВЛКСМ Үзәк Комитетының һәм Хәрби һава Көчләре

Баш штабы политидарәсенең яшьләргә хәрби-патриотик тәрбия бирүнә камилләштерү эшенең перспектив планнары белән таныштырдылар. Бу планнарда Хәрби һава Көчләре ветераннарын пионерлар һәм комсомоллар арасында актив эшләүгә тарту, мәктәп укучыларының сугыш ветераннарына шефлыгын оештыру кебек дистәләгән чара каралган. Мәктәпләр белән хәрби частьлар аралашып яши. «Кызыл эзтабарлар» отрядлары күп еллар дәвамында Бөек Ватан һәм Гражданнар сугышы булган урыннарда эзләнүләр алып баралар. Тимурчылар хәрәкәте җирлегендә шытып чыккан шушы матур башлангычта бурычлары һәм мөмкинлекләре тагын да зуррак, киңрәк булган илкүләм хәрәкәт төсмерләнә. Ләкин шушы күркәм эш балаларның хыялын һәм инициативасын корыта торган формаль чарага әверелә күрмәсен иде. Ул эш балаларда сабый чактан ук социаль актив шәхес формалаштыруга ярдәм итә торган идея-тәрбияви җирлектә, зур педагогик осталык белән алып барылсын иде. Бу хәрәкәт үз Гайдарын көтә.

Хыялланырга өйрәтеп буламы? Өйрәтеп булмаса да, хыял җене кагылдырып буладыр... Мин ике тапкыр Советлар Союзы Герое очучы-космонавт В. А. Шаталовның яшьләргә атап әйткән сүзләрен исемә төшерәм: «Кеше тормышта хыялга тотынып яши. Ул максатка ирешү өчен көч, түземлек бирә. Хыялның гарантиясе — хезмәт». Яңа фикер түгел бу, шулай да хыял һәм хезмәт төшенчәләренең икесенә бергә нәрсә салынганын анykларга тырышыйк. Бәхет турында ниндидер билгесез нәрсә кебек итеп сөйләү гадәткә кергән. Ә бит ул үзе шундый конкрет — ул хезмәт итү белән, эш белән бик тыгыз бәйләнгән. Эш синең җилкәңә камыт булып ятармы, әллә канат булып кунакламмы? Күңелнең балачак хыялыннан башка тагын хезмәт итү ихтыяҗы да бар әле. Эчәсе, ашыйсы килү, сулыш алу кебек табигый һәм зарури ихтыяҗ бу. Ата-аналар балаларын тук, физик яктан сәламәт, шат күңелле, интеллектуаль шәхес итеп тәрбияләү турында кайгыртып та, эшләү ихтыяҗы тәрбияләргә онытала икән, моңа без, язучылар да гаепле.

Иван Киндерның «Дала аҗаганнары» һәм «Озын җәй» исемле хикәя җыентыклары — яшүсмерләр өчен. Яхшы күңелле авыл малайлары, аларның уеннары, көенеч-сөенечләре һәм кайтаваз кебек кенә сугыш заманы сугыштан соңгы мәхрүмлекләр, кыенлыклар. Ә бит язучы тормышның, балалар олы проблемаларны хәл итәргә мәҗбүр булган, аларның ярдәме гомум крестьян хезмәтенә кушылган чорын тасвирлый. Кайбер хикәяләрне укыганда ирексездән уйлап куясың: авторның үз тормышы, бернинди авырулар да сындыра алмаган рухы, оптимизмы, эш сөючәнлеге белән чагыштырганда, алар нинди примитив. Ихтыяр көче, нык характер — табигать бүләге түгел, бу сыйфатлар бала вакыттан тәрбияләнә. Шулай икән, ни өчен соң хезмәт сөючән язучы үзе балаларда хезмәткә омтылыш тәрбияләргә кирәклекне тоймаган?

Марсель Зариповның «Түбән Каманың бәхетле сәгате» исемле документаль китабы һәм «Биеклекләр» дигән очерклар җыентыгы — уйлану өчен бай материал. Зарипов көнләшерлек бер үҗәтлек белән һәр нәрсәнең төбенә төшеп, мавыгып яза.

Зариповның эшлекле, дәртле язу алымын тоеп, очерктагы юллар аша чалымланган нәрсәләрне күңеленә өсти барып, ирексездән, уфтанып куясың: кешеләрне, проблемаларны, материалны шундый тирән белү ни өчен соң берәр романга нигез була алмаган? Хәзер әдәбиятта эшче, җитәкче, инженер образы — заман мәнфәгатьләре белән яшәүче көчле ихтыярлы кеше образы бик кирәк бит. Бу образ, М. Зариповның иң әйбәт очеркының герое Андрей Тригуб кебек, катлаулы характер иясе булырга тиеш.

Рөстәм Кутуй үз укучыларына өч поэтик җыентык — «Җир яфрагы», «Көзге иркенлек» һәм «Тамырлар» тәкъдим итте. Катлаулы һәм гүзәл шигърият дөньясы, акыл белән хис үрелеше, үзеңдәге дөнья һәм дөньядагы «мин»ең, үз-үзеңне күзәтү... Ә мин Р. Кутуйның беренче хикәяләрен, моннан егерме ел элек аны әдәбиятка алып килгән хикәяләрне һәм аның сугыштан соңгы чорга туры килгән бала чагына срынудан алган тәэсирләрне хәтерлим. Нинди ихлас, самими һәм шул ук вакытта саф ул хикәяләр... Быел «Детская литература» нәшриятында Рөстәм Кутуйның яңа хикәяләр җыентыгы — «Нарат гөмбәләре» басылып чыкты. Автор үзе «Балачак иле» дип атаган теманың дәвамы булган бу хикәяләрдә моңлану, хисләр уяна башлау, акыл керү — барысы да бик сизгер, психологик яктан бик төгәл, урыны белән яшертенрәк, кайвакыт хәтта ясалма да сыман. Образлы, төсләргә бай тел, урыны

белән юри дә уратып-уратып язу стиле. Кутуй прозасы аның поэзиясенә аваздаш һәм нәкъ шулай ук авторның яшерен дөньясына алып китә, сүз шагыйрьнең күңел тирбәнешләренә, хисләренә карусыз буйсына.

Җыентыгына сүз башы урынына язган уйлануларында Кутуй болай ди: «Минем үземә һаман бер китапны язам, зурайтам кебек тоела. Ул, мөгаен, тиз генә тәгәлләнмәстер әле. Һәрхәлдә, әгәр мин бер озын еллар китабын язып бетерә алсам, гомерем бушка узмады дип санармын». Бер озын еллар китабы... Ә соң бу, адашкан юлаучы кебек, үз эзеңә кабат баскаңны абайламыйча, йомык сызык буйлап йөрүгә китермәсме? Ләкин талантлы кешедән күбрәкне көтәсең! Рөстәм Кутуйның «...иҗат — хатирәләр ул» дигән сүзләре белән килешергә ярыймы икән? Иҗат ул — иң элек, алдан күрүчәнлек, киләчәкне сиземләү дияр идем. «Иҗат итү» фигыле үзе үк бит яңаны тәэүне, тудыруны аңлата, хәтта үткәнгә, хатирәләргә дә киләчәк хакына, аларны ныграк аңлау өчен әйләнеп кайталар.

Кутуйның М. Зарипов китабына, И. Кәлимуллинның шигырьләр җыентыгына, Л. Топчийның сайланма шигырьләр җыентыгына язган сүз башларын укыгач, аның үзен дә яңа баштан ачкандай буласың — иҗат портретлары шундый төгәл, калку, яратып һәм шул ук вакытта таләпчән язылган; үзе яхшы белгән һәм якын күргән кешеләргә ничек сак һәм сизгер ул. Бәлки бу — яңа Кутуйның тууы, аның балачак дөньясыннан аерылуыдыр?

Илгиз Кәлимуллинның «Таңнар минем аша үтә» һәм «Туар көнгә ышанам» шигырь җыентыклары — ихтыяр ныклыгы белән үз язмышын иҗат иткән, Р. Кутуй сүзләре белән әйткәндә, «үзенең кешелек дөньясына кирәклеген тоя алган» кешенең күңел көндәлеге.

Николай Беляевның яңа шигырьләр җыентыклары —«Хәтер» һәм «Казан дәфтәре»— үзенчәлекле әхлакый эзләнүләр белән аерылып тора. Чын хисләр һәрвакыт аңлаешлы; оригиналь булырга тырышмау, матурлыкны үзмаксат итмәү исә — чын осталык билгесе.

Шагыйрьләр Вячеслав Бәширов —«Вакыт һәм көн уртасы», Николай Алешков — «Мине бәхетле дип хәтерлә», Владимир Лавришко —«Элемтә узелы» исемле беренче китапларын укучылар игътибарына тәкъдим иттеләр. Туасы ел да яшьләр өчен «уңдырышлы» булыр ахры. Сергей Малышевның «Хәтердәге яфраклар» җыентыгы — беренче өмет карлыгачы.

Рус әдәбияты һәм тәрҗемә секциясе исеменнән, Татарстан китап нәшриятына яшь талантларга игътибарлы булган өчен рәхмәт әйтәсе һәм башлап язучы шагыйрьләргә прозаикларга киләчәктә дә нәшрият планнарында, алар инде тәмам өлгереп җиткәч кенә түгел, ә иҗат йөзләре формалашкан чакта ук урын бирелер диген өмет белдерәсе килә. Ләкин ашыгу да хәтәр. Шунысы куанычлы: Вячеслав Бәшировның инде хәзер үк үзенчәлекле үз стиле сизелеп тора, ул образның чынлыгын, төгәллеген ярата. Николай Алешков эзләнә әле. Шәһәр, зур төзелешләрколачы, динамикасы, проблемалар күпләге бик кызыктырса да, авыл малае, җир улы Алешковка баш-аягы белән анда чуму кыенрак. КамАЗга соклану һәм авылда узган балачакның кадерле мизгелләре — Алешковның күңеле ике арада бәргәләнә. Шушы хисләр тартышы — аның шигъри үзенчәлеге. Әмма шагыйрь авыл урамнарының патриархаль тынлыгы бетәр бер көннән арырак үрелеп карамаса, авыл пейзажы һәм аграр комплекслар бергә үрелгән яңа авылны кабул итмәсә, бу юл аны тупикка алып керәчәк.

Производство темасына язарга кыюлык иткән берденбер кеше — Владимир Лавришко. Хезмәт мәхәббәт, фаҗигале һәм көлкеле хәлләр, производство проблемалары гаять зур төзелеш ноктасыннан карап тасвирлана. «Элемтә узелы» поэмасында киндидер конкрет шигырь ялгышлары да табылыр, әмма, гомуман алганда, зур төзелешнең эшлекле һәм киеренке пульсы сизелеп тору, язмышы автогигант язмышы белән үрелгән рәссамның мәгълүм бер позициясе, коллективта кеше һәм күмәк хезмәт булу — авторның казанышы.

«Үзеңне гаҗәпләндергән нәрсәне генә укырга кирәк»— И. Гете сүзләре бу. Шушы киңәшне тотсаң, иң беренчеләрдән итеп Владимир Корчагинның «Молодая гвардия» нәшрияты басып чыгарган «Альп эдельвейсы» романын уку кирәктер. Фәнни фантастика жанры (роман исә шушы жанрда язылган) тиран белем, бай хыял фантазия очышын таләп итә. Авторда бу сыйфатларның барысы да бар. Романда кайбер сюжет линияләренең төгәлләнеп бетмәве сизелә, яңа басмасын эзерләгәндә моны исәпкә алырга кирәк.

Геннадий Трошинның балаларга адресланган «Көмеш балык» исемле хикәяләр җыентыгы укучыны гаҗәеп су асты дөньясына алып китә. Кызганычка каршы, мондый китаплар сирәк языла. Ә бит алар балаларда табигать белән кызыксыну уята, аларның аңында актив шәхес сыйфатлары тәрбияли.

«Басуларым, кырларым»— Алексей Королевның бу хикәяләр җыентыгы авыл тормышына, җир-анага, изге икмәккә багышланган. Сөйләм гадилеге аша җир моңы ишетелә, вакыйгалар талгын гына ага, әмма фикернең риясызлыгында — халыкчан зирәклек, тормыш тәҗрибәсе.

«Алар Казанда булганнар» очерклар җыентыгында Мария Елизарова Максим Горький тормышын өйрәнүне дәвам иттерә. Архив материалларын бик әйбәт белүдән гыйбарәт булган циклы фундаментны тоеп тору күңелле. Әмма авторның теленә сурәтлелек һәм сүз белән иркен эш итү җитмәгәнлеге сизелә.

Өч яшь автор — Әхәт Мушинский, Майя Вәлиева Валерий Ногмановларның «Кайту», «Чиктә», «Өермә» повестьларын үз эченә алган «Юл башы» исемле җыентык аерым игътибарга лаек. Бу авторлар берберсеннән тема сайлауда да, образларны ачу, проблема кую, чишелеш табу җәһәтеннән дә бик үзгәләр. Характерларны һәм вакыйгаларны психологик яктан анализларга омтылу, башлап язучы әдип өчен кыю адым — җәмгыять мәнфәгатьләре бе лән шәхси интересларны эхлакый планд бәрелештерү, эгоизмга, рухи мещанлыкк бердәм һөҗүм итү дә берләштерә алар ны. Быел Әхәт Мушинскийның тагын ик‹ повесте басылып чыгарга тиеш.

Әйе, язучы үзенең әдәби-психологик һәм тарихи-философик тикшерену өлкәсен үзе сайлый, яткын җирләрне үз көче үзенә генә хас ысуллар белән күтәрә, үзенең хыял орлыкларын, фикер энҗеләрен чәчеп, урак вакытында я танылу, я тәнкыйть җыйнап ала. Әмма һәркемгә кагыла торган бер мөһим шарт бар. Бу — үз-үзеңә бикләнеп калмау, тормышны, проблемаларны тоя белү, реаль кешеләргә якын тору — әнә шулар гына тормыш һәм вакыт дәрьясында алга таба юл күрсәтә. Юнәлеш билгеләү, каләмеңне яңа темага төбәү өчен шуны онытмаска кирәк: иң биек күтәрелеш тә, хәтта космик очыш та җирдән башланып, җирдә тәгәлләнә. Җир безгә куәт бирә, һәм ни генә булса да җирдән аерылырга ярамый. Мәкалә ахырында А. И. Герцен сүзләренә мөрәҗәгать итәсе килә: «Китап баштан кичергәннәрдән генә тормый — ул документ. Шушы документ белән без бүгенге көнгә, газаплар бәрабәренә табылган, кайвакыт кан һәм тир белән сугарылган барлык хакыйкать һәм тырышлык суммасына хуҗа булабыз; китап — киләчәк программасы».

*Наил Курамшин һәм Фәрит Гобәев фотолары.*

# ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ X СЪЕЗДЫ РЕЗОЛЮЦИЯСЕ

Татарстан язучыларының унынчы съезды илебез халыклары зур күтәренкелек белән бишьеллыкның аеруча җаваплы үрләрен яулаган вакытта, билгеләнгән үтәлеше инде айлар белән генә исәпләнгән чакта үтә.

Республика әдипләренең IX съездыннан соң, илебез тормышында бик мөһим иҗтимагый-политик вакыйгалар булды. КПССның тарихи XXVI съезды узды, Бөек Ватан сугышында җиңүнең 35 һәм Бөек Октябрь социалистик революциясенең 65 еллыгы билгеләп үтелде, СССР төзелүнең һәм Татарстан республикасының 60 еллык юбилейлары булды. Бу тарихи вакыйгалар безнең бөтен тормышыбызга тәэсир иттеләр. КПССның XXVI съезды һәм КПСС ҮКның аннан соңгы пленумнары карарларының, «Идеология һәм политик тәрбия эшен тагын да яхшырту турында»гы, «Әдәби-нәфис журналларның коммунистик төзелеш практикасы белән иҗади бәйләнеше турында»гы карарларның әһәмияте аеруча зур булды.

Республика әдипләренең фикерен чагылдырып, Татарстан язучыларының унынчы съезды партиянең какшамас ленинчыл политик курсын һәм КПСС Үзәк Комитетының нәтиҗәле практик эшчәнлеген тулысынча хуплавын белдерә.

Бүгенге этапта совет әдәбиятының әһәмияте тагын да арта. Республика язучылары үзләрен йөрәкләре кушуы буенча халыкның коммунистик төзелеш эшенә, хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләү эшенә алынган дип саныйлар. Иптәш К. У. Черненко күп мәртәбәләр күрсәтеп үткәнчә, яңа тормыш төзү ул — яңа кеше тәрбияләү турында туктаусыз кайгырту, аның идея һәм әхлак ягыннан үсүенә ирешү. КПСС Үзәк Комитетының июнь (1983) Пленумында да совет кешеләренең культура дәрәҗәсе үскән саен аларга әдәбият-сәнгать әсәрләренең тәэсире көчлерәк була бара дип билгеләп үтелде. Бу таләпләр язучыларның үз эшләренә карата булган җаваплылыкларын тагын да арттыра. Алар үзләре кулындагы куәтле корал халык эшенә хезмәт итсен өчен тагын да тырышыбрак иҗат итәчәкләр.

Татарстан язучыларының унынчы съезды агымдагы әдәби процесска күп яклы анализ ясады, республика әдәбиятының барлык жанрлары һәм төрләре торышын тикшерде.

Съездда проза өлкәсендәге сизелерлек уңышлар билгеләп үтелде. Прозаиклар җәмгыятебез тормышын- тарихи дөрес һәм халыкчан итеп, әдәбиятның иң алдынгы методы булган социалистик реализм ысулына таянып чагылдыралар. Совет кешеләренең героик эшләрен, бөтенхалык көрәшенең масштаблылыгын сурәтләүче, җәмгыятебез үсешен тоткарлаучы күренешләргә каршы гражданнарыбызның актив социаль көрәшен тасвирлаучы язучыларның иҗаты аеруча хуплауга лаек. Аларның әсәрләрендә совет кешеләренә хас булган тойгылар — дөнья язмышы өчен борчылу һәм патриот-интернационалист сыйфатлары калку чагыла. Нык үскән социалистик җәмгыятьнең типик характерларын сурәтләү — республика әдипләренең төп иҗат юнәлеше.

Шул ук вакытта Татарстан язучыларының унынчы съезды бүгенге татар әдәбиятының алга таба үсешенә комачаулаучы кимчелекләрне авбулуын да билгеләп үтә. Кайбер төссез һәм тәэсирсез әсәрләрнең ав-

торлары тема актуальлеге артына яшеренәләр. Көнкүреш ваклыклары белән мавыгу һәм геройның артык зур әһәмияткә ия булмаган кичерешләреннән уза алмау күренешләре дә күзәтелә.

Съездда татар поэзиясенең күп яклы үсеше хакында сүз барды, тормышны киң чагылдыручы, лирик һәм публицистик дәрткә ия булган поэма жанрындагы уңай үзгәрешләр хакында әйтелде. Ләкин, шул ук вакытта, съезд поэзия үсешендәге кыенлыкларга да күрсәтте. Бу барыннан да элек — кайбер лирик шагыйрьләребез әсәрләрендә гражданлык яңгырашы кими төшү, ул шигырьләрнең тынычкүзәтүчән характерда була барулары. Шагыйрьләр заманыбызның актуаль әһәмияткә ия иҗтимагый темаларына, республикабыз халкын гына түгел, ә бәлки бөтен планета кешеләрен борчыган вакыйгаларга ешрак мөрәҗәгать итәргә бурычлылар.

Съездда республикабыз драматургларының уңышлары аеруча билгеләп үтелде. Аларның әсәрләре илебезнең күп кенә театрларында, шул исәптән Мәскәүдә дә бара. Театрларда да, телевизор экраннарында да, радиоспектакльләрдә дә ул әсәрләр заманның җитди проблемаларын күтәреп чыгалар, әхлакый-психологик һәм тарихи-революцион мәсьәләләргә мөрәҗәгать итәләр. Ләкин әле биредә дә кайбер драматурглар зур иҗтимагый әһәмияткә ия булган мәсьәләләрдән китеп, көнкүрешнең вак мәшәкатьләренә күмеләләр. Тормышның күп проблемалары әле тирән сәнгатьчә үзләштерүне көтеп тора.

Балалар һәм яшүсмерләр өчен булган әдәбиятның уңышларын съезд аеруча билгеләп үтә. Бу өлкәдә татар әдәбияты бәхәссез уңышларга иреште, иң яхшы үрнәкләре белән дөнья аренасына чыкты. Ләкин, әле күптән түгел генә кабул ителгән мәктәп реформасы уңаеннан, балалар язучылары алдына яңа һәм җитди бурычлар килеп баса.

Публицист язучыларның гомум әдәбият файдасына керткән өлешен югары билгеләп үткән хәлдә, съезд аларга тормышка активрак катнашу буенча эш формаларын һәм чараларны тагын да камилләштерү кирәклеген дә күрсәтә.

Әдәби процессны үстерүнең иң мөһим шартларыннан берсе булып әдәби тәнкыйтьне һәм әдәбият белемен тагын да камилләштерү тора. Соңгы елларда республикада әдәби тәнкыйтьнең абруе үсүен, аның активлыгы артуын, эше нәтиҗәлерәк була баруын съезд канәгатьлек белән билгеләп үтә. Киләчәктә безнең әдәби тәнкыйть һәм әдәбият белеме иҗат процессын тулырак колачларга, аның катлаулы һәм күпьяклы яшәешенә тирәнрәк үтеп керергә, әдәбият үсешенә юнәлешлерәк итеп тәэсир ясарга тиеш.

Тәҗрибәле тәрҗемәчеләрнең зур отряды тырышлыгы аркасында дөнья, рус һәм совет әдәбиятының күренекле әсәрләре татарчага тәрҗемә ителүне съезд уңай яктан билгеләп үтә. Ләкин татарчадан русчага булган тәрҗемәләрнең сыйфаты элеккечә үк һаман яхшыртуга мохтаҗ. Билгеле, русчага тәрҗемәләрнең саны да, сыйфаты да шактый үсте. Ләкин вакыт шулай ук зур таләпләр куя. Тәрҗемә эше бик зур эш, әнә шуңа күрә аңа иң зур игътибарны бирергә кирәк.

Ике съезд арасындагы чорда яшь алмаш белән эшләүгә аерым игътибар бирелде. Бу юнәлештә республикада зур эшләр башкарылуын съезд билгеләп үтә. Яшь язучыларның иҗатын үстерү өчен уңай шартлар тудырылган. Киләчәктә дә иҗат яшьләре белән эшләү көн тәртибеннән төшмәскә тиеш, яшьләрнең иҗтимагый активлыгын һәм әдәби осталыгын күтәрү мәсьәләсе игътибар сорый.

Халыкара мәйданда идеологик көрәшнең нык кискенләшүе уңае белән Татарстан язучыларының унынчы съезды республиканың барлык әдипләрен империалистик пропагандага отпор бирергә, безнең

коммунистик төзелешебезгә комачауларга тырышучы дошманнарны үткен һәм образлы сүз ярдәмендә оста фаш итәргә чакыра.

Татарстан язучыларының унынчы съезды карар бирә:

1. Отчет чорында Татарстан Язучылар союзы идарәсенең эшчәнлеген хупларга. Идарәнең эшен канәгатьләнерлек дип табарга.

2. Татарстан Язучылары союзы идарәсенә, республиканың язучылар оешмаларына КПССның XXVI съезды һәм партиянең аннан соңгы пленумнары карарлары яктылыгында, әдәбиятның партиялелеге һәм халыкчанлыгы нормалары буенча эш итәргә кушарга.

3. Татарстан Язучылар союзы идарәсенә съездда куелган мәсьәләләрне, тәнкыйть фикерләрен һәм тәкъдимнәрне ныклап өйрәнергә һәм язучыларның иҗат эшчәнлеген тагын да активлаштыру, әдәбият үсешенең тенденцияләрен анализлауны тирәнәйтү йөзеннән аларны тормышка ашыру планын төзергә.

4. Съезд прозаикларны, шагыйрьләрне, драматургларны, тәнкыйтьчеләрне — барлык язучыларны — үзләренең идея-теоретик дәрәҗәсен һәм осталыгын күтәрү буенча нык эшләргә чакыра. Әнә шул нигездә генә совет кешеләрен идея-политик, әхлакый һәм эстетик яктан уңышлы тәрбияли алырлык, аларны коммунистик төзелешнең олы планнарын үтәүгә туплардай яңа һәм зур әсәрләр туа ала.

# ИСТӘЛЕКЛЕ МИЗГЕЛ

«М. И. Калинин Татарстан крестьяннары янында кунакта»... Әлеге картинага караш ташлау белән үк республикабызның утызынчы еллардагы тормышы күз алдына килә. Колхозчы-ударникларның I съездына «Бөтенсоюз старостасы» М. И. Калинин да чакырыла. Әсәрдә менә шушы тарихи вакыйганың бер мизгеле гәүдәләндерелгән. Ә гомумән, Михаил Иванович Казанда берничә тапкыр була: 1900 елда — беренче сөрген урынына үтеп барышлый, 1919 елда — В. И. Ленин тарафыннан оештырылган «Октябрь революциясе» агитацион-инструкторлык поездында һәм 1933 елда Татарстан крестьяннары чакыруы буенча килә. Соңгы килүендә ул Казан һәм Арча кантоннарындагы «Память Ленина» һәм «Авангард» колхозларында авыл хезмәтчәннәре белән очраша, колхозчыларның тормыш-көнкүреше белән якыннан таныша.

...Гадәти татар өе. Һәр тарафтан яктылык, җылылык һәм пөхтәлек сирпелеп тора. Түрдәге өстәлгә бәйрәмчә ашъяулык җәелгән. Шулай ук өйдәгеләр дә сабан туендагыча киенгән. Бусагадан хөрмәтле зур кунак атлап кергәнлеге әллә кайдан ук күренеп тора. Картина геройларының түгәрәкләнеп әңгәмәләшүе сөйләнелә торган сүзләрнең җитди һәм шул ук вакытта ихлас булуын искәртә шикелле. Тәрәзәләрдән сирпелеп кергән кояш нурлары кешеләрне яктылыкка чыгарган Октябрь таңына символик ишарә буларак аңлашыла.

ТАССРның халык, РСФСРның атказанган рәссамы В. И. Кудельк инның профессиональ осталыгы әлеге картинада аеруча тулы чагыла. Ә мондый камиллек дәрәҗәсенә ул катлаулы тормыш һәм иҗат юллары аша күтәрелде. Гражданнар сугышы елларына туры килгән балачак, Чабаксар художество училищесында һәм Мәскәү художество институтында белем алу, Бөек Ватан сугышы фронтлары, Казан художество училищесында укытучылык һәм директорлык эшчәнлеге... Рәссамның актив иҗтимагый позициясе кызыклы натура эзләүдә генә күренми, ә аның тормыш үзәгенә омтылуы; бүгенге замандагы яңарышларны иҗат итү эшенә үзеннән өлеш кертүе белән билгеләнә. Үзенең геройларын ул хезмәт фронтының алгы сызыгында баручылар арасыннан эзли. Менә «Сәлахов һәм Новицкий портреты», «Электросварщик Любовь Шевцова», «КамАЗ хатын-кызлары», «Никольский авылы сыер савучылары», «Дан орденының тулы кавалеры Н. И. Зотов», әнә татар язучылары Н. Исәнбәт, Ә. Еники, Д. Вәлиев портретлары... Замандашларыбызның әлеге образлары үзләре турында үзләре сөйлиләр. Һәм әлеге әсәрләрдә туктаусыз үсеш юлыннан баручы тынгысыз җанлы рәссам, портрет һәм тематик картиналар остасы Виктор Иванович Кудельк инның үз йөзе дә бөтен тулылыгы белән чагыла.

**Диләрә САДЫЙКОВА,**
Татарстан сынлы сәнгать музееның фәнни хезмәткәре.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** СССРның халык артисты, РСФСРның һәм ТАССРның Дәүләт премияләре лауреаты, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры Марсель Сәлимҗанов.

Рөстәм **МАНСУРОВ** фотолары.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



**КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)**

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА [illegible] И
[illegible]